# КАЗАН УТЛАРЫ

11.1995



## Хөрмәтле укучыларыбыз!

**«Казан утлары» журналы 1996 елда сезнең игътибарга байтак кына кызыклы әсәрләр һәм язмалар тәкъдим итәргә җыена. Менә шулардан кайберләре:**

Тәлгат Галиуллин. «Тәүбә». *Бүгенге көннәр романы.*
Габдулла Шәрәфи. «Тормыш арбасы». *Повесть.*
Зәки Зәйнуллин. «Ат каракларын». *Повесть.*
Фәүзия Бәйрәмова. «Атылган йолдыз». *Пьеса.*
Фәрит Яхин. Мөхәммәт пәйгамбәр турында кыйсса. II китап.
Рабит Батулла. Мин Американы ачтым. *Сәяхәтнамә.*
Әнәс Галиев. «Хыял диңгезе». *Роман.*
Ләлә Гыймадиева. Әтием истәлекләре.
Гурий Тавлин. «Һәлакәт». *Роман.*
Сәйфи Кудаш. Дәрдемәнд турында истәлекләр.
Ибраһим Салахов. «Кайбер хатирәләр».

Булат Солтанбәков. Татар зыялыларыннан Ф. Кәрими, А. Шәехгали, Алкиннар, Сталинның сәркатибе булып эшләгән М. Бурундуков турында тарихи-документаль язмалар.

Шулай ук танылган галимнәребез һәм публицистлардан Әбрар Кәримуллин, Индус Таһиров, Миркасыйм Госманов, Рафаэль Мостафин, Миргазиян Юныс, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Тәүфикъ Әйди һ. б. үзләренең яңа язмаларын тәкъдим итәчәкләр.

Тукай, Фатих Әмирхан һәм Мәхмүт Галәүнең тууына 110 ел, Муса Җәлилнең тууына 90 еллык уңаеннан да кызыклы язмалар белән танышырсыз.

Шагыйрьләребездән Гамил Афзал, Нажар Нәҗми (Уфа), Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Флера Гыйззәтуллина, Клара Булатова, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Харрас Әюпов, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Рашат Низамиев, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Илдус Гыйләҗев, Фәрит Габдерәхим, Халисә Мөдәррисова (Башкортстан) һ. б. үзләренең яңа шигъри шәлкемнәрен тәкъдим итәләр.

**Әйдәгез, алга таба да дуслар, фикердәшләр булыйк. Кыскасы, журнал битләрендә сезне киләсе елда да кызыклы сәхифәләр көтә.**
**Язылыгыз! Укыгыз! Гел бергә булыйк!**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**(877)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. ГАТАШ. Кышкы робагыйлар ........ 3
Ф. ЯХИН. Август ае. *Роман* ........ 10
С. ГӘРӘЕВА. Өмет. *Шигырьләр* ........ 64
Н. ӘХМӘДИЕВ. Үз бәхетем. *Шигырьләр* .. 70
Р. ФӘИЗОВ. Ак каз. *Повесть* ........ 74
Р. КӘРАМИ. Авылдаш. *Хикәя* ........ 107
Р. ШИҺАП. Килер дәвергә сүзем. *Шигырьләр* ........ 115
Х. ИБРАҺИМ. Әүвәл миннән шалаш сорадың. *Шигырьләр* ........ 118

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Ш. ӘХМӘДУЛЛА. Тарихи дөреслекне кайтарыйк ........ 120

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 75 ЯШЬ

Яшьме, картмы? *(Журналның баш мөхәррире Р. Мостафин белән әңгәмә)* ........ 127

ПУБЛИЦИСТИКА

М. МУЛЛАНУРОВ. Тылсымлы кеше ........ 129

ӘДӘБИ МИРАС

С. МАКСУДИ. Англиягә сәяхәт ........ 149

СӘНГАТЬ

Н. ГАМБӘР. Кояшлы тауга күтәрелү ........ 186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 191

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,
бухгалтерия — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: продолжение романа Ф. ЯХИНА «Месяц август»; повесть Р. ФАИЗОВА «Белый гусь»; рассказ Р. КАРАМИ «Односельчанин»; стихи Р. ГАТАУЛЛИНА, С. ГАРАЕВОЙ, Н. АХМАДИЕВА, Р. ШИГАПОВА, Х. ИБРАГИМОВА.
«Острая проблема»: статья Ш. АХМАДУЛЛЫ «Вернем же историческую правду...»
«К 75-летию журнала «Татарстан»: интервью с главным редактором журнала Р. Мустафиным.
«Публицистика»: статья М. МУЛЛАНУРОВА «Волшебный человек».
«Литературное наследие»: статья С. МАКСУДИ «Путешествие в Англию».
«Искусство»: статья Н. Гамбарова «Возвышение на солнечную гору».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сайф Сараи» — картина художника Ф. Фасхутдинова; известный писатель Т. Айди.

## IN OUR ISSUE

«Prose and poetry»: the sequel of Ph. Yakhin's novel «The month of august»; R. Phaizov's narrative «A white goose»; R. Karami's story «Fellow-villager»; the verses of R. Gataullin, S. Garaeva, N. Akhmadiev, R. Shigapov, Kh. Ibragimov.
«Sharp problem»; Sh. Akhmadulla's article «Let's return the aistorical truth».
«To the 75 th anniversary of the Journal «Tatarstan»: an interview with an editor-in-chief of the journal R. Mustaphin.
«Publicism»: M. Mullanurov's article «Magic man».
«Literary heritage»: S. Maksudi's article «The travel trough England».
«Art»: N. Ga barov's article «An ascent of the sun mountain».
«The Diary of the Social and Cultural Life».

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Марсель Гали, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.**

*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 4.10.95 ел. Басарга кул куелды 15.11.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 7916. Заказ Д-500.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

# ШИГЪРИЯТ



**Рәдиф Гаташ**

## КЫШКЫ РОБАГЫЙЛАР

* * *

Килгән иде сиңа кем? Җәбраилмы?—
Хәбәрчесе булдымы Җәбраныңның:[1]
Мин дә тойдым ул шагыйрьдә — балкышын
Ходай дусты пәйгамбәрләр җанының!

* * *

«Милли, нечкә сурәтле газәл-җырлар
Кәрваның бар, кайчан ул сәфәр чыгар?
Гүя,— дисең,— ай нурында дөяләр...
Килә һаман моң-сахрадан юлчылар!»

* * *

Шигырь белән бирсәң иде җавапны!—
Булса да ул миңа авыр, газаплы...—
Яз алдаусыз! Ак кәгазь бит — гөнаһсыз,
Аның алдында без — тигез җаваплы...

* * *

Юктыр хәзер җанда, уйда башкалык,
Янып-көйдек бергә, уттан качмадык...
Әй сынады бу ел: гамь тәгамен без
Яшебезгә манып байтак ашадык!

---

[1] Х. Җәбран — егерменче йөзнең бөек гарәп (Ливан) шагыйре-философы.

* * *

Бәлки, Гаташка хисең дә юк түгел
(Булса да ул — инеш, ташкын ук түгел...),
Күңел диваным[1] — тиңсез җыр, беләм мин,
Тик... борынгы: сиңа ул кызык түгел!

* * *

Әле бәхәс «гарше-күк» тирәсендә,
Бөекләргә инкяр сүзләре синдә...
Аямыйсың берсен! «Гөнаһлы җир»гә —
Миңа чират, бәлки иртәгәсендә?!

* * *

Таудан аска төшеп барган юлымда
Очрадың да, җанны әсир кылдың да,—
Тагын юлым тауга менә... Күрегез:
Күпме яңа гөлләр инде кулымда!

* * *

Күктән аерылмас булды бу күзләрем!—
Анда сине күргәннән соң үзгәрдем:
Айда булдым — уйда, күпме йолдызда —
Көндез дә күренә тәпи эзләрең!

* * *

Бер пишкадәм мин — яшәү мәктәбендә,
Бел, мин — надан... тормыш гыйлеме — синдә!
Ә Хыял һәм Хис бабында мин — остаз,
Шикләнми ал мисалга — фән эшендә!

* * *

Тик мәчеңә синең назларың, ярым,
Аһ, шулай миңа кагылса кулларың!—
Йә җанымны сыйпаса җылы сүзең!
Шуны көтеп җырымда — «мияу»ларым!!!

* * *

Мин дигәнчә түгел, дөнья, агышың!
Җәтмәңдә, хыял, алтын... тик сагышың!
Ихлас йөрәккә лаек өлешме бу?!—
Мирас булыр кемгә фәкыйрь «табыш»ым?

[1] Диван — шигырь китабы.

* * *

Йөз дустан да газиз күргән бер дустым
Дәрәҗәгә менде,— бәхетле булсын!
Тик аның каршында — мин төштем ник?
Аңлый алмыйм бусын,— хәерле булсын!

* * *

«Мисле миңле лалә — төрки гүзәлләр!»—
Мең ел! шулай сөйли фарси газәлләр!
...Ирнеңдә миң мактау көтә синең дә,
Нәслең — Туран иленнәнме әллә, яр?!

* * *

Робагый! дип күңел куйдым быел мин.
Дүрт юл кысасында булдым быел мин.
Чит күрмәс дим Иранның иркә гөле!—
Рухына күп дога кылдым быел мин!

* * *

Шираздданмы китерә җилләр исеп
Сәгъдиләрдән мирас ул гөлләр исен?
Каян белгәннәр фарсылар безне, Яр?!—
Хуплыйлар, күр, ничек бу хисләр хисен!

* * *

«Ирәм багы»нда йөрдем мин хыялда,
Лалә касәсе — хис тулы пыяла!—
Күпме эчтем аны, ахырын уйламый,—
Шуны сузып торам, имеш, сиңа да...

* * *

Искә ал бер! Түгел, «борын заман»да,
Күп «шәй»ләре җайсыз, кырын Казанда
Без бәхетле булдык бер ел!— бер көнең
Гасырга тиң, шактый кыргый заманда!

* * *

«Дөнья — чиксез дәрья, тормыш — корабль,
Батмас өчен тугры дуслар таба бел!»—
Көне буе шул җыр ник пароходта?!
Ярага тоз сипсә кемдер — харап ул!

* * *

Каютамы? Гөл оҗмахы бар бүлмә...
Сөйгән җаннарга гел иркен — тар бүлмә.
Арабызда диңгез! — дип, ник карашың
Кисәтә: — Бел, батасың... Кырә күрмә!

* * *

Без табынган шәркый, төрки шагыйрьләр
Бу мәлдә, мөгаен, сине әрлиләр:
— Рәнҗеттең энебез җанын... Болай да
Ярасы төзәлмәс иде... җәл, — диләр.

* * *

Табынуым озаккамы сузылыр?
Әле бездә уены һәм чыны бер...
Әле син таҗ-тәхетле төштә кебек,
Аh, бер мәлдә уянсаң, кыен булыр!

* * *

Пышылдап әйттем тик — ил ишетте.
Сиңа хисне, хуплап, дөнья иш итте...
Күкләр кабул итмәгән салкын сүзең
Мине түгел, җирне бугай өшетте!

* * *

«Булмады шул, дисең, үз Рәмием минем!»
Шулай аңлыйм бу «милли гам»ең синең:
«Рәми» — булса ук атучы, гашыйк яр,
Уклар үтмәс чын калкан — җаның, димен.

* * *

Бар дөньяга шәрран-яра бу хисләр
Кисәме сезнең тынлыкны, күл-күзләр?
Камыш-керфекләр ник ярсып тирбәлә?
Шик белдерә әллә безләргә — Сезләр?!

* * *

Алтынсу бөҗра ураткан Ай күргәч,
Йөзен сагыш сарган гашыйктай күргәч,
Аман! — дип син аңа әйтә белдеңме? —
Һәм миңа — шул мәлдә искә төшергәч?!

* * *

Табарсыңмы Арча томаннарында
Югалтканны Казан бураннарында?
Бәлки, эзлисең үзеңне? Мине дә
Тапмассыңмы — шул моң урамнарында?

* * *

Кайда ярларың — тезеңә баш куйган,
Яшь койган — гөл храмыңа табынган?
...Храм-кәлисәң дә шул ук... кайда алар? —
«Башка дингә күчте» мәллә ахырдан?!

* * *

Сине сөйгән һәм син яратканга — сүз
Әйтмәскә ант бирдем — калыйм имансыз!
Сиңа — ни дим? Гашыйкларыңны жәллим:
«Азат җаннар! Сез дә коллар булгансыз!»

* * *

Укучым! дип дәштем озак... «Кариэм!» —
Дип тә искечә бер әйтеп карыем?..
Ник җавап юк? Тавышым зәгыйфь, бәлки?
Ә бит — ишеттергән Тукай абыең!

* * *

Юл башында чын дус, сердәш идек без:
Хыял — уртак, ә тапканнар — гел тигез...
Мал-дәрәҗәме аерды? Ник әле
Ихласлыктан — шигырьдән сез киттегез?!

* * *

Кем ул җырлый? — «Карурманда атларым...»
Белгән каян — канатлы, шәп чакларым
Урманында мине егып калдырган
Алтын-җирән, ялкын ялы ат барын?

* * *

Хискә ул чак — Акыл әле ят булмыш,
Бар дөньяны кочам! дигән чак булмыш.
Киңәйдеме дөнья — җитми колачым,
Акыл, белдем: синең сүз дә — хак булмыш!

* * *

«Ә ник томан каплаган Йолдыз-тауны?»—
Пир Солтан[1] бит гел кабатлаган аны!—
...Төрки дөньяда матурлык — яшерен сер.
Күтимме, яр, шул томан таралганны?!

* * *

Ирешсен сиңа җырларым!— пакь яшем...
Ә битараф калсаң? Гел куркып яшим...
Илһамчым — син... Язганым «тетсә» бирәү,
Сөенерсеңме? Йә — йолкырсыңмы чәчен?!

* * *

Әйттеләр:— Кем... Улмы сине яндырды?
Оныгың булырдай бала — ярыңмы?
Дидем:— Килә киләчәктә яшисем,
Шуңа бирәм яшь кулларга җанымны!

* * *

Һаман җанны борчып тора уем — бер:
(Олыгайгач, уй да ахры кыендыр...)
Булмабызмы без дә — картая белмәс,
Олпат булмас, нәфсен тыймас буын бер?!

* * *

Моңнарым бар... әмма шатлык бирүче
Булса иде җырым — сөендерүче:
Мәхәлләгә яңа кием кидереп,
Үзе искегә дә шат бер тегүче!

* * *

Ялкында булып бер, янып-чыныккан
Курыкмый ул башкача инде уттан...
Бүген яндырган ут — сиңа хисем ул!—
Су сибеп тик сүндерүеңнән куркам.

* * *

Ахыргача сине аңлау кирәкме?
Юк, мин алай өйрәтмәдем йөрәкне!
Чынлык — шикле... Аннан өстен күрик без
Үзебез тудырган хыял-сурәтне!

---

[1] Урта гасыр төрек шагыйре.

* * *

Сизәм: күңелдә урыныңны зур иттем!
Җирән чәчне, күр — илаһи нур иттем!
— Лаек түгел мин моңа...— дигәнең юк,
Мактый торгач, ахры, нык горур иттем?!.

* * *

Мин дә мәшһүр гашыйк — Җирдә, янәсе:
Беләләр, дип йөрдем илдә һәммәсе...
Исмем дә ишетмәгәнсең!— шаккаттым:
Менә шул, дим, «дан тиз узу» бәласе!

* * *

Утыз ел!— аһ, бушка узган шигырьдә —
Мине син белмәгән вәйран гомердә!
Языйм тагын утыз ел!— насыйп булсын
Хәйран итәргә — жаныңа керергә!

* * *

Яшьлек! Сиңа кайталмасак тагын без,
«Хис давылы»н картлыкка да алырбыз,
Көндез кызларга сүз кушып, әгәр кич
Җил чыкмаса, күзләргә дә барырбыз!

* * *

Син булганда янсам да ләззәт-утта,
Никтер, аңлыйм моны синсез минутта...
Бергә чакта хис кыза, болыты юк,
Җыр яңгырым да коя, күр — син юкта...

* * *

«Белсәң,— дисең,— минем ни уйлаганым!—
Күк белән Җир арасын буйлаганым...
Бер Газазил — жаным... Юк, сөймәс идең
Син дә хәтта, сизсәң: кай дөньядан мин?!»

* * *

Хатларың башлана иде:— Шагыйрем!..
Бу эндәшне хәзер кайда калдырдың?
Шигең бармы әллә «даһилыгыма»...
Шигырь кадере дә юк илдә, кадерлем!

*1994—1995*



**Фәрит Яхин**

# АВГУСТ АЕ

РОМАН

## 13

Бүген Казансу буена төшеп, көне буена арка кыздырып ятарга ниятләгән Ханбал, тиз-тиз генә иртәнге чәен эчәргә дә, чыгып китәргә уйлады. Ул арада чәйнеге пар бөркергә тотынды. Йомырка тәбәсе дә пешеп чыкты. Аны калын телем итеп киселгән икмәгенә ягып, егет чәйгә утырды һәм радиосын кабызды. Аннан әллә ни игътибарга лаек булмаган көй тапшыралар иде. Ханбал аңа да артык әһәмият бирмәде, сүндерергә дип үрелде, әмма җитешә алмады, кыңгырау шалтырады. Барып ачса, Федор абый калтыранып басып тора иде. Кулында бер бит кәгазе дә дер-дер килә, бабай әйтәсе сүзен белдерә алмый газаплана.

— Исәнмесез, Федя абый! Ни булды?

— Ми-минем Марфам авырып китте. Кичә кич ишек төбенә төшеп утырдым, кире керсәм, яткан. Авырый башлаган... Аргандыр дип уйладым. Ә ул — авырган. Бүген әйтә, үлемем килә, балаларымны чакырт, ди. Ә мин аңа, иртәрәк әле, туйганчы яшәмәдек, дим. Ә ул: «Аллабыз изге Христосны ачуландырма!— ди.— Гомергә миңа каршы булдың, инде хәзер киреләнмә!»— ди. Ә мин: «Ничек сине ялгызың калдырыйм, бәхилләшми китсәң, үземне гафу итмәм!»— дидем. «Юк,— ди,— балаларымны күрмичә китмим әле, аларны сагындым, әйтәсе сүзләрем дә бар. Берәр кешене булса да җибәр!»— ди. Кеше сүзен кем аңлый да, кем тыңлый инде хәзер, йә? Ә Марфам әйтә, сине җибәр, ди. Белә бит ул, тыңларсың дип уйлый... «Бар, шуннан үтен!»— ди. Менә мин сиңа төштем әле. Телеграмма сугарга иде, адреслары да кулымда!

Ханбал аптырап китте. Үз гомереңдә күп булса биш-алты тапкыр күренеп калган әллә нинди ят әби аңа ышансын инде, тыңламыйча да ярамас!

— Хәзер... Андый эшне без хәзер!

Аягындагы чүәген җиңел кроссовкага алмаштырды да, ишеген бер йозакка гына бикләп, адреслар күчереп язылган кәгазьне түш кесәсенә тыкты.

— Менә акча, түләргә кирәк булыр!

---

Ахыры. Башы 10 нчы санда.

Федор абыйсы калтыранып-калтыранып акча янчыгын ачарга маташканда Ханбал:

— Миндә бар, борчылмагыз! Барысын да эшләрмен, тынычланыгыз! Кайтып әйтермен! — диде.

— Рәхмәт ирешсен, сәламәтлек бирсен... Дай бог!..[1]

Аның «бог» дигәненнән Ханбалның арка тамырлары чымырдап куйды. Ул әле Аллаһы тәгалә белән бог икесе дә бер нәрсә икәнлеген белми иде, бәлки аларның, урысларның, аллалары Иисус Христос дип йөри иде. Үлем хәбәрен, берәрсенең вафатын ишетсә, әллә нинди уйлар били башлый инде адәм баласын!

Беренче телеграммасын Ханбал Санкт-Петербург каласына, Константин Зайцев исеменә сукты, икенчесен Яр Чаллы шәһәренә, Регина Әмирова исеменә җибәрде. Икесенә дә бертөрле текст төзеде:

«Әниегез кинәт авырып китү сәбәпле тиз арада килеп җитегез! Күршегез Ханбал».

Телеграммаларны кабул итеп утыручы кыз, язылганны укып чыккач, бер егеткә, бер өстәленә карап-карап куйды. Нәрсә сорарга теләгәнлеген аңлатып, Ханбал белдерергә ашыкты:

— Ул әби карты белән ялгызы гына тора, хәле бик авыр, үләргә дә мөмкин...

— Сәлам, Натали!

Ханбал артка чигенергә мәҗбүр иде. Гәүдәгә таш кыя төсле, тупас егет аны кулы белән генә читкә этәрде, алай да үз урынын бирергә теләмичә, аңа күкрәк белән килмәкче иде, теге терсәген генә куйды.

— Олак әле, мужик... Күрмисеңме, кешеләр сөйләшә монда!

Арты белән килеп, Ханбал кемнедер таптап китә язды. Аяк астына эләккән бер әби чинап җибәрде. Кайчан килеп баскандыр. Бер дә кешекара юк төсле иде...

— Натали, бүген көн ничек булды? Мин барысын да беләм. Ханура... ахмак...

Кыз башын түбән иде, битенә кызыллык йөгерде. Әмма Ташкыя бер дә сүздән туктала торган кеше түгел икән. Аны һаман изә һәм кимсетә торды.

— Ярар инде, теләсә ни сөйләмә, кеше алдында,— дип үтенде кыз.

Ташкыя йөзен җимереп кенә Ханбаллар ягына карап алды, сез монда нишләп торасыз әле, сызыгыз, дигән төсле күзләре белән сөзеп үтте, Натали ягына борылды һәм, эчкә чумарга әзер булган шикелле, бөтен тәрәзәне каплап, сүзен дәвам итте. Авызындагы чәер-сагызы һәм калынтупас тавышы аның нәрсә әйткәннәрен йомып кала сыман иде.

— Минем белән буласыңмы, шунда сөйләмәм, Натали... Күптән сине телим. Миңа эләксәң, кешегә бирмим... Мине беләсең...

Кызга, ризалык биреп, аннан котылырга гына, югыйсә, юк, теләми иде, ахрысы.

Ул кәгазьләр актарган кебек кыланып карады, сүзне икенчегә борырга маташты, әмма берсе дә барып чыкмады. Ташкыя аңа оятсыз рәвештә карап торуын дәвам итте һәм таләбен кабатлады. Кыз баш тартты.

— Ах, син, пад... Натали! — Яңа гына кызып киткән Ташкыя, үз максатына ирешү өчен кабат тавышын йомшартырга ашыкты: — Натали! Ә миндә бер әйбер бар, Ханурада оныткансың! Кызыл чәчәкле... Беләсеңме?

Кыз, тирә-ягындагы кешеләрдән шикләнеп, уңга-сулга карады. Ханбал, аларның сүзләренә колак салмаган кеше шикелле, залга күз текәде. Кирәкләре бар иде.

— Нигә коелып төштең? Күрсәтергәме? Анда көне дә язылган!

Ташкыя кәефле генә елмайган хәлдә кесәсеннән пакетка төрелгән әйбер сөйрәп чыгарды, аннан нәрсәдер алырга теләдеме, сорап куйды:

---

[1] Алла кушсын!

— Күрсәтимме?..

Натали дигәне агарды-күгәрде. Әмма ул беркая да бара алмый иде. Хәзер Ташкыя аның йомшак җиргә кия торган киемен тартып чыгарачак, хатын-кызның итәген күтәреп караган чирканчык үсмер кебек, авыз ерачак, хәтта селкеп тә күрсәтәчәк иде.

— Үтенеп сорыйм, кирәкми... Берүк...

Куркынган кызның тагын да өнен алырлык итеп ыржайды Ташкыя, әмма хатын-кыз трусигын селкеп күрсәтергә базмады, таләбен алга чыгарды:

— Минеке булсаң, бу төргәк — синеке! Юкса, исем китми, халык алдында...

Натали җавап бирергә ашыкты:

— Мин — риза...

— Менә монысы — акыллы! Бүген үк! Килеп алам! — Ташкыя ничек килеп керсә, шулай чыгып китте. Тәкъдиренә буйсынган кыз ачу белән Ханбалга карады. Телеграммасына акча сорады. Алыш-биреш беткәч, егет, аның кәефен күтәрү өчен генә:

— Рәхмәт, Наташа! — диде. Кыз күзләрен шардай ачты.

— Сез мине кайдан беләсез?

Ханбал көлеп кенә куйды.

— Беләм инде, бер шәһәрдә яшибез бит!

Туташ карап калды, егет чыгып китте. Юлда: «Беркатлы нәрсәкәй!» — дип кыздан көлеп тә алды.

Федор абый Ханбалны эчкә узарга чакырып карады. Әмма егетнең бер дә теләге юк иде. Әлеге дә баягы фикере аны монда тоткарланудан саклады: көннәр яхшы вакытта сыртны кояшта кыздырып калырга кирәк!

— Туктап тор, акчасын бирим! Күпме?

— Күпме лә түгел, Федор абый, мондый вакытта да үзара ярдәмләшмәсәк, кешеме без?

Федор абзый, нәрсә әйтергә дә белмичә, аптырабрак калды. Ханбал үз фатирына ашыкты. Эчеп бетермәгән чәен чәйләргә дә комлыкка төшәргә кирәк аңа.

Радиодан астрологик хәбәрләр тапшыра иделәр. Ханбал үзенекен көтеп алды. Серле очрашулардан сак булырга киңәш иттеләр аның йолдызлыгындагыларга. «Федор абый белән очрашу хакында сүз баргандыр», — дип нәтиҗә дә чыгарып куйды егет.

Һе-е, дөрес сукалыйлар болар! Акчалар очты. Хәерлегә булсын. Үзләренә дә акчалары юктыр инде. Бу үзгәрешләрнең пенсионерлар өчен бер дә файдасы булмады шул. Ни гомер буе үлемтеккә сакланган акчалары юкка китте, уйлап та бирмиләр мескеннәрне...

Ул шулай үзалдына сөйләнеп куйды. Кайнап чыккан чәен эчәргә кереште. Бу юлысы беркем дә борчылмас инде!

Ишектә тагын кыңгырау чыңлады. Өзек-өзек ике тапкыр чәрелдәп куйгач, Ханбал шунда ук Федорны исенә төшерде: «Әллә Марфа түтәй өзелеп тә киткән микән?»

Барып ишекне ачты. Аптырап китте. Аның каршысында кичә танышып, кич буе сөйләшеп йөргән Альбина басып тора иде. Егет нәрсә әйтергә дә белмәде. «Эчкә дәшәргәме соң моны?» — дип уйлап алды һәм ишекне киңрәк ачты:

— Ба-а, керегез, Альбина ханым! Минем монда торганымны кайдан белдегез? Рәхим итегез!

Альбина эчкә узды. Ул кичәге тәсле юка җәйге плащтан түгел иде. Ефәк кебек сыланып торган нәзек күлмәгеннән, калын чәчләреннән аңкыган затлы хушбуй исе тиз арада бүлмәләргә таралырга өлгерде. Бу диварлар эчендә мөгаен беренче тапкыр аңкыгандыр мондый шифалы чәчәк исләре.

— Исәнмесез!

— Исәнмесез, исәнмесез, Альбина ханым, узыгыз. Менә өстәл янына, чәйгә рәхим итегез, әле генә кайнап чыкты!..

Алар кухняга уздылар. Өстәлдә кабарлык бернәрсә дә юк иде. Альбина көлеп җибәрде. Кулындагы пакетны Ханбалга тоттырды, үзе тәрәзә янына арт белән килеп басты:

— Болар сезгә, күчтәнәч! Чәй янына яхшы булыр! Җимешләрне юып тормасагыз да була, әгәр дә миңа ышансагыз инде, мин аларны әзерләп үк килдем...

Егет нишләргә дә белмичә, оялып кына пакетны ачып карады. Өркенгән кебек булды. Юк, ул мондый нигъмәтләрне кабул итә алмый, гомерендә дә күрмәгән, татып карамаган, ат бәясе тора торган ризыклар түгелме соң болар!

— Нигә туктап калдыгыз? Алыгыз, ал! Үзегез өстәл янына чакырдыгыз, ә үзегез сыйларга да теләмисез!

— Ни бит...

— Берни дә түгел, үз күчтәнәчен ашаган кунак бәхетле вә хөрмәтле була, дип әйтә торган иде безнең әти!

— Алай дисез икән, бик яхшы. Чыннан да, әйдәгез әле, үз күчтәнәчләрегез белән үзегезне сыйлыйм!

Ханбал өстәлгә төрле-төрле җимешләр чыгарып, тимер табакка тезде. Торт куйды, камыр ризыклары, шоколадлар һәм бер шешә Шампан шәрабе. Күчтәнәчләре өстәлгә менеп утыруга, егет Альбинаның колына әверелде дә калды. Хәзер инде үзе Ханбал белән идарә итәргә тиеш һәм шулай эшләгәндә генә аларның мәҗлесләре күңелле үтәчәк! Моны ханым акылы вә күңеле белән аңлап алды.

— Утырышыйк. Шәрабне, кирәк дисәгез, ачсагыз да була!

Егет үзен-үзе белештермичә аңа буйсынды.

Шампан шәрабе шартлап ачылды, әмма күбекләре идәнгә түгелмәде. Затлы әйбер тиз генә бозыламыни. Пыяла фужерларда вак һава бөртекләре кайнады. Танышу хөрмәтенә күтәрелгән беренче йотымнан кыз туктап калса да, егет ахырына кадәр эчеп тә бетерде, артыннан җимеш тә кабып җибәрде. Шунда рәхмәтле йөзе белән балкып Альбинага күз салды.

— Нигә эчмәдегез?.. Ә, шоколадны ачмаганмын икән!..

Ханым елмаеп куйды. Ханбал шоколадларның берсе артыннан икенчесен кәгазьләреннән чыгарып, Альбина алдына тезде...

— Рәхим итегез, ханым-әфәндем! Үз күчтәнәчегез белән... Этегез кайда соң?

Егет як-ягына каранып алды. Үзен болай тотышы сәер һәм кызык иде. Ханым елмая бирде.

— Нигә алып кермәдегез? Урамда калдымы әллә?

— Юк, өйдә... Аның эше — йорт саклау!

— Һәм сезне...

Егет үзенең телгә оста икәнлеген, акыллы баш булуын бер бокал шәраб күтәрүгә күрсәтә дә башлады. Мондый беркатлылар Альбинага ошамый иде. Әмма бу юлысы аңа кызык тоелды. Егет тагын шәраб койды.

— Нигә эчмисез, әллә нәрсәсе юк бит!

Әллә нәрсәсе булмаса да, шәраб томаны егетнең акылын адаштырырга җитә калды. Аннан күзләре пыялаланды, теле ачылып китте. Әмма тиз үзен кулга алырга өлгерде. Альбина да аның айный баруын тойды һәм шикләнгән җиреннән сөенеп куйды: «Бер алкаш икән бу, дип уйлаган идем, ялганган гына икән!» Егетне тәмам үз хәленә кайтып җитәр дип куркыпмы, аңа икенче фужерын күтәрергә тәкъдим итте:

— Монысын фатирыгызның бәхетле килен күрүе өчен эчик!

— Юк-юк, — дип каршы төште Ханбал, — сезнең кебек күркәм хатынның монда хуҗабикә булып килүе өчен!

Альбинага аның бу сүзе дә ошады. Ә нигә? Кызыклы фикер! Җаны теләгән елан итe ашаган. Ә бәлки? Гомер буе карт ир белән тормас бит инде. Андыен күрде, хәзер яшькә барса да була. Әгәр дә шаяртмаса!

— Сез кызык кеше икәнсез! Әмма фикерегез заманча!

«Уйлап карарга булыр!»— дип тә өстәмәкче иде дә, вакытында тыелып калды. Болай да Ханбал ярты өркегән инде. Ханым, беразга тынып утыргач, сүзен борып җибәрде:

— Нәрсә өчен эчәбез була әле? Сезнең өйләнүегез өченме?

— Юк-юк,— дип тагын каршы төште егет.— Сезнең өчен эчәбез! Йортыбызны үзегезнең якты йөзләрегез белән нурландырган өчен! Күтәрдек!..

Ханым килеште. Фужерлар зеңләде. Пыяла тавышы тонык кына аваз белән: «Әйдәгез!»— дидеме, әллә ул сүзне Альбина әйттеме, Ханбал моңа игътибар бирмәде.

Бу юлысы ханым беренче булып фужерны авызына якын китерде, яртысына кадәр эчте. Аның артыннан калышмаган егет су йоткан кебек бушатып та куйды. Авызына тагын җимеш капты.

— Сез нигә бетермисез инде, бигрәк тәмле бит! Эчегез, эч, шампан шәрабеннән берни булмый!

— Эчәм-эчәм, шикләнмәгез!

Альбина ахырына кадәр күтәрмәкче иде, әмма аз-азлап кына капкалап эчәргә күнеккәнлеге сәбәпле, булдыра алмады. Тынып калган мәҗлестәшләрнең уйларын бүлеп, радио сөйли башлады, соңгы хәбәрләр иде. Ханбал, урыныннан кубып, аны бөтенләй сүндереп куйды.

— Бер авыз сүз әйтәләр дә реклама тутыралар...

— Бүген бик яхшы көй тапшырдылар, тыңламадыгызмы?— Альбина, шушы сүзләрен Ханбалга җиткерүгә, иртәнге якта шул музыка астында кичергән хисләрен исенә төшереп, дулкынланып куйды. Аныңча, егет тә шундый ук тойгылар кичергән кебек иде. Әмма ялгышты. Ханбал исә кызның нәрсә хакында әйткәнлеген бөтенләй аңламады. Бераз утыргач, Альбина урыныннан кузгалды да:

— Әйдәгез, фатирыгызны күрик! Нинди яхшы шалаш икән бу?— дип егетнең кузгалуын да көтмәстән, залга үтте. Аның артыннан җитешкән Ханбал ханымның шаяртандай яңа гына әйтеп узган сүзләрен күтәреп алды:

— Гади шалаш кына түгел! Җәннәттәге шалаш бит бу! Высоцкий җырын хәтерлисезме?

Әллә җырлап та җибәрмәкче иде үзе тагын, әмма бу өлкәдә сәләтенең чамалы икәнлеген тиз исенә төшереп, тукталып калды. Ә ханым, киресенчә, аның ул сүзләреннән ләззәт табып, моңлы һәм күркәм тавышы белән:

— «Я согласен на рай в шалаше...»— дип көйләп тә җибәрде.

— Һу-у, сезнең тавышыгыз моңлы икән!..— дигән сүзләрен Ханбал әйтмичә кала калмады. Ә ханым аны тагын да алдый бирде, ымсындырыпмы җибәрергә теләде:

— Тавышым гына түге-е-ел...

— Йөзегез дә, чәчләрегез дә, башка җирләрегез дә...

Алдан килгән ханым кинәт кенә борылды. Алар күзгә-күз очраштылар. Икесенекенә дә ут төшә башлаган иде инде. Ханым, мондый очракта иренең йөргән вакытларында ничек кыланганлыкларын белгән кеше буларак, егетнең күзләрендәге очкынын тәненә дә йөгертерлек рәвештә әйтеп куйды:

— Сезнең дә... Сез дә бик чибәр кеше, Ханбал!

Көтелмәгән сүз үз эшен эшләде. Мескен егетнең колагыннан үтеп, баш миендә дә туктап тормастан, йөрәгенә барып кадалды. Алар, гүяки, аның сөйгән яры тарафыннан әйтелгәннәр дә үзен мәңгегә бөхетле иткәннәр!

— Син дә...

— Син дә!..

Ханым һәм егет бер-берсеннән калышмадылар. Икесенең дә намус вә сафлыктан башка югалтырлык нәрсәләре юк иде. Булса да башларына кереп карамады. Иреннәренең бер-берсенә күрсәткән назы тән теләгенә әверелде. Әмма егет үзен вакытында тыеп калырга өлгерде, читкәрәк борылды. Аның көтмәгәндә кисәк кенә суынуы Альбинаны чыгырыннан чыгарса да, ханым акыллы иде, үз эшен белеп башкарды, ярым пышылдаган тавыш белән Ханбалны сихерләргә тотынды:

— Сез нишләдегез, җан кисәгем? Сез нишләдегез?..

Егет җиңелде. Хатын-кызлар белән шаяруның нәрсә икәнлеген дә төгәл төшенмәгән, дөресрәге, гөнаһы бар дип белгән Ханбал акланырга тотынды:

— Гафу итегез, мин беләм, сез намуслы кеше... Әллә ничек кенә шулай килеп чыкты инде...

Юк, эшне Альбина башлады, ул буйсындырды егетне. Әгәр дә үзеннән көтсәң, дөнья ахырына кадәр дә җөрьәт итә алмас иде. Аның шулай йөзен читкә борып, оялып кына акланулары ханымның сихер тырнагына яхшы ук кабуын дәлилли иделәр. Хәзер әңгәмә башкачарак юнәлеш алса яхшырак. Егет, чыннан да, бу өлкәдә тулы мокыт икән, димәк Альбина үзе аны җитәкләргә тиеш, җәтмәсенә эләктереп кенә калмыйча, йөрәк итен кыздырып ашарга, ни эшләгәнен дә төшенмәс дәрәҗәгә җиткерергә!..

Һәм шулай булды да.

## 14

Ханбал хатын-кыз белән мөнәсәбәттә үтә дә сак кеше иде. Шул сәбәпле бүгенге көненә кадәр өйләнә дә алмады. Аны дуслары теге яки бу кыз белән таныштырып карадылар, әмма егетебез бер дә сер бирмәде. Сөйләштереп тә, ярәштереп тә аптырагач, аны бу мәсьәләдә борчудан туктадылар. Элегрәк, фатирсыз вакытында:

— Нинди өйләнү, ди, ул! Торырга җирең дә булмасын, тулай торакта бәхетле гаилә төзеп, рәхәтләндереп яшәү мөмкинме соң!— дип кырт киссә, инде бу яктан тормышын көйләп җибәргәч, артыгы белән сайлана башлады. Теге кызның монысы ошамады, ул матурның бу җиренә күңеле төшмәде һәм: «Болар минем үземне түгел, фатирымны күзлиләр!»— дигән нәтиҗә чыгарып, буйдак калуны өстенрәк күрә килде. Нинди генә саран һәм ахмак булмасын, үзенә лаеклы кешенең кайчан да бер очраячагына өмет итеп, һәркемнән шәхсән өстен тотты.

Бергә эшләгән иптәшләреннән читләшеп, аларның барысын да үзенә берәр таныш кызларын тагарга маташудан гаепләп, бу мәсьәләдә активлык күрсәтмәгән Хәниф белән генә әшнәлектә иде. Мөгаен аның хатыныннан еш-еш зарланулары, Ханбалны өйләнмәве аркасында бәхетле дип әйтүләре, хатын-кызга кызыгып күз салмаулары икесен берләштергәндер. Шуның белән алар бүтән ирләрдән нык аерылып торалар. Башкалар, мөмкин икән, күзләре төшкән ханым яки кыз артыннан дөньяларын онытып, бозау кебек йөрергә әзерләр һәм бу өлкәдә шактый күп уңышларга ирешеп, ахырда янгалый да иделәр. Әмма барыбер, мең тапкырлар тәүбә итсәләр дә, тавыш-гауга басылуга, тагын берәрсенә мәхәббәт богауларын әзерләп, йөтмә үрергә тотыналар, адашалар, рисвай булалар. Башкача яшәүне күз алларына да китерә алмаганлыклары аркасында Ханбал аларга көлеп карый, тик сиздерергә җөрьәт итми, юкса үзен җир белән тигезләп китәрләр иде, син үзең булдыра алмыйсың, шунлыктан кешедән көнләшәсең, ким икәнеңне сизенәсең, диячәкләрен белмимени ул? Хәнифнең башка кыз-кыркынга күз салмавы хатынының усаллыгы аркасында гына икәнлеген Ханбал белми, ә Хәниф, киресенчә, Ханбалның өйләнмәү сәбәбен саранлыктан дип күзалламый, ниндидер

бер җитешсезлек белән бәйледер дигән фикердә тора. Шунлыктан, бүлекләрендә берәр бәйрәм оештырылып, хезмәттәшләре шактый кыза башлауга, болар икесе дә, гөнаһтан сакланган диндарлар төсле, өстәлне ташлап таю ягын карыйлар. Икенче көнне кичә булган гаҗәп хәлләр бүлмәдән-бүлмәгә тел ярдәмендә күченеп йөри башлый, анысы моннан көлә, монысы — аннан! Ханбал белән Хәнифкә генә тиюче кеше юк. Алар — тыныч, әмма белмиләр һәм төшенмиләр, өлкәннәр боларны аңлый алмый, яшьләр — чүпкә саный. Арада усалрак телләләр: «Әнә, зәңгәрләр!» — дип үзләреннән көлә. Әмма Хәниф моны үз адресына кабул итми, Ханбал зәңгәрлектә гаепләнерлеге булмагач, игътибарсыз гына уздыра. Аны күпләр күңелсез һәм коры шәхес дип белә, әмма хакыйкатьтә Ханбалның эче тулы сагышлы сер икәнлеген күз алларына да китерә алмыйлар.

Адәм балалары, бер-берсенә бәя биргәндә кемнең күңелендә нәрсә бар икәнлеген белмәүләре аркасында, бик тирән ялгышлар ясыйлар. Ахырда үзләренең ничек ялгышканлыкларын күрсәтә, әмма моның белән килешергә теләмиләр. Ахмак дип уйланган кешенең акыллы икәнлеге, наданның галим булуы вакытлар үтү белән ачыклангач, алдан күрүчәнлек сыйфатыннан никадәр мәхрүм яшәгәннәрен кабул итәргә теләмиләр, үз-үзләренә үпкәлисе урында, вакытында ялгыш бәя биргән бәндәне теләсә ничек хурларга тотыналар. Тормыш һәркемнән өстен, заман бар нәрсәне хәл кылучы! Алар туктый һәм туктала белми. Яралардан коткаралар, хәтерне сафландыралар. Әмма аларның бары тик бер нәрсә — адәм баласының күңеленә генә хуҗа була алганнары юк. Ул кузгалды исә, тормыш та, заман да туктала, вакыт артка таба йөгерергә тотына. Күңеле китек кеше тормыш, заман тәэсиреннән тулысынча азат! Мөгаен, шуның өчендер андый кешеләр озын гомерле була. Ханбал да шундый бәндәләр хисабыннан, ахрысы.

— Ханбал, син минем яшьлегем төсле! — Альбина егетнең бит очыннан үпте, анысы иреннәрен сузды, әмма кыз инде арыган, назларга-назланырга артык теләге юк иде, чалкан ятты. — Еракта калган яшьлегем син минем!

«Сәер, — дип уйлады егет, — юкса мин дә нәкъ шул сүзне әйтергә теләгән идем бит. Үпкәләрме-юкмы, дигән булып, кыенсынып маташтым. Аның да шушындый, миңа охшаш егете булды микәнни? Кызык инде бу дөнья! Кабатланырга һәм кабатларга ярата. Ул бит, Альбина, нәкъ Регинаның үзенә охшаган. Калын чәчләре дә, бит очындагы миңе дә, хәтта исе дә! Оятсыз да кеше инде мин, исләренә кадәр хәтеремдә калдырганмын! Охшаш шул алар бер-берсенә, бик охшаш! Әйтәм аны кичә яныннан китә алмадым!»

Ханбалның күңеле кузгалды, серле сагышы менә хәзер бүселеп китәр дә йөзенә чыгар...

— Регина!

— Кем-кем?..

Альбина, сәерсенеп, егеткә карады: «Син инде бу исемне бишенче тапкырыңмы әйтәсең, оныттыңмы әллә? Мин бит Регина түгел!» — димәкче иде дә, артык күпертмәскә ниятләде. Әмма егет, шәрә тәненә тышсыз кызыл юрганын тарта-тарта, сорауга җавап бирергә тотынды:

— Сиңа бик тә охшаган кыз... Дөресрәге, кыз иде, хәзер инде хатындыр. Яр тапкандыр!

— Кызык! Шул кыз аркасында буйдак калдыңмы?

Бер башланган сүзне инде өзеп ташлау мөмкин түгел иде. Альбинага, хатын-кыз буларак, чит кешенең күңел түрендәге сере, әлбәттә, кызыклы, бик кызык иде. Кемнең серенә керәсең, аның күңеленә үтәсең, колың ясыйсың, кимендә дусты сыйфатында йөрисең. Моңа кадәр андый кеше Альбинага кирәк түгел иде, ә хәзер ул мохтаҗлык татый. Сер бүлешер, яшерен очрашуларга дәшәр, эчендәге тышына чыгарып салыр, кадерләр вә хөрмәтләр иптәш кирәк аңа. Ул чит, моңа чаклы күренмәгән, яшьлеге

төсле җылы һәм ягымлы кеше булырга тиеш. Әмма тулысынча үзенә генә калдырырга теләмичә, иреннән көнләшмәүче, аннан аерырга омтылмаучы, башка хатыннарга күз салып, итәк артыннан кумаучы, ягъни бар барлыгы белән үзенә генә, Альбинага гына гомерен багышлаган ир өстенә ир, дөресрәге, бер дә өйләнмәгән чибәр егет кирәк аңа. Ә Ханбалның барлык сыйфатлары нәкъ менә шушы таләпкә туры килә: буе да, төс-биткә матурлыгы да, дәрвишлеге дә, башкасы да! Һәм тиздән ул аннан «Хөсрәү вә Ширин»дәге дивана Фарһадне ясап куячак! Ул бу эшкә тотынды инде, хәзергә бар да уңышлы бара.

— Ә син ул кызны, Регинаны, дим, ярата идеңме соң?

— Ничек дип әйтим,— Ханбал шунда Альбинаны кимсетермен дип уйлап куярга өлгерде.— Бәлки!

— Юк, син дөресен әйт! Миңа хакыйкать кирәк. Ялган болай да дөнья тулы. Безнең арада бары тик дереслек кенә булырга тиеш! Аңлыйсыңмы, матурым!

Егетнең җәһәт кенә качып китәргә маташуын ханым яратмады. Сүз артының дилбегәсен үз кулына алып, аны яңадан дөрес юлга юнәлтеп җибәрергә тырышты. Әмма Ханбал тәртә арасыннан чыгарга өлгергән иде инде, аны кабат кертү кыенрак булачак. Нигә кыен, дияргә. Җае Альбинаның үз кулында бит! Хисләрендә саташтырырга да күңелен генә кузгатырга кирәк!

— Матурым минем!

Альбина егетнең муены буйлап кулын чәч араларына кадәр назлап кына шудырды, икенче ягыннан кайнар иренен тидерде. Ханбалның бөтен тәне буйлап калтырау йөгерде, аяк бармакларында да эсселек тойды. Әмма ул әле ирлек эшенә әзер түгел иде.

— Матурым минем! Ну-ну-ну-ну! Иркәлим әле үзеңне бер!

Егет ханымны үбеп алды. Моны эшләү кирәк булмаган икән. Тәне буйлап йөгергән татлы рәхәтлек шул мизгелдә үк сүнде. Ул яңадан чалкан ятты. Тамагы ачкан кебек тоелды. Өстәлдә калган татлы җимешләр исенә төште.

— Ни булды?

Альбина, сәерсенеп, үпкән җиреннән башын күтәрде. Калын чәчләре Ханбалның күкрәгенә ишелеп төште. Бу рәхәтлекнең дә кадерен белмичә, егет китәргә талпынды.

— Мин хәзер!

— Юк, җибәрмим! Мин — ягуар, хәзер сине ашыйм! Ха-ам-ам!

Киң күкрәкләре һәм озын тырнаклы куллары, беләкләре белән Альбина аны басып торса да, «ашыйм» дигән сүзе тагын да аппетитын кузгатып, Ханбал күтәрелергә ашыкты. Ханым аның тезләренә кадәр иркәли-иркәли шуып төште һәм үпкәләгән төс чыгарды:

— И-и-и-и!..

— Мин хәзер, айн момент! Сюрприз!..

Альбина бераз ятты һәм күлмәгенә сузылды: «Батты бу!» Киенергә генә әзерләнеп торып басуына, Ханбал килеп тә керде. Кулына поднос тоткан, аның өстенә күчтәнәчкә китерелгән һәртөрле тәгамнәрне, шампан шәрабен тезгән.

— Рәхим итегез, кадерле ханым-солтаным!

— Ой-й-й!

Кияргә җыенган күлмәген аяк астына ташлап, Альбина урын өстенә чүгәләде, егет, Кырым ханшаларына хезмәт иткән евнухлар төсле тезләнеп диярлек аның каршысына подносны китереп куйды һәм үзе дә менеп, каршы яктан чүгәләп утырды:

— Мәҗлес дәвам итә!

Аның бу кадәр сөенеп кычкыруы иш янына куш кына иде.

Әгәр дә үзе алып килмәгән булса, егетнең төшенә дә керәсе түгел сары якут төсле, үтә күренмәле диярлек татлы йөземне өзеп, ханым бармак очларында сак кына аны Ханбалның иреннәренә якын китерде.

— Минем кулдан кап әле, матурым...

Егет авызындагысын чәйнәми генә йотып, ханым тәкъдим иткән йөзем җимешен капты. Әмма, бармакларын да тешли күрмим дигәндәй, мөмкин кадәр саклык күрсәтергә тырышты.

Ахмак түгел икәнлеген дәлилләр өчен үзе дә тәлгәштән бер йөземне өзеп, бармак очында гына ханымга таба сузды. Әмма Альбина кабып җибәрергә ашыкмады. Теле белән егетнең бармак очларын иркәләде-кытыклады, иреннәре белән үпте-шаяртты. Бу хәлдән Ханбалның тәне буйлап тагын кан йөгерде, ирлеге үзен сиздереп куйды һәм, онытып, җимешне төшереп җибәрде. Альбина рәхәтләнеп көлде. Әмма бу көлү егетне үртәмәде, бәлки күңеленә наз булып ягылды. Ул тагын кулына йөзем җимеше алды. Өзде, ханымга таба китерә башлады, Альбина элеккечә авызын сузып якынлашты. Шунда Ханбал ялт кына җимешне үз тешләре арасына ыргытты да:

— Алдадым! — дип көлде.

Ханымга аның бу кыланышы ошады. «Уйнарга бу да өйрәнеп килә!» — дип уйлады. Болай үткен булса, Ханбалдан бер дигән затлы сөяркә чыгачак иде. Альбина аны менә шулай акырын-акырын үзенә ияләштерер, өйрәтер, айнырга бер дә ирек бирмәс, саташтырыр, адаштырыр. Аңа тел бистәсе түгел, менә шундый йомшак та, хәйләкәр дә сөяркә кирәк. Тик усал ниятле генә булмасын. Үзенең кем икәнлеген онытмасын. Бәхетенә сөенеп кенә яшәсен һәм Альбинаның үзен дә яшәтсен. Юк, ханымга байлык та, акча да кирәк түгел. Аларның һәммәсе дә анда бар. Ире туендырып тора. Әмма җан рәхәте, тән сихәте өчен аңа Ханбал кирәк. Ул аның хакында беркемгә дә әйтмәс, сере итеп саклар. Һәм кайвакыт, бик зарыктырмыйча гына, көчтәнәчләрен төяп, шушы «куышка» качып килер. Бу фатирны куыш эчендәге җәннәт ясар. Ханбалны Фәрһад-дивана хәленә төшереп, күзен һәм күңелен буар! Ә ул бирешер! Күренеп тора: беркатлы бит! Теләсәң, өстенә чиләкләр элеп су ташы, теләсәң каршыңда тезләнгән кол яса, теләсәң, үп-коч. Ул — синеке һәм бары тик синеке генә булырга тиеш. Башкаларның аңа күз салырга, мәхәббәтләрен аңлатырга, аны кочакларга хаклары юк!

Бу уйлары белән генә түгел, инде ничә еллар эшсез, тыныч һәм мул тормышта яшәве аркасында Альбина чын мәгънәсендә эгоистка әверелеп беткән иде. Аның шулай бозыла башлавын күреп, ире хафага да төшкәләде. Бу кадәр үк үзен генә яратуы, гел дә башкаларны түбәнсетеп, шәхесен һаман саен өстен куюлары аның ачуын китергәннән китерә барды. Шушы бөтен акылларын җуйдырыр хәләткә җиткергән Альбинасы, кайвакыт күзенә албасты кебек күренә башлап, кая кереп качарга да белмәс дәрәҗәләргә җиткәләде. Алга таба да болайга китсә, гаиләләре өстенә һәлакәт ишеләчәк иде. Әмма ул белә: Альбинасыз тора алмаячак. Аның кем кулынадыр калуын, бөтенләйгә аерылып китүен күз алдына да китерә алмый! Шуның өченмени карьерасыннан баш тартты, шуның өченмени балаларын ташлады. Юк, Альбинаны алыштырырлык бүтән һичкемне үз гомерендә башка тапмаячак ул. Бу чал кергән чәчләр, кесә тулы акча, таныш-белеш, бизнес һәм коммерция — барсы да Альбинасы аркасында гына һәм аның өчен генә. Бүген ул аны ташлап китсә, иртәгә Геннадий сузылып ятып үләчәк! Альбина аның тормышы да, бәхете дә, җан шатлыгы да! Тик менә үз-үзен яратуы белән үтерә. Ничекләр генә шул гадәтләреннән аерырга аны?

Бу хакта азмы баш ватты Вәлишин. Әмма тиз генә җавабын таба алмады. Балалары да юк шул ичмасам. Һәм менә беренче тапкыр ул элекке хаталары өчен үкенеп куйды. Әмма соң иде инде. Врачлар аңа ярдәм итә алмаячакларын белдерделәр. Зөфәр Зарипович янына барырга киңәш иттеләр. Әмма Геннадий моны ук эшли алмый иде. Теге вакытта булган сөйләшүне исенә төшерәчәк һәм куып ук чыгармаса да, берәр төрле сүз әйтеп ташлаячак. Белә ул бу картның кем икәнлеген! Үлемсез татар ул, үлемсез! Үз туксаны туксан булган кеше яшь туксанын да үтеп китә әле, күреп торырсыз!

Геннадийның борчылуларына көтмәгәндә җавап табылды. Ул моңа сөенеп бетә алмады, мең рәхмәтләр укыды. Кешедән сорап, адәм аңлатып бирә белмәгән, китаплар актарып, алардан таба алмаган, хәтерен яңартып, аннан бер мисалга очрамаган чишелешне аңа бер хыялый бәндә китереп алдына салды. Башта Вәлишин аның сүзләренә артык игътибар бирмәде. Бүгенге көндә кем генә байдан ярдәм сорап килми дә, теге яки бу эшкә спонсор булырга үтенми. Мескен артистлардан алып хәтта танылган язучыларга кадәр һәммәсе. Академиклары да килә әле. Геннадий аларга аз-маз акча биргәли ансы, ялына белеп ялынсалар. Ә бу хыялыйга шунда ук тоттырып чыгарырдай булды.

— Мин сезгә «Кызыклы очрашулар клубы» ачарга тәкъдим итәр идем,— диде ул бәндә.— Элекке Париж, Лондон, Санкт-Петербургта булганча. Анда, әйтик, гел хатыннар гына, яки эшмәкәр ирләр генә. Бернинди шәрә сөйрәлчекләргә урын юк. Тыныч, иркен, күпме телисең, шулкадәр сый-хөрмәт, музыка һәм... иң кызыгы...— Чәчләре күптән инде коелып, җилкә турында гына калган зур авызлы бу хыялыйның кечкенә күзләре очкынланып китте.— Иң кызыгы шунда, аңлыйсызмы, очрашу, кызыклы очрашу! Астрологлар белән, астрономнар белән, яхшы шагыйрьләр, җырчылар, ягъни иҗат кешеләре белән дә, галимнәр белән дә, чит ил кунаклары белән дә! Яхшы җиһазландырылган иркен бар яки ресторан булса, бигрәк тә әйбәт. Чит илдән килгән эшмәкәрләрне шундый урынга бер тапкыр алып керсәң, кызыклы очрашу үткәрсәң, аларның сиңа ягъни сезгә, ышанычы да арта, хөрмәт белән дә карый башлый. Һәм иң кызыгы шунда!— Хыялыйның тагын күзләре очкынлана, якасын рәтли, такыр башын сыпыра.— Иң кызыгы шунда, бу клубның җитәкчесе, ягъни президенты — өендә тик ятып арыган, кешеләр белән аралашырга теләгән, иркен тормышлы берәр чибәр ханым булырга тиеш! Әйе-әйе! Ярдәм генә булсын! Акча, акча!..— Хыялый бармакларына сыпыра, ул да түгел, уң кулын йодрыклап, такыр башына шакылдата.— Һәм кызыклы фикерләр, самое главное — кызыклы фикерләр һәм акча, башкасы инде табылыр.

Бу сүзләр Геннадийның акылын томалап алды, иртәгә шушы мәсьәлә буенча очрашуга сөйләшенеп, хыялыйны ишек төбенә кадәр озатып куйды. Ә теге һаман сөйләнде дә сөйләнде, тик Вәлишин аны ишетми иде инде.

Ирнең көткән нәтиҗәләре, чыннан да, сөендерерлек иде. Шушы клубның президенты булып эшкә чумгач, Альбинасы яхшы якка үзгәрде, үз-үзен генә яратуы кимеп, башкаларга хөрмәте артты. Әле бу шәхес, әле икенчесе белән очрашалар. Өстәлләр — түләүле, кеше — дөнья, бигрәк тә Альбинаның үзе кебек эшсез ханымнар — аның клубы әгъзалары. Бу изге эшкә акчаны берсенең дә ире кызганмый. Барсы да күз алдында, нишлиләр икән дип кайгырасы да юк!

Әмма хатынының үз-үзен яратуы вакытлыча гына басылып торганлыгын Вәлишин аңламый калды. «Чир китә, гадәт китми!»— диләр түгелме соң? Альбина мин-минлек хисен еракка яшерде, аны күрсәтмәс булды, тулысынча түгел, азрак та аерылмады. Әмма үз-үзен тотышын яхшыртты. Ул хәзер лаеклы һәркем каршында шәхесен түбәнчелекле итеп алардан җиңел генә, күңелләренә тимичә өстен чыга белә, артыгы белән кычкырып торган киемнәрдән саклана, гади затлы әйберләргә генә күңел сала. Элек бармагы саен алтын-көмеш кисә, теләсә нинди кыйммәтле нәрсәләр тагып бетерсә, хәзер боларның барсыннан да азат калып, гадирәк, күзгә ташланмыйчарак йөрергә тырыша. Болар барсы да ирен сөендерә иде, билгеле.

Бәхетенә, тормыштан барысын да җиңел генә алырга күнеккән ханым, егетнең ихлас күңелдән бирелгәнен тойды, аның тыгыз атлет тәненә мәхәббәте төшеп, үзенеке генә итәргә уйлады. Аңа бу ният тормышка ашар кебек иде. Ул ялгышмаска тиеш иде. Шушы рәвешле уйнатып, мөмкин кадәр алдап, һәрнәрсәне онытырлык дәрәҗәгә җиткереп торса,

әлбәттә, Ханбал бары тик анык гына булачак, бүтән берәү дә аңа кирәк булмаячак.

Ханымның эчкә яшерелгән эгоизмы шушы рәвешле калкып чыкты һәм егетне үзенеке генә итеп күрергә, аннан дивана Фәрһад ясарга юл ачты. Әмма бу гади мин-минлек хисе генә түгел, бәлки бер күрүдә яратып өлгергән күңеленең таләбе белән дә бергә тернәкләнгән җан вә тән сагышына әверелгән омтылышлар иде. Ханбал, сихерләнгән төсле, кем кулына һәм ничек килеп капканын төшенерлек дәрәҗәдә түгел иде. Моңа кадәр сакланып килгән сафлыгы, искәрмәстән төшеп киткән пыяла савыт төсле, челпәрәмә ватылды. Нинди изге әйберне дә мизгел эчендә югалтырга мөмкин шул. Бу — язмыштыр инде!

## 15

Альбина подносны кулына күтәрде. Назлы итеп кенә Ханбалга карап куйды, егетнең акылы башыннан чыгып очуы, нәрсә теләгәнне дә аңлашмый торуы сәбәпле, ханым:

— Читкәрәк алып куярга иде,— дип белдерде.

— Менә монда, яныбызга гына, урындыкка,— дип егет кабаланакабалана подносны чак төшереп җибәрмәде. Альбинага аның шулай бимазалануы тагын көлке булып тоелды, юри кыланган төсле боргаланып-сыргаланып:

— Утыр каршыма!— диде.

Ханбал баш-аяк буйсынды, ханымның каршысына килеп тезләнде. Хәзер ул үбәргә һәм кочарга тиеш иде булса кирәк. Әмма Альбина бер йөзем өзеп капты һәм аны тел очына утыртып, егеткә таба якынайды. Ханбал да, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алган төсле, аңа таба елышты, авызын ачты. Ханым: «Алай түгел!»— дигән төсле башын чайкарга, үртәргә теләде, әмма йөзем җимеше аның теле артына кире кереп китте һәм ул аны йотарга мәҗбүр булды.

— Юк, алай түгел!— диде ул бераздан.— Алай түгел лә инде! Телең белән ал!

— Ничек инде?— Егет аптырап китте.

— Берничек тә түгел! Менә шулай...

— Юк булмый!

Ханым, үпкәләгән төсле ирен турсайтып, назланып куйды һәм:

— Әйдә инде, шулай күңелле бит ул!— дип Ханбалга тагын да якынрак елышып, җилкә очларына сыпырынып үтте.— Курыкма!

— Булдыра алмамын дип куркам!..

— И-и, куркак куян!

Ханым тагын авызына җимеш өзеп капты, тел очына утыртты һәм егеткә таба үрелде, күзләрен йомгандай итте. Ханбал, аның таләбенә буйсынып, шулай ук телен сузды, тыннарына тыннары кушылды. Альбинадан менә хәзер йөземне алырмын да канәгатьләндерермен теләген дип уйлаган иде дә, көтелмәгән хәл аның тәненә яңадан җылы йөгертте. Мәхәббәт уенының барлык төмен татып яшәргә күнеккән ханым тел очындагы йөземен теш арасына кысты, аннан татлы җимеш суы агып чыкты, телләре телләренә кушылганда, ул ширбәт Альбинадан Ханбалга күчте. Егет болай ук буласын өмет итмәгән иде. Тел очына тигән татлы йөзем суты аның тамак төбен рәхәтләндерде. Йоткылыгы тартты һәм ул, түзеп тора алмыйча, телен артка җибәрде, аның белән бергә ханымның иреннәре дә суырылып керде, ул арада элеккегә хәленә кайтырга көйләнгән теле ханымның авыз куышлыгына үтеп керде. Тыела алмыйча Ханбал Альбинаны суырып-суырып үбә башлады. Җаны урыныннан кузгалды, тәне теләк кайнарлыгы белән ханымны үзенә буйсындырды. Акылларын мәхәббәт сөреме тәмам каплап китеп, алар онытылып-онытылып

маташтылар. Әгәр дә шунда кемдер ишектә кыңгырау бирмәгән булса, бу рәхәтлекләре белән чиксезлеккә килеп ирешерләр кебек иде. Чылтырау тагын кабатланды.

Икесе дә сагаеп калдылар. Әмма Альбина егетне өстеннән кузгатмады, биленнән тоткан килеш:

— Ачкычы бармы аның?— дип сорады.

— Юк! Һичкемгә ачкычымны биргәнем юк!

— Әллә берәрсен көтә идеңме?

— Юк, миңа кем килсен!

— Ул вакытта бер дә борчылырлык нәрсә юк!

Бераз суына төшкән егетнең күкрәкләрен үбешә-үбешә йомшарып беткән иреннәре белән үбәргә тотынды. Ханбал, әсәрләнеп, үз-үзен белештерми ыңгырашты, кайнар сулышы ханымның чәч толымнарына кереп буталды, муеннарыннан, маңгай һәм күзләреннән үпте. Альбинага да рәхәт, ул да назланып ыңгырашкандай итә иде.

Кыңгырау өзек-өзек кенә ике тавыш белән тагын кабатланды. Егет шикләнеп, ханымнан аерылырга тартылды, сагаеп калды. Альбинаның моңа ачуы килсә дә, аны биленнән тотып торган хәлендә кала бирде.

— Ни булды?— Бу вакыт аралыгы ханымны суытты. Әмма баш миен каплаган рәхәтлек томаны таралып өлгермәде.— Ташла син аларны! Син өйдә юк! Син минем белән! Син бары тик минеке генә һәм һичкемгә кирәгең юк!— дип егетне үгетләде.

Алар тагын мәхәббәт рәхәтенә чумдылар, әмма элеккеге кайнарлыклары китеп, тәннәре суына башлаган иде инде. Шулай да егет үз эшендә булды, мышнарга-ухылдарга ук тотынды, ханым аны ашыкмаска өндәп, тыярга тырышты, көтелгән ярсу килеп чыкмады.

— Бөтен тәмен бетерделәр!— дип зарланды ул.

Чылтырау тагын кабатланды. Бу юлысы өч тапкыр рәттән бирделәр. Бу хәл Альбинаның чыгырдан чыга язуына җитә калды. Егетне дә ачуланып ташламакчы иде, вакытында тыела белде. Юкса бар теләкләре дә үзе белән калып, планнары челпәрәмә киләчәк иде.

— Хәзер чыгам да баскычтан очырам үзен!

Ханбал көлеп җибәрде:

— Синме?

— Ә нигә? Йөрмәсеннәр вакытлы-вакытсыз!

Альбинаның бу сүзләреннән егет курка калды: «Булыр да! Моңа әләксәң!» Шулай дип уйлады уйлавын, әмма ханымның усаллыгы аны аннан ерагайтасы урынга, киресенчә тагын да якынайтты гына, моңа кадәр үзен якларга әзер торган бер кешене дә очратмаган Ханбал инде канат астына кергәнлеген тоеп сөенә идеме, әллә назлы сүзләрдән соң усалын ишетү дә ярагынлыгын тойгангамы, авызы ерылды.

— Кызу икәнсез!

Шушы сүзеннән соң аның авыр һәм озын гәүдәсе ханымның кочагына тагын да ныграк елышты, ул үзен бала сыман тоя башлады. Ә чынлыкта аларның яшь аермалары бары тик җиде ел гына иде.

— Бер дә кызу түгел! Сине алып китәрләр генә дип курыктым! Җанкисәгем минем! Мин сине беркемгә дә бирмим! Хәтта урлап алып китсәләр дә, артыннан барып табам, тартып алам! Белеп тор! Син бары тик минеке генә булырга тиеш.

Ханым кузгалып, өстенә халат киде дә:

— Кара әле, синеке миңа нәкъ таман икән!— дип көлеп, ванна бүлмәсенә таба юнәлде. Әмма Ханбалның буй-буй халаты аның артыннан идәнгә сөйрәлеп бара иде.

Аның китүеннән файдаланып, Ханбал тиз генә ишек янына килде, «күздән» кем барлыгын карады. Әмма анда, әллә Альбинаның сүзен ишетеп, әллә көтә-көтә зарыгып та ишек ачучы күренмәгәч, киткәннәр, һичкем юк иде. «Кем булыр бу?» Килеп тәрәзәдән тышка текәлде: «Китеп бармый микән берәрсе?» Анда да беркем дә күренмәде.

Ул арада ванна бүлмәсеннән чыккан Альбина ханым аның аркасына килеп асылынды, буе буйлап үпте, иркәләде, шунда үзе дә иркәләнде.

— Әллә нәрсә булды әле минем белән, тәмам гашыйк иттең!— дип сөйләнде.— Яратам мин сине, матурым, бик тә ярата башладым!..

Аның сүзенә егет шундый ук җавап бирергә тиеш иде. Әмма ул әйтми калды. Аңа бүгенге бу рәхәтлекләр артыгы белән житкән, һәртөрле мавыгудан арыган, тәнендә һәм җанында борчылу тоя башлаган иде. Ханым гына һаман да үзенең эшендә булды. Егетнең җавап бирмәвенә үпкәсен белдереп, иреннәрен турсайтты:

— Ну-ү! Әйт инде берәр сүз!..

Ханбал шунда ханымны җилкәләреннән кочып, урындыкка утырды һәм аны алдына алды. Күңелен биләгән Альбинаны үпкәләтәсе килмәде. Гәүдәсе авыраеп калганын тойса да, ханымның калын чәчләре арасына борыны керүгә, җаны тагын җиңелрәк тоя башлады.

— Мин дә сине бер күрүдә яраттым! Дөресрәге, мин сине электән үк беләм төсле!

— Ә ничек итеп яраттың?

Альбина, рәхмәт йөзеннән, аның маңгаеннан үбеп алды. Битенә битен куйды. Иреннәреннән наз өзде.

— Ничек итеп яраттың, сөйлә инде!

— Белмим, әмма яраттым инде... Беренче тапкыр гашыйк булгандагы кебек! Хәтта менә бүгенгедәй очрашуыбыз, шулай итеп якынлашуыбыз тәтемәгән булса да, мин барыбер яратачак идем бит!

— Нәрсә, кирәк түгел идеме әллә?

— Белмим! Болай ук якынаеп киткәч, кире кагу мәгънәсез!

— Бәхетеңнеме?

Ханым үзен Ханбал өчен күктән төшкән бәхет итеп сизә, егеткә дә аның шулай икәнлеген аңлатып калырга тели иде. Белеп торсын, бүтән кабатланмаска да мөмкин бит!

— Әгәр дә мин башка килмәсәм, шуның белән онытсам?

Ханбалга авыр булып китте. Чыннан да, теләсә, ханым аңа һичкайчан килмәячәк. Сагынсаң да, эзләп таба алмаячаксың, егет. Мондый бәхет хактан да гомергә бер генә тапкыр иңәргә мөмкин, кадерен белеп калмасаң, кабатланмаячак!

— Ә мин сине барыбер эзләп табар идем! Беләм мин монда гына яшәгәнегезне. Айзик та мине якын итеп калды! Су буена төшәм дә утырам һәм сез килеп чыгачаксыз. Этең бик ярата бит анда йөрергә, шулаймы? Ә-ә-ә...— Ханбал бүгенгә нинди планнары булганлыгын исенә төшерде, сәгатенә карап алды.— Соң икән инде, өч тулып килә, юкса Казан суы буена төшәрмен дигән идем! Әнә, син ком гарәбе кебек кызынгансың, ә мин — ап-ак!

— Һәм үтә күренмәле!

Альбина көлеп җибәрде һәм, дөрес әйтә микән, дигәндәй, Ханбалның диварга элеп куелган кул сәгатен үзенәрәк тартып, вакытны карады.

— Туктаган түгелме соң бу?

— Ул туктый белми, иртән генә борып куйдым!

Ханбал иске, кыршылып беткән сәгате белән мактанып алды. Әмма Альбина аңа ышанырга теләмәде, як-ягына каранып, бүтән өстәлдә авып яткан «будильник»ка игътибар итмәде.

— Монда башкасы юк мыни?

— Юк, бусы — йөри торган, бердән берем! Әмма иң ышанычлы! Иртән мине күтәреп ала, ашыктырып чәй эчертә, эшкә үзем белән бара, үзем белән кайта һәм менә шушы урынына менеп кунаклый, әтәч төсле ул! Шунлыктан вакытны беркайчан да ялгышмый, гомеренә бер мәртәбә төзәтелгәне юк, теләге дә беленми. Аныкы түгел, иясенеке!

Альбина, күңеленә бу сүзләрне хуш алып, тагын көлеп алды. Әмма егет шикләнеп калды.

— Нәрсә, әллә ялганлый дип беләсеңме?

Балалыгы тышына чыкты. Утыз яшен тутырып та һаман сабый кебек беркатлы булсын инде! Елап та җибәрә күрмәсен тагын. Була ул андый эш диваналардан. «Моннан чын-чынлап дивана Фәрһад чыга!»— дип уйлап куйды Альбина һәм егетне тынычландырырга ашыкты:

— Юк-юк, алай димим! Бары тик күңелле булып кына китте! Кызык итеп сөйлисең бит!

— Ә-ә, алай дисәң генә инде!

Аларның сөйләшер нәрсәләре беткәнлеге сизелә башлады. Альбина яңа тема эзләп газапланмады, кабат вакыт турында сорады да кабаланып сикереп торды:

— Аһ, мин нишләп утырам әле! Кайтырга кирәк бит! Эшләрем дөнья кадәр җыелган!..

Бу аның сыналган гадәте иде. Хәзер ханым артыннан Ханбал ташланырга, тагын да калуын үтенергә тиеш. Ә Альбинаны өендә бернинди эш тә көтми һәм, гомумән, «Кызыклы очрашу клубы»ннан тыш, ул күптән инде бер нәрсә белән дә шөгыльләнми, көч түкми. Керләрен дә килеп алалар, китереп куялар. Ашны да сирәк пешерә, өйдә чагында ире табак-савытларын үзе юа, хәтта ашарга да әзерләштергәли әле! Эшләсен, ул бит Альбина каршында ант сулары эчте, аны гөлбакча эчендә генә, бернинди мохтаҗлык күрсәтмичә яшәтәчәкмен, дип белдерде, һич авырлыклар күрмәссең, диде! Чыннан да, әйткән сүзендә торды. Зур ике катлы йорты, яхшы ак мунчасы, бакчасы бар дачалары өстенә, шәһәр квартирлары уңайлыгына да карамастан, янә бер җирдә кирпечтән өч катлы итеп, саунасы, гаражы, хуҗалык келәтләре булган коттедж төзетеп маташа. Альбинаның барып та караганы юк. Өлгерер әле!

Альбина өмет итсә дә, Ханбал аның артыннан килмәде. Өстенә киенергә тотынды. Ә ханым исә ашыкмады. Егетнең иске халатын урындык башында калдырды һәм анда-монда таралып яткан киемнәрен берәмләп-берәмләп җыя башлады. Менә хәзер ул киенә инде. Тәрәзәгә карап, ашыкмыйча гына! Ә артыннан Ханбал карап торырга тиеш. Күрсен, болар барсы да аның күзләре өчен дә яратылган. Ханым шулай тели! Кырык яшенә карамастан, үзенең егерме яшьлек кызлар кебек нәфис һәм күзләрне кыздырырлык сыны бар бит аның! Күрсен! Кадерен белсен! Ул киенсен, ашыкмыйча гына!» Нигә килми инде?— дип көтмәгәндә уйлап куйды ул, бозау икән бу, өйрәтергә, күп нәрсәләргә өйрәтергә икән әле үзен!» Әмма Альбина андый фикергә ашыгыбрак килгән иде. Көтмәгәндә артыннан кочып алган егеттән өркеп үк китте, тәне буйлап җылы калтырау йөгерде. Ханбал аның колак читеннән үбеп куйды.

— Уф,— дип хәл алды ханым,— котымны чыгардың бит! Җаным очты, дип торам!

Артыгын әйтмәде. Аңа үлеп рәхәт иде. «Кара әле моны,— диде ул үзалдына,— тинтәк-тинтәк, дисәң дә, хикмәт икән әле бу! Чыннан да, гашыйк булырга өлгерде! Суытмаска кирәк хисләрен, суытмаска, һай диванам минем!» Егетнең иреннәрен эзләп табып, аларны суырып үпте, кулына җыйган киемнәре аяк астына төште. Ханбалдан аркасына күлмәген салдыра башлады, әмма алар аның беләкләрендә бөәлеп калдылар. Изүләре арасыннан күкрәгенә, аннан куенына үтте. Әмма егет чишенмәде, күзләрен йомган хәлендә һаманниләрдер пышылдады, аларның бер сүзен генә аңлап калды ханым: Регина! Кем соң ул Регина? Нигә аның хакында сөйләргә теләми? «Хәзер утлы табага утыртам мин аны!»— дип уйлап куйды Альбина һәм кинәт кенә Ханбалны этеп җибәрде дә тавыш күтәрде:

— Һаман да мине теләсә кем исеме белән атыйсың! Нинди Регина ди мин! Кем ул?

Көтелмәгән бу хәлдән нәрсә әйтергә дә белмичә, егет аптырап калды. Аның каршысында, чыннан да, Регина басып торадыр төсле тоела. Күр, охшамаганнармыни? Чәчләре шулай калын аның да, борыны һәм күзләре, иякләре дә... Буйга гына бераз калкурак, яки тәбәнәгрәк булса инде.

Ә күзләре? Юк-юк, күзләренең төсләрендә аермалыклар бар кебек. Әмма карашлары, карау рәвешләре бер үк төрле. Әйе-әйе, нәкъ менә шул яктан алар икесе дә бер кеше төсле! «Әллә сөйләргә инде? Бу кадәр сорагач та әйтмәсәң, үпкәләр тагын». Егет шушы рәвешле уйланып торган арада ханым киенеп тә бетте диярлек.

— Матурым...

— Әү, җан рәхәтем...

Альбина шушы рәвешле җавап бирүгә, Ханбал башларга җыенган сүзен онытып, аңа таба якынлашты. Алар тагын бер-берсен сагынган ярлар кебек кочаклаштылар. Болай булса, алар көнне генә түгел, төнне дә үткәреп җибәрәселәр иде. Ә Альбинага, чыннан да, өенә кайтырга кирәк! Һәм кичекмәстән. Ире килеп кергәндә, каршысына барып басмаса, бетте башы, бүген кичкә кайтам, дигән иде бит! «Ашыгырга кирәк!»— дип кабатландырды ул үзен, әмма егетнең тыела алмыйча, кабат-кабат килеп ябышулары аны тоткарланырга мәҗбүр итә, бәйләгән җирен чишелдерә иде.

— Ярар инде, җан рәхәтем...

Альбинаның шушы назлы сүзе Ханбалны әсәрләндергәннән әсәрләндерә бирде. Онытылып кочты, әмма ханым аңа игътибар юнәтмичә, киенү ягын карады, ә үзе тыныч кына сөйли барды:

— Тагын очрашырбыз әле! Бүген белән генә көн бетмәгән!..

— Ә мин сине җибәрмим!

— Нишләтерсең?

Альбина аңа исе китмәгән көчле кеше кебек итеп карап куйды. Егет тә төшеп калганнардан түгел иде.

Ханым көлеп җибәргәч, Ханбал да аңа кушылды һәм җавабын каткат кабатлады:

— Ишекне биклим дә куям!..

Үз балалыгы үзенә дә кызык кебек тоела иде шул. Альбина, көлеп туйганнан соң:

— Алдан ук белдереп куярга телим. Бу көннәрдә бер нәрсә дә планлаштырма. Атнакич, сәгать кичке алтыларга кереп алырмын үзеңне,— диде.— Мин сине бер кызыклы җиргә алып барырмын. Костюмың бармы? Бик яхшы, киеп куй! Юк, дөресрәге, аста, подъезд төбендә көт, ярыймы?

— Нигә?

Ханбал бер нәрсә дә аңламый иде. Әмма ханым тиз арада план корырга өлгерде: «Шаккаттырыйм әле барсын да!» «Минем фәләнем бар, минем төгән сөяркәм!»— дип мактанган булалар, ә мин аларга дивана Фәрһадны китереп күрсәтәм! Этем артымнан ничек калышмыйча йөрсә, моны да шундый дәрәҗәгә төшерергә кирәк! Иремә дә алдан әйтеп кую хәерле! Табармын әле нәрсә әйтергә! Кайтып җитмәде микән?» Ханым ялт кына кулына алтын сәгатен такты, карады һәм хәйран калды, кычкырып диярлек җибәрде:

— Һай бишенче ярты тулып килә бит инде, синең сәгатеңә ышансаң! Өстән-астан ике таш өстә үзенә,— дип әйтеп тә салды. Ишек янына житүгә:— Исеңдәме?— дигән соравын кабатлады.— Атнакич сәгать алтыда подъездның төбендә көтәсең!

— Нигә?

— Сюрприз!..— дип кыланып кына шунда бармагы белән сәерсенгән егетнең борын очын сыйпап узды, җинеллек белән генә ачкычны борып, Ханбалның иреннәреннән суырып үпте дә юк та булды. Ничек кинәт кенә килеп керсә, шулай ук көтмәгәндә чыгып та китте. Ханбал исәренгән хәлендә аның үбеп кочуыннан соң ишеккә маңгае белән килеп бәрелде һәм моңсуланып калды.

Кичке кояш нурларының кылларын чирткән төсле, кадак үкчәләре белән асфальт юлга тек-тек басып киткән чибәр ханымның ерагая барган аяк тавышларын колаклары белән генә түгел, күңеле белән дә тойды,

ишетте егет. Ул тәрәзәгә килеп җиткәндә, Альбина инде ераклашкан иде. Тиз-тиз атлап, гүяки, очынып-очынып бара иде, нәкъ унсигез яшьлек кыз, диярсең!

Альбина, өенә кайтып керүгә, иренә нәрсә әйтергә икәнен белә иде. Клуб эшләре белән булдым, аннан соң кибетләр карап йөрдем, дияр. Ачуланмас, сагынып кайта бит ул, хатынын күрүгә, дөньяларын оныта. Аяк асларындагы тузан хәленә төшәргә әзер.

Әмма фатирда Айзиктан башка җан иясе юк иде. Ханымның моңа бераз ачуы да чыкты: кайтам, дип аптыраткан була, иркенләп йөрергә дә ирек бирмәде бит үзенә! Юри шулай алдый ул!

Вак-төяк эшләрен бетереп, душта юынып алгач, Альбина үз бүлмәсенә кереп, урын өстенә җәелеп ятты. Бүген кичергән күңелле һәм рәхәт халәте җанына һаман да тынычланып җитәргә ирек бирми, акылын бутый, канатландыра иде. Юк, тормышы күңелсез түгел аның, киресенчә, кәефле вакыйгалардан тора. Менә тагын төрләндереп җибәрде. Моңа кадәр Геннадий белән генә һәвәсләнгән, картая төшкәч, әллә бер-берсенә өйрәнеп җитүләре, әллә инде башка сәбәпләр аркасында онытылып беткән мәхәббәт уеннарын да яңартып җибәргәч, бөтенләй яшәреп киткән төсле хис итте үзен. Бигрәк тә яшь егет, дөресрәге, яшь ир белән булуы аңа ун елын җиңел генә чигереп ташларга ярдәм итте.

Көзге көннәргә тартым кояш нуры каршы як йортның тәрәзәләрендә уйный иде. Чагылып-чагылып киткән күзләренә ирексездән яшь килгәч, Альбина елап та алды. Әмма хәсрәт йотып түгел, бәлки барсының да шулай җае белән матур гына барганлыгына сөенеп!

Аңа рәхәт иде. Бүгенге көндә ул тормыштан табарга мөмкин булган барлык бәхетләрне дә үзенә җыя алды. Иртәгә аңа тагын да күбрәк кирәк булачак. Әмма ашыкмаска һәм кабаланмаска тиеш. «Бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына!» — дип уйлап, Ханбал белән язмышын очратканы өчен Аллаһы тәгаләгә мең рәхмәтләрен укыды. Кемгә-кемгә, әмма аңа ышана иде ул.

Кичә кичтән укырга керешеп, йокыга киткәнлеге сәбәпле онытылган теге кульязманы исенә төшерде. Таралмас өчен тегелгән-төпләнгән папканы ачты. Тагын бер мәртәбә кыйссаның исеменә игътибар итте. «Мөхәммәт пәйгамбәр һәм сөеклесе Хәдичәнең мәхәббәте, яки олуг гыйшык серләре» — мавыктыргыч аталыш. Онытылып укыган иде түгелме соң? Яхшы әсәр кебек тоелган иде. Иренә ул нәрсәгә кирәк булды икән?

Укылган битләрен караштырырга тотынды. Юк, ике генә сәхифәсен узган икән. Ә калган? Төне буе укып чыккан төсле иде бит. Димәк саташылган. Төш күрелгән. Шунда аның хәтеренә кылт итеп төше керде. Ире дә яңгын чыгуы хакында әйткән иде. Анысы — яхшыга, ә үзенеке? Ничек иде әле? Имеш, аларның бер бүлмәләре — кызыл, икенчесе — яшел, өченчесе — зәңгәр. Келәмнәре, челтәрләре, җиһазлары, хәтта идәннәре дә шундый ук төсләрдә. Аларны карап кемдер йөри. «Бу җәннәт эче түгелме?» — дип сорый. Әллә Мөхәммәт пәйгамбәр инде, кызым, дип дәшкән төсле. Мәрхүм әтисе дә түгел бугай... Әллә шулмы? Нигә бу бүлмәләр буталган әле? Берсенең идәне — яшел, диварлары — кызыл, җиһазлары — зәңгәр, пәрдәләре — сары. Аларда бит сары төс бөтенләй дә юк иде бугай. Альбина яхшы белә, сары — сагыш төсе, дип хәтта андый мебель-җиһазлар да алдырмады иренә. Кайдан болай? Залга үтә, анда да шундый ук төсләр. Ә иренекенә керә алмый, бикле. Гомер булмаганны. Беркайчан да ябып йөргәне юк иде. Хәтта фатирлары ишеген дә. Һәрвакыт Альбина үзе аның артыннан бикләп кала иде. Ни хәл бу? Ә Ханбалга монда ни калган? Ни дип дәшә ул? Үзе көлә, тагын кайгыга бата. Ире кайтты бугай — ишектә кыңгырау тавышы... Ә ул телефон булып чыкты. Иртән Геннадий шалтыратып борчымаган булса, төшен Альбина онытмый иде инде. Менә хәзер, Ходайның рәхмәте, исенә төште бит. Юрарга иде үзен. Ханым һәр күргәнен тәртипкә сала-сала, аңлатмаларын эзли башлады һәм соңыннан бер генә нәтиҗәгә

килә алды: «Бу төш — мәхәббәт төше! Ханбал белән икесе арасында булачак һәм инде булган мәхәббәт хакында бит!» Шушы фикере аны тынычландырды, борчылулардан азат итте һәм ул әлеге дә баягы кульъязманы ачып, укырга керешге...

## 16

Альбина, кыйссаны укып чыккач, бераз аңлаша алмый торды. Болай күңелсез бетәргә тиеш түгел иде төсле ич. Алга таба актарды. Анда тагын да берничә хикәя бирелеп, алар тузга язмаган ахмак көлке әсәрләр кирәксез сүз боткаларыннан гына гыйбарәт иде. Кульъязманы өстәл читендә калдыргач, кабат урынына кереп ятты. Тик, ни хикмәт, күзләренә йокы кермәде. Кайтып-кайтып уйлана бирде. Ерак гарәп илендә моннан мең дүрт йөз еллар элек булган вакыйгалар, ничек кенә иске кебек тоелмасыннар, бүгенге дөнья төсле ачык һәм аңлаешлы хакыйкать иде. Ул вакытта бәндәләр нинди уй-хисләр кичерсә, бүген дә шулай. Яратасың икән, яратасың инде, ояты да онытыла, гайбәтен дә колак ишетми башлый. Аның Геннадий белән мәхәббәте нәкъ шул рәвештә түгел идеме соң? Юк, кызганыч, әмма түгел иде. Вәлишин аны алдау ярдәмендә яулап алды, күңел түрендә әле генә кабынырга әзер мәхәббәт учагының яна башлаганын көтеп тә тормады. Башка берәү житешер дип курыктымы? Акларлыгы юк! Мөхәммәт пәйгамбәр төсле изге хисләр эчендә житлекмәде аның сөю-мәхәббәт омтылышлары. Бабасы Сабир Габделбәрович дөрес әйткән икән. Килде бит ул Алабугага, кызы белән киявенең тормышлары бозыла башлауга, килеп житте, эзләп тапты, хәтта чит телләр кафедрасында укытучылык эшен алып барган Альбинаны, кудыртам, дип тә куркытты.

— Ул,— диде. Вәлишинне хурлап,— карьера сөя торган кеше, бары матур әйберләргә генә кызыга, тәмле ашарга ярата. Сез тиң һәм пар түгел. Бәхет таба алмаячаксыз. Кеше сөягеннән төзелгән йортта яшәү мөмкин булмаган төсле, гаилә жимереп, тормыш кору мөмкин түгел. Һәрвакыт шушылай яшь-чибәр калырмын дип уйлыйсыңмы? Үтә һәм сүнә алар барысы да. Күреп торырсың, ташлап китәчәк!..

— Мин аны яратам, дип әйткәнем бармы соң?— диде Альбина, бу комсыз күзле картлачка. Ул хәзер һичнәрсәдән куркып тормый, батыр иде. Югалтыр нәрсәсе дә юк:— Нигә миңа килдегез? Үзенә сөйләгез. Курыкмыйча әйтегез, мине тынычлыкта калдырсын!

Сабир Габделбәрович бик риза иде. Ул гына да түгел, Альбинаның үзен куркусыз һәм иркен тотуыннан файдаланып, инде картлыктан калтырана башлаган кулларын әле биленә, әле аркасына сузды. Тоткалап та маташты. Моны күрә торып, кыз юри игътибар итмәгәндәй кыланды. Картлач, мескен, нәрсәгә килгәнлеген дә онытып, аңа ябырылырга әзер иде. Тагын да бераз котыртса, ул тәмам Альбинаның аяк асларына ятып, табаннарын яларга әзер иде. Теле сөйләгәнен колагы ишетмәс дәрәжәгә болай да житкән иде.

— Син, кызым, артыгы белән гүзәлсең. Безнең чорда синең кебекләр юк иде шул. Кайларда тудың да, кайсы суларда юынып үстең!

Альбина ни якка атласа, диванга утырган картлачның кулы шунда таба үрелә, яннарына китереп кунаклатырдай була иде. Әмма начар да кеше булып чыкты. Киявенә кайтып, бик яман итеп сөйләде.

Икенче көнне Геннадий үзе килеп житте. Кыз, әлбәттә, барсын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде, хәтта нәрсә әйткәнлекләрен дә сүзгә сүз кабатлады. Вәлишингә житә калды, тәгәри-тәгәри көлде.

Ну, картлач, үз башыңа гына йөргәнсең икән, минем белән көч сынашып кара хәзер!— дип куанды һәм бу килүендә ашыгып китеп бармады, ә рәттән өч көн яшәде. Машинасын кайтарып жибәрде. Иртән лекцияләрен-дәресләрен үткәрергә киткән Альбинаны көтеп-көтеп алды

һәм гаиләсе белән араны тәмам өзәчәген белдерде. Әмма кыз моңа сөенмәде. Чөнки хәзер инде барыбер иде. Өйрәнелгән. Ул аннан артыгын таләп итми.

Шушы хакта белдергәч, Вәлишин чыгырыннан чыкты. Нindидер өченче кеше араларында пәйда булды, дип уйлады, хәтта икенче көнне институтка кадәр артыннан барды, көтеп алып, озата кайтты. Чыннан да, Альбинасын һичкемгә бирәсе килми иде аның.

Калганнары үз җае белән, ничектер җиңел генә килеп чыкты. Килде, алып китте. Башта туган йортына, аңа моңа кадәр белдермәгән һәм әлегә исән-имин яшәп яткан әти-әниләре белән таныштырды. Алар, әлбәттә, аптырап калдылар. Шул ук көнне Альбиналар Казанга юл алдылар. Озакламый өлкә комсомол конференциясе Вәлишинне эшеннән алып очырды. Әле дә вакытында китә белде. Тиздән комсомолның да, хәтта коммунистларының да кирәге калмады. Хәзер әнә барысы да һаман бергә, бер үк төрле казанда кайныйлар. Ә ул казаннар бизнес-коммерция дип атала. Элеккечә үк бер-берсен алдыйлар, ничәмә төрле һәм җәпле хәйләләр коралар, әле берсен, әле икенчесен «яндыралар», аннан тагын сөйрәшеп чыгаралар да әллә ниләр эшләп бетерәләр. Болары барысы да Альбинага караңгы һәм кызык та түгел. Ник чукынышып бетмиләр шунда!

Альбинаның бу уйларыннан һәм онытылып укуыннан башы кабарган төсле иде. Вакытның соң икәнлегенә игътибар итеп, утларын сүндерде һәм йокларга ятты: «Геннадий алдады, бүген дә кайтмады!»

Төне буе саташып чыкты, имеш, янында Ханбалның ятканын күреп, аның белән мәхәббәтләрен алышып, әллә ниләр булып бетте. Әмма боларны күрү аңа рәхәтлек һәм тәненә ләззәт бирә төсле иде.

...Маңгаеннан кемдер рәхәт кенә итеп сыпырып, ул йомшаклыктан бөтен тәненә наз йөгерде. Кайнар иреннәрнең үбүе җанын тибрәтте һәм кочакларга дип кулларын күтәреп, Альбина уянып китте.

— Геннадий, матурым, кайттыңмы?

Ханым үзенең ирен көтмәгән иде. Кояш чыккан. Дөресрәге, бу ләззәткә чумдыручысы Геннадий дип күңеленә дә алмаган, һаман да шул кичә укыган кыйссасы һәм гөнаһы аны алдыйлар, хисләрен үзләренә буйсындырып, тагын-тагын да адашуын телиләр иде. Әмма иренең көттереп-көттереп тә кайтмыйча, инде онытыла башлагач шулай иртәнге сәгатьтә аны иркәләп үтүе бер төш һәм хыял гына төсле иде. Саташа булса кирәк.

— Нишләдең?

Геннадий, Альбинаның зураеп ачылган күзләреннән куркып киткәндәй, аптырап сорау бирде.

— Нишләдең? Бигрәк сәер карыйсың!

— Аптырабрак киттем! Син ничек? Айзик тавыш бирмәде бит. Ничек болай җиңел генә килеп кердең?

Элекләрне, ире кайтып җиткәндә, җиде төн уртасы булсын, Альбина аның аяк тавышларыннан һәм ачкычларын шылтыратуыннан ук уянып китә, барып ут яндыра, суынган чәен яңарта торган иде. Ә бүген ничек сизенмичә калды әле? Картаеп барамы әллә?

— Ә мин нигә ишетмәдем?

— Белмим,— дип көлде ире,— белмим! Хәтта Айзик та, сагынган, бичара, ике тапкыр аваз бирде. Мин дә дөбер-шатыр килеп кердем, ә син йоклыйсың да йоклыйсың. Берәр дару эчмәгән идеңме соң?

Нинди дару, ди, ул! Альбина кичәге вакыйгаларны тиз генә күз алдыннан кичерде, хәтеренә укыган кыйссасы килде. Әмма иренә беренчесе хакында әйтмәде, икенчесен генә белдерде:

— Синең бүлмәдән бер кулъязма тапкан идем. Кызык кына. «Мөхәммәт пәйгамбәр һәм сөеклесе Хәдичәнең мәхәббәте, яки олуг гыйшык серләре» дип атала, укып чыкмадыңмы?

Геннадий ул папка хакында инде күптән оныткан иде. Исенә дә төшерә алмый аптырады. «Әгәр дә шаяртмаса, берәр ханымның хатын

яки запискасын әйтмәсә инде юри шулай?» — дип тизрәк белмәмешкә салынуын йөзенә чыгарырга һәм әйтеп бирергә ашыкты:

— Нинди кулъязма, һич аңламыйм!

Альбина өстәл читенә үрелеп, телгә алган папканы кулына эләктереп, якынрак тарта башлады, әмма яңа гына уянган тәне әле ныгып җитмәгән, бармаклары йомшак иде. Кулъязма идәнгә төшеп, таралырга да өлгерде. Чәчелгән битләрен тиз-тиз җыйнаштырып, Геннадий аны күтәреп алды һәм бер дә әллә нәрсә түгеллегенә сөенеп куйды.

— Ә-ә, бу икән әле! Хәтеремә төште. Бер язучы белән таныштырганнар иде. Соңыннан берничә тапкыр килеп-китеп тә йөрде, шушы кулъязмасын калдырды. Бигрәк беркатлы иде дә инде. Бастырырга дип сөйләшкән идек, вакытында килешү төзелмичә калды. Ул арада кәгазь хакы акчаныкыннан күпкә үсеп китте. Ярдәм итүне сораган иде бугай әле, бер нәшрият та тапкан иде. Шулай калды да калды инде. Әллә укып чыктыңмы?

— Ә үзең укымаган идеңме?

— Юк, әлбәттә, мин бит татарча китаплар укымыйм, үзең дә беләсең, кызыгын тапмыйм...

— Русчасын да укыганың юк инде...

— Бар иде, соңгысы — моннан сигез еллар элек, Николай Корчагинның «Корыч ничек чыныкты» әсәре. Анысының да яртысына да җитә алмадым, ахмак һәм микәнә кешеләр турында язылган бу дип, ташладым. Моны сиңа укырмын, бәяләрсең, дигән идем! Ну, ничек? Укып чыктың бит, шулаймы!

— Әйе, укыдым! Шуңа күрә бүген йокланылган инде, кичә дә соң ятылган булган.

— Ну, ничек?

— Миңа ошады, кызык язылган.

— Сиңа ошаса, башкалар да яратачак инде аны, белеп торам. Юкка авторын үпкәләткәнмен икән, вакытында бастыртасым, йә ярдәм күрсәтәсем калган.

— Син аны сәер, диденңме әле? Мондый акыллы кешеләр югалып калмый, китабы әллә кайчан сатуга чыккан инде!

— Белмим шул, белешермен әле... Син мине көтәсеңме, хәзер!

Геннадий шушы сәер сорау белән сөйләшүне тәмамлап, чишенергә кереште. Альбина моңа кадәр булып узган һәм күңеле кичергән барлык вакыйгаларны онытып, аның иркәләвен-яратуын көтә башлады, ире килеп ягылганчы гәүдәсенә кайнарлык йөгерде...

Әмма йөрәге үз эшен башкарды. Ханымны җылы куенында җылытучы Геннадий инде аңа чит, авыр һәм тәмсез кебек тоелды. Кичә Ханбал белән ул үзен шундый яшь, шундый бәхетле итеп хис иткән иде, ә бүген, аның өчен карьерасыннан һәм дусларыннан баш тарткан, егылган җиреннән кабат аякка басып киткән, сигез яшькә өлкән ире янында шәхесен әби, кибешкән хатын сыйфатында тойды. Моңа кадәр мондый ямьсез уйлар бер генә тапкыр да башына кереп карамаган иде. Дөньяга карашы үзгәреп киттеме? Хәзер үз иркәсе һәм бәхете аңа чит, чиркандыргыч булып тоелды. Күзләрен йомды. Аңа кулын һәм тәнен тидермәскә тырышыты, әмма ире эшен башкарды, саташа-саташа диярлек барлык җирләрен ялый бирде. Моңа кадәр Геннадий белән һәм бары тик аның белән генә бәхетле булдым вә булачакмын дип уйлаган ханымның үзүзенә ачуы килде, тәнен эт иснәгән һәм юешләгәндәй хис итте...

## 17

Иртәнге кояшның нурларыннан иркәләнеп уянган Ханбал кичәге хәлләре хакында нәрсә уйларга да белмичә ятты. Аңа рәхәт иде. Моңа кадәр бер генә тапкыр да хатын-кыз назының нәрсә икәнлеген белмәгән хәлдә яшәгән икән. Гомеренең заяга узганлыгын шуннан

күр инде. Юккамы аның хәтта гаиләсе булган хезмәттәшләре, берәр чифәрне очратсалар, кем икәнлекләрен дә онытталар? Һай шаяннар, һай наяннар! Аларны тормышның төбенә төшкәннәр дип уйлыйсың, ә киресенчә бит, рәхәтләнәләр генә. Кая бу оят? Кайда китте кыенсыну, гөнаһ өчен үрсәләнү, шикләнү, гайбәт һәм сүздән курку? Кемнең кемдә эше бар? Юк шул, юк!

Әмма Ханбал үзенең нинди хәлдә калганлыгын аңламый, ул тәмам исергән, мәхәббәтнең назыннан акылын югалткан, җаны кыйбладан тайпылган иде. Коммунистик әхлак кагыйдәләре җимерелүгә, аларны алыштырырдай бер генә дә яңа нәрсә мәйданга чыкмау аркасында гына түгел, бәлки ул җәмгыять череп баруы, нәтиҗәсендә Ханбал кебек меңнәр шушы барышның корбанына әйләнеп һәлакәткә килә һәм шушы бетү, харап ителүне яхшы, рәхәт, хәтта бәхет итеп күрәләр. Ә чынлыкта сәгадәт аларның яныннан гына үтеп китеп бара. Югалган тынычлыктан рәхәт табудан да мәгънәсез нәрсә бар микән бу тормышта? Ханбал үзе дә белмәстән күңел тынычлыгын югалтып, изге мәхәббәт урынына бозыклык вә гөнаһка баткан бер бәндә генә түгелме соң? Һәрхәлдә, шушы рәвешле фикерли иде акыллы егет. Барысын да бәйнә-бәйнә тезеп салып, чагыштырып һәм нәтиҗәләр чыгарып. Бу урында мин үзем дә аны яклар идем. Шулай да әхлак кагыйдәләреннән тыш, тормышның үз кануннары бар, алар уйлап чыгарылмаган, яшәешнең башында ук, адәм балалары табигать кочагында яшәгән вакытлардан бирле урнашып калганнар. Аларны чит-ят күзләрдән еракрак яшерергә мөмкин. Ул кагыйдәләргә һичкемне өйрәтмиләр, алар яши, яшәячәк. Мәхәббәттә гөнаһ була алмый, анда тик изгелек һәм өстенлек кенә бар. Әгәр дә мәхәббәттә гөнаһ күренә икән, ул вакытта нәфрәттә дә яхшылык яшәр иде. Явызлыкның кешелеккә каршы куелганлыгын беләбез, изгелекнең тантана итүе өчен көрәшәбез. Димәк, без моңа күнегергә һәм мәхәббәтнең бары тик яхшылык кына, изгелек кенә икәнлеген танырга өйрәнергә тиешбез. Мәхәббәт көчләп килми, аны зарыгып көтеп ала белергә һәм гомер буена сакларга гына өйрәнергә кирәк!

Ханбалның уйларына чик юк иде. Алар аны алҗыттылар, ул тагын йокыга китте. Кабат уянган чагында кояш инде шактый күтәрелгән, кухнядагы кул сәгате туктап калган иде. Егет радионы ялгады, вакытны менә-менә әйтерләр, дип көтә иде, ишегендә кыңгырау бирделәр. Чыкса, тагын шул урыс. Бу юлысы әллә төшен йокысыз үткәрүе, әллә гомер иткән хатынының үлем түшәгенә яту хәсрәте аны тәмам баскан, сүзсезләндереп калдырган. Башка вакыт булса, Ханбалны алдан кул күтәреп каршы алыр, туйганчы бәхәсләшер, үзенекен өстенгә чыгарыр, әгәр дә егет бирешмәсә, үпкәләп диярлек бер-ике усал сүз катар иде.

— Ни булды, Федор абый? Кирәгез...

Ханбал аңа мөмкин кадәр яхшы мөнәсәбәттә булырга теләде. Электән, күптән килгән танышлыклары дәвамында үчләшкән чаклары да бар иде, ә мондый кайгылы вакытында алай ярамый. Язмыштыр инде, заманында егетнең бәхетенә аяк чалды, үзе генә түгел, хатыны белән бергә, бәлки яхшыга гына эшләгәннәрдер, онытылды ич инде.

— Кереп тормам. Эш белән идем!

Картлач тагын калтырана башлагандай тоелды. Егет үзен тыныч тотты: «Бәлки, тагын телеграмма бирергә кирәктер, килмәделәр микәнни?»

— Телеграмма мәсьәләсендә түгелдер бит?

— Юк-юк, улым...

Каян Ханбал аңарга «улым» булсын ди инде? Нигә шулай ышандырырга теләгән кебек кылана, белмимени, күренмиме? Егетнең моңа исе китә. Ә чынлыкта «улым» аталачак вакытлары бар иде бит, ятрмадылар Ханбалны. Ә тормыш үзенчә эшләде. Китереп, аларны күршеләр ясады. Ярар, булган, беткән, яңартып торасы юк!

— Кайтабыз дип хәбәрләре килде. Кичә дә чылтыраткан идем, ишегенә килеп берничә тапкыр. Эчтә кемдер бар төсле иде, ишек ачмадың...

— Ул ни, Федор абый, радио сөйләп калган иде...

Ханбал ялганлый белми иде, йөзенә кызыллык йөгерде. Әмма картлачка моның шулаймы-түгелме икәнлеге кирәк булмады.

— Мин бит һич ни сорамыйм. Марфа бөтен эш. Чакырта сине. Белмим нигә, ул бөтенләй дә яхшырып китте әле, бәлки аягына да басар? Әллә сер бирмиме? Үлем турында сөйли. «Вакыт инде!» — ди. Рухи атаны чакыррыргамы, дип. Йолабыз шулай. Беләсеңдер инде. Ә ул: «Кирәкми,— ди,— Аллабыз каршында гөнаһым юк. Рухи ата нәрсәгә? Гомерем буе коммунистка булдым, бүтән Аллага табындым. Ә Аллабыз Христос аңлар, ярлыкар!» — ди. Бабасы чаңчы иде бит. Хәтерлим әле. Бер авылдан идек бит без. Башлы мужик иде. Маркс-Ленинны яттан белә иде. Шуның аркасында харап та булды. Коммунистлыкка ул өйрәтте аны, Марфаны. Бер генә демонстрацияне калдырмады бит. Сайлау вакытларында төннәрен дә кайтмый эшли иде участогында. Ә демократларны яратмый, кеше алдыйлар, ди.

Урысның сүзе бетмәсен аңлап, Ханбал аны тагын фатирына үтәргә чакырды, ә ул бу юлысы да кире какты. Әле генә сүзсез тоелган картлачның, хатыны янында утырып, башына җыелган фикер-хатирәләрен оныткančы чыгарып түгеп, кеше колагына тутырып калдырырга теләве идеме бу, әллә инде аклануымы — аңлашылмады. Эшнең нәрсәдә икәнлеге ахырдан гына беленде.

— Ни бит, минем Марфа әйтә: «Теге татар малаен чакыр!» — ди, синең хакта инде. Ачуланма, үзеңне беренче тапкыр «малай» дип әйтәм. Моңа кадәр «улым» дия идем. Синең белән бәхәсләшүләремне өнәмәде ул. Ә мин, карт җүләр, тыңламадым сүзен. Син бит бер татарга охшамаган, гел шуны исемә төшерә идең. Ә аңа үпкәмме, дим, үчемме бар иде. Шуңа күрә сине үземнән түбән куясым килә иде... Ул татар хакында әйтәм, дөрес уйлаганмын. Шигем урынлы булган. Ә ул алай түгел ди иде, Марфаны әйтәм. Ә үзе һаман сине хәтерләштергәләде. Ә менә кичә үзеңне дәштерде. Өеңдә юк идең. Ә Марфа әйтә: «Өеңдә, юри чакырмыйсың!» — ди, үпкәләде. Бөтенләй дә буталып куйгалый, бичара. Үлем хәбәредер инде. Ә бүген мине уятты да төшерде: «Китәр вакытым җитте. Мин аннан гафу сорарга тиеш, гөнаһым бар!» — ди. Синең хакта әйтә: «Мин хәтерлим, исеңдәме? — ди.— Ул безнең онык Регина белән озатышып йөрде, Киров урамында торганда, коммуналкада... Үзебезгә дә килгәне бар иде. Ничек бер-берсен ярата иделәр. Ул вакытта араларын мин боздым бит. Чакыр әле үзен!» — ди. Менә, мин артыңнан төштем...

Ханбал боларны яхшы хәтерли иде, әмма ул вакыттагы үпкәсе күптән онытылып, язмышка буйсынганлыктан, бу урыс әбисен бер дә күрәсе килмәде. Аңа анда ни калган? Чыннан да, барсыннар да рухи аталарын, поп дигәннәрен чакыртсыннар, шуңа сөйләсен, әмма Ханбалның үзенә түгел.

— Юк, мин бармыйм...

Урыс карты моны ук көтмәгән иде бугай, аптырабрак калды. Ничектер авыр итеп егеткә карады. Ханбал аның карашларын күтәреп калырга җыенмады; яки ишеген бикләп куярга, яки барырга туры килер инде. Тапканнар поп. Урыс булып яшәп тә үз диннәрен белмиләр!

— Ярар...— Егет кире уйлады.— Әйдә, күтәрелик...

Тиз генә әйләнеп төшәрмен, дип Ханбал ишеген ачкычка бикләп тә тормады, Федор абзыйның артыннан күтәрелә бирде. Картлачның адымнары авыр һәм акырын иде. Егеткә уйларын тәртипкә салу өчен бу файдага китте. Кичәге рәхәтлекләрнең кабатлануларын теләп хыялланып маташкан җиреннән, мәхәббәт романтикасын ташлап, тормышның үзәгенә төште. Регинасы күз алдында изге сурәт рәвешендә яңарып, ачуланышкан көннәре хәтерендә яңарды...

Алар университетның икенче курсында укыган вакытларында таныштылар, дөресрәге, күптән таныш булып та, бер-берсен читтән генә күзәтеп йөри иделәр, Аллаһы тәгаләнең изге бер сәгатендә, икесенең дә ялгызлык сизгән чакларында, төп бина каршындагы бакчада утырганда сөйләшеп киттеләр. Регина, язгы зачетларга әзерләнгәндәй, дәфтәр-конспектларын актарып маташа иде. Ханбал көлеп кенә:

— Килеп тә җиттеләрмени? — дип сорады.— Ярты ел укымаганны бер көндә ерып чыгабызмы?

— Үзең кем? Шундый ук түгелмени?

Регина аның төрттергән сүзенә шул ук рәвештә җавап биргәнлектән, егет аптырабрак китте, теле көрмәкләнде, әмма җиңел генә бирешәсе килми иде. Тик нәрсә әйтергә дә белмәде. Тагын шулай каты бәрелсә, студентканы үпкәләтергә мөмкин иде. Күңеленнән юньлерәк сүз эзләп карады, тик бер нәрсә дә исенә төшмәде. Ахмаклыгына акылы шашынды, әмма чишелеш үзеннән-үзе килеп чыкты.

— Мин дә шундый инде...

Кызга аның сүз башлавы ошамады. Җавап биреп тормады, конспектларына чумды. Егеткә, ычкын моннан, укырга комачаулама, дигән төсле карап кына куйды, әнә шулай Ханбалны үзенә бәйләде дә куйды. Ничек болай булды соң әле бу? Кызны үпкәләткәнлеген аңлап, гафу үтенү җаен эзләде. Берәү булса, торып кына китәр, сөйләшеп тә тормас иде. Ә Ханбал да, Регина да алай эшләргә җыенмадылар. Берсе һаман конспектларын актарды, икенчесе аны күзләвендә иде.

Май җиле исеп, якын тирәдә генә үскән агачлардан хуш ис алып килде. Регинаның калын һәм кабарынкы чәчләрен күтәреп-күтәреп туздырды. Кыз аның саен аларны кулы белән бастырып куярга тырышты. Әмма дәфтәрләреннән аерылмады. Ул да түгел, тагын талгын искән май җиле көчәйде, Регинаның чәчләре Ханбалныкына уралды, битен каплады. Егетнең күңеленә рәхәт булып китте. Чәчләрдән килгән саф һәм күз-башын томаландырырлык хуш ис Ханбалны хәрәкәтсез итте. Күпме шулай дәвам иткәндер, егет бу хакта уйланмады, бәлки кызның аларны җыеп алмавын теләде, бөдрәләрен акырын гына үпте һәм: «Шушы рәвешле чәчләребез чәчләргә бәйләнсә иде!» — дип теләк теләде. Ул да түгел, аның пышылдаганын тәгәл ишетмәсә дә, Регина башын күтәреп, нәрсә эшли икән, дигәндәй аңа карады, тизрәк гафу сорарга ашыкты:

— Һай, үпкәләмәгез инде, мин бит белмәдем! Бигрәк онытылып киткәнмен! — дип чәчләрен толымга җыештырып алды, икенче ягына әйләндереп төшерде дә, түш кесәсеннән тасма чыгарып, очларын шуның белән бәйләп куйды. Бу хәрәкәтләре егетнең бәгыренә үтте, исен-хушын алды. Ул хәзер кызның каршысына егылырга һәм мәхәббәттә ант итәргә әзер иде, әмма рыцарлар заманы узган булу сәбәпле, үзен тиз кулга алырга өлгерде.

— Зыян юк!

Регина аңа күтәрелеп карады. Нәрсә әйтә икән бу дигәндәй бераз гына уйлап торды, сорамакчы идеме Ханбалның ни өчен шулай дип сүз катканын?

— Чәчләрегезгә, мин әйтәм, чәчләрең бәйләнүдән!

— Ә-ә, — дип сузды кыз, — көне җилле бит, күтәрәләр дә алалар, күтәрәләр да алалар.

Язгы кояшта студентлар янына җылынырга килгән күгәрченнәр гү-гү сөйләнеп, гөлдер-гөлдер серләр алыштылар. Аларга рәхәт, зачет-экзаменнар белән баш катырасылары юк. Яратышалар, кочышалар инде. Оя коралар.

— Күгәрчен тотып биримме?

Ханбал нәрсә әйткәнлеген үзе дә белештерми калды бугай. Хәзер йөрәгенә курку йөгерде: әгәр дә кыз: «Бир тотып!» — дисә, сикерсенмени артларыннан?

— Мәче түгелсездер ич?

— Шулай да...

— Кирәкми, күрмисезмени ничек тату гөрләшәләр... Абау, күзләре кызыл, кып-кызыл икән боларның!

— Әллә беренче тапкыр күрәсезме?— Ханбал бу юлысы кеткелдәргә һәм кызны үпкәләтергә бер дә җыенмый иде, әмма Регина сүз күтәрә торган кеше булып чыкмады, ахрысы.

— Күрсә соң аның ни гаебе бар?..

— Юк-юк, дөрес әйтмәгәнмен икән, гафу итегез...

Кыз җавап бирмичә, тагын конспектларына чумды, егет үзалдына янып-пешеп утыруын дәвам итте. Хәзер аны Регина үзенә бәйләп куйган, буйсындырган, аягыннан еккан иде. Карашы аннан аерылмады. Күзләре һәр йөз сызыгын өйрәнде. Абау, бит очында матур гына кара миңе дә бар түгелме соң? «Йөзкәен ак, бит очына миң яраткан...» Шулайрак булса кирәк Дәрдемәндтә, нәкъ шундагыча түгелме соң бу сызыкларының дәвамы да? Күкрәкләре дә киң, чәчләре дә калын һәм озын! Бу кыяфәтне ясаучы ата белән ана, әллә табигатьме, бер генә кызганмыйча, камиллекнең барлык мөмкинлекләрен файдаланганнар, дөрес эшләгәннәр!

Юктан сүз алмашу белән башланып киткән бу утыруында Ханбал чын мәгънәсендә саташып, үз-үзен бутап, гашыйк булып бетте. Чынбарлыкка караганда хыялы күбрәк тәэсир итте. Хисләрен алдады һәм хисләрендә алданды. Аның шушындый көне, шундый сәгате идеме, билгесез, әмма гашыйк бизгәгенә кабуы чын иде.

Алар матур гына йөреп киттеләр. Регина географакта имтиханнар биргәндә Ханбал аны көтеп ала, озатып куя башлады. Кайвакыт егет янына килеп, тулай торакта кечкә кадәр утыра, хәтта Ханбалга имтихан сорауларына әзерләнергә дә комачаулый торган иде.

Җәйге ялдан алар бер-берсен сагынып килделәр, бу мәхәббәтләренең дәвамы гаилә төзү белән тәмамланырга тиеш булса да, көтмәгәндә кыз егеттән баш тартты. Регина, мәктәпкә йөргән чакларында, җәйге ялларга авылдагы татар әбисенә кайта, татарчаны су кебек эчә иде, университетка укырга кергәч, Казан әбиләрендә яшәве аркасында тормышка карашлары үзгәреп бетте. Әмма Ханбал белән ике телдә дә сөйләшә иделәр. Егет белмәде, сораштырырга кирәк тә санамагандыр, кызның бит исеме чит телдән алынган булса да, фамилиясе татарча — Әмирова, әтисенең исеме дә татар — Гали, ә әнисе ягыннан урыслар икән. Регина аны Казан әбиләренә алып кергәч кенә белде. Кызларын татарга кияүгә биргәч, үзенә дә яхшы мөнәсәбәттә булырлар дип уйлаган иде дә, киресенчә килеп чыкты. Регинаның Казан әбисе шунда ук Ханбалны яратмады һәм кире какты, бер-ике тапкыр авыр карашлары белән карап куйды да, шуның белән бетте, чәйгә дә чакырмады. Шуннан соң бозылыштылар алар. Регина егет белән бөтенләй дә сөйләшмәс булды. Инде дә артыннан Ханбал, кат-кат килгәли, ялына башлагач, әйтеп салды:

— Минем яраткан егетем бар, сине алдап кына йөрдем. Болай, вакытны уздыру өчен генә... Эзләп, аптыратып йөрмә,— диде һәм елыйелый йөгерде.

Ханбал үпкәләде, моңарчы бу кадәр дә ахмак хәлдә калганы булмаганлыктан, ни эшләргә белмәде. Хәтта университетын ташлап, каядыр олагасы да килде. Әмма вакыт савыктыра икән. Очрашмагач, аның хакында уйламагач,— ә уйлата иде, бик уйлата,— Регинаны оныта төшеп, башка беркайчан да кызлар белән буталмаска үз-үзенә сүз биреп, тынычлыкка иреште.

Баскычтан күтәрелгәндә Федор абый туктап-туктап ял итте, Ханбал аны узып китүне кирәк санамады. Фатирларының ишеге бикле түгел икән. Эчкә уздылар. Урыс йортында әллә ни җиһаз юк инде ул. Әмма Федор абзыйның ике телевизоры, яхшы шкафлары, кухня җиһазлары — һәммәсе дә затлы икән. Электән шулай булгандыр инде.

Ханбал авырып ятучы Марфа түти белән түбәнсенеп кенә исәнләште. Ике ел инде бер йортта яшәүләренә карамастан, алар бик сирәк күрешә, анда да Ханбал эшкә ашыкканда яки ачыгып кайтканда гына. Исәнләшә дә китеп бара. Ни сөйләшсен ул анын белән? Теге вакытта, беренче очрашканда яхшы кабул итсәләр, хәзер бәлки башкачарак та булыр иде. Ярар, үткән эшкә салават!

— Якынрак килегез...

Урыс карчыгының тавышы борчулы һәм моңсу иде. Фатирлары да караңгыланып киткән төсле. Үлем вә кабер тынлыгы иңгәнгәме, җан өшеткеч, әмма тынчу. Шулай да Ханбал үзен якын кешеләрә кебек тотарга тырышты. Әби янына килешли өстәлгә күз ташлады. Анда ике телеграмма ята иде. Язулары ачык күренеп, аларга катнашы да булганга, Ханбал иелеп укыды: «Борчылмагыз, атна ахырында кайтабыз. Көтегез».

«Барып җиткән икән»,— дип уйлап куйды егет, икенчесен кулына да алып тормастан. Әчтәлекләре бер үк төсле дер инде!

Урын янына утыруга, Марфа түти егетнең кулларын эзләп тапты, салкын бармаклары һәм учларыннан Ханбалның җанына курку йөгерде. «Нигә чакырган инде бу карчык аны? Ни эше бар?»

— Шикләнмә, улым...

«Нинди «улым» ди ул аңа? Ярар, итагать өчендер инде!» — Ханбал, күзләреннән бу карчык сизенер, нәрсә уйлаганын белер йә, дип башын түбән иде.

— Аллабыз Христос белән үтенәм, гафу ит мине, улым!..

«Нәрсә өчен гафу итәргә тиеш әле ул аны?»

— Синең бәхетеңә мин аркылы төштем. Мин сине Регина кызымнан аердым...

Карчыкның тавышы авыр гына ишетелә, салкын чыга иде. Аның пышылдауга тартым сүзләрен Федор абый колакларына кулларын куеп якынрак килеп тыңларга тырышты, әмма моны Ханбалдан ятсынып кына эшләде. Егет башта Марфаның әйткәннәренә игътибарсыз утырды. Тик үлем хөкеме аның бәгырен умырып алды һәм, эшнең нәрсәдә икәнен төгәл аңлап, Ханбал әйтеп салды:

— Нигә? Ни өчен?

Аның болай соравын әби көтеп торган иде булса кирәк, бер дә селкенмәде, күзләрен дә шардай ачмады, авыр һәм салкын сүзләрен дәвам гына итте:

— Әтиең аркасында...

— Аның ни гаебе бар?

Бу юлысы әбинең күзләрендә аптырау иде. Ханбалның бернәрсә дә белмәвен тәмам төшенеп җитте. Бу нәтиҗәсеннән соң болай да авыр уйлары оеган куркаш халәтенә керделәр. «Димәк, бу егет бернәрсә дә белми, Регина артыннан да чын күңелдән йөргән! Юк-юк, дөрес түгел, алдарга, мыскыл итәргә генә шулай кыланган ул! Агачыннан алма ерак тәгәрәми! Әтисе аны ничек мыскыл итеп китте, бусы да шул буласы иде. Әле дә ярый вакытында комачаулап калды, оныгын коткарды!» — Әлекке уйлары яңадан кабарып чыктылар, Марфа, үтенәсе җирдән, егетне ачуланып ташларга уйлады. Әмма үлемнең салкын кулы бу кызулыгын шунда ук суытты һәм тагын бераз вакыт бирде. Әгәр дә ярлыкау үтенәсе бар икән, ул аны хәзер эшләргә тиеш, аннан соң кирәк тә булмавы мөмкин!

Ханбал, Марфа түтинең күзләре артык зур ачылганын күреп, куркарак калды. «Үлеп китә бу карчык, үзеңне гаепләүләре бар!» — дип бүтән алай орылып бәрелмәскә күңелен ныгытты, тыңлап бетерергә дә чыгып таярга гына кирәк.

— Мин синең әтиеңне белә идем, Самуил иде!

«Нинди Самуил ди ул тагын? Ханбалның атасы татар һәм чын мөселман иде! Нәрсәдер бутый бу карчык!» — егет кире кагарга ашыкты.

— Юк, әтиемнең исеме Исмәгыйль, Вәлиев Исмәгыйль Надыйрович!
Әмма урыс карчыгы Ханбалның сүзләренә колак та салып тормады, үзенекен сөйләүдә булды:
— Ул минем беренче һәм яраткан ирем иде! Син аңа бик охшаш, чәчең дә, борының, авызың — барысы да. Безнең Регина белән килгәч, сине шунда ук таныдым. Әгәр әтиең алдап качмаса, бәхетеңә аяк чалмас идем мин. Ачуым килде. Регинага әйттем... Егетнең күңеле чиста түгел, дидем. Минем һәрвакыт дөрес сүзле икәнемне белә иде ул. Ни дисәм, шул була иде. Ә синең хакта юри ялганладым, ә ул шуңа ышанды, елады... Аны да мин бәхетсез иттем. Ирен яратмыйча яши. Һаман сине исенә ала. Үзе сер бирмәскә тырыша. Кызлары бар. Тормышларының яме юк... Әбигә бу сүзләрен әйтүе авыр иде, тамагы кипте, әмма сүздән туктамады, Ханбалның кулын да җибәрмәде.— Мин синең әтиеңне бик ярата идем, ә ул яратмаган, күрәсең. Татар кызын онытa алмагандыр инде...— Ул кызның нинди бәлаләргә тарыганын белсә дә, Марфа түтәй Ханбалга әйтергә теләмәде.— Аңа булды шул... Самуилдан башка яши алмам дип уйлаган идем, үтте дә китте бит. Яшәдем. Язмышым шулай язылгандыр... Сезнең дә язмышлар Регина белән бергә иде бит. Юкса күршем булмас идең. Аллабыз шулай кушкан. Ул вакытта ялгышмасам, болай ук килеп чыкмас иде. Аллабызга каршы барганмын шул. Гафу ит мине, улым, ялгышымны төзәт, бу дөньяны гөнаһым бар килеш калдырасым килми. Ә калганнары, ни күрдем, бу — минем тормыш. Бер гөнаһым — анысы да шушы... Улым, гафу ит?
Ханбал башын гына селкеде, әмма аңа хәзер барыбер иде. Әгәр дә үзен Регина яраткан булса, әбисенең сүзенә карап тормас иде бит, шулаймы? Димәк, сөюләре шулкадәр генә булган. Узганны кайтарып алу мөмкин түгел, киселгән икмәк ябышмый. Шулай да гафу итәргә тиеш ул Марфа түтине. Башын селкеп кенә түгел, теле белән әйтеп.
— Әгәр шулай тиеш икән, гафу итәм...
Әби кузгалып куйды, әмма йөзенә нур һәм елмаю йөгерде.
— Юк, улым, миңа сүз бир! Регина мине гафу итәрлек булсын. Өйләнешегез! Гаилә төзегез, шул вакытта мин дә ярлыканырмын!..
Марфа түти күзләрен йомды. Ханбал аның бу сүзләреннән соң сикереп диярлек торды, аның куллары үлеп ятучы әбинең салкын учыннан азат иде. Артка чигенде. Әмма шул вакытта Марфа түти зәңгәр күзләрен яктыртып ачты, алар пыяла төсле ачык иде.
— Китмә, улым, китмә... Мине чукындыр, кулың белән йөртеп. Менә болай ит!
Ханбал шашынып дәрәҗәгә җитте. Мөселман башы белән нигә ди әле чукындырсын ул аны, булмаганны!
— Синең рухи ата түгеллегеңне беләм. Шулай да... Синең-минем диннәребез моңа каршы түгел!
Марфа түтинең таләбе котчыккысыз авыр иде Ханбал өчен. Әмма чыгып йөгерә алмады. «Кайдан аңласын ди бу коммунистка ислам динен, үзенекен белүе дә чамалы гынадыр әле!» — дип офтанды. Ул аның шәхес культы корбаны звонарь кызы икәнлеген башына да кертеп карый алмый иде. Федор абзый шунда Ханбалның кулыннан тотты һәм карчыгының өстендә тәре хәрәкәте ясап йөрттерде. Егет курка калды. Әмма Марфа түти күзләрен ачты һәм:
— Рәхмәт,— диде.— Ә хәзер бәхил булыгыз...
Тагын күзләре йомылды. Ханбал ишеккә ташланды һәм фатирына төшеп, ванна бүлмәсенә ашыкты, кулын сабынлап юарга кереште. Үзен, гүяки, сихерләнгән кеше кебек тойды.
Кичкә Марфа түти бу дөнья белән мәңгелеккә саубуллашып, үзләренең Христослары каршысына китеп барды. Зарыгып көттергән балалары икенче көнне генә килеп җиттеләр. Подъезд төбенә кызыл өсле, кара тәреле табут капкачы чыгып басты, күрше-тирә һәм кардәш-ыруларыннан күренеп-китеп йөрүчеләре күп иде.

## 18

Марфа әби бу фани дөньяны ташлап киткәндә Ханбалны авыр уйларга салып калдырды. Ул бары тик үзенә кагылышлы нәрсәләрне генә аңлап, сүзнең бүтәне ни хакында икәнлеген ачык белә алмады. Һәрхәлдә, әнисе офтанган вакытларында әтисенә бер маржа хакында исенә төшергәли торган иде. Вакытыннан элек агарган чәчләрен Ханбал әүвәле шул маржадан күрә, әнисе Гөлсараны кызганып елый, әтисе Исмәгыйльнең ни сәбәпле эчкәнлеген дә белми, аңламый иде. Хәзер аларның бөтенесен шушы мәрхүмә маржа тутәй Марфага йөкләде. Әтисенеке түгел, хәтта язмышы да бу хатын белән килеп бәйләнгәнлеге сәбәпле аңа карата бер генә хөрмәт хисе калмыйча, үлгән кеше артыннан начар сүз әйтеп озату ярамаганга гына тыелып, ачуы вә әрнүләренә таш бастырырга тырышты.

Әмма монда Марфа тутинең гаебе аз иде. Төп сәбәп — аның Самуилга карата гомере буе саклаган мәхәббәтенең ахыр чиктә тыела алмаслык нәфрәткә әйләнеп китүе иде. Берәүләрне сөю мәңгелек сәгадәткә китерә, башкаларныкы Аллаһы тәгаләгә карата гыйшык тоту, гыйбадәт итүгә әверелә, кемнәр мәхәббәтне чиксез диңгез кебек күреп, күбәләк төсле, бер чәчәктән икенчесенә күченеп оча бирә. Ә Марфаныкы нәфрәткә әверелде. Алай да булгалый икән бу тормышта, берни кылырга мөмкин түгел.

Көтте бит ул, бик көтте Самуилның төрмәдән чыгарылып, туган авылына кайтып төшәсен. Инде дә хәбәр-хәтере ишетелмәгәч, жыенды да туры аларның авылына китте. Салкын октябрь ае иде. Җир туңдырырга өлгергән, әмма кар күренми дә күренми. Гүяки, ул да Самуилның кайтканын көтә. Ә Марфаның түзәрлеге калмады. Тотты да, көн уяна башлаганчы китте чыгып туры аларның авылына. Бәлки кайткандыр, сәламәтлеге яхшы түгелдер, өендәдер? Марфасын сагынган, үлеп көтә, килеп күренер дип уйлыйдыр?

Миләшләре яфрак койган, әмма тәлгәшләре кып-кызыл булып утыра. Карны көтәләр, аннан соң җыярлар үзләрен.

Әнисе идәнгә чүгәләп утырган хәлдә зур табаклар юып маташа иде, Марфа килеп кергәч, аптырабрак китте. Ник урысча бер кәлимә сүз белсен. Йортта тагын да икенче кеше, Самуилның сеңлесе бар икән. Сабыр һәм күндәм генә кыз бала. Алар бер-берсен танымасалар да, кемнәр икәнлеген сизенеп, күңел белән тоеп белделәр.

— Кызым, бу бала, теге күрше авыл урысларныкы, абыеңның йөргәне булса кирәк, бар әле, укытучы апаң Санияне чакыртып кил. Әйт, безгә, диген, бер Марфа апа керде, телен аңламыйбыз, күреп чыксын әле. Ашык, мәктәпкә китеп барганчы...

Марфа янына артсыз урындык китереп куйдылар. Өстәлгә чакырып маташмадылар, бер почмакка гына утырттылар. Артыгы Марфаның үзенә дә кирәк түгел иде. Төенчеген тезләренә куйган хәлендә бер-ике кәлимә сүз әйтеп карады, ана кеше аңламады.

— Әллә нәрсәләр ди инде бу? Берәр кирәк әйберсе бар микәнни?

Алар карашып алдылар. Марфа үзенең һичнәрсә аңлата алмаганын төшенде, ана ни диярга дә белмәде. Күзләреннән күреп тора, бу бала татарча аңлый төсле, әмма нәрсә дияргә үзенә?

— Чәй яңартыйм әле булмаса, самавыр куеп җибәрим! Хәзер, балам, укытучы бар бездә, бик яхшы мөгаллимә, урысның үзен сатып җибәрерлек. Кала кызы. Сөйләштерер ул үзеңне. Ә мин самавыр куя торыйм, хәзер...

Өстәл башыннан самавыр кузгатып, аны мич янына китерә-китерә сөйләнде ана. Су өстәп, алдан телеп куелган чыраны ут йөгертеп мәш килде. Марфа урыныннан кузгалып куйды, ана кулыннан алып, үзе эшләргә теләде, әмма ярыймы-юкмы икәнлеген белмәгәнлектән, урындыгында кала бирде.

Килеп керешкә җылы кебек тоелган караңгырак өй эче акрынлап яктыра бирде. Ул да түгел, ишектә мөгаллимә Сабира ханым күренде, исәнләшеп түргә узды, Марфаны да үз янына чакырды һәм сораштыра башлады, йомышын белеште.

— Камилә апа, бу сезнең улыгыз Исмәгыйльне бик яхшы белә торган кеше икән,— дип тәрҗемә итәргә кереште ул.— Киленегез буласы икән дә, Исмәгыйльне алып киткәч, аны да милициягә чакырткannar, чыгарачаклар, дип әйткәннәр иде, кайтмадымыни, ди.

— Кайтмады шул әле, Сабира кызым, кайтмады. Гөлсараның әбисе дә килеп әйткән иде, кайталар, дип, кайтмады шул әле, кайтмады. Бер дә хәбәр-хәтере юк. Чыгарганнар, дип, әйтә, ди югары оч Зарифулла, калада күргән үзен, кайтыр октябрь бәйрәменә, диләр. Күренми бит әле. Шунда эшкә урнашкан. Ярамыйдыр инде, ярамыйдыр. Бер дә күренерлеген калдырмадылар шул. Ничек кайтсын, ди мондагы халыкның кем икәнлеген белмимени ул, тагын башын ашаулары бар.

Сабира мөгаллимә озак сөйләнгән сүзне урысчага ике авыз сүз белән генә әйтеп бирде, әмма Марфа моның белән канәгать кала алмый иде. Казандагы адресын сорады. Шушы көннәрдә үзе барып, эзләп табарга ниятләде.

— Нинди адрес, ди, инде ул,— дип каршы төште ана, бер дә өнәмичә.— Марҗа башы белән минем улымның башын катырып йөрмәсен, беткәнме үзләрендә егет. Бернинди адрес та юк! Булса да бирмәс идем.

— Камилә апа, алай әйтмә әле син,— дип тынычландырырга ашыкты Сабира мөгаллимә.— Урыс булса да, начар түгел бит. Бәлки улың аның белән бәхетле булыр...

— Телен белмә, сүзен аңлама, нәрсәгә кирәк ул,— дип кабарды ана, сөйләшергә дә теләмәгәндәй, аркасы белән басты, йөзе тәрәзәгә чумгандай иде.— Улымның башын шул кара урыслар гына ашады. Аны чиркәү картының кызы, дип әйтәләр бит, үзем исән чакта, ничек итеп йортыма түре кертим, ди инде, уйлап кара, Сабира кызым. Юк-юк, нинди атабабадан күрелмәгән эш, ди, ул? Әйтмәгез дә, кирәк тә түгел. Белмәдем мин аны урыс авылына кызлар янына йөри, дип, белмәдем. Мондый бәлаләргә очрамас иде. Чыгып китсен, күземә күренмәсен, килеп тә йөрмәсен. Исмәгыйль улымны Гөлсара белән яши башлаган, дип кайтып әйттеләр инде. Шулайдыр. Йортка марҗа керткәнче, балалы хатын алып кайтуы мең артык. Гөлсара белән кавышсыннар да торсыннар, бер сүзем юк, әмма марҗаны аяк бастырасым юк! Әйт үзенә, кызым, әйт, бер дә куркып торма.

— Ни бит, Камилә апа...

Сабира каршы чыгарга тырышып карады, аңлатырга алынырга маташты, әмма карчык аны тыңлап та тормады, үгетләренә бер дә колак салырга җыенмый иде.

— Әйт-әйт, бер дә шикләнмә, кызым Сабира. Туп-турысын әйт, йортка марҗа кертәсем юк, йөрмәсен дә, сорамасын да! Улым Исмәгыйль өйләнгән инде, Гөлсарасы белән Казанда яшиләр, дип әйт!

Сабира боларны туп-туры тәрҗемә итүгә, Марфаның бөтен тәне буйлап оят һәм курку йөгерде. Алты күзнең текәлеп каравыннан ятсынып, чыгып чабарга талпынды. Үз-үзен белештермәде. Ничек болай эшләде әле ул Самуил, ярата иде бит, өзелеп-өзелеп ярата иде. Марфаны нигә алдады, ни хакы бар иде? Әгәр дә Гөлсарасы якын икән, нигә үзенең башын катырды? Әйтсен иде, курыкмыйча!

— Чәйгә утыр, чәйгә!.. Чай салдым...— дип, ана үзе дә урысчага күчкәндәй сөйләнеп калды, Марфа саубуллашмыйча да чыгып китте. Авыр вак адымнары читән янына китерделәр. Казык башында ике бөртек чәчәк һаман да җилдә тибрәнә иде. Аларны алырга Марфаның көченнән килмәде, ярым ачык җилкапкадан чыгып, үз авылларына таба атлады, башына бер фикер, бер уй кермәде. Күч алдында Самуилның күркәм йөзе, колагында: «Мин ничек яратам, синнән башка

яши алмыйм!» — дигән сүзләре генә иде. Яши алмыйм дисә дә бик әйбәт торып ята икән бит әле. Төрмәдән чыгуга, эзләп тапкан Гөлсарасын, бер дә аптырап калмаган.

Шулай ачуланса да, Марфа күп нәрсәне белми һәм төшенә дә алмас иде. Исмәгыйльне Казанга китергәч, аның урыс авылында янгын чыгаруын газетада язып чыктылар. Шуннан белеп, авыллардан килеп китеп, очраштыргалап йөри торган Зарифулла абзыйдан барысын да кабат ишетеп, аны Гөлсара эзләп тапты. Төрмәгә төенчек белән кара ипи, бераз май, шикәр керткәләп йөри башлады. Чыгарасыларын белгәч, көтеп алды. Котылуын котылды Исмәгыйль, әмма аңа Казанда калырга боердылар. Кеше өстенә кеше яшәгән калада фатир табылмады. Бу вакытта заводка килеп урнашкан Гөлсараның бер бүлмәле торыр җире бар иде. Исмәгыйль шунда калырга мәҗбүр булды. Марфа утырып кайткан теге көндәге татар әбисе белән бабасының арбасы шул Гөлсараның туганнары иде. Алар барысын да белешеп, кызга, кияүгә чыгарга ниятләгән исерегеннән котылып, Исмәгыйльне ычкындырмаска киңәш иттеләр. Шулай итеп, вакыйгалар үзләре Гөлсара файдасына тәгәрәде. Марфа авыру хәлендә калды.

Ничек кайтып, кайда егылганын белмәде ул. Ничек итеп татар йорты аны кабул итсен, ди инде? Кайда һәм кайчан күренгәне бар андый хәлнең? Шәһәрдә генә мөмкиндер ул мондый бәхетләргә ирешү...

Марфа авырып китте, күңеленең бозылуы, хәтеренең чуалуы аны тәмам эштән чыгарды. Ул һаман,— ил өстенә ак кар ятып, суык кыш башланып китүгә карамастан,— үзенең түрдәге чаршау артына көйләнгән урынында авырый бирде. Дөньяның кызыгы һәм рәхәтен тәмам югалтып, җанын алырга хәерсез үлемнең килүен дә теләде, тамактан калды, ябыкты, агарды. Берәүләр мондый хәлдән ямьсезләнеп китсәләр, ул, киресенчә, унсигез яшьлек кыз, чибәрләнгәннән чибәрләнде, күрер күзгә изге иконадагы Мәрьям-ана сыйфатлары керде. Озак ятып арыган тәнен язар өчен төннәрен торып утыргалаган чакларында, уянып китеп, ут кабызган әнисе аның шундый кыяфәтен күрүдән егылып китәрдәй булды. «Бу бала бер дә мантымас, ахры, тиздән аерылырбыз кебек тоела!» — дип иренә дә сөйләде, аны да шиккә салды. Ул юрауларга карамастан, яңа ел алдыннан, халык бәйрәмнәр ясый башлаган көннәрнең берсендә Марфа иртән аягына басты, юынды, өстәл артына килеп утырды. Моны көтмәгән һәм кызларының авыру булуы белән тәмам килешкән әти-әниләре хәйранга калдылар. Моңа кадәр чукынуны гадәтләреннән төшеп калдырган итсәләр дә, куллары үзләреннән-үзләре хәрәкәтләнде.

— О, Святая дева-Мария![1]..— диде әнисе, әллә кызына, әллә Христос анасы Мәрьямгә сүз юллап.

Кызлары моңа игътибар бирмәде. Туры вә төз аркасын билдән алга бөгеп баш какты, чәй ясады, әти-әнисенә кушылып эчә башлады. Алар бер генә дә сүз әйтергә кыймадылар. Гүя, бу үз кызлары түгел, бәлки аларның табынын уртаклашкан изге зат иде. Чәй тәмамлануга, Марфа шул ук рәвешен саклап кузгалды, рәхмәт әйтте һәм башын иеп кенә:

— Яхшы сәламәтлекләр сезгә, анам! Яхшы исәнлекләр сезгә, атам! — дип сәламләде дә киенә башлады. Әти-әнисе аның чиркәүгә барачагын күзаллап, туктатырга да, аркылы төшәргә дә белмәделәр, гыйбадәтханәләренең күптән инде җимерелә башлавын, анда колхозның ашлык амбары икәнен дә оныттылар. Гүя, менә хәзер чаң кага башларлар төсле иде. Әмма ялгыштылар. Марфа комсомол ячейкасы урнашкан йортка таба китте һәм аннан кич белән генә кайтты. Уйнак Федор, бер артына, бер алдына төшеп, аны озата килде. Марфа сер бирмәде, әмма аның йөзе алсуланып нурлана, җаны яшәү дәрте белән тулы иде.

---

[1] Йа, изге Мәрьям-ана!..

Әти-әнисе моңа да хәйранга калдылар. Һичбер вакыт кызларын бер генә эштән дә тыймаган, үз башы — үзендә, дип яшәгән җирләреннән, бүген кайларда нәрсә кылып йөргәнен сорарга теләделәр. Әмма батырчылыклары җитмичә, вакытыннан элек урыннарын йомшартып, менеп яттылар да бер-берсенең кочагына чумдылар. Ә Марфа кич буе китап укыды, бары тик әтисе икенче тапкыр сәерсенеп ишеген ачып карагач кына йокларга кирәк икәнлеге белән килеште, әмма күзләре озак йомылмыйча, әллә нәрсәләр уйлап бетерде.

Аларның өйләре алты почмаклы, ихаталары ныклы, такта койма белән әйләндереп алынган — бабасы звонарь мирасы иде. Марфа үзләрен Самуиллар белән чагыштырды һәм үзе дә сизмәстән ятсынып куйды: «Менә, дурак, менә дивана! Ахмак түгел диген инде син мине! — дип акылы шашынды.— Кем соң аның алдында Самуил, мескен татар, кем соң ул? Саташу, саташу гына һичнәрсә түгел! Аяк астына палас итеп ташларга да яраклы түгел бит ичмасам, басурман!» Марфа үксеп елап җибәрде, авызына ястыгының тышлыгын кысты, йөрәге белән акылы тарткалашты. Иртән уянган чагында ул үзенең кайчан һәм ничек йокыга киткәнлеген аңлашмый торды, бөтен гәүдәсендә авырлык тойды. Берәүләр ял итеп, рәхәтләнеп караваттан кузгалалар, ә ул ватылып, арып аягына басты. Әниләре белән утырып чәй эчте, үзен кичәгечә тотты, шул ук сүзләрне әйтеп, өстәл артыннан купты һәм киенеп чыгып китте. Әмма бу юлысы әтисе түзмәде, артыннан:

— Озак йөрмә, кызым! — дип калды. Бу хәлләрнең мәхәббәт галәмәте икәнлеген аңлый иде булса кирәк.

Шулай кыш үтте, яз да китте, җәй җитте. Самуил килеп күренмәде, Марфа кабат аны эзләп бармады, сораштырмады. Язмышы һәм бәхетсез мәхәббәте белән килеште, әмма кайчан да булса аларны язмыш очраштырачагына ышанып, юлына, бәхетенә аркылы чалынып, үз хәленә төшерергә һәм ялындырырга ниятләп куйды. Тик уе барып чыкмады, тормыш аның бу теләгән еракларак, гомере ахырынарак саклап калдырырга, кичектерергә мәҗбүр итте. Башланып киткән яңа сугыш бар халыкны берьюлы мең бәлаләргә салды. Язлыкта тимерчелеккә ярдәмче эшкә билгеләнгән Федяның аягына эскәнҗә төшеп сындыруы һәм аның кыек ялгануы аркасында, Марфа кормасыннан бердәнбер егет буларак, ул гына сугышка алынмыйча калды. Самуилның беренчеләрдән китүе килеп ирешсә дә, кыз моңа игътибар итмәскә тырышты.

Ул вакытта сугышның бүген-иртәгә бетәсенә ышана иделәр. Әмма үлем хәбәрләре дә килгәләгәне ишетелә башлады. Районга аның иң беренчесе Камилә анага килде. Самуилның һәлак икәнен бөтен тирә-юнь сөйләде. Ул «похоронка»ның кул арты — бу очракта шушы сүзне куллану уңышсыз икәнен беләм, әмма дөрес бит — җиңел булып чыкты, алар бер-бер артлы килә башлап, һәркем хәсрәтен үз авылында, яки үз йортында гына йотты. Урысларның түр почмакларына иконалар менеп кунаклады, татарларда әбиләр намаз һәм уразаны калдырмый, оныкларына да өйрәтергә тотындылар. Тик Марфаларда гына бар да элеккечә калды. Сугышка йөрү өчен әтисен картка санадылар, гаиләләрендә бүтән ир заты юк иде. Әмма әнисе почмакка сүрәт утыртканын күргәч, кызлары аны шундук алып ташларга боерды. Ул инде хәзер ирләрчә киенеп, чыгымлаган атларның да тезгененә генә басып сөйләшә, кырчылык бригадасына бригадир, фермаларга мөдир, алачыкта тимерче, эттән усал бер нәмәрсәгә әверелгән иде. Болай барса, колхозларына рәис тә булып алырга мөмкинлеге бар иде. Әмма Федор аннан хәйләкәррәк эш йөртте, кызны үзенеке итүнең чарасын тапты.

Моңа кадәр ничекләр генә кыланып карамаган иде ул, берсе дә барып чыкмады. Кырык өченче елдан авыл советына рәис булып куелгач, Марфа белән үзен язылышкан рәвештә документ та тутырмакчы иде, моның бернәрсә дә бирмәячәген төшенеп өлгерде. Көннән-көн ныгый һәм усаллана барган кызны болай җиңел генә алдау мөмкин түгел шул!

Аяк чалырга, каршысына китереп тезләндерергә иде исәбе, әмма ничек? Эшләгән эшенә зыян салыпмы? Юлын кисепме?

Сорауларына җавап үзеннән-үзе табылды. Ирләрчә кыландыра торган Марфа ара-тирә авызына, ныклык өчендерме, аракы да капкалый икән. Моны белеп алгач, Федорның эченә җылы йөгерде: «Берне эчкән кеше, икенчесен дә йота, исереп тә китә! Сыйларга үзен, сәбәбе килеп чыгу белән үк!» һәм ул шулай эшләде дә...

Салкын январь киче иде. Авыл халкы койма-читәннәрен, лапас-сарай төбәләрен ватып, утынга ягып бетергән чаклар. Ә идарә йортында җылы. Ходайның рәхмәте, ни эш беләндер, суыктан өшеп, Федор янына Марфа килеп керде. Йөзендә арыганлык сизелә. Әмма һаман да күз явын алырлык чибәр, чукынган.

Федор аны күрмәмешкә салышты, бер кәгазьдән икенчесенә саннар күчереп язуда булды. Марфа, җылыдан иркенәеп, өстендәге толыпны салды, почмактагы урындыкка куеп, үз язмаларын актара башлады. Алар бер бүлмәдә кайвакыт очрашсалар да, араларында бәйләнешне кыз беткәнгә санап һәм үзенең кемлеген белеп, егеткә әллә ни игътибар бирми иде. Ә бу юлысы, теленнән шайтан котырттымы, әйтеп куйды:

— Йә, Федор, эшләр тәгәри синең, җылыда гына утырасың! Ә мин өшеп йөрим...

Егет, тол хатыннарны һәм кыз-кыркынны караштырып өйрәнгән мәлгунь зат, ризалашкан кеше төсле елмаеп кына:

— Өшегән кешегә чарасы бер генә инде! — дип өстәлгә бер ярты чыгарып бастырды.— Мә, бурычка булыр!

Нәкъ шушы сүзе белән каптырды да Марфаны. Ул ачуы килеп:

— Сыйлыйм әле үзеңне, диген, юньсез! — диде.— Дусларга бурыч була мыни?

Эшнең ахыры нәрсә белән бетәсен уйлап та тормастан, Федор аракыны стаканга бушатты, үзенә дә бүлде. Марфа, әллә бик туңган идеме, әллә гадәтенә кергәнме:

— Җиңү өчен! — диде дә йотты. Федор калышмаска тырышты. Кыз тәнендә җылылык сизенә башлаганчы икенчесен салды. Дөрес эшләгән икән.

— Су гына бугай бу, Федор, утлы табага баскандай итә торган иде,— дип Марфа монысыннан да баш тартмады, шунда гына тәне кызып киткәнен тойды. Әмма аның арыган тәненә монысы артык иде. Үз өстәле артына утыруга, оебрак китте. Нәкъ шушы сәгатьне инде әллә кайчаннан бирле көткән Федор үз эшенә кереште һәм аны кочагына алып, идәнгә толыпларны ташлап, өстенә ауды. Кызга да наз кирәк булган икән. Ул, кем белән нәрсә кылганын белештерми, егетнең теләкләренә буйсынды...

Федорны иң нык гаҗәпләндергәне шул булды: Марфа кыз түгел иде. Ул бит аның артыннан ничекләр генә йөреп карамады, юлларына тузан булып җәелергә, тәннәренә мунчала кебек уралырга риза иде. Ә ул горур башын югары куеп йөргән иде бит, әллә кем, диярсең. Югыйсә төбе тишелгән, имеш...

— Теләгеңә ирештеңме?

Марфаның төгәл һәм айнык сүзләре Федорны үтереп салды. Нинди теләк монда? Нинди теләк? Ахмакка калды бит ул, ахмакка, эт җан! Кыйнап ташларга кирәк үзен моның өчен, кызлар кебек хәтәр йөргәненә!

Әмма Федорның моңа тәвәккәллеге җитмәде. Марфаның тулып пешкән тәннәренә кулы тиеп китүгә, көче вә гайрәте китте, ачуы сүрелде. Кем белә соң әле аның кыз түгел икәнен? Һичкемнең авызыннан андый сүзнең чыкканы юк! Теге, сугышта дөмеккән татар белсә генә инде! Ул да хәзер сөйләп йөри алмый!

Бу фикерләре Федорны җиде кат күккә чөйде. Ул үзен җиңүче итеп тойды һәм кызның тостын исенә төшерде: «Әйе, җиңү өчен булды бу! Һичшиксез, Федорның җиңүе, ничә еллар күзләп йөргән кызны буйсын-

дыру өчен! Һай-ли, булган кеше дә инде үзең! Дөньялары җиде якка тәгәрәп китсен! Әмма дә теләгенә иреште бит!» Федор кычкырып җибәрергә теләде, хәзер сикереп торып, шушылай салкын карга чыгып аунаса да, аның тәне суынмаячак!

— Теләгеңә ирештеңме?

Марфаның кабатлаган бу соравына җавап биреп тормаса да була! Хәзер ул аныкы. Ычкынырга уйлап кына карасын, халыкка гайбәт таратачак, җанын алачак. «Каптың, кызый, бик шәп эләктең! Бөтен барлыгың белән!»

— Син кыз түгел идеңмени?

Федор Марфага үтергеч сорау ыргытты. Әмма ансының исе дә китмәде төсле, җитмәсә, мыскыллы итеп көләргә дә булдырды.

— Анда синең ни эшең бар? Әгәр дә кызлыгым сакланса, бирешеп торыр идемме сиңа?

Алар тынып калдылар. Бераздан Марфа салынып ташланган киемнәрен киенә башлады. Федор да үз җаен карады. Әмма кызның ычкына баруын тоеп, ничек тә аны яңадан үз тырнагына кайтарырга белмичә аптырады. Мәсьәләне чишүдә аңа тагын үзе дә сизмәстән, Марфа ярдәм итте.

— Кешегә сөйләп йөрисе булма!

— Әгәр дә миңа кияүгә чыксаң, һичкем белмәс!

Моны ук ишетермен дип көтмәгән кыз хәрәкәтсез калды. Федорның авызлары ерылды: «Аһ, эләктеңме, асыл кош!» — дия-дия күңеле сөенде. Марфа нык капты, селкенерлек тә җае калмаган төсле иде. Әгәр дә Федорга туры дәшсәң, теленә керсәң, авылына гына түгел, бөтен тирә-юньне сасытачак. Юк, моны Марфа күтәрә алмый! Самуилның онытуын үткәрә алды, яшь иде, тормышка мәхәббәте көчле иде. Үзе һаман аны ярата иде, яратачак иде. Әмма бу юлы, Федорның берне биш итеп сөйләүләрен белмимени ул! Кемгә кирәк ул хәзер һәм кемгә кирәге булачак? Ирләрнең бәһасе мең алтын чак. Гаилә дә кора алмаячак бит...

— Белмәдем мин синең шушындый кабахәт икәнлегеңне! Һай, ялгыштым! — Марфа офтанып куйды.

— Үлчәп сөйләш! Халык алдында рисвай итәм, югыйсә! Үлчәп сөйләш! — Федор көчнең үз ягында икәнлеген яхшы белә иде, шунлыктан тынычланып алды һәм куркынган кызга саклык белән генә, суга күрмәсен, дип якыная төште һәм назланып кына теләген аңлатырга кереште: — Чык миңа кияүгә, чүк тезеңне, ул вакытта балда-майда гына йөзәрсең, һичкемгә сөйләп йөрмәм, хәтта үзем дә онытырмын!

Марфаның башка чарасы калмаган иде, ул буйсынырга әзерләнде. Моңа кадәр күренә башлаган ирләрчә кылану-кыландыру сыйфатлары, усаллыклары тәмам су белән юылган төсле юкка чыкты, нишләргә дә белмәде. Килешүгә йөрәге каршы иде. Бу сасы исле Федор белән ничек гомер буе яшәмәк кирәк? Җаны да кара бит аның! Бөтен тирә-юньдә Зайцевларның эчкече бер зат икәнлеген беләләр бит! Ничекләр генә шушыңа буйсынсын икән ул? Кайларга китеп олаксын икән?

— Йә-йә, әйт тизрәк, яки миңа кияүгә чыгасың, яки мин сине рисвай итәм, гайбәт таратам, абруеңны сындырам!

Федор ашыктырды. Әйткән сүзләрендә ялган юк, ул боларның һәммәсен, һичшиксез, эшләячәк. Селкенә дә алмаячаксың! Марфа үзен мескен, җебек итеп тойды. Әмма чәчрәп тә китә алмаячак иде ул. Хатыннар арасында шактый буталып, рәислегеннән файдаланып куркытырга, җаннарына үтә белергә өйрәнеп алган Федор тантана итәргә әзерләнде. Хәтта кыз ризалашмаса, алга таба ничек эш йөртергә тиешлеген дә уйлап куярга өлгерде. Бу аның бәхет сәгате идеме, әллә язмышы шушында көйләнеп куелганмы, акылы яхшырганнан яхшырды, теле остарганнан остарды. Марфаны тәмам бутап ташлап, елатыр дәрәҗәгә җиткерде, чарасызлыгыннан файдаланып, үзенең хәйлә вә оятсызлык кайчысы белән йөрәк-бавырларыннан кисkәләгәннән-кисkәләде. Болай да буйсынмаса, ул аның башка юлын белми дә иде, югыйсә.

— Мин риза,— диде Марфа, үзенә-үзе хөкем чыгарып,— теләсәң, башымны кис, әмма гайбәтемне генә чыгарма?!.

Федор кызның сүзләреннән хәйлә сизенеп алды: «Ничек шома котылмакчы була! Ашыкмый тор әле, җан кисәгем, эшне болайрак итәрбез! Бер эләктергәч, җибәрү юк инде, өмет тә итмә, башыңа да кертмә!»

— Мин сиңа кияүгә бүген үк чыгарга риза, дип әйт!

Егет әйтелгән сүзләрен кабатлауны таләп иткәч, Марфа сүзсез торды, әмма ул арада: «Беткән баш беткән инде, минем хәзер кемгә кирәгем бар!» — дип ниятләде дә:

— Мин сиңа кияүгә чыктым, дип исәплим үземне! — диде.

Бүрене еккан куян төсле Федор тантана итте. Ашыга-ашыга лампага ут элде, бүлмә яктырып китте. Караңгы чырайлы оятсыз Федор каршында кар кызы төсле ак һәм чибәр Марфа башын аска иеп тора иде. «Ичмасам ут кына яндырмаган булса да ярар иде, бу шыксызның йөзен күрмәс идем!» — дип уйлады ул. Әмма аның белән бергә гомер буе ничек яшәячәге хакында ваемны башына да кертмәде, анысына караганда монысы әһәмиятлерәк иде югыйсә. Акылы чуалганрак чагы шул!

— Мөһере — үзебездә, кенәгәсе — кулда! Бүген үк теркәп калдырыйк! — дип, Федор кәгазьләрне тутыра башлады һәм бераздан Марфага якынрак килергә кушып, аңа каләм сузды.— Менә монда имзагызны калдырыгыз, сөекле ханым!

— Мондамы? — Марфа менә хәзер ире булырга җыенган бу адәмне урындыгы-ние белән тәрәзәдән алып очырыр иде дә...

— Нәрсә? Имзаңның рәвешен оныттыңмы әллә?

Катып калган кызга Федор таләпчән эндәшергә кирәклеген яхшы белеп эш итте. «Кире уйлап куя күрмәсен тагын!» — дип курыкса да, бу хисен җиңәрлек кенә үзендә көч тапты.

— Ничек дип куярга? Волковамы, әллә синеке итепме?

Көтелмәгәндә сәер сорауны ишеткәч, Федор елмаеп җибәрде, әмма аңа бу мизгелдә йомшарырга ярамый иде. Катырак әйтмәсә, кыз хәзер кире уйларга мөмкин.

— Үзеңнекен! Үзеңнекен! Минекен куя башларга өлгерерсең, алда тормыш озын әле!

Марфага барыбер кебек тоелды. Гүяки, ул үзенә үлем карары чыгарган кәгазьгә имза саламыни, куллары акырын гына хәрәкәтләнә. Кая китте аның әле бер сәгать элек кенә булган усаллыклары, ирләрчә тәвәккәллекләре? Берсе дә юк, берсе дә калмады. Намусның тапталу, гыйбатнең таралу куркынычы алдында бирешә икән бу хатын-кыз. Моны ирләр аңлыймыни?

«Волкова» дип имзасын калдыргач, Марфа өстенә тунын киеп, чыгып китү ягына ашыкты. Әмма Федор аның чабуына басты.

— Кая киттең әле болай? Иреңне калдырыпмы?

Никләр өчен генә туктатты да шушы сүзен әйтте инде? Чак кына сабыр итәргә булмый идемени?

Марфа, үз-үзен белештерми, чыгып йөгерде. Җәяүле буран киң урам буйлап чаба, чабуларын ача, йөзенә бәрелә. Кыз карга капланып елап җибәрде. Моңа кадәр, Самуилын югалту белән килешкән төннән бирле болай бушанып, дөньяның яманлыгына ачуланып, йөрәк түрендәге мәхәббәтен каһәрләп, язмышына көенеп үксегәне юк иде. Яңа гына йөзенә бәргән җәяүле буран аның ялан башыннан, тузгыган чәчләреннән, аркасыннан сыйпады, юатырга теләде. Адәм балаларының сагышын алырга табигатьнең көче җитмәсә, кемнең кулыннан килсен, бер Аллаһы тәгаләнең! Бераз елаганнан соң, Марфаның күңеле бушап калды, ул үзенең ахмаклыгына сәерсенеп, башын күтәрде: «Нигә әле мин болай бетеренәм, Федор да начар кеше түгел бит! Белгән юк, бу сугыш кемнәрне нинди хәлгә калдырыр әле, очы-кырые күренми!» — диде дә, үз язмышына ризалашып, кире идарә йортына таба китте.

Ире Федор ишек төбендә, берни булмагандай, басып тора иде. Марфа аңа бер сүз эндәшмәде, ишекне ачып, эчкә үтте, идәндә аунап яткан калын яулыгын күтәреп алды, бияләйләрен тегендә-монда тибелгән җирдән тапты, ишеккә таба борылды. Куркып китте. Анда, тыныч кына күзәтеп, Федор тора иде.

— Син тышта калган идең бит?

— Тышта булса ни, кереп басарга да мөмкин түгелмени? — Федор мыскыллы гына елмая бирде.

— Миңа кайтырга кирәк!

Марфа ялынган кыяфәттә иренә карады. Әмма монысы: «Мин теләсәм, кайтырга!» — дигән төсле кара йөзе белән текәлеп котсыз елмаюын дәвам итте.

— Федор, җибәр инде мине, кайтыйм?

Хатыны коелып төшкән һушын көчкә-көчкә җыеп үтенә иде. Ире һаман елмая бирде. Әмма ишек төбеннән бераз читкәрәк бер-ике адым атлады да:

— Кая? — дип җикерде.— Кая китәсең әле син! Законлы ирең каршыңда тора, ә син «китәм» дисең!

Акырып әйтелгән сүздән Марфаның колагын ярды, ул тагын да коелыбрак төште һәм елап җибәрде. Бер ялгышы белән шушылай ир табаны астына егылырмын дип башына да китермәгән иде, бигрәк тә мәлгунь Федор каршысында бит, бүтән булса, бер хәл иде. Юк, дилбегәне кулыннан ялгыш ычкындырды ул бүген, урыны бу түгел иде, кешесе ул түгел! Кайтарып алыр әле, кайнар табада биетер! Кол ясамакчымы? Киресе килеп чыгар, бәгыренә үтеп, йөрәк канын эчәр Марфа! Бүген буйсынган исәпләнсен, алда күз күрер! Ташлап качардай итәр әле үзен. Каптырдым, дигән буламы? Ничек эләккәнен сизенми дә калыр, гомере буе табан асларына кадәр юар. Юкса төбәккә бер дип сөйләнгән Марфа булмас ул, күреп торыр!.. «Мин җәһәннәмне күрдем, анықын моннан да түбәнрәк итәм, тәмуг ясыйм!» — дип уйлады һәм күңеленә салып куйды. Аягына эскәнҗә төшереп гарипләнгән Федор тормышында нинди каты кыскычка килеп кергәнен әлегә белми һәм төшенми, киресенчә, бәхеткә чумдым, дип тантана итә иде.

## 19

Федор Марфаның ире булырга күптән җыенып, ниятен кисәргә мөмкин егетләрнең барысын да кыздан читләштергән иде. Хәтта Исмәгыйльнең дә башына җитәргә әзер иде. Теге янгын артасында нахак рәвештә тоткынлыкка төшкәч, бу татар мәңге дөнья йөзен күрмәс, дип уйлаган иде дә, аның котылганын ишеткәч, берәр хәйлә табып, харап итеп ташларга кирәк үзен, дигән планнар корды. Әмма акылы белән ул уйларының очына барып җитә алмыйча, ничек эшләсә дә, уңышлы килеп чыкмас кебек иде. Бу юлысы да аңа көтелмәгән очрак ярдәмгә килде. Була бит шулай, берәүләрне, акыллары бар сәбәпле, тормыш ярдәмнән ташлый, үз көчләре белән ирешсеннәр өчен бар юлларны яба, ә икенчеләргә, аларның тинтәк икәнлеген белепме, гел ярдәм итеп, очраклы вакыйгалар рәвешендә теләгән алдына чыгарып куя. «Бирим, дисә колына, чыгарып куяр юлына!» — дигән сыман.

Ул вакытта Марфа урын өстендә иде. Федор үзенең авылдашлары белән дәүләткә ашлык тапшырырга кара көздә олау белән килде. Туры пристаньгә җибәрделәр. Баржаларга бушатырга кирәк иде. Чиратка бастылар. Ярты сәгатьләп торганнардыр, Казаннан килүче теплоход туктады, аннан биштәрләрен аскан карчык-корчык, килен-киленчәк төште, төркемнәрендә ир-ат халкы аз иде. Арада берсен Федор ерактан ук танып алган кебек тойды. Калку гәүдәсе, тыныч һәм саллы адымнары аның кем икәнлеген, кара төстәге киеме, караңгыланып киткән хәсрәтле

йөзе исә кайдан кайтып килгәнлеге хакында ачык сөйлиләр иде. Әмма Исмәгыйль якынайган саен, таныш кебек тоелганлыгы юкка чыгып, читтәт бәндәгә охшап китте. Федор шикләнеп тә алды, бәлки ул түгелдер? Аларның күзләре очрашты, Исмәгыйль, белгән кешесен күргәч, елмаеп җибәрде. Марфаның авылдашы бит, ни хәлләре бар икән? Сорасын, әле кайчан күрешәләр?

— Сәләм, Федор! Танымыйсыңмы әллә, шикләнеп карыйсың?

Исмәгыйль киң күңел белән кул сузса да, теге янгын көненнән соң үзен тотышын исендә саклаган Федор салкынрак булырга тырышты. Нигә ди әле ачылып китсен? Кызыңны, бала чактан карап-күзләп, яратып йөргән кешеңне тартып алсын да, Федор аңа авыз җәеп торсын әле? Шулай да җавапка кулын сузмыйча кала алмады:

— Сәлам-сәлам!

— Нигә бик күңелсез әле?

Федор сүзгә керешергә теләмәгән кеше төсле яны белән борылды. Аның бу хәрәкәтеннән шикләнеп калган Исмәгыйль китеп бармакчы иде туктатты:

— Син инде безнең авылга килеп йөрмә, белдеңме!

— Нәрсәгә? Минем гаебем юк бит!

Исмәгыйльнең какча йөзе тартылып китте, яңа гына ерып җибәргән авызы җыелды, төсе коелып төште. Аның күңеле соңгы вакытта күргән җәберләр аркасында артыгы белән сагайган иде. Эчендә үч һәм ачу йөрткән Федор катырак сөйләшергә тырышты, менә хәзер якалап алырга да арба астына аударып, изеп-таптап ташларга теләде. Әмма бу кадәр үк вәхшиләнергә җөрьәт итә алмады. Ничек тә болай гына, мыскылламыйнитми җибәрергә исәбендә юк иде.

— Марфа кияүгә чыкты, сине көтеп тормады! Шаярткан гына ул сине, белеп тор!..— дип ыржайды.— Безнең авылга килеп йөрисе булма, очрашырга теләгең бар икән, оныт! Юкса, кайткан җиреңә кабат китәргә туры килер! Аңладыңмы?

— Марфа кияүгә чыкты? Кайчан? Ничек?..

Монсын ук егет көтмәгән иде булса кирәк, сорау арты сораулар яудырды да, дулкынланудан төрмә һавасы тәмам бозган күкрәге ялкынсынып, йөткерә башлады, Федорның ашлык төягән арбасына бөгелеп төште. Аның бу хәлен башка олаучылар да күрделәр, әмма янына килүче күренмәде. Әгәр дә алар борылып карамаса, Федор күнитеге белән Исмәгыйльнең эченә тибеп тә җибәрмәкче иде, шикләнә калды, татарларны күзгатуы бар!

— Нәрсә, сине көтеп торыр, дип уйладыңмы? Кирәк ди аңа кулак ялчысы! Ахмак, ди, ул!

Йөткерүдән туктап, Исмәгыйль күзләрен Федорга төбәде. «Алдыйсың бит, шакшы урыс!» — дип уйлый төсле иде ул. Кул суза калса, якалашырга да мөмкин иде Федор, аңа шул гына кирәк бит! Әмма Исмәгыйль башка бер сорау да бирмәде, юлын дәвам итәргә уйлап, аркасына буш биштәрен җайлады, шулай да тукталып:

— А-алай икән,— дип әйтеп куйды.— Ире кем соң? Кемгә барды?

Федор бу очрашуда беренче тапкыр елмаеп җибәрде, тәмәкедән сөрсеп-саргаеп беткән тешләре ыржаеп алга чыкты.

— Мин, дисәм, нәрсә әйтерсең?

— Син? Ничек син?

Исмәгыйль моңа ышана алмый иде. Шулкадәрле чибәрлекләре белән бу котсызга ничек караган икән, дип уйларга аның тулы хакы бар иде, әмма соравы икенче төрле яңгырады:

— Син яшь бит әле, солдат хезмәтенә дә бармаган! Юктыр-юктыр, мөмкин түгел!

Федор тагын да зәһәррәк итеп көлде.

— Солдат хезмәте качмый ул, ә Марфа качты менә үзеңнән! Рәхәтләндереп яшибез әле!

Федорның бу рәвешле мыскыллауларын ахрына кадәр тыңлап торырга Исмәгыйльнең хәленнән килмәде. Аның күзләренә кайнар яшьләр тыгылырга, егетне агызып китәргә әзер. Качсын ул моннан, еракрак, кеше-кара күрми торган җиргә!

Әмма аягыннан нидер тотып калган төсле, әллә йөрәге өзелеп төштеме, әллә Федорның ялганы җибәрмиме? Хәлсезләнеп калды. Аның каравы Федор, көтелмәгәндә мәсьәләнең үз файдасына хәл ителүенә тантана итеп, һаман да елмая-көлә иде. Бу мәсхәрә халәтендә озак кала алмаган булыр иде берәүләр. Әмма Исмәгыйль тагы да салкын итеп Федорның күзләренә карады да:

— Миннән сәлам әйт, бәхетле яшәсен! — дип чын күңеленнән әйтте.— Ә син, белеп тор, аны юкка рәнҗетәсе, кеше алдында ким-хур итәсе, кимсетәсе булма! Ишетсен колагың!

Моңа Федорның ачуы кабарды.

— Синең анда ни эшең бар! — дип, тагын да каты бәрелергә, Исмәгыйльне кыздырырга, калай әтәчләнергә ашкынды. Әмма барып чыкмады, Исмәгыйль:

— Ишеттеңме! — диде катыланып.

Усал күз карашыннан, җитди сүзеннән һәм дә үз ялганы ачылудан шикләнеп калган Федорның җаны калтыранды. Яшь аермалыклары, дөньяга карашларының ике төрле булуы үзләрен сиздерде. Әгәр дә Исмәгыйль шунда өстәп тагын бер-ике сүз дә әйтсә, катырак эндәшүен дәвам итсә, Федор тулысынча бирешәчәк һәм шаяртканын белдерергә дә мөмкин иде, әмма араларында бүтән сөйләшү күренмәде. Исмәгыйль, кискен генә борылып, юлдан югарыга таба менеп китте. Бераз баргач, аның йөткерүе башланды. Ул арада Федорның иптәшләре.

— Кем иде ул, кем иде, теге татар түгел идеме? — дип янына җыелыштылар.

— Юк, ул түгел иде! — диде Федор, ачуы кабарып.— Былтыр миннән бурычка акча алып торган адәм иде, һаман кайтарып бирми!

Ул тагын ялганлады. Әмма арадан танып калучылар да булган икән.

— Шул иде, шул иде!..— диючеләр дә табылды.

— Бөтенләй бетерешкән икән, бичара!..

Шунда аларны ашыктырып, баржа ягына дәштеләр. Барсы да, артык сүз куертып тормастан, үз арбаларына таралыштты.

Кире кайтканда Федор бары бер нәрсәдән, Исмәгыйльнең юлда очрап, берәрсенә утырып, серне бүлешүеннән, ялганы тотылып, харап ителәсеннән шикләнеп, атын олаудан алгарак чаптырды. Әмма шикләнүе урынсыз булган. Исмәгыйль аларга очрамады. Үзгә юлдан киткәнме, әллә инде район үзәгендә тоткарланганмы, билгесез калды. Баштарак Федор аны алларына килеп чыгар, авылларына килер, Марфаны эзләргә, сөйләштерергә маташыр дип тә уйлады. Әмма егет күренмәде. Марфа да урын өстендә ята бирде. Бары тик кыш җиткәч кенә, аракы эчеп, урамда йоклаудан салкын тидереп, каты авырудан шифаханәгә эләккәч кенә Федор, җай китереп, Исмәгыйльнең авылдашыннан белеште: Казанга күченеп киткән икән...

Бу сырхавы аркасында, Федор ул елда солдаттан калды. Әгәр дә алган булсалар, сугыш башлануга һәлак ителәсе икән. Ярый әле боярның алма бакчасын яңартып, аны тәртипкә салуга кереште, тимерчелеккә килеп, һәртөрле эш коралларын хәстәрләүгә тотынды. Бәхетең килсә, артыңнан куып йөри. Кирәк бит шулай! Моңа кадәр урынында мәңге кузгалмас кебек утырган эскәнҗә аягыңа төшсен дә тубыктан түбән изеп ташласын инде. Баштарак Федор моны Исмәгыйльнең каргышы дип кабул итте. Җитмәсә аягы да дөрес ялганмады, эчкә таба кәкре булып калды. Аны солдаттан азат иттеләр, кулына ак битлек тоттырдылар. Килеп чыккан сугыштан ул шулай имин калды. Әнә, Исмәгыйльләр кырылсын, аларга төс ул!

Федорның Марфаны күзләп йөрүен, артыннан килеп йөдәтүләрен бөтен авыллары белән белә иделәр. Инде Исмәгыйльдән дә отылдырды, аның дә эзен суытты, кыз үзе дә онытса, Федор кулына төшәчәк. Ул моны яхшы белә, хәйләсен генә таба алмый иде.

Менә, салкын, җәяүле буранлы кышкы кич анысын да хәл итте. Марфаның кочагында хәзер Федор, бары тик ул гына җылыначак, бернинди егет һәм ир комачау итә алмаячак. Ә Исмәгыйльдән ничек котылуының серен, һичкем ишетмәгән төсле, хатыны да белми калачак. Нигә әйтеп торсын ди әле ул аңа, ахмак түгел ич!

Кургаш янгыр булып Исмәгыйль өстенә ишелгән нахак бәла инде үтеп китте, дип санасалар да, чынлыкта әле аңа шактый гомерен билгесезлектә яшәргә туры киләсен күпләр белми иде. Бояр улы Вороновскийның кылган яманлыклары шактый күп җыелган, аларның иге-чиге күренми, шунлыктан тикшерү эше дә артык озынга зураеп сузылды. Исмәгыйльнең гаепле түгеллеге ачыкланып җитә алмады, бәлки ул аларның тозагына капкан ялчыларыдыр, дипме уйладылар, әллә теге бар гөнаһларын да танып бетермәде, монсын егет белеп җиткерә алмады. Әмма аны мәҗбүри рәвештә Казанда калдырдылар. Тикшерү барышында кирәге чыга калса, чакыртырга тиешләр иде.

Чыннан да, аның янына ике мәртәбә Гөлсара килде. Беренче тапкырында аларны очраштырмадылар, шулай да китергән әйберләрен алып калдылар, Исмәгыйльгә керттеләр. Бернинди ышанычы һәм таянычы калмаган чагында үзен кемнеңдер искә төшерүе өчен олы сөенеч булды, икенче тапкырында күрештерделәр. Гөлсара аның хакында гаепле дә, гаепсез дип тә уйламый иде. Теләге бары бер генә: көтеп ала алмавы сәбәпле гафу үтенү! Язмышының шулай килеп чыкканына үкенә иде ул. Бәлки Исмәгыйль шушылай авыр хәлгә төшмәсә, очрашу теләге күңелендә уянмаган да булыр иде. Менә бит дөньялар нишләтә! Адәм балаларын кайгы берләштерә шул. Хәсрәтлене хәсрәтле бәндә генә таный, бәхетлеләрнең газаплыларда эше вә сагышы юк! Күңеленнән киселеп ташланган Гөлсараның яңадан кире кайтарылуы менә шушы вакытта башланып китте. Әмма бу үпкәләүне алыштырган рәхмәт хисе генә иде, егет моны яхшы аңлады. Мәхәббәте һаман дә Марфага төбәлгән, аның белән генә бәхетле булырга омтылу белән куәтләнгән иде.

— Син минс, Исмәгыйль, гафу ит инде,— диде Гөлсара аңа бу очрашуда.— Төшләремә кереп газапладың, ачуландың... Шуны гына үтенеп килдем!

Исмәгыйль һаман да чибәр, матур иде. Гөлсараның чәчләренә вакытыннан элек ак йөгерергә өлгергән. Хәсрәте олы булып, бик авыр кичергән иде, бичара. Янында яклаучысы һәм киңәшчесе юклык та аны бетергәндер инде. Әгәр дә акыллы киңәш биреп: «Моның белән генә дөнья җимерелми, алда гомерең бар әле, әллә нинди бәхетләргә дә ирешерсең!» — дип бер әрсе ышындырган булса, ул болай ук чарасыз калмас иде дә, андый кеше табылмаган, күрәсең.

— Ә синең чәчләреңә ак куна башлаган, Гөлсара,— диде аңа Исмәгыйль тыныч кына.— Мин сине күптән гафу иттем инде, дөресрәге, монда ни гаебең бар, синең бит бер гөнаһың юк! Борчылма, шатлыклы көннәрең алда булсын!

— Юк, Исмәгыйль...

Гөлсара еларга әзер иде, әмма сыгылып төшмәде, үзен тыныч тотарга тырышты. Хәзер ул әйтә, нигә иртәгәгә яки берсекөнгә калдырырга, белеп торсын: «Исмәгыйль, юк, мин сине яратам, үлемгә бармавымның сәбәбе дә бары тик син генә. Гафу итәсең икән, ул вакытта минем хисләремә дә җавап бирә аласың!» Алдан ни сөйләшергә икәнен уйлап куйган Гөлсараның башында бу фикерләре юк иде, ярлыкау үтенү һәм чыгып китү генә иде. Әмма яратып йөргән, төн йокыларын алган егетен күрү аның хисләрен уятты, элеккечә үк өзелеп сөясе һәм Исмәгыйлен мәхәббәт чолтәренә төрәсе килде. Бу тыелгысыз хисләр ташкыны ике

арадагы тимер рәшәткә һәм чит-ят карашлар барлыгын онытгырып, аны егетнең кочагына этәрделәр. Исмәгыйль моны сизде, әмма үзе хакында уйлауга күчте. Гөлсара урынында Марфаны күрәсе килде. Күзләренә яшь тыгылды. Тоткынның хисләре үз эшен эшләде. Алдында Марфаның шәүләсе яңарды һәм ул:

— Минем бер генә дә гаебем юк, күңелем сизенә, чыгарырлар, гөнаһлы кешене табарлар... Мин сине эзләп табармын...— дип тезеп киткәнен сизенми дә калды. Бу арада инде вакыт беткән, аларны камераларга куа иделәр. Башка тоткыннар белән күрешергә килгән карендәш-туганнары аерылышырга теләмичә, рәшәткәләргә ябышкалаган очраклар да булды, әмма Исмәгыйльне беренчеләрдән йолкып алдылар, кабат очрашулар тәтемәячәген белдерделәр.

Гөлсара егетнең әйткән барлык сүзләрен дә колагына элде, бигрәк тә «мин сине эзләп табармын» дигюләре аның каефен күтәреп җибәрде һәм ул үзен яңадан балкып киткән чәчәк төсле тойды. Ул көнне Яңа бистә абыстаена барып, догада искә алырга сәдака да калдырып чыкты, Аллаһы тәгаләдән Исмәгыйльнең төрмәдән исән-имин чыгарылуын үтенде. Ни хикмәт, килеп тора бит, авылдашы Зарифулла абзыйны очратып, аңа да шатлыгын уртаклашты, Исмәгыйльнең тиздән чыгарыласын, аның белән күрешкәнлекләрен әйтте. Гөлсараның икенче сүзе дөрес булса да, беренчесе өчен һич тә ныклы җирлек юк иде. Әмма күңеле сизенгән икән, егетне чыннан да чыгардылар.

Казаннан беркая да, хәтта туган авылына да китмәскә кушылгач, Исмәгыйль ничек булса да барып урнашырга теләп почмак эзләп йөрде. Кесәсендә акчасы юклык аркасында ул гаҗиз иде. Шулай этелеп-бәрелеп йөдәгән чагында алар тагын очраштылар.

Кич иде, Гөлсара сабын заводыннан кайтып килә. Арган-талчыккан. Барактагы бүлмәсенә ирешсә, ял итәр иде. Көне буе аяк өсте тырмашу йончыта шул.

— Сәлам, Гөлсара, син түгелме соң бу?

Куанып китте: Исмәгыйль бит! Менә, Аллаһы Тәгалә юк, язмыш юк, дип, ахмак сүз сөйләп йөре әле. Юлларына кадәр туры килеп тора бит, рәхмәтләр төшкере!

Гөлсараның барлык арганлыклары юылып алынды. Елмаюга каршы ачык йөз белән җавап бирде: «Ничек болай? Чыгардылармыни?» — дип сораштыра башларга җыенган акылын узып, алдан йөрәге эндәште:

— Әйдә безгә, тормышымны күреп китәрсең...

— Ни бит әле...

Исмәгыйль әйтергә теләгән сүзен кайсы урыннан башларга белмичә аптырабрак калды. Аның каравы, Гөлсараның күзләр уйнады. Менә бит ул, сөекле кошы Исмәгыйль үзе монда! Тагын сиңа кем кирәк! Алып кайт та чәең белән сыйла, башкасын куй...

Гөлсараның артыннан ияргән Исмәгыйль һаман да үз сүзен әйтеп бирергә аптырап барды, инде агачлык та күренә башлаган иде. Кыз алдан элдерә генә, ничек куып җитмәк кирәк.

— Ни бит әле, фатир эзли идем.

Егетнең сүзләре бу юлысы Гөлсараны тыя төштеләр. Көтмәгәндә тукталды да:

— Нинди фатир? — дип сорады.

Исмәгыйль аның йөзеннән аптырауга караганда өркеп калу кебек сәер төсмерләр сизенде. Ул ничә кешегә кереп чыкты, барысы да аны шушындыйрак йөз белән озатып калдылар бит. Кем икәнлеген, күпме вакытка кирәклеген белгәч, сөреп чыгару җаен карадылар. Мөгаен базарда итәк астыннан гына вак сәүдә йөртә торганнардыр, милиция белән бәйле кешене оялатасы килмәгәннәрдер инде.

— Яшәп торырлык кына. Мине бит әле бөтенләй азат итмәделәр. Төп гаепле кешегә суд булмыйча торып, мөмкин эш түгел икән, Казанда торып калуымны таләп иттеләр,— Исмәгыйль сөйли бирде,

әмма Гөлсара өчен боларның әллә ни әһәмияте юк иде. Шунлыктан ул бер биргән соравын кабатлады һәм өстәп китте:

— Нинди фатир, ди, ул? Нигә кирәк? Безнең баракта ятак җитәрлек. Эш кирәксә, заводта гел урын чыккалап тора. Син бит солдаттан кайттың, гайрәтле, көчле. Кайда да алырлар. Бернинди фатир эзләп йөрү юк. Бүген минем урында йокларсың, иртәгә сине үзем белән заводка алып барам, тик ятмассың бит инде.

Яңа гына өстендә йөргән авыр болыт таралу белән балкып кояш чыккан төсле, рәхәт булып китте Исмәгыйльгә. Ул берсүзсез диярлек Гөлсара белән килеште.

Барак дигәннәре элеккеге озын вә олы агач йорт булып, эче такта һәм фанера белән бүленгән кечкенә бүлмәләрдән гыйбарәт иде. Гөлсара исәнләшә-исәнләшә керде. Йөзләренә вә сүзләренә караганда, монда яшәүчеләрнең күбесе татар икәнлеге беленерлек иде. Исмәгыйль хакында берсенең дә туктатып: «Кем бу?» — дип сорамавы егетне икеләтә куандырды, аңа бер генә төнгә булса да тыныч калырга мөмкин иде. Әмма ялгышты. Баракның икенче башыннан берәү бакырып җыр сузды, исерек икәнлеге аңлашылды. Аны кемдер туктатырга теләде, теге исә буйсынмады, кычкырышу китте, бер яктан яшь бала чинап елый бирде, күрше дивар артыннан икенче хатын сукранды. Дөньяның мәхшәре һәм тынгысыз почмагы шушы иде. Әмма Исмәгыйльгә шау-шу ничектер үз кебек тоелды.

Ул арада Гөлсара кайнап чыккан чәйнеген дә күтәреп керде, өстәлен дә тиз арада япты, кадерле кунакларына гына куя торган тәм-томын да чыгарды. Боларга карап, аның матур гына яшәп ятуын чамаларга мөмкин иде. Үзе һаман сөйләде дә сөйләде:

— Әле берничә көн генә элек, авылдан килеп киттеләр, әби белән бабай, синең белән күрешкәннән соң төш күргән идем. Имеш, бер коега егылып төшкәнсең дә, чыга алмагач, аптырап утырасың икән, кинәт яныңда гына ишек ачылды да китте. Аннан кояш нуры керде, барасың, ямь-яшел болын икән. Кычкырам, кычкырам мин сиңа, ишетмисең. Шулай уянып киттем. Кичкә әби-бабай килделәр. Иртән киттеләр. Сөйләдем синең белән очрашуларымны да, төшемдә күргәнемне дә. «Чыгарырлар үзен, озак тотмаслар, котылыр!» — диделәр, дөрескә булган икән. Юкса шулкадәр хәсрәтләнгән идем...

Сүзе кебек шикәрле-татлы тоелды чәй. Күптән авызына бер кыйпылчык ризык әсәре кермәгәнлектән Исмәгыйльнең карыны ачкан, инде башы да авырта башлаган иде. Әмма Гөлсараның бер генә сүзе дә артык кебек ишетелмәде. Ул, гүяки, үзе белән күрешкәнгә сөенә торган кешене беренче тапкыр очрата иде. Хисләре һәм уйлары изге булу сәбәпле күңеле дә нурланып, тәне ныгып киткәндәй тоелды. Алар кат-кат чәй эчтеләр. Гөлсара һаман сөйли торды.

— Зарифулла абзыйны да күргән идем. Теге көнне. Очраштык бит әле. Аңа да әйттем. Гаебең юк икәнлеген дә сөйләдем. Ул да, шулай, ди. «Баланы урыслар гына әрәм иттеләр, бер дигән кеше иде. Андый бәндә ут чыгара, димени, кешенең нәрсәсенә кул сузганы бар? Булмаганны! Урыслар гына башын ашадылар!» — ди. Бар сүзләрем белән дә килеште. Әниең һәм сеңлеңә дә сәлам тапшырырга куштым...

Чәйдән соң ятып алсаң да ярар иде дә, мона кадәр сизелмәгән тынчу һава Исмәгыйльнең борынына кереп, тәнен тирләтә төште. Урамга чыгып керергә уйлады, әмма берәрсенә очрап, тегене-моны белешә башлавыннан шикләнүе аркасында утырган урыныннан кузгалмады. Гөлсара тиз-тиз өстәлен җыештырып өлгерде. «Эштән соң аның да ятып аласы килә торгандыр?» — дип уйлап, Исмәгыйль күтәрелергә ниятләде. Ул торып басуга, Гөлсара аны туктатты:

— Ары-бире барасың юктыр бит? — диде.

— Белмим инде, юк инде, анысы...

— Алайса, ят та йокла. Хәзер мин сиңа урын җәеп бирәм. Ни дисәң дә, чит кеше түгелсең бит әле. Миндә генә калырсың.

Гөлсараның күңеле һаман да бер сүзне, соңгы аерылышканда Исмәгыйль әйткәнне кабатлый иде: «Мин сине эзләп табармын!» Әгәр дә шулай икән, бик яхшы.

Кыз ары тартылды, бире нәрсәләрдер эзләнде. Ул да түгел, урын җәйде, өстән ак җәймә бөркәде. Аның буй-сынының җитмәгән җире юк иде, кыяфәте бүген биш ирне тезгә чүктерерлек. Тик Исмәгыйльнең күңеленнән генә күптән кисеп ташланган. Ул күзләре белән Гөлсараны күзәтә, ә үзе Марфаны сагына. Әкәмәт тә инде бу кеше күңеле, авызына кергән ризыкны күрми, һавадагы торнага тартыла.

— Мин күрше Фәгыйлә апаларда йокларммын, син монда урнаша тор, кыз белән егеткә бер бүлмәдә яту килешмәс, кешеләрнең әллә нәрсәләр уйлавы бар. Шикләнмә, һич тә аптырама...

Ул арада Гөлсара чыгып та китте. Күрсәтелгән урында җайланырга гадәтләндерелгән Исмәгыйль аның тәкъдименә күнүдән артыгын белмәде. Чишенә башлады. «Боларның гадәтләре бардыр инде, үзләре беләләрдер,— дип уйлады ул.— Кыз, диме, ә? Шулай диде шул! Мондагылар аның ни газаплар күргәнлеген белми дә торганнардыр. Нигә кирәк. Искәрмәүләре яхшырак...»

Исмәгыйльнең караватка сузылып иркенәюе генә булды, Гөлсара килеп тә керде. Ул тагын нәрсәләрдер эзләнеп маташты. Ары-бире эленгән әйберләр арасыннан күлмәк алды. Тукталып торды. Егет, күзләрен йомгандай итеп, барысын да күреп торса да, сүз дәшмәде, аны янына чакырмады.

— Иртәгә таң белән эшкә, йокларга кирәк инде, йокларга,— дип сөйләнде Гөлсара үз алдына,— Аллага шөкер, Фәгыйлә апаларның бер урыннары буш икән.

Ничек шыпырт кына килеп керсә, шулай чыгып та югалды. Марфаны күз алдына китереп, аның белән сагынышып очрашулары алда көткәнлеген уйлап, хисле вә изге хыял дөньясына күчкән Исмәгыйль йокыга батканлыгын сизенми дә калды.

Иртәнге якта аны Гөлсара уятты. Егетнең үзенә насыйп булачагын алдан ук сизенепме, кыз вакыйгаларны ашыктырмады, мөмкин исә дә кочагына кереп ятуны кирәк тапмады. Тиз генә чәйләделәр дә эшенә киттеләр. Башка җирләрдән эзләп йөрисе дә итмәде Исмәгыйль, сабын заводында урын табылыр, дип өметләнде.

Ышанычы бушка булмады. Аны сөяк кайнату цехына урнаштырдылар. Гөлсараларныкыннан ерак түгел баракта бер почмак та бирделәр. Әмма монысы тегесе төсле аерым бүлмәчекләрдән түгел, бәлки гомуми ятак җирдән гыйбарәт, араларда чаршау яки чыпта гына иде. Исмәгыйльгә иң читтәге салкын почмак туры килде. Бара-тора үзенә чүпрәк базарыннан иске юрган шикелле нәрсә дә алды, салам матрац юнәтте.

Кар соңга калып төшәргә чамалаган елда кыш салкын булырга охшый. Бөтен кеше шул турыда, беләме-белмиме, сөйләште. Барактагы халык эчәргә яратса да, Исмәгыйль аларга кушылмады, шунлыктан аңа «Күндәм» кушаматын тактылар. Әмма егетнең эченә җыелып килгән үч һәм ачу эшнең бөтенләй башкача борылып китүен кайнатып чыгарырга мөмкин иде. Әгәр дә тагын да шулай дәвам итсә, ул шеш көннәрнең берендә шартлап, Исмәгыйль башкалар кебек үк эчә башлаячак, йә инде йодрык канунына бөтәннәрне буйсындырырга омтылганда яңадан башы төрмәгә барып керәчәк иде. Ярый әле Вороновский эше вакытында тогәлләнде, бояр улын терәп атарга хөкем иттеләр, егет һәртөрле шикләрдән азат кылынды. Хәзер нәрсә эшләсә дә була иде. Вакыт-вакыт үзенә килеп, хәлләрен белешкәләп йөргән Гөлсарага да рәхмәт әйтеп, саубуллашып тормастан, эштән чыгуын белдереп гариза язды да, көзге караңгы иртәдә авылларына кайтырга чыкты. Паромга өлгерә алмады.

Әмма Казаннан китәргә җыенган теплоходның алар пристаненә тукталачагын белгәч, шуңа билет сорады.

Идел аны каралып-дулкынланып каршылады. Төньяктан искән салкын җил ким дигәндә берничә көннән кар вәгъдә итә иде. Исмәгыйль күбрәк Марфа хакында уйланды. Өйләнү иде исәбе. Бүген кайтса, иртәгә үк авылларына барачак, күрәчәк һәм кулын сораячак, нигә озакка сузарга, кешеләр бит ярәшеп тә кавышалар әле. Һич тә начар тормыйлар. Бер-берсен яраталар икән, бәхетле булырлар! Күпне күрде бит инде, нахак бәлаләргә тарды. Әгәр дә аны да кире какса, дөньяның халык үлчәвенең тәлинкәләре өзелгән дигән сүз! Ул вакытта һичкемгә бәхет тәтемәячәк бу тормышта.

Уйлары Исмәгыйльне алдаган булып чыкты. Пристаньдә Федор белән очрашканнан соң, ул, җанын кая куярга белмичә, урамнар буйлап озак барды. Бер җиргә дә тукталмады. Хәтта әнкәсенә кучтәначкә дип кала икмәге алырмын дигән уен да онытты. Бары тик юл аркылысына сузылган инешкә җиткәч исенә төште, әмма кире борылырга соң иде инде.

Исмәгыйль каенсарның түренә кадәр керде һәм тыела алмыйча елап җибәрде. Ә югыйсә әле яңа гына бәгыре ташка әверелгән төсле иде, аңламассың бу адәм баласының күңелен.

Ул арада олаучылар атларын ашыктыра-ашыктыра узып киттеләр. Урыслар иде. Теге мөртәт Федор. Исмәгыйль аларга борылып карамады, туктаган булсалар да утырмас иде. Моңа кадәр урысларга карата хөрмәте булса да, аның кими баруын тойды. Көтмәгән шул Марфасы, көтмәгән. Димәк, яла ягучыларга ышанган...

Исмәгыйльнең туган авылында уздырган атна-ун көне бер дә файдага булып чыкмады. Аны эшкә дәшүчеләр күренмәде. Ул, гүяки, чит һәм ят иде. Урамда очраган кешеләр дә артыгын сораштырырга базмадылар, кайтарганнар икән, бик яхшы, дигәндәй, тизрәк китеп бару ягын карадылар. Кем белә, бәлки кабат алырлар? Дөньясы бер дә төзек түгел, ышанырлык-таянырлык җире юк. Бигрәк тә гомер бакый үзен кимсенгән итеп яшәргә мәҗбүр татар халкының күңеле сак.

Яздан хәстәрләп куйган агачларын кискәләп, утын итеп, Идел буеннан кышлык чыбык-чабык күтәреп, йортларын салкыннарга әзерләде дә кабат юлга җыена башлады егет.

— Улым, өйдә генә калсаң, ни була?

— Әни, шулай да, ир күңеле бу авылга гына сыеп ята алмый, бераз җилләнеп, онытылып, кайтыйм, дигән идем, фатихаңны бир инде!

Мескен ана ризалашты. Нишли ала иде соң? Марфаның килгәнен, Исмәгыйль улын сораштыруын әйтсә, марҗаны йортка кертергә бер дә йөрәге җитми. Югыйсә ул кыз аны тотып калыр иде дә бит. Юк-юк, нәселдә-затта күрелмәгән эшкә ризалык бирәсе түгел! Барсын, йөрсен. Дөнья күрмәгән кеше түгел, бәхете чакыра торгандыр, ризыгың читтә икән, эзләтеп таптыра инде! Тик марҗасыннан гына ераккарак китә күрсен. Ул гына шушы хәлләргә калдырды үзен.

— Борчылма, әни, бик читкә бармам, Казанда гына булырмын, елларда кайткалап-киткәләп тә йөрермен әле...

Исмәгыйль шушы сүзләр белән чыгып китте. Әнисе җил капкада аерылып калды, урам чатыннан борылганчы улыннан күзләрен алмады. Калада Исмәгыйль тиз генә юньле эш таба алмады. Килеп төшкән көнендә үз барагына борып, почмагында өши-туңа төн уздырды. Дивар тишекләренә чүпрәк-чапрак кыстырылган булуга карамастан салкын бүрәнәләр ашамы җил йөри иде.

Икенче көнне Гөлсара янына кереп чыкмакчы иде, кире уйлады. Ул хәзер үз бәхетен эзләп түгел, ә бәлки көтеп калган сөенеченнән качып йөрүче кешегә охшаган иде.

Кала кадәр калада аңа эш табылмасын инде! Йөри торгач, шифаханәгә кереп чыгарга итте һәм дөрес эшләде. Күптән түгел генә боларның

эшчеләре авырып киткән икән, ул карт җәйләрен утын кистереп, аларны ваткан, кышларын мичләргә ягып, төннәрен каравылда да кунгалый икән. Әмма көтмәгәндә аякларының саулыгын югалтып, шушы ук шифаханәгә салганнар үзен. Табиблар аның урынына да кизү торып, завхозлары кеше табалмыйчарак аптырап калган. Күндәм дә, сүзсез дә, артыгын күрмәүче дә кирәк икән. Сынау шарты белән генә Исмәгыйльне яллаганнар иде, табышларына сөенеп бетә алмадылар. Егетнең үзенә дә яхшы булды. Хәзер ул көннәрен-төннәрен җылыда, сәламәтлеген торгызу өчен бик кирәкле шартларда гомер кичерә.

Ә бер айдан аңа бүлмә дә бирделәр. Исмәгыйль акрынлап-акрынлап тормышын җайга сала башлады. Үз итеп завхоз аңа чәйнек бүләк итте. Йөткерүен белеп, табиблар ярдәм кулы суздылар. Акчасы аз булса да, бер башына таман гына иде. Завхозның анда-санда утын сатуларына да күз йомарга тырышты. Үзе андый эшләр белән шөгыльләнмәде. Ә теге җирбит, карак исә дә, Исмәгыйльне гел караштыргалап кына торды. Артыгын күрмәве, күп сөйләшмәве егетнең үзенә тагын ярап куйды. Яңа ел алдыннан аңа завхоз ак җәймә бирде һәм кирәгенә файдаланырга кушты. Шулай итеп, барысын да үз рәте-чираты белән матур ага барды. Әгәр алга таба да гомере шушы юнәлештә тыныч кына тәгәрәсә, өйләнү хакында да уйлана башларга вакыт иде. Хәтта завхоз да аңа каршы килмәде. Язга чыккач, утын хакында сөйләшеп киткәч.

— Иртәрәк түгелме әле, алда җәй бар, көз, дигәндәй,— дип елмаеп кына түгәрәк пыяла күзлеген кузгаткалап куйды, үзе кәгазьләрен актара бирде.

— Көзгә таба башка эшләр дә килеп чыгарга мөмкин.— Исмәгыйль җаен-җайга китереп кенә сүз ташлады.

— Ягъни мәсәлән...

Теге, аптырап, туры карады, комачаулаган күзлеген салып: «Ни димәкче бу малай актыгы?» — дип сынап маташты. Исмәгыйльгә шунда ук җавап тотарга туры килде.

— Өйләнсәм, мин әйтәм.

Завхоз баштарак уйга калды, аннан авызы ерылды.

— Бик әйбәт кенә булыр, бик әйбәт кенә... Тик, менә, кайда торырсыз соң?

— Белмим инде, шушындадыр?

— Бала беләнме?

— Өйләнгәч тә тумый торгандыр бит әле.

— Ә, шулай шул, аңынчы фатир ягын да кайгыртырбыз.

Завхоз көлеп җибәрде:

— Туй итәселәр дә бар икән әле. Яхшы эшләсәң, утыннарыңны алдан әзерләштереп куйсаң, шифаханәдә тәртип сакланса, булыр, кимсетмәбез...

Бу аңлашудан соң Исмәгыйль Гөлсараның сукмагын җылытып, көннән-көн аңа ешлый башлады. Болай йөрсә, тормышларын корып җибәреселәр дә иде, әллә нигә ашыгырга итмәде. Бәхеткә кинәнер иде, әмма сугыш башланып, беренчеләрдән Исмәгыйльне чакырттылар. Бер кичкә әнисе янына кайтып килде дә, ут эченә китеп тә барды. Ачыргаланды да соң Гөлсара, нигә үзен шушы кичкә генә булса да күреп, кочаклап йоклатмавына үкенде. Бер килмәсә, килмәс икән ул җәпләр.

Боларның берсен дә Марфа белмәде. Аларны бергә торалар дип ишетеп, шуңа ышанып, әмма күңеле белән башканы тоеп яшәде. Бары тик кырык өченче елның салкын, җәяүле буранлы киче генә кызны алдаштырырга юл ачты. Аның артыннан күңеле дә суынды. Исмәгыйльне күптән сугышта үлеп калган, дип белделәр, әмма аның гомере озын икәнлеген ул вакытта бер Аллаһы тәгаләдән башка, хәтта егет үзе дә белми иде бит. Үлем кануннары тормышныкыннан аерыла шул, елап килә, адәм баласы җир йөзенә, көлеп-елмаеп китә. Моннан да олуг сер бармы икән?

## 20

Подъезд эчендә тынлык иде. Марфа түтине соңгы юлга озатырга туганнары һәм балалары килеп бетте. Ире белән Регина да монда иде. Әмма Ханбал аны күрергә атлыгып тормады. Кичке сәгать алтыны көне буе көтеп йөрде, вакытыннан шактый алда ишек төбенә төшеп, шунда йөренде. «Алтыда көтәргә кушкан иде, килер микән? Оныткандыр инде!» — дип уйлады Альбина хакында. Әмма ялгышкан булып чыкты. Чит ил маркалы җиңел машина тыныч кына аның янына килеп туктады. Чиста ак күлмәктән, затлы киенеп-ясанган, кара күзлекле бер ханым аңа елмаеп карап торды да сигнал бирде. Аны Ханбал Альбина дип башына да китермәгән иде. Ярый әле янында эте булып, Айзикны танып алды һәм аңа таба ашыкты.

— Исәнмесез, ә мин сезне, оныткансыздыр, дип уйлаган идем,— дип сөйләнеп алды.— Кайда утырыйм?

— Сәлам,— диде ханым.— Артка, Айзик янына... Курыкма, миңа карата кискен хәрәкәтләр ясамасаң, тими ул.

— Ә нигә сезнең янга түгел?

Бу соравын бирмәсә дә ярый иде, әмма ханым егетнең ахмаклыгына игътибар итмәде, аңлатып китүне кирәк тапты:

— Көндез ярамый, иремнең дуслары күрмәсен, ә кичен... карарбыз, менә шулай!..

— Ә-ә-ә,— дип сузды егет. Алар инде кузгалып киткәннәр, машина, йөргәнгә караганда, тик торган шикеллерәк иде, бер чит тавышы, сикерткәне сизелми.

— Алдан ук тагын шуны килешеп куярга тиешбез! — Альбина сораулы карашын, сүзләре әйтелгән вакытта, Ханбалга арткүреш көзгесе аша төбәде, егет баш какты.— Анда син бары тик минем кунагым гына, безнең танышлык юк дәрәҗәсендә. Мин сине күрмим, ә син күзеңне миннән алма, кирәк булып куюың бар. Юк-юк, йодрык сугыштырырга түгел, бер-бер эшкә, диюем. Аңлыйсыңмы?

— Аңлыйм-аңлыйм! — диде Ханбал, үзенең нинди кармакка килеп капканлыгын сизенмичә.

— Килештек...

Альбина канәгать иде. Шушы таләбе аркасында егет аңа кичәнең башыннан ахырына кадәр карап утырачак, үзен чын мәгънәсендә гашыйк Фәрһад кебек тотачак, әйләнә-тирәдәгеләрнең күзәтүен сизенмәячәк. Ханым да сер бирмәс. Ханбалга күз дә ташламас, ишарә дә итмәс, әмма бүтәннәр тарафыннан да кимсетергә юл куймас.

Арткүреш көзгедән, исенә төшеп, ханым Ханбалның өсте-башын тикшереп узды. Ул уйлаганча иде монда да: егетнең бар киенгәне иске фасон буенча!

— Бу күлмәк-чалбарыңны салып, башкаларны кияргә туры килер!

Альбинаның сүзләреннән Ханбал аптырап китте. Ничек инде башкаларын? Аның бит бердәнбер костюмы менә шушы. Ярамаган тагын.

Егетнең хәсрәткә калганлыгын чамалап өлгергән ханым пакет сузды:

— Мин әнә теге борылыштан сулга чыгармын, шунда менә боларны киенерсең!

Ханбал аңа ирексездән буйсынырга мәҗбүр иде.

Егетнең кием алыштыруына сәерсенеп өрергә маташкан этне алып, Альбина бераз йөреп килде. Бу арада кәефен югалткан сыман тоелган Айзик бераз сабырсызлана төшкән иде. Аның моңа кадәр күренмәгән гадәтләре калкып чыга башлады: ул әле төн уртасында өреп куя, җәле ишеккә аркылы ята. Нигәдер күңеле сагайды, мескеннең. Әллә ханымның хис-кичерешләрен сизенәме?

Ханбалга бар киемнәр дә таман килде. Бераз гына җайсызрак булса да,— яңа өс-баш һәрвакыт баштарак тәнгә ярашып бетми инде,— егеткә күңелле иде. Шулай да ул:

— Бәлки кирәкмәс иде бу карнавал,— дип, руль артында яңадан урын алган ханымга әйтеп карады. Альбина аның авызын шунда ук япты:

— Мине оятлы итеп йөрмәссең бит инде, искеләрең белән...

Аларның «Клуб» дигәннәре бик затлы ресторанның банкетлар залында уздырыла икән. Кирәгенчә пөхтә һәм уңай итеп җиһазландырылган, йомшак урындык-кресло, тәбәнәк өстәл. Аларда — Альбина төсле кәттә киенгән ханымнар, берничә ир кисәге, төрле нәселдән олы-кечкенә этмаэмайлар «гапләшә». Өстәлләрдә җаның теләгән җиләк-җимеш һәм эчемлек. Уңай, тыныч, рәхәт. Әгәр дә, җәннәт менә шушы була инде, дисәләр, Ханбал моңа шикләнүсез ышаныр һәм сизенмәстән үзе дә бу сүзнең хак икәнлеген раслый башлар иде.

Альбинаны, килеп керүенә, хөрмәтләп каршы алдылар. Ул түгәрәк узды. Һәммә ханым каршысына килеп, аерым-аерым сөйләште. Кайсы юан, кайсы нәзек, әмма бар да чибәр ул бикәләр, ишек янындагы урынга утырып калган егетне ара-тирә генә караштыргалап куйгаладылар. Ханбал күзләрен Альбинадан алмаска тиеш иде. Үзенә елмаеп карауларыннан егетне ошатмауларының әсәре дә юк икәнлеген аңламау мөмкин түгел иде. Хәтта арадан берсе, тәбәнәгрәк буйлысы, кара чәчләрен маңгаеннан салындырып, үзен киң күңелле хатын кебек тотканы: «Альбинадан соң миңа булырсың!» — дигән төсле сәлам дә бирде, тик Ханбал гына моның мәгънәсен төшенми калды.

Һәркем бокалларына шәраб алды. Альбина егетне үз янынарак дәште, аның баш селкенүенә җавап итеп, Ханбал утырган өстәлен калдырды, төркемгә катышты. Әмма бу кадәр аны теләп һәм сөеп каравыннан башы әйләнеп киткән иде. Аларның нинди сүзләр әйтүләрен дә, ничек беләкләренә ябышып алгалауларын да тәгәл аңлап бетермәде. Гүяки, Ханбалны түгәрәк эченә алып, уңга-сулга әйләндерә иделәр. Ә ул күзләрен Альбинадан читкә күчерергә базмады. Бүтәннәргә житә калды: шунда ук егетне мәҗнүннәр исемлегенә керттеләр. Әмма телләрендә башка сүзләр йөреп, боларны бары тик карашлары белән генә тәкрарлыйлар төсле иде.

Ханбал арыды. Моңа кадәр гомерендә дә талчыкмаган төсле ялыкты. Башы әйләнүдән туктамады.

Ул арада очрашу да башланып китте, һәркем үз урынына утырды. Ханбал тиз генә акылын җыя алмады. Каршында Альбинаның кем хакындадыр җае белән сөйләве, бер ханымның чыгып, дулкынлана-дулкынлана нәрсәләрнедер дәлилләве, экранда якты һәм караңгы ноктлардан торган сурәтләр күрсәтүе тиз-тиз алышынып торды. Ханбал болардан һич нәрсә аңламады. Эчке дулкынлануы тышкы тоемсызлыкка әверелгән иде. Әмма, алдан ук программалашкан робот шикелле, күзләрен гел Альбина тарафында тотты. Ахыр чиктә үзенә һичкемнең игътибар күзе салмавын сизенгәч кенә кире дөньяви халәтенә кайта башлады. Ул хәзер барысын да ишетә, әмма аңлап кына житеп бетерми иде.

Сүз йолдызлар, космос турында бара икән. Боларны бәян итүче ханым, кыска буйлы, Себер йөзле, сәеррәк бер кеше иде. Ара-тирә шигырьгә күчеп, аннан кабат төрле дәлилләргә һәм фәнни фаразларга кайтып, күңелләрне яулап алырлык рәвештә сөйли. Башкалар, әллә чыннан да кызык табып, әллә юри генә инде, аны йотылып тыңлагандай иделәр.

— Безнең кояш системасы,— дип тәкрарлый иде ул,— әле ярты гомерен дә узмаган. Галимнәр исәпләвенчә, җир шары бернинди хәвефхәтәрсез тагын да алты йөз миллион ел яшәячәк. Бу саннар безнең өчен ничектер чикле кебек тоелса да, аларның башы-ахыры юк икәнлеген төшендерәсем килә. Без, астрономнар, җир йөзе мәсьәләләреннән бик ерак торуга карамастан, поп һәм мулладан да динирәк булсак кирәк. Мин коллегаларым арасыннан Аллага ышанмаган бер генә кешене дә очратканым юк. Бу хәл коммунистлар чорында да яшәде, хәзер дә бар.

Әгәр дә безнең йолдыз һәм йолдызлыкларны туктаусыз өйрәнүләребезнең ахыры нәрсә, дип сораучы табылса, әйтә алам: мин үзем Аллаһы тәгаләне эзлим. Әйе, күпләр миңа ышанмыйлар һәм мине төшенә дә алмыйлардыр. Ничек инде, янәсе, йолдызларның туып, ни рәвешле һәлакәткә килүен дә күзләре белән күзәтеп торган галимә ханым Аллага ышана, дип. Хәзер үк җавап бирә алам: болар берсе дә гади рәвештә генә бармый. Гүяки, бу олуг галәм машинасы белән, гафу итәсез «галәм машинасы» диюемне, кемдер, бер бөек зат идарә итә, аның төзеклеген һәм тәртиптә торуын саклый-кайгыртадыр сыман. Чиксезлеккә омтылган саен чикләрнең юклыгын ачыграк аңлыйсың. Галәм ул — мәңгелек, шул ук вакытта терек тә, безнең белән сезнең кебек, әмма тере калу мәңгелек белән берничек тә тәңгәл килә алмаганлыгын сез беләсездер. Тереклек мәңгелек була алмый. Без туабыз, яшибез, үләбез. Галәм өчен төп канун менә шушыннан гыйбарәт. Икенче төрле әйткәндә: бүген тудык, иртәгә яшәячәкбез, берсекөнгә үләчәкбез. Һичкемгә кирәгебез юк төсле. Һәм бәндәләрнең барлык уй-омтылышлары менә шушыңа буйсындырылган. Бүген табып, иртәгә куанып, берсекөнгә аны юк итәргә, аннан баш тартырга. Гүяки, безнең тормыш бер көнлек кенә. Ә ул, чыннан да, шулай. Ул бары тик бер көнлек. Моны күптән Шәрекъ фәйлүсүфләре ачыклаган, шагыйрьләре сөйләгән...

Кабатлап әйтеп үтик: галәм кануннары буенча, яшәеш — бер көнлек хакыйкать. Ул бүген бар, иртәгә юк. Әмма аның юклыгы — үлем, барлыгы исә яшәеш белән аңлатылмый. Яшәеш бервакытта да үз рәвешендә генә кала алмый, әгәр дә ул һаман да бер төрле генә икән, димәк, ул әле терек түгел. Яшәеш бер хәлдән икенчесенә керергә, аннан тагын башкасына күчәргә тиеш. Сезнең көннәрегез төсле, ул кичә болай иде, иртәгә тегеләй. Һәм бу вәзгыятьне туктату мөмкин түгел. Аны туктаттыңмы, димәк, үлдең, беттең, дигән сүз. Әмма безнең, югары акыл ияләренең, ягъни катлаулы оешкан матдәнең яшәве өчен шартлар бар, сез аларны миннән дә яхшы беләсез. Аның төп шарты, әгәр дә моңа кадәр башыгызга килгән икән, бик әйбәт, аның төп шарты — мәхәббәт! Әйе-әйе... Мәхәббәт. Әгәр дә ул сүнә икән, димәк гомер дә бетә, кешеләргә чир йога, авыру килә, аның артыннан — кабер. Әйе-әйе... Мәхәббәт төрлечә булырга мөмкин, берәүгә багышланган гомерлек мәхәббәт, ягъни бер кешене генә ярату, аннан башка яшәүне күз алдына китерә алмау. Моны без «илаһи мәхәббәт» дип атар идек. Аннан соң чуарлык таләп итүче мәхәббәт, монысы инде гөнаһ аркасында барлыкка килеп, бары тик алга таба да шулай гөнаһлы рәвештә яшәүне таләп итә торган мәхәббәт. Аның объекты күп вакыт кем икәнлеге, аның кемгә насыйп кылынганын белү шарт түгел. Ул мәхәббәт бары тик очрашкан вакытларда гына үзенең татлы җимешен бирсен дә, гашыйклар бер-берсенә тулысынча бирелсеннәр, онытылсыннар гына. Әхлак принципларыннан чыгып карaганда, монысын бозык мәхәббәт, шайтаный сөю-сәгадәт, дип тә атыйлар. Мәхәббәт башка төрле һич була алмый, аның өченче һәм дүртенче төре юк. Моны белергә кирәк. Шайтаный мәхәббәт — вакытлы күренеш, ул һәрвакыт уен таләп итә, көннәрнең берендә туйдыра, оныттыра һәм башканы эзләтә. Моны, икенче төрле, азгынлык, дип тә атыйлар. Кайбер фикер ияләре бу тип сөюне сәгадәткә санамыйлар һәм кискен ялгышалар. Чөнки галәмнең төп кануннарыннан берсе нәкъ менә шушы принципка корылган. Билгеле, сез монда ана белән бала арасындагы мәхәббәтне исегезгә төшерерсез, туган туфракка мәхәббәтне һәм башкаларны. Әмма болар гомуми әйберләр, гомуми төшенчәләр, алар мәхәббәтнең икенче төрлесе. Алар шунлыктан һәркемгә ачык аңлашыла, берсүзсез кабул ителә. Бу мәхәббәтләр алга таба яшәеш, яңа сыйфат үзгәреше хасил итүдән чикләнгән. Алар кимеми һәм артмый. Алар, әйтик, хистән үбешүгә, үбешүдән кочышуга, кочышудан башкасына күчүне таләп итми. Шуның өчен дә мин аларны җан ризыгы дип кенә атар идем. Ягъни, адәм баласы ашый, чөнки ашыйсы килә, кызыга, чөнки нәфсесе бар, ала-куя

һәм башкалар, киенә... Болар барысы да тән таләбе. Шулай ук туганнарны ярату, әти-әнине, туган туфракны — болары җан таләбе. Алар, җан һәм тән таләпләре, кешелек үсеше вакытында шулкадәр үзара буталып беткәннәр ки, җанныкы, дигәндә, тәннеке дә кебек, һәм киресенчә аңлашыла башлый. Без әгәр дә чын мәхәббәтне күз алдына китерсәк, аның призмасы аша караганда барысы да ачык төсләр кебек аерылып китәләр. Тәннеке тәннең үзенә, җанныкы — җанның үзенә. Ә мәхәббәт асылда тәннеке дә, җанныкы да. Дөресрәге, җан кабул иткәнне тән таләп итүгә керешә, әгәр дә беренчесеннән соң икенчесе килми икән, ул вакытта без аны «бәхетсез мәхәббәт» дип кенә атый алабыз.

Кояш системасының барлыкка килүе дә нәкъ менә шушы закончалыклар белән бәйләнгән. Төп шарты, әгәр дә халык сүзе белән әйтсәк, мәхәббәт булуда. Шартлы рәвештә аталган бу сүз асыл мәгънәне ачыклап бирә дип уйлыйм.

Менә, сез бу сурәттә томанлык күрәсез. Анда болыт-болыт кебек кара һәм ак урыннар бар. Аның кайсылары — яна торган йолдызлар, ә башка урыннары — киресенчә, сүнгән, якты бирмәүче тузан һәм бушлыклардан гыйбарәт. Безнең кояш системасы да кайчандыр шушы рәвештә галәмдә яшәгән, аны һичнәрсә борчымаган. Ул, сабый бала төсле, җиһан-ана кочагында гомер кичерә. Космик тузанны үзенә җыя тора, авырая, үсә, ныгый. Шулай итеп, миллиард еллар узып китә. Ә ул һаман да камыр хәлендә.

Монысына игътибар итегез. Бу сурәттә сез бөтенләй башка әверелешкә тап буласыз. Без, астрономнар, аны «мәхәббәт» төене» дип тә атыйбыз. Менә ул, ике кызыл нокта, гүяки, ике гашыйкның бер-берсен яратулары аркасында янып торган йөрәкләре төсле. Әмма бу процесс әүвәлгесеннән тизрәк һәм ашкын көч белән бара. Бу ике үзәк бер-берсенә тартыладыр. Кыз тирәсендә егет ничек бөтерелсә, боларның менә монысы, зуррагы, икенчесе, кызыллыгы белән көчлерәге тирәсендә хәрәкәт итә башлый. Гүяки, үзенә буйсындырырга омтыла һәм аның үзәгенә үтеп керә, шартлау хасил кылына һәм яңа бер яшәеш рәвеше башланып китә. Томанлык, яки камыр, диик, хәрәкәткә килә, йөри, әйләнә. Тотрыклы гаилә төзегән кебек, бу ике кызыл нокта бергә кушылалар. Аның берсе — тозакта утырган кыз төсле, икенчесе — аны яраткан ир рәвешендәрәк. Икенче төрле без аны Кояш, яки йолдыз, дип атыйбыз. Димәк, йолдыз булу өчен ялгыз яну зарур түгел. Ялгызлык, киресенчә, сүндерүче итеп карала ала.

Кешеләр арасында да шулай бит, гашыйкларга күңел тартыла, алар хакында гайбәт сөйләүгә караганда, шигырь язу яки җыр чыгару мактаулы эш санала. Моны шул рәвештә күз алдына китерергә мөмкин. Боларның мәхәббәт ялкыны үз тирәләрендәге космик тузанга да күчә. Ваграклары янып, юкка чыга, эрерәкләре укмашкан урында ялкын озаккарак дәвам итә. Безнең җир шары да кайчандыр шушы рәвешле ялкын эчендә яшәгән. Аны да без йолдыз дип исәпли алабыз. Әмма ул сүнгән. Чөнки башкалар мәхәббәтендә җылынучы кебегрәк токкан үзен.

Мәхәббәт кешеләрне ничек яшәүгә чакырса, аларны хәрәкәтләнергә, тормыш өчен кирәкле шартлар тудыруга этәрсә, монда да шулай. Бу куш йөрәкле үзәк бер бөтенгә әверелеп, үзенең хәрәкәтен дәвам итә һәм тирәсендә сибелгән космик тузанны ияртеп, кайсын яндырып юкка чыгара, ә кайсының әйләнеш тизлеген көчәйтә. Шулай итеп, кояш тирәсендә йолдызлар барлыкка килә, аннан алар планеталарга әвереләләр. Боларның берсе — безнең Җир шары...

Ханым моннан соң да шактый сөйләде. Төрле фәнни кагыйдәләргә һәм формулаларга кереп китте. Әмма алары бу клуб әгъзаларына һич тә кызык түгел иде инде. Ханбал моның фаразмы, әллә инде чын мәгънәсендә фәнни дәлилләнгән теорияме икәнлеген төшенә алмады. Хәер, кирәге дә юк иде төсле. Астрономнарның да кайвакыт, астрологлар шикелле, бәндәләрнең игътибарын үзләренә каратасылары килә торгандыр. Бәлки, чыннан да, хакыйкатьне ачыклагандыр?

Һәр сүздә мәгънә булса, анда гыйбрәткә дә урын бар. Очрашу тәмамланганда Альбина җылы хисләр уянган күңелен чак тыеп тора иде. Ханымның чыгышы аны тәмам аяктан екты, сүзсез калдыру дәрәҗәсенә җиткерде һәм ул бәхетнең менә шушындый мәхәббәт белән бергә генә киләсен аңлап алды. Аңа салкын күзләре белән карап утырган Ханбалның уйлары кайда йөзгәндер, әмма Альбина бары тик аның хакында гына хыялланды. Әгәр дә ире Геннадий инде сүнгән йолдызны хәтерләтсә, Ханбал аның өчен әле яңа дөрләп кабынып килүче иде. Ни өчен егет тәвәккәлрәк түгел соң, нигә бөтен барлыгын вә юклыгын онытмый, мәҗнүнгә тулысынча әверелеп җитми? Әгәр ул да шашса, аларның икесеннән дә бәхетлерәк кеше бу дөнья йөзендә булмас иде.

## 21

Альбина машинасын Ханбаллар подъезды төбенә туктатты. Инде караңгы төшкән иде. Ханым китәргә дә, чыгарга да ашыкмады. Тыныч кына утырып, егетнең нәрсә булса да әйтүен көтте. Бу мескен исә кичәнең шушы кадәр дә затлы үтүенә хәйран калып, телен йоткан иде.

— Кайтып җиттегез түгелме? — диде Альбина.

— Юк,— диде Ханбал,— кайтып җиттегез түгел, җиттек! Мин сине үземә чакырам, чәйгә...

Ханым көлеп куйды.

— Бу вакытта, шушындый мәҗлестән соң нинди чәй инде ул? Арылган, бүген мөмкин түгел.

— Ә кайчан мөмкин? — егетнең ханымны югалтасы килмәгәнлеге аңлашылып тора иде.

— Мин үзем белдерермен, килеп чыгармын!

— Юк... Юк-юк, андый билгесезлектә мин ничек түзеп яшәрмен? Сине бит кайдан табарга да белмим. Йортыгызны күрсәттегез, ә фатирыгызны?

— Илле бишенче фатир... әмма килеп йөрү юк. Бик кирәксә, почта тартмасына хат ташларсың.

Егет диванага әверелгән, ул хәзер тәмам диярлек Альбинага гашыйк булган, аның алдыннан тузан сыпырырга әзер иде. Әмма ханым бер дә сер бирми. Аңа бик кирәк инде синең кебек уҗым бозаулары!

Ханбал ишектән чыгарга тартылды. Альбина туктатмады. Димәк, егет аңа кирәк түгел.

— Ярый, хушыгыз!

Үпкәләгән кыяфәт белән Ханбал ишекне япты, китәргә дип борылды. Шунда гына Альбина аны исеме белән дәшеп туктатты. Өс-башына ишарә итте. Егет моны сизенде дә:

— Аһ, гафу итегез, салырга, чишенеп калдырырга онытканмын,— дип төймәләренә ябышты. Ул, чыннан да, хәзер киемнәрен алыштырырга мөмкин иде. Альбина аны бу ниятеннән туктатты:

— Юк, болар сиңа, әйе-әйе, сиңа бүләк! Салып калдырсаң, үпкәлим үзеңә, башка бервакытта да очрашмыйбыз!

— Рәх-мәт,— дип иҗекләде, аптырап калган Ханбал. Үз гомерендә чит кешедән мондый бүләк алганлыгы булмау сәбәпле, ул нәрсә диярга дә белми иде. Әмма Альбина аны тагын да үтереп ташлады:

— Бусы да сиңа. Кухня тәрәзәң челтәрсез, әләрсең! Килештекме?

Пакетка салынган җиңел әйберне кулына алуга, егет тагын рәхмәтен кабатлады. Әмма кире бирергә яки баш тартырга батырчылык итмәде.

— Бары шул гынамы?

Альбинаның нәрсә әйтергә теләгәнен Ханбал аңлый алмады. Ханым иреннәрен сузды.

— Бәлки, үбәрсең!

Ханбал бар дөньясын онытты. Алар үбешкәндә Айзик шыңшыпшыңшып боргаланды.

— Мин сине яратам,— дип пышылдады Альбина.

— Мин дә яратам,— диде егет.

— Айзик та сине ярата,— диде ханым, чын сүзне уенга борып,— хәзер иремне дә янәшәдә яткырмый, ә синнән үптертә. Башсыз түгел, диген, күңелдәгеен ул да белә...

Тагын бер-ике сүздән соң алар очрашу хакында вәгъдәләшеп аерылыштылар. Ханбал аның машинасы күздән югалганын озак күзәтеп торды. Кереп китәргә ашыкмады. Аңа рәхәт иде. Күңеле тантана итә, сөенә, куана. Әгәр дә мөмкин, дисәләр, ул хәзер Айга кадәр менеп җитәр иде. Бәхетлеләр күккә сикерә, хәсрәтлеләр җиргә сеңә шул.

* * *

Марфа түтинең вафатыннан соң өч көн узуга, туганнары тәмам җыелышып, аны соңгы юлга озатырга килделәр. Подъезд төбендәге табут өстенә кара тәре куйдыртсалар да, кызыл төс белән тукыма тарттырган иделәр. Бар борчуларыннан азат калыр өчен Ханбал да анда чыкты. Башка күршеләре дә шушында иде.

Менә хәзер, тиздән алып китәрләр сыман. Әмма ни сәбәпледер ашыкмыйлар. Машиналары да килеп җитте, югыйсә. Ә Ханбалның эче тулы шом. Кичә Альбина белән саубуллашып калганнан соң фатирына керде һәм гомерендә беренче тапкыр диярлек мондагы шыксызлыкка игътибар итте, аңа күңелсез булып алды. Әгәр дә язмыш көяз хатынның мәрхәмәтенә юлыктырмаса, ул шушы рәвешле күңелсез тормышын уздырып ятарга да мөмкин иде. Ярый әле вакыты үткәч түгел, нәкъ кирәк чагында таныштылар.

Альбина бүләк иткән костюмны саласы килмичә, хәтта чәен дә чишенмәгән килеш эчте. Аннан соң төргәкне ачып карарга булды. Анда, чыннан да, кухнясына яраклы челтәр-пәрдәләр иде. Боларның затлылыгы Ханбал фатирына түгел, музейга эләрлек. Шулай да егет куанып куйды: ничек матур булачак болар!

Ә төнлә төш күреп саташты. Гүя, Марфа карчык, кара киемнән аның фатирында йөри икән, әллә нигә почмакларны карый, нәрсәдер эзли, тикшерә, ә үзе зәңгәр күзләрен яндырып төбәлә. Ни кирәк аңа? Нәрсә сорый ул? Челтәр-пәрдәнеме? Кулын суза, салкын, җан өшеткеч. Нидер сөйли. Хәерлегә түгел, дип мыгырданамы шунда? Бу нәрсә тагын? Нигә төргәкне чишә? Ул бит аныкы түгел. Көлә? Ничек начар итеп көлә! Ерткалый? Нигә телгәли ул челтәр-пәрдәләрне? Яндыра да түгелме? Юк икән! Ирен чакыра. Федор абзыйның, кулына таяк тоттыра, ахрысы?» Хезмәтчем бул, хезмәтчем!» — дип көлә. Нәрсәгә көлә? Ханбал иртәгә Альбинага ни әйтер? Бер юләр карчык телгәләде челтәреңне, диярме? Тукта, бу карчык үлгән иде түгелме соң? Әйе-әйе, вафат ул, вафат!..

Йокыдан тирләп-пешеп уянган җиреннән, егет үз-үзен белештермичә кухня ягына чыкты. Каршысыннан Марфаның шәүләсе үтеп киткәндәй тоелды. «Әгүзе биллаһи...» Юк икән, әллә ниләр күренә. Мөгаен, кичәдән алган тәэсирләре бетеп җитмәгәндер. Ә шулай да күңелле булды бит. Теге галимә хатын күп кенә кызыклы нәрсәләр хакында сөйләде, бәлки ул, чыннан да, дөрес фикердә тора торгандыр. Фәннең инде аның очыкырые юк. Фәлсәфәсенең бигрәк тә! Ә тормышны аңлыйсы килә. Төбенә төшенденме, бәхетле итеп яшәү серен дә беләсең. Ә бәлки кирәк тә түгелдер. Чыннан да, гадидер аның кануннары? Бер көнлекме бу тормыш? Бүген тудың, иртәгә яшәячәгең берсекөнгә исә үләчәксең. Бернинди авырлык та, борчу да юк. Намусыңа да тугрылыклы калдың, вөҗдан газабын да кичермисең...

Бер уянгач, Ханбал йоклап китә алмый йөдәде. Гүяки, менә хәзер тагын төшенә Марфа керер, аны борчыр, куркытыр сыман иде. Шулай таң аттырды. Кояш беленә башлаганда гына күзләренә йокы эленде.

Менә хәзер монда басып тора. Алып китсеннәр иде инде. Ханбалны авыр тойгыларыннан азат итсеннәр. Аның әле эшләре җитәрлек. Бернечә көнгә генә булса да туганнарын күреп, Әлмәт-Җәлил якларыннан әйләнеп кайтасы бар. Барып, автобуска билет алырга кирәк. Алдан хәстәрен күрмәсәң, юл мәшәкатеннән аптырап бетәрсең.

Подъезд ишегеннән авыр табут күренде. Күпләрнең күзендә яшь, аерылу газабыннан күңелләре ватык иде. Алар Марфа түтинең мәңгелеккә китүен шулай авыр кичерәләр. Үлем бервакытта да шатлык алып килми, һәрхәлдә, яшәп калган кешеләр өчен; ул бары тик киткәннәргә генә сөенеч. Бер көнлек дөньядан аерылу, мәңгелеккә ирешү — моны бирәүләр диннәре өйрәткәнчә аңлый. Анда кемне нәрсә көтә, һичкем белми, бу бары тик Аллаһыга гына мәгълүмдер...

Озатучылар арасында Регина да бар иде. Ханбал белән бер-берсен тиз танып алдылар, баш кагып исәнләштеләр. Ире дә мондадыр инде. Анысын егет танымый. Әмма дә Регина үзгәрмәгән, матурланыбрак та киткән түгелме? Әйтүләренчә, ире урыс бугай. Игорь, диме шунда, башкамы. Бер балалары да бар түгелме әле. Шунысы гына инде, ире эчә, вакыт-вакыт тавыш чыгаргалый, аптырата икән Регинаны, дип ишеткәләгәне бар Ханбалның, анысын Марфа белән Федордан түгел, андасанда очраштыргалаган танышларыннан гына. Әмма аның өчен Регина хәзер кызыклы түгел. Хисләре чын йөрәктән булмады микәнни? Кем белә, бәлки барысы да янып сүрелгәндер? Әллә иргә чыгуы аркасында егет хәтереннән сызылып ташландымы? Нигә инде аннан Марфа карчык булмастай эшне таләп итте? Ханбал нишләргә кирәклеген үзе дә бик яхшы белә бит.

Алып киттеләр... Егет үкергән машиналар артыннан карап калды. Күпләрнең күзләрендә яшь бөртекләре күренсә дә, Ханбал тыныч кебек иде.

Шәһәрдә йөреп, кирәкле аз-маз күчтәнәчләр җыйгалаганнан соң, фатирына Ханбал кайтып кергәндә Марфа карчыкның «поминкасы» башланган иде инде. Мөгаен, исереп тә киткәннәр булса кирәк, авыр һәм озын көйләр дә җырлаштырып, тавышланышып та алгаладылар. Егетнең эшләре әллә ни юк иде, чакырулы исә дә, урыс туена менүне яхшысынмады. Альбина бүләк иткән челтәр-пәрдәләрне эләргә уйлады. Әмма кадак-чүкеч тавышы белән исерекләрнең ачуын китерергә мөмкинлеген аңлап, бу фикереннән кире кайтты. Шулай да төргәктә калдырасы килмәде. Элекке хуҗалардан калган кадакка гына булса да эләргә исәпләде.

Кухня ягы бер карауга чибәрләнеп, ямьләнеп китте. «Моны залга да эләрлек икән, нигә монда кушты икән?» — дип уйланып, Ханбал урынын җәйде. Исенә төшереп, китәсе хакында Альбинага белдереп куярга кирәклеген уйлады һәм төгәл адресын күрсәтеп тормастан, хат яза башлады.

**«Кадерле Альбина ханым!**

**Ачуланма, мин туганнарымны күреп килергә уйладым. Иртәгәгә Әлмәт автобусына билет алдым. Бер атнадан әйләнеп кайтырмын дип уйлыйм. Мин сине яратам! Сагынырмын инде! Син дә онытма, күкләрдән бары шуны гына телим! Хуш, сау бул! Озакламам.**

**Ханың-балың, ягъни Ханбалың».**

Башта теләмәсә дә, китү вакытын төгәл күрсәтергә булды, аннары үзе белән аласы барча әйберләрен бер сумкага тутырды. Бу эше генә беткән иде, ишектә кыңгырау чылтырады. Һаман да Альбина хакында гына уйлаган егет моны да ул дип юрады, әмма ялгышты. Ишекне ачса, анда Регина басып тора иде.

— Исәнме, Ханбал! Әллә оныттың дамы? «Поминкага» да менмәдең, сине чакырулы дигәннәр иде.

— Анда мин артыктыр...

Регина сәрхүшрәк иде. Ханбал аны фатирына чакырмады. Әмма хатын тиз генә китеп барырга җыенмады, үтәли карап торды да:

— Чакырмыйсың да... Сөйләшеп алсак, дигән идем,— дип белдергәч, үтәргә өндәгәндәй итте.

— Синең сараең шушымыни инде?

— Ат сараең, димәкчеме?

— Юк, син бит — Хан-бал! Хан сараең, димәкчемен шул!

Әллә инде Федор абзыйлар фатирының һавасы шундый, Регинаның чәчләреннән Марфа түтәйнең исе килә иде. Ханбалга авыр булып китте. Шулай да кунакны куып чыгару ярамас иде.

— Чәй куяргамы?

— И Ханбал, сыйлыйсы килгән кеше сорап торамыни ул?

Регина кисәк кенә борылды да егетнең җилкәләренә кулларын куйды.

— Ни булды, Регина? Авырмы әллә...

— Бик авыр, Ханбал, бик авыр...— дип Регина шунда егетнең башына маңгаен терәде.— Синсез бик авыр, бәгырем телгәләнә. Белә идем, белә идем мин синең монда, бабайларга күршедә яшәгәнлегеңне, килергә батырчылык итмәдем. Бүген-иртәгә, дия-дия калды. Сагындым мин сине, Ханбал! Мин бит сине яратам, беләсеңме шуны, яратам...

Егет аны тынычландырырга ашыкты. Баштарак аптырап калса да, аннан соң ире барлыгын, кызын исенә төшерергә тырышты. «Альбина белән моны бер-берсенә охшатып аптыраткан идем, тәңгәл килер җирләре юк икән!» — дип көенде. Әле кайчан гына онытa алмый газапланган мәхәббәте күптән сүнгән, көле дә калмаган төсле иде.

— Регина, ирең дә монда бит. Нишлисең син? Бар, мен, тынычлан! Аның алдында нәрсә әйтерсең? Ачуланыр бит!

Хатын хахылдап көлә башлады.

— Улмы нәрсә әйтер? Ул чүпрәкме? Әллә кайчан исереп ауды инде! Аның бар белгәне шул! Исерә дә ава, исерә дә ава... Ә мин сиңа килдем... Сине эзләп! Үзең йөри белмәдең, ташлады, дип үпкәләдең! Ә мин ташламадым. Юләр булганмын. Әби сүзен тыңладым, ул мәрхүмә, үзе дә бәхет тапмады, миңа да күрергә насыйп итмәде. Җимерде дә куйды!

Ханбал хәзер Регинага әбисенең соңгы сүзләрен әйтергә тиеш иде. Һәрхәлдә, бүген исерек, айныгач белдерермен, дисә, кайчан эшләячәк? Әллә Федор агайдан гына сорасынмы?

— Ул гафу үтенде бугай... Ни, Марфа әби мине дә чакырган иде, синең хакта күп сөйләде ул. Федор абый иртәгә әйтер әле.

— Чукынып китсеннәр барысы да. Миңа аларның берсе дә кирәк түгел! Мин сине эзләп килдем. Синең белән очрашу өчен. Ханбал, мин сине яратам! Белеп торам, син дә минсез яши алмыйсың! Шуңа күрә өйләнмичә йөрисең... Ал мине менә шушы килеш, ал!

Хатын шашынып китте һәм өстендәге кофтасын салып ташлады.

— Кил мондарак, кочакла мине, Ханбал, синең иркәләвеңне, яратуыңны телим...

— Ярамый, Регина!

— Нигә ярамасын? Яратышкан кешеләр бергә булырга тиешләр. Дөньяда бу эш әхлаксызлык, дип атала алмый. Киресенчә, кемнәр мәхәббәтсез бер-берсе белән яшиләр, алар әхлаксыз! Алар дөнья йөзен әшәке итеп бозучылар. Кеше җаны ирекле кош кебек. Әмма ул кемне дә сайлый икән, гомерлеккә...

Регинаның күзләрендә яшь бөртекләре күренде. Ул битләрен учы белән каплады һәм, килеп, бүлмәдәге утны сүндерде. «Ояладыр!» — дигән уе белән Ханбал аның бу эшенә каршы төшмәде. Әмма хатын күңелендә башка ният тә бар икән. Монысы соңрак беленде.

— Хәзер болар хакында нигә искә төшереп торырга. Буш фәлсәфә кебек кенә бит бу. Әйе, яраттым мин сине, Регин, саташып-саташып яраттым...

Тагын да шулай тезеп китсә, Ханбал бу юлысы да сүзләр ярдәмендә хисләрен уятып, мәхәббәт учагын кабат тергезеп җибәрергә мөмкин иде. Әмма араларына Альбинаның назлы сылу гәүдә сурәте керде. Сүзләреннән егет туктап калды. Ә Регинага шулар гына кирәк булган. Ул кабат Ханбалга таба елышты һәм үбә башлады.

— Исеңә төшер, Ханбал, исеңә төшер барысын да...

Егет артка чигенде, караватына туры килеп, буйга сузылды. Регина аны ургылып үбә-коча башлады. Аның авызыннан аракы һәм ачый төшкән кәбестә салаты исе килә иде. «Эчкән, хәзер моңа күңел юаткычы кирәк инде!» — дигән уй егетнең акылын ярсытты, әмма хатынның назлауларына күңеле килеп, кузгалмый торды. Чишелгән төймәләре аша үтеп, күлмәгенә урала-урала, Регина аның күкрәкләрен үпте һәм кабат иреннәренә үрелде. Теге аракы белән укмашкан әчкелтем кәбестә исе тагын Ханбалның борынына керде. Аның саен гайрәтен чигерә иде.

«Мәче исләре килә!» Шушы рәвешле уйлаган егетнең күңеле укшыды, чыннан да шулай бит, Федор абзыйлар фатирына кергәндә, әллә нинди ят һавадан шикләнде, моны үлем хәбәре дип уйлады, мәче исе икән ләбаса...

Ханбал читкә тартылды. Бу вакытта Регина күтәрелеп, өстеннән барча киемнәрен салырга тотынды һәм тиздән анадан-тума хәлендә калды. Аны ничек тә авызлыкларга белмәгән егет көчек кебек урынга сеңәргә яки чыгып качарга тиеш иде.

Була бит шулай, кулыңнан килмәгән эштә кемнеңдер ярдәме тия һәм ул сине бәладән коткара.

Ишектә кыңгырау бирделәр. Көтелмәгән бу хәлдән Регина артка чигенде. Кыңгырау артыннан ишекне төя башладылар. Анда бер исерек ирнең нидер таләп иткән тавышы бөтен подъездны яңгыратты:

— Регина, мин синең анда икәнеңне беләм!

Ханбал монысын ук көтмәгән иде. Хәзер керә калса, нәрсә эшләтә алачак ул аны. Гаебем юк, дип тә әйтә алмаячак. Әнә бит, иредер, Игоредер? Кем булсын тагын.

Ишекне төюче каты сүгенеп куйды. Ул да түгел, ничек бар шулай, хатын киемнәрен күтәрде, уңга-сулга тартылды. Нәрсә эшләргә дә белми, үзе һаман пышылдый:

— Ирем бит бу, ирем...

Ханбал да сикереп торырга мәҗбүр иде. Әле яңа гына бөтен дөньясына төкерергә әзер булган хатын, әллә оятыннан, әллә көтмәгәндә айнып китүеннән, почмакка сеңде. Ашыгып киенә башлады. Әмма һичбер киеменең рәтен-җаен таба алмыйча газапланды.

Егет ишек янына килде. Әгәр дә ватып ача калса, ничек тә туктатып калдырырга иде исәбе. Ул арада ирне кемдер тынычландыра башлады:

— Игорь, Игорек, син нишлисең?.. Бөтен кеше йокыда, ә син? Нигә тавышланасың? — Бу кеше, сыйпап кына диярлек сөйләүче, Регинаның бабасы Федор иде. — Кем кирәк? Монда синең хатының кайдан килсен? Ул кухняда калды, җыештырып... Шундый көндә бит, бөтенләй акылыңны югалтып. Болай да кайгыбыз баштан ашкан. Ә син читләр ишеген кагып йөрисең. Кайтыйк өйгә, әйдә, кайтыйк...

Исерек ир аның сүзләренә колак салмады булса кирәк, этеп тә җибәрмәдеме әле, картлачның кулындагы таягы таш идәнгә шалтырап төште.

— Монда минем хатын, беләм мин...

— Эһ, кияү, ни өчен өлкәннәр сүзенә колак салмыйсың? Хатының табак-савытлар юып калды бит, монда юк ул! Бар, әйдә, күтәрелик. Кешеләр күптән йоклый. Уятып бетерәсең. Ни уйларлар? Анда һичкем юк. Ышанмасаң, кычкыр, төй ишекләрен!

Регинаның монда булуын кем-кем, әмма Федор чамалый иде. Хатынының әйткән сүзләрен исенә төшереп, яшьләргә комачаулыйсы килмәде. Ни дисәң дә, тиздән, бәлки шушы хәсрәтләр үтеп китүгә, Регина Ханбалга кияүгә чыгар, дип исәпли, ире белән аерылышыр, дигән өметтә иде. Нигә шулай булмасын, алар бит бер-берсен үлеп яраттылар. Ул вакытта ук әйткән иде хатынына, кермә яшьләр арасына, дип, тыңлатып кара син хатын-кызны, чыгымлаган ат кебек. «Катышма!» — дип кенә җикерде. Ә ахыры нәрсә белән бетте? Тәүбә беләнме?

— Тәярмен дә!

Игорь шактый исерек иде булса кирәк, йодрык белән төясе урынга, җилкәсе белән ишеккә ышкынды һәм үз хәлен төшенеп, Федор абзыйның үтенеченә колак салырга ниятләде.

— Киттек, Игорек, киттек... Анда һичкем юк. Әллә кайчан ачарлар иде инде. Хатының өйдә бит, табак-савыт юа! Киттек...

Аларның аяк тавышлары ишетелде. Ханбал ишектәге күзне күтәрде. Моны сизенепме, кияүләре кире борылып карады, әмма тавыш ишетелмәгәч, Федор белән менеп китте. Аның атлавына караганда аякларын шудыртуы үрмәләп барган кешене хәтерләтә иде.

Тавыш тынгач, Регина да ишек янына килде. Куллары Ханбалны кочакларга үрелде. «Ну бу хатын-кызны, әле яңа гына аны бабасы бәладән коткарды, ә ул инде икенчесен эзли!» — шулай уйлаган Ханбалның шушы вакытта Регинаны типкәләп чыгарасы килде. Әмма ашыкмады. Ул хәзер үзе дә китәргә мөмкин.

— Мондалармы әле?

Регина пышылдаганга Ханбалның исе китмәде. Аның тавышында аз гына булса да курку вә калтырау бар иде. Егеткә кызык кебек тоелды: «Әле яңа гына бит, синнән башка һичкемне яратмыйм, дип сөйләнгән хатын түгелме соң бу?» — Шушылай диярге дә мөмкин иде, әмма үзен тыеп калды. Үчекләргә исәбе юк, кирәкми.

— Иреңне яратасың икән ич!

Ханбалның мондый сүзен хатын көтмәгән иде. Хәленә керер, тынычландырыр, курыкмаска кушар, дип уйлаган иде. Ә аның өчен Регинаның хисләре бер нәрсә дә түгел. Кызгана да белми. Юк, бу элекке сөеклесе Ханбал түгел, юк-юк.

— Тавыш чыгаруыннан куркам. Ни дисәң дә, ирем бит әле. Аерылыша башласак та мине гаепләве бар. «Сөйрәлчек!» — дисә, нәрсә әйтермен. Кеше алдында бит!

Сүзләрендә хаклык бар иде. Ханбал шунда ук аның белән килеште, әле яңа гына исерек кебек күренгән хатын хәзер айныган төсле. Инде чыгып та китсә, бик яхшы.

— Синең белән сөйләшергә генә дип төшкән идем, әллә ничек булды инде, ачуланма? — дигән үкенечле һәм кызгандырырлык сүзләрен тезеп китте Регина.— Бабай әйтте дә, әбинең сине чакырып,ниләр васыять иткәнен, күңелем кузгалды. Сөйләшергә дип кенә төштем, син моны ук көтмәгәнсең икән...

— Дөрес, көтмәдем.

Хатынның җылы кулларыннан аерылыр өчен Ханбал ут яндырды һәм көлеп җибәрде:

— Син бит киемнәреңне тискәре ягы белән кигәнсең!

Регина көзгегә килде. Ул да көлде.

— Шулай икән шул! Караңгыда күренәмени...

Рөхсәт тә сорап тормастан, кофтасын салды. Күкрәкләре шул килеш асылынып төште. Хәтта итәген дә Ханбал каршысында уңай ягына алыштырмакчы иде дә тукталып калды.

— Карап торма, юньсез, оялтасың бит,— дип әйтеп салды.

Егет арты белән борылып басты, әмма утны сүндерергә батырчылык итмәде. Яңа гына оялган кебек маташкан хатын кабат бәйләнә башларга мөмкин иде.

— Ә шулай да сөйләшә алмадык...

Регина киенеп беткән иде. Ханбал аңа таба борылды. «Ни сөйләшәсең инде?» — дип уйлады, шунда хатынны алдарга булды.

— Иртәгә аңлашырбыз, бүген генә димәгәндер бит! Анда ирең чыгырыннан чыккандыр, бар, мен инде! — диде.

— Ярар, хуш, сау булып тор...— Хатынның өмет зурдан иде.— Иртәгә көндезен төшәрмен. Безнекеләр кибетләргә чыгарбыз, дигәннәр иде, мин синдә калырмын!

— Ярар-ярар, бар, хуш, сау бул!

Ханбал ишекне ачты. Җинел генә шуып чыгарга уйлаган Регина шунда бабасы Федор белән йөзгә-йөз килде. Ул аны эзләп, белеп төшкән иде. Шунда ук нәсыйхәт тә бирә башлады:

— Эһ-һ, кызым, болай ярыймы инде? Ирең тузына, ә син! Аерылышкан булсагыз, бер хәл иде... Кавышыр идегез...

Алар менеп киттеләр. Ханбал иртәгә иртәнге сәгать алтыда автовокзалга барып җитешәсен уйлап, бишенче яртыга будильнигын көйләде дә йокларга ятты.

## 22

Бер тынгылык бирмәсә, бирми башлый икән бу саташулар. Ханбал тагын куркынып уянды. Будильнигы буыла-буыла шалтырый иде. Егет аңа басарга өлгергәнче, кулы белән таба алмыйча интекте, ул арада күзләре ачылды һәм ул юыну бүлмәсенә кермичә кухняга йөгерде. Альбина бүләк иткән челтәр-пәрдәләрне барлады. Алар урыннарында иделәр. Әмма егетнең саташулы төше һаман да күңелен кузгата бирде.

Ничек күрде әле ул? Башта тәрәзә ачылгандай иде. Кемдер керде бугай? Юк, туй бара. Урыс туе. Җырлыйлар. Сүзләре әллә нинди генә шунда, аңлашылмый. Комсомол җыры төсле. Ул да түгел, Ханбал үзе өйләнә икән. Альбинага! Юк, ул булмады әле. Марфа карчыкка түгелме соң? Шуңа! Мәче исе килә. Әллә нинди котсыз, затсыз ис. Ә нигә әле Альбина бүләк иткән челтәр-пәрдәне ябынган ул карчык? Юк, ертып маташа, телгәли түгелме соң? Кем ул анда? Федор, нигә ята ул челтәр-пәрдә өстендә. Йөзе ап-ак! «Син үтердең!» — дип Ханбалга төртәләр. Ә нигә Марфа түти көлә? Ханбалга таба киләме? Таяк күтәргән? Ханбалга нигә таяк? Бирми, буарга маташа. Бүлмә тулы кызыл вак җимеш. Ишек артында Альбина тора түгелме соң? «Әйдә, моннан качыйк, тизрәк!» — дип чакыра. Алар өскә таба йөгермәкчеләр. Кемдер кыңгырау шалтырата...

Бу җан өшеткеч куркынычлардан кая да булса тизрәк чыгып ычкынырга кирәк иде. Ханбал сәгатен карады. Биш тула унбиш минуттан! Студент вакытыннан бирле иптәше урынына озатып йөргән будильнигы шалтыраганнан соң туктап калган иде. Гадәтен һаман саклый тагын. Мөгаен шуның өчендер озак хезмәт итә, кичләрен генә йөри. Уята да туктый, гүяки, йокларга яткан шикелле була.

Ханбал салкын чәй генә эчте дә юлга ашыкты. Аның бит автобуска җитешәсе бар, әле кайчан барып өлгерә?

Альбинага кичтән язып, әзерләп куйган хатны күкрәк кесәсеннән чыгарып, почта тартмаларында калдырды. Тәрәзәсенә күз салып торды. «Шушы булырга тиеш фатирлары, йоклыйдыр рәхәтләнеп! Ярый, хуш, кабат очрашканчыга кадәр!» — Бу рәвешле сөйләнеп алуыннан үзенә дә күңелле булып китте, саташулары онытылып, самими хыял дөньясында ул үз юлыннан ашыкты. Гүя, яшәгән җиреннән түгел, бәлки газаплы һәм тынгысыз эштән качып киткәндәй, хис итте үзен. Алда аны шатлык һәм бәхет көнә көтәдер сыман!

Әмма вакыйгалар башкача юлдан киттеләр...

Иртәнге якта, кеше-кара йөри башлаганчы, Ханбал яшәгән йортның каршысына машинада егетләре белән Варис килеп туктады. Сәгатен карап куйды, алты тулып килә иде.

— Ярый, егетләр,— диде ул аннан соң.— Кузгалыйк! Тавыш чыгарасы түгел. Ишеген ачып керәбез, яткан урынында акылга утыртып китәбез! Бетте!

Ашыкмыйча гына баскычтан күтәрелеп, саклык йөзеннән кеше-кара тавышын тыңлап алдылар. Һичкем юк, тыныч иде. Бары тик өске катларның берсендә генә кемнәрдер йөренә төсле. Ә, сөйләшәләр, аңлашылып җитми, бер хатын белән ир бугай!

Ул арада таза гәүдәле егет ишекне каерып ачты. Эчкә үттеләр. Варис сак кына кереп, кухнядан пычак алды. «Үзенеке үзенә! — дип уйлап куйды.— Үз-үзен харап иткәнгә бер дәлил булыр!»

Ике амбал зал ишегенең ике ягына бастылар, акрын гына ачып җибәрделәр. Монда һичкем юк иде. Варис ванна тарафына ымлады. Анда да кеше-кара күренмәде.

— Аһ, шайтан алгыры, кайда йөри бу?..

Эшләре барып чыкмаганга көенеп куйдылар.

— Монда кемнәр?

Өчесе тиң борылып карадылар. «Бусы кем тагын?» — Варис артларыннан кергән кешегә таба якыная башлады. Шунда ук кызулык белән бер фикергә килде: «Суярга үзен. Кем чакырып керткән? Әҗәлен эзләп йөри, олаксын! Берьюлы ике эш башкарылыр, ичмасам, шаһит та юкка чыгарылыр! Аның үлемен дә фатир хуҗасына сылтарлар, төрмәдән башы чыкмас! Тикшерүчеләрне «дөрес» юлга юнәлтү өчен Геннадий тырышыр!»

Яңа гына Ханбал хакында Регина белән сөйләшеп торган Федор, бу пычаклы кешеләрне егетнең фатирында күрүгә, өнсез калды. Үз-үзен бәладән саклау нияте белән артка чигенде. Әмма подъездга чыгасы урынга чатан аягы кухня ягына таба тартты. Инде котылу мөмкин түгел иде. Аңа чыгу юлын өчәүләп капладылар. Тәрәзәдән сикерсәң генә! Анысы да мөмкин эш түгел.

Шулвакыт Варис аңа Ханбалның кухня пычагы белән китереп кадады. Кулыннан эз калырлык түгел иде. Картның күзләре зур ачылды, ул үтерүчесенең йөзенә текәлмәкче иде дә, перчаткалы олы кулларыннан карашы өскә күтәрелә алмады. Йөрәк турысына әллә нинди җылыкайнар тимер керде. Шашыныр дәрәҗәгә җитте. Кычкырырга теләде. Тавышы чыкмады. Ул арада тегеләр таю ягын карадылар. Әле һаман да үзен егылмыйча тоткан картлачның күкрәгән капшаган кулы кара кан иде. Ул үзенең үлеп барганын тойды. Ханбалга Альбина бүләк иткән челтәр-пәрдәгә ябышты. Гүяки, шушы чүпрәк аны һәлакәт тырнагыннан алып кала төсле иде. Әмма ул арада хәле китте, асылынган пәрдә-челтәр бавыннан өзелеп, Федор идәнгә ауды, җан бирде.

Регина аның Ханбал яныннан менгәнен үз катларында түземсезлек белән көтте. Ире торганчы сөйләшеп калырга иде исәбе. Аңлатырга егеткә бар хәсрәтләрен, кирәк икән, гафу үтенергә! Ярата бит ул аны, ярата! Белеп торсын! Ханбалны ул хәзер һичкемгә бирмәячәк!

Урамда кояш акырын гына күтәрелә-күтәрелә, көннең кызу булачагын белдереп, инде хәзердән үк мул елмая иде...

Альбина да вакытыннан элек йокысыннан торды, Айзикны йөртергә чыкты. Гадәте буенча почта тартмасына күз салды. Аннан хатны алып укыды һәм Ханбалны эт итеп сүгеп ташлады. Түзмәгән бит, китеп барган! Альбинага кирәк чагында, ахмак! Рөхсәтсез йөрергә ни хакы бар! Әнә, аның белән чагыштырганда, Айзик акыллырак, хуҗасы кая кушса, шунда гына чаба, тавыш-гауга да чыгармый. Бөтен булганлыгы белән тугрылыклы.

Шулай да алар Ханбалларның йортына якынлаштылар. «Йоклап калса, һай шәп, кызык булыр иде!» — дип уйлады Альбина, Айзикны күздән югалтмаска ашыгып.

Бу вакытта үз эшләрен кылып, урамга атылып чыккан Варис һәм аның иптәшләре Альбинага туры килделәр. Ашыгулык сәбәпле ханымга игътибар да итеп тормадылар, ә ул аларны ачык таныды. Тик нишләп йөргәннәрен генә уйларга өлгермәде. Кешенең эше бетә димени?

Варислар машиналарын шудыртып кына диярлек кузгатып, тавышын да ишеттермичә юк булдылар. Айзик арлы-бирле чапкан жиреннән сәерсенеп алгалады. Альбина монысына да игътибар бирмәде. Эте өреп куйды. Ханым: «Тукта әле, Ханбал йоклап калмаган микән, менеп төшимме әллә, үзен үртәп?» — дип уйлады, кәефе килеп, авызы ерылды. Әмма кинәт кенә төсе качкандай булды. «Бу Варис монда нишләп йөри соң әле? Тукта әле, Ханбал... минем өчен!..» — дигән шиге йөрәген яндырып узды. Ул да түгел өй эчендәге бер хатынның чинап җибәргәне ишетелде. Тавыш кат-кат кабатланды. Айзик сагаеп калды. Ул арада кешеләр күренгәли башлады. Кемдер, монысы икенче берәүнең тавышы:

— Үтерделәр! — дип кычкырды. Айзик подъездга ташланды. Аның артыннан тыны бетә-бетә Альбина ашыкты. Өченче этажга менеп житкәнче күз аллары караңгыланды. Аңа хәзер кая барырга күрсәтүче кирәкми иде. Ханбал фатирының ачык ишегеннән узды, җыелып өлгергән халык төркемен ерып кухняга узды. Исе-акылы китте. Анда, идәндә, Альбина үзе бүләк иткән челтәр-пәрдә өстендә батып бер картлач ята, күкрәгенә кухня пычагы кадалган иде. Янында бер яшь хатын-кыз чәчләрен йолка-йолка елый:

— Ай, бабам, бабам...

Бер ир аны тынычландырмакчы булып маташа.

«Болар кемнәр? Нишләп монда? Ничек Ханбалның фатирына килеп кергәннәр? Әллә Варислар махсус эшләгәннәрме?» — бу сораулары Альбинаны шашындырырлык иде. Ул уңга-сулга карады, егет күренмәде.

Айзикның чакырып та тормастан, ханым үзләренә таба атлады. Әмма тугры эт аның артыннан килә, вакыт-вакыт, елаган төсле, шыңшыпшыңшып куйгалый иде.

Ханым туктап калды. Милиция машинасы да күренде, аның артыннан ук диярлек «ашыгыч ярдәм» чабып килә иде.

Альбина кире борылып, тагын Ханбал фатирына барырга ымсынды. Аннары башына бүтән уй төшеп, өенә кайту җаен карады. «Әгәр дә картны иремнең хезмәтчесе Варис үтергән, дип барып әйтсәм, Геннадий гаепле була! Беллерми калдырсам, Ханбалны төрмәгә ябачаклар!»

Альбина дөрес фикерли иде. Варисларны башка һичкем күрмәде бугай. Әгәр дә ирен тоттырса, Альбинаның барлык бәхете, рәхәт тормышы юкка чыгачак. Ә Ханбал аның өчен алай ук кирәкле кешемени? Булган-беткән. Юк, ирен тотып төрмәгә утыртырга ярдәм итмәячәк ул!

Ханым кесәсеннән егет калдырган хатны алды. Аны вак-вак кисәкчекләргә erтkaлады да агачлар арасына сипте. Әгәр дә автобус билетын югалтса, бу бәлки Ханбалга бик тә кирәкле алиби була алыр иде. Юк, ниндидер бер мескен өчен ир кадәр ирне саталар димени!

Альбина фатир ишеген ачты. Үтерүне оештырган көнче Геннадий инде торган, хәтта чәйләр дә куеп маташа иде. Ханым аңа җылы итеп елмайды да муенына килеп сарылды:

— Тордыңмы, сөеклем!

Бу араларда үзен салкын тоткан хатынының көтмәгәндә җылынып китүе аның йортында кояш нурын тагын да көчәйтеп, балкытып җибәрде һәм Геннадий мөмкин кадәр йомшак булырга тырышты.

Урамда, яңгырлар белән башланып, хәзер инде урак өсте кояшын балкыткан шул ук август ае иде.

*1994.*



# Салисә Гәрәева

## Өмет

И мәркәзем, халкым тажы — Казан!
Якты синең Ирек мәйданың!
Илдә фетнә барган кара чорда
Син азатлык юлын сайладың!..

Дүрт йөз еллык жанны изгән коллык
Зынжырлары, бәлки, таралыр?
Азатлыкка Ватан ирешер дә,
Яңа дәүләтебез яралыр!

Азатлыкның татлы өмете дә!
Фидакарьләр эзли Идел-йорт!
Гарасатлар үткән байрагыңны,
Кыю милләттәшем, биек тот!

Чөнки Ирек алтын кайма төшкән
Тәлинкәгә салып бирелмәс!
Исән икән татар — йөрәгендә
Азатлыкка дәрте сүрелмәс!..

## Нида

Бардыр ул Тукай шикелле
Фидакарь татар улы!
Халык — бөек, ул — көрәшче,
Максаты изге, олы!..

Үз кауменнән Ирек даулар
Ирләрен алга дәшеп,

Чыгара торыр мәйданга,—
Чорлар карар көнләшеп!

Сатлыкларның маңгаена
Кара тамгасын сугар!..
И халкым, иркен мәйданга
Батыр ирләрне чыгар!
Җаннарны һәм күңелләрне
Ирек суында сугар!..

## Каршылыклы дөнья

Каршылыклы без яшәгән дөнья:
Бозга — ялкын, утка... су кирә.
Шатлык көтсәң, кайгы, яшерен шикне
Раслап, ни көтмәсәң, шул килә!

Җәйгә каршы, куып бураннарын,
Җил өстерәп, салкын кыш туа,
Хыялланып, ата малай көтә,—
Үч иткәндәй аңа, кыз туа!..

Үз дөньям да гаҗәп каршылыклы:
Бер өшим, бер эчем-тышым ут.
Бер сөенсәм, мең хәсрәте килә:
Мин яратам аны, ә ул... юк!

Яшьлегемне урлап, картлык килә,
Ул килде дип йөрәк картаймый!
Ә йөрәкнең яратасы килә...
Тиле яшьлек кабат кайталмый!

Япь-яшь кала йөрәк, картаймый!..

## Камал

Бәдрикамал, Бибикамал, хәтта
Гади Камал гына булса да,
Шушы исем татар кызларының
Йөзләренә якты нур сала.

Миңлекамал — аның уң битендә
Кара миңе — гүя ай табы.
Җаның тулар сөю сагышына,
Миңен үпсәң, бирәр җай табып!

Гыйлемкамал — дисә, укымышлы,
Зыялы кыз баса каршыңа.
Син үзең дә, егет, гафил булма —
Кулга китап тотып каршыла!

Дөррикамал күрсәң,— тетрә, дөрлә —
Утлы күмер кебек күзләре!

Яр буенда керләр чайкаганда
Күренеп китәр йомры тезләре!

Алиһәләр безнең үзебездә —
Матурлык та, Яз да, Бәхет тә!
Синең йөрәк изге тәхет булса,
Бәдрикамал менсен тәхеткә!

* * *

Өй турында үскән талларыма
Кайгы иңгән:
Яшел яфраклардан аерырга
Көзләр килгән!..

Аерыласы килми талларымның
Баласыннан:
Ботаклары инде сураеша
Арасыннан.

Мин дә шушы көзге талларыма
Охшаганмын:
Газиз гомеремне көзләр белән
Очлаганмын!..

Яшь тал кебек зифа газиз кызым,
Анаң бит мин!
Баш очыңда кызыл усак булып
Янам бит мин!..

* * *

Көзге урман. Ак каеннар
Сары шәлен иңгә салган.
Мәхәббәт — мәңгелек, диләр,—
Кемгә дөрес, кемгә ялган...

Яндым аның утларында,
Көзге урман янган кебек.
«Яр сөймәм!» — дип антлар эчтем,
Мәхәббәттән канган кебек.

Көзге урман уртасында
Сары томан, сары ялкын.
Ялкыннарга урап мине,
Урман юлларына тарттың...

Ак каеннар сары шәлле,
Куркалар җил бәргеннән.
Күздә яшем. Җаным тора
Моң һәм йөрәк әрнүеннән.

Куркам көләч карашыңнан,
Ялгыш кулың бәрелүеннән...

## Карлыгач

Карлыгач канатын җәйде.
Кояшка арка куеп.
Кинәт күккә ыргытылды,
Зәңгәр иркенлек тоеп!..

Аваз бирде тиңнәренә,
Чакырды үзе белән,
Бик ерактан күпне күрде
Сәйләндәй күзе белән.

Күңелдәге хыял кебек,
Әй, очты, әй, талпынды!
Кайнар күкрәген суытты
Искән җилнең салкыны...

Иярде күңел шул кошка,—
Очынды, исәрләнде.
...Шулай яшәргә чакырам
Йөрәге исәннәрне!..

## Тургай

Яз күгенә, атылып, тургай менә,
Канатларын кагып, талпына;
Яшәү гимнын, тормыш тантанасын
Яңгырата галәм халкына!..

Саф көмештәй ул ягымлы тавыш
Чылтырый да һаман чылтырый,
Җавап булып аңа аста — Җирдә
Гөрелдәгән сулар елтырый...

Көмеш нурлар белән бәйләгән дә
Соры тургай Җирне үзенә,
Алып оча аны биеклеккә —
Күрсәтим дип галәм күзенә!

һаман оча, көмеш кыңгыравын
Армый-талмый безгә тыңлатып;
һәм Җир шарын зәңгәр төпсезлеккә
Алып менә гүя, чыңлатып!..

* * *

Өзелгән җеп бәйләгәндәй, ике арада
Кулдан-кулга үрелеп бер кызчык бара.

Сөенмә, и, ялгызлыктан арыган күңел! —
Кыз белән дә бәйләнерлек түгел ара...

Яраларны яңартырга вакытлыча
Бер очрашу — ялгыш бер очрашу җитә!
Искә төшә рәнҗү тулы күз яшьләре —
Ике кеше капыл ике якка китә!

Бәхет бер дә яраланмас кебек иде
Күңелләрне күңел, янып, тарткан чакта.
Нарасый да бәйли алмый араларны —
Онытылмый күз яшьләре, хәтер сакта...

Нәрсә булды? Ник бәхетне сакламадык?
Күңелләрне нинди үпкә яралады?!
Кулдан-кулга үрелеп барган йөрәк назы —
Нарасый да бәйли алмый араларны.

## Хатын-кызның күңелен кем белә

Хатын-кызның күңелен кемнәр белә —
Татлы серләр анда өзлегә.
Серләреңне тарат, дияр идем,—
Хатын-кызның күңелен кем белә...

Серләреңне тарат, дияр идем,
Серләрнең дә бит бар төрлесе:
Башларына башлар куя-куя,
Күгәрчендәй бардыр гөрлисе.

Хатын-кызның күңелен кемнәр белә,—
Карлыгачлар анда уйныйдыр.
Серләрнең дә була яшерен-яты —
Күңелләре ниләр уйлыйдыр...

Серләреңне тарат, дияр идем,
Таратмас шул...
Ә ник таратсын?!
Хатын-кызның күңелен кемнәр белә:
Үз дигәнен тапсын, яратсын,
Яратканы өчен җан атсын!..

## Елый беләсеңме?

— Елый беләсеңме соң син?! — диде
Таш бәгырьле кеше, рәнҗетте дә.
— Юк! — дидем мин. Әмма керфекләрем
Авырайды яшьтән, төн җитүгә.

Төн җитүгә, үзем генә калгач,
Салкын мендәремә тигәч башым,
Ялгызлыкта түккән кайнар яшем
Җан эреткеч тансык, татлы да соң!..

Татлы да соң ялгызлыгым яше,—
Тиң булмаган ярым хатирәсе!
Ничек кенә аны табасы да,
«Сөям!» дигән сүзен әйттерәсе!..

Әйттерәсе иде яратуын,—
Кибәр иде керфекләрем очы!
Күкрәгенә башым куяр идем,
Анның көчле иңнәреннән кочып.

Елар идем шунда татлы итеп,
Яңгыр яуган җилле төн житүгә!
— Елый беләсеңме соң син?! — диде
Таш бәгырьле кеше, рәнжетте дә.

— Юк! — дидем мин. Серем аңа түгел!
Кайнар яшем — изге, тансык, татлы!
Тилереп яратуны,
илереп-эреп
Елауны кем таткан минем чаклы?!.



# ШИГЪРИЯТ



**Нур
Әхмәдиев**

## ҮЗ БӘХЕТЕМ

### Саташу

Кинәт җылытып җибәрде,
Юлда — су, гөрләвекләр.
Мәхәббәт туе ясыйлар —
Урамнар тулы этләр.

Саташты бугай каргалар:
— Яз! — диләр тамчы күреп.
Кышның яртысы узмаган,
Өстә — тун, башта — бүрек...

Ә без каргадан артыкмы:
Куллар богауда килеш,
Дөньяга сөрән салабыз:
Бәйсезлек килде, имеш...

Һәм ышанырга телибез:
Кол түгел, дип, җаныбыз.
Акны карадан аермый
Имгәтелгән аңыбыз...

1995, март

### Колыма хакында

*Яңа юлдан барган идек инде,*
*Колымага килеп тап булдык.*
Г. Афзал.

Колыманың юлы сикәлтәле,
Бармы икән берәр такыры?

Яңа заманнарның башымы бу,
Шулмы әллә — заман ахыры?

Этап белән барганнарның юлы
Тау микән дә текә яр микән?
Еракларда күгелҗем бер рәшә —
Җәйләрен дә әллә кар микән?

Колымага илтер юллар чиксез,
Кайтыр юллар гына ябылган.
«Халык дошманы» дип тормаганнар,
Хат көткәннәр шулар ягыннан,
Аларны да кемдер сагынган.

«Халык дошманы» дип тормаганнар,
Аларга да гашыйк булганнар.
Төрмә законнары нигезендә
Мәхбүсләр дә тормыш корганнар.

Кем онытсын җәһәннәмдә узган
Котсыз көннәр, шыксыз төннәрне?
Кимсетүгә түзә алган җаннар
Нахак бәлаләрдән керләнде.

Ничә тәмугың бар, и илаһым,
Әйт дөресен безгә, ачыкла:
Оҗмах юлы — коммунизм диеп,
Колымага бардык — тәмугка.

*1994.*

## Читтән кайтып килеш

Мүк куагы үрен төшеп киләм,
Мең тапкырлар моннан үтелгән.
Кесәләргә кереп җил сызгыра,
Бу — кайтуым җирнең читеннән.

Ни доллары, марка, стерлингы —
Ертык берлек хәтта калмаган.
Читтән кайткан, сине бай саныйлар,
Бик сирәктер — хәлне аңлаган.

Кайтып киләм сукыр бер тиенсез,
Тик ул хакта куркып уйламыйм.
Мин бирелә Кеше.
Туган җирдә
Ялгыш та, юк, мескен булалмыйм.

Күтәрелә башым,
Бил турая,
Вак-төяккә ничек ис китсен.
Бәхетле хис җанны сарып ала:
Кайтып җиттең, димәк, егет син!

Каршы чыккан этләр койрык болгый,
Тәтеннәре җиргә түшәлә.
Ничек тордың, туган нигезкәем,
Тагын күрештек без, иншалла!

Ачып кердем,
Ишетмәдем хәтта
Ыңгырашкан өнен капканың.
Шундый халәт:
Әйтерсең мин бүген
Бер әллә кем булып кайтканмын.

Эре генә узам ишек төпкә,
Тавык, үрдәкләрне аралап:
Кая бассам, кая карасам да,
Үз бәхетем тора сагалап...

*1994.*

## Белмибез

Без тарихтан инде ничә тапкыр
Зур имтихан тоткан кешеләр.
Бик беләбез сыман барысын да:
Кем акыллы булган, кем юләр?

Кайсы елны кемнәр сугышканнар,
Кайсы патша үлгән ярадан.
«Ахиллесның үкчәсе»н дә хәтта
Күпләребез «тотып» караган.

Күккә төбәп ярсу карашларны,
Яңа йолдыз, серләр эзлибез...
Ә үзебез өч буынга кадәр
Әби-бабайны да белмибез.

*1990.*

## Шөкер кылам

Көтү китә.
Язгы ашкынулар
Һич калмаган хәзер малларда.
Чыбыркы да инде сирәк шартлый,
Малларга да вакыт аңларга.

Сыерларның качу — гамендә юк,
Этләр йөри кысып койрыгын.
Энә очы кебек пыскып төшә,
Явар ахры яңгыр көнозын.

Каңгылдаша казлар...
Сизәләрдер:

Күп калмаган инде көннәре.
Кайсы парга тәмле йокы бирер
Бала казның мамык мендәре?

Кайсы өйгә кермә, табаларда
Тәбикмәге пешә, коймагы.
Кемдер килү һич мәҗбүри түгел,
Үзебез дә дөнья кунагы.

Намазыннан торган аксакалны
Кайнар чәе көтә өстәлдә.
Көзге муллык белән табигатькә
Моңсулык та бераз өстәлә.

Радиодан Казан концерт бирә,
Яңа көйне, белмим, кем җырлый.
Чыпчыкларның гына вакыты юк —
Яңа йортларына мүк урлый.

Күңелләргә иңә канәгатьлек,
Сөенә белү — нинди хозурлык.
Бу дөньяда — исән булганыңа,
Язмышыңа шөкер кылырлык.

*1994.*

## Хисап

Ярты юлын узганыма байтак,
Ахырына күпме гомернең?
Кайчак уйлап куям:
Тормышымда
Ни эшләргә генә өлгердем?

Бодай чәчтем, үсте алабута,
Кишер чәчтем — әрем утадым.
Салынасы йортым тәмам түгел,
Язылмаган иң шәп китабым.

Ташка бастым — ташым нык булмады,
Күп дусларым — көнчел бер бәндә...
Таянырлык кемнәр генә кала
Ахырзаман көне килгәндә?

Бер юаныч: барын эшләп таптым,
Хәләл булды җыйган икмәгем.
Җил искәнгә карап, сырт куймадым,
Төп юлымнан читкә китмәдем.

Белеп торам: соңгы көннәрем дә
Узып китәр ташкын, җил булып.
Язып өлгерәлми калган җырлар
Каберемдә шытар җыр булып.

*1994.*



# Радик Фәизов

## АК КАЗ

ПОВЕСТЬ

Мәгълүм ки, безнең татар халкы мал-туар, кош-корт асраурга һәвәс. Йорт терлекләренә, кошларга ихтирамлы караш, аларны ихлас күңелдән кайгыртып тәрбия кылу, хәтта инде гаиләнең бер әгъзасы итеп күрү безнең халыкта борынгы бабалардан ук килә. Хәтерлим, сугыш алдыннан һәм аннан соңгы елларда да безнең әни сыерны савар өчен кыш көннәрендә өйгә алып керә иде. Әни башта аклы-кызыллы, бура чаклы сыерны абзардан чыгара, аннан үзе җәһәт кенә алдан өйгә йөгерә. Өйалдында сыерның тояк тавышлары ишетелүгә, өй ишеген киң итеп ачып аны каршы ала.

— Әйдә, минем сөтлебикәм, әйдә, җанашым! Бер рәхәтләнеп өйдә җылынып чык әле. Хәзер менә тәмле ризыклар да бирәм үзеңә,— дип сөйләнә әни, кадерле кунагын каршылагандай елмаеп. Сыер бусагада тоякларын шакылдатып, үзе белән салкын пар болыты ияртеп, авыр атлап өйгә керә. Керешенә әни аны сыртыннан кочып ала да борылырга булыша. Тәмле бәрәңге кабыклары салынган, өстенә тоз да сибеп җибәрелгән тагаракка башы белән борып куя. Аннан үзе сыер янына чүгәли, бисмилласын әйтеп, җиленен җылы су белән юып ала, чиста тастымал белән корытып сөртә дә, сава башлый. Өйгә гаҗәеп тәмле, җылы сөт исе тарала. Әни сыерны оста, җиңел хәрәкәтләр белән, ничектер көйләп, җырлатып сава. Сыер үзе дә моны бик ярата, ахры, ул рәхәтләнеп күзләрен йома, борыны аша тирән итеп, шаулатып сулый. Кайчак башын тагарактан алып, әнигә борылып карый, авызыннан идәнгә су агыза. Әмма моның өчен әни аны ачуланмый, тик:

— Аша, җанашым, аша! Бер дә тартынып торма. Идәнне аны мин үзем сөртеп алырмын,— дип кенә куя.

Сыер бозаулыйсы көн дә бөтен гаилә белән көтеп алына. Инде кыш урталары үткәч, сыер сөт ташлап, табигать билгеләгән вакыты җиткәч, әни беркөн шатлыклы хәбәр әйтә:

— Безнең сыер җилен башлаган! Бүген иртә белән үзем тотып карадым.

---

Радик ФӘИЗОВ (1931) — *прозаик. «Күңелем кыры», «Дусларым», «Бәхет» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Арчада яши.*

Шуннан соң инде өйдә тынычлык югала. Һәркем, тышка чыккан саен, лапаска керә, абзарга күз сала. Әти исә төнлә торып та фонарь яндыра, лапаска берничә тапкыр чыгып керә. Һәркемдә бер кайгы: белми-нитми генә сыер бозаулап ята күрмәсен! Әгәр искәрми калсаң, яңа туган бозау салкында озак ятса — эш харап. Бәләкәчнең аяклары өшеп, тояклары төшүе, йә булмаса, үпкәсенә салкын тиюе ихтимал. Менә шуңа күрә бозау бөтен өй халкы тарафыннан ут йотып көтеп алына. Ул тугач инде, әни белән әти сыер яныннан китмиләр. Әнкәсе ялап чистарту белән, әти яңа туган бозауны кочагына күтәреп, өйгә алып керә. Без — балалар инде аны шатлыктан идәндә тыпырдап каршы алабыз.

— Менә сезгә тагын бер иптәш, балалар! — ди әти, үзе дә безнең кебек үк шатланып.— Күрегез әле аны, ниндәен сөйкемле ул!

Чыннан да, бозау искитмәле матур. Әнкәсе төсле аклы-кызыллы, күзләре бик зур, ялтырап торалар, колаклары да зур. Өсте кибеп бетмәгәнгә, ул әле туңа, күрәсең, кызганыч итеп мөгри, аз гына калтырана. Без, өйдәге бала-чага, бу бәләкәчне сырып алабыз, аны идәнгә иске юрган җәеп, алдан ук әзерләп куелган йомшак урынга яткырабыз, маңгаеннан сыйпыйбыз.

— Сабыр итегез, борчымагыз аны. Ул бит монда ерак юллар үтеп килгән. Ял итсен иркенләп, йокласын! — ди әни безгә.

Чыннан да, әле беренче көннәрендә бозау гел йоклый, әнисе кергәч тә аны имәргә генә, анда да безнең ярдәм белән, аяклары идәндә тая-тая гына тора. Тик берничә көн үтүгә инде ул нәни тояклары белән идәнгә тык-тык басып йөри башлый, кайчак хәтта сикергәләп тә ала. Туктаусыз идәнне юешли. Әмма без аны барыбер яратабыз, гел муенына сарылабыз, матур ситса кисәкләреннән муенчак тегеп кидерәбез. Әти мич артына рәшәткә ишек куя, идәненә салам җәя дә, бозауны шунда кертеп яба. Аңа карап без бәләкәчне онытмыйбыз, аны гел карап, сыйпап кына торабыз.

Безнең абзарда әле тагын ике сарык бар. Алар бәтиләгәч тә шулай. Бәтиләр җылы язга тикле өйдә, безнең белән бергә торалар, бергә уйнап үсәләр.

Бу хәлләр бер бездә генә түгел. Авылда кемгә генә килеп кермә, ишекне ачып җибәрешкә аның мич артында бозавы мөгрәп тора, өстәл астында бала-чага белән бергә сарык бәтиләре уйнап йөри, мич башында гаҗәеп терчә, гаҗәеп матур кәҗә бәтиләре сикерә. Ә инде язга таба, карлар эри башлагач килеп керсәң, мич артындагы ояда йомыркалары өстендә утырган каз каңгылдап җибәрә.

Әйтәм бит, мал-туарга, кош-кортка гашыйк безнең халык. Шуның өстенә ярты кышны бозаулар, бәтиләр белән бергәләп көн итеп ятсалар да, өйләре дә бик чиста бит әле. Беркемдә шапшаклык күрмәссең. Вакытында карап, асларын чистартып торгач, исе дә сизелми диярлек.

Монысы — бозаулар, бәтиләр. Ә менә безнең ак казны күрсәгез икән сез! Ничек буялмый торгандыр, һәрвакыт яңа яуган кар төсле ап-ак, авылдагы бөтен казлардан да зуррак, аның озын муены рәсемнәрдәге аккошларныкы кебек дугаланып, бөгелеп тора. Бу — беренчедән. Икенчедән һәр күрше-күләнне иң кызыктыра, көнләштерә торганы, ул ел саен унбишкә кадәр бәбкә чыгара. Авылдагы иң әйбәт саналган казлар да ун-уникене чыгарганда. Җитмәсә, безнең ак каз чыгарган бәбкәләр һәммәсе дә гаҗәеп терчә, таза булалар, әни әйткәнчә, тупырдап торалар, берсе дә үлмичә, үсеп җитәләр. Ошбу каз безнең гаиләнең мактанычы! Алай гына да түгел, бөтен авыл халкы белә һәм таный аны. Өченчедән, ул бик усал да, акыллы да. Тирә-юньдәге барча казларны куркытып, аларның башлыгы булып тора, тау астында аларны үзенчә ияртеп йөри. Кич белән карап торасың, тау астыннан ниндидер бер ташкын сыман булып, бөтен урамны тутырып, каңгылдашып каз көтүе кузгала. Иң алдан барча бәбкәләрен ияртеп, башын бик югары күтәреп, безнең ана каз килә. Ул горур төстә як-ягына карана, кайсы да булса аны үтеп китә

башласа, яман ысылдап, теге тәртип бозучыны хәзер көтү эченә куып кертә. Менә нинди ул безнең ак каз!

Инде «без» дә «без» дигәч, азрак үзебез турында да әйтим. Әни безнең олы гәүдәле, озынча йөзле, туры борынлы, бик батыр, тәвәккәл холыклы хатын. Берәр авыр хәл, бәхетсезлек килеп чыкса, күрше-күрпеләр безнең әни янына киләләр.

— Гайшәбикә, чуар тавыгыбызның аягы сынган иде. Чалып кына ташлар идек тә, кызганабыз, йомырканы күп сала. Син бер әмәлен тапмассыңмы?

— Гайшәбикә апай, улыбыз егылып иңбашын каймыктырган. Безгә кереп кенә чык әле.

— ...Сарыгыбыз бәтили алмый ята. Бәтие аркылы килмәде микән?

Безнең әни беркемнең дә гозерен илтифатсыз калдырмый, мондый чакта өйдәге бар эшен ташлап тора. Почмак яктагы савыт-саба куя торган киштәнең яшерен бер урыныннан борынгы зур, авыр акча чыгара. Көмеш тимерчыбык кысалы күзлеген киеп куя. Бер пыяласы нәни генә кителгән бу күзлек тә атаклы, авылда күзлек кигән хатын-кыз безнең әни генә бугай. Менә ул кулына игәү ала да инде яртысы ашалып беткән җиз тәңкәне игәүли башлый. Өстәлгә җәелгән кәгазьгә бакыр комы коела. Шушы бакыр комы — кошлар һәм терлекләр дә аякларын сындырса, менә дигән дару.

— Менә моны әчеткегә кушып бир. Бер атна дигәндә чуар тавыгың йөгереп йөрер, алла боерса! — ди әни һәм кәгазьгә төрелгән бакыр комын һәлакәткә очраган тавык иясенә тоттыра. Һәм, чыннан да, бер атнадан тавык иясе хатын безгә тагын килеп керә. Аның авызы колагына җиткән, кулына йомарлаган күлмәк итәгендә бер дистә йомырка.

— Рәхмәтләр яусын инде сиңа, Гайшәбикә. Аллага шөкер, тавыгым терелде, йөгереп йөри. Менә монысы сиңа, кул ялы,— ди хатын, итәгендәге йомыркаларны күрсәтеп.

— Тавыгың терелүе әйбәт. Ә кул ялы — мин аны алмыйм! Син, дивана, балалар авызыннан өзеп. Кире алып кайт йомыркаларыңны! — ди әни. Ул ныклы итеп, өздереп әйтә ки, аны тыңламый мөмкин түгел.

Әни кулын каймыктырган малай янына да бара. Киреләнеп, елап яткан малай безнең әни кулларына килеп эләккәч, ничектер тынып кала. Әни йомшак кына итеп аның иңбашларын тотып, тикшереп карый, кулыннан тота һәм кисәк кенә бу кулны нык итеп үзенә тарта. Малай акырып җибәрә һәм... икенче мәлдә үк инде күз яшьләре аша елмая.

— Иңбашым инде сызламый. Сызламый! — ди ул гөрьян куанып.

Бәрәнли алмыйча газап чиккән сарыкны да коткара безнең әни. Ул чын табибларча җиңнәрен сызганып куя, бик әйбәтләп сабын белән кулларын юа, хуҗаларга идәнгә чиста чыпта җәяргә боера, үзе шунда тезләнә һәм тәвәккәллек белән эшкә керешә.

— Хәзер, җанашым, хәзер була. Котыласың бу азаплардан,— дип иркәли ул бичара терлекне. Үзе аһ-уһ килә, көчәнә, маңгаена тир бәреп чыга. Әмма тиз арада чыптага ак бәти дә килеп төшә. Бичара хайван башын борып, әнигә карый, нәкъ рәхмәт әйткән төсле бәэлдәп куя.

Хуҗа хатын куанычыннан кулларын чәбәкли. Алъяпкычының эчке ягындагы яшерен кесәсеннән бөгәрләнеп беткән акчасын чыгара. Тик әни бу әҗерне кискен төстә кире кага.

— Нишлисең син, дивана! Барлы-юклы акчаларың белән. Үзеңнән арттыра алсаң, әнә балаларыңа конфет алып бир,— дип, тиргәп ташлый ул теге хатынны. Сүз дә юк, бу акча безнең йортта да бик ярап куяр иде. Тик безнең әни бервакытта да кул ялы алмады.

Колхоз эшендә дә шулай безнең әни. Кая гына барса да тәвәккәл, батыр. Ирләр белән бергә торып печәнен дә чаба, атын да җигә, сукасын да сукалый ул. Кая кушсалар да, кире какмый. Кичтән бригадир Сафа абый килеп, безнең тәрәзәне шакый.

— Гайшәбикә, иртәгә сиңа урманга! Ат җигеп барырсың.

— Булыр, алла боерса. Тик Закирҗан миңа үзебезнең алашаны куйсын. Кичтән яхшырак ашатсын. Гайшәбикә кушты диген! — ди әни.

— Гайшәбикә, чалгың әзерме? Иртәгә печәнгә төшәбез.

— Чалгым әзер, алла боерса. Тик мине Шәфикъ бабай белән янәшәгә куярсың. Ул чалгыны әйбәт таптый. Минем анда кешеләрдән калышып торасым килми! — дип кисәтә әни бригадирны.

Монда бер аңлатма кирәк. Әле мин сөйләгән хәлләр утызынчы еллар ахырында, әле сугыш башланганчы. Әле колхоз чыкканга да әлләни күп вакыт үтмәгән. Авыл кешеләре үзләренең аерым хуҗалык вакытын, ничек итеп күмәк хуҗалыкка берләшеп йөрүләрен, әле кайчан гына шәхсән үзенеке булган, хәзер исә колхоздагы атларының исемнәрен дә онытмаган. Шуңа күрә атларны кеше исеме тагып, Сәет айгыры, Абдулла биясе, Гайшәбикә алашасы дип йөртәләр. Һәм күмәк эштә дә һәркем, табигый инде, үз атын җигәргә тырыша. Ул бит инде аны артыгын кумый, чыбыркысын күтәреп кыйнамый да, тамагын да әйбәтләп кайгырта. Безнең әни дә шулай. Маңгаенда йолдыз сурәте төсле агы булган туры алашабызны җигеп, Мари урманына утынга барса, кичен аны өйгә алып төшеп тугара. Пешкән бәрәңгегә азрак онын да туглап, аны сыйлый. Аннары гына колхозның ат абзарына озатып куя.

Мин берчак үземә бик сәер булып тоелган бер хәлне дә күрдем. Әни урманнан кайтты, ул утынны югары очта, колхоз кәнсәләре янында бушаткан, арбада печән астына яшереп, үзебезгә бер ярканы алып төшәргә дә онытмаган. Шунда ул туры алаша алдына үзенең гадәттәге сыен куйды да, ат йотлыгып ашарга керешүгә аның янына чүгәләде. Ниндидер сәер, авыр ыңгырашу чыгарып, муенынннан кочып алды. Шунда мин имәнеп киттем. Минем безгә дә шактый кырыс торган, батыр әниемнең йөзе тәмам мескенләнеп калган, күзләреннән яше тама иде.

— Әни, әни! Нишләп елыйсың син? — дидем мин бик аптырап.

— Һай, улым... Соң бу бит минем атым. Минем үз атым бу. Мин аны әнисе Карлыгачны ни саклап колынлатып, үзем кабул күреп алдым. Үзем карап, ялларын тарап үстердем. Хәзерге колхоздагы Гайшәбикә алашасы түгел иде ул. Теләсә кем җигеп, теләсә кем типкәләгән бичара малкаем... Аның исеме дә бар иде. Минем Йолдыз Кашкам бу! — диде әни өзгәләнеп. Атның маңгаендагы йолдызсыман ак тапны бик кадерләп сыйпап утырды һәм авыр сулап, өстәп куйды. — Син, улым, берни төшенмисең шул инде. Бүтән чор балалары инде сез...

Чыннан да, колхозның ат абзарына илтеп ябыласы ат янында әниемнең алай уфтанып утыруын мин ул вакытта аңлап бетермәдем шул...

Ә менә безнең әтине исә әнинең нәкъ киресе дияргә була. Гәрчә исеме зимагур Габделхәй булса да, әти юаш вә йомшак кеше. Ул үзе болай әнидән дә олпат гәүдәле, куллары бик дәү, учлары киң, көчле-куәтле кеше. Тик менә ат җигеп урманга да бармый, ирләр рәтендә торып, печән дә чапмый. Дөресен генә әйтим, булмый аннан бу эшләр. Аны төрле урыннарга, богыл яисә эскерт салырга, әвендә көлтә кагарга куялар. Ә кышларын исә, колхозда җыен вак-төяк эшләр беткәч, үзе кебек тагын берничә авылдашка ияреп, әти авылдан бөтенләй чыгып китә. Алар Брянск якларына китәләр. Берничә айлар буена шунда җир казып, субай сугып, акча эшләп кайталар.

Безнең өйдә әни хуҗа.

— Габделхәй, он беткән. Иртәгә үк тегермәнгә төш!

— Ярый, Гайшәбикә, төшәрмен.

— Габделхәй, Әтнә базарына җыен!

— Ярый, Гайшәбикә, җыенырмын.

Менә шулай. Нәрсә генә кушса да, әти әнигә каршы бер сүз дә әйтми. Тулысынча матриархатлык, кыскасы. Ә алай да безнең әти әйбәт күңелле, бик тәртипле кеше. Ул гомеренә тәмәке тартмады, аракы эчмәде. Аш янына бисмилласын әйтеп утыра, амин итеп, торып китә иде. Әти ашны кызык итеп ашый, кашыкны тәлинкәдән алуга аның астына киң учын куя,

авызына кадәр шулай озата. Ашның тамчысы алдына таммасын дип бугай. Терлек-туарны, аерата үзебезнең ак казны бик ярата ул. Сыер-сарыкларны, казны әти карый, әни өйдә юк чагында сыерны да сава. Ә каз йомыркалар салып, алар өстендә утыра да башлагач, әти инде тәмам тынычлыгын югалта. Колхоз эшеннән кайту белән ул мич артына кереп китә. Йомыркаларына тиюдән куркып яман ысылдаган, үзенең кулларын мәрхәмәтсез чукыган казны оясыннан күтәреп ала, кадерләп кенә күкрәгенә кыса. Агарышып яткан җылы йомыркалар өстенә иске бишмәт каплый. Алар суынып-нитеп, алла сакласын, эчләрендәге бибиләр үлмәсен өчен шулай эшли ул. Казны ишегалдына алып чыга, аның алдына иң кадерле ризыкны, суга вак итеп туралган ипи куя. Каз ашап туйганчы аны саклап тора, шулай ук күтәреп өйгә кертә дә, йомыркалары өстенә утырта.

Кадерле ризык дип шуңа әйтәм, ул елларда инде колхозлар шактый ныгып, хезмәт көненә ашлык бирсәләр дә, авыл кешесе пешкән ипине бик саклап кына тотты. Моның төп сәбәбе — хезмәт көненә бирелгән ашлыктан үзеңә ипи сала, терлекләргә фураж тарта торгач, ел тәүлегенә ул такы-токы гына чыга. Икенчедән, безнең халык ул ризыкка борынгыдан ук хөрмәтле булган, аны әрәм-шәрәм итмәгән. Ул заманда терлекләргә пешкән ипи ашату кайда ул! Үзебез дә ашны иписез генә эчәбез, ипине әни тастымалга төреп куйган җиреннән сирәк ала, бәрәңге яисә катык янына гына бирә. Анда да әле:

— Ипине саклап кына ашагыз. Валчыгы идәнгә коелмасын! — дип кисәтеп куя.

Ашау-эчү, гомумән, кысынкы. Әни көн саен шаулатып сыер сава, әмма безгә дигән катыкны аертылган зәңгәрсу сөттән оета, ашка да шундый сөт. Ник дигәндә, куе сөтне югары очның Гарифә апайларга алып менеп, сепаратта аертасы, ә аннан чыккан каймактан май язасы бар. Ул май бик-бик тәмле дә, әмма тагын безгә элəкми! Аны, әни әйткәнчә, хөкүмәт бабайга тапшырасы бар. Ел саен көз көне бер бозау, кимендә ике бәти сарык чалабыз. Тик менә итле шулпаны кыш көннәрендә генә ашап калабыз шул. Җәйгә чыктың исә тагын шул зәңгәрсу сөтле арыш умачы. Итнең иң әйбәт кисәкләрен әти Әтнә базарына алып китә. Ник дигәндә, тагын шул — хөкүмәт бабай. Аңа әллә никадәр акча түлисе бар, заемга да яздыралар. Шуның өстенә хөкүмәт бабай үзенә дә итне түшкәсе белән каерып ала. Инде дистәдән артык тавык асрап, безгә йомырка тәбәсе дә бик сирәк элəгә. Йомыркаларны әни зур тубалга тутыра да аны җыеп, хөкүмәткә тапшырып торучы Латип абыйларга меңгереп бирә. Йомырка тулы тубалны өстәлгә куйгач, әни әле өйдән чыгып киткәнче, өстәл янына утырып, хәл ала. Шунда ул әле өстәлдәге йомыркаларга, әле безгә — күзебезне шул тәмле йомыркалардан алмыйча кызыгып утырган балаларга карый. Аның гадәттә сабыр, кырыс чырайлы йөзенә сагыш чыга, куллары салынып төшә.

— Һай, ходаем, һай балаларым! Пешереп кенә бирер идем шушы йомыркалардан сезгә тәбә. Табагымны тутырып. Ашагыз иде бер рәхәтләнеп. Булмый бит, булмый!... Ни эшләттеләр бит шушы дөньяларны, имансызлар... Зәгыйфь булып, тилмереп үсәсез бит сез. Тамагыгыз юньле ризык күрмичә,— ди ул авыр сулап һәм аның күзләрендә яшь тамчылары җемелди.

Без тамагыбызның юньле ризык күрмәгәнен, чынлап та, үзебез дә яхшы ук чамалыйбыз. Юкса, аермаган сөттән оетылган гаҗәеп тәмле катыкны да, өстендә май күзәнәкләре йөзгән итле шулпаны да, сөткә тугылап пешерелгән сап-сары йомырка тәбәсен дә көн саен ашыйсыбыз килә. Болары безгә бик яхшы аңлашыла. Ә менә кемнәр, бу дөньяны ни эшләткәннәр, алар ник әле имансызлар икән? Монысын инде без — балалар һич төшенмибез. Алай да көннәрдән бер көнне ул «имансызлар»ның кем икәнлеген әни минем үземә генә бик яхшылап аңлатты. Әмма аның бу сүзләреннән минем котым алынды. Мин элеккедән дә битәр буталып, тәмам тетрәнеп, югалып калдым. Бу турыда сүз алга табарак булыр.

Балалар димәктән, әти белән әнинең без — өчәү. Олыбыз Әдһәм абыйга инде унике яшьләр, ул дүртенче класста укый. Әдһәм абыйның борыны да, авыз уемнары да әнинекенә охшаган, күзләре дә әнинеке кебек, ул кулына алган әйберләргә дә, китаплар укыганда да күзенә якын ук китереп, текәлеп карый. Аның тагын бер һичкем ирешә алмаган сәер гадәте бар, яланаяк атлап барганда ул атлавыннан һич тукталмыйча, бер аягы белән икенче аягының балтырын бик тиз генә кашып ала. Ул моны бәлки үзе дә сизмәстән шундый өлгер эшли ки, аңа күз дә иярми кала.

Аннары Флүрә апай, ул да инде укый, икенче класста. Флүрә апай да әни шикелле озын торыклы, әмма аның йөзе әтинеке төсле түгәрәк, кара чәчләре бик калын, озын, ул аларны инде толымлы итеп үреп йөри.

Аннары инде мин үзем — Таһиржан. Мин әле мәктәпкә киләсе елга барам.

Әдһәм абый белән Флүрә апайның үз дөньялары, алар миңа бик катышмыйлар. Иртә белән торып ашауга, аякларына чабаталарын киләр дә, әни тегеп биргән киндер букчаларын иңнәренә асып, мәктәпкә менеп китәләр. Төштән соң да алар өйдә түгел — басуга башак җыярга, чүп утарга чыгалар. Әдһәм абыйга өйдә дә эш җитәрлек, ул абзарларны җыештыра, тирес түгә, уфалла арбасына җигелеп, елга-ерымтылардан сыерга печән алып кайта. Аны киптерә, печәнлеккә өя бара. Флүрә апай да гел эштә инде: ул су китерә, бәрәңге әрчи, әти белән әни эштән кайтканчы аш та пешереп куя.

— Минем кызым уңган ул, үземә охшаган,— дип мактый аны әни һаман саен.

Кичләрен без барыбыз бергә җыелабыз. Ашап-эчкәч, әни кучкардагы җиделе лампага ут кабыза да аны өстәлгә китереп куя. Шунда Әдһәм абый белән Флүрә апай дәрес әзерләргә утыралар. Бик матур рәсемле китапларын укыйлар, мине кызыктырып каләмнәрен кара савытына мана-мана дәфтәрләренә язалар. Шунда инде мин түзмим, өстәл янына киләм дә аларның арасына кереп басам, муенымны сузып әле берсенә, әле икенчесенә карыйм. Тегеләр зарлана башлый.

— Кит әле моннан! Колак төбендә ничек мышнап тора бит. Кибәк ашаган сыер төсле. Кит хәзер үк! — дип, куа берсе.

— Әни, кара әле бу Таһирҗанны. Бернәрсә исәпли алмыйм. Гел мишәт итә дә тора,— дип, әнигә чага икенчесе.

Мин алар кугач китәм дә, тагын киләм. Тегеләрнең китапларына, андагы хәрефләрне ничек итеп укуларына, дәфтәргә язуларына күз салам. Шулай итеп, акрынлап мин укырга да өйрәнеп алдым. Китапларда язылганны алардан бер дә ким итмичә укый алам. Алар китапларын миңа бирмиләр, кызганалар. Тик мин алар мәктәпкә менеп киткәч, өйдә калдырган китапларын барыбер алып укыйм.

Кичләрен безнең өйдә ничектер җылы, тыныч, күңелле була. Түрдәге зур сәкедә әни белән әти ашыкмыйча гына, шыпырт итеп кенә үзара сөйләшеп утыралар. Кемнең сыеры нинди бозау китергән, быел басуда игеннәр ничек, бәрәңге ничек булыр, кемнең казы күпме биби үстерә... Аларның бар сүзе шулар турында. Әнинең кулында кич белән дә эш, ул йон эрли яисә оекбаш бәйли. Эш арасында үзе гел авыл хәлләрен сөйли. Әти исә дәү кулларын тез башларына салып, тыңлап кына утыра. Дәрес әзерләүчеләр куа торгач, мин дә әти белән әни янына килеп утырам.

Ә шулай да мин күбрәк ялгыз булуны, берүзем йөрүне яратам. Шуңа күрә иптәш малайларым да күп түгел. Кечкенәдән ялгыз уйнап үскәнмен. Авылда нәни балалар йөри торган ясле юк, азрак дәү малайлар йөри торган бакча гына бар. Әле мин тәпи йөри башлаганчы ук болай булган: әни Әдһәм абый белән Флүрә апайны бакчага меңгезеп куйган да, мине ялгызым калдырып, үзе эшкә киткән. Ишегалдына уртага казык кагып, мине күлмәк итәгемнән шул казыкка бәйләп калдырган. Өйгә кешеләр кайтканчы мин шул ишегалдында, җыен тавык-чебеш, мәчеләр белән бергәләп яшәп ятканмын, мүкәләп казык тирәли әйләнеп йөргәнмен.

Кайчак күрше малайлар кереп, миңа төрле уенчыклар күрсәткәннәр, «мүһ-мүһ!» дип, мине үз яннарына чакырганнар. Мондый ялгыз калдырып китүләр бәлки әлләни күп тә булмагандыр, әмма алай да мин шушы эткә дәшкәндәй «мүһ-мүһ!»кә мөкәләп килергә өйрәнеп киткәнмен. Монысын үзем дә хәтерлим: инде өч-дүрт яшемә җитеп югары очтагы балалар бакчасына йөри башлагач, тәрбияче Зәйнәп апай безне ашарга чакырганда миңа «мүһ-мүһ!» дип эндәшә иде. Гәрчә инде бик әйбәтләп тәпи йөрсәм дә мин тәрбияче апайның күңеле булсын дип, эт кебек дүрт аякланып киләм. Шундагы бөтен апайлар да шаркылдап көләләр, минем аркамнан сөяләр. Җитмәсә, бик матур бизәкле агач җамаякка салып бирелә торган искиткеч тәмле баллы су да миңа бүтәннәрдән мулрак эләгә. Бакчада да мин бер читтә ялгызым гына, бер дә еламыйча уйнап утырам. Менә монысы өчен Зәйнәп апай да, бүтәннәр дә мине бик яраталар. Бакчада анда рәхәт, тәмле ашлар ашыйсың, уйнарга уенчыклар да күп, йомшак урынга ятып, көндезен дә йоклыйсың. Тик бу рәхәтлекләр озакка бармады шул. Биш яшемдә инде мине бакчадан чыгардылар. Ни хәл итәсең, бүтән балаларга да урын кирәк.

— Ак казның бәбкәләрен карап үстерү — синә, улым. Әнә Ильяслар, Нуруллалар белән бергә тау астына алып төшәрсең. Шунда бер очтан үзебезнең бозауга да күз-колак булырсың,— диде миңа әни йомшак кына итеп һәм шунда ук ныклы кисәтеп тә куйды: — Бибиләрне тилгән-карга алмасын. Бозау казыкка чалынып егылмасын, ычкынып китмәсен. Кара аны! Юкса колагыңны борырмын!

Без, Нурулла, Ильяс һәм мин, каз бәбкәләрен авыл астындагы нәни генә инеш буена алып төшәбез. Нурулла Түбән очныкы, тәбәнәк кенә булса да, бик кызу йөгерә торган, кып-кызыл битле, борын өсте гел кубалакланып торган, көчле малай. Ул ташларны бездән ераккарак ыргыта ала. Ильяс югары очтан, акрын гына сөйләшә, ак чырайлы, мактанчык кына бер малай. Алай да без дуслар. Без бибиләрне тау астына алып төшәбез дә, тиз арада алар турында онытып та җибәрәбез. Ник дигәндә, безнең ак каз бар. Ул барында инде бибиләр янына бер тилгән, эт яисә мәче килеп кенә карасын! Ак каз канатларын киң җәеп, муенын сузып, зәһәр елан кебек ысылдап, хәзер тегенең янына килеп җитә. Килеп җитә дә канатлары белән сугып, яман усал чукып, дошманының хәзер кирәген бирә. Шуңа күрә без каз бибиләре өчен тыныч булабыз. Ул заман тау асты тулы кузгалак, акбаш. Без аларны җыеп ашыйбыз, аннан китә көрәш, инешнең тирән төшендә ярыша-ярыша суга сикерү. Өйгә кич белән генә, арып-талып кайтабыз.

Өй димәктән, без яшәгән йорт Түбән очта. Инде авыл урамын чыгып китәм дигәндә генә, кисәк уң якка борылып кергән тыкырык бар, шул тыкырыкның иң түрендә атау кебек аерылып торган бер калкулык. Безнең йорт шул калкулык өстендә. Безнең ишегалдыбыз да күршеләрнекеннән әллә никадәр иркен, өебез дә биегрәк түшәмле, зуррак та. Җитмәсә, ишегалды түрендә, түбәле баз артында ниндидер иске, сүтеп алынган өй урыны кебек чокырлар да бар. Болар барысы да ничектер миңа серле, аңлашылмый. Мин бу хакта еш уйлап йөрдем. Ни эшләп безнең ишегалды алай иркен, ул нинди йорт урыннары? Әллә безнең ишегалдында элекке заманда тагын бүтән кешеләр дә тордымы икән?

Бервакыт, инде кичке аштан соң, Әдһәм абый белән Флүрә апай дәрес әзерләп утырганда, безнең өйдә ут сүнде. Җиделе лампаның керосины беткән икән. Инде авыл кибете күптән ябык, күршеләргә дә кереп карадылар, керосин табылмады. Шулай итеп, өй утсыз, караңгыда калды. Әдһәм абый белән Флүрә апай, шуны гына көтеп торганнар диярсең, җәтрәк өсләренә киенделәр дә, өйдән чыгып та тайдылар. Авыл уртасындагы Гани тавына менеп киттеләр алар. Анда малайлар-кызлар кара төнгә кадәр шугалак, чана шуа, уйный-көлә. Ул тирә төнгә кадәр гөрләп тора. Бу инде кыш башы, әти дә иптәшләре белән Брянск ягына чыгып киткән иде. Без өйдә әни белән икәү генә калдык. Өй җылы, рәхәт,

тып-тын, кап-караңгы. Менә шундый караңгылыкта, тынлыкта утырырга бик яратам мин. Төрлесен уйлап. Урынга да ятасым килми, әни дә әле ятмаган, каядыр шунда сәкедә, авыз эченнән генә нидер көйләп утыра. Шунда мин аңа күңелемдә күптән әзерләп куйган сорауларымны бирдем.

— Ни эшләп безнең ишегалды бүтәннәрнекеннән шулай дәү ул, әни? Баз артында нинди чокырлар бар? Әллә безнең янда тагын икенче кешеләр тордымы? — дидем.

— Ә? — диде әни, минем бу сүзләремнән сискәнеп киткәндәй.— Бигрәк зиһенле бала булдың әле син, улым. Әллә ниткән сораулар бирәсең...— диде ул һәм тынып калды. Нидер уйланып, ахры, байтак вакыт дәшми утырды. Аннары нindидер миңа ят, хәсрәтле, ярым шыпырт тавыш белән сөйләп китте:— И улым, сез күп нәрсәләрне белмисез шул. Күп нәрсәләрне төшенмисез дә. Алла үзе ярлыкасын инде сезне... Син бит, улым-җаным, мондый бала буласы түгел идең. Бер дә мондый буласы түгел... Өстеңә иске, абыеңнан калган бишмәт, аягыңа тишек чабата киясе бала түгел идең син. Әгәренки дөньяга шушы имансызлар баш булып алмаса...— диде әни, серле итеп.— Без бит сәвит чыкканчы, колхозлар чыкканчы мондый кешеләр түгел идек, улым. Хәзерге көндәге шикелле менә бу хәерче... Без авылның бик хәлле, маллы кешеләре идек. Минем әтием, синең бабаң Сәгъди өч ат тотты, әбиең Сәхипҗамал шаулатып ике сыер сауды.

— Өч ат! — дидем мин, әни сөйләгәннәргә таң калып.— Аның белән ни эшлисең, әни? Аңа бит өч арба, өч чана кирәк? Аларны каян аласың?

— Бар иделәр, улым, һәммәсе дә бар иделәр,— диде әни сагышлы итеп.— Безнең арба-чаналарыбыз өчәр генә дә түгел иде әле. Чыбыктан үрелгән чем кара тарантасыбыз, тимерле, кашуфкалы чанабыз да бар иде. Карлыгачны җигеп, кунакларга гына йөри торган. Аннан килеп, безнең урак ура, печән чаба торган машиналарыбыз да бар иде. Машиналарга тикле... Ай аллам! Ничек гөрләтеп эшли, гөрләтеп яши идек бит без! — диде әни өзгәләнеп.

— Ул урак ура торган машиналар ни эшкә тагын? Уракны бит аны колхозда гына уралар. Безнең бит бернинди басу да, болын да юк. Басу-болыннар алар колхозда гына була бит инде,— дидем мин, берни дә аңламыйча.

— Һай, улым, җанашым! — диде әни.— Синең ул колхозныкы дигәннәрең... Безнең басулар, безнең болыннар иде ул. Колхоз чыкканчы һәммә авыл кешесенең, һәммәсенең үз болыны, үз басуы бар иде. Үз аты, арбасы, сукасы-тырмасы... Әни тагын шактый вакыт тын утырды. Сагышлы дәвам итте:— Ай, аллам! Әле моннан җиде ел гына элек бит. Син туган елны колхоз чыкты, улым. Бөтен җирне, бөтен нәрсәне кешеләрдән тартып алдылар да уртак иттеләр. Эт тә җыймый торган уртак мал. Сәвитләр шулай кушты, имансызлар кушты. Авыл халкы мескен ни эшләсен инде ул. Надан, кыйналган халык. Бар җирен, атын, мөлкәтен колхоз авызына илтеп тыкты. Менә шулай ул, улым, асылда. Синең колхоз дигәнең шул була инде ул,— дип сөйләде әни.— Ә безгә алар җәбернең дә зурысын салдылар. Кара син бу дөньядагы гаделсезлекне... Алты почмаклы ак өебезне, келәт-амбарларны сүтеп алдылар. Мунчага тикле. Ул каралты-кураларны бүтән кешеләргә сүтеп салдылар... И улым, ярый әле, бабаең белән әбиең бәхетле җаннар икән. Алланың рәхмәте, колхоз чыгар алдыннан алар икесе бер елны вафат булдылар. Котылдылар инде, котылдылар. Юкса, картлар дип тормыйлар иде. Икесен дә җилтерәтеп өтермәнгә алып китәләр иде.

— Ни эшләп өтермәнгә? Ни өчен? — дидем мин, инде курка ук башлап. Өтермәннең ишек-тәрәзәләренә тимер челтәр сугылган, кешеләрне ябып куеп ач тота торган бер бик тә шомлы йорт икәнен ишетеп белә идем.

— Ни эшләп булсын, улым, имансыз ич алар...— диде әни ачынып.— Тамагы тук, өсте бөтен булып яши белгәннәрне өчен. Гомерләре буена

бил бөгеп, тырышып эшләгәннәре өчен, улым. Тәртипле, ипле, житешле, динле адәмнәр булганнары өчен! — диде әни, инде нәфрәтле итеп.— Ярый әле, менә үзем акыллы була белдем, улым. Бабаңнар вафатыннан соң, колхозга авылда иң беренче кеше булып мин язылдым. Сезнең хакка, балаларым хакына берниемне дә жәлләмәдем. Барча булган мал-мөлкәтемне, атым-сыерымны колхозга менгереп бирдем. Юкса үземне дә алып китүләре бар иде. Менә шулай ул бу дөньялар, улым.

— Ә... әти? Безнең әти кайда булды ул чагында? — дидем мин.

— Әтиеңнең безнең мал-мөлкәткә әлләни катнашы юк аның, улым. Ул җаен-кышын безгә булышып, ялланып эшләп йөргән бер егет иде. Шунда без аның белән тормыш та корып җибәрдек. Бергәләп эшли, бик әйбәт тора идек. Һәммәсе дә житешле иде. Менә шушы имансызлар гына бозды дөньяларны... Ай аллам, кемнәрнең генә каргышлары төште икән безгә..... — диде әни авыр сулап һәм тынып калды.

Өй җылы, тын. Инде шактый соң да бугай. Тик минем әле һаман да йокым килми. Мине төрле сораулар борчый.

— Имансызлар... нинди кешеләр ул, әни? Кемнәр була инде алар? — дидем мин.

— Кемнәр булсын инде, улым. Шул бәлшәвикләр инде. Әнә безнең колхоз прсидәтеле Нәфикъ абыең төсле камунислар,— диде әни шыпыртлап кына.— Адәмнәрнең мал-мөлкәтен талап, йолкып алучылар. Менә сине тишек чабата белән иске бишмәткә калдыручылар...' Аларның Мәскәүдә утырган башлыклары...

Әнинең шыпырт итеп, ниндидер җан ачысы белән әйтелгән бу сүзләреннән караңгы өйдә миңа шомлы була башлады. Мин прсидәтел Нәфикъ абыйны беләм дә бит әле аны, әллә ничә тапкыр күргәнем дә бар. Башына зур кызыл йолдызлы, әкәй чүнкәсе төсле яман кызыклы әйбер киеп йөри. Аягында да, кайчан ялтырап торган итек булса да, күп вакытта чабата киеп йөри. Аның борыны битенә тагып куйган кишер төсле озынча, зәңгәр күзләре бик зур. Нәфикъ абый бер дә усалга, әйбер тартып алучыга охшамаган. Аның күзләре ничектер тирән сагышлы, үзендә сырхау кеше чырае. Урамда барганда ул кисәк тукталып кала да, койма буена борылып, косып җибәрә. Аннан бик озак эчен тотып, күзләрен сөртеп тора. Монысын мин үзем күрдем. Эче авыртудан азап чигеп йөри торган бу кеше юаш та бугай әле. Миңа бер тапкыр да усал итеп караганы юк аның. Алай гына да түгел, урамда күрсә, янымда туктала, елмаеп, башымнан сыйпап үтә. Шуңа күрә әнинең сүзләренә минем бик ышанасым да килмәде.

Бу сүзләрне әнием түгел, ә караңгыда посып кына утырган бөтенләй икенче кеше әйткәндәй тоелды. Тик анда бит ят кеше түгел, минем әнием генә утыра... Куркуымнан, чарасызлыктан ни эшләргә дә белмичә, мин елап җибәрдем. Әни шунда ук сәкегә янәшәмә килеп утырды.

— Чү, балам, чү! Син елама инде, миңа үпкәләмә дә,— диде ул, үзенең җылы куллары белән минем башымнан сыйпап.— Син минем бу сүзләремне уйлама, улым. Оныт син аларны. Мин аларны сиңа яңлышып кына әйтеп җибәргәнмен. Янган йөрәгемә чыдый алмыйча гына. Сез инде бүтәнчә белгән балалар шул... Алар сезгә ничек тәрбия бирәсен бик белә шул. Син мине төшенә алмыйсың шул инде, дип сөйләде әни һәм кисәк кенә пышылдап, бик ялынып әйтте: — Син минем әйткәнемне кешеләргә сөйләп йөри күрмә, улым, яме! Беркемгә дә, абыең белән апаеңа да әйтмә. Бергә уйнаган малайларыңа да ычкындыра күрмә. Әгәренки әйтәсең икән, мине хәзер килеп өтермәнгә алып китәләр, улым. Кәтер җибәрәләр. Ишетсен колагың! — диде әни ялварулы да, усал да итеп.

Әле бала гына булсам да, минем дә әллә ниткән шомлы хәбәрләр ишеткәнем бар иде инде. Төнлә белән генә күн киемле, кара машиналы кешеләр килгәннәр дә, фәлән авылдан фәлән кешене алып киткәннәр икән, дип. Укытучыларны, хәтта инде Нәфикъ абый шикелле колхоз

прсидәтелләрен дә. Ул кешеләр бик тә хәтәр, яшертен адәмнәр булганнар икән. Хәтта Ленин бабайга, атабыз Сталинның үзенә дә каршы уйлап йөргәннәр икән, дип. Ул кешеләрне өтермәнгә алып китәләр икән дә, алар шунда хәбәрсез-нисез юк та булалар икән... Явыз уйлы кешеләр... Әмма! Мин Ленин бабаебыз белән әтиебез Сталинны бик, бик яратсам да, үземнең әниемне барыбер алардан күбрәк ярата идем шул. Учлары җылы, озынча йөзе гаҗәеп тә шәфкатьле, алъяпкычыннан тәмле токмач исләре килеп торган, минем өчен иң кадерле, газиз әниемне. Шуңа күрә аның бу кичтә әйткән сүзләрен мин күңелемнең иң түренә яшереп, бик күп йозаклар белән бикләп куйдым. Беркайчан да, бер генә малайга, бер генә дустыма, беркемгә дә белгертмәдем. Һе әйтеп кенә кара син... Минем әниемне килеп өтермәнгә алып китсәләр, булыр аннары...

Тик, ни гаҗәп, күңелемнең иң түренә салынган бу сер минем үзем өчен дә гомерем буена диярлек чишелмәс бер сер булып калды. Мин әниемне, нәкъ ул үзе әйткәнчә, тәки төшенә алмадым. Аны бик яратсам да, инде читтә яшәгәндә аны уйлап гел сагынсам да, аңа карата ниндидер аңлаешсыз, сәер, каршылыклы фикердә булдым. Күпме еллар буена, хәтта инде әнием вафат булгач та. Ахырында: «Нәрсә әйтәсең инде монда. Надан бер авыл хатыны, нәселдән килгән крестьян. Кайчандыр үзенең шәхси милкенә ябышып яткан. Яңа тормыш төзү бәрабәренә Совет хөкүмәте, партиябез аны шушы милкеннән мәхрүм иткән. Шуңа күрә генә сөйләгән минем әнием андый сүзләрне. Дөнья барышын, сыйнфый көрәшнең асылын, коммунизм идеяләрен аңлап җиткермәгәнгә күрә генә. Ә асылда әйбәт, гадел күңелле, бик эшчән хатын иде ул. Үзе эченнән тиргәп йөргән шул ук колхозда ирләр рәтендә торып эшләде бит. Бу үзе генә дә аның бөтен ялгышларын тулысынча аклый»,— дип хәл иттем мин. Һәм шуның белән күңелемне тынычландырып яшәдем.

Безнең йорт, әйткәнемчә, Түбән очта, авылның читендәге тыкырыкта булса да, безгә кешеләр күп керә. Күрше-күрпеләрне әйткән дә юк инде, югары очтан төшәләр, хәтта аргы яктан да чыгалар. Һәм бу хәлнең зур бер сәбәбе — безнең ана каз. Ул яз көне йомыркалар салып, алар өстенә утыру белән, безгә килүчеләр күбәя.

— Гайшәбикә апай, алла боерса, быел көзен ак казыгызның бер бибиен безгә бирерсез. Аның нәселе таза.

— Гайшәбикә апай, безгә бер биби әбизәтелни.

— Безгә дә... Көз көне үскән бибигә алыштырып алабыз.

— Соң, бибиләрнең барысы да ана булып чыкмас ич,— ди әни соңрак килүчеләргә.

— Безгә ата булса да ярый. Ата казның да яхшы нәселле булуы мәслихәт бит,— диләр сораучылар.

Шулай итеп, ул ак каз үзе дә бик-бик күп еллар буе яшәде, аның бәбкәләре дә гомерле булды. Без аларның берсен дә диярлек үзебез чалмадык. Көз көне авыл халкы үзендә үскән бәбкәләргә алмаштырып барды. Әти сукрана иде:

— Безнең бибиләр нинди эре. Ә алмаштырырга нинди вак чеулдембиләрне алып китәләр...

— Булсын! Кешеләргә бездән яхшылык булсын. Үзебезгә савап ул,— дип кенә куя әни андый вакытта.

Мин бу ак казның үзе шундый зур, гайрәтле булуын, бибиләренең дә берсе дә үлмичә тупырдап үсүләрен үземчә юрадым. Минем уемча, аның әнисе яз көне тау астында йөргәндә кыргый казлар белән кушылган булырга тиеш. Иректә, узбуйлы яшәгән казлар белән. Кыр казлары якындагы киң болынга очып килгәндә, бик сирәк кенә булса да, тау астына да кунгалыйлар. Үзем күргәнем бар. Алар кеше килә башласа, шундук очып китәләр. Әмма йорт казлары белән аралашалар, бергәләп каңгылдашалар. Безнең ак казның башын югары күтәреп йөрүендә, бибиләрен саклап бик яман ысылдавында, бөтенесен куркыта алуында ниндидер бер кыргый, табигый көч бар. Көз көне, инде бибиләре үзе

хәтле булып. Шашы тау башына башак чүпләргә менгәч тә, ул аннан бүтән казлар кебек алпан-тилпән килеп җәяү төшми. Бибиләрен иртә дә, алар йөгерә барып, һавага күтәреләләр. Басулар өстеннән авыл ягына очып кына төшәләр. Нәкъ кыр казлары кебек. Канатлары киң җәелгән, салмак кына селтиләр, нәкъ алар шикелле үзара каңгылдашып, нидер сөйләшәләр. Карап торырга матур! Тау асты турысына җиткәч тә әле, шунда ук җиргә төшеп кунмыйлар. Зур түгәрәк биреп, авыл өстеннән бер-ике тапкыр әйләнәләр, гүяки үзләрен күрсәтәләр. Инде тау астындагы яшел чирәм өстенә төшеп кунгач та, бик озак тынычлана алмыйлар. Киң җәелгән канатларын да җыйнамастан әрле-бирле йөренәләр, үзара тагын нидер сөйләшәләр. «Һавада очып йөрүләре нинди күңелле. Зәңгәр күктә рәхәт, иркенлек анда. Безгә бу тау астыннан киң болыннарга очып китәргә кирәк!» — дип киңәшәләр бугай. Әмма, бәхеткә, ни өчендер очып китмиләр, һаман саен җиргә әйләнеп төшәләр дә, кич белән мин аларны алып кайтып, абзарга ябып куям. Ә бит теләсәләр, бездән бөтенләй очып китеп, кыргый кардәшләре белән бергәләп, иркенлектә яши аласылар үзләре. Алар ни өчендер моны эшләмиләр һәм бу миңа сәер тоела.

Кайчак мин кичләрен йокламыйча ятам. Көне буе ерактагы кеше йөрмәгән басуларда җим чүпләгән кыр казлары төн кунарга болынга юл алалар. Шул чагында алар безнең авыл өстеннән очып үтәләр. Караңгыда бер-берсен югалтмас өчен алар гел үзара тавыш бирәләр. Шунда мин аларның канатлары сызгырганны, «квыйк-квыйк!» дип кенә, акрын гына үзара сөйләшкәннәрен аерымачык ишетәм. Менә шул тавышны бу вакытта ояда, йомыркалары өстендә утырган безнең ак каз да ишетеп ала. Ишетеп ала һәм... үзе дә аларның сөйләшүләренә кушылгандай итә. Юк, каты итеп, йорттагыларны уятырлык итеп кычкырмый ул. Мич артыннан аның үзенең иректәге туганнарына җавап итеп нинди дер эчке, саңгырау тавыш белән нәкъ аларча «квыйк-квыйк!» итеп куйганы гына ишетелә. Мин инде озак йокыга китмичә уйланып ятам. Кыр казлары очып йөргән биеклекләрне күз алдына китерәм. Аннан ерак-ераклар, Әтнә авылы, хәтта Казан каласы үзе дә күренә torгандыр әле. Ә безнең кечкенә генә, ярлы гына авылыбыз уч төбендә кебек инде. Әнә салам түбәле лапаслар, авыл башында зират, ә авыл уртасында үзенең очлы манарасын күккә сузып, мәчет утыра... Их, кешеләрнең дә канаты булса иде. Шул кыр казлары янында теләсә кая очып йөри алсаң иде...

* * *

Авыл никадәр кечкенә, чабаталы фәкыйрь, тамагы умач белән бәрәңгедән бүтәнне белмәгән булмасын, анда тормыш кайный. Кешеләр колхоз басуларында эшлиләр, сабанын сөрәләр, печәнен чабалар, урагын уралар. Башына җете кызыл яулык бәйләп, иңенә күн сумка асып, аякларын үзенә үлчәп тектергән хром итекләр киеп йөргән клуб мөдире Маһирә иң алдынгыларны — самолетка, уртачаларны — автомобильгә, ә ялкауларны инде ташбака өстенә утырта. Ул Югары очтагы янгын сарае стенасына зур калын кәгазь ябыштырды. Шул кәгазьгә матур гына итеп аэроплан, автомобиль, тарантаска җигүле ат җирдән шуышып барган ташбака рәсемнәре ясап куйды. Шул рәсемнәр турысына кешеләрнең исемнәрен язып куя да, атна саен алыштырып тора. Иртән басуларга, болыннарга барган кешеләр ул рәсемнәр янына тукталалар, бик кызыксынып карыйлар.

— Кара әле Закир Нәсимәсен. Урак уруда тәки самолетка утырган бит, әй!

— Нәсимә апай бик оста уракчы шул ул. Аңа җитеп кара син.

— Әнә карагыз, Гатау Шәңгәрәе — афтамабилдә. Үзен күргәч, авызы ерылыр инде.

— Иһи-һи... Гафурҗан тагын ташбакага утырып калган. Ялкау. Шул кирәк аңа.

Без — малайлар да бу күрсәткеч тактаны карап кына торабыз. Кемнең әнисе-әтисе кайда? Ильяс белән Нурулла каршысында минем борын күтәренке. Чөнки безнең әни һәрвакыт самолетта була. Ә аларның әниләре автомобильдән үтә алганнары юк әле.

Алай да безнең өчен иң кызыгы — авылга кино килү. Әй, күнелле дә була инде безгә шул чакта! Сугышка кадәрге елларда без иң яратып караган, хәтергә гомергә сеңеп калган картиналар «Чапаев», «Валерий Чкалов», «Броненосец Потемкин», «Волга-Волга», «Александр Невский»... Күп инде алар. Без аларны ничә кат караганбыздыр, анысын бер алла гына белә, килгән саен керәбез. Әмма «керәбез» дип әйтүе генә ансат. Безнең өчен кинога керү үзе бер кино ул... Кич белән кино башланганчы авыл башындагы клубның ишеге төбендә шул ук кызыл яулыклы Маһирә тора. Билет тикшерә. Олыларга рәхәт, алар киномеханик Хатиф абыйдан акча түләп билет алалар да, ашыкмый гына, күкрәк киереп, клубка кереп тә китәләр. Ә без малайларга әниләрдән кинога акча сорау турында уйлыйсы да юк. Бирмиләр. Юкны ничек бирсеннәр инде. Без — мескеннәргә кинога ничек тә булса бушлай керү юлын эзләргә кала. Ә көндезләрен уйнап-көлеп кенә сөйләшә торган, болай үзе әйбәт кенә тоелган, әле кияүгә дә чыкмаган Маһирә апай безнең өчен кичләрен чын бер усалга, әшәкегә әйләнә. Син шунда олылар арасына посыпмы, ничектер яшеренепме клубка билетсыз керергә маташып кара. Хатиф абый белән авызын ерып нидер сөйләшеп торган Маһирә апай сине әллә ничек кенә күреп ала. Ул нәкъ ачуы килгәндәге безнең ак каз кебек ысылдап, очынып синең янына килеп җитә. Күзләрендә хәтәр яшькелт ут кабына. Иңбашларыңнан умырып тотып ала да сине җилтерәтеп баскыч төбенә алып чыга. Баскычтан үзенең очлы башлы итеге белән артыңа тибеп төшерә җитмәсә, мыскыллы итеп кычкыра:

— Йолкыш! Акчаңны алып кил.

Хәзерге көнгә кадәр мин бер нәрсәне аңламыйм. Коммунистик тәрбия сагында уяу торган, сүз саен «Ленин бабабыз эше өчен! Сталин атабыз эше өчен! Коммунизмның җиңүе өчен!» дип авыз суын корыткан бу итәкле атаман ничек итеп үзе гади генә бер нәрсәне аңламады икән? Кино бит менә дигән, гаять тә куәтле идеология чарасы. Ул чагындагы кинолар бигрәк тә. Алар дөрестән дә чын сәнгать әсәрләре, бик яхшы, барысы да уйлап эшләнгәннәр, аларның безгә тәэсире, тәрбияви йогынтысы әйтеп бетергесез көчле иде. Безне, авылдагы ун-унбиш малайны, кино караудан мәхрүм итәргә тырышып, бу кызыл кикрикле тавык үз-үзенә каршы килгән, чын бер ахмаклык эшләгән бит. Нәкъ менә коммунизм эше өчен көрәшчеләр итеп тәрбияләүгә, үзе дә белмәстән, киртә куеп маташкан! Соң, кесәләрендә сукыр бер тиен акчалары булмаган малайларны кинога бушлай гына кертеп җибәрсә, бу бит тәрбия эшендә ярдәм генә булыр иде. Зур ярдәм. Ни эшләп ул чагында хөкүмәт бу мәсьәләне үзе хәл итеп, балаларны һәркайда кинога бушлай кертүне куймагандыр? Монысы да аңлашылмый. Аннан гына Совет хөкүмәте бөлмәс тә, җимерелеп тә төшмәс иде әле. Җитмәсә, авыл халкында акча юк икәнен, бар булганын заемга, налоглар түләп үзенә үк кертеп бара икәнен дә яхшы белгәндер бит инде ул хөкүмәт дигәнең.

Без, анысы, бер картинаны да карамыйча калдырмадык. Авылга кино килү хәбәрен ишетү белән без, Ильяс, Нурулла һәм мин, бергә җыелабыз. Әле кичен кеше керә башлаганчы ук бер җаен туры китереп, клубка үтеп керәбез. Аннан инде ялт түрдәге сәхнә астына. Ә сәхнә асты тәбәнәк, анда мүкәйләп кенә йөреп була, ятып кына тора аласың. Анда тынчу, чат тузан, идәнендә әллә ниткән бөҗәкләр, хашәрәтләр шуыша. Җирдәге тәмуг дигәннәре шушы була торгандыр инде. Ә шулай да без кереп ятканда анда инде өч-дүрт малай Югары очтан, тагын Аргы яктан бер-ике малай була. Ятабыз шулай кайсыбыз кайда. Күп вакыт үтми, төрле чыш-пыш башлана.

— Ай, борыным кытыклана. Хәзер төчкереп җибәрәм.

— Төчкерә күрмә! Борын өстенне кулың белән ышкы. Маһирә клуб тирәсендә генә бугай... Төчкермә, хәзер ишетеп ала, кара аны! — дип кисәтәләр борын иясен.

— Малайлар, үләм... минем бик каты пес итәсем килә! — дип пышылдый берсе, гөрьян кайгы белән.

— Чыгып йөрмә. Җибәр шунда гына,— дип рөхсәт итәләр кысталучыга. Төрле исләр иснәп ятасы булса да, түзәбез инде. Әгәр кысталучы чыгып, Маһирә аны күреп алса, бөтенебезне сөреп чыгаруы бар бит. Безнең малайлар түземле анысы, берсе дә эшне бозмый.

Без кысталып, кычытып, җан атып ята торгач, бервакыт клубта хәрәкәт башлана. Ишектән, көлә-көлә сөйләшеп, Хатиф абый белән Маһирә апай килеп керәләр. Хатиф абый, дөп-дөп басып, идән буйлап йөренә, сәхнә каршысына ак пәрдә китереп элә, үзенең аппаратларын урнаштыра. Маһирә апай исә бик күп көлә, кайчак тыпырдап биеп тә ала, «Комсомолка Гөлсара»ны җырлый. Ул арада алар бергә килеп, ни өчендер сәхнә артына керәләр. Бездән күп булса өч-дүрт адым арага. Без инде сөмрәк булабыз. Әгәренки шунда малайлардан кем дә булса төчкереп, йөткереп җибәрсә, яисә тегеләр шырпы сызып, сәхнә астына иелеп карасалар... без — мескеннәрнең эшләре харап! Хәзер сөреп чыгарачаклар. Әмма тегеләрнең анда-монда эшләре юк. Алар кыштырдыйлар, чыштырдыйлар, ул тарафтан «чуп та чуп!» итеп үбешкән тавышлар ишетелә. Хатиф абый кайнар итеп пышылдый:

— Әйдә инде, Маһирә җанашым... Бер генә...

— Юк, юк, Хатиф... Ярамый... Монда ярамый... Хәзер әнә кешеләр дә килә башлый,— ди Маһирә дә, шулай ук кайнар пышылдап. Һәм алар тагын «чуп-чуп!» итәләр.

Боларын мин гаеп итеп әйтмим анысы. Алар арасында чын яратышу, мәхәббәт булгандыр. Берничә елдан Хатиф абый Маһирәне үзе торган район үзәгенә алып китте. Алар тату гына гомер иттеләр, балалар үстерделәр.

Менә клуб ишеге төбендә кешеләр сөйләшкәне ишетелә башлый. Хатиф абый белән Маһирә апай җәтрәк шунда китәләр. Кешеләр клубка керә, озын агач эскәмияләрне дөбердәтеп этә-төртә, урыннарга уңайлап утыра. Аннан жуылдаган тавыш ишетелә, клубта якты булып ут кабына. Бу инде көтүче, акылга берәз саерак Гафурҗан тәрәзә төбенә беркетеп куелган динамоны әйләндерә башлады дигән сүз. Халык Гафурҗанны төрлечә куәтли.

— Әпүр, тырыш әйдә!

— Кинаны яхшы күрсәтсәң, бер төрерлек тәмәке сиңа.

— Кәҗә койрыгын борган шикелле итеп бор.

Гафурҗан тырыша. Ул арада кино аппараты да үзенә хас тавыш белән чытырдап әйләнә башлый. Пәрдәгә беренче сүрәтләр төшә. Хәзер инде безнең чират. Малайлар сак кына булып яткан урыннарыннан кузгалалар, берәм-берәм сәхнәгә menәләр. Без киноны башта әле сәхнә артында торып кына карыйбыз. Кино ул пәрдә аша да күренә, тик берәз тонык кына була, сурәтләр дә кире якка хәрәкәт итәләр. Шунда аргы якның Шәркә, иң житез, кыю малайлар, пәрдә кырыеннан гына залга төшеп, разведка ясап менә. Маһирә апай алдагы рәтләрдә утырмыймы? Әгәр ул анда утыра калса, безгә бит бөтен картинаны пәрдә аша гына карарга туры килә. Бәхеткә, ул һәрвакыт диярлек артта, аппаратлары янына баскан Хатиф абый тирәсендә була. Шәркә пәрдә читеннән башын тыгып безгә пышылдый:

— Төшегез, теге тәре монда түгел...

Кача-поса гына залга төшкәч тә, эш аның белән генә бетми әле. Ярым караңгылыкта сине беренче күреп алган кеше, кагыйдә буларак, синең башыңа яхшы гына итеп берне китереп ямый. Моңа ачулана да, шыңшый да алмыйсың. Монысы инде синең билетсыз икәнеңне белә торып та клуб мөдире Маһирәгә тотып бирмәгән өчен түләү хакы була.

Ул заманда әле кино тавышсыз. Хатиф абый үзе аппарат ручкасын әйләндерә, үзе картинаның эчтәлеген дә сөйләп бара.

Менә болары — аклар. Әнә алар ничек рәхәтләнеп су коеналар. Әле бер нәрсә дә белми ул хәчтерүшләр. Хәзер урман юлыннан үзенең отряды белән Чапай килеп чыгачак. Күрсәтәчәк әле ул бу капкорсакларга! Әнә, әнә үзе дә күренде! Кара, ничек гайрәтле килә Чапай. Әнә аклар ничек курыктылар, ничек качалар. Хәзер Чапай аларны пулеметтан кырып сала әле. Юк, үзе атмый ул, кулы белән кая атасын күрсәтеп кенә тора. Шундый ул Чапай! Әнә, пулемет сиптерә дә башлады. Әнә аклар ничек кырыла!— дип, барысын да аңлатып бирә киномеханик. Халык барысын да үзе күреп, аңлап торса да, шым булып тыңлый.— Менә монысы — Петя. Чапайның ординарецы. Әнә анысы — Анка. Гаять тә оста пулеметчы кыз ул. Бераздан ул акларның әфисәрләрен кырып салачак әле. Шул хөрмәткә Чапай аңа үзе чәй эчерә!— дип сөйли Хатиф абый горурлык белән. Клубка җыелган халык та картинаны горурланып, хисләнеп, тәмам бирелеп карый, Чапаев һәлак булганда чын күңеленнән тетрәнә. Әле картина беткәч тә, кешеләр дулкынланып, хисләнеп, урыннарыннан кузгалмыйча утыралар. Кызларның, яшьрәк хатыннарның күзләрендә яшьләре күренә.

Ә без инде — малайлар! Безгә бер картина карау атналар буена житә. Без картинаны башыннан ахырына кадәр тагын бер кат күңелебездән кичерәбез, әйтерсең, аны үзебез уйнап карыйбыз. Тау астында, казлар саклаган җирдә, талчыбыкларны кисеп, селтәгәндә чыжылдап торган кылычлар ясыйбыз. И китә шуннан тамаша! Ильяс, та-та-та! дип кычкыра, «пулеметтан» сиптерә. Без кылычларны нәкъ Чапай шикелле селтәп, «дошман» өстенә ташланабыз. Кырып кына салабыз. Син шунда безнең кулга чын корал тоттырып, чын дошманны күрсәт, без ике дә уйламыйча, үлемнән бер тамчы куркып тормыйча, ул дошман өстенә ташланачакбыз. Һәм мин уйлыйм ки, кино-картиналарның тәэсире олыларга да нәкъ шундый иде. «Кино сәнгате — иң бөек сәнгатьләрнең берсе» дигән фикерне Ленин тикмәгә генә әйтмәгән. Ул заманда кино авыл халкының күңелен тулысынча биләп алган бик көчле идеология чарасы иде. Безнең әнинең исә кинога карата үз сүзе бар.

— Анда нәрсә күрсәткәннәрен бик яхшы беләм мин. Барып йөрмәсәм дә. Анда аклар җиңелә, кызыллар һәрчакта җиңеп чыга инде. Кызыллар барысы да бик әйбәт, батыр кешеләр, аклар ерткыч, адәм актыклары, куркак тычканнар инде. Шуңа күрсәтәләр дә ул кино дигәннәрен алар сезгә. Ни эшләсен бик беләләр алар...— ди ул томанлы итеп һәм мин аны тагын һич кенә дә аңламыйм. Дөрестән дә, солдатны шомпол белән кыйнап үтерергә приказ биргән аклар полковнигы кем инде ул? Улмы ерткыч түгел! Соң, безнекеләр акларны һәрвакыт җиңеп чыкмаган мыни? Нәрсә, алар җиңелергә тиеш иде мәллә? Безгә аклар кул астында калыргамы, элеккечә тагын байларга, алпавытларга кол булыргамы?!

— Бер нәрсә дә белмисең син, әни. Кинога бармыйсың бит син, карамыйсың. Ә үзең сөйләшкән буласың!— дим, бик әтәчләнеп. Әни минем белән бәхәскә кереп тормый.

— Яхшы, яхшы, син бик беләсең инде, улым. Сез бик күпне беләсез инде хәзер...— ди дә шуның белән бетерә. Әни бер нәрсә дә белмим дип, мин бик дөрес әйтмим. Сугышка кадәрге елларда безнең авылда да наданлыкны бетерү курслары булды. Укытучы Галия апай кышын, балаларны укыткач, төштән соң олы кешеләрне дә мәктәпкә җыйды. Хәреф танырга, язарга өйрәтте. Безнең әни, бик җете акыллы, зиһенле әниебез шунда йөреп, тиз арада укырга да, язарга да өйрәнеп алды. Әти зимагурлыкта йөргәндә аңа хатларны да үзе яза торган булды.

Ул елларда авылга тагын бер яңалык килде. Биш чакырымдагы районнан болын аша безнең авылга телеграмм баганалары утыртып чыктылар. Җепкә тезгәндәй туп-туры итеп. Ул баганалар урам буйлап түбән очка кадәр төште, хәтта безнең тыкырыкка да керде. Билләренә

чылбырлы бик киң каешлар буган, аякларына галәмәт тә зур тимер тырнаклар таккан кешеләр бик ансат кына итеп шул баганалар башына менеп киттеләр. Анда ике яктан колак шикелле тырпаеп торган бик матур ак чәйнекләргә бәйләп, тимерчыбык суздылар. Стенаны тишеп, ул чыбыкның башын өйгә үк керттеләр. Түр стенага аш тәлинкәсеннән аз гына зуррак кара катыргы тәлинкә элеп куйдылар.

— Бу — радио. Ул сөйли. Мәскәүдән дә, Казаннан да төрле хәбәрләр тапшырып тора. Җырлап та җибәрә. Менә авылга кертеп кенә бетерик әле. Бер-ике көннән үзегез дә күрерсез! — диделәр.

Теге кешеләр өйдән чыгып китүгә, мин урындык куеп, катыргы тәлинкәне җәтрәк тотып карадым. Ул бик каты кәгазьдән ясалган түгәрәк булып чыкты. Уртасында тагын ниндидер йомры тимер, шнур ялгый торган нәмәрсәләр дә бар. Бу тәлинкәнең кеше шикелле сөйли аласына минем тамчы да ышанасым килмәде.

— Ничек итеп кәгазь сөйли алсын инде? Юк сүздер ул, — дидем.

— Һе, сөйләмәс... Әллә ниләр сөйләп бетерер әле. Сәвит нәрсә эшләсен бик яхшы белә ул, — диде әни.

Чыннан да, бер көнне иртән ул радиода нәрсәдер кыштырдады, шытыр-пытыр килеп торды да, ап-ачык тавыш белән сөйләп тә җибәрде. Бөтен өйне яңгыратып, шәрран ярып. Ярый әле, әти өйдә вакыт иде. Ул тәлинкә уртасындагы винтикны борып, аның тавышын әкренәйтте. Радио русча сөйли иде, мин аның нәрсә сөйләгәнен төшенмәдем. Әмма, «Слушайте, говорит Москва!» дигән беренче сүзләрен бик яхшы отып алдым. Әти урындык алып, радио астына утырды, үзе эшкә менеп киткәнче аны тыңлады. Ул чит җирләрдә күп йөргән кеше, урысчаны белә иде шул. Тик радио яныннан торып киткәндә әтиемнең йөзе сүрән, борчулы иде.

— Дөньялар бер дә тыныч түгел, әнисе. Европада сугышлар бара, адәм балаларының каны коела. Фашистлар котырыналар, теләсә кая кулларын тыгалар, — дип аңлатты ул, кулларын алъяпкычы астына кушырып үзен көтеп торган әнигә.

— Безнекеләр дә тыгылмыйча булмастыр әле, — дип куйды әни.

— Белмәссең. Анысы да бардыр инде, — диде әти томанлы итеп.

Тиз арада бу катыргы тәлинкәнең өйдә бик кирәкле, бик әйбәт бер әйбер икәнлеге беленде. Кич белән безнең бөтен гаилә җыелып, сәкедә ашап утырганда ул кисәк кенә: «Тыңлагыз, Казан сөйли!» — дип, саф татар телендә сөйләп җибәрмәсенме! Ул арада моңарчы без беркайчан да ишетмәгән гаҗәеп хәбәр дә китерде: «Хәзер иртәгә булачак һава торышы. Иртәгә Казанда һәм Татарстанда аз болытлы һава, җил — көньяктан. Егерме-егерме ике градус җылылык». Бу хәбәрдән без барыбыз да кашыкларыбызны куеп, тын калдык.

— Йа аллам, бар икән әле күрәселәр... Иртәгә нинди көн буласын да әйтеп бирә икән бит болар. Дөрес сүз булып чыгар микән соң бу? — диде әни.

— Ничек кенә дөрес була әле. Кайчак төп-төгәл туры килә, — диде әти.

— Менә онытмагыз. Иртәгә сынап карыйк әле шуны. Ни булыр икән... — диде әни, әле һаман ышанып бетмичә.

Әле дә хәтеремдә, радионың әйткәне иртәгесен тәки туры килде. Иртәдән аяз, ялт иткән зәңгәр күктә безнең ак каз кебек болытлар гына күренде. Җил дә йомшак, иситкеч җылы, рәхәт көн булды. Җылылык та туры килгәндер, ул вакытта безнең өйдә термометр кебек нәрсәләр юк иде әле.

Алай гына да түгел әле. Һава торышын хәбәр итеп тагын нәрсәләрен сөйләп торды да, радиобыз саф татар телендә җырлап та җибәрде. Бөтен өйне яңгыратып, гаҗәеп матур, моңлы хатын-кыз тавышы белән. Шундый якында гына кебек инде менә. Әйтерсең, безнең өй түрендә, сәкедә бик матур тавышлы, үзе дә бик матур, бик сөйкемле бер апа җырлап

утыра иде. Ул бик озын, моңлы көйгә җырлады. Ахрысы, «Карурман» булды. Без тын калып тыңладык. Әнигә исә җыр бигрәк тә ошады. Ул иягенә таянып, дөньясын онытып тыңлап утырды да, җыр тукталуга, акрын гына елап җибәрде.

— Абау, бигрәкләр дә өздереп җырлый ич бу... Бөтен күңелләрем кузгалды. Кыз чакларымны искә төшерде...— дип сөйләнде әни, үзенең бу йомшаклыгын аклагандай һәм алъяпкычы белән күзләрен сөртеп алды.

Шуннан соң инде радио безнең өйдә, әйтерсең, бер җанлы кешегә, хәбәрләр биреп, иртәгесе көннең ничек буласын әйтеп, җырлар белән күңелебезне ачып торучыга әйләнде. Үзе эшкә менеп киткәнче әти сәке читенә утырып яңалыкларны тыңлый. Ә инде кич концерт тапшыру вакыты җиткәнне бөтенебез, аерата әни көтеп ала. Хатын-кызлар да ирләр, хәтта балалар, бик күп кеше җырлый икән ул радиодан.

— Борып җибәрегез хәзер үк. Хәзер җырлый башларга тиеш!— дип кенә тора безнең әти.

* * *

Шундый матур, кызыклы яңалыклары булса да, әллә нинди хәвефле, хәтәр, шомлы еллар иде бу. Илдә бик тә явыз, әшәке, мәкерле, хыянәтче кешеләр бар икән. Халык дошманнары! Радио әледән-әле Мәскәүдә, башка шәһәрләрдә, Казанда да андый хәерсез бәндәләрнең эзләп табылуын, бик каты, гадел хөкемгә тартылуын хәбәр итеп тора. Аларның кайберләрен атып та үтерәләр икән. Шул кирәк аларга! Кара әле син, алар бит Ленин бабайны бер дә яратмыйлар, ә сөекле юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович Сталинның үзен үтереп ташларга җай гына көтеп йөриләр икән бит. Илебезне менә хәзер ныклы адымнар белән бәхеткә, яктыга барган юлыннан борырга, эшчеләрне тагын кол итәргә, ә колхозларны бөтенләй дә таратып ташларга. Безне бәхетле балалыктан, мәктәпләрдә укып йөрүдән, якты киләчәктән мәхрүм итәргә. Имансызлар!— Радио бу хакта көн саен сөйләмичә калмый. Мондый хәбәрләрдән соң без бик нәфрәтләнәбез. Тик безнең әни генә монда да үзен бик сәер тота.

— Ай аллам, мәхшәр, мәхшәр бит бу... Гөнаһсыз җаннар кыела, нахакка кан коялар бит... Бер дә гаепсездән, бер дә гаепсездән эшләнә булыр бу гөнаһлар. Имансызлар, алласызлар! Ай Аллам, үзең ярлыка гаепсездән гаепле булган гөнаһсыз җаннарны...— дип, әллә нәрсәләр сөйләнә башлый ул. Әгәр шунда:

— Син нәрсә сөйләнәсең соң, әни? Әллә инде шул халык дошманнарын җәллисеңме?— дисәң, җен ачулары чыга.

— Тик кенә тор ичмасам! Син нәрсә генә беләсең соң әле... Бәрәңге боламыгы тутырылган башың белән. Менә сез дә шул имансызлар булып үсәсез инде. Шулар үстерәләр сезне...— дип, тиргәп ташлый. Халык дошманнары сирәк кенә булса да безнең тирә-юнь авылларда да табыла тора. Нindидер кышкариларны, укытучыларны табып алып китteләр. Бер авылда ат карауч да халык дошманы булган. Колхоз атларына корчаңгы ияртеп, эшкә аяк чалырга ниятләр корып яткан бит, явыз бәндә.

Тирә-юньнән шундый хәбәрләр килеп торса да, бәхеткә, безнең авылны Алла саклады. Безнең авылда андый яшертен уйлы кеше, халык дошманы табылмады. Әмма безнең авыл кешеләре арасында да берберсенә ышанып җитмәү, шикләнеп карау, җае чыкканда сынап та карау бар иде.

Югары очта атларга яңа абзар салдылар. Баш ат караучы Закир абый монда да баш булып йөрде. Нәкъ теге рәсемдәге Буденный кебек озын буйлы, зур борынлы, озын мыеклы кеше. Шунда балта остасы Хәсән Закир абыйдан сорап куйды:

— Бу багана төпләрен дегетләп утыртабызмы, Закирҗан абый?
— Ә нигә аны дегетләп торырга? Утыртыгыз шул көе генә! — дигән Закир абый. Бик ашыгучан, каударлы кеше иде ул. Шуннан үтеп барган Мәһирә аның бу сүзләрен ишетеп ала.
— Шулай итеп, синеңчә багана төпләрен дегетләп торырга кирәк түгел инде, Закир абый, шулаймы? — дип сорый ул, әле йомшак кына итеп.
— Кирәкмәс дип уйлыйм мин, сеңлем. Вакыты тар бит аның. Атларны көзге яңгырларга чаклы яңа түбә астына кертәсе иде, — ди берни абайламаган Закир абый. Мәһирә шунда кызыл яулыклы башын артка чөя.
— Ярый, Закирҗан абый, син дегетләмәдең дә ди. Син нәрсә, колхоз ат абзарының баганалары тиз черсен дисеңмени? Тиз җимерелеп төшсен дисеңме? Әллә син колхозның да тиз арада таркалуын көтәсеңме? А ну әйтеп бир әле син шуны?! — ди Мәһирә, Закир абыйның каршысына ук килеп. Бу хәлдән агай тәмам югалып кала. Буденный гәүдәле агай кызыл яулыклы кечкенә генә кыз алдында гүяки җиргә ишелеп төшә.
— Сеңлем, җаным, ни сөйлисең син?!. Ни эшләп алай дип әйтим... Гомердә булмаганны. Шул колхозыбыз өчен тырышып йөрүләрем бит инде. Баганалар болай да имән, йөз ел торырлык... Андый сүзләреңне сөйли күрмә миңа карата, Мәһирәбану сеңлем! — дип ялвара ул, клуб мөдире каршысында җиргә тезләнергә җитешеп.
— Менә, менә, йөз ел торырлык булсын! Без төзегән колхозлар йөз ел да, мең ел да торырлар алар. Мәңге торырлар. Ә сиңа, Закир абый, андый кулак сүзләре сөйләшергә кирәкми! — ди Мәһирә эре генә һәм итәкләрен җилфердәтеп китеп бара. Бичара Закир абый бик түбәнсетелгән, мескен кыяфәттә, кулларын салындырып басып кала. Бераздан исен җыеп, балта осталарына кычкырып җибәрә:
— Дегетләргә! Бөтен баганаларны да дегетләргә. Утыртканнарын казып алып...
Мәһирә байтак кешеләргә бәйләнеп, аларның сүзләрен төзәтеп, акылга утыртып йөрде. Бервакыт Нурый абый, атын тугарып куйгач, арбасын сарайга кертә икән. Арба тәгәрмәчләренә пычрак ябышып каткан булган. Инде олы яшьтәге, күзе дә шактый сукыр Нурый абый монысын абайламаган, күрәсең. Әмма шул тирәдә йөренгән клуб мөдире моны күреп алган.
— Сарайга пычрак каткан арба куясыңмы, Нурый абый? Үз арбаң булса, син тәгәрмәчләрне кагып кертә идең бит. Колхозныкы ярый, колхозныкы череп бетсен дисеңме? — дип, очып кунган ул Нурый абыйга. Тегесе тәгәрмәчләрне кагып кына калмаган, коедан су алып килеп, ялт итеп юып куйган. Кыек әйтеп гаеп таккан сүздән, бәлага тарудан бик курка иде авыл халкы. Сүзне бит аны һич уйламаганча кирегә борып була.
Монысы гына ярар да иде әле. Шундый бер ышанмаучылыкның, бер-береңне сынап карауның ахыры зур фаҗига белән бетте.
Көзгә таба югары очның Муллагали абыйлар яңа өй котлату мәҗлесе үткәрделәр. Ул заман мәҗлесләр болай. Өйдә бернинди өстәл-урындыклар калмый, аларны чыгарып торалар. Өйнең түр ягына тоташтан паласлар җәяләр. Үзләре иске чүпрәкләрдән тукыган паласларны. Аякка ак йон оекбаш, ак күлмәк, башка чигүле түбәтәй кигән кунаклар аякны бөкләп идәнгә, стена буйлап тезелешеп утыралар. Токмачлы итле аш зур-зур табаклар белән уртага чыга. Итле бәлеш тә шунда. Бәлешне мәҗлестәге борын санынча вак кисәкләргә бүләләр. Эчәргә аракы түгел, мондагы алтмыш-җитмеш кунакка аны төткәрә алмыйсың. Өч литр сыйдырышлы, чирекле дип аталган шешәләргә тутырып, өйдә ачытылган бал куела. Эчә торган стакан да һәркем алдында түгел. Мәҗлес түгәрәген ике стакан әйләнә. Һәркем үзе теләгәнчә эчә, моны гаеп итеш юк, тик исерүчеләр сирәк була. Стаканнар түгәрәкне бер-ике әйләнергә

өлгерми, тальян гармун телгә килә. Кунаклар болай гына да, бер-берсенә атап та җырлый башлый. Мәҗлес матур бара. Авылдагы мондый мәҗлесләрнең күрке Галимулла абый. Авылның күренекле кешесе, ат докторы. Ул инде барча малларны, колхоз атларын, кешеләрнең сыер-сарыкларын, эт-мәчеләрен дә карый. Киң борыны астында ике якка таралып киткән калын мыеклы, кызыл йөзле, чибәр кеше. Үзенең гөбедән чыккандай калын, көр тавышы белән иң беренче җырны ул башлый:

Биек тауларның башында
Бөтерелә бер үлән,
Их дусларым, сезнең өчен,
Бер терелəм, бер үләм.

Бүтәннәр шунда ук аны күтәреп ала:

Галимулла абый, кеше икәнсен,
Чикләвек төше икәнсең.
Мәҗлестә утырырга
Беренче кеше икәнсең.

Без, малайлар, кәзәлектә, ягъни мич белән стена арасындагы куышлыкта. Безгә, билгеле инде, аш-су эләкми. Ә алай да йорт хуҗалары кайчак: «Монысы малайлар өлеше!»— дип кәзәлеккә берничә чәй ашы сибеп җибәрәләр. Өстен шикәр комы белән катырган бу гаҗәеп тәмле чәй ашларын без бер вакытта да идәнгә төшермибез. Хуҗалар өстебезгә сибеп җибәрүгә, һавада ук тотып алабыз. Табыш төгәл итеп санала, гадел төстә бүленә. Әмма бу сый безгә сирәк эләгә. Алай да без зур түземлек белән мәҗлесне башыннан ахырына кадәр тамаша кылабыз.

Муллагали абыйларның да яңа өй котлату мәҗлесе шулай тәртип кенә барды. Инде ул азагына да якынлаша иде. Галимулла абый инде үзенең эчмичә кыстатып утыручыларга карата чыгарган:

Кәримулла энем, син эчмәсәң,
Кәчтүмеңә сибәрмен!—

дигән җыруын да җырлады. Шунда әйтә куйды:

— Кара әле, Котдус абзый юк бит бу мәҗлестә. Ул кайда икән?

— Кайда булсын инде ул — болынында. Үзенең шалашында. Яшелчә бакчасын саклый,— диделәр сораучыга.

Безнең авылдан бер чакрымдагы болында, Ташлы елгасының бөҗраланып кергән зур бер тугаенда колхозның яшелчә бакчасы бар. Котдус абзый, инде өлкән кеше, колхоз чыкканнан бирле яшелчәче булган. Ул кыяр, кишер, кәбестә, шалканнарны үзе карап, бик кадерләп үстерә, үзе үк төннәрен саклый да. Колхозныкы дигәндә, яман да саран, сакчыл кеше. Без ул галәмәт тәмле яшелчәләрне читтән генә күзәтеп, кызыгып йөрибез. Болынга су коенырга төшкәндә яшелчә бакчасына якын да килә алмыйсың. Кая ул! Анда әллә нинди ботаклы, озын таягына таянып, башына киң кырыйлы салам эшләпәсен кигән, мыеклары да салам төсле сап-сары Котдус абзый калкып тора. Килеп кенә кара! Аның эшләпәсе астындагы кысык күзләре карчыганыкы кебек...

— Җенләнгән инде ул шул яшелчәләре белән. Чакырган мәҗлесләргә дә килмичә шул болынында утыра, ябалак. Шушы дөм төндә болында бер ялгызың утыр инде. Бу кадәр ихлас кеше дә булыр икән — диде йорт хуҗасы Муллагали.

— Ә менә ихлас микән әле?... Алай сакчыл микән? Әллә шалашында йокы симертеп ята микән?— дип күтәрелде шунда Галимулла абзый бик җай утырган җиреннән.— Колхоз малын күзәтүсез калдырып. Менә шунысын тикшереп карарга кирәк әле. Мин хәзер шунда — болынга төшәм!— дип белдерде, ачы балдан шактый кызып алган ат докторы гайрәтләнеп.

— Ай, Галимулла абый, йөри күрмә! Төне бик караңгы. Күзгә төртсәң дә күренми торган. Зинһар, йөри күрмә,— диде Муллагали.

— Менә, менә, караңгы төн. Самый караклар йөри торган. Тикшереп карау кирәк,— дип кызды теге һаман.

— Ниткән карак? Безнең авылга кайдан килсен ди ул караклар? Йөрмә үз башыңа яэҗүз-мәэҗүзләр эзләп, Галимулла,— диде Хәбибулла агай.

— И Хәбибулла, бигрәк беркатлы кеше син. Каравылчың гына йоклап ятсын. Карагы хәзер табыла аның... Юк, мин төшеп менәм әле. Күптән шикләнеп йөрим мин ул Котдустан. Бер дә гөнаһсыз булып юри генә кылана ул. Менә күрсәтим әле шуны!— диде Галимулла абый, һәм башына камчат бүркен киеп, ишек катыннан үзеннән калдырмый йөртә торган кәкре башлы чия таягын алды да, мәҗлес халкының ай-ваена да карамастан, чыгып та китте. Азрак яңгыры да төтәләп торган шомлы караңгылыкка.

Ну киткән кеше китте, аны тотып калып булмый. Аңа карап кына мәҗлес таралып төшмәде әле. Тагын бераз утырдылар, җырладылар, күңел ачтылар. Бөтен мәҗлес киткән бер кешегә карап «аһ» ормый. Кешеләр мәҗлестән таралганда төн урталары җиткән, яңгыры да көчәя төшкән иде.

Иртән без йокыдан торышка урамга көтү куарга чыккан әни шомлы хәбәр алып керде.

— Галимулла югалган. Кичә кич мәҗлестән торып, болынга төшеп киткән булган икән ул. Яшелчәче Котдус картны тикшерәсе килеп. Шуннан әлегә тикле өенә әйләнеп кайтмаган. Хатыны Маһинур урамда аһырып йөри. Ай аллам, нәрсә булды бу кешеләргә... Кара төндә нинди тикшерү икән инде ул...— дип сөйләнде әни.

Иртән сәгать уннарда да Галимулла абый һаман да өенә кайтмады. Алар капка төбенә халык җыелды. Сораулар китте:

— Ни эшләп кайтмый икән бу Галимулла абый?

— Әллә районга ук китеп барды микән? Анда эшләре бетми торган иде.

— Соң, җәмәгать, Котдус картка барырга кирәк. Бәлки, ул берәр нәрсә беләдер.

Тиз генә Котдусларга йөгерделәр. Ул көндезләрен чәй эчәргә кайта, өендә була.

— Мин төн озын йокламадым бүген. Төне буе яңгыр сибәләп чыкты. Минем янга килүче-китүче булмады. Андый-мондый шикле авазлар да ишетмәдем,— дигән ул. Яшь егет Гайсә тиз генә Сәет айгырына атланып, район үзәгенә, ат больницасына барып кайтты. Галимулла анда да күренмәгән. Инде төш вакытлары да үтеп киткәч, Галимулла абыйның хатыны Маһинур, бик юан, кәкре аяклы апай, аларның бала чагалары ишегалдындагы яшел чирәмдә ауный-ауный, бик яман кычкырып елый башладылар. Аларга ияреп, хатын-кызлар да елаштылар. Ул арада көне дә яман бозылды, кисәк кенә салкынайтып җибәрде, күктән бертуктаусыз әллә ниткән вак, томан сыман ябышкак яңгыр сибәләде.

— Йа, хода, олы хәвеф бар микән? Әнә күге дә ничек елый бит аның... Нәрсәләр генә булып бетәр икән инде бу?— диделәр җыелган кешеләр.

Икенче көнне инде халык җыйналып, зур сөзгеч, багорлар алып болынга юнәлде. Ташлы елгасын сөзеп, Галимулла абыйны эзләделәр, яр буйларын, камыш араларын, карамаган җирне калдырмадылар. Өч көн буена, һәм өч төн буена шундый салкын, ямьсез, шыксыз һава торды. Табылмады Галимулла абый. Бөтен авыл ихтирам иткән, бөтен авылга кирәкле, тап-таза, әле ир уртасы гына кеше, бер дә булмагандай, юкка чыкты.

— Шул имансызлар коткысы гына бу. Шулар гамәле... Шулар өстерә халыкны бер-берсенә. Берсе артыннан икенчесен шпионлык итеп йөрергә... Ни булса да, Галимуллага шулар зәхмәтеннән генә булды. Йа, хода! Дөнья бәһаләре кеше иде бит үзе. Ниләр уйлап кына ялгышты икән?— дип сукранды безнең әни кичләрен.

Ә Галимулла абый, чыннан да, суга төшкән булып чыкты. Бер атнадан көтүчеләр аның камчат бүрке белән кәкре башлы таягын табып алдылар. Ташлы суы ярыннан, куе камышлар арасыннан. Шул көнне үк авыл ирләре тагын сөзгеч алып болынга төшеп киттеләр. Бу юлы озакка бармады, бүрек табылган тугайда ук сөзгечкә ияреп, суга баткан Галимулла абыйның инде катып беткән гәүдәсе килеп чыкты. Шунысы гаҗәп, авылның һәр кешесеДәй бик яхшы йөзә белгән Галимулла сай гына, билдән аз гына тирән төшкә батып үлгән, ә аяк куллары кем беләндер көрәшкәндәй, кизәнеп-бөгелеп каткан иде. Аны ярга чыгарып салуга шунда йөренеп торган клуб мөдире Маһирә шик белдерде:

— Кем белән булса да сугышып үлгән булу ихтималы бар моның. Кемгәдер каршы торып. Монда үтереш булмагае әле... Милиция чакыртмыйча булмый монда. Ул килгәнче мәетне кузгатмаска!— диде ул. Бу әмергә буйсынмый чара юк иде.

Районнан атка атланган милиция икенче көнне генә килде. Аңарчы Галимулла абыйның үрмәкүч рәвешенә кереп бөгәрләнгән мәете шунда су буенда, чыпта өстендә ятты. Муллагали абый белән бригадир Сафа төне буе каравыллап чыктылар. Билен киң каеш белән буган, тәбәнәк, юантык милиционер башта Галимулла абыйның гәүдәсен әйләндерә-түлгәндырә карады, аннары тирә-якны, яр буйларын бик җентекләп тикшереп чыкты. Тәмәкесен тартып, әрле-бирле йөренде. Аннары инде шунда көтеп торган Маһирәгә бер дә яратмыйча, сөзеп кенә карап алды.

— Үтереш, имеш... Бернинди үтереш-алыш юк монда. Яхшы ук исерек булган бичара. Юлыннан язып, караңгыда суга килеп төшкән. Шунда батып та үлгән,— дип хәл итте кулын селтәп. Тик Маһирәнең алай гына бирешәсе килми иде.

— Ә ник әле ул кулларын болай бутаган алайсам? Кемгә кизәнгән ул? Сез миңа шунысын төшендереп бирегез!— диде ул, милиционер абыйның каршысына ук килеп.

— Кизәнгән пычагым! Ярга үрмәләп менмәкче булган ул. Менә башлаган да аягы таеп суга төшкән. Шулай тырмаша торгач, тончыгып үлгән дә. Әнә, яр читенә кул белән тырмашкан эзләрне күрмисеңмени? Сукыр түгелсеңдер ич!— диде милиционер, аңа тупас кына итеп.

— Син... Маһирә туташ, тырнак астыннан кер эзләп йөрисең инде. Безнең авылдан да бер-бер кешене гаепле итәсең бик килә инде синең. Халык дошманы итеп башын төрмәнгә илтеп тыгасың килә... Башыңа әтәч кикриге киеп куйган тавык син! Ә тавык әтәч булып кычкырса, замана ахрыга була...— диде бригадир Сафа, нәфрәт белән җиргә төкереп. Шуннан соң гына Маһирә төпченүеннән туктады.

Галимулла абыйны атлы арбага салып, өйләренә алып менделәр. Хәзер инде үрмәкүчтәй тырпаеп яткан гәүдәне юарга, кәфенләргә кирәк иде. Моны ничек эшләргә? Җиназага җыелган агай-эне аптырашта калды.

— Күп итеп су җылытыгыз. Мәетне шунда салыгыз да бераз вакытлар яткырыгыз. Үзе акрынлап йомшый, языла ул,— диде милиционер.

...Галимулла абыйны зиратка озатканда бөтен авыл халкы елап калды. Бөтен кешегә дә кирәкле, бөтен кешегә булыша торган әйбәт җан иде ул. Ходайның хикмәте: ул югалып-табылып, аны җирләгән көннәрдә һавасы да гел начар булып, еламсырап торды. Аны җир үз куйнына алгач кына, кояш чыгып, көне дә җылытып җибәрде.

* * *

Ул арада авылда моңарчы бер дә ишетелмәгән, әллә ниткән шомлы хәбәрләр йөри башлады.

— Динне бетерәселәр икән!

— Китче, гомердә булмаганны...

— Булмаганны?.. Дин генә түгел, муллаларның указын алып, үзләрен кәтер сөрәселәр ди.
— Ай, аллам, ай, мәхшәр!
— Мәхшәр... Мәчет манарасын да кисеп төшерәселәр ди әле!
Тиз арада ул хәбәрләр безнең авылга да якынлашып, чынга әйләнә башлады.
— Кышлау мәчетенекен кискәннәр дә ди инде. Дөбердәп килеп төшкән ди, җанашым. Җирләр тетрәп киткән, ди. Бөтен халык карап елап торган. Йа, ходa! Бар икән әле күрәселәр...
Безнең авыл мәчете авылның нәкъ урта өлешендә, шактый иркен буш урында. Тирә-ягы матур рәшәткә белән әйләндереп алынгач, өч буй бүрәнәләрдән салынып, такта белән тышланган мәчет авылда иң биек, иң иркен бина. Ул хәтта югары очтагы клубның үзеннән дә шактый зур. Түбәсе калай, ул түбәне ел саен матур итеп кызылга буйыйлар. Ә инде манарасы, манарасы! Тәрәзәләре әллә ничә, үзе күккә ашкан, очындагы гөмбәзе белән ае шундый биектә ки, кая гына барсаң да, күренеп тора. Түбән очтан, болын тау башыннан, хәтта инде без казлар көтә торган тау астыннан да. Җәйге иртәләрдә авыл өстенә күтәрелгән кояшның беренче нурлары шушы манараның гөмбәзенә, ә аннан инде тәрәзәләренә төшә. Ул тәрәзәләр ниндидер яшел, шәмәхә төсле нурлар чыгарып, балкып куялар. Шунда салкын иртә дә җылынып киткәндәй була.
Бу заманда инде безнең авылда указлы мулла юк иде. Утызынчы еллар башында карт хәзрәт вафат булгач, аның урынына яңасы килмәгән. Мулланың йорты торып калган. Мәчет каршысында гына биек коймалы, авылда бердәнбер калай түбәле, ике ишекле иркен бу йортта Рәхим абыйлар яши. Мулласы булмаса да, мәчет авыл халкын һаман да үзенә тартып, ничектер, үзе янына туплап тора. Җәйгә чыктың исә, егетләр-кызлар мәчет янындагы яшел чирәмдә кичләрен әйлән-бәйлән уйныйлар, җырлый-бииләр. Кыш көне инде бала-чага шау килеп, кара төнгә кадәр мәчет тавында чана шуа. Дини бәйрәмнәр көннәрен дә әле халык бөтенләй үк онытып бетермәгән. Андый көннәрдә тимерче Каюм абзый манарага менеп, азан әйтә. Аның гаҗәеп моңлы тавышы бөтен авыл өстенә тарала. Мондый көннәрдә инде без — малайларга да чынчынлап бәйрәм була. Кичләрен мәчеткә башларына чигүле түбәтәй, аякларына читек-кәвеш кигән карт-корылар, урта яшьтәге кешеләр дә җыйнала. Алар үзара акрын гына сөйләшеп, салмак кына атлап, мәчеткә кереп китәләр. Без дә мәчеткә керәбез, шома култыксалы киң баскычтан югары күтәреләбез. Тик шуннан ары инде безне үткәрмиләр. Ишек төбендә өлкәннәрнең намаздан чыкканын көтеп торабыз. Менә алар ашыкмыйча гына, вәкарь саклап кына ишектән чыгалар һәм... безнең һәркайсыбызга бер уч таракан җимеше бирәләр. Бер уч шулкадәр тәмле җимеш! Андый тәмле җимешне минем шул еллардан соң инде беркайчан да ашаганым булмады.
Шундый матур мәчетне манарасыз калдырырлар микәнни? Шундый биек, мәһабәт манараны кисеп төшерерләр микәнни? Бөтен авыл халкы борчуга төште. Бу хакта безнең өйдә дә берничә тапкыр сүз булды.
— Шулай итеп, безнең мәчет манарасын да кисеп төшерерләр микәнни? Ышанасы да килми бит моңа, — дип куя әти кичке аш вакытында.
— Кисәрләр... Бу имансызлар кеше башын да кисә ич. Бер дә гөнаһсызга. Мәчет манарасына җиткәч кенә, ник туктап калсын алар. Кисә дә кисә инде, — ди әни.
— Соң, анда кеше... Аның чынлыкта дошман булып чыгуы да ихтимал әле. Монда бит манара... Җансыз манара беркемгә дә дошман була алмый ич инде ул. Бу ниткән хәл була инде бу? — дип аптырый әти чарасыз төстә.
— Аларга барчасы дошман. Мәчете дә, аның җансыз манарасы да. Алар бит инде барчасын бетерәбез, кырабыз дип керештеләр. Мөлкәтеңне дә, динеңне дә, денеңне дә... Алар халыкның үзен дә бетерә әле. Менә

карап кына тор!— ди әни. Аның мондый сүзләреннән әти куркып кала, бер әнигә, бер безгә карый.

— Кызып китәсең син, әнисе... Артык күп сөйләп ташлыйсың,— ди ул шелтәле итеп.

— Менә уйлаган сүзеңне сөйләшергә дә ярамый шул инде. Жанына, теленә богау салып куйды ул имансызлар...— ди әни ачынып һәм тынып кала.

Ул арада, озак көттермичә, манара кисүчеләр килеп тә җиттеләр. Таза-таза, кып-кызыл чырайлы дүрт ир кеше. Болар төрле авыллардан җыелганнар, һәммәсе дә зимагурлыкта йөргән, икесе өтермәндә утырып та чыккан кешеләр икән, дип сөйләде авыл халкы. Үзләре болай гади генә киенгән кешеләр, кулларында да балта-пычкы. Гадәттә, безнең авылга читтән килгән кешеләрне, кое казучылар яисә балта осталарын кем дә булса үз өенә кертә, тәмле ашын пешерә, чәен куя, урынын җәеп йоклата. Үзләре дә бик аз сүзле бу әзмәвер кешеләрне беркем дә үз йортына дәшмәде, авыл кешеләре алар белән кул биреп күрешмәделәр, сөйләшмәделәр дә. Мәктәп ашханәсендә аш пешереп Маһирә апай аларны үзе ашатты, каравыл өендә йокладылар.

Берничә көн маташты кисүчеләр. Үзләрен билдән бау белән бәйләп, дөбер-дөбер килеп мәчет түбәсендә йөрделәр. Манара төбеннән аның калаен каердылар. Нинди матур түбә җилкә турысын умырып алган адәм төсле гарипләнеп калды, ямьсезләнде. Аннары алар манара төбендә кайнашып, нәрсәләрдер кистеләр, шакылдаттылар. Менә авыл өстеннән давыл кебек шомлы хәбәр үтте:

— Бүген кисәләр!!

Кара көз, инде аяк асты да туңдырган. Салкын җилле, әллә нинди шыксыз көн. Авылның яше-карты, бала-чагасы, бар халык иртәдән үк мәчет янына җыелды. Кешеләр мәчет рәшәткәсе тирәсенә ярым түгәрәк булып бастылар. Кисүчеләр билләрендәге бауларын өстерәп, очырмага менеп киттеләр. Җыелган халык алдына клуб мөдире Маһирә, колхоз рәисе Нәфикъ абый һәм авыл Советы рәисе Габдрәхим абый чыктылар.

— Җәмәгать, артка чигенегез. Алга чыгып баса күрмәгез, берүк! Тыныч кына торыгыз,— диде Габдрәхим абый халыкка. Бүтән чакта җил-җил атлап йөри торган, кискен сүзле бу кеше бүген үзе дә ничектер басынкы күренә. Сүзләрен дә уңайсызланып, йомшак кына итеп әйтте:

— Шулай итеп, алла йортына да кул күтәрәсегезмени инде, Габдрәхим? Без инде мәчетсез дә торып каласыбыз микәнни?— диде олпат гәүдәле тимерче Каюм абый. Зур башына һәрвакыт чигүле түбәтәй киеп йөргән, аракы эчмәгән, тәмәке тартмаган бу диндар агай халык төркеменең иң алдында басып тора иде.

— Ни хәл итик соң, Каюм абзый. Өстән фәрманы шулай аның. Манараны хәзер кисеп төшерәләр. Берни кылыр хәл юк...— диде авыл советы рәисе.

Шунда Каюм абзый үзенең көчле, моңлы тавышы белән нидидер дога укый башлады. Кайбер ирләр дә аңа кушылдылар. Хатын-кызларның күпчелеге, аларга ияреп хәзер нинидер куркынычлы хәл буласын сизенгән бала-чага кычкырып, тавышланып елый башладылар. Барлык ирләр башларыннан бүрекләрен салып, кулларына тоттылар. Халык аһыра, инри, фаҗига көтә иде. Шунда Маһирә кызыл яулыгын җилфердәтеп, Каюм абзый каршысына килеп басты.

— Каюм абзый, хәзер үк туктал бу эшеңнән! Халык куркытып... Сиңа ниткән дин? Мулла-мунтагай түгел бит син, гади бер тимерче. Туктал хәзер үк!— дип җикеренде ул.

Тик тимерче үзенең баһадир гәүдәсе белән тимер багана сыман баскан, үзе каршысына килеп әтәчләнгән кызыл яулыкны гүяки күрми дә, ишетми дә. Һирелеп, илһамланып догасын укый. Хатын-кызлар елый, балалар шыңшый. Ирләр тынычсызланып, бер урында таптана.

Ул арада кисүчеләр дә эшне кызулатты. Аларның берсе манараның очына ук диярлек бәйләнгән бик озын, юан аркан башын җиргә ташлады. Өчесе җиргә төшеп, шул арканга totындылар, мәчеттән мөмкин кадәр еракка киттеләр. Өстә калганы аларга кискен итеп нидер кычкырды да, үзе, кулындагы балтасын ялтыратып, манара төбенә кереп китте. Анда нәрсәдер тиз-тиз шакылдатты. Манараның алдан ук кисеп куелган терәүләрен бәреп чыгарды, күрәсең. Менә гаҗәеп төз булып, зифа булып күккә омтылып утырган манара, авыр ыңгырашкандай яман шытырдап, бер якка янтайды. Аның каршы яктагы терәүләре шатырдап сындылар. Җыелган халык күкрәгеннән куркынулы аһылдау атылды. Ә кисүчеләр, баһадирны егып салырга теләгән явыз кәрләләрдәй, бердәм ябырылып, чирәшеп, арканны тарттылар. Манара тагын тураеп басарга талпынгандай бер чайкалып алды да, үз көчәре тирәсендә әйләнгән көйгә, очлы ае белән һаваны сызгыртып ярып, яман шатырдап, гөрселдәп җиргә килеп төште. Тәрәзәләреннән өстәрәк өлешендә ул урталай сынды, бер-берсенә ышкылып кәкерәйгән калайлардан очкыннар чәчрәде. Пыялалары коелып төшкән тәрәзәләрдән бер көтү күгәрченнәр очып чыкты. Ул бичаралар соңгы мәлгә кадәр нәрсәгәдер өметләнеп, ояларын ташлап чыкмыйча утырганнар, күрәсең. Манараның оч өлеше Шәфикъ бабайларның бакча коймасын җимереп, бәрәңге бакчасына килеп төште. Ярый әле, инде бәрәңге алынып беткән иде. Тәмам тетрәнгән халык шым булып, кыймылдамыйча да басып тора иде. Без — малайлар исә җәтрәк йөгереп, шунда — манара очындагы ай һәм түгәрәк гөмбәз янына килдек. Аны тиз генә үзебезгә алабыз да бер урынга яшереп куябыз, ай белән гөмбәз үзебезгә була, дип, алдан ук сүз беркеткән идек. Манара исән вакытта аның очында, биектә нәни генә булып күренгән бу ай белән гөмбәз якыннан караганда галәмәт дәү булып чыктылар. Тик без аны әйбәтләп карарга да өлгермәдек, кисүчеләрнең берсе килеп тә житте.

— Һайт, малайлар, һайт! Йөрмәгез аяк астында буталып. Сезгә дигән ай түгел ул. Хөкүмәт үзе җыя аларны. Югалыгыз моннан хәзер үк! — диде ул тупас итеп һәм гөмбәз белән айны агач очлыктан шатырдатып каерып, йолкып алды да, аһылдап иңенә салды, Рәхим абыйлар ишегалдына алып кереп китте.

Шулай итеп, манара белән эш бетте. Әмма кешеләр әле тиз генә өйләренә таралышмадылар. Бу хәлләргә ышанмагандай аптыраган кыяфәттә, нәрсәдер көткәндәй дә булып, кайсылары әле һаман да күз яшьләрен сөртеп, тик басып торуларында булдылар. Манарасыз калган мәчет бөтен ямен, серлелеген, мәһабәтлеген югалткан, түбә калайлары кубарылып, бик ямьсезләнеп тора, ул инде гап-гади бер зур бина булып кына калган иде. Ә кешеләр исә мәчеткә һаман карыйлар да карыйлар. Инде колхоз председателе Нәфикъ абый йомшак итеп:

— Таралышыйк, җәмәгать, иртәгә эш көне,— дигәч кенә, кешеләр акрынлап тарала башладылар. Анда да әле, инде ерак киткәч тә, артларына борылып-борылып карадылар. Халык көн дә күреп ияләнгән манарадан мәхрүм ителгәч, авылның күге бушап, ямьсезләнеп калган. Авыл урамы күңелсез, ниндидер кайгы-хәсрәттә. Капка төпләрендә әбиләр кулларына калын дип китаплары тотып, кычкырып укып торалар.

Манара кискәнне карарга безнең әни менмәде. Колхозда ат җигеп, печән чабып эшләгәнлектән, ул ураза тота алмый, бүтән дини йолаларны да бик үти алмый, әмма җае чыккан саен, бер-ике сум гына булса да, Каюм абзыйга сәдака бирә.

— Нигезебезгә дога укырсың, Каюм абзый,— ди.

Мин әнигә манараны ничек кискәннәрен, аның ничек әйләнеп, ыңгырашып авып төшкәнен кулларым белән күрсәтә-күрсәтә, хәтта шатырдаган тавышлар чыгарып сөйләп бирдем. Әни мине дикъкать белән тыңлады, яулык чите белән күзләрен сөртеп алды.

— И алла, кара инде син бу денсезләрне... Нинди дөньяларга калдык бит... Безнең ак каз да алыштырып куйган кебек бүген. Әллә ничә тапкыр

бик моңлы итеп кычкырды, җанашым. Менә хайваннар да сизә шул. Болай булгач, динеңне тәмам бетерә инде болар. Аннан соң инде халык дигәнең дә бетә,— дип сөйләнде әни үзалдына.

— Дин беткәннән халык ник бетсен ул? Алай түгел ул, әни. Дин бетсә, халык дини хорафатлардан арына гына. Яңа тормыш килә авылга. Ә син шуны исәпкә алмыйсың,— дип, каршы төште әнигә дәрес әзерләп утырган Әдһәм абый.

— Әйтмәсәң дә инде. Безнең әни кайчан әллә ниләр сөйли ул. Аның сүзләрен тыңлап бетерсәң,— диде Флүрә апай да.

— Һай, балалар... Кем белә, бәлки алла рәхмәте белән заманалар бер үзгәреп китәр дә, сез минем бу сүзләремне дә искә алырсыз әле. Тик ул чагында мин генә булмам инде,— диде әни, көрсенеп.

Манарасын кисеп ташлагач, инде мәчет алла йорты булудан, дин учагы булуыннан туктады. Каюм абзыйга азан әйтергә дә, карт-корыга җыелып намаз укырга да урын калмады. Мәчеткә йөрүдән авыл халкы бөтенләй тукталды, безгә дә тәмле җимешләрне төштә генә күрергә калды. Мәчетнең бинасы әле иске түгел, бик нык иде. Алай да безнең авыл мәчетен бүтән кайбер авыллардагы кебек ашлык амбары итмәделәр. Өч бүлектән торган бу йортның иң түренә берничә елларга авыл Советы урнашты да, бүтән өлеше күп еллар буена, мәчет сүтелеп, югары очта башлангыч мәктәп итеп салынганчы, буш торды.

Авыл уртасында утырган бу бинага халык һәрвакытта да ихтирам белән карады, аның рәшәткәләренә дә, ишек тәрәзәләренә дә кагылучы булмады. Төнлә белән эченә ялгыз керергә дә курыктылар. Авыл Советы секретаре булып эшләгән, әле кияүгә дә чыкмаган Рәхимә апай үзенең иптәш кызларына мондый хәлне сөйләгән.

Рәхимә көзге бер кичтә аулагөйгә бара. Гадәт шулай инде, егетләр-кызлар уйный-көлә торгач, төнге сәгать уникеләр җитә. Өйләренә таралышалар. Шунда инде ялгызы гына калып, үз өйләренең капка төбенә кайтып җиткәч, капылт кына итеп Рәхимәнең исенә төшә. Ай Аллам, ул бит бүген мәчеттәге авыл Советы бүлмәсенең ишеген бикләмичә онытып калдырды. Барча документлар, язулар сакланган бүлмәне ачык калдырды! Кызларның эчләре «жу!» итеп китә. Ни эшләргә, ни эшләргә!? Комсомолка кыз ярдәм сорап кемгә дә булса әйтергә тартына. Хәер, бу вакытта, яңгырлы кап-кара төндә ничек итеп кеше бимазалап йөрисең. Ә бүлмәне биксез калдырырга ярамый, һич тә ярамый! Моны белеп алсалар, әллә нинди нәтиҗәләр ясаулары бар. Яшь башкайларыңны өтермәнгә кадәр илтеп тыгарлар. Һәм кыз тәвәккәлли, пычрак, дөм караңгы урам буйлап мәчет ягына атлый. Тәвәккәллекне бирсә, кыз балага да бирә ул Ходай. Бар батырлыгын җыеп, җанын ике учы белән дә кысып, мәчет эченә керә бу. Баскычтан күтәрелә, эчке бүлмәгә үтә. Тып-тын, зур тәрәзәләрдән аз гына яктылык төшә. Шунда кызның җаны урынына утырып, бераз тынычланып киткәндәй була. Авыл Советы бүлмәсенең ачык ишегеннән кереп, шырпы сыза, өстәл тартмасыннан ачкычлар бәйләмен ала. Аннан үз-үзен тезгендә һаман да тоткан хәлдә, ишеккә юнәлә. «Артка борылып карамаска! Борылып карамаска!» — дип әмер бирә ул үз-үзенә. Әмма инде бүлмә ишеген япканда түзә алмый. Тәки артына борылып, дөм караңгы бүлмәгә күз сала. Һәм... кызның бөтен гәүдәсе буйлап башыннан аягына кадәр көйдергеч кайнарлык йөгереп үтә. Менә нинди хәл күрә ул. Бүлмә идәнендә, стена буена тезелгән урындыкларның аяклары арасында бер карт мүкәйләп йөри.... Ул картның гәүдәсеннән ниндидер яктылык сирпелә, бүлмә дөм караңгы булса да, аның кәкре аякларын, елмаюлы йөзен, күкрәктәй ап-ак сакалын аермачык итеп күрә. Ярый әле, теге сихри карт кызга туры карамый, үзалдына гына карап елмая. Шунда туры карап алса... Рәхимә үзенең мәчеттән ничек йөгереп чыкканын, көзге пычрак урамнан үз өйләренә ничек кайтып җиткәнен икенче көнне иртән дә, аннан соң да берничек тә хәтерли алмый. Ничек кирәк алай өйгә кереп, урынга менеп яткач та

тынычланмый ул, төнне йокламыйча үткәрә. Тагын да зур хәсрәткә төшә. Хәзер бит ул куркуыннан авыл Советы бүлмәсен генә түгел, мәчетнең тышкы ишеген дә бикләмичә калдыргандыр! Төн үтеп тәрәзәләргә аз гына яктылык төшү белән, кыз урыныннан сикереп тора да җәтрәк мәчеткә бара. Тикшереп караса, мәчетнең тышкы ишеге дә, авыл Советы бүлмәсе дә бикләнгән! Куркуыннан үз-үзен белештермәсә дә, комсомолка кыз үз вазифаларына турылыклы булып кала...

Мәчет манарасыз да авыл уртасында бик күп еллар буена утырды. Аннары аны, әйткәнемчә югары очка авыл башына күчереп, мәктәп итеп салдылар. Бу бина әле дә, менә хәзерге көндә дә исән. Хәзер инде ул клуб булып тора. Әле дә тузмаган, тап-таза. Алай да, изге йорт салырга бүрәнәләрне сайлап ала белгән безнең бабайлар.

Сугыш еллары алдыннан авыл халкы арасында килеп туган берберенә ышанмау, хөсетлек, көнчелек безнең йортка да үзенең җәберен салды. Дөресе, без үзебез дә, тирә-күршеләр дә бик яраткан ак казыбызга салды ул җәберне. Бәхетсезлегенә күрә, кешеләр генә түгел, ата казлар да бик ярата иде шул. Язның бер көнендә, инде казлар бергә йөреп аталанган вакытта, безнең ак каз бер аягына бик нык аксап, канатларын салындырып кайтып керде. Ишегалдына чыгып карасак... «аһ»лар иттек. Казыбызның арт юлыннан бармак юанлыгы, ботаклы талчыбыгы тырпаеп тора!

— Ай аллам... Кайсыдыр юньсезнең эше инде бу. Каз үзеннән-үзе чыбыкка килеп болай кадала алмас. Берсе безгә ачу итеп башкарган бу гөнаһлы эшне,— дип хәл итте әни. Ул ара да булмады, капкадан Сәхәп абыйлар кызы Мәймүнә килеп керде, гадәтенчә, җәлт итеп кенә борынын сөртеп алды.

— Гайшәбикә апай, теге Чатан Саттар малае Вәли бар ич әле. Шул сезнең казыгызның эченә таяк тыкты. Мин үзем күреп тордым. Безнең ата казныаздыра ул, диде. Безнең ата каз үзебезнекеләрне басмый аннары, диде. Сезнең ак казны тотып алды. Кычкырса да, таяк тыкты ул аңа. Вәли ул начар малай икән әле,— дип хәбәр итте Мәймүнә.

Әти дә, без дә нишләргә дә белмичә каушап калдык. Әни исә ак казны кулына күтәреп алды, күкрәгенә сак кына кысты.

— Түз, җанашым, түз минем матурым. Хәзер коткарам үзеңне бу хәлдән...— дип сөйләнә-сөйләнә, бик җайлап кына каз артыннан тырпаеп торган чыбыкны алырга итә башлады. Каз бичара яман кычкырды, канатларын җилпемәк булды. Әмма әни сабырлык белән һаман үзенекен эшләде. Канга буялган чыбыкны каздан тәки тартып чыгарды. Бичара казкайның инде тәмам хәле беткән иде. Әни кулыннан төшүгә ул шунда ук җиргә утырды, атлап китә дә алмады.

— Чалмыйча булмас моны. Быел йомыркалар да салмас инде ул. Бибиләр дә чыгармас,— диде әти.

— Чалмыйсың! Быел булмаса, киләсе елга чыгарыр. Минем ак казым ул! Үзем тәрбияләп тергезәм дә мин аны,— диде әни, нык итеп.

Әти белән Әдһәм абый бездән биш-алты йорт аркылы торган Саттар абыйларга менәргә, аның үзен дә, малае Вәлине дә урамга чакырып чыгарырга җыена башладылар. Безнең әти болай юаш кына булса да, ачуын чыгарсаң, яхшы ук кыза торган, көчле-куәтле кеше. Зимагур Габделхәй, диләр аны.

— Мин ул Саттарны урамга чакырып чыгарам. Аңа бер-ике генә сүз әйтәм әле мин!—диде әти.

— Мин ул Вәлинең авызына берне кундырам анысы!—диде Әдһәм абый да. Тик аларның бу яу чабуларына әни киртә куйды.

— Йөрисе булмагыз!—дип кырт кисте ул.— Гөнаһсыз кошны рәнҗеткән өчен аларга алланың каһәре төшәчәк әле. Ә сез тавыш кузгатып йөрмәгез. Тагын әллә ниткән үчлекләр ясарлар...

* * *

Сугыш башланып киткән көнне бик ачык хәтерлим. Кояшлы, жылы, аз гына җиләс тә, гаҗәеп матур көн иде ул. Мин, инде мәктәпнең икенче классын бетергән малай, әнигә булышырга колхоз эшенә дә йөри башлаган идем. Без — әниләр, кызлар һәм малайлар — аркылы юл буендагы югары басуда чүп утыйбыз. Шунда, инде төштән соң, авыл ягыннан атка атланып, бик каты чаптырып бер егет килде.

— Сугыш башланган! Герман безгә сугыш ачкан. Бүген иртән таң белән. Радио шулай хәбәр итте! — дип кычкырды ул, ат өстеннән генә һәм тагын бүтән басуга чапты.

Сугыш хәтәре турында сүзләр авылда инде әллә кайчаннан бирле йөрсә дә, бу хәбәр басудагы халыкка аяз көндә яшен суккандай булды. Барысы да эшләрен ташлап, юл буена чыгып басты. Аһ-ваһ килде, хатыннар, аларга ияреп бала-чагалар да елый башлады. Яп-якты, ап-аяз көн әллә ниткән шомлы, куркынычлы, караңгы сыман булып калды.

— Ай Алла, бетәбез икән болай булгач...

— Герман кузгалса, бөтен дөньяны бетерә ди ул.

— Нимесләр хәзер галәмәт көчле ди...

— Ир-атларсыз калабыз икән инде... Ятимлеккә тарыйбыз икән, күрмәгәннәрне күрәбез икән, — дип, такмаклау белән елау көчәя генә барды. Шунда минем әни уртага чыгып басты. Минем бөтенесеннән дә озын, зифа буйлы, туры борынлы, матур әнием.

— Хатыннар, елап тормагыз! Монда елау белән генә котыла алмыйсың, — диде ул, тавышын Маһирәләр кебек күтәрмичә гади генә итеп әйтте. — Герман ул тар җирдә утыра. Халкы кырмыска кебек күп. Ул бөтенесен алырга бик тырышып караячак. Монда да килеп җитәргә. Менә бу басуларны, бу ашлыкларны үзенеке итәргә телидер. Ирләребез, егетләребез иртә таңнан сугышка чыгып китәр. Менә шушы малай-шалайлар белән эшләргә кала безгә, хатыннар. Елап тормагыз! Әгәренки елап тормасак, без ул дошманны монда чаклы китермәбез. Ирләребез кадәр итеп эшләсәк. Шәт иншалла, ул фашистлар бер дөмегер әле. Артыгын кыланганны Алла үзе җәзалый аны... — дип сөйләде әни. Һәм гаҗәп, бернинди җитәкче дә, агитатор да булмаган гади авыл хатынының сөйләгәне кешеләрне җәлеп итте. Елау-сыктаулар шунда ук тукталды, басудагы бар халык тын калып, әнине тыңлады. Аннары акрын гына эш урыннарына таралдылар...

Әнинең сүзе хак булып чыкты. Сугыш башланып, бер-ике көн үтүгә безнең әти, тагын байтак кешеләр фронтка китеп тә бардылар. Радио күңелле хәбәрләр китермәде, сугышка китүчеләрнең: «Тиздән җиңеп кайтырбыз!» — дигәннәре дә чынга чыкмады. Радио немецның һаман ил эченәрәк керүен хәбәр итеп торды. Безнең әни инде көнне-төнне белмәде. Көндезләрен ул басуда эшләде, ә кич кайткач, җәйге челләдә олы мичкә ягып, бәрәңге киптерә иде. Сугышка киткән әтиләргә җибәрергә. Кич белән без — Әдһәм абый, Флүрә апай һәм мин, капчыклы бәрәңге янына түгәрәкләнеп утырабыз. Әни безнең кулларга пычак тоттыра.

— Менә шушы бәрәңгене арчыгыз. Кара аны, әйбәт итеп, чиста итеп арчыгыз, токмач кебек итеп турагыз. Сугыштагы атагызга, Сафа абыйларыгызга китәсе бәрәңге ул. Шунысын онытмагыз! — дип кисәтә ул безне. Үзе яулыгын артка бәйләп, җиңнәрен сызганып, мич тирәсендә кайнаша. Ул хәзер хәтта ил түрәләрен, коммунистларны «денсезләр», «имансызлар», дип тиргәүдән дә тукталды.

— Фашистны җиңеп кенә кайтсыннар, алла боерса! Сугыш кына туктасын. Бу дөньялар бөтенләй икенчеләнеп китәр әле ул чакта. Тормышлар да әйбәтләнер. Безнекеләрне дә акылга утыртыр бу сугыш. Халык канын эчә алмаслар моннан ары, — дип юрады ул, без капчыгы-капчыгы белән бәрәңге арчыганда. Ул бәрәңгеләрне безгә бөтен авыл җыеп китерә, ә киптергәнне районга илтеп тапшыралар иде.

Шул җәйдә үк безнең авылга, өч атлы арбага төяп, ниндидер хатыннарны, балаларны кайтардылар. Бер ат безнең тыкрыкка да борылды, бездән ике өй аша гына постау торган Галимҗан абыйның капка төбенә тукталды.

— Ай Аллам, Мәскәүне дә алыр микәнни бу фашист? Болар — Мәскәү кешеләре. Урыслар болар...— диде тәрәзәдән күзәтеп торган әни.

«Урыслар» дигәч, миңа әллә ничек, шомлы булып китте. Әлегә чаклы минем урыс кешесен бер дә күргәнем юк иде. Шунда ук йөгереп капка төбенә чыктым. Эчтән шактый шүрләп булса да, тегеләр янына бардым. Баксаң, куркып торырлык бернәрсә дә юк, төрле төенчекләр, мендәрюрган, чемоданнар төялгән арба янында ике малай басып тора. Икесе дә минем буйлы малайлар, тик сап-сары чәчләре генә минеке кебек үткер пәке белән кырып алынмаган, маңгайларына төшеп тора. Икесенең дә күзләре җете зәңгәр. Алар икесе дә минем янга килделәр.

— Вовка, Петя! — дип, минем кулымны кыстылар.

Анда тагын ике хатын — безнең әни яшьләрендәге бер апа, инде олы, тәбәнәк, биле бөкрәя башлаган бер әби бар иде. Гаҗәп, үзләре хатын-кызлар, ә үзләренең чәчләре малайларныкы кебек кыска, башларына яулык та бәйләмәгәннәр. Әбисенең бите җыерчыклы булса да, күзләре бик дәү, матур, якты, ягымлы күренә. Ул минем яныма килде дә, иңнәремнән сыйпады, кесәсеннән кәгазьле кәнфит чыгарып бирде. Мин бу күчтәнәч сөенеченнән җәтрәк өйгә йөгердем.

— Әни, урыслар алар алай усал түгел икән. Малайлары да, әбиләре дә. Әле марҗа әби кәнфит тә бирде. Менә! — дип мактандым мин.

— Алар да безнең шикелле үк кешеләр инде, улым. Барыбыз да Ходай бәндәләре. Тик менә бәхетләре генә юк. Мәскәүдән тиңентен монда кайтканнар. Ай Аллам, һәй бу дөньялар,— диде әни.

Мәскәүдән килгән урыслар белән без бик аралашып яшәдек дип әйтә алмыйм. Тик алар, безнең әни әйткәнчә, нәкъ безнең кебек үк кешеләр түгел иде, күрәсең. Тегеләр килеп берничә көн үткәч, әни җамаякка салып, миңа бер дистә йомырка бирде.

— Мәскәүләргә кертеп чык. Тәбә пешереп ашасыннар. Тамаклары да ачтыр инде ул бичаракайларның. Ай Аллам...— диде әни.

Мин кайчкандыр кибетче Хабил абыйлар торган бик иркен, биек түшәмле өйгә кердем. Хабил абыйлар күрше авылга кибетче булып күченеп киткәнче бу өй һәрвакыт бик чиста, бөтен әйберләр үз урынына куелган була, көн дә юылган идәннәр ялтырап тора иде. Хәзер килеп керсәм, аптырап киттем. Идән чүпле, тузанлы, өйдә бернинди тәртип юк. Теләсә кайда ачык чемоданнар, урын-җир әйберләре таралып ята, кәгазь кисәкләре. Теге малайлар идәндәге түшәк өстендә таралышып, көпәкөндез йоклап яталар. Әби белән апа үзләре түрдәге өстәл янында утыралар. Аякларындагы күн әйберләрен дә салмаганнар. Менә инде, түр башында аякларына киеп утыралар! Дөрес, сугыш бара, кайгы-хәсрәт, кешеләр мондый вак нәрсәләрне уйлап та тормагандыр. Тик миңа — бернигә карамастан, өйдә саклана торган тәртипкә, чисталыкка күнеккән малайга — болар барысы да сәер тоелды. Әмма мине тагын да гаҗәпкә калдырганы икенче нәрсә булды әле. Өстәл өстендә бөкесе ачылган аракы шешәсе тора, аның янындагы стаканнарда яртылаш аракы бар. Теге әби белән апаның йөзләре өсте кызарып пешкән коймак төсле, үзләре елмаялар. Мин ирләрнең аракы эчкәнен беләм, исерек кешене күргәнем дә бар. Әмма үземнең әни шикелле хатын-кызның аракы эчкәнен ишеткәнем дә, исерек хатын-кызны күргәнем дә юк иде. Шуңа күрә ишектән кердем дә, тегеләргә карап, ни эшләргә дә белмичә аптырап калдым. Әби акрын гына урыныннан торды да минем яныма килде. Шунда мин тетрәнеп киттем: әбинең якты күзләре яшь белән тулы иде. Бактың исә, болар кайгыларыннан аракы эчеп, елашып утыралар икән! Әби үзенең бик нәни, матур куллары белән йомыркаларны алды да, кесәсеннән чыгарып җамаякка кәгазь акча салды.

— Юк, юк, акча кирәкми. Әни бирде, бушка бирде! — дидем мин, акчаны кире сузып. Тик урыс әбие яшьле күзләре белән миңа карап елмайды да, акчаны учыма кыстырып, мина таба этәрде.

Өйгә чыккач та, мин ашыгып сорау бирдем:

— Әни, хатыннар да аракы эчәмени?

— Эчми, улым. Ә ни эшләп әйтәсең әле син алай дип? — диде әни.

— Әни теге марҗалар эчеп утыра ич әле. Мин үзем күрдем.

— Булмас ла... — дип ышанмады әни башта һәм аннары тагын сүзен кире алды. — Ә нишләп булмасын икән ди. Ниндидән матур Мәскәүне калдырып, безнең караңгы авылга кайтырга мәҗбүр булган бит ул бичаралар. Бәлки ирләре, туганнары сугышта һәлак булгандыр. Эчәрләр дә шул, улым. Бик булыр. Урыслар болай да аракыга хирес ди бугай алар. Ишеткәнем бар иде... Бу хәвефле заманада аракы түгел, әллә ниләр эчәрсең... — диде әни.

Алай да мәскәүлеләрнең тормышы безнең авылда әллә ни авыр булмады. Аларга районнан алып кайтып пешкән ипи, чәй-шикәр кебек әйберләрне биреп тордылар. Авыл халкы да үз авызыннан өзеп, йомырка, бәрәңгене, катык-сөтне кертеп торды. Без, малайлар, Вовка һәм Петя белән дә дуслашып, аралашып китә алмадык. Алар урамга, капка төбенә сирәк чыгалар, анда да безнең танышлык бу малайларның матур чалбарларына, ялтыравык перәшкәләренә кызыгып карап торудан үтми. Бер авыз сүз без русча, алар татарча белмәгәч, уйнап та булмый. Хәер, аларның безнең белән бик уйныйсы да килми иде бугай. Мәскәүлеләр авылда озак та тормадылар. Җәй-көз үтеп, яңа еллардан соң, үз шәһәрләренә кире кайтып та киттеләр.

Эш белән, фронтта һәлак булганнарның ачы хәсрәте, күз яшьләре, заем, налоглар түләү авырлыгы белән иңрәп яшәгән авыл тормышын аз гына үзгәртеп, төрләндереп җибәргән тагын бер вакыйга булды. Ул елларда лотереяларны бик уйнаталар, лотерея билетларына иңбашына һава чүкече күтәргән шахтер рәсеме төшерелгән була иде. Югары очның Камали бабайларга зур отыш чыкты — автомобиль! Камали бабай үзе тәбәнәк буйлы, башына җәен-кышын чүпрәктән тегелгән әллә ниткән кәпәч киеп, күзләре гел яшьләнеп йөри торган бер карт. Колхоз җыелышларында чыгып сөйләмичә калмый, сайлаулар булганда клуб ишеге төбенә иртә таңнан ул менеп баса, иң беренче булып сайлый. Ул автомобиль откан икән дигән хәбәр таралгач, моңа бөтен авыл сөенде. Авыл кешеләренең кайберләре әле ул автомобильне күргәннәре дә булмагандыр, район түрәләре утырган бик матур, ялтырап торган автомобиль безнең урамнан күп булса елына бер-ике тапкыр үтә. Без — малайлар — тәгәрмәчләр астыннан битебезгә тузан болытлары бөркелүгә карамастан, аның артыннан чабышабыз. Дәррәү кычкырабыз:

— Тукта әле, утырт әле! Аз гына утыртып бар әле!

Машинада утырган ак күлмәкле, кызыл битле абыйлар безгә борылып карыйлар да көләләр. Аларга кызыктыр инде. Тик алар бер генә тапкыр булса да машинаны туктатмадылар, безне утыртып бармадылар шул.

Камали бабай автомобиль откач, төрлечә юраулар булды.

— Әһә, бер туйганчы карыйбыз икән инде атсыз арбаны! Камали бабай тотып караганга гына ачуланмас әле. Бәлки утыртып та йөртер әле, — дип, фараз кылды малайлар.

— Камали бабайның оныгы Хәйдәрне укытып кайтарырга кирәк. Авыл белән җыелышып. Өйрәнеп кайтсын машина йөртергә. Районга, больницага алып барыр иде. Бик читен бит ун чакрым җәяү йөрүләре, — дип өметләнде олылар. Тик бөтен авыл көтеп торган бу машинаның язмышы икенче төрле хәл ителде. Беркөнне төштән соң басуларга ашыккан янгын сарае янында туктаттылар. Халык алдына Камали карт чыгып басты. Башындагы кәпәчен салып, яшьле күзләрен сөртеп алды.

— Җәмәгать, менәтерә нәрсә... Мин лоторинга афтамабил оттым бит әле... Бик зур шатлык бит, менәтерә! — диде Камали карт.

— Бәрәкалла, Камали абзый, игелеген күр!

— Үзең йортә алмассың инде аны. Әнә оныгың Хәйдәрне укытып кайтартам. Мир белән ярдәм итәбез.

— Авыруларны, балаларны больницага алып барыр. Акчасын үзебез түләрбез! — диделәр картка. Тик Камали, бу сүзләргә каршылыгын белдереп, башын гына селтәде.

— Юк, юк, алай итмим мин, җәмәгать. Мин ул афтамабилне, беләсезме, ни эшләтәм әле! Кадерлебез иптәш Сталинның үзенә бүләк итеп бирәм мин аны. Тели икән, әнә үзе утырып йөрсен, тели икән, ярдәмчеләренә бирсен. Минем сүзем шул, менәтерә вәйт! — диде ул, куанычыннан тавышы нечкәреп. Картның күзләре тагын яшь белән тулган, бу инде шатлык, дулкынлану яшьләре иде.

Маһирә белән Нәфикъ абый, аларга ияреп, Камали карт үзе дә кул чаптылар. Җыелган халык кул чапмады. Кешеләр бер сүз дә әйтмәделәр, җәтрәк басуга юнәлделәр.

Сугыш авыл өстеннән коточкыч бер өермә, афәт булып үтте. Безнең кеп-кечкенә, нибары йөз йортлы авылдан җитмеш биш кеше әллә кайда ерак җирләрдә ятып калды. Шушы җитмеш биш кеше кемнең дә булса газиз улы, оныгы, әле һич сөеп туймаган ире, дөньяда бер генә, иң әйбәт булган әтисе, иң яраткан абыйсы, энесе, туганы икәнен искә алсак, башка афәтләрне инде әйтеп тә торасы юк.

Безнең әти сугыштан исән-сау кайтты. Бәхеткә, ул обозда йөкче булып йөргән. Берничә тапкыр җиңелчә яраланса да, өйгә кайтып кергәндә сау-сәламәт, яралы төше күренми иде. Алай да сугыш безнең өйдән дә бер кешене суырып алды. Кырык дүртенче елны әле унҗиде яше дә тулмаган Әдһәм абыйны, армия исәбеннән дип, Уралга алып киттеләр. Ул хәтта заводта да түгел, Чиләбе өлкәсенең бер совхозында балта остасы булып эшли башлады...

Сугышның беткән көнен дә бик яхшы хәтерлим мин. Язның иртәдән кояшлы, иртәдән җылы, гаҗәеп ямьле көне иде. Әти белән әни иртәдән колхоз эшенә киттеләр, без Флүрә апай белән бәрәңге бакчасында җир китмәнлибез. Егерме биш сутыйлы диңгез чаклы бакчаны көрәк белән казып чыгу безнең өстә. Аңа шулай ук көрәк белән бәрәңге утыртасы, чүбен утыйсы, төбенә өясе алда әле. Инде кояш Күшәр өстенә күтәрелеп, кыздыра гына башлаган иде, Низами тыкрыгыннан хат ташучы Гайсәнең чиксез куанулы, яңгыравык тавышы ишетелде:

— Сугыш беткән! Әһ-әй, сугыш туктаган!

Без Флүрә белән авыр, кулларны кабартып, авырттырып бетергән каһәр суккыры көрәкләрне читкә атып бәрдек. Ызанга чыгып егылдык. И шатланабыз, көләбез, сикерәбез. Бакчалардагы бар халык шулай итә. Җиһан әби исә үз ызаннарына чыккан да, кагып куйган казык кебек тураеп баскан, кулларын югары күтәргән, кычкырып дога укый.

Сугыш елларында авылда күп терлекләр чалынды, сатып җибәрелде. Әмма безнең ак каз һаман да исән калды. Теге чактагы үзенә һөҗүмнән соң ул янә тазарды, тагын әле күп еллар унбишкә кадәр бәбкә чыгарды.

* * *

Булмады! Безнең әнинең: «Алла боерса, җиңеп кенә кайтсыннар. Сугыш кына туктасын. Дөньялар бөтенләй үзгәреп китәр. Безнекеләрне дә акылга утыртыр бу сугыш. Халык канын эчә алмаслар моннан ары!» — дип юраулары бер дә туры килмәде. Аз гына да ичмасам. Сугыш тукталу белән, бу никадәрле сәер ишетелмәсен, авыл халкына бернинди җиңеллек килмәде. Үлем хәбәрләре килүдән туктауны исәпкә алмасаң. Дәүләткә ит, сөт, май тапшыру, акча налогы, заемнар

түләү кимемәде. Авыл халкын оятсыз төстә талау дәвам итте. Сугыш бетте, өч көн үттеме икән, төш вакытында авыл Советы рәисе Габдрәхим белән Маһирә безгә керделәр. Мондый вакытта Маһирәнең кулында, ни өчендер, сыгылмалы озын талчыбык була. Ул аны кулыннан төшерми, хәтта өйгә кергәндә дә үзеннән калдырмый.

— Быел сезгә заем өч мең тәңкә, Гайшәбикә апай! Бер тиен дә ким түгел! — дип ярып салды Маһирә, ишектән килеп керешенә. Әйтерсең, кулындагы талчыбыгын чажылдатып селтәде. Бу сүзләрдән әни, беркемнән дә курыкмый, беркемгә дә баш ими торган безнең әниебез дә бөгелеп төште.

— Булмый, Маһирә җаным, булмый. Ике меңе дә күп безгә. Әнә балаларның өчесенең дә бишмәте тузган... Күлмәкләрендә ямау...— дип санап киткән иде әни, Маһирә аны тупас итеп бүлде:

— Булыр! Әнә богыл чаклы ирең сугыштан исән кайтты. Әле сугыш туктамас борын. Сыер тотасың. Ак казың ел саен унбиш бәбкә чыгара. Шуларны сатарсың, түләрсең! — диде ул кискен итеп һәм, әнинең айваена да карамастан, кулын селтәде дә ишектән чыгып та китте. Кергәннән бирле бер кәлимә сүз дәшмәгән Габдрәхим абый аңа иярде. Әни исә бөгелгән җиреннән турая алмыйча торды да, хәлсезләнеп сәкегә килеп утырды.

Авылдагы бөтен өйләрдә дә шулай инде бу. Заемга яздырырга төш вакытында, яисә кичен, кеше өйдә чагында керәләр. Бөтен кешегә бернинди ташлама ясамый, зарын тыңламый, элек кәнсәләрдә билгеләп куйган суммага заемга яздыра Маһирә. Бөтен авыл халкының күз яшен коя ул.

Сугыш тукталу белән ачлык афәте дә карыш та чигенмәде. Инде авылдагы беркемдә дә бернинди он, бөртек запасы калмаган. Иртә яздан кешеләр былтыргы арыш, бодай басуларына чыгалар. Пычрак ярып, әрле-бирле йөренәләр, былтыргы чүмәлә, кибән төпләрендә коелып калган башакларны җыялар. Аннан ул башакларны түбәләргә җәеп, кояшта киптерәләр. Шуны уалар да коелган бөртекләрне табада кыздырып ашыйлар, яисә кул тегермәнендә тартып, көлчә пешерәләр. Ул арада авылда берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр таралды:

— Былтыргы ул орлыклар агулы икән!

— Шуның белән агуланып, Күшәрдә ике гаилә үлеп беткән, ди.

— Канны сыеклый икән. Авыз-борыннарыннан кан киткән. Бөтен стеналары кан белән тулган, ди...

Маһирә белән Габдрәхим халыкны янгын сарае янына җыеп алдылар.

— Җәмәгать, былтыргы башакларны җыюдан туктагыз. Ул быел кар астыннан агуланып чыккан. Районнан шулай диделәр,— диде Габдрәхим абый.

— Берегезне башак белән күрсәм, карагыз аны. Басудан урлап кайтканга чутлана! — дип кисәтте Маһирә. «Урлаганга чутлана!» дигәнне ишеткәч, беркем дә каршы дәшмәде. Моның нәрсә икәнен һәркем бик яхшы белә.

Башак димәктән, башак белән булган бер вакыйга бөтен авылны тетрәндерде. Машинасын Сталинга бүләк иткән Камали бабай үзе инде бернигә ярамаган, дөрселдәп беткән бер карт булса да, әле һаман да бик актив, кыбырсык. Ул, әйтергә була, бөтен авылны, колхозны күзәтеп, барлап, кайгыртып тора. Әвендә эшләгән хатыннар кесәләренә салып, өйләренә арыш яисә борчак алып төшмиме, урак уручылар басуда ут ягып, таба белән бодай куырып ашамыйлармы, олаучылар арбаларына салам-печән салып кайтмыймы, басуда үсеп утырган игеннәргә кул сузучы юкмы? Ачы таннан кара кичкә тикле басуларда, ындыр табагында, амбарларда йөренә Камали бабай. Аның яшьләнеп торган күзләре барысын да күрә, ул барысына да өлгерә, барысын да искәртә. Бу тырышлыклары бушка да китми. Көннәрдән бер көнне ул эләктереп тә ала.

Басуда инде арыш башаклары өлгереп килгән вакыт. Ә авыл халкының иске бәрәңгесе инде беткән, яңасы әле өлгермәгән иң авыр һәм фәкыйрь көннәре. Алма апайлар белән Камәрия әбиләрнең мәктәп яшендәге кызлары Гөлзада белән Тәслимә Әптерәмән тау башындагы арыш басуына баралар. Кесәләреннән кайчы чыгаралар һәм басу кырыенда гына торып, иң өлгергән башакларны кисеп ала башлыйлар. Кисеп алалар да кесәләренә салып куялар. Шул заман арыш арасыннан нәкъ болар каршысына Камали карт пәйда була. Җир астыннан калкып чыккан җен, пәри, убыр сыман. Бичара кыз балалар качып китү юлы бар икәнен дә онытып, катып калалар.

— Килеп каптыгызмы, җанашларым! — ди Камали карт, үзе дә нәкъ тәти уенчык тапкан бала кебек куанып һәм тегеләрне кайчы тоткан кулларыннан эләктереп тә ала.

Кызларны колхоз кәнсәләре янына алып кайттылар. Каяндыр чәчрәп Маһирә килеп чыкты. Велосипедына атланып, районнан участок милиционеры, озын буйлы, ябык кеше Галимулла килеп җитте, Габдерәхим абый күренде. Алма апай белән Камәрия әби икесе дә монда, алъяпкычлары белән күзләрен сөртеп, пышык-пышык елыйлар. Тагын берничә карт-коры куркышып карап тора. Теге бичара кызлар уртада, котлары алынып як-якларына каранаалар. Шунда Камали, картларча беркатлы, ахмак елмаеп, кызлар янына килде, аларның кулмәккә махсус тегелгән кесәләрен әйләндереп салды. Һәр кесәдән җиргә берәр уч башак коелды. Моны күреп, җыелган халык өнсез калды. Бу бит инде дәүләтнең нигезен какшаткан җинаять иде... Камали бабай кулын күтәреп, кояшта ялтыраган кайчыларны халыкка күрсәтте:

— Менә аларның бурлык кораллары!..

— Ах, син, оятсыз! — дип, Маһирә кулындагы талчыбыгы белән үзенә якын торган Тәслимәгә кизәнде. Тик сугарга өлгерми калды. Авылда зәһәрлеге белән данлы Камәрия әби очынып аның янына килеп җитте, кулындагы талчыбыгын тартып алды да, урталай сындырып, читкә атып ташлады. Эш аның белән дә бетмәде әле. Әби бар куәтен салып, клуб мөдирен шундый итеп этеп җибәрде ки, теге аркасы белән чирәмгә барып төште. Итәге ачылып китте, ябык кына ботлары, хәтта ыштан төбе күренде. Ыштаны кырык ямаулы иде... Шунда халык та Маһирәнең бер дә аермалы, асыл зат түгел икәнен, ә гап-гади, ямаулы ыштан кигән бер авыл чәчбие икәнен күреп алды.

— Ягылма минем оныгыма, җирбит! Ашаган табагыңа кәкәй иткән нәрсә. Кечкенә вакытында ачтан бетә идең бит син. Вак бәрәңгеләремне биреп, мин генә алып калдым сине. Хәзер йөргән буласың... кызыл кикрик тагып. Тьфү! — дип төкерде Камәрия әби Маһирә тарафына. Гаҗәпкә каршы, тегесе бик тә каушап, куркып калган иде. Камәрия карчык Маһирә тарафына тагынниләрдер әйтмәкче иде дә, аны милиция Галимулла туктатты:

— Җитәр инде сиңа, әбекәй. Бик тә боевой әби булып чыктың әле син. Әгәр сугышка барсаң, бөтен немец куркып качар иде синнән,— диде ул көлеп. Аңа кушылып бүтәннәр дә көлеп җибәрде. Тик бу кызык озакка бармады, карак кызларның язмышын хәл итәргә кирәк иде.

— Шулай итеп, миңа нарасыйларны үзем белән алып китәргә микәнни? Районга алып барсаң, боларга колония бит инде... Кимендә биш ел...— диде Галимулла аптырап кына.— Камали бабай, син... тукта әле.Бәлки эш икенче төрлерәк булгандыр? Бәлки алар башакны басудан кисеп алмагандыр да әле. Юл читеннән, былтыргыдан үскәнне алгандыр шунда. Беткәнмени басуда башак...

— Юк, юк! Ниткән ул. Үз күзләрем белән күрдем.Басудан, орлыкка дигән кишәрлектән алдылар, иптәш учаскавай! — диде Камали карт ашыгып.

— Сез... нәрсә, иптәш милиционер?! Алып китәргә, утыртырга боларны. Бүтәннәргә сабак булыр,— диде Маһирә. Ул инде җирдән торган, төзәтенгән, йөзендә элеккечә тәкәбберлек иде.

— Соң... миңа нәрсә. Мин алам да китәм,— диде Галимулла.

Мондый хөкемне ишетеп кызлар да, Камәрия әби белән Алма апай, аларга кушылып шундагы барча хатын-кызлар кычкырып, тавышланып елый башладылар. Әйтерсең лә авыл өстенә мәхшәр якынлашып килә иде.

— Туктагыз әле, җәмәгать. Әлегә яңгыр кирәкми, әле кичә генә яуды бит. Шулай булгач, күз яшьләрегезне тыеп торыгыз! — диде Габдрәхим абзый, аз гына булса да кызык сөйләргә тырышып.— Бу кызларны буш калдырып булмый анысы. Һәм без аларны җәзага тартабыз да. Без көз көне алар гаиләсенә тиешле ашлыкның унар килосын тотып калабыз. Менә булыр бу — җәза!

— Иптәш прсидәтел, сез иптәш Сталин күрсәтмәләренә каршы киләсез! — дип очынды Маһирә.

— Бер дә каршы килмим, Маһирә туташ. Иптәш Сталин матди җәзаны кулланырга да куша ул. Яшәсен кадерлебез иптәш Сталин! — дип кычкырды Габдрәхим абый.

Моңа җыелган халык кул чапты. Алма апай белән Камәрия әби, йомшак төшләренә суга-суга, оныкларын өйләренә алып киттеләр.

Сугыштан соң авылда ачлык кимемәде түгел, бәлки көчәйде генә. Җәй көннәрендә өлкәннәр арасында хәтта ачка үлүчеләр булды. Бөтен авылга чабата ясап торган Әхми абый ачтан үлде, югары очның Мәхмүт бабай хәер эстәргә чыгып киткән җиреннән Мари ягы авылларының берсендә, урамда ятып үлгән, аны шунда җирләгәннәр дә.

Бервакыт без малайлар югары басуга менәбез. Уфалла арбасы тартып, әрем җыярга. Күрәбез, аркылы юл чатында Низами бабай утыра. Шунда кечкенә капчыгы, таягы да янында. Хәер эстәүдән кайтып килеше, ял итеп утырадыр.

— Низами бабай, исәнме! — дип дәштек без. Бабай җавап кайтармады, шул утырган килеш калды. Инде арбаларны әрем белән тутырып, кире авылга төшәбез. Шактый вакытлар үтте, көн дә кичкә авышты. Күрәбез, Низами бабай һаман да шунда, шул килеш утыра, селкенми дә.

— Низами бабай, нишләп утырасың инде син монда? — дип дәштек без. Бабай тагын җавап бирмәде. Шунда Ильяс аның янына барып, иңенә кагылды һәм... бабай таш сын кебек түнеп китте. Аякларын бөкләгән килеш. Ул әллә кайчан үлгән, катып беткән икән инде!.. Безнең бу хәлдән котыбыз алынды. Акыра-бакыра җәтрәк авылга, олыларга хәбәр бирергә йөгердек.

Шунысы да гаҗәп, сугыш вакытында авылда кеше әйберенә кул сузу, аракы эчү кебек ямьсез күренешләр булмады диярлек. Сугыш елларында авыл ул таркалмады да. Шәхсән, безнең йөз йортлы авылда бер генә нигез дә бетмәде. Авылның рухи һәм физик яктан таркалуы сугыштан соң башланып китте.

Сугыштан соң авылның рухи һәм физик таркалуына төп сәбәп Сталинның һәм аның иярченнәренең авыл кешесен, крәстиянне гомумән адәми затка санамавы, аңа бары тик эш аты итеп кенә каравы булды. Сугыштан соң авыл белән шәһәр тормышы кискен аерылды. Эшче эшләгәне өчен акча алды, башка ярдәмнәр алды, ул кешегә саналды. Ә крестиянгә, колхозчыга сугыш тукталу белән бернинди җиңеллек бирмәделәр, ул һаман да бушка, бөтенләй диярлек бушка эшләвен дәвам итте...

Гәрчә коммунист түрәләр алай исәпләмәсә дә, авыл кешесендә дә җан, акыл вә зирәклек тә бар бит әле. Ул күрде: аз гына кешечә, эшләгәненә тиешлесен алып яшим дисәң, авылны калдырып, шәһәргә таярга кирәк. Туган-үскән, суын эчкән, зиратында ата-бабаларың яткан авылны калдырып, ничек тә булса таярга! Ничек булса да дип шуңа әйтәм, ул заманда авыл кешесенә хәтта аның шәхесен раслаган паспорт та бирелмәде. Тик кешеләр барыбер җаен таптылар, хәйләсенә кердeләр. Авыл яз көне гөж килеп эрегән кар өеме кебек таркалды.

Бу таркалу безнең авылга да килеп керде. Табигать законнары һәр нәрсәне чит-читеннән, баш-башыннан тарата. Безнең авыл белән дә шулай булды. Түбән очның Фәүзия, Ясминә, Маһинур апайлар, Котдус абыйлар Казанга эшкә ялланып киттеләр. Анда төзелештә эшләп, фатир алдылар һәм әти-әниләрен үз яннарына алдырдылар. Безнең тыкрыкка каршы урамда өч йорт берьюлы сүтелеп, урам кыскарып калды. Аннан югары очтан Хәсби, Сөнгать абыйлар, авыл уртасыннан тагын күп кешеләр читкә чыгып китте.

Бу таркалу очланып торган ике терсәген киң җәеп безнең өйгә дә килеп керде. Әдһәм абыйны Уралга алып китүләре хакында әйткән идем инде. Аннары нәүбәт миңа җитте. Мин авыл мәктәбендә алтынчы класска кадәр генә укып калдым. Авыл Советы рәисе Габдрәхим абый, районнан бирелгән нәрәд буенча мине Казанга, өченче номерле һөнәр училищесына җибәрде. Мин шунда токарь һөнәре алып, югары разрядлы эшче булдым.

Апам Флүрә, хәтта әби белән әни үзләре дә авылда торып калмадылар. Уралдагы бер совхозга урнашкан Әдһәм абый аларны үзе янына алдырды. Ул заман анда муллык, бар нәрсә арзан булган. Безнең хәерче авылыбыз түгел. Әдһәм абый кызыктырып хатлар яза, үзе кайтып кодалый торгач, картлар тәвәккәлләгәннәр. Йорт-җирне юк бәягә генә сатканнар да, гомер иткән авылны калдырып, Урал тарафларына юл алганнар. Әни аннан торып миңа хатлар язды:

**«Сөекле улым Таһирҗан! Без монда бик әйбәт яшибез. Ни теләсәк, шуны ашыйбыз, өстебез дә бөтен. Әмма дә ләкин авыл бик сагындыра. Үзебезнең капка-коймалар, Акый коесы сукмаклары, Әптерәмән таулары көндез — уебызда, төнлә — төшләребездә. Монда казлар кычкырганны ишетсәм, күңелләрем әллә нишләп китә. Үзебезнең ак казны искә төшерәм. Ул әле дә исән, каз дигәнең бик озын гомерле икән ул. Безнең авылдан киткәндә әтиегез аны чалып юлга алырбез дигән иде. Мин рөхсәт итмәдем. Без аны Алма апайларында калдырып киттек. Авылга кайтсаң, үзебезнең нигезгә утырып бер ял ит, улым, Алма апаеңа сәдака бир. Без ерактагылар өчен, туган туфрагыннан аерылганнар өчен дога кылсын. Кайчак әтиең белән утырабыз да, елап күңел бушатабыз. Безнең сагынуларыбыз, безнең сагышларыбыз Урал таулары чаклы, улым».**

* * *

Гомерләр үтте. Дөньяның асты-өскә килде. Минем әнкәй «имансызлар!» дип тиргәгән коммунистлар үз иманнарына үзләре хыянәт иттеләр, халык нинди авырлыклар белән, кан-яшь түгеп күтәргән, инде ихлас күңеленнән ышанган социализм эшенә хыянәт иттеләр. Хәер, эш башында әле дә булса шул ук коммунист-түрәләр, тик инде алар бөтенләй икенче иманны тукыйлар. Асылда халыкны икенче ялганга ышандырмакчы булалар...

Мин инде үзем дә картаеп килгән бер кала кешесе. Бик сирәк кенә авылга кайтам. Безнең тыкрык бөтенләй юк инде. Анда йортлар бетеп, урам тураеп кына калган. Алай да йорт урынын, үзебезнең нигезне табып була әле. Мин үзебезнең нигезгә килеп утырам. Хәзер әйләнә-тирәдә каралты-кура да, коймалар да юк. Бөтен тирә-як, тау аслары, анда йөргән ак казлар күренә. Кем белә, бәлки алар безнең ак казның нәселеннәндер. Ә бәлки алар минем чит илләрдә туган якны сагынып, саргаеп яшәгән, инде күптән вафат әтием белән әниемнең җаннарыдыр... Кем белә?..

*1994 ел, Арча.*

# Чәчмә әсәрләр



## Рәфкать Кәрами

# «АВЫЛДАШ»

хикәя

Юньсез ирдән аерылган ялгыз хатынның өй мәшәкатьләре чагыштырмача азрак була, диләр, Әнүзә дә хәзер моны яхшы белә. Ире белән яшәгәндә алты елга ничә тапкыр зоопаркка бардылар икән? Хәтерендә — ике мәртәбә. Ә ял паркына чыгулары? Анысы да ике-өчтән артмагандыр. Хәтта заводтан бушлай бирелгән юллама белән Иделдәге ял базасын да күрергә насыйп булмады. Гел мәшәкать, гел борчу, юк-бар ыгы-зыгы белән үткән икән ул еллар: дөнья малы артыннан куу, туган-тумачалар килү, аларга үзләре бару, авылга кайту, килүчеләрне каршылау, кибет юлын таптау, бере-беренә үпкә-рәнҗеш... Театр-концертлар да һаман читтә кала килде. Чыршы бәйрәмнәре дә сирәк тәтеде анын кызына. Тимераякта, чаңгыда шууларны әйткән дә юк инде.

Шуларның әҗерен кайтарырга теләгәндәй, Әнүзә, кызы Илюзияне иртә дә, һәркөн булмаса да, атнаның һәр бирмеш шимбә-якшәмбесендә каядыр чыгып югала. Моны күршедәге бер апа шулай шаярып әйтә: чыгасың да югаласың, ди. Юк, Әнүзә югалмый. Ул тормыш вак-төягеннән арынып, онытылып тора. Әмма югалмый. Чөнки аның юл күрсәтүчесе — кызы бар. Әйе, Илюзия белән алар көне буена дип чыгып китәләр дә, арып-талып, теге апа әйтмешли, чистый эштән чыгып, кайтып авалар.

Бүген дә Әнүзә, кызы Илюзияне житәкләп: сәйрәп дисә дөресрәк булыр, өенә кайтып килә. Күпме йөреп, уйнап арса да, кызының әле һаман керәсе килми икән.

— Әни, әнием, тагын берәр жиргә барыйк әле,— ди ул, ялынып.

— Кызым, кайтыйк инде,— ди Әнүзә һәм, чүгәләп, аны битеннән үбеп ала.— Әле иртәгә дә көн бар.

— Һе, иртәгә хәтле...

Шуның белән сүз бетә. Әнүзәнең сүзе бетә. Ә кызының? Юк. Шулай да кызчык дәшми. Әйтүдән ни файда? Әнисе аны барыбер өйгә алып кайтачак. Ә анда... Нигәдер Илюзия бу яңа йортка ияләшә алмый. Һавасы да икенче, кешеләре дә бүтән, әйләнә-тирәсе дә... Ә элекке өйләре

нинди матур иде! Кыз күңелендә якты хатирәләр уяна: ул йортта үткәргән көннәре һәм... әтисе. Әйе, әтисе. Илюзиянең гел урамга чыгарга, тегендә-монда барырга теләвенең дә төп сәбәбе шул түгел микән әле?! Кыз моны анык кына аңламаса да, күңеле белән тоя шикелле. Дөрес, әтиләреннән аерым яши башлагач, аларның өенә тынычлык иңде: тавыш-гауга, минут саен диярлек яңара торган җәнҗал-низаг бетте, куркуөркү юкка чыкты. Кыз башта моңа, әнисе шикелле үк, бик сөенде. Әмма тора-бара әтисен юксыну, аны күрәсе килү теләге көчәйгәннән-көчәя бугай. Өйдә гел ызгыш булса, күп нәрсәне күңеле аша үткәрергә, үз эченә бикләнеп яшәргә өйрәнгән балалар кебек, Илюзия дә соңгы бер-ике елда йомыкыйланды. Ә менә хәзер язгы бөредәй ачыласы, әтисе очраса, йөгереп барып: «Әтием!» — дип муенына сарыласы килә аның.

Кайбер хатыннар балаларның мондый халәтен бик тиз төшенеп алалар һәм, ирләреннән аерылгач та, өйгә берәр ир-ат ияләндерәләр. Бала хакына. Дөрес, балага үз атасын башкалар алыштыра алмый. Әмма шулай да сабый тора-бара читләргә дә ияләшә, диләр. Әйбәт кеше булса, әлбәттә... Әнүзәнең андый кешесе әлегә юк. Яшь ана моны үзе дә сизә башлады. Хәтта күршеләре — әлеге апа — әйткәләп тә куя:

— Балаң кечкенә чакта берәрсен йортка кертәсеңме әллә? Аңа ата да кирәк бит.

Әмма әлегә бу хакта ныклап уйлаганы юк. Хәлбуки, аңа сүз кушучылар байтак. Сүз катмаслык та түгел шул: Әнүзә бик чибәр, мөлаем хатын. Аның ходай биргән матурлыгы да карап туймаслык. Ә бар булган затлы киемнәрен киеп, бизәнеп-ясанып та чыкса, аңа, кызыкай, дип, теләсә нинди егет күз салачагына иманы камил. Узган ел, ире белән яшәгән чорда, Әнүзә ялгызы гына эштән кайтып бара иде. Тротуарда сөйләшеп торучы салмышрак өч егет яныннан үтеп китте. Һәм шунда ук артта тавыш ишетелде:

— Их, егетләр, моны кайсы бәхетлесе коча икән?

Әнүзә кисәк артына борылды:

— Сезнең шикелле үк бер охламон инде!

Егетләр телсез-өнсез калдылар.

Әйе, булды андый хәл. Ләкин ире белән алты ел җәфа чигү аның бәгырен катырган: әлегә ир затына әйләнеп тә карыйсы килми иде. Дөрес, хатын-кыз буларак, кемнедер иркәлисе-назлыйсы, кемнәндер сөеләсе килү — инде үзен сиздерә башлаган иде. Ләкин сүз чыгу, танышбелеш, дус-иш, туган-тумача алдында данын китү дә бар бит әле. Әнүзәне бу четерекле мәсьәләнең шул яклары да тыеп-йөгәнләп тора иде шикелле.

Менә бүген дә, кызы белән йөргәндә, ничәмә-ничә карашның үзенә сокланып яки ашардай булып текәлүләрен тоеп йөрде ул. Болардан аның кыйгач кара кашлары тартышып куйгандай була, алсу бит алмалары тагы да кызара төшә, калынча иреннәре ирексездән ачылып, ап-ак тешләрен елмайтып күрсәтә, тулышып торган «алмалары» күкрәкчә бавын өзәрдәй булып тыгызлана, кара чәч төпләре кызып, уч төпләренә хәтле дымлана. Әмма гелән генә шулай рәхәт булмый. Кайчагында ул чирканып та китә: гүя аны тәненең һәр күзәнәгенә керердәй булып чишендереп карыйлар, гәүдәсенең иң яшерен җирләренә кагылалар...

...Өйләренә җитәргә бер квартал кала Әнүзә туктады. Каршыга кулына кәрҗин тоткан күрше апа килә иде.

— Исәнме, наныем,— дип, апа башта Илюзияне аркасыннан сөйде, кәрҗиненнән уч тутырып җиләк алды.— Мәле, наныем, ашап җиффәр әле.

— Рәхмәт.

— Тәлгыя апа, бу җиләкләр юылмагандыр бит? — дип, шиген белдерде Әнүзә.

— Курыкма, чип-чиста,— диде күрше хатын.— Бакчада төне буе яңгыр яуды.

— Сатаргамы?

— Әйе. Астануфкага. Иш янына куш булыр дип чыгу инде. Пенсионерны беләсең. Җиләге дә күп. Әрәм иткәнче. Вәринҗә кайнатырга да җитә. Өләштем дә. Әле тагы өч-дүрт чиләк булыр. Сиңа да калдырдым. Кич кертермен.

— Рәхмәт, Тәлгыя апа.

— Анысын ашагач әйтерсең. Ярый, киттем әле.

— Сәүдәләрең уң булсын.

— Амин, шулай булсын.

Әнүзә кызын кулына алып, бер-ике адым атларга да өлгермәде, арттан янә Тәлгыя апаның ягымлы тавышы ишетелде.

— Әнүзә, наныем, туктале.— Ул җәһәт кенә кире килде.— Онытып китеп барам икән. Анда сине бер кеше көтеп тора.

— Кайда?

— Ишек төбендә.

Илюзия кычкырып җибәрде:

— Әти!

Тәлгыя апага уңайсыз булып китте.

— Юк, наныем, юк. Бер генә күрсәм дә, мин әтиеңне таныйм. Чит кеше ул.

Әнүзә аптырап:

— Мине кем көтсен?—диде.

— Сине инде, сине. Үзем сорадым.

— Ниндирәк адәм соң ул?

— Күз күргән нәрсәм түгел. Озын гына буйлы, аксыл чырайлы, кара киемле. Кемең ул? Әллә...

— Белмим,— диде Әнүзә тиз генә.— Авылдан берәрсе килсә генә инде.

— Ай-һай,— диде күрше апа күз кысып һәм, ялт борылып, тукталышка юнәлде.

Әнүзә әллә нишләп китте: зиһене таралды, тәне эсселәнде, хәтта сулыш алуы тукталды сыман. Кем булыр икән ул? Ире түгел. Әллә... Мөгаен шулдыр. Кара киемле... Озын буйлы... Ничек?.. Ул бит... Әнүзәнең аяк атлавы авырлашты. Бөтен тәненә тир бәреп чыкты.

Менә таныш тыкрык, биш катлы йорт, балалар бакчасы, аның артында—Әнүзәләр яши торган өй. Биек-биек тупыллар арасына күмелеп утыра ул бина. Ике катлы. Анда бүлмәләр бик күп. Шуларның берсендә, икенче катта, кызы белән Әнүзә яши. Төрле кеше бар бу йортта. Әмма әлегә хәтле Әнүзә беркем белән дә телгә килмәде; күрше-күлән белән тату гына яши. Транспортка да ерак түгел, кибете-фәләне, мунчасы, дигәндәй.... Бөтен уңайлыклары булган элекке фатиры түгел түгелен, әмма... һәрхәлдә, моңарчы Әнүзә бу тормышыннан канәгать иде. Аның яшәеш көймәсе тыныч кына, салмак кына агып бара иде.

— Кызым, бар, бакча ишегалдында уйна. Әнә Миләүшә дә, Наташа да шунда. Читкә китеп йөрмәгез, яме. Кызларны җиләк белән сыйларсың.

— Ярар,— диде кыз һәм койма ярыгыннан бакча ихатасына кереп тә китте.

Әнүзә отыры шөбһәләнә, гасабилана башлады. Өенә якынлашкан саен анда керәсе килмәү теләге артканнан арта барды. Әмма кызыксыну һәм... тагын нидер аны үзеннән-үзе өенә таба этәрә иде.

Әнә теге адәм йорт почмагында ук Әнүзәне көтеп тора! Ул! Таныды Әнүзә, ерактан ук таныды. Ләкин һич кенә дә йөгереп килеп аңа ташланырга, кечкенә чакта малайлар кыерсыткандагы кебек сыенырга теләмәде. Ул хәзер Әнүзә өчен бөтенләй икенче кешегә әйләнгән иде бугай. Хәтта кара киеме генә түгел, төс-кыяфәте дә күңелдә шом уята: кыска чәч, кырыс аксыл чырай, каш астыннан караучы усал күзләр. Әнүзәне күргәч тә, аларга якты нур иңмәде.

Әнүзәнең йөрәге жу! итеп китте: «Качкандыр, мөгаен?! И-и ходаем, тагын әти-әнигә хәсрәт...»
Килеп житәр-житмәс соравын бирде:
— Качтыңмы?
— Юк. Чыгардылар.
— Бөтенләйгәме?
— Ты че... Әле тагын дүрт ел.
— Ә ник чыгардылар?
— Өйгә кайтып килергә.
— Шушы кыяфәтең беләнме?
— Берәр кием табарсың.
— Каян алыйм?
— Иреңнеке...
Ире турында сүз чыккач, Әнүзәнең тагын кәефе кырылды. Шушының аркасында күпме сүз ишетте Әнүзә. Ире ачуланышкан саен колак итен ашый иде: «Юньле булса, абыең төрмәдә утырмас иде. Нәселегез...» Ире бер генә мәртәбә дә аның янына бармады, Әнүзәне дә җибәрмәде. Дөрес, баштагы елларда иренә сиздермичә генә Әнүзә бер-ике тапкыр передача илтте. Аннан үзенең дә күңеле кайтты. Чөнки шушының аркасында әнисе чиргә сабышты, әтисе кеше күзенә күренергә кыенсана башлады. Әлмәттәге энесен ике мәртәбә тотып кыйнадылар. Бу этлекне абыйсының әшнәләре эшләгән, диделәр. Кара эт бәласе — ак эткә. Өй-йортка күпме җәбер-җәфа китерде бу бәндә. Төрмәдә нәрсәгәдер кысылып кулы өзелгәч тә, Әнүзә аны жәлләмәде. «Шул кирәк аңа. Ходай каргагандыр. Әнинең күз яшьләре төшкәндер...»
— Кабатлап сорыйм: җибәрделәрме, качтыңмы?
— Әллә ышанмыйсың? Кәгазьне күрсәтимме?
— Кирәкми. Әйдә, өйгә.
Әнүзә үзе алдан китте. Як-ягына каранды. Очрамыймы соң?! Бу йортта кешегә күренмичә керү дә, чыгу да мөмкин түгел. Төнлә бәдрәфкә барганда да кем беләндер очрашасың. Анысы ярап куя тагын. Кара төндә хатын-кызга берүзең урамга чыгып йөрү... Кайчагында, бик караңгы төннәрдә, өйдә генә йомышыңны үтәгән чаклар да була. Анысы — сирәк. Чөнки өй тирәсендә кеше өзелми, гел йөреп тора. Әйе,чит күзләрдән яшереп берни дә кыла алмыйсың монда. Ә бүген, ни гаҗәп, берәү дә очрамады. Әнүзә сумкасыннан тиз генә ачкыч алып, җәлт кенә бүлмә ишеген ачты, башта ир-атны алдан уздырды.
— Кер!
— Нигә ашыгасың? Әллә барасы...
— Юк,— диде Әнүзә һәм тынычлана төшеп әйтте:— Диванга утыр, телевизор кара. Мин хәзер чәй куям.
Әнүзә телевизорны кабызды да коридорга чыкты, өстәлдәге өч камфоркалы газ плитәсен кабызып җибәрде, чәйнек белән су һәм таба куйды. Бераздан бүлмәсенә керде.
Кунак стенадагы карточкаларны карап маташа икән.
— Бөтен туганнар бар. Ә мин кайда?
— Син — юк.
— Ничек? Менә бит мин бар.
— Юк, и все. Мин сиңа отчет бирергә тиешме әллә? Үз өем... Телевизорда нәрсә күрсәтәләр?
— Мультфильм буласы.
— Ач бүтән программаны.
— Кеше әйберенә рөхсәтсез кагылырга куркам.
— Кайчаннан бирле?
Әнүзә телевизорның икенче бер төймәсенә басты да, урындык куеп, шкаф өстендәге чемоданны сөйри башлады.
— Булышыйммы?
— Кирәкми. Үзем.

Әнүзә чемоданнан зәңгәр төстәге спорт костюмы алып, диванга ташлады.

— Ирең калдырдымыни?

— Калдырыр, көт. Туган көненә дип алып куйган идем, аерылышкач, бирмәдем.

— Хәзер килгән-киткәнгә кигертәсеңме?

— Беренче алуым,— диде Әнүзә чемоданны ябып, шкаф өстенә куйганда һәм, кинәт, сүзләрнең мәгънәсенә төшенеп, нәфрәт белән карады.— Син нәрсә дидең?

— Шаярттым гына.

Әнүзә дәшмәде. Ул тагын коридорга чыгып, байтак вакыт плитә тирәсендә кайнашты. Ә кергәндә зәңгәр спорт костюмы кунак өстендә иде инде. Өстәл әзер булды.

— Кил, утыр...

— Кулны юасы иде.

— Умывальник ишек артында. Сөлге дә шунда.

Берүзе калгач, Әнүзәнең күңеле тулып китте. Утырырга дәшкәндә тагын бер сүзне чак кына әйтеп җибәрмәде бит. Әйе, бик аздан тыелып калды. Теләсәң теләмәсәң дә, ул сүз әйтеләчәк, әйтелергә тиеш. Тиеш. Тиеш бит. Ул бит минем... Аһ алла, нишләтә бу язмыш кешеләрне?! Кем гаепле соң моңа? Үзе түгелмени?!

Ишек ачылды.

— Әйдә, утыр,— дип Әнүзә аны түргә утыртты, үзе — ишек катынарак.— Житеш.

— Тамак чылатырга юкмы?

— Юк.

Кунак үпкә-фәлән белдереп тормады, йотлыгып ашарга кереште: әле ипи каба, әле чәнечкегә үрелә, әле чынаяктан чәй чөмерә, бармакларына хәтле татуировка белән капланган кулы гел хәрәкәттә. Башта Әнүзә: «Әбәү, ходаем, өч көн ашамаган кешедәй...— дип уйлап куйды да, кинәт әллә нишләп китте, гүя ниндидер үткен әйбер йөрәген телеп үтте.— Аның бит кулы бер генә!» Йөзен җыерчык баскан, вакытсыз картайган абыйсын кызгану хисе бөтен барлыгын биләп алды һәм ул шкафтан шешә чыгарды. Шешәне үзе ачты, сервантттан алган рюмканы кунакка табарак этәрде.

— Мә, үзең салып эч.

— Ә син?

— Мин эчмим.

Кунак кыстатып тормады. Ашавы акрыная төште, ниһаять, теле ачылды:

— Мин иртәгә авылга кайтам. Билет кесәдә.

— Сезне еракка да җибәрәләрмени?

— Әйе. Хәзер шулай. Өйдәгеләр ни хәлдә икән?

— Әйбәт. Узган атнада гына хатлары килде.

— Авырмыйлармы?

— Юк.

Кунак ашый тора, сала тора, сөйләшергә дә онытмый.

— Үзең?

— Нормально. Күрәсең.

— Ирең киләме соң?

— Юк.

— Кызы бар бит.

— Булса соң.

— Ә...— кунак нидер әйтмәкче иде, вакытында тыелып калды һәм сүзне икенчегә борды.— ...Кызың, дим, күренми.

— Урамда.

— Син авылга кайтмыйсыңмы?

— Юк. Әтиләр янында узган атнада гына булып килдем.

Шешә яртылаш бушады. Кунак ашап туйды. Өстәл янынннан кузгалды. Әнүзә янә телевизор кабызды, табын җыештырганчы урамга чыгып китте. Бераздан кызы белән әйләнеп керде.

Илюзия кычкырып сәлам бирде.

— Исәнмесез.

— Ә, бәләкәй кыз, исәнме?

— Мин бәләкәй түгел, ә дәү кыз. Миңа бабам шулай әйтә.

Әнүзә кызын тиз генә өстәл янына утыртты, ашарына куйды, сөйләшмәскә кушты. Ә үзе уйга талды. «Бабаң безгә дә шулай әйтә иде. Менә бу ят абыйга да. Иң яратканы да ул булмады микән әле. Бабаңның кул арасына без түгел, малай чактан ук ул керә башлаган бит. Сабан туе көрәшләренә алты-җиде яшьтән мәйданга чыга бу ят абый. Унны бетергәч, шәһәргә китүенә дә каршы килмәгән иде бабаң. Әнә шунда училищеда укыганда бозылды да инде бу дәү абыең. Менә шул чордан бирле ул бөтен гаиләнең кара кайгысына әйләнде. Кеше күзенә карарлыгыбызны калдырмады. Атаң ызгышкан саен искә төшерә иде: «Абыең — төрмәдә!» Аһ, кызым, ул чакларның авырлыгын син аңлап-төшенеп бетерми идең шул. Авырның да авыры иде ул сүз минем өчен. Кайчагында уйлап куя идем: ичмаса яңак төбемә китереп орсын иде, фәкать шул сүзне генә әйтмәсен иде. Мин аны үзем теләп алганмыни? Шундый абыем булуга мин гаеплемени? Ә кем? Үземе? Бәлки, иптәшләредер? Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, диләр бит. Яки яшәү шартлары, яшәү рәвеше моңа сәбәптер? Шулай да булсын, ди. Ә икенче тапкыр... Димәк... Юк, үзе, монысында бары үзе генә гаепле. Акылга утырырга бик вакыт иде, кирәк иде. Ата-ана хакына, безнең хакка... әгәр инде үзе турында уйламаса. Юк. Менә хәзер утыра каршымда. Сирәк-мирәк ютәлли, ябык, гарип... Кем ул минем өчен? Ни яхшылыгы тиде аның миңа туган буларак? Менә хәзер завод юньләп эшләми, хезмәт хакы аз, аны да үз вакытында бирмиләр. Сине йөрткән өчен бакчага күпме түләргә кирәк... Әгәр бу кеше — абыйсы — иректәге юньле бәндә булса, шушы мөшкел заманда — үз сеңлесенә ярдәм кулын сузмас идеме?! Адәм рәтле кеше булса... Ә атаң юри акчасы аз төшә торган, буш вакыты күбрәк кала торган эшләрне сайлый. Ә буш вакытларында шабашкада... Абый авыр чакта киңәшкә барырлык кеше бит ул югыйсә. Ә әти-әнигә китергән җәбер-җәфаны, мәсхәрәне нинди мыскалларга салып үлчәргә мөмкин? Юк андый мыскал. Ул хәсрәтне күтәрә торган үлчәү юк. Их, абый...»

Әнүзә кисәк, үзенә текәлгән карашны тоеп, тетрәнеп китте. Юк, бу өлкән абыйсының сеңлесенә яратып, үз итеп, якын туган итеп каравы түгел иде. Бу — урамда узган-барганның чибәр хатынга ашардай булып, ир-ат теле белән әйткәндә, аны чишендереп каравы иде. Әнүзәнең бая урамдагы шикелле тәне чымырдап китте... Ләкин бу юлы хисләре бөтенләй башка иде. «Әбәү, — дип куйды хатын җирәнеп, — мин аңа бөтенләй ят икәнмен бит. Ул гына миңа ят кеше дисәм...»

Әнүзә — ир-ат карашын беренче мәртәбә үзендә тоеп, аяк атлавын саташтырып, башын аска ия торган унөч яшьлек үсмер түгел — бу юлы үзен тиз кулга алды: бернинди хәрәкәт ясамады, кием-салымын төзәтмәде, хәтта аның битенә кызыллык та йөгермәде; бөтен барлыгын бары җирәнү, нәфрәт биләп алды.

Кунак тагын бер рюмка салып эчте. Яңадан диванга барып утырды. Үзе телевизор карый, ләкин сирәк-мирәк өстәл ягына да күз ташлый.

— Кызым, тагын ни бирим? — дип сорады Әнүзә, ямьсез уйларын куып җибәрү өчен. — Чәй эчәсеңме?

— Юк. Алма бир. Урамга чыгам.

— Кызым, соң инде. Миләүшәләр дә кереп киттеләр. Өйдә генә утыр.

— Чыксын, — диде кунак гамьсез генә.

Шулвакыт ишек шакыдылар һәм җавап та көтеп тормыйча Тәлгыя апа килеп керде.

— Кунак бар икән. Исәнмесез.

— Саумысез.

— Ә-ә, танымый да торам, баягы егет икән лабаса... Мә, Әнүзә, җиләк керттем.

— И Тәлгыя апа, кызга биргәч җиткән иде.

— Юк, юк, наныем, тартынма, ал.

— Чәйгә утыр, Тәлгыя апа.

— Рәхмәт.

— Юлың уңдымы соң?

— Уңды. Аллага шөкер. Кулга да тимәде. Бигрәк әйбәт бит җиләге. Ниме, бу егет кемең була? Туганыңмы?

— Юк, Тәлгыя апа. Авылдаш кына... Читтән кайтып килеше... Иртәгә авылга китә.

— Ә-ә, ярый, ярый, авылга кайтып хәл белү ярый. Менә үзем бик кайтыр ием, якын туганнар бетте. Ә чыбык очы — тал очына кайтасы килми. Әллә көтеп торалар, әллә юк, кешенең якты йөзен караңгылатып. Хәзер заманасы да мәзәкләнеп китте...

Тәлгыя апа, берөзлексез сөйләнә-сөйләнә, ишеккә юнәлде. Әнүзә аны озата чыкты. Ул яңадан әйләнеп кергәндә кунак тагын бер рюмка бушатып куйган иде. Әнүзә аны, Тәлгыя апага әйткән «авылдаш кына» дигән сүзне ишеткәч, әллә яшь чагындагы кызу канлылыгы белән чәчрәп чыгармы, дип уйлаган иде. Ялгышкан икән. Кунак дәшмәде. Эченә йотты. Күрәсең, ни уйлаганының барысын да әйтеп бетермәскә, уйхисләрен тышка чыгармаска өйрәнгән. Дөресрәге, дөнья өйрәткән, ахрысы.

Телевизор карадылар. Илюзия әнисе белән дә, коридорга чыгып күршедәге бала-чага белән дә мәш килде. Кич җитте.

— Мин чыгып керим әле,— диде кунак.

— Үзең күрерсең, урамда — сул якта.

Әнүзә диванны төшерде, урын җәйде. Берникадәр вакыттан кунак әйләнеп керде.

— Әнә урын, ятарсың. Иртүк торасы бит.

— Әйе. Авырайдым да. Үзегез кая ятасыз? Идәнгәмени?

— Юк. Без күршеләргә керәбез.

Кунак аптырап китте.

— Ничек? Монда сез ятыгыз, ә мин — идәнгә. Не привыкать.

— Юк,— диде Әнүзә кискен генә һәм кызына дәште.— Әйдә, кызым. Кунакка хуш, хуш әйт.

Әнүзә ике бүлмә аша гына яшәүче Тәлгыя апага кереп кунды. Иртүк торып кунакны уятты, чәй хәстәрләде. Аны коридорга озата чыккач, кулына сумка тоттырды.

— Мә, моны әниләргә бирерсең. Бераз күчтәнәч. Сәлам әйтерсең.

— Ярый, әйтермен.

— Хуш, исән бул.

Кунак баскычтан төшеп китте. Әнүзә бүлмәсенә керде. Тәрәзә каршына басты. Менә ишек шапылдаганы ишетелде: кунак урам якка чыкты, ахры. Әйе, әнә китеп бара. Бер кулында Әнүзә биргән сумка, икенчесе — саргылтрагы салынып төшкән, селкенми диярлек. Өстендә Әнүзә кичә кидерткән зәңгәр төстәге спорт костюмы, аягында аксыл кроссовка. Өстән караганда башының пеләше дә беленә икән. Аркасы да бөкрерәк сыман күренде. Әйе, нужаны нык татыган җилкәләр баскандыр... Кулын да өздерде. Юкса, бик җәллисе, күңел җылың биреп юатасы, якыны итеп кызганасы, абый, әле син бик олы яшьтә түгел, исән-сау котылып чыксаң, гаилә корып җибәрерсең. Кызлар карамаса, берәр тол хатынга керсәң дә ярый, дияси килә. Әнүзә үзе үк табышыр иде. Ә юк бит, әйтергә тел әйләнми, сөйләшергә сүз юк. Авылда, әти-әниләре

янына кайткач, агай-эне арасында, көндәлек мәшәкать белән сизелмәгән ялгызлык кинәт Әнүзәне буып алгандай итте. Бугазына төер тыгылды. Ире белән торганда да ялгыз иде бит ул. Ире башта көнләшеп нахакка рәнҗетте, аннары үзе ачыктан-ачык йөри башлады һәм шулай ничә ел мыскыл итеп яшәде... Уртак нәрсә — бала гына булган. Һаман ялгыз, ялгыз... «Их абый, абый, бәләкәй чакта ничек ярата идем бит мин сине!.. Җилкәңә мендереп, муеныңа атландырып та уйный идең, кулымнан күтәреп әйләндерә идең, чана шуганда күрсәң, тартып йөгерә идең... Их, азмыни андый гамьсез, бәхетле мизгелләр безнең хәтердә! Нишләп синең күңелеңдә безгә, миңа карата бер җылы хис тә калмады. Төрмәнең шыксыз тормышы бөтен кешелегеңне изеп-сытып бетерде мени? Андагы тормыш сиңа шулкадәр якынмыни соң? Беренче тапкыр котылып чыккач, салган баштан, и төрмәм, дип елагансың бит. Бөтен яшьлегеңне шунда үткәреп, хайван хәленә калдыңмыни?! Үз сеңлеңә азгын күз белән карап утыргач...»

Абыйсы һаман ерагая, ерагая... Әнә балалар бакчасы турына җитте, биш катлы йортны да узды һәм борылышта... югалды. Тагын югалды. Бөтенләйгәме? Кайтырмы ул безнең арага?

Төнлә яуган яңгырдан җир өсте генә түгел, Әнүзә бүлмәсенең тәрәзәләре дә парланып-суланып тора. Юк, бу тәрәзә түгел, Әнүзәнең күзләрен әкрен-әкрен дым каплый икән...

Әнүзә диван янына килеп тезләнде дә, әле абыйсының җылысы да суынып бетмәгән мендәргә капланып, тыела алмыйча, үкси-үкси елый башлады. Үз-үзен белештермичә сөйләнә иде ул: «Абыем җаным, туганым минем... Без бит бер ата-ана балалары, бер карында үскән кешеләр... Абыем җаным, кайт безгә кире... Кайт... Безнең тормышка кайт син... Мин сиңа кабат беркайчан да, авылдаш кына, димәм. Сиңа яратып, үз итеп, якын туганым итеп, Абыем! диярмен... Абыем минем... Кайт кына... Безнең тормышка кайт кына... Абыем...»

*Гыйнвар, 1995.*



**Рәшит Шиһап**

## Килер дәвергә сүзем

Китерегез миңа тизрәк куып —
Якынлашкан яңа гасырны.
Минем аңа әйтер сүзләрем бар,
Сүзләрнең дә әле — асылы...
Ниләр сөйләр идең, дисезме сез,
Бик хикмәтле сүзләр әйтермен:
— Оныта күрмә сугыш кырларында
Ятып калганнарның хәтерен.
Синең күкрәгеңдә туасы көн —
Алар биргән тормыш чаткысы.
Көлеп атасы һәр алсу таңың
Кыска гомерләре яктысы.
Мәрхәмәтсез бул син явызларга,
Тыйнаксызларны һич зурлама,
Байларыңны теләсә ни эшләт,
Хәерчеләрне бик хурлама.
Синең чорда, бәлки, тирен сыккан
Гадел эшчән калмас чикмәнгә?!
Газраил бул — берни тудырмыйча,
Талау юлын кәсеп иткәнгә.
Әҗәле бул әрәмтамакларның,
Шәфкатьле бул дөнья көткәнгә,
Миһербанлы бул син намуслыга,
Хезмәт итеп хәсрәт сүткәнгә.
Айлы манарадан нурың алма,
Һәрвакытта зурла иманны,
Әдәп-әхлакларны юлдашың ит,
Гөнаһлардан чистарт җиһанны...
Милләтемә көч-куәтең җибәр,
Башын идерә күрмә халкымның,
Туган җирдән этлекләрне себер,
Канатларын чарла акылның.
Әйтер сүзем шушы, килер дәвер,
Өметләрне акла, сыгылма:

Безнең гасыр хаталарын сөртеп,
Аягыңда нык тор — егылма!

## Үпкәм юк

Тәкъдиремә язган юлларымны
Узалмадым диеп әйталмыйм.
Шунысы үкенечле: тик аларның
Матурына кире кайталмыйм.
Ни эшлисең, күкнең кануннары
Тәгәл үлчәүләргә салынган.
Җир үзе дә мәңге бишек түгел,—
Галәм кәфененә ябынган.
Ни булса да фани бу дөньяның
Шактый сукмаклары үтелгән.
Күпме хәсрәт йөген тартып йөргән,
Кайгы йомгаклары сүтелгән.
Шәхси файда, байлык табу өчен
Кумадым мин көннәр артыннан.
Кара төннәр килгән чакларда да,
Аерылмадым туган халкымнан.
Нинди һавалы сүз, димәгез сез,
Һаваланып һич тә йөрмәдем.
Эчтән генә тыйнакларны сөйдем,
Иманлыдан бераз көнләдем.
Гарип-горабага кулны бирдем,
Яшьне олы итеп сөйләштем,
Мыскал гына шатлык килгәндә дә,
Очраганга теләп өләштем.
Кыен чаклар сыгып алганда да,
Кайнар күз яшьләре түккән юк.
Гомерем буе бәхет читләп уза —
Барыбер тормышыма үпкәм юк.
...Бәхет елмаймый дип көрсенмәмен:
Туган җирем булды гел тәхет:
Шул тәхеттә хезмәт итеп яшәү —
Менә нәрсә икән чын бәхет!

## Вәхшилек

Кычкыра болан, кычкыра,
Елаулы тавышлары.
Елаулы тавышларында
Югалту сагышлары.
Югалтулы сагышында
Йөрәге кагышлары,
Өзгәләнеп каргавында
Ләгънәтнең агышлары.
Тарала әрнүле аваз
Урман киңлекләренә.
Бу сагыш, каргыш, ләгънәтләр
Үтә җелекләренә...
Алан түрендә баскан да —
Нарасые янына,

Туктатырга уйлап, сыйпый
Йөзен — аның канына:
Ялап ала, төзәлсен, дип,
Сылукае ярасын,—
Бәгыре таш булган берәү
Атып еккан баласын.
Болан баласы карашын
Каплаган соры томан.
Ул:— Нишлисез, кешеләр?! — дип,
Ачынып сорыйм сыман.
Аланда пәри туйлары —
Давыл сорап җил исә...
Болан — гомер дип күрәшә,
Кеше... ник гомер кисә?!

## Хыянәт

Һәрбер кичтә юл чатына чыгып
Бер эт елый,
Елый тоташтан.
Нинди хәвеф, нинди кайгыларга
Шушы елау барып тоташкан?
Авылга ул нинди хәсрәтләрнең
Киләчәген алдан кисәтә?
Кара төннәр алып килә торган
Шомлы уйны гына көчәйтә.
Юксынулар тулы зарлы елау
Җәелеп ята кырлар өстенә,
Һаваларны иңләп тарала да,
Болытларга барып сөртенә.
Кире тауга төшә һәм кемнедер
Яше белән үзенә чакыра,
Аннан, көчсезләнеп, ялгыз гына
Тагын кайта юллар чатына.
Елау-чинау... Чинау-елау, елау...
Кабатлана шулай күп тапкыр...
Их!
Һәрвакытта көткәннәргә читен,
Китүчегә генә юл такыр...
Юк,
Берсенә дә михнәт юрамый ул,
Авыл урамнарын каргамый.
Ташлап калдырганнар чын бирелгән
Җан йөрәген генә аңламый.
Дулкын-дулкын булып елау ага
Пычрак көзнең тымызык таңына.
Эт һаман да
Тугрылыкка — хыянәте белән
Җавап биргән дустын сагына.



# Хәбир Ибраһим

* * *

Әүвәл миннән шалаш сорадың.
Хәзергесе инде — дүрт бүлмәле,
Дүрт ягына ачык дүрт ишек.—
Хәтта дөнья үзе кермәле!

Мөмкинлекләр безнең чикләнгән ник?
Миннән уңыш көттең.
Байлыкка,
Теләсәм дә, сине күмәлмәдем,
Күмдем бары кайгы, сагышка...

Нигъмәт тулы затлы өебездә
Тынчу никтер. Чүпрәк калдыгына
Әйләндемме соң мин?!
Күңел әнә
Яшьлек хыялларын сагына...

* * *

Син кайчандыр шундый якын идең,
Хәзер сиңа якын әйберләр —
Затлы келәм, бәллүр, кеш якалар,
Асылташлар, алтын әйберләр...

Табыйк, дисең!
Шундый кайгың төшкән.
Кырау төшкән — безнең бакчага.
Яшьлек хыялларын сүтеп аттык,
Җаныбызны саттык акчага.

Мине дә бер, вакыт җитү белән,
Өзеп атарсың күк бәгырьдән.
Ишек ачып, көчкә сулыш алам:
Гүя
Җан кысыла салкын әйбердән.

## Бер теләк

Теләмәс идем
Үлгәч тә
Җанның кабат терелүен.
Гүзәл җәннәт бакчасының
Җимешенә үрелүен.

Үлем алып китү белән,
Арындырсын газаплардан.
Азат кылсын рәхәтлектән,
Яңа бәла-казалардан.

Мин телимен
Мәңгегә бер
Уй йөгеннән арынырга.
Батыр, матур әкиятнең
Дәвамына ышанырга.

Көферана сөйлим бугай!
Ходай белсә, мине каргар.
Үзен алдый белгән генә
Киләчәккә өмет баглар...

* *
*

Яшәгәндә кадер-хөрмәт
Күрүчеләр бик сирәк.
Тиеш бәя алыр өчен
«Үлеп карарга» кирәк.

Туракланган башлар аша
Чажлый Иблис кайчысы...
Бу мизгелдә даһи туды —
Ничәнчесе?!
Кайсысы?!



Шәрәф Әхмәдулла

# ТАРИХИ ДӨРЕСЛЕКНЕ КАЙТАРЫЙК!

Татарлар — бик күп төрле ыруг-кабиләләр катнашында барлыкка килгән милләт. Алар арасында болгар, кыпчак компоненты бар, хазар, угро-фин компоненты да яши, шулай ук татар, монгол компоненты да көчле.

Милләтнең күп өлешләрдән формалашуы — бер татарларга гына хас күренеш түгел. Бүгенге рус милләте дә бер кабиләдән генә барлыкка килмәгән. Ул элеккеге «полян», «вятичи», «кривичи», «словен»... кебек кабиләләрне үз эченә ала. Хәтта «татар-кыпчак»лар да тора-бара рус халкын «төзүдә» актив катнашкан. Бүгенге көндә русларның шәҗәрәсен тикшерә башласаң, адым саен татарларга килеп төртеләсең, дип юкка гына әйтмиләр бит. Бу җәһәттән караганда татарлар белән русларның милләт булып формалашуында охшашлык та күренеп тора. Ләкин милләткә исем бирүдә аларның һәркайсы үз юлы белән киткән. Руслар, мәсәлән, бу очракта конкрет бер компонентны — әйтик «кривичи», яки «вятичи» компонентын нигез итеп алмаган, аларга алмашка бөтенләй башка исем — «рус» исемен кабул иткән. Ә менә безнең халык бер компонент исемен — «татар» сүзен — милләтне формалаштыруда катнашкан барлык кабиләләр өчен уртак исемгә әйләндергән. Бу исем — «татар» исеме — безнең халыкны нәсел башына кайтара, Алтын Урда дәүләте нигезенә тоташтыра.

Дөрес, зыялылар арасында бу фикергә каршы чыгучылар да юк түгел. Аларча уйлаганда, безнең халыкка «татар» исеме, янәсе, көчләп тагылган, милләтнең формалашуында татарларның катнашы юк, Алтын Урда дәүләте безнең уртак нигез түгел. Бабаларыбыз, янәсе, тикмәгә генә «татар» исемен йөртүдән читенсенмәгәннәр, тикмәгә генә үзләрен — без «татар» түгел, без — «болгар», яки без — төркиләр, яки без — мөселманнар, ... дип йөрергә тырышмаганнар. Алар, янәсе, шул рәвешчә үзләренең татарлар белән уртаклыклары булмауны раслаганнар.

Дөрес фикерме бу? Тикшерәбез: альйк татарларның үз исемнәреннән читенсенү, читләшү мәсьәләсен. Әйе, читенсенү, читләшү булган һәм ул хәзер дә яши. Моның сәбәбе нидә соң?

Мәгълүм ки, татарлар рус илендә, алар аша Аурупа илләрендә дә үтерүче, кан эчүче, вәхши итеп күз алдына китерелә. Чиркәү әһелләре, башбаштак патша түрәләре татарлардан дошман образы тудырдылар. Татар куркыныч, дәһшәт, үлем символына әйләндерелде. Өстәвенә әлеге хурлаулар тора-бара рус патшалары тарафыннан татарларга каршы юнәлтелгән теләсә нинди җәбер-золым һәм сугыш өчен акланырга сәбәп итеп файдаланыла башлый. Мәсәлән, «Казан, Әстерхан, Себер ханлыкларында яшәүче татарлар рус дәүләтенә куркыныч тудыралар» дигән сылтау белән әлеге ханлыклар Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан басып алына. Ләкин татарлар өстенә гаеп ташлау моннан соң да бетми, дәвам итә. Җәбер-золымнан тәмам аптыраган татарлар эзәрлекләүләрдән котылу нияте белән «без — татар түгел», «без — төркиләр», «без — мөселманнар», «без — болгар», дип йөри башлыйлар. Нишләмәк кирәк, башка чара юк! Уңнан да, сулдан да, арттан да, алдан да кычкырып торсыннар әле: татар — үтерүче, татар — вәхши! Мондый хурлауларны, җәберләрне баштан кичергәнче, җиде кат җир астына керерсең! Һәм бу аңлашыла да. Әле безнең көннәрдә генә бер гыйбрәтле факт теркәлде: «Вечерняя Казань» газетасы (26.09.88) хәбәр иткәнчә, ирле-хатынлы немец коммунистлары безнең илдә эшләгәндә кулга алыналар.

Бердәнбер уллары — Клаус Вилде балалар йортында үсә. Көннәрдән бер көн бу үсмер үзенең немец булуын белеп ала. Аның фикеренчә «немец» сүзе «фашист» төшенчәсенә бәйле саналганлыктан, малай нишләргә белми. «Минем немец буласым килми»,— дип кан-яшь түгә.

Татарларга да элек заманда Клаус Вилде башына төшкән газапларны гына кичерергә туры килми. Алар туган җир-судан куылалар, диннәрен алыштырырга, «татар» исемен кулланмаска мәҗбүр ителәләр. Мондый хәл бер көчәеп, бер йомшарып Октябрь революциясенә кадәр дәвам итә. Хәер, бүгенге көндә дә татарларны үз исемнәреннән — «татар» исеменнән — биздерергә теләүче борынгыдан килгән сәбәпләр кайтавазы өзлексез ишетелеп тора. Дәлил итеп, академик М. Зәкиев сүзләрен китерергә мөмкин: «Хәзерге чорда,— дип яза галим,— милләтләрнең аралашулары татарларга «татар» этнонимы йөртүнең күп читенлекләрен ача башлады» («Соц. Татарстан», 19.08.88).

Менә шуның өчен татарлар «татар» исемен йөртүдән читенсенгәннәр. Һич кенә дә яратмаудан түгел, хуп күрмәүдән түгел. Изелүдән куркып, җәбер-золымнан куркып читенсенгәннәр алар.

Инде килеп «татар» исеме көчләп «тагылган» дигән сүзгә тукталыйк. Беренче сорау: «татар» этнонимы руслар арасында кулланышка кайчан кергән? Мәгълүм булганча, 1223 елда Чыңгыз хан яулары кыпчаклар белән берләшеп, Калька елгасы буенда Киев князьләренең гаскәрләрен тар-мар итәләр. Шушы вакыйгага уңаеннан Н. М. Карамзин үзенең «Предания веков» исемле хезмәтендә болай яза: «Россиялеләр, котлары очып, бер-берләреннән «кемнәр соң бу килгән кешеләр», дип сорашалар. Берәүләре, таурманнәр, икенчеләре, печенеглар, ди. Ә күбесе, юк, алар — татарлар, ди» (Н. М. Карамзин. Предания веков. М., из-во «Правда», 1989 г., стр. 259). Шушы вакыйгадан башлап руслар арасына «татар» сүзе килеп керә. Хәер, сүзе генә түгел, татарлар үзләре дә. Димәк, «татар» исеме кайбер татар авторлары раслаганча, XVIII—XIX гасырлар дәвамында түгел, бәлки XIII гасырда ук кулланылышка керә. Чөнки Чыңгыз хан гаскәрләренең төп массасын «Төньяк Кытай Татарстаны» дип аталган каганаттагы татар исемле кабилә кешеләре һәм аларга бәйле монголлар тәшкил итә.

Калька елгасы янындагы сугыштан соң тарих ничек дәвам итә соң? 1227 елда Чыңгыз хан үлә. Аның варисы Октай үзенең оныгы Батыйга өч йөз меңле гаскәр калдырып, Төньяк Кытай Татарстанына кайтып китә. Батый житәкчелегендәге татар-монголларның бер өлеше хәрби походларны тәмамлагач, рус җирләреннән чыгып китә, көньяк кыпчак даласында — үзләренең тугандашлары булган кыпчаклар җирләрендә — төпләнеп кала, 1243 елда Алтын Урда дәүләтен төзи.

Шушы дәүләт шартларында бергә яшәү һәм бергә эш итү барышында кыпчак, болгар, татар, монгол, хазар, угро-фин компонентларын үз эченә алган бер төрки халык барлыкка килә. Һәм «татар» исеме бу гомумилекнең уртак атамасы булып әверелә. Ни өчен «татар» исеме соң? Сәбәп шул: ул заманда татарлар җиңүләрдән җиңүләргә баручы каһарман халык, батыр халык булып дөнья күләмендә таныла. «Татар» исеме һәр тарафта киң яңгыраш, зур дәрәҗә ала. Аны ишетү белән мактанчыклар тынып кала, тәкәбберләр баш иярга мәҗбүр була, көчсезләргә көч керә, кыюсызларга — тәвәккәллек, куркакларга — батырлык рухы иңә. Шушы хәл «татар» исемен Алтын Урдадагы төрки телле халыкка да үз иттерә, якын иттерә. Көчләп тагылмый. Ул — тарихи үсеш барышында үзеннән-үзе гамәлгә кергән, халык тарафыннан ирекле рәвештә кабул ителгән исем.

Кыскасы: милләтнең формалашу процессында татарларның катнашы юк дип, үзебезне ул компоненттан аерып маташу дөрес түгел. Татарлар да, кыпчаклар да, болгарлар да... халкыбызны төзүдә катнашкан компонентлар. Алтын Урда дәүләте — аның уртак нигезе.

Бу фикерләрне раслап торучы фактлар аз түгел. Алыйк татар халык моңнарын. Аларда сизелеп торган монгол, кытай аһәңнәреннән кергән моң-бизәкләрне, охшашлыкны кем инкарь итәр икән? Каян килгән аларга мондый охшашлык? Бу — борынгы татар-монголларның кыпчак даласына килеп, татар милләтен формалаштыруда катнашу нәтиҗәсе түгелме соң?

Икенче факт: галимебез С. Исхакова раславынча, бүгенге көндә Себер татарлары сөйләмендә борынгыдан мондый сүзләр сакланып калган — цац (чәч), цай (чәй), цал (чал), цана (чана)... Шул ук сүзләр, шул ук мәгънәдә монгол телендә дә кулланышта йөри икән. Каян килгән бу уртаклык? Безнеңчә шуннан: Себер татарлары — Кучум ханлыгы төркиләре, ә Кучум ханлыгы — Алтын Урда кыйпылчыгы. Димәк, әлеге уртаклык — ул бүгенге татарларның Батый нәселе белән

тугандаш булуын раслый. Тагын шунысы да игътибарга лаек: югарыда китерелгән сүзләр хәзерге мишәр сөйләмендә дә актив кулланышта йөри. Шулай итеп, бу җәһәттән караганда да, бүгенге татарларның узган чорларда формалашуында борынгы татар катнашы бәхәссез булып чыга.

Аннары «Идегәй» дастанында сурәтләнгән Идегәй белән Туктамыш без, татарларны, Алтын Урда дәүләте нигезенә тоташтырмыймыни?

Шуңа да карамастан, татар зыялыларының кайберләре үзләренең Төньяк Кытай Татарстаныннан килгән татарлар белән якын кардәшлекләрен танырга теләмиләр. Сәбәбе шул: кардәшлекне тану — ул татар-монголлар өстенә төшкән барлык хурлауларны, гаепләүләрне үз өстеңә алу дигән сүз. Ничек моңа риза буласың, ди? Ләкин менә ул татарларны бетереп хурларга нигез бармы соң? Чыннан да, китапларда язылганча, русларның татарлар тарафыннан изелүе, җәфа чигүе, кайгы, бөлгенлек кичерүе хакмы? Рус китапларының болай раславында Уйдырма, бозып күрсәтү, ялган юкмы? «Татаро-монгольское иго», чыннан да, булганмы? Әйдәгез, җавап эзләп төрле басмаларда булган мәгълүматларга игътибар итик. Барыннан да элек, немец җәмәгать эшлеклесе, Муса Җәлил язган «Моабит дәфтәре» шигырьләрен беренче булып немец теленә тәрҗемә иткән Франц Лешницер сүзләре игътибарга лаек. Үзенең «Моабит дәфтәре» безнең өчен дә язылган» исемле мәкаләсендә ул болай ди: «Ауропада татарларны вәхши, үтерүче, кан эчүче дип йөртү гадәткә кергән иде. Татар шагыйре Муса Җәлил үзенең шигырьләре һәм каһарманнарча үлеме белән әлеге шовинистик уйдырманың көлен күккә очырды». («Зоннтаг», 34 сан, 1964.)

Әйе, татар исеменә бәйле буяуларда «шовинистик уйдырма»ларның өлеше юк түгел, бар.

Менә рус галиме, тарихи романнар авторы Михаил Каратеев фикере: «Русские летописцы были далеко не беспристрастными судьями. Для них татарин был... поганы и для его описания существовала только одна краска: черная». (Михаил Каратеев. Русь и Орда. М., из-во «Современник», 1992 г., ст. 159).

Өченче мисал. «Князь Игорь» операсының икенче пәрдәсендә кыпчак даласы сурәтләнә. Кончак Игорьга: «Син — минем кунак, әсирем түгел. Син — ирекле. Китәсең килә икән, тотмыйм, теләсәң, хәзер үк»,— ди. Кончак Игорьның кәефен табу өчен күп кешесен эшкә җигә. Алар җырлыйлар, биниләр... Әгәр дә татарлар, әйтик, монахлар язып калдырган елъязмаларда сурәтләнгәнчә, вәхши, ерткыч... булсалар, ул сыйфатлар, шөбһәсез, Кончак образында да чагылыш тапкан булыр иде. Чөнки XIX гасыр рус реалистик сәнгате тормыш дөреслегенә хыянәт итмәде. Бу факт Кончак образында да ачык чагыла. Әнә бит ул ничек сурәтләнгән: ул — нинди кунакчыл, нинди игътибарлы! Шулай булгач, татарны бетереп хурларга нигез каламы соң?

Мәшһүр рус тарихчысы Н. М. Карамзин хезмәтләрендә дә татарлар турындагы уйдырмаларны фаш итә торган мисалларны күп очратырга мөмкин. Мәсәлән, шовинистик пропаганда болай бәян итә: «Татар басып алуы,— 240 елга сузылган татар изүе, Русьны Көнбатыш Ауропадан артта калуга китерде». (Кратка история СССР. Ленинград, 1978, 63 бит.)

Игътибар итик: биредә ике факт күрсәтелә — «татар игосы», аның нәтиҗәсе — Көнбатыш Ауропадан артта калу. Болай раслау тарихи дөреслеккә туры киләме соң? Тикшерәбез. Мәшһүр рус тарихчысы Н. М. Карамзин: «Ярославтан алып Батыйга кадәр узган чорда Россия канга батырылды, күз яшьләрендә коенды. Князьләрнең үзара сугышлары, кылыч һәм ут тормыш тәртибен, тынычлыкны өзлексез бозып торды. Нәтиҗәдә без XIII йөздә үк инде Көнбатыш дәүләтләреннән артта калган идек». (Н. М. Карамзин. Предания веков. М., из-во «Правда», 1989, 423.) Аңлашыла ки, Россиянең Ауропадан артта калуы татарларга кадәр үк барлыкка килгән һәм аның сәбәбе татарлар түгел, бәлки рус князьләренең үзара талашып, сугышып, кан коеп яшәве.

Рус китапларында һәм аларга ияреп язылган бүтән милләт әдәбиятларында татарлар Россия тормышына төрле әхлакый бозыклыклар, эчкечелек, сүгенү, шәфкатьсезлек, вәхшилек кертүдә гаепләнәләр. Мондый гаепләүләр дә тарихи дөреслеккә туры киләме? Тикшерәбез. Шул ук Н. М. Карамзин: «Хатын-кызларның иреген кысарга, кешеләр белән сату итәргә, судларда ришвәт алырга безнең бабаларыбызны татарлар өйрәтмәде. Мондый гадәтләр славяннарда, урысларда күптән — татарларга хәтле үк яшәп килде». Аннары тарихчы болай дип өсти: «Татар хакимлеге астыннан чыкканда, россиялеләрдә азиялеләр тәэсиренә караганда күбрәк ауропалылар йогынтысы сизелә иде. Алардагы төп сыйфатлар артта калган кыргый славян гадәтләренең немец гадәтләре белән кушылуыннан барлыкка килгән булып чыкты» (430 бит).

Рус китапларында һәм кайбер кинофильмнарда (мәсәлән, А. Тарковскийның «Рублев» фильмында) татарлар чиркәүләрне ватучы, җимерүче вәхшиләр итеп сурәтләнә. Бу тарихи дөреслеккә туры киләме? Тикшерәбез. Н. М. Карамзин: «Россиядә татар хакимлегенең уңай нәтиҗәләреннән берсе — дин әһелләренең хәле яхшыру, монахларның ишәюе, чиркәү җирләренең артуы булды. Ханнар сәясәте чиркәүне һәм аның хезмәтчеләрен яклауга юнәлтелгән иде. Ханнар аларга даими рәвештә толәрантлык күрсәтеп килде, митрополитлар, епископлар бигрәк тә зур хөрмәткә ия иде». «Ханнар,— ди Н. М. Карамзин, сүзен дәвам итеп,— монастырьларга кул тидергән өчен үз гражданнарын үлем җәзасына тартканнар, чиркәү биләмәләрен салымнардан бөтенләй азат иткәннәр» (430 бит).

Рус түрәләре һәм алар җырын җырлаучы шовинистик пропаганда татарларны Россия өстеннән «и г о» урнаштыруда гаепли. Татарларга мондый гаеп атуның тарихи дөреслеккә туры килмәве турында Л. Гумилев үз хезмәтләренең берсендә әйтеп киткән иде инде. Тарих галименең бу фикерен раслаучы дәлилләр Н. М. Карамзин хезмәтләрендә дә күпләп табыла. Укыйбыз: «Ханнар,— дип яза Н. М. Карамзин,— читтә, Алтын Урдада яшәгән килеш, эчке эшләребезгә тыкшынмыйча гына безнең өстән идарә итәргә омтылдылар. Акча сорадылар, буйсынып, сүз тыңлап яшәүне таләп иттеләр. Бары ние шул» (424 бит).

Нидән гыйбарәт була соң ул «буйсыну», «акча таләп итү»? Шуннан икән: Князьләр үз керемнәренең ун процентын хан казнасына кертергә тиеш була. «Тынычлык телисез икән, бар табышыгызның уннан бер өлеше — безнеке!» — диләр татар илчеләре. (267 бит).

Зур салыммы бу? Һич юк! Коммунистлар хакимлеге чорында Татарстан үз байлыгының 98 процентын Мәскәүгә җибәреп торды түгелме соң? Ә теге заманда әнә шул ун процентны хан казнасына керт тә, эшең бетте, вәссәлам!

Әйе, башка һични таләп ителми! Әйтик, хан гаскәрләрендә хезмәт итү соралмый, рус телен кысрыклап татар телендә генә сөйләшергә мәҗбүр итү юк, көчләп ислам диненә инандырмыйлар... Хәтта рус иленә хәвеф-хәтәр килгән очракларда әлеге ун процент салымны түләүдән дә князьлекләр бөтенләй азат ителгән. Мәсәлән, Үзбәк хан, Олуг Мөхәммәт хан шундый мәрхәмәт-шәфкать күрсәтә. Инде килеп хан-князь мөнәсәбәтләренә күз салсак, бу өлкәдә дә «и г о» дип атарлык бернинди нәрсә күренми. Киресенчә, князьләрнең тәхет өчен, хакимлек өчен, җир, мал-мөлкәт өчен барган талаш, ызгышларында ханнар арбитр вазифасын — килештерүче, татулаштыручы ролен үтиләр. Сүз белән, үгет-нәсихәт юлы белән. Гаделлек урнаштыру өчен ул гына җитмәгәндә, теге йә бу князьгә ярдәмгә сугышчан отрядлар җибәрелгән. Мәсәлән, Мәскәү князе Георгий белән Тверь князе Михаил арасындагы низагны чишүдә шушы юл сайланыла. Ә мондый мисаллар хан — князь мөнәсәбәтләрендә аз булмый. Гомумән, татар ханнары рус князьләренә карата мәрхәмәт-шәфкать күрсәтеп эш итәләр. Сугышта батырлык күрсәткән руслар татарларда аерата зур хөрмәт казанган. Андыйлар әсир төшкәндә тоткын ителмәгән, иреккә җибәрелгән.

Хан-князь мөнәсәбәтләрен тулыландыру йөзеннән Н. М. Карамзин хезмәтеннән тагын бер мисал китерик: «Татарлар,— дип яза ул,— сугыш кырында князь Василийны әсир итәләр. Хан аны хөрмәт белән каршы ала, аннары князьдән рәхмәт әйтүен һәм коткарган өчен бераз акча бирүен таләп итеп, аны әсирлектән азат итә. Василий, князь Михаил һәм боярлар белән бергә, Курмыштан Мәскәүгә юл ала. Аларны татар илчеләре башкалага хәтле озылап озата баралар» (405 б.).

Татар ханнарында үч алу гадәте дә булмаган, ә бит югыйсә моның өчен сәбәпләр адым саен чыгып торган. Мәсәлән, Үзбәк ханның абыйсы Шәүкәлне ясак җыярга баргач, руслар үтерәләр. Үзбәк хан моның өчен руслардан үч алмый, җәза отрядлары җибәрми. Киресенчә, князьләрне ясак түләүдән вакытлыча азат итә. Үзенең бертуган сеңелесен — Кончакны Мәскәү князе Георгийга кияүгә бирә. Әйтелгәннәрдән аңлашылса кирәк, кыпчак далаларына — үзләренең кардәшләре җирләренә — килеп Алтын Урда дәүләтен төзегән татарлар рус җирләренә «татар-монгол иго»сын түгел, бәлки руслар өчен гаять әһәмиятле, актуаль булган бердәмлек идеясен китерә. Бу җәһәттән Н. М. Карамзин болай яза: «Батый гаскәрләренең Россиягә китергән яхшылыгы — бәхәссез. Электәге кебек князь белән князь сугышып тагын 100 яки аннан да күбрәк ел узарга мөмкин иде. Ә бу ни белән беткән булыр иде икән? Ватаныбызның һәлакәте белән, билгеле. Шуңа күрә дә Мәскәү үзенең югарыга күтәрелүе өчен — ханнарга бурычлы» (429 б.).

Ләкин Батый нәселе һәм татарлар Россиягә китергән уңай нәтиҗәләр әйтелгәннәр белән генә чикләнми әле. Биредә тагын шуны өстәргә кирәк: рус җирләре бары XV гасырның икенче яртысыннан XVI гасыр яртысына кадәр чорда гына да а л т ы мәртәбә арта, халкы исә биш-алты миллионнан тугыз миллионга җитә.

А л т м ы ш т а н артык яңа шәһәр барлыкка килә. («Краткая история СССР», 86, 92 бб.). Шул ук вакытта рус князьләре Көнбатышта ничаклы сугыш алып баралар. Швед, Литва... илләре җиңелә, төрле рыцарь орденнары тар-мар ителә һ. б. Әгәр дә татар-монголлар рус җиренә торгынлык, артталык, иго китергән булсалар, Россиядә әлеге уңай үзгәрешләр барлыкка килә алыр идеме икән? Юк, мөмкин түгел! Чөнки «иго» — ул халыкның рухи көчсезлеген, хуҗалыкның җимерелүен, һәлакәт, үлем китереп чыгара. Ә бирелә — үсеш, алгарыш! Дөрес, рус князьләре үз ватаннарында ызгышып, сугышып яшәмәгән булса, үзгәрешләр бәлки тагын да зуррак булган булыр иде. Әнә бит Н. М. Карамзин ни яза: «Князь князьгә каршы баш күтәрә, энесе абыйсын үтерергә җыенып, кылыч кайрый, оның үзенең бабасын суям дип, корал ясый» (384 б.). Нәкъ менә шушындый хәл рус иленең көчен, байлыгын, акылын суыра, әрәм-шәрәм итә. Нәкъ менә князь белән князь талашлары рус җиренә сагыш, кайгы, фаҗига, күз яше, үлем китерә. Татарлар түгел! Явыз Иван патшалык иткән еллар халык өчен әрәмгә киткән гомерләр, кан коюлы, борчулы, тынычсыз көнкүреш белән аерылып тора. Аның Новгородка каршы походын гына алыйк. Максатына ирешү өчен патша нинди канлы, һәлакәтле юл сайлый бит!

...«1569 елның декабрендә,— дип яза Н. М. Карамзин,— Иван Грозный улы Иоанны һәм барлык сарай кешеләрен ияртеп үзенең яраткан дружинасы белән Клин шәһәренә килә. Биредәге кешеләрне Мәскәү дәүләтенең яшерен эчке дошманнары, дип санап, Иван аларның берсен дә калдырмый үтереп бетерергә әмер бирә. Йортлар, урамнар үле гәүдәләр белән тула. Беркемгә, хәтта хатын-кыз, бала-чагаларга да рәхим-шәфкать күрсәтелми. Аннары Клиннан Тверьга илтүче юл үлем, кан-яшь кырына әйләнә. Тверь үзе талана, җимерелә, кешеләре үтерелә, асыла. Илмен күленә хәтле урнашкан барлык авыллар, шәһәрләр шушындый ук язмышка дучар була. Шаһитлар калмасын, дип, бу канлы поход турында беркем белмәсен дип, очраган һәр кеше үтерелә, туры килгәндә бәкегә ташлана» (591б).

Ниһаять, менә Новгородны буйсындыру эпизодлары: «1571 елның икенче гыйнварында,— дип яза Н. М. Карамзин,— патша дружинасы Новгородка килеп керә. Бер генә җан иясе дә качып котыла алмаслык итеп, шәһәр бөтен яктан камап алына. Чиркәүләрне биклиләр, монастырьларны ябалар. Чиркәү хезмәтчеләре кул-аякларыннан бәйләп ташлана. Аларның һәркайсы 20 шәр сум акча түләргә тиеш була. Түли алмаучылар иртәдән кичкә кадәр кыйнатыла, суктырыла. Сәүдәгәрләрне, кунакларны, эшкуарларны чыбырлап куялар, богаулыйлар. Ни өчен? Ни сәбәпле? Моны беркем белми. Тирә-юньне фаҗига һәм дәһшәт чолгап ала» (591.).

Явыз Иван үзе ничек эш итә соң? Н. Карамзинны укыйбыз: «Ул чиркәүгә керә, чукына. Аннары архиепископ янына килә, барлык боярлар белән бергә өстәл артына кереп утыра, ашау-эчү башлана. Кинәт патша кулы белән өстәлгә бик каты сугып, күкле-яшелле тавышлар чыгарып, вәхшиләрчә кычкырып җибәрә. Шунда ук патшаның сугышчылары җыела. Алар архиепископны, чиновникларны, хезмәтчеләрне тотып алалар. Талау башлана: акча, савыт-саба, иконалар, кыңгыраулар... барысы-барысы җыеп алына. Моннан соң патша кешеләрне хөкем итәргә керешә. Көн саен аның янына 500 дән алып мең кешегә кадәр новгородлылар китерелә. Аларны кыйныйлар, җәзалыйлар, нининдер матдә кулланып утка тоталар, аннары һәркайсын йә башыннан, йә аякларыннан чанага бәйләп Волхов елгасына өстерәтәләр. Биредә аларны күпердән елгага ташлыйлар. Судан тере килеш калкып чыкканнарны көймәгә утырган сугышчылар үтереп йөриләр: сөңгеләр белән кисәкләргә турыйлар». Ләкин фаҗига болар белән генә бетми әле. Н. М. Карамзин тагын мондый мәгълүматлар китерә: «Үтерүләр тәмамлангач, шәһәрдә киң колач белән талау, җимерү, вату башлана. Иван үзе атка атланган килеш урамнан урамга чаба, үз солдатлары ничек капкаларны җимерүләрен, тәрәзәләрне ватып, эчкә ыргылуларын күзәтә. Солдатлар исә патшага ярарга тырышалар: ерткыч хайваннар кебек ефәк тукымаларны, мехларны үзара тарткалаша-тарткалаша бүлешәләр, дуңгыз мае, балавыз елгага ташлана, алып китәргә читен булган хәзинәләр яндырыла... Новгородтагы вәхшилек 6 атна дәвам итә, 60 мең тирәсе кеше һәлак була» (592 б.).

Китерелгән эпизодлар Иван патшаның нинди явыз, шәфкатьсез, канэчкеч, вәхши кеше булуын күрсәтәләр. Кайда гына булмасын, ул шунда фаҗига, кан кою, үлем, җимерү, вату китерә. Иван патша — тиран, палач. Кагыйдә буларак, андый шәхесләр, кешеләргә никадәр авыр золым, явызлык эшләсәләр, аларда үз гомерләре өчен курку, калтырау шулкадәр арта, һәркемгә шикләнеп карау гадәткә әйләнә. Күңелдә аз гына шик-шөбһә уяндымы, нининдер шикле сүз колакка

кердеме, тиранның җәзалау инстинкты шунда ук хәрәкәткә килә. Иван патшаның шиге төшкән кешеләргә җәзасы аерата шәфкатьсез, куркыныч һәм вәхшиләрчә була. Кешене газаплап үтерү аның өчен ләззәт чыганагы, күңел ачу, тамаша кылу булып тора. Биредә тиран портретын тулыландыру өчен тагын бер эпизод китерик: «Китайгородтагы сәүдә мәйданы уртасында,— дип яза Н. М. Карамзин,— 18 дар ясап куялар, бик күп җәзалау кораллары китерәләр. Янәшәдә үк зур учак ягып җибәрәләр, аның өстенә казан-чан асып куела... Ак атка атланган патша үзенең яраткан өлкән улы белән мәйданга килеп туктый. Боярлар, кнәзләр аның тирәсенә тупланалар. Алардан соң тәмам хәлсезләнгән гаепләнүчеләр көчкә-көчкә аякларын өстерәп мәйданнан урын алалар...

Ниһаять, җәзалап үтерү башлана: «Бер гаепләнүче өстенә башта кайнап торган су, аннары салкын су коялар. Түзә алмаслык газаплар эчендә гаепләнүче, ниһаять, җан бирә. Калганнарын чәнчеп, асып, кисәкләргә тураклап үтерәләр. Грозный үзе атка атланган килеш бер картны сөңге белән чәнчеп үтерә. Җәзалау 4 сәгать дәвам итә һәм 200 тирәсе кеше үтерелә. Эшне бетергәч, үтерүчеләр патша каршына килеп басалар һәм «Гойдя! Гойдя!» дип, кычкырып, патшаның хөкемен тәбрик итәләр» (597 б.).

Иван патшаның халыкларга карата кулланган җәзалау, изү, үтерү ысуллары әйтелгәннәр белән генә чикләнми әле. Н. М. Карамзин аның тагын шундый ысулларын күрсәтә: «Грозный яшь Федор Басмановны үзенең туган әтисен үтерергә мәҗбүр итә».

«Иоанн үзенең гаскәр башлыгын бер мичкә дары белән шартлатырга куша. Схимниклар — фәрештәләр. Алар күккә ашарга тиеш, ди. Шаярткан булып кылана».

«Бер чиновникның хатыны бик чибәр икән. Патша аны тотып ала да, ире күз алдында көчли, мыскыл итә, соңыннан асып куйдырта. Моны карап торырга мәҗбүр ителгән иренең исә башын кисеп ташлата».

«Ачудан да, мәзәк өчен дә патша кешеләр өстенә аюлар өстертә. Аюларның кешеләр өстенә ничек ябырылуын күзәтеп, кешеләрнең куркудан, авыртудан кая качарга белми акыра-бакыра чабуларын күреп, патша рәхәтләнеп көлә».

«Бервакыт Грозный янына гаскәр башлыгы килә, җиргә кадәр иелеп сәлам бирә. Патша: сәламәт бул, сөекле воевода, син бүләккә лаек, ди һәм тегенең колагын кисеп алып, кулына тоттыра» (600 б.).

«Вакыт-вакыт тиран кинәт кенә аш-су мәҗлесен калдырып атына атлана, кычкырып дружинасын чакырып китерә дә, кан эчендә йөзәргә — Мәскәү төрмәсенә китә. Анда 100 дән артык әсир төшкән литвалыларны үтереп «Гойдя! Гойдя!» авазлары астында сарайга кайтып, һич ни булмагандай ашау-эчүне дәвам иттерә» (600 б.).

Россиядә кешеләрне җәзалау ысуллары, кораллары да бик күп төрле була. Бу турыда Н. М. Карамзин болай яза: «Күп төрле җәзалау кораллары кулланыла иде. Кызу табага утырту, махсус мичләргә тыгу, тимер кыскычлар, үткен эскәкләр, озын инәләр,— менә аларның кайберләре шулар. Моннан тыш кешеләрне тураклау, тиреләрен салдыру, арка тиресен бил каешына файдалану кебекләре дә киң кулланыш тапкан» (595 б.).

Менә шушындый күп төрле җәзалау кораллары, акыл ирешмәслек газаплап үтерү ысуллары рус илен кан-яшь, изү — үлем белән тутыра. Боларга тагын рус кнәзьләренең ызгыш-талашлары, рус патшаларының башбаштаклыгы, идарә итүдә кулланылган вәхшилек килеп кушыла һәм алар барысы бергә халыклар өстенә, шул җөмләдән рус халкы җилкәсенә дә коточкыч фаҗига булып төшә. Кабат Карамзинга мөрәҗәгать итик: «Тиран ачуы гаиләләр өстенә төшкәндә, ир-хатын, бала-чага гына түгел, хәтта аларның туган-тумачалары да бетмәс-төкәнмәс газапларга дучар ителә иде. Кешеләр андый газапларны кичергәнче, тизрәк үлеп китүне сорап, аллага ялваралар иде» (599 б.).

Игътибар итик: бүгенге көндә рус шовинистлары үзләренең таркалуга дучар ителгән империяләрен теш-тырнаклары белән саклап калырга тырышалар, гасырлар буенча төзелгәнне таркатырга безнең хакыбыз юк», дип лаф оралар.

Хәлбуки, әле генә китерелгән өзекләрдән күренгәнчә, рус империясе Явыз Иван патша тарафыннан әнә бит ничек кан кою, үтерү, җәзалау, вату-җимерү ысулы белән төзелә башлый һәм шул ук рәвештә алдагы гасырларда да дәвам ителә. Казан ханлыгына да 8 поход ясала бит! Моннан соң да басып алу сугышлары тынып тормый. 1556 елда Әстерхан ханлыгын юк итүдән алып, 1940 елдагы фин сугышына кадәр узган чорларда әлеге империяне зурайту

максатыннан чыгып алып барылган буйсындыру-талау сугышлары 39 мәртәбә кабатлана.

Бүгенге көндә шундый сугышлар бәрабәренә төзелгән империяне саклап калырга тырышканчы, яңа Россия федерациясе — халыклар дуслыгына, тигезлегенә, бәйсезлегенә нигезләнгән федерация төзү отышлырак түгелме соң?

Тагын бер гаделсезлек яшәп килә: рус халкы кичергән җәбер, золым өчен гаепне бүген дә татар-монголлар өстенә ташлыйлар, янәсе алар гаепле.

Кызганычка каршы, үзеңне аклап, гаепне күршегә ташлау, аны бетереп хурлау бүгенге көндә дә гамәлдән чыкмаган әле. Әнә бит Кырымтатарларын ата-баба җиренә — Кырымга кертмәс өчен Кырымны татарлардан тартып алучылар тарафыннан нинди явызлыклар эшләнә! Ә сылтау шул: янәсе алар гаепле. Идел буе немецләре дә гаепсездән гаепле булып, үз җирләреннән сөрелделәр. Бүген дә аларга үз җирләренә кайтып, автономия төзергә ирек бирмиләр. Шикләнеп карау, чит кешеләрне посып торучы дошман итеп күрү нәтиҗәсендә 21 мең 857 поляк хәрбие Катын урманында мәңгелеккә ятып калды. Тагын калмыклар, чечен, ингушлар нинди авыр язмышка дучар ителделәр!

Бүген Ичкериядә яңа фаҗига. Ул да бит чеченнәрне дошман итеп караштан башланды. Имеш, чеченнәр — җинаятьчеләр өере; имеш, чечен Республикасы законсыз коралланган бандитлар оясы; имеш, Ичкерия — җинаятьләр эшләп, качып йөрүчеләрне сыендыру урыны; имеш, анда кеше хокукларын аяк астына салып таптаган кораллы җинаятьчеләр хөкем сөрә. Бу хурлауларның максаты бер: Берләшкән Милләтләр Оешмасы раслаган хокукларга таянып, үз телендә сөйләшүне, үз традицияләрен дәвам итүне, үз баласын, үз җир-суын, үз йортын яклап көрәшкә тупланган талантлы, батыр чечен халкын юк итү, үтереп бетерү.

Без хәзер үз тарихыбызны рус патшалары кулланышка керткән ялганнан һәм субъектив карашлардан арындырырга тиеш. Тарихыбыз — чын тарих, дөрес тарих булсын. Шушы рәвешчә эш иткәндә, татар халкы күп компонентлар кушылып формалашкан милләт дип, татар этнонимы — тагылма түгел, законлы исем дип, Алтын Урда — без татарларның үз дәүләте, хокукый дәүләте дип танырга тиеш булабыз. Нәкъ менә шушы караш тарихи дөреслекне чагылдыра да. Тагын бер документ: «Сокровищница документов прошлого». Укыйбыз: «Покорение Казани — одного из осколков и правоприемников Золотой Орды...» Күренә ки, Казан ханлыгы — ул Алтын Урда кыйпылчыгы, шулай ук Себер ханлыгы. Әстерхан ханлыгы да Алтын Урда кыйпылчыгы булып тора. Чөнки алар бер нигездән — Алтын Урда нигезеннән килеп чыкканнар.

Бүгенге көндә татар бабаларыбызны эштән чыгарып яманлыйлар икән, бу хәлдән котылу өчен халыкның дәрәҗәсен, абруен күтәрү буенча барыбызның да бер җан, бер тән булып, фидакарьләрчә эшләвен сайларга кирәк. Әйе, халкыбыз арасыннан күбрәк академиклар чыксын, талантлы шагыйрьләребез, әдипләребез, драматургларыбыз, рәссамнарыбыз, архитекторларыбыз, композиторларыбыз, җырчыларыбыз, артистларыбыз күбәйсен. Зирәк юристларыбыз, педагог-тәрбиячеләребез, оста-үткен дәүләт эшлеклеләребез, дипломатларыбыз, хуҗалык җитәкчеләребез барлыкка килсен һәм арта барсын. Данлыклы механизаторларыбыз, терлекчеләребез, игенчеләребез күтәрелеп чыксын! Нәкъ менә шундый юмарт талант ияләре халык данын күтәрә, арттыра. Берләшкән көчебез шундый олы максатларны гамәлгә ашыруга юнәлсен.

Ә халкыбызның килеп чыгышы мәсьәләсенә килгәндә, ул — ачык һәм билгеле.

Шагыйрь Нури Арслановча әйтсәк:

Татар дигән исем йөртәбез без —
Татар каны ага тамырда!

# ЯШЬМЕ, КАРТМЫ?



**Татарстан Республикасы
хөкүмәте тарафыннан оештырылган
иҗтимагый-сәяси
һәм
теоретик «Татарстан» журналына
1995 елның декабрь аенда
75 яшь тула.
Шул уңай белән без
журналның баш мөхәррире,
танылган язучы,
тәнкыйтьче һәм публицист
РАФАЭЛЬ МОСТАФИНГА
берничә сорау белән
мөрәҗәгать иттек.**

*— Рафаэль Әхмәтович! Сез бервакыт телевидение аша чыгыш ясаганда: «Татарстан» — әле бик яшь журнал,— дип әйткән идегез. Ә үзегез быел журналның 75 еллыгын үткәрергә җыенасыз. Моны ничек аңларга?*

— Әйе, бер яктан караганда, «Татарстан», чыннан да,— яшь журнал. Аны чыгару турындагы карар 1990 елның көзендә, ягъни Татарстан Республикасы суверенитеты игълан ителгән көннәрдә генә кабул ителде. «Татарстан»ның беренче саны исә 1991 елның гыйнвар аенда гына чыкты. Шулай итеп, безгә әле нибары бишь яшь тирәсе — «ыштансыз малай», дип әйтергә була.

Әмма бу журнал, җөмһүриятебезнең бердәнбер иҗтимагый-сәяси һәм теоретик журналы буларак, буш урында барлыкка килмәде. XX гасыр башларында татарларда «Шура», «Аң» шикелле җитди, бай эчтәлекле журналлар чыга башлаган. Бүгенге «Татарстан»ның тирән тамырлары күпмедер дәрәҗәдә шуларга барып тоташа. 1917—18 елларда алар барысы да ябыла. Ләкин халык матбугатсыз яши алмый. 1920 елның көзендә яңа оешкан Татарстан совет социалистик республикасы хөкүмәте (ул вакытта ул ЦИК — Үзәк башкарма комитеты дип атала) яңа журнал чыгару турында карар кыла. Бу эш партия өлкә комитетына тапшырыла. 1920 елның беренче декабрендә «Вестник Татарского областного комитета РКП(Б)» дип исемләнгән журналның беренче саны дөнья күрә. Башта журнал рус телендә чыга. Берничә елдан татар теленә күчеп, «Җитәкче» исеме астында чыгуын дәвам итә. Төрле елларда ул төрле исем йөртә: «Агитатор ярдәмчесе» («Спутник агитатора»), «Ильич юлы» («Путь Ильича»), «Причал», «Коммунистический путь», «Спутник партийного активиста». Ниһаять, утызынчы елларның икенче яртысында, журнал үз йөзен, үз төсен табып, ике телдә, башта «Татарстан большевигы» («Большевик Татарстана»), аннан, 1958 елдан башлап, «Коммунист Татарии» («Татарстан коммунисты») исеме белән чыга башлый.

Шулай итеп, безне бик яшь тә, шактый өлкән, хәтта журналларыбыз арасында иң карты дип тә әйтергә була.

*— Заманында «Татарстан коммунисты»ның коммунистик идеологиягә тугрысынча бирелгән, партия кануннарыннан бер мыскал да читкә тайпылмый торган журнал дип даны чыккан иде. Аңарда басылган мәкаләләр директив характерда була иде. Хәтта аңа язылу да мәҗбүри рәвештә алып барыла иде...*

— Ул елларда кайсы матбугат органы коммунистик идеологиягә каршы бара ала иде соң? Һәрберсе йә обком, йә горком, йә райком органы булып торды.

Исегезгә төшерәм: «Татарстан коммунисты» 1990 елны чыгуыннан туктады. Аның урынына бөтенләй яңа типтагы, яңа төстәге журнал чыга башлады.

Шулай да без үткәнне кара буяу белән генә буямас идек. Торгынлык елларында да журнал шактый файдалы, кирәкле эш башкарды. Аның сәхифәләрендә республикабызның атаклы язучылары, галимнәре, абруйлы җитәкчеләр, җәмәгать эшлеклеләре чыгыш ясый иде. Без көндәлек эшебездә шул уңай традицияләргә дә таянабыз.

*— Рафаэль Әхмәтович! Сез алтмышынчы елларның икенче яртысында «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып та эшләдегез. Өлкәнрәк яшьтәге укучылар бу чорны яхшы хәтерлиләр. Сез килгәч, журнал яңарып, үсеп, күтәрелеп китте. Аның эчтәлеге дә, тышкы бизәлеше дә тамырдан үзгәрде. Тиражы да сизелерлек үсеп китте. Шул уңай белән бер сорау: «Татарстан» журналы «Казан утлары»ннан кайсы ягы белән аерылып тора? Ике журналда да эшләгән кеше буларак, сез моны аеруча яхшы сиземмисездер...*

— «Казан утлары» — беренче нәүбәттә әдәби журнал. Ул язучыларга, әдәбият сөючеләргә, гомумән, әдәби әсәрләрне укырга яратучыларга төбәп чыгарыла. Сүз дә юк, «Казан утлары» — инде ничә дистә еллар буе татар халкының төп мәдәни басмасы, рухи көзгесе булып килде, һәм ул үзенең тарихи миссиясен бүген дә уңышлы үтәп килә. «Татарстан» исә — үз алдына башкачарак максатлар куя. Әйе, монда да вакыт-вакыт әдәби әсәрләр — хикәяләр, шигырьләр, күләмле әсәрләрдән өзекләр басылгалый. Ләкин безнең төп юнәлешебез — милләтебезнең гасырлар буе хурланып килгән рухи казанышларын барлау, аларны яңа шартларда үстерү. Без халкыбызның ерак һәм якын тарихын яктыртуга зур әһәмият бирәбез. Татар халкының килеп чыгышы, борынгы Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы тарихы һ. б. турындагы язмалар журналда даими рәвештә урын ала. Татарстан җөмһүриятенең һәм, гомумән, татар халкының бай мәдәнияте, мәгърифәте, мәгариф системасы, инде дәүләт теле статусы алган туган телебезне саклау проблемалары... Боларга өстәп, яңарыш кичергән ислам дине, республикабызда яшәүче башка халыклар культурасы, гореф-гадәтләре...

Кыскача әйткәндә, безнең төп максатыбыз — Татарстан Республикасы иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади тормышына даими һәм төпле анализ ясап тору.

*— Гадәттә, һәрбер матбугат органы диярлек язылу вакытында «Без — киң катлам укучыларга төбәп чыгабыз»,— дип игълан итә...*

— «Татарстан» турында мин алай дип әйтмәс идем. Без беренче нәүбәттә укымышлы, зыялы укучыларны күздә тотабыз, интеллигенция вәкилләренә төбәп чыгабыз. Аеруча укытучылар өчен тирән эчтәлекле һәм кызыклы материаллар бастырабыз.

*— Чит өлкәләрдә яшәүче укучылар журналыгызга языла аламы?*

— Әлбәттә. «Татарстан» журналы Бөтенроссия каталогына кертелгән. Индекс: татарчасыныкы 73377, русчасыныкы — 73947.

*— Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Рафаэль Әхмәтович. Сезне һәм редакция коллективын юбилей белән котлыйбыз, эшегездә һәм иҗатыгызда яңадан-яңа уңышлар телибез.*



**Мөхәммәтнур Муллануров**

# ТЫЛСЫМЛЫ КЕШЕ

**«Планетаны яңарту» халыкара ассоциациясе вице-президенты, халык табибы, югары дәрәҗәдәге савыктыручы Рәфыйк Миңлебай улы Миңнекәев 1955 елның май аенда Татарстанның Кукмара районы Вахит авылында туып, шунда үскән гади бер милләттәшебез.**

**Рәфыйкны тәртипле, инсафлы итеп үстергән өчен, ата-анасына рәхмәт. Әтисе Миңлебай исән-сау, авылында яши, ә әнисе Миңлегөл — вафат. Җаны җәннәттә булсын!**

**Авыл мәктәбен тәмамлагач, Рәфыйк Янилдә укыган. Гаиләсе биш кешедән тора: хатыны Рәйхана, ике кызы, бер уллары үсә.**

**Рәфыйк әфәнде үсеп җиткәч тә тәрбияле, әдәпле булуы белән башкалардан аерылып тора. Спорт белән шөгыльләнә, кыш көннәрендә чаңгы шуа, табигатьне ярата. Аның эшләгән урыны да табигать кочагында — урманчы булып эшли. Соңгы елларда икмәк заводы директоры вазифасын башкара. Аның гаиләсендә дә, эшләгән җирендә дә тынычлык, дуслык хөкем сөрә, ызгыш-талаш булмый.**

## Сүз — аның үзенә

Минем кешеләрне савыктыру эше белән шөгыльләнә башлавыма 1995 елның март аенда өч ел тулды. Соңгы елларда экстрасенсларның күбәеп китүе, ә «Алардан файда аз»,— дип язылган төрле мәкаләләр тәэсире нәтиҗәсендә, гадәти булмаган халык дәвалау системасына карата кире мөнәсәбәт туды. Шулай да соңгы вакытларда авыр, озакка сузыла торган, терелә алмастай авыруларның елдан-ел арта баруы, кешеләрне савыктыруның кирәклеге бүген бөтен булган мөмкинлекләрдән файдалануны таләп итә.

Минем савыктыручы булырмын дип уйлаганым да юк иде. Шуңа карамастан, язмыш кушкандыр инде: 1991 елның октябрь-ноябрь айларында Вятка аланында яшәүче сеңелем Рәйсә үзе белән бергә эшләгән хатынның Галәм белән элемтәгә керә алуы турында сөйләде һәм озакламый шушы система буенча укыту курс-

лары булачагын әйтте. Мин үзем ул системага ышана торган кеше түгел идем, шулай булса да каршы килмәдем.

Курсларда ике көн укыгач, миндә кеше организмын кул белән тою сәләте барлыкка килде. Бу курсларда укып чыккач, Мәскәүгә, «Планетаны яңарту» ассоциациясенә укырга киттем. Аны әйбәт кенә тәмамлап, 1992 елның мартында халыкара дәрәҗәдәге дипломга лаек булдым.

Диплом алган көнне миңа Мәскәүдә эшкә калырга тәкъдим ясадылар. «Фатир һәм кул астында эшләргә институт бирәбез»,— диделәр. Мин бу тәкъдим белән килешмәдем, чөнки бердәнбер теләгем — үземнең туган җирдә, Татарстанның Кукмара районында дәвалау үзәге ачу иде. Кукмара район хакимият башлыгы минем бу фикеремне хупларга нишләптер ашыкмады. Шул сәбәпле эш урынымны Казанда булдыру турында уйлый башладым.

Беренче сеансларны Свердловск өлкәсенең Түбән Тагил шәһәрендә үткәрдем. 1992 елның май башларында Кукмарадагы мәдәният йортында дәвам иттем. Баштагы сеансларны бушка үткәрдем. Аннан соң халык белән сөйләшеп, эшемә бәя куярга сорадым. Бераз төзелеш оешмаларында эшләдем.

Сеанслар үткәргәндә тәнәфескә туктагач, бер бүлмәгә ял итәргә кердем, күккә менәргә булдым. Монда минем ярдәмчеләрем Зиннур белән Эльмира янәшәмдә иде. Ул вакытта Эльмираның да, минем дә күрәзәчелек сәләте бар иде инде. Мин күккә күтәрелеп киттем. Тауларны, болытларны узып, бер планетага җиттем. Ул планетада бик чиста, бар нәрсә алтыннан гыйбарәт. Ике рәткә тезелеп бабайлар утырган. Ике якта да 10 ар бабай утыра. Беренче рәттәге ике бабай торып мине җитәкләп алдылар. Мин башта уй белән исәнләштем. Алар, мине җитәкләп, түргә таба алып киттеләр. Түргә барып җиткәч, минем кулны ычкындырып, үз урыннарына барып утырдылар. Бу эшләр барысы да күз йомык һәм минем физик гәүдә җирдә хәлдә башкарыла. Алар мине калдырып киткәч, аларга уй белән генә рәхмәт әйттем. Шул арада каршымда миннән бер ярым тапкыр зурлыктагы бик мәһабәт кеше пәйда булды. Уй белән генә исәнләштем. Ул минем уң кулымны алып, уң кулы белән, чәнти бармак янындагы бармакка әйбер кидерә башлады. Бу эшне Эльмира да карап тора, мин дә күзәтәм. Мин бу кешеләр белән сөйләшә белмим, ә Эльмира аралаша ала. Теге зур кеше минем бармакка балдак кидерә иде. Мин Эльмирага бу балдакны ни өчен биргәннәрен сорарга куштым. Ул болай дип аңлатты: «Рәфыйк абый, сиңа көч бирәбез, дип әйттеләр. Бу көчеңә бөтен кеше шаккатачак»,— диде. Бу 1992 елның июнь ае иде.

Эльмирага балдак белән ничек эш итәсен сорарга куштым.

— Балдакка карыйсың да, уй белән генә борылырга кушасың, аннан соң ул син нәрсә әйтсәң, шуны эшли,— дип аңлаттылар. Көч биргәннәре өчен уй белән генә рәхмәт әйттем һәм җиргә төшәргә кирәклеген аңлаттым.

Җиргә төшеп барганда, миннән 5—6 метр ераклыкта гына бер аппарат төшеп бара. Мин җиргә төшеп бастым, аппарат якынга гына төшеп утырды. Ишеге ачылып, аннан 70 сантиметр биеклектәге бабай чыкты, миңа таба килә башлады. Ул вакытта минем сул якта үземнең кеше бар иде инде. Бабай минем кеше белән исәнләште дә, уң ягыма басарга рөхсәт сорады. Мин ризалаштым.



Минем янга күктән килгән бабай баскач, бик кызык кына уй барлыкка килде. Ул бабай минем белән идарә итмәсме? Шулар турында Эльмирага сорарга куштым. Бабай безгә Сириус планетасыннан килгән, мине сакларга, киңәшләр биреп, миңа ярдәм итәр өчен. Шул көннән башлап бу бабай гел минем белән. Гади тормышта миңа беркайчан да комачаулык иткәне булмады.

Шуннан соң, эш дәверендә миңа, ярдәмгә күкнең төрле катламнарыннан фәрештәләр килә башлады. Бүгенге көндә минем шундый 540 тан артык фәрештәм бар.

Әкренләп мин бу бирелгән көчләрне сыный башладым. Зиннур белән Кукмарадан сеанстан кайтып килгәндә, Бояр тавы башыннан Вахит авылы өстендә кап-кара яңгыр болыты күрдек. Авылга яңгыр кирәк булмаганлыктан, мин болытны таратып карарга уйладым һәм болытка энергия җибәрдем. Без авылга кайтып җиткәндә ялт итеп кояш чыккан иде. 15—20 минут эчендә болытның әсәре дә калмады. Балдакның көчен, Лениногорск районының (Татарстан) Түбән Чыршылы дигән авылында 82 яшьлек бабайның бот сөягендәге 50 ел элек кергән пуля тишеген дәвалаганда файдаланырга туры килде.

Арча районының «Ватан» совхозында сеанслар биргән вакытта мин совхоз директорыннан печән сорадым. «Рәфыйк, печән басуда, бүгеннәрдә кибеп бетә, аннан тюк белән алырсың»,— диде. Төшке аш вакыты иде. Безнең авыл өстенә бик көчле яңгыр болыты килде. Совхоз басуыннан печән аласы булганлыктан, минем башка әлеге болытны таратырга дигән уй килде. Болытны урталай бүлдем, бер ягын Балтачка, икенче яртысын Мари Элга җибәрдем. Балтачка киткән болыт явып китте. Ә Мари Элга җибәргәне, республикага кермичә, чигенә башлады. Мин моның сәбәбен тикшердем. Ни өчен болыт республикага керми?

Өч ел элек Мари республикасына кайбер җитәкчеләрнең әшәкелекләре аркасында күктән җәза бирелгән икән. Шул чор эчендә анда яңгырлар күренмәгән, республикада корылык булган. Республика өстенә гади кеше күзенә күренми торган шар сыман әйбер куелган иде. Мин ул шарны ярдым һәм республика өстеннән чыгарып ташладым. Шуннан соң территориядә яңгыр ява башлады. Минем бу эшне башкарганны ярдәмчем Нажия апа күзәтеп торды. Аның күрәзәчелек сәләте бар. Ул, олы яшьтә булуына карамастан, озак вакытлар миңа ярдәм итеп йөрде. Бу эшләр 1993 елның җәй айларында булды.

1993 елның ноябрь аенда Балык Бистәсенә сеанслар бирергә барган идек. Фатирда ял итеп, телевизор карап утыра идем, экраннан Новороссийск шәһәрен су басканын күрсәттеләр. Без караган вакытта диңгездә 4 пароход баткан, 5 кеше үлгән, диделәр. Бу хәбәрне алуга мин, Космос белән элемтә ярдәмендә, су басуның сәбәбен ачыкладым. Су басу Кара диңгезнең төбеннән, җир тетрәү нәтиҗәсендә дулкын күтәрелеп барлыкка килгән иде. Без кичке сәгать 8 ләрдә бу эшләрнең шаһите идек. Мин тиз генә Кара диңгезне ярсуыннан туктатырга керештем. Башта диңгезне генә тынычландырдым һәм Космостан Җир тетрәүнең кайчан туктыйсын сорадым. Иртәнге сәгать дүрткә туктый, диделәр. Мин, туктау процессын тизләтү турында уйлап, яңадан эшли башладым. Җир астындагы тетрәгән урынны тынычландырдым һәм яңадан Космостан диңгезнең кайчан тынычланасын сорадым. Иртәнге сәгать 2 гә, диделәр. Шулай итеп, мин тагын 2 сәгать вакытны кыскарта алдым. Бу эшләр синоптиклар хәбәре буенча 3 көн барырга тиеш иде. Минем катнашуым аркасында көн ярымда туктады. Икенче көнне сеанска килгәч, халыкка «Новости» программасын тыңларга куштым. Анда су басуларның тукталачагын хәбәр итәрләр, дидем. Сеанслардан кайткач үзем дә ул программаны карадым. Анда диктор: «Меры приняты, наводнение остановилось»,— дигән булды.

Залда кеше белән эшләгәндә, минем беренче бурыч — кешенең аң дәрәҗәсен күтәрү, яшәү рәвешен үзгәртү. Икенче эш итеп кенә физик гәүдәне чистартуны күз алдында тотам.

Авыруларның барысы да диярлек кешенең дөрес яшәмәвеннән барлыкка килә. Күп авыруларның сәбәбе булып гәүдәдәге бозык тора. Бозыклар бик күп төрле. Кайберләре, әти-әнинең үтәлми калган нәзерләре өчен Күктәгеләр тарафыннан бирелгәннәре, нәселдән килә торганы була. Андыйларны, Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгәнгә күрә, бүгенге көндә бик сирәк кеше генә чыгарырга сәләтле. Моңа чынбарлыкта гади дәвалаучының көче җитми дигән сүз. Әгәр дә кешенең гәүдәдәге бозыгын ала алмасаң, аны дәвалап торуның кирәге юк. Ул авыру тиз арада кире кайтачак. Әгәр дә әти-әнигә бирелгән булса, әти-әни күп еллар элек үлгән булса, бозыкны чыгарыр өчен үлгән әти-әнинең кабердән — үзләре яныннан җаннарын иреккә чыгарырга кирәк. Җан иреккә чыккач кына бу нәселдән Ходай Тәгаләдән бирелгән җәза алыначак.

Кайбер бозыклар йортларның пычрак урынга салынуыннан да килә. Мондыйлары да нәселдән килә. Нәселне чистарту өчен бозык булган йорт урынын чистартырга кирәк. Кешедән бозыкларны чыгарганда, күккә яки җиргә чистарып кайтсын дип җибәрергә кирәк. Безнең күп кенә җирдә, укыту системасында, бозыкны чыгаруны дөрес өйрәтмиләр. Аны алгач, сазлы урынга ташларга кушалар. Әгәр дә бозыкны сазлы урынга ташласаң, ул анда яшәүче кешеләргә гөмбәдер, җиләктер җыйганда, яисә шул урыннарда эшләүчеләрнең организмына

кире кайтачак. Моның ачык мисалын мин Төмән өлкәсендә эшләгәндә күрдем. Анда миңа күренергә килгән кешеләрнең барысыда да бозык иде. Мин кешегә, бозыкны бик тиз аерсын өчен, аның тышкы билгеләрен аңлатам. Гәүдәдә бозык булганда бик еш баш авырта, хәлсезлек була, анализлар исә әйбәт күрсәтә.

Бүгенге көндә безнең Казанда, «Меховщик» берләшмәсендә, бозыкны күрсәтә торган аппарат бар. Анда булган кешегә врачлар диагноз куеп, бозык икәнен әйтеп, әбиләргә барырга кушалар. Ә бозыкны алырдай әбиләр безнең Татарстан территориясендә бүгенге көндә юк. Кашпировский, Чумак, Джуна кебек халык арасында танылган белгечләр дә бозыкны чыгарырга сәләтле түгел. Шуның өчен мин бозыгы булган кешеләргә әбиләрне алҗытып йөрмәгез дип әйтер идем. Беренчедән, үзләренә материаль яктан экономия булыр, икенчедән, әбиләр тыныч кына яши бирерләр. Кайбер кешеләр, өшкерү юлы белән бозыклар чыгадигән фикердә торалар. Бу дөрес түгел. Өшкереп кенә нәселдән килгән бозыкны беркайчан да чыгарып булмаячак. Мин бозыкларны чыгарыр алдыннан, күп кешегә, үтәлми калган нәзерләре өчен дип Коръән ашы уздырырга кушам. Коръән ашлары да күп очракта кабул ителми. Моның сәбәпләрен ачыклап китәм.

Кайберәүләр чират узсынга гына уздыралар, чын күңелдән эшләмиләр. Ә кайбер очракларда гаеп укыган кешедә була. Күп еллар аракы эчеп йөргән кеше бүген муллага әйләнеп, Коръән ашларында укып йөрсә дә, аның бер укыганы да кабул булмаячак. Шуның өчен хәзерге заманда, дин торгызылган вакытта, авылларда муллалар сайлауга бик зур игътибар бирелсен иде. Аларның төп бурычы — халык арасында аңлату эшләре алып бару. Әбиләрне җыеп уздырган ашларның да күбесе кабул ителми. Чөнки аш вакытында әбиләр гайбәт сөйләп утыра.

Безнең Җирдәге бөтен кылган гамәлләрне, көндезен дә, төнлә дә күктәгеләр язып бара. Ул язманы алып уку безгә берни дә тормый. Мин, мәсәлән, залдагы бөтен кешенең дә үткән тормышын әйтеп бирә алам һәм киләчәген дә күрәм. Алай гына да түгел, мин Җирдә яши торган халыкның язмышын үзгәртергә дә сәләтле. Бу эшләрне башкарыр өчен миңа Ходай Тәгалә үзе көч бирде. Җирдә яши торган кешеләргә дөрес яшәр өчен мин аң бирәм.

Бу эшләр белән шөгыльләнә башлаганчы мин үзем дингә ышанмаган һәм динне кире дә какмаган кеше идем. Безнең совет чорында, дөрес тәрбия булмау аркасында, Коръән китабында нәрсә язылганын аңлый алмадым. Бу эш белән шөгыльләнә башлагач, Коръән китабы белән кызыксынырга туры килде. Анда язылганнар — минем бүгенге эшли торган эшләр. Элек-электән дин эзлекле аңлатылып киленсә, бездә бүген тәртип тә икенче төрле булган булыр иде.

Күптән түгел генә миңа Сирия дәүләтендә булырга туры килде. Анда дин бик көчле сакланган. Шуның нәтиҗәсендә урлашу, караклашу дигән нәрсә юк. Урамда калдырып киткән әйбереңә кагылучы юк. Кибетләргә әйбер алырга керсәң, сатучы чыгып каршылый, син әйбер алсаң да, алмасаң да, чәй эчәргә тәкъдим ясый, сөйләшкәннән һәм аралашканнан соң бик яхшы гына итеп озатып кала.

Минем эшләү вакыты өч елга якын гына булуга карамастан, бүгенге көндә эшләү дәрәҗәм бик югары. Галәм сүзе белән әйткәндә, Җир шарында бүген миңа тиңләшә торган көч юк. Сеанслар вакытында минем нәрсәләр эшләргә сәләтле икәнемне белгәч күп кешедә сорау туа: ни өчен миңа гына шундый көч бирелгән, бүтән кешегә түгел? Гади генә авыл малаена, татар баласына мондый көч бирелү күп кешене гаҗәпләндерә.

Чаллыдагы сеанслар вакытында, залда халык алдында, үземнең элемтәчеләрне Галәм белән элемтәгә кертеп, ни өчен миңа шундый көч бирелүен сораттым. Галәмнең җавабы: «Бар яктан да иң, иң, иң яхшы булган өчен»,— дигән җавап булды. Урманчы, пекарня директоры, склад мөдире булып эшләдем. Ләкин аракы кулланмадым. Гаиләдә барысы да тәртип, өч бала белән Кукмара районының Вахит авылында яшим.

Диплом алган көннән үк, бүтән эшне ташлап, кешене дәвалау белән шөгыльләнәм. Бүгенге көндә Җир шарында миңа каршы тора ала торган авыру юк, дип әйтә Галәм. Үзем һәм шәкертләрем Галәм белән иң якын элемтәдә торабыз. Күрәзәчелек сәләте булган 50 дән артык шәкертем бар. Аларның бик әзенә генә мөстәкыйль эшләргә рөхсәт бирдем. Яңа ачылган кешедә, кешенең авыруын үзенә күчерү сәләте барлыкка килә. Мин моны «промокашка» дип атыйм. Мондый кешегә медицинада йокмый дип санала торган авырулар да йога ала. Әгәр дә бик көчле авыру килсә, «промокашка» хәлендәге белгеч бу авыруны үзенә күчерәчәк, үз-үзен чистарта алмау сәбәпле, ул да шушы авыру белән авырый башлаячак. Яңа ачылган кешенең үзен генә эшкә кушу — яңа туган баланы 40 градуслы суыкка чыгарып утырту белән бер. Башта мин аларны үземнең контрольдә нығытам, аннан соң гына янына бер иптәш куеп, чистарта алырлык хәлгә килгәч кенә эшләргә рөхсәт бирәм.

Зал белән эшләгәндә табигатьнең үз көченнән файдаланам. Монда мин генерал ролен үтим. Ә аерым авырулар белән эшләгәндә үй белән органнарга операция ясыйм. Гади сеанслар вакытында төшкән органнар урынына утыра. Беренче сеанста ук кешедән бозыкларын чыгарам. Шикәр авыруы, кызыл волчанка (тире туберкулезы) кебек авырулар өчен минем 8 сеанс та житә. Полиартрит, эпилепсия, рак, тире авырулары, лейкоз, радиация, паралич, ишетми торганнарны дәвалар өчен 30 һәм аннан да күбрәк сеанслар кирәк. Төзәлү вакыты да 1 елдан 3 елга кадәр. Кешенең яшәү рәвеше дөрес булганда гына һәм гаеп үзендә булмаса, төзәлү процессы әйбәт барачак. Төшкән органнар, чыккан куллар беренче сеансларда ук урынына утыра һәм кеше үз хәленең яхшырганын тоя. 20 шәр ел кулын күтәрә алмаган кешеләрнең минем беренче сеанстан ук куллары күтәрелеп, эшли башлаган очраклар күп булды инде.



Рәфыйк Миңнекаев сеанс вакытында.

Безнең бу системаны Җирдә яшәгән бөтен тереклек иясендә дә кулланып була. Эче күпкән сыерны үзебезнең шушы система белән чистарту аркасында үлемнән алып калганым бар. Ике тапкыр ашказанын чистартканнан соң (үй белән) телен асылындырган, үләргә яткан сыер, 15—20 минуттан бөтенләй аякка басты һәм икенче көнне көтүгә йөрүен дәвам итте.

1982 елны Америка галимнәре озон тишеген өйрәнү өчен күккә ясалма иярчен жибәрделәр. Күккә менгәч аппарат бик яхшы эшләде, тикшерүләр алып барды, ә Җиргә төшкәч, пленкаларның буш булуы ачыкланды. Хикмәт шунда: озон тишеге — Космос теле белән аңлатканда, атап эшләнгән урын. Ул — Җир шарының кеше иң аз яши торган өлкәсендә ясалган. Аннан кергән нурларның зыянына караганда, безнең Җир шарыннан пычрак чыгуның файдасы күбрәк. Бу — Җир шарындагы зарарлы һава чыга алсын өчен эшләнгән урын. Аның зурлыгын үзгәртмичә тотып торучы, шуның өстендә эшләүче аерым роботлар бар. Моны гади кеше гади күз белән күрә дә, белә дә алмый. Болар турында үтәли күрү сәләте булган, галәм белән турыдан-туры элемтәгә керә ала торган кешеләр генә белә ала.

Әгәр дә Җирдә яшәү бүгенге көндәгечә дәвам итсә, безне һәлакәт көтә. Безгә һәлакәтнең еллары, көннәре дә мәгълүм. Яшәү рәвешен үзгәртә алмасак, һәлакәт булыр алдыннан аңлы кешеләрне икенче планетага күчереп торасы була. Ә аңсызлар монда калып югалачак. Җир шары су басулар, жир тетрәүләр белән бетәчәк. 13 ел тәнәфестән соң, бүтән планетага күчерелгән кешеләрне алып кайтып, Җирдә яңадан тереклекне башлыйсы була.

Җир шарындагы халыкның яшәү рәвешен үзгәртә алсак, аң дәрәҗәсе күтәрелсә, Җирдә һәлакәт булмас. Яшәүне дәвам итәчәкбез.

Кешенең яшәү рәвеше дөрес булса, аң дәрәҗәсе югары булса, ул авырып үләргә тиеш түгел. Үзенә бирелгән гомер белән, авырмыйча гына китәргә тиеш. Кеше үлгәч, 40 көннән соң җан күккә күтәрелә. Җан — үлемсез. Анда күтәрелгәч ул йә оҗмахка, йә тәмугка эләгә.

Минем сеанслар вакытында, Чистай шәһәреннән килгән Рабига апаны, үзенең соравы буенча, күккә күтәрдем. Тәмугны һәм оҗмахны күрсәттем. Аннан соң, сеанслар ахырында, ул анда нәрсәләр күргәнен халыкка сөйләп күрсәтте. Бу хәл Кама Аланындагы сеанслар вакытында булды. Рабига апа хәзер үтәли күрү сәләтенә ия.

Бүгенге көндә безнең Җир шарында гади кеше күзенә күренми торган көчләрнең 280 меңгә якын төре бар. Мин эшли башлаганда аларның кырык проценты ак, алтмышы кара көчләр иде. Хәзер ак көчләр 70 тән артты. Кара көчләрне җиңү гади экстрасенс көченнән килә торган эш түгел. Кара көчләр безнең Җирдә яши торган йомшак холыклы кешеләрдә, психик авыруларда һәм алкоголикларда була. Шуңа күрә, психик авыруларны һәм аракы эчүчеләрне медицина юлы белән дәвалауның нәтиҗәсе юк һәм була да алмый. Аларны нәтиҗәле дәвалап, кеше хәленә кайтару өчен, янында йөри торган кара көчләрдән азат итәргә кирәк. Югарыда сөйләп киткән эшләрнең берсен дә гипноз белән башкарып булмый.

Минем эшләү системасы яңа булганлыктан, кешеләрдә төрле караш туарга мөмкин. Бу турыда газета битләрендә дә мәкаләләр күп басыла. Сеанслардан файда алып сәламәтләнгән авырулардан рәхмәт хатлары килүе мине нык шатландыра. Эшләү системасын дөрес аңлап, карашлары уңай якка үзгәргән, газетага язарга батырчылык иткән халкыма бигрәк тә рәхмәтлемен.

●

## Булмас димә, дөнья бу!

Рәфыйк әфәнде Миңнекаевнең могҗизаларына кеше аркылы ишетеп кенә ышанырлык түгел, әлбәттә, ә инде үз күзең белән күрсәң, үз колагың белән ишетсәң, аның бөтен эше чынбарлык икәненә тәмам инанасың! Минем үземнең кеше көлдерер өчен әкиятләр, юморескалар язганым бар. Дөньяда булмаган хәлләрне уйлап тапканыма чынлап та горурланып йөри идем.

Ә Рәфыйк әфәнде миннән берничә мәртәбә уздырып җибәргән, ул чынбарлыкта кеше әгъзаларын озынайта да, кыскарта да, умыртка баганаларын турайта, төзәтә! Кыскасы шул — кеше ышанмаслык могҗизалар булса да, аның эшләре — чынбарлык, фактик гамәлләр!!.

Мин Рәфыйк әфәнденең савыктыру сеансларында журналист буларак айлар буе утырдым, башта шикләнсәм дә, соңыннан аның савыктыру сәләтенә тәмам ышандым. Бу яңача дәвалау эшен аңлар өчен иң элек Ходай Тәгаләнең барлыгына инанырга кирәк, чөнки Рәфыйк Миңнекаев илаһи көч белән эш итә. Иң әүвәл аның «Уй белән операция ясау» дигән процедурасын тикшереп карыйк.

Савыктыручы сәхнәдә микрофонын тотып утыра, ә пациент залда, яисә фойеда. Ул авыруны күрми дә, күрүнең хаҗәте дә юк, ә шулай да ул аның тәненең кирәк җирен кайсы ягыннан теләсә, шул ягыннан, якынайтып кына җентекләп карый ала. Тәннең тышкы ягын гына түгел, эчке органнарны да, якынайтып, кирәк икән зурайтып, хәтта молекулаларны да күрә, җентекләп тикшерә ала! Ул гына да түгел, Җир шарының икенче ягында булган объектны да шулай ук якынайтып, ап-ачык итеп күрә һәм тикшерә ала! Мондый мөмкинлек күрәзәче (күңел күзе белән күрү) сәләтенә ия булган кешедә генә була. Аны урыслар ясновидение диләр.

Рәфыйк Миңнекәевнең Аллаһе Тәгаләдән чиксез күләмдә илаһи көч алганлыгы безгә инде мәгълүм. Шулай ук аның вазифалары да ачыкланды. Ул әйтә: «Минем төп максатым кешенең аң дәрәҗәсен, рухын күтәрү, тормышта тәртип, әдәп торгызу! Дингә кайтмый торып, бәндәләрнең әхлакый тәрбиясен югары дәрәҗәгә күтәрү мөмкин түгел! Матди кызыксыну, дөнья артыннан куу безне изге юлдан тайпылдырды, упкынга алып китте!

Икенче бурычым итеп адәмнәрнең физик гәүдәсен чистартуны, савыктыруны күз алдында тотам һәм бу четерекле вазифамны мәгълүм дәрәҗәдә гамәлгә ашырам да инде. Диплом алып эшли башлаганыма 1995 елның мартында өч ел тулды, ләкин эшләгән эшем әле бик аз әле дип саныйм. 1992 елда Казанда эшли башлаган идем, анда сәламәтлек саклау министры тарафыннан килеп: «Дипломыгыз Мәскәүнеке, монда, Казанда бу диплом көчсез»,— дип, сеансны катгый рәвештә туктаттылар. Күпмедер вакыт узгач рөхсәт бирүен бирделәр, тик лицензиядә кисәтеп: «Сеанста авыруларның саны 15 кешедән дә артык булмасын!» — дип язылган иде. Шуның нигезендә, 1994 елның ахырында «Сеансларны бөтенләй туктатабыз!» — дип янаулар булды. Бу бит ничаклы халыкны сәламәтләнү мөмкинлегеннән мәхрүм итү дигән сүз».

Рәфыйк әфәнде киләчәктә бер үк вакытта бөтен шәһәр, республика, бәлки Җир шарының халкын (аерым бер төр авырудан) дәвалау сеанслары үткәрүне күз алдында тота.

Шулай ук радио, телевидение аша кешеләрне савыктыруны җайга салу турында да уйлана милләттәшебез. Ул читтән торып дәвалау практикасын яхшы үзләштерде. Берничә генә кеше булганда табип үз энергиясен бирә, ә халык күп булса, туры Галәм энергиясенә күчерә.

Беренче мәсьәлә — тәрбия мәсьәләсен хәл иткәндә дини оешмаларның ярдәме кирәк. Алар бу мөһим эшне берсүзсез күтәреп алып, киң җәелдереп җибәрергә тиешләр. Рәфыйк әфәндинең савыктыру һәм тәрбияви эшләре — Ходай Тәгаләнең кодрәте белән. Ул биргән көч белән, һәрдаим Галәм ризалыгы нигезендә алып барыла.

Бу сеансларда булган имансыз мөртәт иманга кайтмый калмый, әлбәттә! Менә кайда ул дин әһелләренең тәҗрибә ханәләре! Америка ачылгач, ана юлны беркем дә яба алмаганы безгә мәгълүм бит. Шуның кебек, Рәфыйк әфәндене «ябарга» тырышу да — үзе бер зур гөнаһтыр. Рәфыйк Миңнекәев — Аллаһы Тәгаләнең Җир йөзендәге илчесе! Ә «Илчегә үлем юк!» — диләр! Аны эшеннән аеру гафу ителмәслек хата булыр!

Зур түрәләр тирәсендә берничә шәхси сакчының булуы инде гадәткә кергән, ә Рәфыйк әфәндегә беркем дә кирәкми, чөнки аның як-ягында даими сакчы-фәрештәсе бар, тик без аны күрмибез, үтәли күрергә сәләтлеләр генә күрә ала.

Сеанска килгән кешеләрнең күбесе татар милләтеннән. Рәфыйк әфәнде татар телен яхшы белә, сеансларны күбесенчә туган телдә алып бара. Шул авырулар өчен зур тәнәфестә артистлар чакырып, бушлай концерт бирдерә, ике мәртәбә спектакль дә куйдырды. Болар барысы да туган телгә мәхәббәт уятуда бик кирәкле гамәлләр. Хәзер инде татар һәм урыс телләрендә Рәфыйк Миңнекәев үз акчасына «Әүлия» дигән гәзит чыгара башлады. Киләчәктә бу гәзитне ул башка телләрдә дә чыгарырга ниятли.

●

## Юмарт кеше

Халык арасында йөргәндә Рәфыйк Миңнекәев турында төрле фикерләр, төрле сүзләр ишетергә туры килә. Кем артык мактый, кем бинһая тәнкыйтьли. «Акча өчен тырышадыр, күп миллионнар җыйгандыр инде»,— диючеләр дә бар. Әйдәгез, тәптәнрәк уйлап карыйк әле. Савыктыручы көн

саен, ял көннәрендә дә иртәдән кичкә кадәр эшли. Көнозын бертуктаусыз авыруларны савыктыра, йөрәк, бөер һәм башка әгъзаларын алмаштыра. Пациентлар бу зур операцияләр өчен бер тиен дә түләмиләр. Савыктыручы әйтә: «Әгәр мин акчага хирыс булсам, көненә бер-ике миллиардерны кабул итәр идем дә, күп акча алып, рәхәтләнеп тыныч кына яшәп ятар идем». (Йөрәкне алмаштыру операциясе Мәскәүдә әллә ничә миллион сум тора икән!)

Рәфыйк Миңнекәев әфганчыларны, рак белән авырганнарны гомумән түләүсез кабул итә. Журналистларны, табипларны, мөлаем йөз белән каршы алып, түрдән урын бирә. Әле шушы көннәрдә генә савыктыручы яңа белдерү ясады: «Билет алырлык акчасы булмаганнар миңа мөрәҗәгать итә күрсеннәр, аларга түләүсез керергә рөхсәт итәбез»,— диде. Бөек Җиңүнең 50 еллыгы уңаеннан сугыш ветераннарына махсус сеанслар үткәрде мөхтәрәм савыктыручыбыз.

●

## Халык табибы — юморист!

Һәр сеанста миңа якын кеше җыела, шуларның күбесе авыр хастага дучар булган, хастаханәләрдә ятып та, врачлар ярдәм итә алмаган, терелүдән өмет өзгән кешеләр. Аларның соңгы өметләре — халык табибы Рәфыйк әфәндедә. Савыктыручы шул бичараларны караңгы чырай белән кабул итсә, аларга тагын да авыррак булыр иде, ә табип елмаеп тора, аның йөзендә нур уйный. Сүзләрен гел юмор белән башлый. Пациентның да йөзе ачылып китә, авыр хәлдәге кешедә дә өмет хисе уяна. Мин үзем савыктыручының ачык йөзле, шаян сүзле булуын хуплыйм.

Залдагы һәм фойедагы микрофонга чиратка баскан авыруларның саны кайчакта җитмеш-сиксәннән дә артып китәдер. Табип аларның һәрберсенең гозерен дикъкать белән тыңлый, диагнозын ачыклый. Берничә минутта йә операция ясап өлгерә, яисә ничә сеанс кирәклеген һәм төзәлү вакытын әйтә. Беренче сеанста утырганнарга микрофон янына чыгарга рөхсәт итми, чөнки яңа килгән кеше дәвалау тәртибе белән таныш түгел, юк-бар сораулар биреп, вакытны әрәм итә. Микрофон янына чыккач, кыска гына итеп, булган авыруларның дәвага авыр бирешә торганын гына әйтергә кирәк, башкаларны әйтмәсәң дә, шунда бергә дәвалана, кешенең бөтен организмы сәламәтләнә.

Табип күбрәк сөйләүче әбиләрне туктата алмый аптырап бетә. Кайчакта «Туктамасаң, бәби биреп кайтарам»,— дип шаяртып куркыткач кына әбекәй кинәт туктап кала.

Пациентның озак итеп зарын сөйләп утырасы килә, табипның: «Булды инде, утыр!» — дигән сүзен кайчакта кырыслык дип кабул итәләр һәм шулай сөйләп йөрүчеләр дә бар. Табибыбызның шулай тиз эшләве күбрәк кешене савыктырырга тырышудан килә.

Рәфыйк әфәнденең көч-куәте белән, аның киңәш-нәсихәтләрен бозмый гына дәвалангач, бары да ал да гөл булыр инде дияргә нигез бардыр, әлбәттә. Шулаең-шулай да, тик терелү процессы кешенең үзеннән дә тора. Бу яңа дәвалау системасы Хак Тәгаләнең кодрәте белән башкарыла. Әгәр синең гөнаһларың күп булса, хәзер дә әле өстәлә барса, дәвалау процессы әлбәттә туктала, яисә, һич югында, әкрен бара. Шундый хәл килеп чыга калса, зинһар, Рәфыйк әфәндегә мөрәҗәгать итегез, кеше аркылы яисә почта аша хат җибәрсәгез дә була. Сәбәбен ул үзе ачыклар, чарасын күрер. Рәфыйк әфәнде операция ясаганнан соң, яисә билгеләнгән сеансларны алып бетергәч тә кайберәүләр «файдасы тимәде»,— дип шомланалар, төзәлеп, терелеп җитәр өчен бирелгән вакытны искә дә алмыйлар. Табип юкка гына сабыр итәргә кирәк дип әйтми бит! Аның тагын бер сере бар әле. Мәсәлән, врачлар операция ясап, алып ташлаган бөер урынына табип яңа бөер куйды, ди; УЗИ ул бөерне бөтенләй күрсәтми. Бөер бар ул, бик яхшы эшли, авыртмый да, анализлары да яхшы. Яңа бөерне ул авыру бөер өстенә куюы да мөмкин.

●

Кешеләрнең аң дәрәҗәсе, әхлакый тәрбиясе дә бик түбән булган өчен Ходай Тәгалә Җир шарына җәза бирәчәк диган идек инде. Ул һәлакәт хәзерге урта яшьтәгеләрнең гомеренә туры киләчәк. Һәлакәт көненә, минемчә, нибары 15—20 ел калган. Бу бик аз вакыт бит! Аңа кадәре бөтен Җир шарында яшәгән кешеләрнең аң дәрәҗәсен күтәрергә, әхлакый тәрбия бирергә кирәк. Әлбәттә, бу иң зур инкыйлаб (революция) булачак, тик сугыш белән түгел, солых юлы белән, гомуми пропаганда, аңлату юлы белән. Моның өчен бөтен илләрнең бердәм эш итүе мөһим.

Киләчәктә Рәфыйк әфәнденең дөньяда иң зур дәвалау йорты Казанда булачак. Шунда ук аның резиденциясе дә урнашыр. Дәвалау үзәгенә мөхтәрәм табиб чит илләрдән төрле-төрле белгечләрне сайлап кына үзе җыячак. Ул чакта бөтен дөньяның сейсмология идарәсе Казанда, Рәфыйк әфәнденең кул астында эшләячәк. Алдан төзелгән килешү нигезендә, Рәфыйк Миңнекәев, Җир шарындагы бөтен һәлакәтләрне — җир тетрәү, су басу, таулар җимерелү, корылык, җилдавылларны булдырмау чараларын күрәчәк. Бу зур эшләре өчен Рәфыйк әфәндегә әҗере дә аз булмас. Шул «алтын яңгыры» Татарстанны баетыр, республикабыз, Аллаһы боерса, бер бай утрауга әверелер, даны бөтен илләргә таралыр дип уйларга нигез бар. Тик мәшһүр милләттәшебезгә, Аллаһының илчесенә-арадашчысына, Миңлебай улы Миңнекәевкә исәнлек-саулык телик!

•

## Күккә менү

*Дания Миңнегәрәй кызы Әхмәтҗанова (Балык Бистәсе, Татарстан).*

*1955 елның 1 июнендә тудым. Әнием — Шәрифуллина Гыйлембәнат, әтием — исән түгел.*

*Хәзерге вакытта Балык Бистәсенең Бертуган Бакировлар урамының 57/2 нче йортында яшим. Гаиләбездә 17 яшьлек улыбыз, 14 яшьлек кызыбыз үсә.*

*Ирем белән бик тату яшибез. Үзем Арча педагогия училищесын тәмамлап Сабада эшләдем, Балык Бистәсенә күчкәч, Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын бетереп, бухгалтерия эшенә күчтем. Хәзерге вакытта район кулланучылар җәмгыятенең хозрасчетлы предприятиесендә өлкән бухгалтер булып эшлим.*

Рәфыйк Миңнекәев белән 1993 елның 9 октябрендә Менжинский клубында үткәргән сеансларында очраштым. Аның турында «Татарстан яшьләре» газетасыннан укып белә идем. Газетада аның Галәм белән элемтәсе һәм бик көчле авыруларны да дәвалый алуы турында язылган иде.

9 октябрь көнне беренче сеанста мин күземне йомган хәлдә сәхнәдә Рәфыйк Миңнекәевне башка сурәттә: ап-ак киемнән, башына таҗ киеп тәхеттә утырган хәлендә күрдем. Аның кырыенда берничә бабай утыра иде. Икенче көнге сеанста ике бабай мине күккә алып менеп киттеләр. Андагы пөхтәлеккә, матурлыкка, чисталыкка исләрем китте... Алар миңа шунда калырга тәкъдим иттеләр. Әмма мин җиргә төшерүләрен үтендем. Алар миннән җирдәге кешеләргә ярдәм иткән очракта төшерәбез, дип сүз алдылар һәм алга таба Рәфыйк Миңнекәевнең киңәше, рөхсәте белән кешеләрне әхлаки, рухи яктан тәрбияләргә, физик гәүдәләрен авырулардан арындырырга тиешлегемне әйттеләр. Боларны миңа алар уй белән сөйләшү рәвешендә аңлаттылар. Алга таба табигать тәртипләрен һәм кешенең гәүдә төзелешләрен, әгъзаларын, кан әйләнеше системаларын һ. б. өйрәттеләр. Шулай итеп мин кеше әгъзаларындагы авыруларны кул белән дә тоя һәм күз белән (күңел күзе) дә күрә белә башладым. Алар тагын үземне керләнгән энергиядән чистарынырга, ничек итеп Галәмнән ярдәм сорарга икәнен аңлаттылар. Барысы өчен дә мин Ходай Тәгаләгә, Рәфыйк Миңнекәевкә, бабайларга мең рәхмәтлемен. Алар минем язмышымны көтелмәгән якка борып куйдылар.

Сеанс вакытларында миңа намазга басарга тәкъдим иттеләр. Алга таба бабайлар ярдәме белән мин шәригать тәртипләренә һәм биш вакыт намаз укырга өйрәндем. Беренче вакытларда биш вакыт намазымны бер дә калдырмадым,

хәзер инде Галәм информациясе буенча әйткән вакытта гына укыйм. Догаларны бик еш укырга кушалар. Ходай Тәгаләгә рәхмәтне гел әйтергә кирәклеген дә аңлаттылар. Чөнки Ул барысын да булдыручы бөек зат. Рәфыйк Миңнекәевне безгә ярдәмгә җибәрүе өчен дә Аңа рәхмәт әйтергә тиешбез. Безнең бит хәзер күңелләребез пычрак, яшәвебез бернинди калыпка да сыймый, дөреслек юк, табигатьне үз кулларыбыз белән бетерәбез. Ходай Тәгалә безгә тагын бер тапкыр ярдәм итәргә булды, дөньяны һәлакәттән алып калырга Үзе ярдәмгә килде. Бу ярдәмне тормышка ашырып өчен Ул Рәфыйк Миңнекәевкә үзенең көчен биреп, безнең арага җибәрде. Рәфыйк Миңнекәев шундый авыр шартларда, бернинди каршылыкка карамыйча халык арасында йөри, аларны рухи һәм физик яктан чистарта, терелтә. Аның көче көннән-көн арта бара. Ул бик зур илаһи көчкә ия. Чөнки аңа дөньяны һәлакәттән алып калырга кирәк, моның өчен аң ягыннан да, көч ягыннан да, гомумән бар яктан да камил булу кирәк. Ходай Тәгаләбез аны сайлап алган һәм аңа үз көчен биргән, чөнки безнең аңыбыз бик түбән дәрәҗәдә. Без бит матди тормышка кереп баттык, ә рухи яктан бөтенләй ярлы, түбәнбез.

Мин үзем дә гади халык арасында яшәдем, эшләдем. Үземне чиста, гөнаһсыз кеше дип санамыйм. Гөнаһларыбыз бик күп. Аларны без гел арттырып торабыз. Вакытында мине дөрес юлга басарга ярдәм иткәне өчен, язмышымны үзгәрткәнәре өчен мең рәхмәт әйтәм. Гөнаһлар алар бик күп төрле. Ходай Тәгаләнең барлыгын оныттык, бу иң зур гөнаһ. Кеше рәнҗетү, кеше үтерү, хәрам малдан файдалану, хәмер эчү, гайбәт сату, кеше өстеннән шикаять йөртү, үз гәүдәңне пычрак йөртү, ызгышу-талашулар, артык мал җыю, әти-әнине ихтирам итмәү — барысы да гөнаһлы эшләр. Без шулардан котылып, Ходай Тәгаләдән үзебезне кичерүен чын күңелдән сорый алсак һәм алга таба без аларны кабатламасак, Ул безгә мәрхәмәт итәчәк. Бу дөньяда без бит кунакта гына. Ә теге дөньяга мәңгегә китәсебез бар. Анда Җир йөзендә кылган гөнаһларыбыз өчен тулысынча җавап бирәчәкбез. Шуңа күрә яшәү рәвешебезне үзгәртергә кирәк. Мин үзем моның өчен Рәфыйк Миңнекәевкә мең рәхмәт әйтәм. Миңа моны күккә менгәч аңлаттылар, җәннәтне һәм тәмугны күрсәттеләр.

Күк (Галәм) бик күп катлаулардан тора. Анда күңеле чистарак булган саен кешенең җаны шулкадәр өскәрәк менә. 12 нче катка кадәр материаль кат, 12 нчедән өстә — рухи катлар. Анда ак, чиста көчләр, ә 12 нчегә кадәр күбрәк кара көчләр (катына карап). Кара көчләр Җир өстендә дә бик күп. Мин аларның байтак төрләрен күрдем. Алар белән уй белән сөйләшә идем башта ук. Бу системага мине кертмәскә алар бик күп көч кулландылар, рәхмәт аларга. Хәтта алар миңа әрҗә-әрҗә алтыннар, киемнәр тәкъдим итәләр иде. Аларның кеше башлы кош формасындагысын, елан кебек шуышып йөри торганын, бер мөгезле, сыңар аяклы йонлач хайван рәвешендәгесе, дию пәрие кебекләрен һ. б. төрләрен күрдем. Алар минем аңымны алырга да килделәр, әмма мин бирешмәдем. Мин ярдәмгә Рәфыйк абыйны, фәрештәләрне чакыра идем. Алар миңа көннең теләсә кайсы вакытында ярдәмгә килеп җитәләр иде. Аларга мең рәхмәт. Фәрештәләр ак төстә, кирәк чакта үзләренең формаларын төрле халәткә кертә алалар. Аларны мин өченче күз белән күрәм, уй белән сөйләшәм. Информация миңа төрле формада: аңга, уй белән аңгәмә аша, күреп (язулар үзебезнең алфавит һәм цифрлар белән) тә, кулга да килә. Әмма мин информация алу белән бик кызыксынмаска тырышам. Рәфыйк абый рөхсәт биргәндә теләгән сорауга, үзең теләгән вакытта җавап алырга була. Җавап секунд эчендә килә. Кешенең сәламәтлеген тикшергәндә гәүдәне ничек күрәсе килсә, шул халәттә күрсәтәләр: зурайтып та, кечерәйтеп тә. Әгъзаларны да шулай ук карап була. Кирәк икән гәүдәдән аерып та, зурайтып та күзәтергә мөмкин.

Ярдәм сорый белгәндә Күктән бөтен нәрсәгә дә ярдәм алып була: көнкүрешкә дә, сәламәтлеккә дә. Чын, чиста күңелдән изгелек өчен сорый белергә генә кирәк.

Моңынчы мин гади, гөнаһлы җир кешесе булып яшәгәнмен. Үземнең шундый уңай якка үзгәрүем белән Рәфыйк Миңнекәевкә рәхмәтлемен. Миңа кешеләр: «Син дә безнең кебек яшәгән кеше, нигә сине сайлаганнар?» — дип сорау бирәләр. Мин аларга: «Минем күңелем чистарак, сезгә караганда тәрбиягә җинелрәк, тизрәк биреләмдер, аңым, хиска бирелүем югарырак булгандыр»,— дип җавап бирәм. Дөрестән дә ул шулай. 1993 елның 9 октябрена чаклы булган гомеремне тормышымнан сызып ташладым. Мин аңа кадәр яшәмәгәнмен, ә җан асраганмын. Шуңа күрә минем Рәфыйк Миңнекәевкә халык арасында эшләргә булышасым, халыкның аңын күтәрергә ярдәм итәсем килә. Җир йөзендәге барлык кешеләрнең дә аңнарын чистартырга булышасым килә. Чөнки болай

ахырзаманны без үзебез якынайтабыз бит. Тик моны әлегә аңлап кына бетермибез. Бу бик авыр, катлаулы юл. Әмма Рәфыйк Миңнекаев кебек илаһи көчкә ия, кодрәтле шәхес моны җиңеп чыгар, аңа алга таба юл ачылыр дип ышанам.

●

## Инанмау — иң зур гөнаһ

*Газизова Фәүзия, Яр Чаллы, Татарстан.*
*Ике балабыз бар — кызым Фирүзә, улым Данир.*
*1977—93 елларда шәһәр санитария станциясендә лаборантка булып эшләдем. 1993 елның августыннан Рәфыйк Миңнекаев белән эшлим. Үтә күрүчәнлек (ясновидение) сәләте ачылу 1993 елның унтугызынчы августында булды.*

Адәм баласы дөньяда яшәгәндә Аллаһының барлыгына инанмаса — иң зур гөнаһ шул. Кеше үтерү, рәнҗетү, зина кылу, харам ризык, урлашу, сүз йөртү, гайбәт сату, ызгыш-талаш һәм башкалар — гөнаһлы гамәлләр. Аларны һәркем яхшы белергә тиеш.

Без бит Җиргә кунакка гына килгәннәр, кешенең кадерен белик, гомерне заяга уздырмыйк, бер-беребезгә якты йөзле булсак, комсызланмасак, булганына шөкерана кылып, канәгать булып, файдасын күрсәк, рәхәт яшәргә Ходай үзе юл бирә. Аллага шөкер, хәмер эчү безнең гаиләдә гадәткә кермәгән. Эчү түгел, аны телгә алу да хатын-кыз өчен гөнаһ дип аңлыйм мин. Гөнаһтан котылу чарасын эзләгәнче, баштан ук аны булдырмаска кирәк!

Яхшы кешегә генә түгел, начар кешегә дә чын мөселман яхшылык күрсәтергә тиеш! Аны кунак итә белү, кичерә белү, үз гаебеңне танып, гафу үтенә белү мөһим. Бу инде гөнаһтан арыну чарасына керә. Җәннәт ул — гөнаһсыз һәм гөнаһысы аз булган кешеләр өчен. Җаннар күккә ашса, аларның урыны җәннәттә! Сират күперен чыккан затлар да оҗмахта урнашалар.

Тәмуг ул, гөнаһысы күп булган, җаны күккә ашмаган кешеләр урыны. Тәмуг утының янганын, анда кешеләрнең ничек интегеп, ялварып торганын күрдем. Кара богаулар белән богауланган кешеләрне күреп гыйбрәт алдым. Мин моны сират күперен чыкканда күреп исем китте. Ул сират күпере шундый нык, нечкәдән-нечкә кылдан икән, и куркыныч...

Безнең нәселдә күрәзәчелек белән шөгыльләнүчеләр булмаган. Әнием минем белән авырлы вакытында, балам күрәзәче булсын иде, дип теләгән икән. Аллаһның рәхмәте белән, аның теләге кабул булган ахры, миндә күрәзәчелек сәләте ачылгач, ул бик шатланды. Галәм белән беренче мәртәбә элемтә 93 нче елның августында, Рәфыйк абыйның сеансларында булды, шуннан башланды инде.

Физик гәүдәне калдырып күккә менү бик зур рәхәтлек бирә, чистарынып, ләззәткә чумып, матур җирләрдә булып төшкәч, бик кысн да кебек тоела. Галәм белән элемтәгә кирәк булганда гына керәм. Информацияне үзләре аңлатып бирәләр. Аңлап җиткермәсәң, яңадан кабатлыйлар. Галәм ул, күкнең бик чиста катлавы, никадәр югары булса, шул кадәр чисталык, хозурлык! Түбәнге катлауда кара көчләр күбрәк, мәсәлән, 5, 6, 7, 8 нче катларда. Монда кара көчләр яртысын тәшкил итә, ә яртысы — ак көчләр.

Үтәли күрә башлаган чорда информацияне җиһаннан гарәпчә ала идем. Бу минем өчен сөенеч булса да, гарәп телен үзләштерүне максат итеп куйсам да, информацияне аңлап булмый иде. Шунлыктан үз телемдә — татарча бирегез дип үтенеп сорый идем. Вак хәреф белән язылган булса, тиз укып булмаса, сорагач, эре хәрефләр белән, төрле төсләрдә язып бирәләр иде. ЭВМ аппаратыннан чыккан информация кебек булып тоела иде миңа. Искиткеч тизлек белән бирелә.

Фәрештәләр бик изге затлар. Алар төрле кыяфәттә була алалар: әби, бабай, аккош булып күренүләре мөмкин. Төсләре ак, чиста, төрле зурлыкта булып, кайсы катлаудан икәнен белдерә.

Күкнең бик түбән, матди катлавы — 8 нче катларда, ә инде югары күтәрелгән саен рухи катлаулар китә.

Рәфыйк әфәнденең исеме, дәрәҗәсе, зурлыгы — әйтеп аңлата торган түгел! Ходай Тәгалә аңарга үз көчен, күп кенә вазифасын тапшырып, Җиребезне сафландырырга, аңыбызны үстерергә, Җирне һәлакәттән коткарырга, кешеләрне

савыктырырга, сәламәт акыл белән эш итәргә үзе җибәргән. Ул безнең Җиребезнең Аллаһысы!.. Без аны бик зурлап, иң чиста күңел белән гыйбадәт кылып яшәргә тиешбез! Бу затны Җиргә биргән Ходай Тәгаләгә чиксез зур рәхмәт!!. Күз алдыбызда, Хак Тәгаләнең кодрәте белән эшләп, таң калдыра ул! Бу — күзгә күренеп торган, аңга үтәрлек, тетрәндергеч мисал бит!

Илаһи көче белән, иң яман чирләрдән котылып терелгән меңләгән кешеләрнең, шатлыкларына түзә алмыйча, елый-елый Рәфыйк әфәндегә рәхмәтләр укулары — халык табибының көче-сәләте чиксез икәненә дәлил!

Аяксызны — аяклы, күзсезне — күзле итү, йөрәк, бөер, үпкә һәм башка әгъзаларны алмаштыру — табипның могҗиза иясе икәнен күрсәтә. Бүгенге көндә кешеләрнең язмышын үзгәртү мөмкинлеге Рәфыйк әфәндегә генә бирелгән! Миңнекәевнең сеансларында булып, савыгып киткәннәр икеләтә бәхетле дип саныйм мин, чөнки мондый зат белән якыннан күрешү, сөйләшү — үзе зур бәхет!

●

## Рәхмәтем чиксез

*Шәмсиева Рушания Әхмәтвафа кызы.*

*Әтием — Минһаҗев Әхмәтвафа Сафа улы, әнием — Минһаҗева Тәзкирә Кыям кызы, ирем — Шәмсиев Әмир Нури улы, кызларыбыз — Чулпан белән Айназ.*

*Белемем буенча мин укытучы. Соңгы ун елда укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып һөнәр-техника училищесында эшлим.*

Үтәли күрүнең башы... Ничек килеп чыкты соң әле? Бу — Рәфыйк Миңлебай улы Миңнекәев белән бәйле.

Җәйнең аяз, кояшлы иртәсе иде. Кем инде мондый көнне өйдә утырсын. Билгеле, табигать кочагына тартыла күңел: саф һава, күз күреп туймаслык сихри елга буйлары, гүзәл кырлар, шаулап торган урман. Бергә эшләгән күршеләребез белән табигатьнең иркен кочагына җиләк җыярга дип юл тоттык.

Поселок тормышыннан, таш стеналардан аерылгач безгә табигать — җәннәт булып күренде. Без аңа бераз сихерләнгәндәй карап тордык. Ә җиләк җыярга дип килгәч, карап торып кына булмый бит. Кичен гаиләңне, туган-тумачаны, күршекүләнне хуш исле җиләктән авыз иттерә-иттерә чәй эчәсе бар. Ашыгабыз. Тик җиләкләребез бездән качалар. Иптәшләрем икенче аланга чыгып карарга тәкъдим иттеләр. Китәсем генә килми бит басып торган урынымнан! Үзем чыклы чирәмдә үсеп утырган чәчәкләрдән күземне алалмыйм. Аларның бик кыска гомерле булуларын бераз җәлләп тә куям. Якында гына ирләр печән чабалар. Кызлар инде югала ук башладылар. Адашып калмыйм дип мин дә кузгалырга уйладым. Чү, әллә инде елмайган кояш астында башым әйләнеп китте, миңа җиләкләр: «Без монда бик күп, канәгать бул, китмә»,— дип пышылдадылар. Шулчак чәчәкләрне генә күргән аланым — җиләкле аланга әйләнеп куймасынмы! Аһ иттем. Иптәшләремне чакырып карыйм — ышанмыйлар. «Юк анда җиләк, шаяртма»,— дип ары киттеләр. Мин утырып, җырлый-җырлый җиләк җыя башладым. Бу аланнан киткәндә бик ямансу булды, андагы чәчәкләргә, җиләкләргә ачуланмагыз инде, рәхмәт сезгә, дип, иптәшләремнең ак яулыклары күренгән якка йөгердем. Килеп җитсәм ни күрим... «Нишләп кенә йөрдегез сез, кая җиләкләрегез?» — дим. Шулчак, савытымнан аларга да өлеш чыгарырга кирәк, дигән уй килә. Ә җиләкләрем «Ышанмадылар бит, ышанмадылар»,— дип пышылдап куйгандай булдылар. Бу — могҗизаларның башы гына булган икән.

Өемә кайткач, чиләгемдәге кып-кызыл җиләкләргә сокланып, бер 10—15 минутка йокыга киткәнмен. Сәер төш дисәң төш түгел, бер хикмәтле вакыйга күрдем.

Мөлаем йөзле, нурлы карашлы бер кеше кулына ике балык тотып өйгә керә. Ничек тотып тора, дим икән. Нинди зур балыклар, авырдыр бит! Балыкны кулыма сузды бу. Балыклар күбәя башлады. Бүлмә тулы балык. Түшәмгә хәтле. Шунда уянып та киттем. Аптырап куйдым. Әллә ниләр керә инде башка, дидем. Ләкин шул көннән башлап, ничә көн җиләккә, гөмбәгә барсак та, иелеп эшләүдән дә бер дә башымның авыртмавына сәерсендем бераз. Җиткән икән минем дә сәламәтләнәсе көннәр! Арыдым бит инде анальгин ашаудан. Кан басымы гел югары, хәтта 210 га менгән очраклары була иде. Тик шифаханәгә йөрисе килми, аяк тартмый.

Сер бирмәскә, форманы югалтмаска тырышам. Ял вакыты булса да, табель тутырырга дип, училищега чакырдылар. Казанда бер хезмәттәшем экстрасенс килә, әйдә барыйк, ярдәме тимәсме үзеңә диде. Кая ул, экстрасенсларга йөреп карадым инде, көне-сәгатендә әйбәт булгандай тоела да, икенче көнне кабат җил-давыл кебек урый-урый башка ябыша. «Юк» — дидем катгый гына, туйган имеш ул «шарлатаннардан»! Кинәт борылып карасам, бүлмәнең телефон аппараты урнашкан өстәл янында бер кеше басып тора. Кая күрдем соң бу кешене, дип уйга калдым. Капылт зиһенем ачылып китте: теге, балыклар биргән кеше түгелме соң бу? дим. Әйе, әйе, нәкъ үзе! Һәм мин, шунда ук урындык алып, үземнең эш эшләргә килгәнемне дә онытып, Актлар залына кереп киткәнмен. 1993 елның 16 июль көне иде бу — Рәфыйк абый ярдәмендә якты дөньяда сабыйларча авырмыйча, җиңел итеп, елмаеп, күңел тулы яктылык, рәхәтлек тоеп яңадан яши башлаган көнем.

Кереп утыруга ук күземне ниндидер бер көч йомдырып куйды, сеанс тәмамланды. Елаудан шешенеп беткән күзләрем кинәт Актлар залындагы барлык тирә-юньне яктырак күрә башлады кебек, хәтта тәрәзә артындагы күл, йортлар да бик якында кебек.

Ә нәрсә күрдем соң мин? Тау башыннан агып килгән, сусауны баса торган нинди су иде соң әле, битемә тигергән саен бөтен гәүдәгә чәчрәгән су ничек җиңеләйтә тәште соң мине? Ә кояш ничек янәшәмдә торып та пешермәде соң мине, ә йолдызлар... Тукта, тукта, дидем үземә, хыялланып китмә әле син, бу гипноз белән сәерләнеп калмагаек, тагын...

Чыккач, Рәфыйк абыйга рәхмәт әйтеп, өйгә киттек. Зал тулы халык та, дусларым да күземә күренмәде. Рәфыйк абыйның йөзе гел күз алдында. Ә үзем уйлыйм, күргән төш белән бу училищеда очрашу очраклы булмаган, дим. Соңыннан шуны аңладым: без җиләк җыйганда Рәфыйк абыйның Нажия апа белән бергә Арча районында сеанслар биреп йөргән чагы булган. Һәм нәтиҗә — ул вакытта, читтән торып, бер белмәгән-күрмәгән кешегә — миңа Рәфыйк абый ярдәм иткән. Һәм бүгенгесе көнгә хәтле минем бер генә дару да капканым юк, Аллага шөкер. Иксез-чиксез рәхмәтләремне Рәфыйк абыебызга гомеремнең соңгы сулышына хәтле әйтсәм дә аз дип уйлыйм. Мөлаем йөзле, тыйнак, үтә гадел, шәфкатьле, бик сабыр, шул ук вакытта юморга бай шәхес — Рәфыйк абый бүгенгесе көндә әйтеп бетергесез зур көчкә ия. Кадерен белсәк иде! Рәфыйк абыйның кешелек дөньясын үзенең Ходай Тәгаләбездән килгән көче ярдәмендә гөл-бакчага әйләндерәсе килә. Кешеләрне, тереклекне тулаем афәттән коткарасы килә.

Аллаһы Тәгаләбез биргән зур түземлек һәм сабырлык белән ул безнең аңыбызны үстерү өстендә эшли. Кешеләрдә мәрхәмәт, әдәп, тыйнаклык, вәгъдәдә тору, гаделлек, тырышлык, татулык сыйфатларын көчәйтә. Шуның ярдәмендә гасырлар буена җыелган, Җир анабызны инде һәлакәткә китереп җиткергән явызлык, кан кою, тупаслык, саранлык, көнчелек, хыянәт, икейөзлелек һәм башка күп тискәре сыйфатларны һәрбер кеше үзендә бетерү дәрәҗәсенә ирешкәч кенә Җир шарын саклап калып булыр. Шуңа ирешү өчен Рәфыйк абый армый-талмый эшли.

Халкыма үзебезнең рәхәт мизгелләрне тулаем аңлатып бирәсе килә, рәсемнәр аша чагылдырасы килә, җырлар-шигырьләр аша тудырасы килә. Үзебездә җыелган ул җыр, шигырьләр, рәсемнәр, мөгаен, икенче җыентык булып чыгар, һәркем үзенең Аллаһы Тәгаләбезгә, Рәфыйк абыебызга, ак бабайларга булган чиксез рәхмәт сүзләрен җыентыкка тәкъдим итәр дип уйлыйм.

Чөнки гамәли тормышта табигать ничек кенә матур булса да, безгә күрсәткән урыннар — оҗмах — күп тапкырлар, аңлатып бетермәслек дәрәҗәдә сокландыгыч. Аны сүз белән, гади төсләр белән генә чагылдырып бетереп булмыйдыр. Җирдәге табигать аңа караганда күп тапкырлар төсенең ялтыравын яшерә бездән. Чөнки без аңа күңел күзебез белән карый белмәгәнбез. Тирә-юньне пычраткач, аның ялтыравыгын тузан каплый. Агачлар сындырудан сыкрыйлар, җәнлекләр ату тавышларын ишеткәч үксеп җылыйлар. Ә кешеләр күзләре йомык халдә җимерәләр, ваталар, үтерәләр, тарткалашалар, чөнки аларда нәфесчелек, көнчелек, явызлык өстенлек ала. Ул ялгышлыкларны кабатлый-кабатлый кеше тома сукыр, чукракка әйләнә бара. Өлкәннәр: «Бала хакына яшим», дияргә яраталар. Бу кечкенә генә җөмлә бик олы мәгънәгә ия. Баласын ашатып-эчертеп, киендереп, тормышында матди ярдәм күрсәтү дип кенә аңлаучылар да бар бу фикерне. Балаларың өчен яшәү ул — үз гонаһларыңны, нәзерләреңне аларга калдырып китмәү дигән сүз. Шул чакта гына, дөньяга сау-сәламәт балалар туар

(гарип, чукрак, телсезләр саны кимер), авырулар саны көннән-көн азаер. Кеше гәүдәсен каплап торган кара бозыклык (нәселдән килгән) юкка чыгар.

Һәр эшләгән эшенә, көн тәмамланганда анализ ясап, Аллаһы Тәгаләнең барын да күреп торуларын онытмыйча, гөнаһлы эшләр эшләүдән куркып-тыелып яшәү ул — балалар хакына яшәү.

Менә шулай итеп, беренче карашка бик гади генә тәрбия эшләрен Рәфыйк абый сеанс саен һәркем белән дәвам итә. Алай гына да түгел, Рәфыйк абый безнең уйларыбызны да сеанстан соң да контрольдә тота. Рәфыйк абыебызның карашыннан ук, хәтта йөрешеннән үк безнең тәртиптән канәгать булу-булмавын аңлап була. Күп вакыт без бик авыр формулаларны чишәбез, ә кайчакта гади генә сораудан да югалып калган кебек булабыз.

Ә Рәфыйк абый үз эшен иң гади сораудан башлый. Һәм таләпне көннән-көн арттыра бара... Һәм, ниһаять, килеп җитәр Рәфыйк абый көткән көн — Җир йөзендә тынычлык урнашыр, гаделлек, намуслылык, тырышлык, дөреслек өстенлек алыр. Рәфыйк абый башлаган эш эзсез югалмас, киресенчә, ул башкарган эшләр зур җиңүгә китерер. Кеше — кеше исемен йөртергә лаек булыр.

Бу космик дөньяны тырышып якыннанрак тасвирлыйсы килә. Сеанс вакытында без Рәфыйк абыебызның зал тулы Ак бабайлар белән бергә, Аллаһы Тәгалә рөхсәте белән эшләгән, чиксез күп операция башкаруын карап утырабыз. Ул минутларда ни эшләнгәнен күреп кеше хәтта аңын югалтырга мөмкин. Рәфыйк абыйга көч исәпсез килеп тора. Һәр кеше янында — бабайлар. Берәүнең янында — 2, икенчесе янында — 5, ә өченчесе янында — 10... Алар авыр-авыр операцияләрне Рәфыйк абый кушу белән башлыйлар. Һәм, бер минут та үтми, сәхнәдә басып торган, корсет кигән авыруларның, сколиоз, кифоз диагнозы белән чыккан кешеләрнең, хәтта урыннарында утырганда карап кына утырам бит дип уйлаган кешеләрнең дә умыртка баганалары турая, турая, турая.... Кеше күзләрендә рәхмәтле күз яшьләре чагыла. Рәфыйк абыйның күзеннән тәгәрәп төшкән бөртекләрне бары без — ярдәмче кызлар гына — күрәбез. Һәм олы шәхесебез, табибларның табибы, укытучыларның укытучысы Рәфыйк абыебыз белән бергә шатлану минутлары кичерәбез. Рәфыйк абыйның яшьле күзләрен аска иеп куйганда алар өчен йөрәген кызганмаганын сеанста утырган һәммә кеше дә аңлый торгандыр. Рәфыйк абыйга бер-бер артлы ике яклап микрофоннан сораулар бирәләр. Күпме сорау! Ничек түзә икән, диясең кайвакыт. Һәр сорау артында кеше язмышы, ә ул кеше тагы туганнары, якыннары хакында да уйлап утырса, бер сорау эчендә мең сорау барлыкка килә.

Әйтик, кемдер үзен Галәмгә мөнгезүләрен сорый. Рәфыйк абый елмая. Ә без җавап бирәбез: «Юлны яптылар». «Ни өчен?» — дип аптырый халык. Ничек инде? Кылган гөнаһлар, нәзерләр кая китсен, гафу үтенергә кирәк. Ә юк, гафу күктәгеләр тарафыннан җиңел генә кабул ителми. Шулчак Рәфыйк абый, үзенә биргән көчтән файдаланып, кешене авыр хәлдә калдырмаска тырыша. Ул аңа аш уздырырга, аш мәҗелесе кабул булсын өчен таләпләрне онытмаска куша. Дин әһелләреннән дә Коръәнне дөрес, чиста күңел белән уку сорала, ашта утыручылар сүз йөртмәсен, зарланмасын, уфтанмасын. (Ничек инде моңарчы эчеп, кеше кыерсытып, малга табынып йөргән мулла-абыстайлар ашны күктәгеләр таләп иткәнчә җиренә җиткерә алсын!) Ә инде аш вакытында кеше сөйләү — гөнаһ. Чын күңеленнән әзерләнгән кеше ашын юкка чыгару түгелме бу! Димәк, уйланырга кирәк: кемне, нинди кешеләрне чакырырга?

Менә тагын үтенеч. Һәм авыруны Рәфыйк абый бина өстендә торган аппаратка тапшыра. Кеше үзен очып йөргәндәй хис итә башлый, аны Рәфыйк абый тиеш дип санаган вакыт эчендә операция ясап кире кайтаралар. Кайбер авыру сизә үзендә нәрсә эшләнгәнен. Ә без аның ничек итеп эчке органнарын алып, юдырып, кире урынына урнаштырганны карап торабыз. Операция тәмам. Авыру елмая, берни булмагандай торып китә, авыртуны инде сизми, хәтта биеп күрсәтә.

Могҗиза! Әйе, Рәфыйк абый — могҗиза иясе. Сораулар, сораулар. Алар агыла да агыла. Берәү дә җавапсыз, җылы карашсыз калмый. Ә күңеле белән чистарак кешеләр үзләренең дә эш башкаруларын тоя ук башлыйлар. Тәннәрендә авырткан җирләре кузгалып китә. Менә бер хатын-кыз кычкырып-кычкырып гафу үтенә. Гаебеңне тану сәламәтләнү процессын бик күпкә тизләтә.

Сорауларга җавап бирү тәгәлләнә, ә залдагы кешеләрдә сораулар бихисап. Шул чиксез сораулар аша Рәфыйк абый инде күзләрегезне йомыгыз, уйларыгызны юкка чыгарыгыз, дип әйтә. Залда кинәт тынлык урнаша. Һәркем чәчләреннән шпилька, кулдан сәгатьләрне салып, аяк-кулларны кушырмыйча сихри космос дөньясына юнәлә.

Без кечкенәдән әкиятләрне ярата идек. Дөрес яраткандыз, чөнки бала күңеле — чиста кәгазь кебек. Рәфыйк абый сабырлыгы, ихтыяр көче белән кешегә әкиятнең инде бүген чынбарлыкка аша барачагын аңлатып килә.

Үземнең Әкият дөньясына кучүемне тасвирлап китәм. Рәфыйк абый күзләрне йомдыруга, гәүдә бер хәрәкәт кичереп ала да, физик тән бер тышча кебек утырып кала, ә чынлыкта гәүдә күккә күтәрелә башлый.

Елгалар, таулар... Аска карыйм: кечерәйгәннәр, хәтта күренми дә башладылар. Ә менә бер илаһи көч алып менә, отыры менә. Инде болытларга менеп життек. Без жирдән күреп бетерә алмаган һәрбер төс, үзеннән нурлар чәчеп, төрле төсләргә керә башлый. Күк йөзе жиде генә кат түгел, чиксез, чиксез. Ниһаять, Кояш. Аның нурлары якыннан көйдереп алыр кебек. Ә ул синең сокланып торганыңа елмаеп куя, ягымлы гына үтә дә жылылык тарата.

Һәм менгән саен төрле бүлмәләргә керергә рөхсәт бирәләр. Фәрештәләр, ак бабайлар... Ак бабайларга уй белән гел рәхмәтле булып торасың.

Аннары икенче ишектән үтәбез. Нинди генә агачлар, нинди генә жәнлекләр, нинди генә кошлар юк! Безнең жирдәге кошларга охшашлары да бар, аерымраклары да бар. Әкияттәге кебек, алар аралашалар. Сине дә хөрмәтли беләләр. Син дә аларга рәхмәтле булып йөрисең.

Яңадан ак бүлмәгә керәсең, анда утырталар, булган авыруларны әкрен генә сыпырып куялар да, жиңеллек тоеп уянасың. Әгъзаларны сөт кебек куе суларда юдырып алалар. Кире урнаштырып куялар. Терраса кебек жирдән чәчкәле бүлмәгә күчеп, өстәлдәге ризыкларга карыйсың. Йә, Хода, нинди генә жимешләр юк! Пыяла кебек үтә күренмәле йөзем жимешләре. Бер бөртегенә карап та сихәтләнерсең, күз белән дә тамагың туяр кебек. Алма — әкияттә тасвирланган алмага караганда да алсурак, алтынсурак. Тотып карасаң да тамак туярдыр шикелле. Су... Бер генә тамчысы да чылтыраган чишмәдәй, бөтен халкымның сусавын басардай...

Менә шулай ишек ачылган саен яңа ачыш. Һәм ул чиксез кебек. Берсе дә бер-берсен кабатламый. Яңалык өстәлә бара. Минем, Жәннәт шушыдыр инде, дип әйтәсем килә.

Кара көчләр... Кара көчләр турында бала чакта әкияттә генә ишеткәнем бар иде. Ә бүген аларның булуы хакында мин шикләнмим.

Ничек итеп күрдем мин аларны? Сеанста утырабыз шулай. Бер ханым микрофоннан сорау бирә. Рәфыйк абый: «Карагыз әле, кызлар, кем бар анда?» — ди. Ни күрик, теге хатын-кызның аркасында жанварга да, ир кешегә дә охшаган бер албасты муеныннан эләктереп тора. Хатынны артка таба өстери. Бераздан теге адәми-жанвар китә башлады. Бу — Рәфыйк абый эшли башлады дигән сүз. Коточкыч күренеш. Жанвар китәргә теләми. Ләкин Рәфыйк абыйга бер генә кара көч тә каршы тора алмый. Бозыклык һәм кара көчләргә каршы торырдай көч Аллаһы Тәгалә ризалыгы белән, бары тик Рәфыйк абыйга гына бирелгән. Галәмнән килгән информациягә караганда, бу гасырда мондый илаһи көчкә ия булган башка кеше котелми.

●

## Сүзенең нигезе — Коръәндә!

Яхшылык белән явызлык бертигез булмас, чөнки яхшылыкта файда һәм савап бар, явызлыкта зарар һәм газап бар. Әгәр сиңа берәү явызлык кылса, син аңа жавап итеп яхшылык кыл. Ул кеше сиңа явызлыкны дошманлык илә кыладыр, әмма син сабыр ит һәм дә явызлыгына каршы һәрвакыт изгелек ит. Соңра ул синдә явызлыкның юклыгын белеп, явызлык итүеннән туктар һәм тәүбә итәр, синнән гафу сорар, аннары бер-берегезгә якын дус булырсыз.

Ләкин бу эшне һәркем эшли алмас, мәгәр көчле, иманлы чын сабыр мөселманнәр генә эшли алыр, вә явызлыкка каршы изгелек итү һәрбер кешегә бирелмәс, мәгәр олуг бәхетле кешегә генә бирелер.

Әгәр явызлык итүчегә изгелек итәргә шайтан сиңа ирек бирмәсә, шайтанның шәреннән Аллаһыга сыен, ул сине шайтан вәсвәсәсеннән саклар. Аннары явызлыкка каршы изгелек итә алырсың, ул бит Аллаһы — ишетүче вә белүче.

Рәфыйк әфәнде: «Чын иманлы, сабыр булган хәлдә, үзегезнең яшәү рәвешегезне Аллаһы кушканча алып барсагыз, бер-берегезнең арагызны төзек кылсагыз, адәм баласының җаны да, тәне дә төзек булыр»,— дип аңлатты.

Менә шул Рәфыйк әфәнде сеансларына йөргән вакытта адәм баласының сәламәт булуы өчен — тән сәламәтлеге, җан сәламәтлеге Аллаһы кушканча булган вакытта гына яшәү рәвеше дөрес икәнен аңладык.

Адәм баласы һәрвакытта иман китереп, Аллаһыны танып, изге гамәлләр кылганда бер-берсе белән хаклыкта һәм сабырда булса, ул һәрвакытта да сәламәт булыр. Менә шушы сыйфатларны без Рәфыйк әфәндене авызыннан ишеттек һәм аның һәрбер әйткән сүзенең Аллаһының илһамы белән әйтелгәнен аңладык. Аллаһы Тәгалә аңа бу изге эшендә хәерле ярдәмен бирсен. Амин.

Искәрмә: Рәфыйк әфәндене вәгазьләре Коръәннең 34, 35, 36 нчы аятьләре нигезендә корылган.

Наил хәзрәт.
Казан.

●

## Хәзрәт сүзе

Рәфыйк әфәндене сеансларында булдым, бер күреп, танышып кайтасым килгән иде. Әлбәттә, бик күп эшләренә гаҗәпсенеп карасам да, хатакимчелекләрен дә күреп, күңелемдә бераз ризасызлык та туды. Гаҗәпләндергән нәрсә: үзенең тәрҗемәи хәлен сөйләгәндә күпләргә үрнәк булырлык гаиләви тормыш коруы, хәләл-харамны аера белүе, дөньяга ачык күз белән каравы, бу чорда гаҗәеп бернәрсә дип әйтер идем.

Өч балага ата буларак тормышын матур итеп, Аллаһы риза булырлык, хатынын-балаларын Аллаһы кушканча, дини-дөньяви тәрбия бирә алса, мин хәер-догада калыр идем.

Икенче күренеш — сыйфат: хәсне-холык, мин аны күркәм холыклы дип әйтер идем. Берәүгә дә ачуын чыгармый, тыныч мөгамәләдә җавап бирә белә.

Өченче күренеш сыйфаты — Аллаһыга, иманга ышануы, үзенең сөйләвенә караганда: «Аллаһы Тәгалә мине сайлады изгелек кылу өчен, акчага-малга кызыкмаган һәм дәрәҗәгә кызыкмаган өчендер»,— ләкин күңеленә тәкәбберлек хисе кермәсә иде, дигән теләктә калам. Меңләгән халыкны үзенә җәлеп итеп, буйсындыруы мине бик гаҗәпләндерде. Һәрбер кеше авыруыннан гаҗиз булып, сәламәтләнү өмете белән килгән. 12—15 сеанс кабул итүчеләрне күрдем. Бер көндә өч сеанс, иртәнге сәгать уннан, кичке сәгать җидегә кадәр, һәр сеансы ике сәгать. Сеанс вакытында ник бер тавыш булсын! Шуның бер сәгатен бөтенләй дөньясыннан ваз кичеп, сабый баланың авызына имезлек каптырып йоклатамыни! Бу үзе искиткеч рухи тәрбия дип таптым. Менә сиңа авырулар, бер ыңгырашкан кеше юк!

Дүртенче күркәм сыйфаты — авыруларга гөнаһларыгыздан тәүбә итегез, дип, мәҗлес җыеп Коръән укытыгыз дип боеруы. Аллаһының боеруы нәкъ шулай. Иманлы адәм беренче ярдәмне Аллаһыдан сорар. Аллаһы Тәгаләгә табынса, ярдәмен бирер. Мин анда Рәфыйк әфәндене ярдәмче кызлары белән танышып сөйләштем — Равилә һәм Зөһрә иде. Алар да: «Без Аллаһыга ышанабыз, башкаларга да Аллаһыга ышаныгыз дип әйтәбез»,— диләр. «Лә илаһа иллалаһы»,— кәлимәсен әйтегез дип, тәкъдимнәр итәбез»,— диләр.

Тагын мине бер гаҗәпләндергән нәрсә — бөкреләре чыккан, сөякләре зәгыйфь булганнарны төзәткән эшләренә, кайбер табипларны шаһит итеп куеп, шаһәдәт бирүләре, шул авырулар елый-елый рәхмәтләр әйтүләре, минем дә күз яшемне чыгара иде.

Дөрес, мин аңлыйм, авыру хәлен авыру гына белә. Минем үземдә дә күренеп торган авыруларым бар иде, ләкин мин бу турыда Рәфыйк әфәндене үзенә әйткән идем дә, сеанста торып әйтмәгәнгәдерме, миңа тәэсир итмәде, файда бирмәде.

Инде кайбер кимчелекләрен дә әйтми булмый. Беренчедән, Рәфыйк әфәндене үз күз алдында бик күтәреп мактыйлар. Рәсүлулла пәйгамбәребезнең хәдисе —

«берәүне күз алдында мактаучының йөзенә туфрак сибегез»,— диган. Бу мактау Рәфыйк әфәндегә зарар итү була. Адәм балаларында тәкәбберлек хасил була.

Минем Рәфыйк әфәндене яманлап әйтүем түгел, бәлки дин мәсьәләләрендә, Коръән аятьләренә эшләгән эшләре, сөйләгән сүзләре муафыйкмы?

Аллаһы каршында үзенең бурычымны үтәдем, дип әйтер идем. Рәфыйк әфәнде рөхсәт итсә, аның сеансларына барып, халыкларга вәгазь сөйләр идем, бәлки аның үзенә дә файдасы булыр иде дип, әйтәсем килә.

Гаптерәүф хәзрәт.
Казан.

●

## Аллаһының кодрәте белән

Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахим.

Соңгы елларда халыкның яшәү рәвеше дөреслектән тайпылды, ул ялгыш юлдан бара — хәмер эчә, зина кыла, кешене рәнҗетә, бозыклыкка бирелә, гайбәт сөйли, кеше үтерә, авыру тарата торган кораллар чыгара. Болар барысы да Аллаһының кодрәтенә каршы чыгу. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә Җир йөзенә төрле афәтләр, бәла-казалар, төзәлә алмаслык, бәндәләр җәфа чигәрлек авырулар җибәрә. Болар — Җир йөзендә үзең, нәсел-нәсәбең кылган гөнаһлар өчен.

Кичекмәстән бәндәләр тәүбәгә килергә, Ходайдан гафу үтенергә тиешләр! Шушыларны халыкларга аңлатыр өчен, Аллаһы Тәгалә: «Җир йөзенә изге бәндәләрне, табипларны һәр йөз ел саен җибәреп торырмын»,— диган.

Иншалла, шуларның берсе күз алдыбызда, Ходай Тәгаләнең кодрәте белән кеше тәннәрендә булган авыруларны бетерүче Рәфыйк әфәнде Миннекаев. Ул медицина әһелләре күз алдында, бер-ике минут эчендә кыйгайган умыртка баганасын турайта ала. Бу берничә кешедә берьюлы эшләнә.

Аннары зал уртасындагы микрофонга бер-бер артлы авырулар үзләренең күз яшьләренә төрелгән рәхмәтләрен белдерү өчен һәм авыруларын әйтер өчен чыгалар. Рәфыйк әфәнде һәрберсен дикъкать белән тыңлап, үзе сәхнәдә утырган көенчә карап, диагноз куя, кайсыларына шунда ук ярдәм итә, кайсыларына ярдәмчеләре белән киңәшеп, ничә сеанс алу һәм төзәлеп бетү вакытын билгели.

Бу эшләр шифаханәләрдә бүгенге көндә миллионнар торадыр, ә ул Ходай ризалыгы өчен бушка эшли. Ә инде гарип балалы аналарга: «Бу сезгә Аллаһының җәзасы. Тәүбә итегез, Коръән укытыгыз! Кабул булса, минем ярдәмемнең нәтиҗәсен сизәрсез, балагыз савыгыр!» — ди.

Соңыннан залны тынычландырып, үзенең киңәшләрен биреп, сеансны башлый. Сәхнәдән залга талгын гына шифалы җылы агым бөркелә, һәр рәткә, һәр кешегә Аллаһының кодрәте бу изге кешенең ярдәме белән бәндәләргә сәламәтлек иңә. Бу гаҗәеп кешенең эшен фән, медицина өлкәсендәге эшлекләр һәм дин галимнәре белән киңәшеп эшләгәндә планетабызны начарлыктан, баткаклыктан коткару мөмкин булыр иде. Кешенең аң дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм итәр иде. Шәхсән мин үзем шундый фикергә килдем.

Рәфыйк әфәндегә һәм аның ярдәмчеләренә, шушындый могҗизалар күрсәткәне өчен, Алланың рәхмәте яусын! Я раббил галәмин, зур ихтирам белән

Рәфгат хәзрәт Харрас.
Яр Чаллы.

●

*Үзе дә Рәфыйк Миңнекәевнең савыктыру сеансларында 70 ләп сәгать утырган журналист һәм язучы Саимә Ибраһимова шулай ук бу сеансларга йөргән биология фәннәре кандидаты Казан дәүләт медицина университетының фәнни хезмәткәре Е. Г. Щеглова белән әңгәмә үткәрде. Рәхим итеп шул әңгәмә белән танышыгыз.*

*— Елена Геннадьевна, халыкара «Планетаны яңарту» ассоциациясе вице-президенты халык табибы-экстрасенс Рәфыйк Миңнекәевнең эшләгән эшен сез фән күзлегеннән чыгып ничек аңлатыр идегез?*

— КДУның биология факультетын тәмамлаган биолог буларак, шулай ук шәфкать туташлары әзерли торган уку йортын, медицина институтының дүрт курсын тәмамлаган, анатомияне белгән торган кеше буларак, кайбер нәрсәләргә шактый объектив бәя бирә аламдыр дип уйлыйм.

Беренчедән, анатомияне белгән, умыртка баганасының төзелешен һәм аның нормаль бөгелешен белгән кеше буларак, мин умыртка баганасының тураюын, умырткаларның үз урынына урнашуын үз күзем белән күрдем, күтәрелгән яки төшкән калак сөякләрен үз урынына урнаштыручы мускулларның хәрәкәтен үз күзем белән, визуаль рәвештә күрдем.

Икенчедән, шул хәлләрне күзәтеп торучы буларак, яман шеш, бавыр циррозыдыр кебек үтә җитди диагнозлар белән килгән кешеләрнең урыннарыннан торып, йә хәлләре җиңеләйгән өчен яисә бу авырудан бөтенләй арынганнары өчен табипка әледән-әле рәхмәт укуларын өзлексез күзәтеп торам. Шулай булмаса, рак яисә шуның ише башка каты авырудан котылдым дип кеше кызык өчен генә әйтер иде микән.

Кызганычка каршы, авырулар, чирләреннән арыналар да, бәхетләреннән нишләргә белмичә, Рәфыйк әфәнде алдындагы бурычларын да онытып, чыгып чабалар. Алар үзләреннән соң килеп дәваланырга тиешле кешеләр алдындагы бурычларын да исләренә төшермиләр, шушында ничәдер сеанста сихәтләнүләре турында килеп әйтергә, чирләреннән арынулары хакында дәвалаучы врачларыннан белешмә китереп бирергә кирәклеген дә уйлап та карамыйлар.

Өченчедән, физик булмасам да, шушы мәсьәләгә кагылышлы әдәбиятны күзәтеп барам, матдәнең лептон төзелеше ноктаи назарыннан чыгып караганда, Р. М. Миңнекәев тарафыннан кылына торган гамәлләрнең булу һәм аларның шул дәрәҗәдә эффектлы булуы бик тә мөмкин хәл. Лептон ул — тереклекнең иң вак кисәкчәсе. Физиклар бу дөньядан китеп баручы җанның, лептон массасының авырлыгын үлчәделәр. Конкрет кеше тарафынан лептон дәрәҗәсендә тудырылган образларның чиге билгеләнә (кешенең уй эшчәнлеге тарафыннан тудырылган образның материаль нигезе булып лептон структура тора). Кеше начар уйласа, материаль булган уй аша лептон структура «туа», һәм бу — структураны хасил итә торган шартлы-кире лептон болыт булып тора. Күтәренке энергетик мөмкинлекләргә ия булган кешенең хәрәкәтләре юнәлдерелгән башка кешеләрнең иммунитетлары бу минутларда түбәнәйгән булса, теге кеше начар уйлаган очракта аның боларга күз тидерүе мөмкин. Әгәр дә югары энергетикага ия кеше дәвалаучы булса, бу очракта, мәгълүм кешегә билгеләнгән уңай образ тудырып, ул аның хәлен, кәефен, лептон структурасын (җанын) яхшырта ала, моның исә кайберәүләр аура дип йөртә торган нәрсә булуы да ихтимал. Бу процессның билгеле бер максатка юнәлдерелгән, аңлы рәвештә эшләнгән булуы мөмкин. Әгъзаларның лептон структураларын һәм аннан да нәфисрәк структураларны да «күрә» торган кешеләр дә була.

Атлантларның дүртенче цивилизациясенә тулаем экстрасенслык хас булган. Җыелган кешеләр (майялар кабиләсе) энергиясе исәбенә алар котсыз зур ташларны бик зур араларга күчерә торган булганнар. Әмма Тифон кометасы, Җир атмосферасын тишеп, Атлантиданы океан төбенә төшереп җибәргән, атлантларның аны тотып калырга көчләре җитмәгән. Аллаһ тәгалә кешеләре исә үзен аклый алмаган цивилизацияне шулай җәзаладылар дип исәплиләр, чөнки кешеләр бу вакытта күбрәк материаль байлыкны кайгырта башлаган булалар. Җанның камиллеге турында ялгыз каһиннәр генә кайгырта торган булып калганнар. Иртәме, соңмы, безнең цивилизацияне дә башка бер цивилизация алыштырачагы сер түгел инде. Әгәр без үзебезнең гөнаһларыбыз, «үтәлмәгән нәзерләребез» турында, ялганнарыбыз һәм башка төрле әшәкелекләребез турында ешрак уйламасак, ул шулай булыр да.

*— Медицина белән Миңнекәев феноменының тәэсир итешүе нинди юнәлештә булырга мөмкин? Алар бер-берсенә ничегрәк ярдәм итә алырлар?*

— Рәфыйк әфәнде үзенә Галәм тарафыннан чиксез зур энергетик мөмкинлекләр бирелүе турында сөйли, эшләгән эшләре аның чиксез зур энергетик мөмкинлекләре турында сөйләгән сүзләреннән берничек тә аерылмый. Аның бу гамәлләрен нәфис структураларны өйрәнә торган физиклар гына аңлатып бирә ала. Медицина исә, диагнозлары төрле булган бер төркем авыруларны җыеп, Р. Миңнекәев сеансларын алганнан соң, рентгенологрaмма, УЗИ һәм медицинада булган башка чараларның мәгълүматлары ярдәмендә табипның аларга клиник тәэсирләрен өйрәнә ала. Медицина күп диагнозларны куя ала, ләкин, кызганычка каршы, барлык авыруларны да дәвалый алмый.

Күрәсең, Рәфыйк Миңнекәев гамәлләренең механизмы түбәндәгечә: уе белән ул организм һәм әгъза дәрәҗәсеннән хромосома, ген, молекула дәрәҗәсенә кадәр булган норма, зурлык структура образын тудыра. Һәрхәлдә, ул шулай дип әйтә. Әгәр аңа шулкадәр көчле энергия бирелгән булса, бу очракта авыруга яисә үзгәргән әгъзага карап, ул аның элекке нормаль хәлен яисә җитмәгән нәрсәсен күз алдына китерә ала, «күләгәсе» буенча шул лептон структураны төзи яисә яңарта ала (һәрнәрсәнең эзе кала, һәрнәрсә материаль, бәлки әле лептон күләгәләр дә бардыр, тик алары тагы да югарырак дәрәҗәдәдер) һәм әгъзага яңадан «әйләнеп кайтырга», «яңартырга», күзәнәкләрне яңадан торгызырга, үзенең элекке нормасы эченә кереп утырырлык, шуңа кирәрлек булып үсеп җитәргә яисә кечерәйтерлек нигез бирә ала. Аннары, әгәр дә лептон дәрәҗәсендә яисә хәтта тагын да югарырак дәрәҗәдә фикерли яисә аралаша ала икән, бу очракта ул җитешмәгән әгъзаны барлыкка китерергә, аны алыштыра алырга, әгъзаны яисә аның өлешен, мәсәлән, лептон структурасын (ягъни образын) уй белән юкка чыгарып, шешне яисә полипны алып ташларга сәләтле булырга тиеш: калганы инде организм эше — теге яисә бу механизм ярдәмендә эшне эшләп бетерү өчен тәэләү вакыты гына кирәк була. Мәсәлән, фагоцитоз мисалында ул түбәндәгечә була:

1) лейкоцитлар (фагоцитлар) организмдагы чит күзәнәкләрне юк итә алалар;

2) шундый ук фагоцитозны койрыклы чукмарбаш койрыксыз бакага әйләнгәндә күзәтергә мөмкин. Моны тикшерү — галимнәр эше, әмма иң әһәмиятлесе: бу — принципта мөмкин хәл.

Шушындый ук юнәлешне бөтен бер залга, күп санлы кешеләргә бирергә мөмкин, һәм организм инде бөтенләе белән үзенең нормаль лептон структурасына яраклаша, бөтенләе белән үзенең дәвалана, ә инде ашыккан яисә вакыт җитмәгән очракта (мәсәлән, рак яисә ими баласының үпкәсе ялкынсынганда һ. б.) конкрет әгъзага конкрет күрсәтмә бирергә мөмкин.

*— Медицинага якын торган кеше буларак, Сезне аеруча шаккатырганы нәрсә булды?*

— Нәфис структуралар белән һәм өлешчә медицина белән таныш кеше буларак, мине бернәрсә дә артык шаккатырмады. Менә шушындый кешенең барлыкка килүе, шушындый мөмкинлекләре булган кешене күрүем, аның безнең Казанда булуы, медикларга үзенең сеансларына керергә тәкъдим итүе, аларга үз карамакларына бер төркем күргәзмә авырулар җыеп, сеанслардан соң диагнозларын расларга тәкъдим итүе, ләкин һаман әле чын белгечләрнең моның белән шөгыльләнмәве мине гаҗәпләндерде.

*— Сез шәхсән үзегез сеанслар вакытында нәрсә хис итәсез?*

— Сеанслар вакытында үзем бернәрсә дә сизмим, әмма өченче сеанста авыру әгъзам өлкәсендәге авыртулар борчымый башлады. Дүртенче, бишенче сеансларда хәлем әкренләп тагын да җиңеләя барды. Хәзер инде уноч сеанс алдым, авыртулар инде гомумән кабатланмый. 24 сеанс алмакчы булам. Мөгаен, тәэлү вакытын үткәреп, аннары дәвалаучы врачыма һәм УЗИга күренермен. Миңа операциясез котылып булмас, дигәннәр иде. Әгәр дә операциясез генә бары да нормальләшсә, врачым моны раслаячак. Ул бик гадел кеше.

*— Рәфыйк әфәнде эшләгәннәрдән нәрсәне аеруча әһәмиятле дип саныйсыз?*

— Ул эшләгәннәрдән иң әһәмиятлесе дип мин аның кеше җаны, кеше күңеле турында кайгыртуын саныйм. Кешенең күңеленнән ул аның бөтен явызлыгын

алып ташларга омтыла. Фәнни телгә күчереп әйткәндә, бу — үзеңнең уең белән кире лептон образлар тудырмаска дигән сүз, ә Рәфыйк әфәнде теле белән әйткәндә — гөнаһ ясамаска, нәзерләреңне үтәргә, башкаларга явызлык теләмәскә, явызлык эшләп үзеңнән соң килә торган буыннарны җәзага дучар итмәскә — авыру, гарип, рухи кимчелекле кешеләр тудырмаска. Чынында исә бу — кешелек популяциясен, шулай ук Галәмне, Космосны чистартуга карата үзенә күрә бер күрсәтмә; космоска инде без үзебезнең бөтен явызлыгыбызны, әшәкелегебезне чыгарып ташлыйбыз, ә ул шакшы, үз чиратында, аннан, югарыдан, безнең үзебезгә, безнең илебездәге вакыйгаларга йогынты ясый.

Фән ноктаи назарыннан чыгып караганда табигатьтә тагын да югарырак дәрәҗәдәге йогынты ясаулар булырга мөмкин, чөнки бит табигать ул иксез-чиксез, аны теләсәң ничаклы өйрәнергә була, күп төрле күренешләрне аңлатырга була. Дөньяда экстрасенслар, ягъни бик үк нормаль булмаган төр кешеләр булуы һәркемгә мәгълүм: әйберләрне бер урыннан икенче урынга күчерү, үтүкне күкрәктә тоту күренешләре һ. б. күптән инде тасмага төшерелеп, Үзәк телевидениедән күрсәтелде. Бу тәҗрибәләр галимнәрнең каты күзәтүе астында үткәрелде. Кеше сөякләре дә — шундый ук әйберләр, аларны да башка әйберләр кебек, бер урыннан икенче урынга күчерергә мөмкин. Медиклар гына бу тәҗрибәләрне җентекләп тикшерсеннәр иде дә, уңай нәтиҗә биргән очракта, үз проблемалары турында гына уйламыйча, яңа чынбарлыкны кабул итсеннәр иде һәм Р. М. Миңнекәевкә сәламәтләндерү үзәге булдырырга ярдәм итсеннәр иде.

— *Безнең һәрберебез Рәфыйк әфәндегә ничек булыша алыр иде?*

— Һәр пациент аңа ярдәм итә ала: дәвалана торган учреждениеңнән авыруың турында тәфсилләп язылган, мөһер куелган белешмә алырга кирәк. Беренче белешмә кешенең кайчан, нинди авыру белән авырый башлавы турында. Икенчесе сеанслардан соң тиешле төзәлү вакыты үткәч, шул ук врачтан алынырга тиеш: авыруың беткәнме яисә кимегәнме. Р. М. Миңнекәев сеансларына кайчан һәм күпме йөрүеңне дә күрсәтергә кирәк.



## Садретдин Максуди

# АНГЛИЯГӘ СӘЯХӘТ [1]

(ИНГЛИЗ МИЛЛӘТЕНДӘ КУНАКТА)

**1909 нчы санәдә Англия халкының бөтен сыйныф вә тәбакаләренә [2] мәнсуб [3] кешеләрдән мөрәккәб [4] бер һәйьәт [5] Дума вә Совет әгъзаларыннан егермеләп кешене бөтен Англия халкы исеменнән рәсми кунаклыкка чакырганнар иде. Депутатлар арасында мөселманнан мин барган идем. Бу китабым шул рәсми сәяхәттә күргәннәремнең тәфсыйләтедер [6].**

* * *

**Бу сәяхәтнамә вакытында «Йолдыз» гәзитәсендә тәфәррыка сүрәтендә [7] басылып чыккан иде; минем өчен кыйммәтле хатирәләрне укырга теләүчеләр өчен әле дә интересыны гаиб итмәгән [8] бәгъзы мәгълүматны хави [9] булганга, хәзердә китап шәкелендә нәшер итәргә уйладым. Ләкин тәртип җәһәтеннән дә, өслүб вә ифадә[10] җәһәтеннән дә «Йолдыз»да чыккан рәвештән үзгәртмичә бастыруны муафикъ таптым.**

*Садретдин Максуди*
*1914 нче ел, 17 февраль*

---

[1] Текст 1914 елны Казанның «Өмид» матбагасында гарәп әлифбасында чыккан китап басмасыннан алынды. Хәзерге алфавитка транскрипциясе, гарәп-фарсы сүзләренең бит асты тәрҗемәләре, ахырдагы искәрмәләр, соңгы сүз Ә. Кәримуллин һәм Р. Даутов тарафыннан эшләнде.

[2] *Тәбакаләренә* — катлауларына.
[3] *Мәнсуб* — хас, мөнәсәбәте булган.
[4] *Мөрәккәб* — төзелгән.
[5] *Һәйьәт* — делегация, вәкиллек.
[6] *Тәфсыйләте* — аңлатмасы, тасвирламасы.
[7] *Тәфәррыка сүрәтендә* — сибелгән, таралган сурәттә.
[8] *Гаиб итмәгән* — югалтмаган.
[9] *Хави* — эчено алган.
[10] *Ифадә* — тасвирлау, сүз сөреше.

I

## Бу сәяхәтнамәне ник язарга уйладым?

Мин Англиягә бер хосусый кеше булып түгел, Русия мөселманнарының бер нөмаиндәсе [1] булып, Русия мөселманнарының бер нәмүнәсе [2] булып барганга, минем бу сәяхәтемнән асыл максуд — зур бер мәмләкәтнең төрле җирләрене, кешеләрене, мәдәниятене, әхвалене вә хәяте иҗтимагыясене күреп, үземнең генә мәгънәви ләззәт алуым түгел, сәяхәттән асыл максуд — дөньяның иң куәтле бер халкына үзеннең милләтең хакында тугъры вә күркәм фикер бирү, үзеннең милләтеңне инглиз күзендә күтәрү, күтәрә алмасаң да, һич булмаса, төшермәү иде. Бу сәяхәттән максуд — инглизләргә Русия мөселманнарыны мөмкин кадәр мәргуб рәвештә [3] танытмак булса, вазифа сәяхәт илән генә бетмидер. Мин милләт вәкиле булып баргач, бу сәяхәт әснасында [4] кылган эшләремнән, сөйләгән сүзләремнән үз милләтемне хәбәрдар итәргә тиеш буладыр. Садәрәк [5] итеп әйткәндә, ниләр кылып йөргәнемне халыкка белдерү минем өсткә бурыч буладыр. Бу фикерләргә бинаэн, Англиягә сәяхәтемнең, үз фикеремчә, әһәмиятле булган тарафларыны язарга булдым.

Әлбәттә, бу сәяхәт эчендә булган бөтен вакыйгаләрне, күрелгән һәрбер кеше вә шәһәрләрне, сөйләшелгән һәммә сүзләрне язу мөмкин түгел; бунын өчен әллә ничә җилдләр [6] лязем булыр иде. Бунын кирәге дә юк. Минем бу язачакларымда әһәмият бирәчәгем нокта вә мәсьәләләр югарыда тәгъриф ителгән [7] сәяхәттән, максудтан табигый сүрәттә килеп чыгалар.

Югарыда минем Англиягә барудан максуд, икенче төрле итеп әйткәндә, Англиягә ватандашларымыз руслар барганда алар арасында бер мөселман да баруыннан максуд — инглизләргә Русия мөселманнары, төрек вә татарларның барлыгыны белдерү вә алар хакында мөмкин кадәр яхшы фикер бирүдер, дигән идем. Димәк, беренче бу сәяхәтнамәмдә минем — инглизләргә вә инглизләрнең миңа каршы күрсәткән мөнәсәбәтләрене язарга кирәк буладыр.

Әлбәттә, буны язу өчен әүвәл гомумән Дума вәкилләренә булган истикъбаль [8] вә илтифатлардан бәхәс итү кирәк буладыр.

Аннан соң, мин милләт вәкиле булып барганга күрә, безнең Русия мөселманларыннан бу рәвештә бер мәмләкәткә рәсми кунакка бару беренче мәртәбә булганга күрә, бу кеби сәяхәттәге зур кабулларны, истикъбальләрне тәфсыйлән тәгъриф итү дә файдалы булыр дип уйлыйм. Бәлки киләчәктә бундый зур миһманлыкларда [9] булачак яшьләремез буннан истифадә[10] дә итәрләр.

Бу гына да түгел, бундый зур мәдәниятле бер мәмләкәттә сәяхәт иткәннән соң, буны халык өчен язган вакытта, инглизләрнең ничек кабул вә илтифат итүләрене генә бәян итү җитмидер, зур бер мәдәнияте хакында да бер фикер бирергә тырышу тиеш буладыр. Бу мәдәнияттән бәхәс иткән вакытта да, әлбәттә, бер сәяхәтнамәдә озын тәгърифләргә кереп булмый; бу мәдәниятнең иң мөһим тарафларыны, иң диккатемне җәлеп иткән тәгаҗҗеб[11] вә тәхсинемене, муҗиб булган[12] хәлләрене генә бәян илә канәгатьләнергә кирәк буладыр.

Сүзне күп озайтмыйк, асыл сәяхәтне язарга башлыйк.

---

[1] *Нөмаиндәсе* — дәрәҗә күрсәткече.
[2] *Нәмүнәсе* — үрнәге.
[3] *Мәргуб рәвештә* — әйбәт сыйфатта.
[4] *Әснасында* — арасында.
[5] *Садәрәк* — гадирәк.
[6] *Җилд* — том.
[7] *Тәгъриф ителгән* — сөйләнгән, аңлатылган.
[8] *Истикъбаль* — хөрмәтләп каршылау.
[9] *Миһманлыкларда* — кунак булуларда.
[10] *Истифадә итү* — файдалану.
[11] *Тәгаҗҗеб вә тәхсинемене* — гаҗәпләнү һәм мактавымны.
[12] *Муҗиб булган* — сәбәпче булган.

II

## Англиягә сәяхәт фикере каян чыкты?

Англиядә «Русия әхвалене өйрәнү» җәмгыяте исемендә җәмгыять бар икән. Мәгълүмдер ки, Яурупада, хосусән [1] Англиядә, җәмгыятьтән күп нәрсә юктыр.

Бу җәмгыять әгъзалары Англиянең Русия илә дустлану вә якынлануыны бик күп җәһәттән бу ике мәмләкәт өчен файдалы дип табалар, һәрвакыт бу якынлашуга ярдәм итә торган һәрбер васитадан [2] истифадә итәргә тырышалар икән. Русиядә идарәи мәшрута [3] башланганнан, Дума ачылганнан бирле мәмләкәт идарәсенә халык вәкилләре катыша башлагач, Русия илән Англиянең якынлануы, дустлануы өчен Русиядәге Дәүләт Думасының вәкилләренең Англияне яхшы танулары вә, таныганнан соң, мәхәббәт итүләре ярдәм итәчәк дип уйлаганнар да, Думаның һәрбер мәшрутият [4] тарафындагы партияләреннән берничә кешене кунакка чакырырга ният иткәннәр. Ләкин болай хосусый җәмгыять тарафыннан гына чакырылса, Дума вәкилләренә Англиядә зур вә мәһабәт бер истикъбаль булмас дип, бу дәгъвәткә мөмкин кадәр парламент һәм хөкүмәт кешеләреннән байтак кешене катыштырырга уйлаганнар, таки дәгъвәт рәсми сүрәт алсын; шул фикер илә байтак зур кешеләргә мөрәҗәгать иткәннәр.

Вә һәр җирдә һәртөрле табәка [5] кешеләре арасында бу дәгъвәт фикерене бик хуш кабул иткәннәр. Шулай итеп, тиз заманда «Русиянең Дума вә Совет вәкилләрене дәгъвәт комитеты» исемендә бер комитет ясалган. Бу комитетка профессорлардан, әдипләрдән, депутатлардан, хөкүмәт кешеләреннән, тәҗҗардан [6] иң зур кешеләр кергән, таки дәгъвәт Англиянең һәр табәкасе тарафыннан җибәрелгән булсын. Бу комитетта Англиянең мәшһүр кешеләреннән хариҗия [7] министры Эдуард Грей, иске министр мәшһүр Бальфур, лорд Уирдэль, иске Мисыр валисе [8] лорд Крумэр, болардан башка әллә никадәр депутатлар, профессорлар, тәҗҗарлар бар иде.

Комитет ясалганнан соң чакырырга бару, Думадан кемнәрне чакыру, Лондонга килгәч, рус депутатлары кай көн вә кай сәгатьләрдәниләр эшләячәк вә кайда булачакларының программасы тәртип итү, кунаклар килгәч, аларны идарә итү Англиядә Ливерпуль шәһәрендә рус тарихы мөгаллиме профессор Перскә тапшырылган.

Профессор Перс, Англиядә эш оешып беткәч, Русиягә килде. Үзе русча бик яхшы белгәнгә, Русия әхваленә бик вакыйф [9], Русиядәге партияләрнең фиркаләрене бик белә, Думада кайсы партия нинди роль уйнаганыны бик аңлый иде. Комитетның әмере буенча, профессор Перс, Думада булган һәрбер партиядән кеше чакырмаенча, бары идарәи мәшрута тарафыннан булган партияләрнең кешеләрене генә чакырырга уйлаган.

Шул сәбәптән, бу дәгъвәткә Думаны тәсдикъ итмәгән уңлар да кермәгәннәр, җөмһүрият тарафында булган социалистлар да кермәгәннәр. Перс кадетлардан башлап мөселман, поляк, прогрессист, октябрист вә урта уңнарны шамил [10] алты партияләрнең һәрбереннән берничә кеше чакырырга муафикъ тапкан.

Думадан унбиш кеше, Государственный Советтан биш кеше чакыру ният ителгән. Дума эчендәге унбиш урын да бу рәвештә бүленәчәк булган: рәис Хомяковтан башка октябристлардан ике кеше. Кадетлардан өч кеше, прогрессистлардан бер кеше. Поляклардан ике кеше. Мөселманнардан бер кеше. Урта уңлардан вә националистлардан өч кеше.

Профессор Перс Русиягә килгәч үк бу хакта иң әүвәл Хомяков илән мөшавәрә [11] итеп, югарыда мәзкүр [12] партия вә фракцияләрнең нөмаиндәләреннән

---

[1] *Хосусән* — бигрәк тә.
[2] *Васита* — арадашлык.
[3] *Идарәи мәшрута* — конституцион монархия.
[4] *Мәшрутият* — конституциялелек.
[5] *Табәка* — катлау.
[6] *Тәҗҗар* — сәүдәгәрләр.
[7] *Хариҗия* — чит, тышкы.
[8] *Вали* — губернатор, валайәт башлыгы.
[9] *Вакыйф* — белүче, төшенүче.
[10] *Шамил* — эченә алган.
[11] *Мөшавәрә* — киңәш.
[12] *Мәзкүр* — телгә алынган.

мөрәккәб [1] Думада бер комитет ясарга кирәк тапканнар. Бу комитет, озак вакыт үтмәде, ясалды. Бу комитетка безнең мөселманнардан фракциямезнең рәисе Котлыгъ-Мөхәммәд мирза Тәфкилев дахил иде [2].

Англия сәяхәтенең бөтен тәфсыйләтене шул комитет Лондондагы комитет илә хәбәрләшеп тәгаен иттеләр. Бу комитетка әгъза булып Котлыгъ-Мөхәммәд мирза кергәнгә кадәр комитет эчендә кызыклы, без мөселманнар өчен әһәмиятле бер сахнә [3] булган. Бу вакыйгане миңа соңыннан юлдашларымнан берничәсе сөйләде. Миңа сөйләүчеләр яшерергә лязем күрмәгәнгә вә бу вакыйга безнең өчен бик гыйбрәтле булганга, бу урында язу кирәк дип уйлыйм.

Сахнә буннан гыйбарәт. Югарыда мәзкүр комитет эчендә кайсы партияләрдән кеше чакыру кирәклеге мөзакәрә [4] ителгән вакытта профессор Перс сораган:

— Мөселман фракциясе кеби кечкенә бер фракциядән һәм бер кеше булу кирәк микән? — дигән, моның кирәклеге хакында шөбһә иткәнлегене күрсәткән, аның өстенә гыйлавә [5] иткән: — Безнең Һиндстан мөселманнарыннан депутат сайланмаганлыгы җәһәтеннән дә Русия Милләт мәҗлесеннән бер мөселман килүе безнең Англия өчен гаҗәбрәк, уңгайсызрак булмас микән,— дигән.

Мин бу урында шәрех итмим, сүзнең кая барганы аңланса кирәк.

Буңа каршы иң әүвәл ачык фикерле сул октябристлардан А. И. Звегинцев болай җавап биргән:

— Без чакырылачак кешеләр арасында мотлака [6] мөселман булуыны лязем дип беләбез. Сез, инглизләр, Русия Милләт мәҗлесенең депутатларын чакырасыз, Англиядәге комитет үзе кайсы партияләрдән кешеләр чакыру тиеш булганыны белмәгәнгә, дәгъвәткә кайсы партияләрдән кешеләр иштирәк итәргә [7] тиеш, бу, җәһәтләрне комитетка тапшырадыр. Инде бу җәһәтләр Дума эчендәге комитетка тапшырыла торган булса, без мәшрутият тарафыннан булган һәрбер партиядән бер кеше кертелүне бурычымыз дип беләмез. Хосусән мөселман фракциясеннән бер кеше чакырылуыны мотлака лязем дип беләмез. Чөнки бу фракция гадәд [8] җәһәтеннән зур булмаса да, һич шөбһәсез, егерме миллион мөселманның хакыйкый вәкилләредер. Думада һичбер башка фракция үзене хакыйкатән егерме миллион Русия әһалисенең [9] вәкиле дип игълан итә алмас. Без яңа Русия әһле ватаный мөселманнарга үзебез илән мөсави гайне[10] хәл вә хокукка малик булырга тиеш ватандашлар дип карыймыз. Безнең Русия зур мәмләкәт, анда төрле милләтләр бар. Әгәр бер җирдә Русиянең нөмаиндәләре бара торган булса, анда мөселман да булырга тиеш. Чөнки Русия рус, поляк, мөселман вә башкаларның мәҗмугыннан гыйбарәттер,— дигән.

Звегинцевның бу фикерене Хомяков, Милюков, Гучков вә Ефремов тәкъвия иткәннәр[11].

Бу сүзләрдән соң профессор әйткән:

— Мадамки[12], Русиядә сезнең мөселманнарга нәзарыңыз бу рәвештәдер, мадамки аларның Русия эчендә бундый зур әһәмиятләре бар, моңа каршы минем һичбер сүзем юк. Билгакес[13], кунаклар арасында бер мөселманның булуы бөтен Англия өчен гыйбрәтле булыр. Безнең Һиндстандагы мөселманнар сайлауларга катышмыйлар, Русиядәгеләр катнашканыны күреп, бәлки, безнең хөкүмәт әсхабы[14] буннан бер гыйбрәт алып, бер нәтиҗә чыгарыр,— дигән.

Шулай итеп, Дума комитетында мөселманнан бер кеше кертүгә карар бирелгәч, профессор Перс безнең фракция рәисе Котлыгъ-Мөхәммәд мирзага мөрәҗәгать итде. Котлыгъ мирза үзенең бәгъзы хосусый эшләре җәһәтеннән бара алмавыны сөйләгәч, мөселман фракциясе үзенең актык җыелышында, Котлыгъ-Мөхәммәд мирза үзе бармагач, мотлакан аның урынына мөселман фракциясеннән бер кеше барырга тиеш вә бу кеше Садри әфәнде булырга тиеш, чөнки

---

[1] *Мөрәккәб* — төзелгән.
[2] *Дахил иде* — кертелгән иде.
[3] *Сахнә* — сәхнә, куренеш.
[4] *Мөзакәрә* — фикер алышу.
[5] *Гыйлавә* — өстәмә.
[6] *Мотлака* — һичшиксез.
[7] *Иштирәк итәргә* — катнашырга.
[8] *Гадәд* — сан.
[9] *Әһалисе* — халкы.
[10] *Мөсави гайне* — тулы, бердәй тигез (хокуклы).
[11] *Тәкъвия иткәннәр* — яклап чыкканнар.
[12] *Мадамки* — әгәр шулай икән.
[13] *Билгакес* — киресенчә.
[14] *Әсхабы* — ияләре, хуҗалары.

ул гомуми тел булган французчаны беләдер, лязем булганда сөйләр. Русия мөселманнары хакында лязем булган җирдә мәгълүмат бирер-фәлән, дип, төрле дәлилләр китереп, Котлыгъ-Мөхәммәд мирзадан комитетка мөрәҗәгать итеп, үзе бара алмаганыны, үзенең урынына фракциянең сәркятибе Садретдин Максудины тәкъдим иткәнене әйтергә үтенделәр. Ләкин сайлау ихтыяры булганга, комитетның минем баруыма ничек каравы мәгълүм түгел иде.

Иртәгесен Думада Котлыгъ-Мөхәммәд мирза миңа килеп әйтте:

— Мин сезне комитетка тәкъдим иттем; бөтен комитет бер сүздән сезнең баруны хуш кабул иттеләр,— диде.

Ләкин мин, Хомяков, Гучков вә Милюковларның һәрберенең минем баруыма хөсне нәзар[1] кыйлуларын мәмнүн[2] вә мөтәәссир[3] булсам да, бару тарафына карар биреп бетерә алмый идем, тәрәддед[4] итә идем. Буның сәбәбе, бердән, йөрисе килмәү, арыганлык, икенчедән, мәсарифның[5] бик күп булуы, өченчедән, бу сәяхәтнең ул вакытта бу кадәр үк зур әһәмиятле бер сәяхәт буласыны бөтенләй алдан күреп булмау иде.

Галимәрдан бәк Тупчибашев, ул көннәрдә Петербургта булган Исмәгыйль бәк Гаспринскийның, иптәшләремнән Котлыгъ-Мөхәммәд мирзаның, Сыртланов, Мәхмүдев, Тукаев вә Хәйдәревләрнең, фракциядә хезмәт иткән Исмәгыйль Лимановның хосусый мәҗлесләрдә: баруым милләт өчен мөһим, файдалы, дип димләүләре соңында гына барырга карар бирдем.

## III

## Китүгә хәзерләнүләр. «Донон»да мәҗлес. Баручылар арасында танышулар

Думадагы комитетка кемнәр баруы мәгълүм булгач, комитет һәрбер баручыны бергә җыяр өчен өченче июньдә Петербургның мәшһүр «Донон» ресторанында, бакчада, бер мәҗлес ясады. Бу мәҗлестән максуд, бердән, баручыларны бер-беренә таныштыру, икенчедән, ни вакыт Петербургтан китү, ничек бару, кайдан бару мәсьәләләрене киңәшү иде.

Бу мәҗлескә чакырылган кешеләрнең һәммәсе килмәде. Кайсы мәшгуль, кайсы иртә белән үк Петербургтан киткән. Мәҗлестә хазир[6] булганнар Хомяков, Шидловский, Звегинцев, граф Бобринский, граф Олсуфиев, Стахович, кенәз Волконский, Маклаков вә Садри Максудов иде. Хомяков илә Думада рәсми сүрәттә бик күп мәртәбә күрешкәнем булса да, болай якыннан бер мәҗлестә булганым юк иде. Хомяков фәүкыльгадә[7] мәҗлеси күңелле, ачык, простой бер кеше икән. Башкаларны, граф Олсуфиевтан башкасыны, һәрберене бер мөнәсәбәт илән бик яхшы таный идем, күрешкәнем, мәҗлестәш булганым бар иде. Михаил Стахович илән Икенче Думадан бирле якын таныш. Маклаков вә Бобринский илә һәм Икенче Думадан бирле танышидек.

Мәҗлеснең ибтидасында[8] сәфәр мәсьәләсенең вак тәфсыйләтенә керешмәй, сәрбәст мөкяләмә[9] илән башланды. Рәис могавине[10] кенәз Волконский минем илән хосусый сүрәттә таныштьі. Беләсеңез, без Думадагы танышлыкны хисаплмыймыз, бу рәсми танышлык. Танышкач, безнең мөселман фракциясенә берничә мөдаһәнәле[11] сүзләр сөйләде.

— Сезнең фракция кечкенә генә булса да, иң үз-үзене тота белгән бер фракция,— диде. Бу сүзне Хомяков та күтәреп алып, мөселман фракциясенә булган хөсне нәзарыны аңлатты.

Граф Бобринский бик егет табигатьле, көлдерергә яраткан бер кеше, үзе бер дә көлмичә, Хомяковтан сорады:

---

[1] *Хөсне нәзар* — яхшы караш.
[2] *Мәмнүн* — шат, канәгать.
[3] *Мөтәәссир* — тәэсирләнгән.
[4] *Тәрәддед* — икеләнү.
[5] *Мәсариф* — чыгым.
[6] *Хазир* — хәзер, шушы вакыт.
[7] *Фәүкыльгадә* — гадәттән тыш.
[8] *Ибтидасында* — башлангычында.
[9] *Сәрбәст мөкяләмә* — ирекле гәп, сөйләшү.
[10] *Мөгавин* — ярдәмче.
[11] *Мөдаһәнә* — ялагайланып мактау.

— Николай Алексеевич, безне син Англиягә алып барасың, шулай бит? Анда барырга булгач, ул мәмләкәтнең тарихыны-фәләнене азрак белергә кирәк булыр; мин бу хакта азрак үземнең мәгълүматымны яңартасым килә.
Хомяков: — Бик яхшы, яңартыгыз.
Бобринский: — Ул Англия бер җәзирәдә [1] түгелме? Шулай бит. Күрәсенез, мин җәгърафияне онытмаган әле.— Бобринскийның бу мәзахтан [2] максуды Англия хакында мәгълүматы кяфи [3] булмаганына, бу хакта калган берничә көн эчендә уку лязем булуына бер киная иде.
Бу сүздән соң Шидловский һәрбереннән сорады:
— Сез Англия хакында бу арада берәр нәрсә укыдыгызмы? — диде.
Хазирун [4] һәрбере, яртылай уйнап, яртылай чынлап, укыган нәрсәләрене санадылар. Хомяков:
— Мин мөтәвәффа [5] атамның Англиягә сәяхәтене яңадан укыдым,— диде.
Мәгълүмегез Хомяковның атасы мәшһүр рус әдибе Алексей Хомяковтыр. Аның Англия хакында язган «Сәхифәләр»е гаять әһәмиятле имеш.
Нәүбәт миңа килде. Звегинцев миннән сорады:
— Хуш, Садри Низамович, сезниләр укыдыгыз? — диде.
Мин:
— Мәгаттәәссеф [6], сезнең кеби барсын алдан белеп тормадым, шуның өчен хәзергә бик күп нәрсә укып өлгермәдем. Ләкин алай булса да, әүвәлдән Англия тарихы вә Англия мәдәнияте хакында берничә төрле нәрсәләр укыганым бар. Бу мәгълүматымны яңарту вә куәтләү өчен ике көннән бирле Сеньобос вә Лавис (икесе дә мәшһүр француз мөаррихләреннән) [7] тарихларында янә Англиягә гаид [8] кыйсемнәрне ашыгып-ашыгып күздән кичердем. Аның өстенә, бу көн мәшһүр Тэнның «Англиягә сәяхәт» исемле китабыны Вольф дөкәненнән [9] таптым, моны да юлга укырга өмид итәм,— дидем.— Шуларны укыгач, инглизләргә мәмләкәтләре хакында бөтенләй наданлыкны сиздермәскә мөмкин булыр дип уйлыйм,— дидем.
Болай дигәч, граф Бобринский:
— Болай булгач, нинди наданлык? — Сез мине болай хәрап итәсегез-фәлән дип, уйнап көлде дә: — Менә нишлик, Максудов, сәяхәттә сез минем белән янәшәрәк йөрегез, мин кирәк булганда сездән тарихларны сорармын,— диде.
Мин тиз генә:
— Билгайен вәррәс[10], мин сезнең илән бергә йөрергә хәзермен. Сезгә тарих үгрәтергә түгел, бусы бер мөбаләгаи ләтыйфә, һазмы нәфес[11]; билгакес, мин сездән истифадә итәргә, чөнки сез инглизчәне ана теле кеби беләсегез имеш, һәр җирдә инглизчә кирәк булыр, күп җирләрдә, бәлки, нотыклар да инглизчә булыр, әгәр мин янымда сезнең кеби мәгълүматлы тәрҗеманга малик булсам, бик шат булырым,— дидем.
Звегинцев:
— Алай булса, Бобринский вә Максудовны бергә язам,— диде.
Звегинцев сәяхәтне оештыручы мөдәббирләрнең[12] берсе иде.
Буннан соң мәҗлеснең ахырына таба эшлекле сүзләр сөйләнде. Мөдәббир хазирунга түбәндәге планны сөйләделәр. Вә бу планга каршы хазир булганнар тарафыннан игътираз[13] булып-булмаганны сорадылар. Игътираз итүче булмады. Һәркем муафикъ тапты.
План буннан гыйбарәт.
Сәяхәт бишенче июньдә (1909) башлана. Сәгать 11дә Варшау вокзалыннан кителәчәк. Алдан киткән кешеләр булса, бунлар Франциядә, Ла-Манш диңгезе буенда Кале шәһәрендә көтәләр. Аннан диңгезгә бергә утырыла. Аерым билет алырга хаҗәт юк. Мөдәббирләр һәркемгә билет алырлар. Ләкин алдан билет вә

[1] *Җәзирә* — утрау.
[2] *Мәзах* — көлке, юмор.
[3] *Кяфи* — җитәрлек, кирәк кадәр.
[4] *Хазирун* — шунда булучылр.
[5] *Мөтәвәффа* — вафат булган.
[6] *Мәгаттәәссеф* — кызганычка каршы.
[7] *Мөаррих* — тарихчы.
[8] *Гаид* — кагылышлы.
[9] *Дөкән* — кибет.
[10] *Билгайен вәррәс* — баш өсте (бик риза).
[11] *Мөбаләгаи ләтыйфә, һазмы нәфес* — гүзәл арттыру, нәфесне канәгатьләндерү.
[12] *Мөдәббир* — оештыручы, башкаручы.
[13] *Игьтираз* — каршылык.

башка мәсарифлар өчен баручылар мөдәббирләргә бирәр йөз сум акча биреп куярга тиеш. Петербургтан Германия границасына кадәр махсус бер вагон биреләчәк. Бу вагонда бүлмә күбесе икешәр кешелек. Бу урында кем белән кем бер бүлмәдә булачагы да тәгаен ителде.

Бу мәҗлестә шу[1] карарлардан соң бишенче июньдә сәгать уннарга якын Варшавский вокзалда очрашачак булып таралдык.

Бишенче июньдә сәгать тугызларга якын фракциядә кятиб мөгавине Исмәгыйль әфәнде Лиманов илән бәрабәр Варшава вокзалына юнәлдек. Исмәгыйль әфәндедән башка мине озатырга бераз соң мөхтәрәм Галимәрдан Тупчибашев, фракциядәге рәфыйкләремнән[2] Галиәсгар мирза Сыртланов (мәрхүм), Ибраһим Хәйдәрев һәм төштеләр. Башка рәфыйкләремнең күбесе Петербургтан киткән иделәр.

Мин вокзалга иң элек төшүчеләрдән берсе булдым. Поезд китүгә байтак вакыт булганга, Исмәгыйль әфәнде илән буфетка барып, каһвә[3] эчәргә уйладык.

Без буфетта каһвә эчкән вакытта Германиягә бара торган кызыны озатырга төшкән депутат Родичев, минем өстәлемә якын килеп, миннән ике нәрсә үтенде: берсе — Англиядән кайтышлый Франциягә рәсми сүрәттә кунак булырга керәчәк булсаңыз, миңа телеграм җибәренез, диде. Икенчесе — сезнең илән бер поездда минем кызым Германиягә барадыр, риҗа итәмез[4], аңа күз-колак булыңыз. Әгәр границалардан үткәндә кирәк булса, ярдәмнән ташламаңыз, диде.

Без Исмәгыйль бәк белән каһвәләремезне бетереп торганда, китәр вакыт та якынлаша башлаган иде. Буфеттан вокзалның китү тарафына чыктык. Китүче депутатларны һәр яктан халык чорнап алган иде. Халык арасында: «Милюков кайсы?», «Граф Бобринский кайсы?» дигән сүзләр ишетелә иде. Ул арада бер фотограф та килеп җиткән, Хомяковтан китүчеләрнең рәсемнәрене алырга рөхсәт сораган.

Һәрберемезне чакырдылар, мин дә китүчеләр тезелгән җиргә кердем. Фотограф: «Тәмам булды»,— диде, рәхмәт укыды. Халык та тарала башлады. Әле китәргә берничә минут калган иде. Шул арада мине Родичев табып, кызы илә күрештерде. Кызына:

— Әгәр берәр ярдәмгә ихтыяҗың булса, Максудовка мөрәҗәгать итәргә тартынма,— диде.

Родичевның кызы икенче вагонда иде. Буннан соң тиз генә үз вагонымызга кайттым. Үз вагонымыз янында торган Галимәрдан бәк Тупчибашев:

— Родичев сезне кая алып китте? — диде.

Мин сәбәбене сөйләдем. Ул аңа кәефе килде дә, көлеп:

— Күрәсеңме, мөселманга ышаныч һәркемнән артыграк,— диде.

Ләкин бунын сәбәбе ул көн китүчеләр арасында кадетлардан башка кеше булмавы булса кирәк. Маклаков бик соң килеп җитте, Милюков вә Челноков алдан киткән иделәр. Шунлыктан мин мөселманны кадетларга иң якын кеше хисап иткәндер.

Вагонга менәргә куштылар. Мине озата килгән мөселманнар илә күрешеп, вагонга утырдым. Күп вакыт узмады, поезд бер гайрәт илә сызгырды. Һәр тарафтан «хуш», «хуш» дигән тавышлар ишетелә иде. Кузгалып киттек.

Китүчеләрне карарга төшкән халык, гәзитәдә язучылар яулыклар селкиләр иде. Петербург калды.

Бу поездда безнең илән кемнәр барганыны әйтү лязем. Без бу вагон илән бишендә китүче 14 адәм идек: Хомяков, Хомяковның кызы (Мария Николаевна), Звегинцев вә аның хатыны, Гучков, граф Бобринский, Стахович, Шидловский, граф Олсуфиев һәм Садри Максудов иде. Болардан башка өч гәзитә мөхбире бар иде. Берсе «Новое время»дән Суворинның кече угылы Борис Суворин, икенчесе «биржевые ведомости» гәзитәсеннән Стенбу вә өченчесе «Петербургский телеграф» агентствосы илчесе Александровский иде. Бу өч кеше сәфәремезнең башыннан ниһайәтенә[5] кадәр безнең илән йөрделәр, һәрбер әхвальне телеграм яхуд хат илән үзләрене җибәргән гәзитләргә язып тордылар.

Бу язучылар һәр җирдә диярлек без кабул ителгән җирләргә кабул ителделәр. (Әлбәттә, Англия падишаһына күренү шикелле эшләр мөстәсна[6].) Мәдәни галәмдә гәзитәчеләргә илтифат бик зур. Аларны һәр җиргә кабул итәләр, һәр

---

[1] *Шу* — шул.
[2] *Рәфыйк* — иптәш.
[3] *Каһвә* — кофе.
[4] *Риҗа итү* — үтенү, өмет итү.
[5] *Ниһайәтенә* — ахырына.
[6] *Мөстәсна* — аерым.

жиргә кертәләр вә шул сайәдә [1] һәр шәй [2] матбугатка чыга, һәр эш, һәр вакыйга матбугатта үлчәнә, хөкем вә интикад [3] ителәдер. Шулай итеп, әфкяре гомумия [4] хасил буладыр.

Юлда баручылар бик тиз бер-беремез илән танышып беттек. Берлингә кадәр артык эш булмады. Берничә мәртәбә станцияләрдә Хомяковның кызы Мария Николаевна үзенең фотограф аппараты илән рәсемнәремезне алды. Аннан кала һәркем үз бүлмәсендә укый иде. Гучков инглизчә зур бер китап укый иде, аңлавыма күрә, Англия тарихы иде. Минем илән бер бүлмәдәге граф Бобринский «Англиянең конституциясе» дигән бер китап укырга тотынды. Графның кулында бу китапны күргәч, Маклаков уйнап:

— Ай-яй, граф, син Русиядәге конституциядән курыккан булып маташасың, Петербургтан китеп тә җиткәнең юк, үзең Англиянең конституциясене үгрәнергә тотынгансың,— диде.

Граф:

— Мин ул конституциядән һич курыкканым юк. Мин сез кадетлар Русиягә кертергә тырышкан конституциядән генә куркам,— диде.

Маклаков:

— Алай булса, син курыкмый торган конституцияне Русиягә кертик, разый буласыңмы?— диде.

Граф буңа тугъры җаваптан качты. Бәхәснең ниһайәтендә Маклаков көлеп:

— Дөрест, син хөкүмәт кешеләре белән яхшы таныш, алай булса да, границадан-фәләннән үтеп киткәнче бу китабыңны бер жиргә төребрәк тот. Белеп булмый, ихтираз [5] яхшы,— диде.

Һәрберемез көлештек.

Баручылар төрле партиядән булганга, һәрвакыт уен-көлкеләр шул партияләрнең фәрекъләренә даир иде.

Границага килеп җиттек. Андагы чиновниклар начар мөгамәлә итәрләр дип уйлаучылар күп иде. Ләкин аларның мөгамәләсе гаять назиканә булды. Белмим, бу көн китүчеләр арасында Дума әгъзалары булганыны белгәнгә күрәмедер, түгелмедер.

Границадан үттек. Германиягә чыктык. Хөдүдтән [6] үтеп, бераз киткәч үк мәдәниятнең башка икәне күренә: карьйәләр [7] төзек, юллар матур, басуларда адәм кулы тимәгән жир юк; әле Литва полякларының басуларына татбикан [8] фәрекъ [9] бу кадәр, әгәр Германия юлларыны, басуларыны безнең Урта Русия басуларына, юлларына, авылларына чагыштырылса, фәрекъ инсанны тагы да озын төшенчәләргә сәвекъ итәр [10] иде.

Хөдүдтән иртә белән иртүк үткән идек, кич сәгать жидедә Берлингә барып керәчәк идек. Бу көн бердә артык вакыйга булмады. Һәркем йә укый, йә сәхраларны карый иде. Маклаков инглизчә үгрәнә иде. Көн бик матур, һава яхшы иде. Биш-алты айдан бирле Дума залының, комиссия бүлмәләренең начар һаваларында утырып, кычкыра-кычкыра, сөйли-сөйли арыган башларга эштән туктап, яхшы һавада матур сәхра вә мәгъмүр [11] карьйә вә шәһәрләрне карап бару бик рәхәт тоела иде. Үземезне гуя имтиханнан муаффәкыйәт [12] белән котылган таләбә [13] кеби хис итә идек.

Кич Берлингә килеп кердек; Берлиндә ике сәгать кадәр торып, поездны алыштырып, тиз генә киттек. Бу урында Берлинне тәгъриф итмәячәкмен. Чөнки бу юлга кереп китсәм, мин сәяхәтнамәне тиз генә язып бетерә алмам.

Берлиндә безне көткән Мәскәү депутаты, Икенче Думада думаның сәркятибе булган Челноков белән Совет әгъзасы Глебов безгә кушылдылар. Милюков вә Ефремов Каледә безне көтәчәкләр иде. Буннан соң вагоннарымызда йокладык. Иртә белән уянганда Германиядән узып, Бельгиягә житәргә озак

---

[1] *Шул Сайәдә* — шул күләгәдә, ышыкта.
[2] *Шәй* — нәрсә, әйбер.
[3] *Интикад* — тәнкыйть.
[4] *Әфкяре гомумия* — гомуми, уртак фикер (җәмәгатьчелек фикере).
[5] *Ихтираз* — саклану.
[6] *Хөдүд* — чик.
[7] *Карьйә* — авыл.
[8] *Татбикан* — чагыштырганда.
[9] *Фәрекъ* — аерма.
[10] *Сәвекъ итү* — юнәлдерү.
[11] *Мәгъмүр* — төзек.
[12] *Муаффәкыйәт* — уңыш, яхшы нәтиҗә.
[13] *Таләбә* — шәкерт, укучы.

калмаган иде. Озак вакыт та үтмәде, Германиянең шимали [1] шәһәреннән Кельн шәһәренә җиттек. Вагоннардан төшеп карарга вакытымыз булмаса да, ул шәһәрдә мәшһүр католик кәлисәсенең [2] тышкы ягын күреп уздык. Буннан соң озакламый Бельгиягә чыктык.

## IV

## Бельгия вә Франция. Диңгез һәм Лондонга килеп керү

Бельгия хакында берничә фикер язарга мәҗбүрмен. Чөнки бу кечкенә мәмләкәтнең хәле мине бик озын төшенчәләргә салды; бунларны бунда язу файдасыз булмаса кирәк. Бельгиянең бөтенләе безнең Русиянең бер зуррак өязе кадәр зурлыкта бер мәмләкәттер. Шунда җиде миллионга якын адәм яшидер. Иң әүвәл фикергә киләдер: бу кадәр күп кеше бу кадәр кечкенә сатхы арызда [3] ничек яшиләр? Ничек бунлар бунда ачтан үлмиләр? Бунда безнең Русия мужиклары торса, һич шөбһәсез, бик күп ачлыклар булып, халык үлеп бетәр иде.

Ләкин бу гайрәтле халык, үзенең тәкъдиренең, язмышының тарлыгыны күргәч, тиз генә чара вә әсбаб эзләргә тотынган. Әллә кайдан ярдәм көтмәгән, бушка вакытны үткәрмәгән. Мөселман булмасалар да, «ләйсел-нисан әл-мәсагый [4]» айәте кәримәсе мужибенчә [5] гамәл итәргә уйлаган. Мәмләкәтемез кечкенә, бунда үскән ашлык, богъдай безнең һәрберемезне туйдыру ихтималы юк. Инде нишлик, җыелышып-кычкырышып үликме? Ярдәм кайдан көтик? Хөкүмәттәнме? Хөкүмәт үзе кайдан алсын? «Мәдәт» ходадан көтмәле, ләкин гадәте алла шулай җари ки [6], һичбер вакыт хода, бәндә үзе тырышмаенча, адәм кулына бер нәрсәне дә китереп бирмидер. Алай булгач, нишләргә? Бельгия кешесе буңа болай җавап биргән: «Инсан үзенә үзе ышанып, ярдәмне үзеннән генә көтәргә тиешледер. Әүвәлдә, җир иркен вакытта, бабаларымыз аз-маз эшләп тә көн күргәннәр; ләкин инде хәят тыгызлык, читен; әгәр бу тыгызлык хәяттән куркакланып качарга, үләргә уйламасам, Инсан буласым килсә, бабаларым кадәр ике кат, өч кат эшләмәлемен, таки хурлык булган ачлык хәленә калмыйм»,— дигән. Менә Бельгия халкының уе-фәлсәфәсе: дөньяда тормыш нә кадәр агырайган саен, шул дәрәҗә эшчәнлекне арттырып, хурлык, ачлык хәленә калмау.

Бу фикер, болай уйлау бу көндә бөтен Яурупа халкына кереп урнашкан. Бу фикергә бары безнең Русия кешеләре вә Шәрекъ кавемнәре генә барып җитмәгән. Җитәрләр, хәят безне дә тиздән чыбыркылар. Ләкин куркылачак хәл будыр:

Хәятның читенлекләре яурупалыларны чыбыркылый да фәгалиятләрене, эшчәнлекләрене, гайрәтләрене арттыра. Безнең исә бу хәят зарбәләре [7] бик тиз хәлдән тайдыру, үлтерү ихтималы бар. Алла сакласын! Минем фикеремчә, без русиялеләр гомумән, шәркый Русия халкы хосусән [8] белергә тиешмез ки, дөньяда тору көннән-көн читенләнә барадыр, истикъбальдә [9] хәят дәһшәтле бер мөҗадәлә [10] хәлене алачактыр.

Без бу «мөҗадәләи хәят»ка хәзердән үк хәзерләнә башларга тиешмез. Әлбәттә, иске тормыштан аерылу читен, Русиядә авыл халкы җәйне бер-ике ай эшли дә, кыш буенча пич башында ята иде. Безнең төрки кабиләләрдә исә ирләре бөтенләй бер эш эшләми иде диярлек: хатыннары суккан киезләргә утырып, хатыннары сауган сөттән ясалган кымызны эчеп тик рәхәтләнеп утыралар иде. Ара-тирә күрше кабилә илән сугышып алалар иде. Бу бик күңелле иде: эш юк, һәрвакыт бәйрәм иде. Бу көн авылга җырчы килә, иртәгә такмакчы килә. Уен да көлке. Әлбәттә, бу хәяттән аерылу, бу рәвештә тормышка әле ләбеддә [11] «хуш, сау бул» дип әйтү бик читен. Ләкин, әгәр дөньяда торасымыз килсә, шәркыйләр гомумән, без русиялеләр хосусән, бу иш «аз эшләү» тормышына әл-видагъ [12]

---

[1] *Шимали* — төньяк.
[2] *Кәлисә* — чиркәү, собор.
[3] *Сатхы арыз* — җир өсте.
[4] *Ләйсел-нисан әл-мәсагый* — тырышмаган адәм түгел.
[5] *Мужибенчә* — тәртибенчә.
[6] *Шулай җари ки* — шулай ага, дәвам итә ки.
[7] *Зарбә* — тукмак, удар.
[8] *Хосусән* — бигрәк тә.
[9] *Истикбальдә* — киләчәктә.
[10] *Мөҗадәлә* — бәхәс.
[11] *Ләбеддә* — котылгысыз.
[12] *Әл-видагъ* — хуш, сау бул.

дияргә тиешмез. Инкяр итмим, бу әл-видагъ бик авыр. Дөньяда һәр видагъ, һәр аерылышу бик читен, ләкин лязем. Балалыктан чыгып, атаң эшкә җибәргәндә дә балалыктан аерылу бик авыр буладыр. Ләкин буңа карап гомергә бала булып булмыйдыр, бер бөлугъ [1] заманы киләдер. Инсан булырга тиеш буладыр. Шуның кебек үк, милләтләргә дә сабавәттән [2] чыгып, балигъ булырга тиеш буладыр. Эшкә тотынырга вакыт килеп җитәдер.

Бу вакыт безнең Русия әһалисенә килеп җитте. Аграрный мәсьәлә диямез, рабочий мәсьәлә диямез, һиҗрәт мәсьәләсе диямез. Бунлар һәрбере, әгәр тирәнрәк уйлап каралса, «артык эшләү яки күбрәк эшләү» мәсьәләсенә кайтып калалар. Һәр шәй бу мәсьәлә әтрафында [3] тулаша.

Гамәл, сәгый [4] вә гайрәт. Вә бу сайәдә хәятның агыр, үткен тешле чарыкларына килеп кысылмау.

Менә бу хәлне яурупалылар аңлаган. Менә бу Бельгиянең хәленә бераз дикъкать итик: 11 375 квадратный миль кадәр җирдә җиде миллион кадәр кеше яшидер. Һәм дә ничек яшидер! Имин булыңыз, ач кеше юк. Простой эшчегә кадәр көндә ике мәртәбә итле аш ашыйдыр; мәмләкәт шулкадәр бай, иң гади эшчегә кадәр аенда кырык сумнан ким казанмый.

Ничек итеп болар бу хәлгә килә? — Бик күп эшләп; Бельгия халкы гүя үз-үзенә дигән: «Иген игеп кенә бу кадәр аз җир илә без һәрберемез туя алу ихтималымыз юк. Без башка кәсеп итик. Без башка мәмләкәтләргә кирәк нәрсәләрне ясап сатыйк, бу акчага үземезгә лязем ашау нәрсәләрене алырмыз,— дигән. — Без сату вә фабрикачылык юлына керик» — дигәннәр. Бәхетләренә каршы, фабрикачылыкка лязем булган җир күмере дә мәмләкәтләренең астында тулы икән. Затән [5] җир күмере күп булу бу халыкны фабрикачы иткәнме, яки халыкның күплеге фабрикачылыкка сәвекъ [6] иткәнгә, бельгиялеләр җир күмерене эзләргә мәҗбүр булганмы?

Бу хакта бер мөбахәсә [7] ачарга да мөмкин. Бундый мәсьәләләрдә сәбәп бер генә булмый, галә-гайне заманда мәгълүл була [8]. Мәгълүл галә була. Гомумән, иҗтимагый мәсьәләләрдә бу хәл ярыйдыр.

Һәр нә исә, бу мәмләкәт дөньяның иң эшчән, иң бай бер мәмләкәтедер. Бу мәмләкәтнең фабрикалары вә бу фабрикаларда эшләнгән маллар — өмтәга [9] — дөньяның һичбер мәмләкәтенә юл куймыйдыр.

Бу мәмләкәттә ясалган маллар мәдәниятка иң кирәк нәрсәләрдер. Машиналар, комачлар, постаулар вә һакәза[10]. Буннан башка, Бельгия үзеннән арткан җир күмерене дә бик күп сатадыр. Буңа карап иген тарафыны бөтенләй ташлаган дип белмәңез. Иген игүдә дә Бельгия беренче урынны тотадыр. Шул кечкенә җир өстеннән мөмкин кадәр иң күп ашлык алалар, әллә никадәр хайваннар үстерәләр. Хәлясан[11], ничек кенә итеп җирнең өстеннән-астыннан файдалану мөмкин булса, шуны эшлиләр. Шулай тырышу аркасында бельгиялеләр мәмләкәтләрене беренче бай мәмләкәт дәрәҗәсендә тоталар. Бу мәмләкәтнең акча вә капиталлары бөтен дөньяда эшлидер. Бу мәмләкәтнең кешеләре дөньяның һәр тарафында мәдәният тараткан хәлдә кесәсене тулдырадыр. Бу хәл ничек мөмкин буладыр? Тәкрар әйтәм, бу мәмләкәт халкының армый-талмый бик күп эшләве аркасында.

Бельгия бер баштан икенче башына кадәр бер завод вә фабрика хәленә килгән дисәм, мөбаләга[12] аз булыр.

Бельгиядән үткәндә, Германиядә вә Франциядәге кеби, авылсыз басулар һич юк. Ун-унбиш сажинда бер йорт булмаган бер җир дә юк. Дөрест, без үткән җирләр бик тәҗарәт вә сәнагать[13] мәркәзе булган җирләр иде. Алай булса да, бу мәмләкәтнең кувәи мәгъмүрияте[14] дикъкатьне җәлеп итми калмыйдыр.

---

[1] *Бөлугъ* — җитлегү, балигълык.
[2] *Сабавәт* — сабыйлык.
[3] *Әтрафында* — тирәсендә.
[4] *Сәгый* — тырышлык.
[5] *Затән* — үзе.
[6] *Сәвекъ итәнгә* — этәргәнгә.
[7] *Мөбахәсә* — бәхәс, сүз көрәштерү.
[8] *Галә-гайне заманда мәгълүл була* — үз заманы сәбәпләренә нигезләнгән була.
[9] *Өмтәга* — сатыла торган мал, әйбер.
[10] *Вә һакәза* — һәм башкалар.
[11] *Хәлясан* — җыеп әйткәндә, кыскасы.
[12] *Мөбаләга* — арттыру, күпертү.
[13] *Тәҗарәт вә сәнагать* — сәүдә һәм промышленность.
[14] *Кувәи мәгъмүрият* — төзелеш куәте.

Бу кадәр фабрикачылык, бу кадәр эшләүнең уңгайсыз тарафлары да бар. Социализм вә гамәлә [1] мәсьәләләре шушы уңгайсызлыклар эченнән килеп чыгадыр. «Мал» илән «гамәл» мөҗадәләләре шундый фәгалийәт әуҗбиләгә [2] житкән вөсталарда туадыр. Бу жир бунларны тәфсыйль урыны түгелдер. Ләкин шул кадәресене әйтим: без, әксарийәть [3] нәзары илән әйткәндә, пич башында ятучыларга, хозур гына кымыз шапыручы кавемнәргә мал вә гамәл мөҗадәләсе, хәл вә нәзариясене [4] нә тәнкыйть итәргә вә нә тәкълид итәргә иртә вәояттыр. Буннан дәм [5] өрәсе килгән кешегә: «Уңмаган, ялкау, ни сөйлисең? Эшлә әүвәл» — дигән фикер авызга киләдер...

Франция хөдүденә життек.

## V

## Франциягә керү. Франциянең мәгъмүрияте. Бу хактагы җаһил фикерләр. Диңгездә. Франциягә Дума сәяхәте. Милюковның тырышлыгы. Лондонга житү

Франциягә кергәндә поезд алыштырмадык. Шул ук поездга Бельгия мәэмүрләре [6] жиренә француз мәэмүрләре менде. Германия вә Бельгиянең акрын вә салкын табигатьле мәэмүрләреннән соң сөемле, ачык, сөйләшергә ятучан мәэмүрләр һәр каюмызга гаять хуш тәэсир итте. Хосусән ул матур француз лисанында сөйләшү тавышлары күңелгә гаять хуш килә иде. Германия вә Бельгиядән үтеп Франциягә чыкканда хис ителгән хисне нигә кыйас итим [7] икән?

Бик яхшы танымаган, гакылы салмак бер кеше белән азрак эчпошып сөйләшеп утырганда, искедән таныш, шат, якын бер дустың килеп кергәндә ничек мәмнүн булсаң, Германиядән яхуд Бельгиядән соң Франциягә кергәндә һәм шундый бер шатлык хасыйл буладыр. Бу хәлне бу сәфәрдә генә хис вә тәҗрибә итмәдем, буннан башка вакытта Франциягә килгәнем вакытларда һәм гайн хәлдә [8] булган идем.

Поезд бик каты сөргать [9] илә Франция жиреннән тәгәри башлады. Һава кичә Германиядәге кеби матур, саф, ачык иде. Эссе түгел иде. Франциянең шимале шәркыйсеннән үтә идек.

Франциянең бу кыйсеме игенчелек, хайван асрау илә көн күргән кыйсемедер.

Алдымызда матур игенлекләр, мәгъмүр карьйәләр, яшел болыннар, зур һәм вак, ике тарафы тезелеп, агач утырткан бик матур таш юллар күренә иде. Бу юллар һич шөбһәсез Германиядәгедән һәм Бельгиядәгедән матуррак иде. Безем Русиянең күп жирендә матур юл дигәч, нә икәнен дә аңламыйлар. Яурупада юл көпчәк эзе төшкән, арбалар уза торган, басуның бер кырында чокырланган сызыклр дигән сүз түгел, Яурупада юл ясалган, төзелгән, тәгъмир ителгән[10] бер нәрсә. Яурупада ике иң кечкенә карьйә юктыр ки, арасында ике тарафы агач илә зиннәтләнгән, тигезләп таш җәелгән, һәр лязем жирендә күперләр ясалган бер юл илән берләшкән булмасын. Яурупа көзге былчырак, язгы юлсызлыкның нә икәнен белмидер. Хосусән бу хакта Франция юлларының пөхтә вә матурлыгы гаҗәептер; Франция үзенең юллары матурлыгы илән искедән ифтихар итә[11] килгән бер мәмләкәттер. Франция юлларының шулкадәр матур жирләре бар ки, үзеңне бер бакчада зан итәрсең[12]. Юлның ике тарафыны, зур күләгә бирә торган агачлардан башка, башыны тигезләп киселгән акация илән зиннәтләгән буладыр.

---

[1] *Гамәлә* — эшләүче, гамәл итүчеләр (эшчеләр).
[2] *Фәгалийәт әуҗбиләгә* — эшчәнлек югары ноктага.
[3] *Әксарийәт* — күпчелек.
[4] *Нәзария* — теория.
[5] *Дәм* — сулыш.
[6] *Мәэмүр* — чиновник.
[7] *Кыйас итү* — охшату, чагыштыру.
[8] *Гайн хәлдә* — шул хәлдә.
[9] *Сөргать* — тизлек, ашыгычлык.
[10] *Тәгъмир ителгән* — төзекләндерелгән.
[11] *Ифтихар итү* — мактану, горурлану.
[12] *Зан итү* — уйлану, хис итү.

Поездның тиз баруы һәркемне йокымсырап барудан уяткан иде. Иптәшләремезнең күбесе вагонның коридорына чыкты. Болар да Франциянең мәгъмүриятенә дикъкать иттеләр.

Граф Бобринский миңа:

— Менә, Максудов, сезнең сөйгән мәмләкәтеңез,— диде.

— Аны якыннан белсәңез, сез дә сөяр идеңез. Бу французлар яхшылап танылганда сөймәслек бер халык түгел. Анларның мәмдух[1] сыйфатлары косурларыннан[2] артыграк,— дидем.

Мин буны әйтеп бетерер-бетермәс граф:

— Мин үзем дә французларны фәүкыльгадә яратам. Минем бу мәмләкәттә бала вакыттан бирле хатирәләрем бар,— диде.

Графның бу фикеренә Шидловский һәм тагы берничә кеше катышты, гомумән, хор илән Франция вә французларны мактарга тотынды.

«Новое время» мөхбире Суворин да безнең илән басып тора иде. Мин аңа да карап дидем:

— Бездә юкка Думада уңлар Францияне җай чыккан саен кагалар,— дидем.— Бу сәнә бер уң депутат: «Харап булачак Франция», диде; менә карыйк инде, бу мәмләкәт харап булып барганга охшыймыдыр? Карыйк бу матур карьйәләрне, карыйк бу юлларны, карыйк бу игенлекләрне, карыйк басуларны сугара торган су каналларыны — арыкларны, карыйк бу үсеп яткан бәрәкәтле богъдай басуларыны, карыйк чәчеп үстергән мул печәнлекләрне, карыйк бу симез хайваннарны, карыйк менә бу һәр авылның уртасындагы мәктәпләрне. Ничек итеп бу мәмләкәтне харап була диярга кирәк? — дидем.— Бу мәмләкәтнең мәгарифенең алда икәненә һичкем бер сүз әйтү ихтималы юк. Байлыклары исә галәмгә мәшһүр; безнең Русиягә 13 миллиард кадәр акча биреп тора алалар. Бу Францияне бетә дию безнең Германияне яраткан уң матбугатның эшедер,— дидем.— Асылда уңларның харап була-фәләннән максудлары Франциянең хөрриятене күрә алмаудан башка бер нәрсә дә түгел,— дидем.

Бу сүзләрдән соң граф Бобринский:

— Сез нинди Франция мөдафигысеңез![3] — диде.

Шидловский, зирагать[4] җәһәтеннән Франциянең алда булуыны авылларда милекнең хосусый булуыннан, дип бәян итте (Шидловский 9 нчы ноябрь законының докладчигы иде).

«Новое время» хуҗасының угылы Суворин диде:

— Мин Максудов рассуждениеләрене дөрест табам; Франция дөресте дә дәүләт вә байлык ягыннан замечательный бер мәмләкәт, мин бугенге фикерләремезне үземезнең гәзитәгә һич шөбһәсез язарым,— диде.

Шулай сөйләшә-сөйләшә барганда диңгез кырыендагы Кале шәһәренә килеп життек. Кале тугърысында: Англия илән Францияне аерган Ла-Манш диңгезенең иң тар жиредер. Диңгездә озак йөрергә яратмаган кешеләр һәрвакыт Яурупадан Англиягә Кале аркылы чыгалар.

Каледә безне көтеп торган Милюков вә Ефремовны таптык. Поездан төшү илән тугъры пароходка мендек. Диңгез пароходларыны бу урында тәгъриф итүгә хаҗәт юк. Диңгез тыныч иде, пароход бик аз селкенә иде. Шуның өчен диңгез авыруына мөбтәлә[5] кеше күренмәде. Диңгездән кичү илле дәкыйка[6] кадәр дәвам итте.

Бу мөддәттә Думада бәйнәлмиләл[7] группасының рәисе Ефремов миңа үзенең ике көннән бирле Парижда булганыны, Парижда байтак парламент әгъзаларыны күргәнене, үткән сәнәдән Берлиндә танышкан француз депутатларының миңа сәлам әйткәнене сөйләде вә Лондоннан соң бер генә көнгә булса да Парижга сугылуымызны үтенгәннәрене белдерде.

— Бу ел Парижга керү чын сәяхәт саналмый, шул, Дума әгъзаларыннан чын сәяхәтене ничек ясарга, кайчан ясау хакында бер киңәш зиярәте булып кына саналачактыр,— диде.

Бу Думаның бәгъзы кешеләренең Парижга бару вә француз депутатларының Петербургка килүләре мәсьәләсене асылда үткән сәнә Берлиндә Ефремов белән мин кузгаткан идек. Мин бу хакта Думада бәйнәлмиләл группасының икенче

---

[1] *Мәмдух* — мактаулы.
[2] *Косур* — кимчелек.
[3] *Мөдафигь* — саклаучы.
[4] *Зирагать* — игенчелек.
[5] *Мөбтәлә* — дучар булу.
[6] *Дәкыйка* — минут.
[7] *Бәйнәлмиләл* — интернациональ, халыкара.

кятибе булу мөнәсәбәте илә француз депутатлары илән хатлар да язышкан идем. Бу хатлар язышу хосусый булса да, буны бәйнәлмиләл группа рәисе Ефремовтан башка Милюков, Гучков вә Хомяков кеби кешеләр һәрберсе белә иде. Без Франциягә чакырылган идек. Әгәр дә кинәттән Англиядән чакыру-дәгъвәт төшмәсә, без бу сәнә Англиягә бару урынына Франциягә барачак идек.

Ләкин Англиягә бару Франциягә бару фикерене бетерде түгел, билгакес, куәтләде. Француз депутатлары әүвәл Англиягә баруга бер дә үпкәләмәделәр, дөньяның иң иске парламентына иң әүвәл бару бер дә гаҗәп түгел, табигый, диделәр.

Шул сәбәпләргә мәбна[1] Ефремов миңа:

— Лондоннан соң берничәмезгә Парижга керергә тугъры килер,— диде. Бу мәсьәләне бездән ерак түгел укып утырган Милюковка да сөйләде.

Милюковның укыган китабына дикъкать иттем. Франциянең иң зур гәзитләреннән «Тан» гәзитәсенең зур мөхәррирләреннән мосье Тардьеның «Сәясәте харижия»[2] дигән китабы иде. Бу Милюковка хәйран калмау мөмкин түгел. Бертуктамый укый. Карый, тикшерә; бертуктамый үзенең мәгълүмат чемоданыны тутыра, мәгълүматыны яңарта барадыр; һич арымый, һәрвакыт сәяхәттә, бүген — Америкада, соңра — Болгариядә, тагы бераз соң — Төркиядә. Ниндәй генә мәсьәләдән сүз ачсаң, ярты, кайчакта берничә сәгать сөйләрлек мәгълүматы бар. Нә кадәр куәтле бер баш! Нинди каты бер гайрәт! Нинди арымас бер фәгалийәт!

Никтер, шул көн Милюковның, игътибарының, шөһрәтенең вә хакыйкый игътидарының сәбәбене хис вә кәшеф итәр[3] кеби булдым, үз-үземә Милюков тикмәгә Милюков түгел, дидем.

Диңгез пароходы Англия сахиленә[4] килеп туктады. Пароходтан Дувр шәһәренә төштек. Бунда һәм Каледәге вокзал илә пристань бер җирдә үк, мәшәкатьсез күчеләдер.

Безгә махсус хәзерләнгән вагон илә Лондонга юнәлдек. Бик арыганга күрә, вагон тәрәзәсеннән күп карый алмадык. Алай булса да, күз салгаладым. Яшел-яшел болынлык вә басулар күренә иде. Әллә кайдан башыма кереп калган, Англиядә яшел басулар көннән-көн юк була бара, дигән сүзнең ялган икәнене мөшаһәдә[5] итдем.

Буген якшәнбә булганга, якшәнбә көн Лондонда һәр шәй ябык булганга, вокзалда рәсми кабул булмас, диделәр. Арыган идек. Фәбиһа вә нигамә[6], дидек. Алай булса да, вокзал төрле гәзитә мөхбире, фотографлар илә тулы иде. Аннан башка профессор Перс вә башка берничә, югарыда мәзкүр комитет кешеләре дә каршы (алырга — *ред.*) төшкән иде. Безне вокзалдан автомобильләргә утыртып, Лондонның иң зур миһманханәсе «Вестминстер палас һотел» (Westminster palase hotel) дигән һотелгә алып киттеләр.

## VI

### Лондонда килгән көн кич. Ирландияләләр табигате.
### Тәрәкъкыйпәрвәрләр клубы. Англиядә клублар хәяты.
### Лондонда беренче көн. Рәсми кабул. Лондонны карау

Килгәч, үземә тәгаен ителгән бүлмәгә нәрсәләремне бераз урнаштыргач ук, звонок басып, хадимне чакырдым. Французча тиз генә: «Ванна хәзерли аласызмы»,— дидем. Хадимә бер сүз аңламады.

---

[1] *Мәбна* — нигезләп.
[2] *Сәясәте харижия* — тышкы сәясәт.
[3] *Кәшеф итү* — ачу, төшенү.
[4] *Сахиленә* — диңгез ярына.
[5] *Мөшаһәдә итү* — күз белән күрү.
[6] *Фәбиһа вә нигамә* — бик хуш.

Мин Германиядә, Швейцариядә миһманханәләрнең һәрберендә хадим вә хадимәләрнең французча белүләренә өйрәнгән идем. Англиядә эш бүтән икән. Англиядә простой халыкта әҗнәби лисан [1] белү бер дә мәгъруф [2] түгел икән.

Мин бервакыт Франциядә вакытымда җәй көне бераз инглизчә үгрәнергә маташкан идем, шул вакытта үгрәнгән берничә йөз сүз вә җөмлә тәркибе рәвеше әле дә хәтеремдә иде. Шул белгән сүзләремнән кушып: «Хәзерләргә мөмкин буламы?» — дигән сүзләрне оештыра алдым. Ләкин «ванна» кәлимәсене белмим. Тиз генә чемоданымны чишеп, лөгатьнамәне алдым. «Ванна» кәлимәсене һәм таптым. «Бат» икән. Ләкин аның белән дә хадимә оештырган җөмләне тиз аңламый каефне җибәрде.

Шулай хадимә илә бәйләнешеп торганда каршы бүлмәдән безнең мөкяләмәне [3] ишеткән Милюков килеп чыкты:

— Сез «бат» кәлимәсендәге «һ»ны «т» кеби тәләффыз итәсеңез [4], бу — француз тәләффызыдыр. Буны «тс» кеби сакау тәләффыз итәргә тиеш,— диде. Вә тиз генә кызга минем морадымны аңлатты.

Рәхәтләнеп «бәтс»дә юынганнан соң, якаларымны вә пиджәкләремне алыштырып, түбәнгә, кичке тәгамга төштем. Тәгамнан соң комитет кешеләреннән бер яшь егет:

— Әфәндем, әгәр арыган булып, ятарга теләмәсәңез, эстәсәңез, сезне тәрәкъкыйпәрвәрләр клубына алып барам. Сез ул клубта бу көннән игътибарән [5] бер айга кадәр әгъзасыңыз,— диде.

Ваннадан соң рәхәтләнеп киткән идем. Йокласым килми иде, кабул иттем. Миңа җитәкчелек итүче яхшы гына французча сөйли белә торган бер егет иде. Тиз генә үзенең кем икәнене сөйләде. Гәзитә мөхбире икән. Күптән түгел Ираннан, Тәбриздән кайткан. Анда байтак заман «Таймс» вә аннан башка бер гәзитәдә язып торган икән. Үткән сәнә Төркия вакыйгаләре заманында Салоникада булган икән. Ираннан вә Төркиядән бәхәс иткәч, мин мөселман вәкиле икәнемне әйттем.

— Мин аны беләм,— диде.— Комитет мине, сез мөселманнар илә мөгамәлә итә беләсеңез, французча да беләсеңез дип, сезгә тәгаен итте. Комитетка сезнең безнең телне белмәвеңез дә мәгълүм иде,— диде.

Егет — шатырәтле [6]. Үзенең башына килгән бөтен хәлләрдән озын бәхәсләр итәргә башлады. Табигате инглизләр хакында минем белгәнемгә бер дә охшамый иде. Ачык, уйный-көлә. Ахыры үзе дә минем баштагы бу сөаль хәзерләнгәнне сизде бугай:

— Минем тип сезгә бәлки гаҗәп күренә торгандыр. Инглизләр хакында әҗнәбиләр [7] арасында мәшһүр булган мисалга тугъры килмим, шулай бит? Мин бу җәзирә инглизе түгел, мин ирландияле,— диде.

Һәм дөресте дә, буннан соңра мин байтак ирландиялеләр күрдем. Алар бер дә салкын түгел. Бик сүзчән, көлүчән, ачык. Сима [8] җәһәтеннән һәм зур фәрекъ бар. Ирландиялеләр күбесенчә кара, хәлбуки инглизләрдә иң таралган тип — сары типтыр.

Шулай сөйләшкәндә клубка килеп җиттек.

Кердек. Клуб — бер «Сарай». Клуб хәятының фазыйләтләрене [9] күптән ишетсәм, бу хакта укысам да, бүгенгә кадәр буны хис иткәнем юк иде. Без килгән клубның рәсми исеме Национал либерал клуб («Насионал либерал клуб»), бунын әксәр әгъзалары — парламент әгъзалары, депутатлар имеш. Аннан кала әдип, журналист вә сэрлар да дахил имеш.

Иң әүвәл барып кердек икенче каттагы укый-укый чәй яхуд башка нәрсә эчә торган җиренә. Бер дә безнең Русия клубларына охшамыйдыр. Бунда үзеңне хосусый йортка кунакка килгән кеби күрәсең. Һәр җирдә йомшак палас җәелгән. Һәр җирдә уңгай-уңгай, йомшак сәхтиян белән капланган урындык-креслолар; һәр җирдә вак, түгәрәк өстәлләр. Дикъкать итәчәк бер хәл: урындыклар да, өстәлләр дә бик тәбәнәк. Боларның болай булуы клубка тагы да бер хуш рәң [10] бирәдер.

---

[1] *Әҗнәби лисан* — чит тел.
[2] *Мәгъруф* — билгеле, мәгълүм.
[3] *Мөкяләмә* — сөйләшү, гәп.
[4] *Тәләффыз итәсеңез* — әйтелештә бирәсез.
[5] *Игътибарән* — башлап.
[6] *Шатырәтле* — житез, шаян.
[7] *Әҗнәбиләр* — чит-башка милләт кешеләре.
[8] *Сима* — чырай, төс.
[9] *Фазыйләт* — өстенлек.
[10] *Рәң* — төс, рәвеш.

Аннан соң уку бүлмәсенә кердек. Һәртөрле инглиз гәзитәләре илә залның әтрафы тулы. Әҗнәби гәзитәләр аз күренә; бер-ике француз гәзитәсе күрдем. Буннан башка дикъкать ителәчәк нәрсә — өстәлдә бюджет проектлары вә башка әллә никадәр закон проектлары ята иде. Күренә ки, әгъзалар арасында депутат күбрәк, юкса бу күңелсез нәрсәләрне укучы күп булмас иде.

Уку бүлмәсенең өстәле бик уңгай; һәр укучыга махсус, вак электрик лампалары бар. Шуннан ерак түгел бер кечкенә бүлмә язуга махсус.

Буннан соң бильярд бүлмәләрене, уен бүлмәләрене карагач, янә каһвә эчә торган бүлмәгә кайттык. Җитәкчем миңа бу клуб вә гомумән клуб хәяты хакында мәгълүмат бирә иде.

Лондонда бундай зур клублар җитмешләп бар имеш. Бунларга әгъза булу бик асат түгел имеш. Бердән, әгъзалыкка кабулдан әүвәл бик каты бер сайлау бар имеш. Буннан башка, кергәндә 25 фунт стерлинг кадәр, ягъни ике йөз илле сум чамасында бер мәблəгъ[1] түләгәннән башка, бердә һәр ел илле сум кадәр «сәнәвия»[2] түләргә кирәк була икән. Ләкин әгъза булгач, һәртөрле уңайлыклар бунда мәүҗүд: чәйханә, көтебханәсе, кыйраәтханәсе[3], уенханәсе. Ашханәсендә Лондонның иң яхшы ресторannарыннан яхшырак ашарга мөмкин була имеш. Бәһасе төшкән бәһасенә бирелә имеш.

Инглизләр буш булдымы, клубка чаба имеш; клублар инглиз хәятында бик зур роль уйнаганыны шунда да күрергә мөмкин: күбесенчә визит карточкасына кайсы клуб әгъзасы икәне язылган була. Кызык! Һәр мәмләкәттә бер җыелып сөйләшә торган бер җир буладыр. Французларда күрешү, сөйләшү каһвәханәләрдә була, немецләрдә сыраханәләрдә була, төрекләрдә һәм каһвәханәдә. Безем Казан исламнарында — чәйханәдә вә һакәза; һич бер мәмләкәт юк ки, кешеләр өендә генә утырсын.

Безнең русларда акрынлап клуб хәяты модага кереп барса да, клублар күңелсез, рухсыз, әксәрия ресторannарга, эчке җирләренә охшыйлар. Клублар тыныч кына барып, дустлар белән сөйләшеп утырып, сөйгән гәзитәләрне укып, бераз дөнья әхваленнән хәбәрдар булып, теләсәң, аз гына берәр уен уйнап эчпошканыны бетереп кайта торган булырга тиеш. Безем Петербург клубларында иң әүвәл клубка керсәң, күзгә төшкән тау кадәрле мөскират[4] илә тулган буфет була. Ләкин инде Петербургта һәм яңа тәртиптә берәр кружок, бик күңелле клублар ясадылар бугай.

## VII

### Лондонда беренче көн. Килүемезне рәсми тәбрик. Лондон хакында берничә мәгълүмат. Лондонны тамаша. Лондон Биржасы. Англия банкысы

Егерме беренче июньдә иртә белән торып, миһманханәмезнең йимәк[5] салонында каһвә эчкәннән соң, һәрберемезне «мөдәббирләр» (мөдәббир дип комитет тарафыннан куелган кунакларны алып йөртүче кешеләрне атыймын. Инглизләрдән — профессор Перс вә саир, безнең арадан — Звегинцев) безгә махсус тәгаен ителгән салон бүлмәгә чакырдылар. Без, һәр депутат вә Совет әгъзалары, салонга җыелып озак утырмадык. Безне рәсми кабул итәргә берничә кеше килде. Боларның башында Англиянең безем Государственный Советы кабиленнән[6] булган Лордлар палатының әгъзасы вә бәйнәлмиләл группасының рәисе лорд Уирдэль иде. Лорд Уирдэль безгә безне чакырырга катышкан бөтен Англия халкы исеменнән инглизчә «Хуш килдеңез» нотыгы сөйләп, буңа Хомяков рәхмәт укыды. Буннан соң Лондон дарелфөнүне[7] профессорларыннан берсе генә бер кечкенә нотык сөйләп, буңа Милюков җавап бирде. Хомяков та, Милюков та инглизчә беләләр. Болардан башка Шидловский,

---

[1] *Мәблəгъ* — сумма, акча күләме.
[2] *«Сәнәвия»* — еллык (взнос).
[3] *Кыйраәтханә* — уку бүлмәсе.
[4] *Мөскират* — исерткеч эчемлек.
[5] *Йимәк* — ашау.
[6] *Кабиленнән* — төркеменнән, даирәсеннән.
[7] *Дарелфөнүн* — университет.

Бобринский, Звегинцев инглизчә бөтенләй яхшы сөйлиләр. Калганнары сөйләшерлек белмиләр. Бу кечкенә нотыклардан соң лорд Уирдэль безнең көн эчендә ниләр кылачагыбызны, кай җирләрдә булачагыбыз хакындагы програмны укыды. Буннан соң бер почмакка оештырып, һәрберебезнең рәсемнәрemезне алдылар. Бу рәсем, мәгаттәәссеф[1], начар төште. Шул начар көенчә бөтен Англия рәсемле гәзитләрендә сәяхәт итте. Арабыздан бары бер-ике генә кешене яхшылап танып була иде. Кем белсен, бәлки рус гәзитәләренә дә күчкәндер.

Бу мәрасимдән[2] соң, мөдәббирләр игълан иттеләр ки, бүген ике төрле эш бар: берсе — Лондон дарелфөнүн профессорлары мәгыйтендә[3] Лондонны карап йөрү, икенчесе — Лондоннан ерак түгел бер шәһәрдә булачак бер тарихи бәйрәмне карарга бару, диделәр. Депутатларга икегә бүленергә кирәк була, диделәр. Минем авылга барасым килмәде. Лондон караучыларга кушылдым.

Профессорлар илән бәрабәр урамга чыктык. Автомобильләр күтеп тора иде. Миһманханәмезнең коридорында гәзитә мөхбирләре тулган кеби, урамда һәм рус депутатларыны карыйсы килгән кеше тулы иде. Рәсми кунак булганга, без һәрвакыт урамга чыкканда башта цилиндр кияргә мәҗбүр идек. Өстебездә иртә белән пиджак, өйләдән соң — сюртюк, кичке мәҗлесләрдә һәрвакыт фрак кия идек.

Автомобильләргә утырып Лондонны карарга киттек.

Иң әүвәл мөһим урамнарыннан узып, бер дәрәҗә зур урамнарының ничек салынганы хакында вә Лондонның гомумән мәүкыйгы[4] хакында бер фикер хасыйл иттек. Янымыздагы профессор вә кичәге ирландияле егет французча һаман кирәк бәйанәтне сөйләп кенә торалар иде. Мин дә аларның Лондон хакында безгә сөйләгән тәфсыйләтләреннән, үзем күргәннәрдән җыелган мәгълүматымны сезгә язам.

## Лондон

Лондон — дөньяның иң зур шәһәредер. Бу көндә Лондонда биш миллион чамасында халык яшидер. 1891 нче сәнәнең тәхрире нөфүсенә[5] күрә, Лондонның үзендә 4.211.056 торучы кеше бар имеш. Хәлбуки, дөньяның иң зур шәһәрләреннән Парижда мәҗмугъсы өч миллион кадәр генә кеше яши.

Лондон әһалисе, халык күплегеннән киная итеп, Лондонда Шотландиянең пайтәхете булган Эдинбург шәһәрендәгедән күп Шотландия кешесе булганыны, Фәләстыйндәгедән дә күп яһүди булганыны, Румадагыдан да күп католик булганыны, Ирландия мәркәз идарәсе Дублиндагыдан да артык ирландияле булганыны сөйлиләр.

Ләкин Лондонның зурлыгы хакында бер тасхих[6] лязем. Лондон Париж кеби бер шәһре вахид[7] түгел. Лондон зурая-зурая бер-беренә килеп кушылган дүрт шәһәрдән мөрәккәб. Шуның өчен әһәмиятле булган, мәркәз булган җире Париждан бер дә зур түгел. Билгакес.

Лондонның беренче тәэсире бик яхшы түгел: Лондон, шөбһәсез, Париждан да, Берлиннән дә ямьсез. Лондонда Париждагы кеби мәһабәт мәйданнар да юк, Берлиндәге тәмизлек[8] тә юк. Һәр шәйдән әүвәл күзгә төшкән нәрсә — зурлык. Зурлык вә күплек. Урам, урам, тагы урам. Урам тулы кеше, извозчик, кеше, извозчик. Автомобиль белән чабамыз. Янә урам, янә кеше. Магазин, кантор, банкы. Бу тулы кешеләр һәрбере кыймылдый. Әллә кая бара, килә. Җөмләсенең бер планы, үе бар — тикмәгә чапмый. Бөтен шәһәр гөжелди. Автомобилемез һаман бара.

Мин янымдагы яшь профессордан сорадым:

— Лондонның һәр җирендә шулай тыгызлыкмы, әллә бу кыйсьме генәме? — дидем.

— Башка әтрафы бу кадәр тыгыз түгел. Сезне без хәзер иң галәбәлек[9] булган, сәүдә вә тиҗарәт мәркәзе булган Сити (City) дигән җиренә китердек. Менә хәзер Биржага килеп җитәмез. Биржаны кереп карармыз, — диде.

---

[1] *Мәгаттәәссеф* — үкенечкә каршы.
[2] *Мәрасим* — рәсми йола, тамаша.
[3] *Мәгыйтендә* — юлдашлыгында, бәрабәрлегендә.
[4] *Мәүкыйг* — урын, мәйдан.
[5] *Тәхрире нөфүс* — халык саны язмасы.
[6] *Тасхих* — төзәтү, искәрмә.
[7] *Шәһре вахид* — бербөтен шәһәр.
[8] *Тәмизлек* — чисталык, пакьлек.
[9] *Галәбәлек* — өстенлек.

Озак үтмәде, автомобильләр Биржага килеп туктады. Тыштан бер дә мөһим бина булып күренмидер. Тәбәнәк бер бина. Алдында курант, тарзы мигъмарийәсендә[1] таш баганалар. Фасадның өсте катында кинаяле рәсемнәр.

Тиҗарәттән киная бер кеше үзенең имтиязларыны (привилигияләрене) кулына тоткан; аның әтрафында, аның уң тарафында — шәһәр головасы (мохтары) вә башка шәһәр мәэмүрләре, бер гарәп, бер һиндстанлы, бер дә госманлы төрки; сул тарафта — инглиз сатучысы, бер кытайлы, бер кара негр. Болар һәммәсе бу Биржаның бөтен дөнья тиҗарәтенә мөнәсәбәте булганына бер галәмәт имеш.

Биржаның эченә кермәстән әүвәл бер кечкенә даирә (двор) бар. Бу даирәнең әтрафында зур картиналар. Арада берсе мәшһүр Англия короличәсе Елизаветаның рәсеме, ат өстендә. Бу рәсем алдында житәкче профессор безгә диде:

— Караңыз безем Елизаветаны, нинди матур рәсемлиләр. Ул андый матур хатын түгел иде,— диде.

Мин буңа каршы:

— Билгакес, бу тарихан һәм матур хатыннардан санала түгелме? — дидем.

Профессор көлеп:

— Тарихта ялганнан күп нәрсә юк. Минем үземнең дә ихтисасым[2] тарихтыр. Хәзерге яңа тарихилык ысулы шул иске тарих ялганнарыны арчудан гыйбарәттер. Истикъбальдә бик күп тарих потларыны җимерергә тугъры килү ихтималдыр,— диде.

Безнең илә бәрабәр булган поляк депутаты Монтивил бу сүзләрне яратмады:

— Нигә тарихны җимерергә кирәк? Милләтләр тарихның матур сәхифәләреннән рух аладыр. Тарихның матур мисалларыны күреп, гайрәт вә хәмийәт[3] хасыйл итәдер. Һәм милләт үзенең милләте тарихының матур сәхифәләрендә күңел юата, истикъбале өчен өмидләрене арттыра,— диде.

Буңа каршы яшь инглиз профессоры:

— Дөрест, ләкин шул ялган мәхәббәтләр, ялган мисаллар аркасында мәдәният юлыннан сабаң, ялгыш юлларга кереп китәдер...

Яшь профессор шул юлда дәвам итәчәк иде. Ләкин ул арада башка иптәшләрем килеп:

— Әйдә, тизрәк, өйләгә кадәр башка берничә җирне дә күреп өлгерик,— диделәр.

Биржаның чынлап кягадләр[4], әүракы сәмәния[5] сатуы була торган бүлмәсенә кермәдек. Ләкин ишектән карадык. Шау-шу житәрлек иде.

Биржаның рәсми исеме Королевский Биржа — Royal Exchange — иде. Буннан соң Англия банкысына килдек.

Минем фикеремнән яшь профессорның «тарих потлары» дигән сүзе чыкмый иде. Бу егет ник болай үз мәмләкәте тарихына ямьсез карыйдыр? Бу бунын шәхси фикереме? Тарихта хәкыйкать эзләү ысулы булса да, бу ысул әсхабидә[6] бөтенләй үк искедән килгән тарихи олугъларны атып ташлаганга охшамыйлар. Мисал — француз мөәррихләреннән Сеньобос.

Монда нә сер бар, дидем. Шөбһәсез, бу егетнең бөтен тарихка нәзары, тарихе мәдәниятка нәзары башка, дидем. Моны белер өчен еракган китереп сорадым:

— Сөйләсәңезлә, профессор әфәнде, дарелфөнүн даирәләрендә Карл Маркс фәлсәфәсенең абруе бармыдыр? — дидем.

Егетнең чырайлары яктырды: Маркс фәлсәфәсендә тарихка нәзарның әһәмиятене, ләкин, мәгаттәәссеф, дарелфөнүн даирәләрендә бу тарихка маддиюнанә[7] әһәмият бирмәгәннәрене сөйләде.

Буннан соң банкыга бардык.

Бу Англия банкысы дөньяның иң зур банкысыдыр. Бу да искедән калма бер бина булганга, бунын да харижи рәвеше бер дә мәһабәт түгел, бер генә катлы бина. Ләкин эчендәге алтыннары тышкы ягыны гафу иттерә. Шу кечкенә бер бакча эчендәге банкы дөньяның иң зур акча хәзинәседер. Банкы 1691 сәнәдә тәэсис ителгән[8]. Вильям Патерсон дигән шотландияле бер кеше тәэсис иткән. Ул вакытта банкының бар капиталы 1200000 фунт стерлинг булган. Бүген аның капиталы бунын кадәр 12 өлеш булган имеш. Банкыда бар хезмәт итүче 900 ләп

---

[1] *Тарзы мигъмарийәсендә* — төзү-архитектура ысулында.
[2] *Ихтисас* — белгечлек.
[3] *Хәмийәт* — соклану дәрте.
[4] *Кягад* — кыйммәтле кәгазь.
[5] *Әүракы сәмәния* — акча язулы кәгазь (акция).
[6] *Әсхабидә* — иялэрендә (белгечләрдә).
[7] *Маддиюнанә* — материалистик.
[8] *Тәэсис ителгән* — төзелгән.

вар имеш. Банкының базларында һәрвакыт 15—20 миллион фунт стерлинг кадәр, ягъни 200 миллион (рубля) кадәр сугылмаган алтын ята имеш. Вә шуның кадәр кыйммәтле кәгазьләре бар. Банкы фәкыйрь түгел. Һәр көнне 20 миллион кадәр оборот ясый имеш. Бу банкы бер акционерный общество. Бу формада ачылган банкыларның беренчесе имеш. Англиядә кәгазь акча чыгару бары бу банкыга махсустыр.

Банкыны өстән-өстән генә карап бетергәч, өйгә кайттык. Күчердән килгән юлдан кайтмай, башка җирдән алып кайтырга үтенгән идек. Ләкин бунын бер дә фәрекы булмады. Янә урам, урам. Янә кеше, арба, кеше, арба... Һәр шәй кыймылдый.

Өйлә тәгамене ашагач, янәдән йөрергә чыгачаксыңызмы? дигәннәр иде. Ефремов илә мин сәфәрдән арыганымызны бәһанә итеп[1], бераз ялгыз буласымыз килә, дидек. Дөресте, бүгенге ярты көнне бу бәйанчылардан башка Лондонны үземез генә сәер итәсемез килә иде. Йимәктән соң, чынлап та бераз ял иткәннән соң, Ефремов илән икемез, кешедән башка, мөстәкыйль, Лондонны карарга киттек.

## VIII

## Пикаделли. Һайд Парк. Англиянең сәрвәте[2]

Кешесез-йөртүчесез, Ефремов илән икемез Лондон карарга чыктык. Мәгълүменез, бундый зур шәһәрдә җәяү йөреп бер нәрсә дә күрер хәл юк, бик тиз адашылачак. Лязем булды арбачы алырга. Лондонда ике төрле арбачы бар. Берсе ике көпчәкле арба җиккән арбачылар. Икенчесе — дүрт көпчәкле. Бу соңгылары көннән-көн азая бара имеш. Алар урынына атсыз арба — автомобильләр йөридер. Ике көпчәкле арбалар Лондонга махсус бер нәрсәдер. Бу ике көпчәкле арба гадәттәге пролеткага охшамыйдыр. Бу үзе көймәле. Көймәнең артында күчергә бик биек бер урын ясалган, таки күчер утыручыга шәһәрне карап барырга манигъ булмасын. Яурупаның бөтен шәһәрләрендәге кеби, ат, әлбәттә, дугасыз җигелгән. Бу Лондонның хосусиятләреннән булган бер нәрсә булганга, шуны ялларга уйладык. Менеп утырдык. Арык нәселдән җинел бер ат чаба. Аның тиз баруы да, арбаның кыяфәте дә әллә ничек көлдерәсе китерә иде. Миңа һаман арба күчер утырган якка таба чүйкәлеп китеп, йә ат егылыр да, без алга тәгәрәрмез шикелле була иде. Ләкин бу хәтәрләрнең берсе дә булмады.

Озакламый Пикаделли дигән иң бай, зур мәгазәләр[3] булган җиргә килеп җиттек. Бунда бернична хаҗәт нәрсәләр алачак идек. Күлмәк, яка вә галстук кеби нәрсәләр Лондонда, Парижга вә Берлингә караганда, бик кыйммәт. Ләкин маллары тазаракка охшыйдыр.

Парижда һич сатулашу юк. Мин күлмәкләр алган мәгазәдә уйнап сатулашкан идем, ун шиллинглык нәрсәгә бер шиллинг төшерделәр. Сатулашу бөтенләй үк юк булмаса кирәк.

Пикаделлидә нәрсәләр алып, бераз мәгазәләр карап йөргәч, Лондонның мәшһүр паркларыны карау фикеренә килдек. Бу паркларны атлы арба илән карап йөрсәк, бик күп вакыт лязем булачакка, автомобиль алырга уйладык. Бунда автомобиль гади арбачы бәһаседер. Автомобильгә менеп утырып, иң әүвәл Лондонның иң зур паркларыннан Һайд Парк (Hyde Park) дигән паркны күрсәтергә куштык. Һайд Парк Лондонның ифтихар иткән бер нәрсәсе, һәм ифтихар итәргә дә урыны бар. Лондон уртасында 158 дисәтинә чамасында бер парк вә болын.

Һайд Паркны Лондоннан бары тимер рәшәткә аерадыр. Тугыз җирдә зур арба илә кереләчәк зур капулары бар. Буннан башка җәяүлеләргә бик күп вак капулары бардыр. Һайд Паркның иң матур капусы Веллингтон сараена каршыдыр. Бу Веллингтон сараеннан киләчәктә бәхәс итәрмен.

Бу капудан кергәч үк ике тарафыннан зур-матур агачлар тезелгән ике зур аллея аерылып китә. Бу ике аллеянең уртасында озын, матур, киң бер күл башланадыр. Яшел чирәмлек уртасында су ялтырый. Веллингтон сараеның эченнән күрелгән бу манзара — минем дөньяда бер шәһәр эчендә күргән манзараларның иң матурыдыр.

---

[1] *Бәһанә иту* — сылтау.
[2] *Сәрвәт* — байлык, хәзинә.
[3] *Мәгазә* — магазин.

Һайд Паркның уртасындагы бу су байтак озын. Буның әтрафы паркның иң гүзәл җире. Табигатьне нинди матурлый торган нәрсә булса, һәрберсе бар. Агач, яшел чирәмлек, су. Су әтрафы өйләдән соң Лондонның иң кибарларының [1] тәфәррежгяһедер [2]. Бунда күргән кадәр матур арбалар, киенгән дамалар, бундагы кадәр туалетлар, бундагы кадәр энҗе, мәрҗән вә бриллиантларны дөньяның һичбер җирендә күрмәдем. Арба артыннан арба һич туктамый. Арбалар, атлар бере береннән тәмиз [3], бере береннән матур. Һәр берендә цилиндрдан лакейлар. Һәр берендә бер-береннән уздырырга киенгән, ясанган, ефәкләргә, муслиннарга чорналган, бриллиантларга күмелгән хатыннар, кызлар. Әллә чакрым кадәр җир бер мәгърузәи сәрвәт [4] хәленә китерелгән.

Һайд Паркның бу җире хәкыйкатән бер зиннәт вә нәфасәт вә сәрвәт мәгърузәседер, сус вә тәфахир [5] мәйданыдыр. Гаҗәби, бу сәрвәт, бу малның мәнбагы [6] кайдадыр? Ничек итеп инглизләр бу кадәр баеганнар? Хәзер генә Пикаделли урамында булган идек, андагы мәгазәләр, кичә Биржада булган идек, соңра банкыда — һәр җирдә күзгә төшкән мал, миллионнар. Бу көн бу паркта бу кадәр арбалар, бу кадәр бриллиантлар, бу кадәр ничә меннәр, арбаларда бриллиант эчендәге хатыннарның гизүе — шәһәр эчендә булган зәнгин [7] кешеләрнең гаять мокътәдир [8] булуыны телидер. Бу сәрвәт кайдан килгән? Инглизләр ничек бу кадәр бай? Бу ике сөаль Һайд Парктагы бу мәгърузәи сәрвәтне тамаша иткәндә һич башымнан чыкмадылар. Бу сөальләргә соңра күргән, аңлаган әхваль бер дәрәҗәдә җавап бирәчәктер.

Берничә көн соңра шул Һайд Паркның үзендә буңа байтак җаваплар таптым. Укучым! Бу көн сезгә инглиз мәдәниятенең уң якларын гына күрсәтәм. Бу уң ягы нә кадәр ялтыравыклы, нә кадәр шәүкәтле булса, сул тарафында шулкадәр кара, күңелсез вә гүя өмидсез хәлләр бар. Ләкин җавап шунда: уң тарафының җалисе [9] шулкадәр тирән ки, тиздән сул тарафтагы карангылыкны һәм яктыртачагы мәэмүлдер [10].

Буннан соң калган Сен Җемс Парк вә Реженс Паркларны тиз генә карап үттек. Һәрбере хәкыйкатән матур. Бу Лондонның парклары зур шәһәрләрдә һич гадәттә күрелми торган бер мәнбагы сәгадәттер [11]. Бигрәк тә бу паркларны тәрбияләүләре, тотулары шаян тәхсиндер [12]. Мин һичбер җирдә инглиз паркларындагы кадәр күләгәле матур агачлар күрмәдем. Агачлар, болай матур булу өчен, бик карт булып, озак вакытлардан бирле яхшы тәрбия күргән булырга тиеш имеш. Чирәмлекләр дә шулай ук матур, тип-тигез, ямь-яшел. Бу чирәмлекләрнең һәм болай куе-тигез булуы өчен берничә гасыр чирәмлекләр тәрбия ителергә тиеш имеш, кем белсен.

Ләкин инглиз паркларыны яратмау һич мөмкин түгелдер. Хосусән бу кадәр матур бакчалыкларның шәһәрнең там [13] уртасында булуы бөтен шәһәргә бер сәгадәтдер. Башка шәһәрләрдә бу Һайд Паркка охшар урманнар, парклар булса да, алар шәһәрнең там эчендә түгел. Анда барырга вакыт кирәк һәм акча да кирәк. Парижның Болонья урманында гади көннәрдә бары кибарлар [14] гына бара аладыр. Гади Париж кешеләре бары якшәнбә көннәрдә генә вакыт табадыр.

Хәлбуки, Лондонда бай булсын, фәкыйрь булсын — Һайд Паркка кереп, чирәмгә сузылып ятарга һәрвакыт һәркемгә мөмкиндер. Укучы, моны укыганда һаман бу паркның 158 дисәтинәлек җир икәнене онытмаңыз. Бу асылда бер парк кына да түгел. Лондонның кыл уртасында бер урман вә зур бер печәнлек. Агым су да бар. Уртасына барып җиткәндә Лондонның шау-шуы да ишетелми башлыйдыр. Аркадашым Ефремов илә шәһәр эчендә бундый бер җирнең фазыйләтләреннән бәхәс иткәндә, мин әйттем:

---

[1] *Кибрларының* — олы-бөекләрнең.
[2] *Тәфәррежгяһ* — күңел ачу урыны.
[3] *Тәмиз* — чиста, пакь.
[4] *Мәгърузән сәрвәт* — байлык күргәзмәсе.
[5] *Сус вә тәвахир* — горурлык һәм мактану.
[6] *Мәнбәгъ* — *чыганак.*
[7] *Зәнгин* — *бай, дәүләт иясе.*
[8] *Мокътәдир* — *көчле, сәләтле.*
[9] *Җалисе* — *урыны, нигезе.*
[10] *Мәэмүлдер* — *ихтималдыр.*
[11] *Мәнбагы сәгадәт* — *бәхет чыганагы.*
[12] *Шаян тәхсиндер* — *мактауга лаектыр.*
[13] *Там* — *нәкъ, тәгәл.*
[14] *Кибар* — *олы, дәрәҗәле кеше, аристократ.*

— Бу парк никадәр Лондон бичараларыны интихардан[1] котылдырды икән, чөнки шөбһә юк ки, бик күп бичаралар, өмидсезләр бу бакчага кереп кайгы вә хафаларыны мувәкъкатән[2] булса да онытканнардыр,— дидем.

Аркадашым һәм тәсдикъ итте[3]. Берничә көннән соң Лондонның мәшһүр адвокаты мистер Барклай илән Һайд Парк тарафыннан үтеп барышлый, янә сүз чыгып, бу фикеремне сөйләгән идем, мистер Барклай диде:

— Белмим, шәхесләрне интихардан котылдыргандырмы, ләкин һич шөбһәсез берничә мәртәбә Англияне революциядән коткарды,— диде.

Барклайның фикрене аңлар өчен якшәнбә көн бу паркта, чирәмлек өстендә, ачык һавада булган собраниеләрнең ни икәнене белергә кирәк. Бер якшәнбә мин бу гаять мәргуб җәмгыятьләрне карарга бардым. Киләчәктә буны да язарым.

## IX

### Англиядә бер рус кызы. Англиядә бер гади ханә. Квартирларның хосусияте. Һәр ханәгә бер мәдхәл[4]

Паркларзиярәтеннән соңра өйгә кайттык. Йимәктән соң мин бер әманәтне тапшырырга хосусый бер ханәгә бардым. Бу да моннан гыйбарәт иде. Казан земствосыннан Государственный Советка сайланган әгъзасы Трубников минем бик танышым. Аның ханәсе Петербургта. Минем баргалап йөргән ханәләремнән берседер. Господин Трубниковның үзене таныган кеби, гаилә әгъзаларын да таныймын. Бу сәнә өч ай Лондонда җәйне торып, Лондон хәятына ашна булыр өчен вә инглиз лисанын да истикмаль итәр[5] өчен Трубниковның бер кызы Александра Юрьевна Трубникова Лондонга киткән иде. Мин китәсе көннәрдә Трубников миңа кызына тапшыру өчен бер мәктүб биргән иде. Мин шул хатны илтер өчен бу ханәгә бардым. Мадмуазель Трубникова, инглизләрчә мисс Трубникова, өйдә икән. Бүген генә Лондон гәзитәләреннән руслар килгәнене, кайда төшкәнене һәм белгән. Минем дә килүчеләр арасында булганымны белә икән. Үзем килмәсәм дә, ханә сахибәсе мине бер көн чәйгә чакырасы икән. Көннәремез фәүкыльгадә тулы булганнан, буш булу мөмкин булмаячагыны сөйләдем.

Бу ханә — искедә Һиндстанда инглиз мәэмүре[6] булып торган бер кешенең тол хатынының ханәседер. Моны язудан максудым — бик бай булмаган бер инглиз гаиләсенең тормышы хакында бер фикер бирүдер. Иң әүвәл дикъкатьне җәлеп иткән нәрсә — хосусый йортларның парадныйлары. Һәр парадный гаять мәһабәт, юнан мәгъбүдханәләренең[7] алды кеби таш баганалар илә зиннәтләнгән; бу озын урамнарда тезелеп бик матур булып торадыр.

Килгәннән бирле Трубникова илән русча сөйләшә идем. Трубникова диде:

— Мосье Максудов, французча сөйләшсәгез лә, өй сахибәсе французча белә-дер. Аңа күңелле булыр, аңласа,— диде.

Мин тиз генә буңа кадәр нәзакәтсезлек иткәнем өчен гафу үтендем. Сәбәбе — үзем инглизчә белмәгәнгә, мадамның французча белгәнене белмәгәннән иде, дидем.

Бераз сөйләшкәч, ханә сахибәсе ханәсене күрсәтергә башлады. Кабул салоны беренче катта иде. Зур салон икенче катта имеш. Ятак бүлмәләре өченчедә имеш.

— Бу нидән болай? — дидем.— Юкса сез бу йортның һәр этажыны билисеңезме? — дидем.

— Әлбәттә, үземезнең квартирның һәр катыны билимез,— дип җавап алдым.

— Бүтән квартирчылар кайдан йөри соң? — дидем.

— Аларның үзләренә аерым ход,— диделәр.

Аңланды ки, Лондонда һәр квартирга аерым-аерым ход икән. Бу мөмкин булсын өчен һәр квартирга төрле этажда бүлмәләр ясарга тугъры килә икән.

---

[1] *Интихар* — үз-үзенә кул салу.
[2] *Мувәкъкатән* — вакытлыча.
[3] *Тәсдикъ итте* — раслады.
[4] *Мәдхәл* — ишек, керү юлы.
[5] *Истикмаль итү* — төгәлләү.
[6] *Мәэмүр* — чиновник.
[7] *Юнан мәгъбүдханәләренең* — борынгы грек гыйбадәтханәләренең.

Квартирлар җәелми, күккә таба сузыла икән. Бу иттифакый[1] бу йортта, бу мәхәлләдә генә шулай түгел, бәлки бөтен Лондонда, бөтен Англиядә шул кагыйдәдер.

Бу ханәнең түшәлмәсе гаять хушыма китде. Бик бай булмаган бер мәэмүр ханәсендә иң әүвәл бу кадәр китап булуына гаҗәпсендем. Түбән каттагы кечкенә салон дигән бүлмәләре бер көтебханә хәленә килгән. Бөтен дивар китап өчен махсус шкафлар илә тулы иде. Аннан башка калган мебельләр һәм нәфис акава агачыннан. Урындыклар бик уңгай, йомшак. Камин өсте дә вә башка өстәлләр дә төрле мәмләкәтләрдән килгән хатирә нәрсәләр илән тулы иде. Бу салоннан туп-тугъры бакчага чыгарга мөмкин. Бик бай булмаган бер гаиләнең болай матур тора белүенә гаять тәхсин иттем.

Өй сахибәсе ханәсене күрсәтеп йөргәндә, хуҗасыннан калган Һиндстан хатиратыны[2] күрсәтте. Арада бер матур Һиндстан мылтыгы күрсәтеп, хатын диде:

— Бу мылтыкны ирем иясен үтереп алган,— диде.

Бу сүз миңа бик агыр тәэсир итте. Чәһрәмдә[3] бер тәгъйир[4] пәйда булуны хатын сизде булырга кирәк:

— Бу мылтык, асылда, бер әфганлыныкыдыр,— диде.— Ирем Һиндстанда әфган хөдүдендә сәяхәте заманында бер әфганлы иремне үтерәчәк булган. Әфганлы атып өлгермәгән, ирем элек аткан да, афганлыны үтергән дә мылтыгыны алган,— диде.

— Алай икән,— дидем.

Бу сүз бөтен бу кичәмне агулады. Өй сахибәсе вә Трубников кызы илә күрешеп, кайтырга чыктым. Ханә сахибәсенең угылы Лондонның иң зур көтебханәсендә хезмәт итә икән. Мине җир астыннан йөри торган тимер юл станасына кадәр озата килде.

Ханәдән чыкканда дикъкать иттем: вакыйган[5] һәр йортның алдында безнең Русиядәге, яхуд Франциядәге кеби бер генә ход түгел, бәлки йортта никадәр квартир булса, шулкадәр ход икән. Мин килгән йортта дүрт таш баганалар илән ясалган парадныйлар; һәркем үз квартирында хан. Затән[6] инглизләрнең бер мәкале дә бар икән: «Һәр инглизнең ханәсе бер къәлгадер». Мәгълүмегез, кълга — крепость дигән сүз. Бу да Англиядә шәхеснең вә мескеннең хөррият вә мәсунийәтеннән[7] кинаядер.

Җир асты тимер юлы илән кайтканда уйлый идем. Әллә ни бер нәрсәгә кәефем киткән иде, нидер дип эзләдем. Эзләп таптым. Күз алдымда бичара бер инглиз кулыннан һәм хәятыны, һәм мылтыгыны җуйган әфганлы килә иде. Әфганлыны үтереп алган мылтык күз алдымда тора иде.

Тимер юл белән кайткач, безем һотелгә кадәр бераз җәяү барачак җир бар иде. Аннан барганда матур урамнар, зур хәрби вә гаскәрия нәзараты даирәләре — һәрбере бик мәһабәт, ләкин ул көнне болар һәрбере әфганлыны үтереп алган мылтык шикелле тоела иде. Бу мәдәният Һиндстанны сыгып-кысып җәберләүдән хасыйл булган кеби күренә иде. Бу кадәр мөтәәссирийәт кайдан килә? Әгъсабым[8] бу көн бик арыган булырга кирәк, тизрәк кайтып ятырга кирәк, дидем.

## X

Лондонда икенче көн. Ламбас сарае. Англиядә руханиунның дәрәҗәсе. Буның әһәмияте. Парламент бинасы. Парламентта өйлә тәгаме. Нотыклар безем тарафтан. Инглизләр тарафыннан — баш министр Асквит. Иске министр Бальфур нотыклары

---

[1] *Иттифакый* — очраклы.
[2] *Хатират* — хатирәләр, истәлекләр.
[3] *Чәһрә* — йөз, бит.
[4] *Тәгъйир* — үзгәреш.
[5] *Вакыйган* — чыннан да.
[6] *Затән* — үзләрендә, асылда.
[7] *Мәсунийәт* — саклык, иминлек.
[8] *Әгъсаб* — нервлар.

Сабах [1] йокыдан торуга Лондонны күрсәтүче профессорлар килеп житкән иде. Автомобильләр дә хәзер иде. Утырып киттек. Иң әүвәл Англиядә иң зур руханиуннан Кентербери (Canterbery) архиепископның сараены зиярәт итәчәк идек.

Сарай — Лондонның бик матур жирендә, Темза нәһре [2] үзәрендә, зур бер бакча эчендә искедән калмыш бер бинадыр. Сарайның хәваләсенә [3] кергәч, шулкадәр тынычлык ки, Лондонда икәнең бөтенләй онытыладыр, әллә кайда, коруне вөстада [4] бер хикәя сараенда булган кеби тоеладыр: шулкадәр сөкүнәт [5] вә тарихи бер искелек.

Сарайны карап йөрдек. Һәр жирдә гайн тәэсир [6] иде. Шактый зур әксәрият үзрә дини китаплардан мөрәккәб бер көтебханә дә бар. Пыяла эчендә ящиктә беренче сәхифәсене ачып куйган бер Мосхәф [7] шәриф тә күрдем. Бундый бер жирдә Кәлям шәриф булуы бер мөселман күңеленә бер гажәп төрле тәэсир итәдер. Мосхәфне алып үбәсе киләдер. Сарайның бер башында манарасы да бар. Чыктык. Аннан бик матур Лондонның бик күп жире күренәдер. Манарага менгәндә бер жир зиндан аталадыр. Бу жирдә әүвәлдә руханиуннан гаепле булган кешеләрне хәбес итәләр [8] икән. Багълап куя торган тимер элмәләр әле дә торалар. Безгә күрсәтеп йөрүче баш руханиның каим мәкамләреннән [9] берсе икән. Архиерей үзе өйдә юк имеш, өйдә була алмаганнан гафу үтенәдер. Архиерейнең үзе тора торган жирләрене һәм зиярәт иттек. Бик матур. Сарай бары бер квартира. Зур салонның тәрәзәләре зур бер бакчага чыгадыр. Архиерейнең жәмагате вә бала-чагасы да бар имеш.

Англиядә руханиларга хатынлы-жәмәгатьле булырга мөмкиндер. Бу хакта, католик вә ортодокслык мәзһәбләрендәге кеби, зур дәрәжәле руханилар өчен «хатынсызлык» шарты юктыр. Бу Кентербери — зур архиерей, бөтен Англия руханиларына баш хисап ителәдер. Дәрәжәсе вә игътибары шулкадәр имеш ки, теләсә кай вакыт корольгә барып күренә имеш. Һәр эштә, мәмләкәтнең иң зур мәнсаб ияләре[10] кеби, гъәд итело[11] вә фикере вә киңәше сорала имеш. Англиядә руханиларның игътибары бик зур. Безем Русиядә һәм ортодокс руханилары әһәмият алырга тырышсалар да, дөньяви эшләрдә артык игътибар вә икътидарлары юк.

Хәлбуки, бунда һәр эштә, дөньяви эшләрдә һәм руханиуннан зурлар киңәшләре дә хазир була имеш, бер нәүгъ мөдажәләләре[12] була имеш. Ләкин бу мөдажәлә табигый, һичбер вакыт халык хилафына, хөррият вә тәрәккъый хилафына булмый имеш. Затән Англиядә бүген дә хөррият хилафында булу һичкемнең хәтеренә килми торган бер хыялдыр. Безнең Русиядә һич чәй эчүгә хилаф булу фикеренә килмәгән кеби, Англиядә һәм теләсә ни язу, уку вә сәер хөрриятләр зарурына тырышу фикеренә бары тиф белән авырганнар гына төшсә төшә торгандыр. Буннан тугъры һотелгә кайттык.

Бүген сәгать 12 дә парламентта парламент әгъзалары тарафыннан безгә бирелгән өйлә тәгамәнә чакырылган идек. Тиз генә пиджәкләрне алыштырып, сюртюклар кидек тә парламентка бардык. Парламент без төшкән һотелгә бик якын иде. Иң әүвәл, мәжлескә керүдән әүвәл, мәжлесе мәбгусан[13] бинасыны күрсәттеләр. Бу бина гаять зур вә фәүкыльгадә кыйммәткә төшкән бер бинадыр. Утыз миллион рубля чамасына төшкән. Бина иске түгел. 1840 сәнәләрендә эшләнгән бер бинадыр. Парламент әүвәл һәм шул урында булган. Тарыз мигъмарисы[14] готик дигән тарыз мигъмаридыр. Бундый зур бинаның бөтен матурлыкларыны тәгъриф бик читен. Зурлыгы шулкадәр ки, 32373 квадрат метр мөрәббәгъ[15] кадәр жир ишгаль итәдер[16]. Эчендә унбер ачык холла. Йөз кадәр

---

[1] *Сабах* — иртә.
[2] *Нәһер* — елга.
[3] *Хәвалә* — әйләнә-тирә, ихата.
[4] *Коруне вөста* — Урта гасыр.
[5] *Сөкүнәт* — тынлык.
[6] *Гайн тәэсир* — шул тәэсир.
[7] *Мосхәф* — Коръән.
[8] *Хәбес иту* — төрмәгә ябу.
[9] *Каим мәкам* — урынбасар.
[10] *Мәнсаб ияләре* — дәүләт хезмәтендәге кешеләр.
[11] *Гъәд итело* — санга сугыла (алына).
[12] *Бер нәүгъ мөдажәлә* — аерым бәхәс-киңәш.
[13] *Мәбгусан* — депутатлар.
[14] *Тарыз мигъмари* — төзү стиле (архитектурасы).
[15] *Мөрәббәгъ* — квадрат, дүрткел (мәйдан).
[16] *Ишгаль иту* — биләү.

баскыч, 1100 бүлмә, яхуд даирә бар имеш. Бинаның өч җирдә манарасы бар. Бу манараларның иң биегендә бер зур сәгать бар. Сәгатьнең дүрт якка дүрт циферблаты бар. Һәр циферблатның котры[1] җиде метр кадәр. Шуннан чамалап манараларның зурлыгы хакында бер фикер хасыйл итеп булыр. Башняләрнең берсендә бер зур кыңгырау бар. Бу кыңгырау дөньяның иң зур кыңгырауларыннан имеш. Һава тыныч вакытта сукканда бөтен Лондонга тавышы ишетелә имеш.



Англия Парламентының террасасында. Алгы рәттә утырганнар *(сулдан уңга)*: Глебов, Маклаков, Стахович, Уирдэль, Бенжамин Стон, Шидловский, Гучков. Артта басып торучылар арасында, уртада — Садри Максуди *(башына цилиндр кигән кеше алдында)*.

Англиядә һәм, мәгълүмегез, бездәге кеби ике палата бар. Бере әһали тарафыннан сайланган палата — Палата общин — бу безнең Думага мөкабил[2]. Икенчесе безнең Советка мөкабил — Англия әшрафының[3] мәҗлесе — Палата лордов. Бу ике мәҗлеснең һәр икесенең дә җыела торган җирләре — Зал заседаний — шул бер бинададыр. Мәҗлес була торган даирә бинаның тышкы ягы нисбәтендә мәһабәт вә зур түгел. Хәтта беренче палатаның мәҗлес бүлмәсе, әгәр һәрбер әгъза мәҗлескә хазир булса, сыячак түгел имеш. Бер инглиз көлеп:

— Ләкин хәтәр бу бер дә ихтимал түгел, һичбер вакыт бөтен әгъзалар хазир булганы юк, — диде.

Буны ишеткәч, безнең Дума әгъзаларында инглиз әгъзаларына караганда вазифашинаслык[4] артыграк икән дип уйладым. Чөнки бездә һәр әгъза хазир булган мәҗлесләр булгалады.

Мәҗлес бүлмәләре дә готик зәвекъ мигъмарисе үзәренә ясалган.

Зал түгәрәк түгел. Урындыклар ике яктан ясалган. Уртада узып йөрергә буш урын бар. Түрдә мәҗлес рәисе, мөгавиннәр вә кятибләр, аның уң ягында министрлар урыны. Депутатлар утырган җирләреннән сөйләргә ихтыярлы. Рәис, мәһабәтрәк булыр өчен, ак парик киеп утырадыр, мөгавиннәр һакәза[5]. Бу искедән калган бер гадәт. Англиядә һәр эштә искедән калган гадәт вә горефләрне сакларга яраталар.

Беренче палата мәҗлесе даирәсеннән соң, кулуар аркылы чыгып, икенче палата — Лордлар палатасы — мәҗлесе даирәләренә карадык. Моның залы әүвәлгедән кечрәк, ләкин аннан матуррак вә яктырак. Бунда бер хосусият бар. Король вә короличәгә махсус бер урын бар. Һәр сәнә парламент ачылганда вә ябылганда король үзе дә хазир була имеш. Тәхет нотыгы дигәнне (тронная речьне) шуннан

---

[1] *Котр* — диаметр.
[2] *Мөкабил* — тиңдәш, охшаш.
[3] *Әшраф* — шәрифләр, затлы нәсел кешеләре.
[4] *Вазифашинаслык* — вазифалык гыйльме.
[5] *Һакәза* — шулай ук.

сөйли имеш. Бу тәхет нотыгыны беренче палата әгъзалары залга кермәенчә, бер рәшәткә аркылы гына тыңлыйлар имеш. Искедән калган бер гадәт булганга, буны беренче палата әгъзалары тәхмил итә [1], бер дә кимчелеккә санамыйлар имеш. Бундый бер эш Франциядә мөмкин булмас иде.

Бу Лордлар мәҗлесе залында урындыклар кызыл сәхтияннан белән капланган. Бу зал бик матур. Диварда унсигез кечкенә статуялар бар. Бу Англия падишаһларыннан Җирсез Иван дигән падишаһны Англиягә беренче конституцияне бирергә көчләгән бароннарның һәйкәлләредер. Бу Җирсез Иван дигән король биргән конституция, мәгълүмеңез, Европаның тарихе хөрриятендә мәшһүр бер сәнәд кәгазедер [2]. Бу инглиз милләтенең иң элек алган хөррият мокавәләседер [3]. Исеме — «Бөек хөррият хартияседер» (Великая хартия вольностей) — 1215 нче елда бирелгән. Англиядә бу беренче хөррият вәгъдәсе буннан җиде гасыр әүвәл бирелгән иде. Хөррият манифесты Русиядә 1905 нче елда 17 нче октябрьдә чыкты. Шуннан чамалап Англиягә нисбәтән ничә гасыр артта икәнемезне аңлап булыр.

Залның югары тарафларында бик матур фреска картиналар бар. Холясән, бу зал матур, бик җайлы бер җир. Безнең иптәшләрдән байтак кеше урындыкларына утырып залны карадылар. Мин дә бер урынга утырып карадым. Бер инглиз лордының дөньяга «ноктаи нәзарыны» чамаласым килә иде.

Ләкин болай утырып кына лордларның дөньяга нәзарыны белү читен. Чыннан буны белер өчен миллионнар тора торган әмляк сахибе [4] булырга, Лондонда сарайлы вә ничә гасырдан бирле әҗдадтан [5] лорд булып килгән ирси рухка [6] малик булырга кирәк. Болар мине, чынлап әйтәм, бер дә кызыктырмыйлар; идеалларым икенче төрле; ләкин яраткан кешегә мәүкыйгы [7] сафасыз булмаса кирәк.

Мәҗлес палатаның йимәк бүлмәсендә — буфетында хәзерләнгән иде. Буфет — бинаның иң түбән катында, Темза нәһере буендагы парламентның зур террасы илән янәшә, тәбәнәк, ләкин гаять хуш күңелле бер бүлмә. Йөздән зиядә [8] парламентның иң мөгътәбәр кешеләре хазир иде. Либераллар партиясенең рәисе, бу көндә баш министр Асквит (Asquith) вә мөхафәзәкәрләр (консерваторлар) партиясенең рәисе Бальфур (Balfour) да хазир иделәр. Бу ике кеше Англиянең иң зур сәяси кешеләредер диярргә мөмкиндер. Буннан калган кешеләре дә Англиянең иң мөһим сәяси кешеләре иде. Әүвәлдә министр булган, йә киләчәктә министр булачак адәмнәр иде. Бинаән галәйһи [9] бу мәҗлес безнең шәрәфкә ясалган мәҗлесләрнең иң зуры иде.

Буфетка җиткәнче бу даирәдә килгән көн безне тәбрик иткән лорд Уирдэль һәрберемезне беренче палатаның рәисенә тәкъдим итте. Һәрберемез берәм-берәм рәис илә күрештек. Башка хазир депутатларга баш илә селкедек. Һәркем белән аерым лязем түгел имеш.

Мәҗлес булачак өстәлләрдә һәркемнең урыны язылган иде. Мин дә үз урыныма утырдым. Безнең аркадашлар да, инглизләр дә гаять хуш вә кәефле күренәләр иде. Һавада бер шатлык вә мөгамәләләрдә самими бер дустлык заһир иде. Инглиз депутатлары әле беремез, әле беремез илә килеп күрешәләр иде. Миңа да берничәсе сүз кушты. Инглизчә белмим дигәч, французча сөйләшергә башлыйлар иде. Берсенең французчасы бик сай икән, туктадык. Ләкин күз ишарәсе илә симпатиясене белдерә иде.

Бальфур илә Асквит та урыннарына килеп утырдылар. Мәҗлес башлана иде. Мәҗлес бер зур өстәлдә булмай, вак өстәлләрдә иде. Мин булган өстәлдә руслардан миннән башка Челноков иде. Мәҗлес башлана дигәндә бик матур Темза тарафыннан кояш төште. Терраса ишеге ачык иде. Нәһер күренә иде. Нәһернең аргы тарафында иртә белән күргән Лямбас сарае, аның бакчасы вә саир [10] зур биналар күренә иде.

Йимәк башланды. Янымда утырган депутатлардан икесе илә таныштым.

---

[1] *Тәхмил итә* — күтәрә, кабул итә.
[2] *Сәнәд кәгазедер* — документтыр.
[3] *Мокавәлә* — килешү.
[4] *Әмляк сахибе* — милек иясе.
[5] *Әҗдад* — ата-бабалар.
[6] *Ирси рух* — нәселдән килгән рух.
[7] *Мәүкыйг* — урын.
[8] *Зиядә* — күбрәк, артыграк.
[9] *Бинаән галәйһи* — шуның өчен.
[10] *Саир* — башка, үзгә.

Берсе. Русиядә берничә мәртәбә сәяхәт иткән бер кеше, мөкәммәл французча сөйләшә иде.

Бүген, бу мәҗлес соңында, Асквит вә Бальфурның нотык сөйләячәге мәгълүм иде. Һәркем боларның нә сөйләячәгенә әһәмият бирә иде.

Мөгамәләләрдә, һавада самимият илә бәрабәр бер нәүгъ тантаналы рәсмият бар иде. Йимәк озакка бармады. Шампанскигә килеп җитте. Иң әүвәл бәйнәлмиләл парламентлар иттифакы группасының рәисе лорд Уирдэль безне тәбрик итеп бер нотык сөйләде. Буна каршы безнең Думада шул ук группа рәисе Ефремов буңа җавап бирде. Ефремовның нотыгы һәр каюымызның тәхсинене җәлеп итте. Һәм хәкыйкатән, җиренә муафикъ, гакыллы булу илә бәрабәр гаять хөррият пәрвәранә иде.

Мин бүген дә, буннан соң башка мәҗлесләрдә сөйләнгән нотыкларны да тәфсыйлән бу сәяхәтнамәмдә нәкыль итмәм [1]. Чөнки боларның һәрберене нәкыль итмәк лязем булса, язуларым бик озаер. Вакытында, зан итәм [2], бу нотыклар урыс матбугатында басылды бугай. Мин сәяхәтнамәне Русия хариҗендә [3] язганга, буны белмим. Ләкин бунда үзем сөйләгән нотыклар мөстәсна [4] булачактыр. Ягъни үзем сөйләгән нотыкларның тәфсыйләтене язачакмын. Бунын сәбәбе үзем өчен бер истисна [5] ясау түгел. Бунын сәбәбе ниләр сөйләгәнемне укучыларга да, халкымызга да белдерүдер. Затән [6] баштук әйттем: бу сәяхәтнамәне каләмгә алудан максудның иң беренчесе — бу сәяхәтемнән хисап бирүдер, дидем.

Уирдэль вә Ефремовтан соң Асквит вә Бальфур сөйләде. Һәр икесе Думаны тәбрик иттеләр. Истикъбален [7] теләделәр. Инглизләрнең нотык сөйләү формасы бик хушыма китте. Гаять салмак. Һичбер төрле кул берлән жест ясау юк. Болай сөйләү безнең Думада да юк, французларда да юк. Һәрберемез тәкълид итү [8] лязем дип уйладык. Ләкин бунын өчен суык канлы булырга кирәк. Тәмамән мәүфикыятьлә тәкълид читен булса кирәк. Ләкин нотык заманында салкын канлы булу гаять кибари вә килешәдер. Хосусән бу кеби рәсми нотыкларда. Бер инглиз депутаты илә бу хакта сөйләштем.

— Болай һич хәрәкәтсез сөйләшү безем инглизләрдә һәм табигый түгел, акрынлап, практика илә генә хасыйл буладыр, башта депутатлар бездә һәм кулларыны селкеп, жестлар ясаучан буладыр, — диде.

Асквит та, Бальфур да нотыкларында Думаны тәбрик иттеләр. Истикъбалене теләделәр, Русиядә яңа бер куәт булган Милләт мәҗлесенә мәхәббәтләрене, симпатияләрене белдерделәр. Нотыкларының холясасене [9] тиз генә янымдагы депутат тәрҗемә итте. Затән аннан башка да мәзмунене [10] аңлаган идем. Мәгълүменез, инглиз телендә сүзләрнең яртысы француз сүзләредер. Француз сүзе дигәнне инглизләр яратмас, ике телдә гомуми сүзләр дип әйтик. Хосусән бундый сәяси нотыкларда французча белгәч вә бераз да инглизчә тәркибләрене [11] белгәч, тәкърибән [12] аңлап буладыр. Инглизчә илә французча фарсы илә гарәби кебидер. Фарсыда нә кадәр гарәпчә сүз булса, инглизчәдә һәм шулкадәр француз кәлимәсе күптер.

Бу ике инглизнең — иң зур кешеләренең — нотыкларына безнең Хомяков вә Стахович җавап бирделәр. Хомяков нотыгы җитди, мәкянәнә [13] гаять муафикъ иде. Стахович французча сөйләде. Нотыгы бер дә сәяси булмай, бик әдәби иде. Мәҗлес ниһайәтенә муафикъ иде.

Мәҗлестән соң каһвә эчәр өчен террасага чыктык. Бу терраса Англиянең сәяси хәятында бик мөһим бер җирдер. Англиянең сәяси хәятында күп киңәшләр шунда оеша имеш.

---

[1] *Нәкыль итмәм* — сөйләмәм.
[2] *Зан итәм* — уйлыйм.
[3] *Хариҗендә* — тышында (чит илдә).
[4] *Мөстәсна* — аерым.
[5] *Истисна* — чыгарма, аерып алу.
[6] *Затән* — шуны шулай ук.
[7] *Истикъбален* — киләчәген.
[8] *Тәкълид итү* — ияру.
[9] *Холясасене* — кыскача мәгънәсен.
[10] *Мәзмунене* — мәгънәсен.
[11] *Тәркиб* — сүзләр тезмәсе.
[12] *Тәкърибән* — якынча, чамалап.
[13] Мәкянәнә — урынына.

## Парламент тирәсендә сөйләшүләр. Лондон. Англиянең куәт вә шәүкәте, мәдәнияте хакындагы уйларым

Бу терраса парламент бинасының эчендә, Темза нәһере буенча сузылган бер җирдер. Безнең татарча буңа мокабил[1] сүз булмаганга, тәгъриф читен. Парламентның Темза суына караган тарафында бер зур балкон дисәк, бер дәрәҗә якынлашкан булырмыз. Йимәктән соң һәрберемез шул балконга чыктык; балконда бик күп җирендә вак-вак өстәлләр бар иде. Хадимнәр һәркемгә каһвәләр өләштеләр. Теләгән кешеләргә ликерлар да тәкъдим иттеләр. Хомяков һәрберемезне аерым-аерым баш министр Асквиткә, соңра Бальфурга тәкъдим итте. Һәрберемез янына берәр инглиз министры, яхуд депутат килеп сүз ача иде. Һәрбере әүвәл: «Инглизчә беләсеңезме?» — дип сорый иде. Бу хакта французлар кеби түгел. Французлар һичбер вакыт әҗнәби кешедән французча беләсеңезме дип сорамыйлар. Гүя һәркем алар телене белү лязем дип уйлыйлар. Бәлки, кунак булгангадыр, инглизләр миннән һәрвакыт әүвәл: «Инглизчә беләсеңезме?» — дип сорыйлар иде. «Юк, французча гына беләм»,— дигәч кенә французча сөйләшә башлыйлар иде. Бу урында шуны да әйтеп китим: Англиядә хөкүмәт вә парламент кешеләре арасында французча бер дә белмәгән кеше бөтенләй юк диярга мөмкиндер. Кайсы, табигый, начар беләдер. Ләкин яхшы белгәннәре күбрәк дип уйлыйм.

Мин террасада бераз лорд Уирдэль илән сөйләштем. Үткән сәнә Берлин конференциясендә булганыбыздан бәхәс иттек. Шул тирәдә генә Бальфур кешесез тора иде. Янынарак бардым. Минем инглиз түгел икәнемне тиз белде булырга кирәк, французча:

— Лондонга элек килүеңезме? — диде.

— Элек,— дидем.

Лондон хакында хәтеремә килгән баш фикерләремне сөйләдем. Соңра, форсаттан истифадә итеп, бу көн аның илән танышканыма бик мәмнүн булганымны сөйләдем.

— Мин Сезне шәхсән мөгарәфә ясап[2] булмый торган бер тарихчы гына кеше дип уйлый идем,— дидем.— гәзитәләр укый башлаганнан бирле Сезнең исемеңез, бөтен гасырдашларга мәгълүм булган кеби, миңа да мәгълүм иде,— дидем.

Бу сүзне әйтеп бетерер-бетермәс шиккә төштем. Бу сүз картлыгына ишарә булып, кәефе китә күрмәсен, дидем күңелдән. Ләкин бер дә кәефе китмәде. Билгакес, бу тарихчы булу мәсьәләсе хушына китте кеби тоелды. Минем хакта: «Сез бик артык зур фикердәсеңез-фәлән»,— диде. Ләкин кәефе киткәнгә охшамый иде. Бик кәефләнеп, парламент бинасы хакында мәгълүмат бирә башлады. Мин бинаның зурлыгы, зиннәтләре хакында хәкыйкый тәхсинемне ифадә иттем[3].

Һава һаман матур иде. Аяк өстендә көенчә каһвәләремезне эчтек. Темза нәһере алдымызда сузылып ята иде. Ике тарафтан матур, зур-кибари биналар. Бераз тынып булса да Лондонның гөжелдәве ишетелә иде. Һәркем кәефле, шәтаратлы[4] иде. Бальфурдан аерылып, балконның ак таш рәшәткәсенә таянып, нәһергә карап, еракта шау килгән Лондонга колак салып, тирән уйларга чумдым. Бунын кеби хәятның надир дәкыйкаларендә[5] баштан үткән фикерләрне, мәгаттәәссеф, язып булмыйдыр, бундый заманнарда башка фикерләр ташу дулкыннары кеби тулып киләдер вә яшен кеби тиз үтәдер. Бу кеби дәкыйкалардәге тәхвилате рухия вә фикрияне[6] нә сәхифәләргә кыйль итеп[7] буладыр, нә сәяхәтнамәләргә язып буладыр. Алай булса да, фикерләрем, төшенчәләрем нә кеби мәсьәләләр әтрафында әйләнгән кадәресене языйм. Иң әүвәл Лондонның зурлыгы, сәрвәте хакында уйлап, буннан бөтен Англиянең сәрвәт вә куәтенә күчтем, бу куәтнең мәнбагы — гамәл-сәгый вә мәдәниятенең искелеге. Кувәи бәхрия[8]. Англиянең чиксез, ниһайәтсез тиҗари вә хәрби көймәләре. Флот. Англия сахиленнән, Бәхре

---

[1] *Мокабил* — ярашлы, тәңгәл.
[2] *Мөгарәфә ясап* — танышып.
[3] *Ифадә итү* — аңлату.
[4] *Шәтарат* — шуклык-шаянлык.
[5] *Надир дәкыйкаләрендә* — сирәк очрый торган минутларында.
[6] *Тәхвилате рухия вә фикрия* — рух вә фикер үзгәреше.
[7] *Кыйль итү* — әйтү.
[8] *Кувәи бәхрия* — диңгезчелек куәте.

Сәфидтән [1], Бәхре Әхмәрләрдән [2], Бәхре Һиндиләрдән [3] та [4] Австралиягә кадәр диңгезләр сатхы [5] Англия куәи бәхриясе илән тулган. Бу куәтене кем вә нә вөҗүдкә чыгарган?—Инглизләр вә боларның армас-тукталмас сагый-пәрвәрлеге [6]. Эчемнән: «Яшәсен сагый!»—дия идем. Бу Англия куәи бәхриясеннән фикерем Англиянең гакылларга сыйгмаз зур мөтәгаддид [7] мөстәмләкәтенә [8] (колония) китте. Фикрән һәрберене саный идем. Канада, Африканың яртысы, Яңа Зеландия, Австралия вә никадәр вак җәзирәләр [9]! Вә Һиндстан! Бөтен гасырлардан бирле бөтен фатихларның һәвәсләрене яндырган Һиндстан! Бу да Инглетерәнең! Бу мәмләкәтләрнең әксәре тәмамән мәдәниятләндерелеп беткән, күбесе мәдәниятнең әүҗбиләсенә[10] җиткән, калганнары тәдриҗән[11] мәдәният юлына куелган, һич шөбһәсез, мәдәниятләнәчәк. Бу мәмләкәтләрдә дә һәрбере бер дөнья, һәрбере бер аерым галәм. Ләкин һәрбере инглизнеке.

Бу мөтәгаддид икълимнәрдә[12] мөтәгаддид шәраит[13], хәят эчендә булган бөтен мәдәниятне, әсбабе тәрәкъкый вә вәсаите тәмәдденне[14] кем кертте? Кем хәзерләде? Янә шул сәбатлы, житди, эшчән инглиз гонсыры[15]. Төшенә идем. Австралиядә, Африкада, Канадада, Һиндстанда вә, белмим, кайларда әллә никадәр күперләр, тимер юллар, матур шәһәрләр, мәктәпләр, дарелфөнүннәр, театрлар, банкылар, фабрикалар, заводлар, плантацияләр—һәрбере шул инглиз инженерлары, шул инглиз архитекторлары, инглиз галимнәре, инглиз төҗҗары, инглиз капиталы, инглиз колоннары саясендә вөҗүдкә килгән сәмәрәләрдер[16]. Дөньяда кайсы милләт бу кадәр хәйрәтләрдә[17] калдырачак зур бер мәмләкәт-империя вә бу кадәр житди сагълам бер мәдәният тәэсис итде: иске румалылар? Зан идәрем ки, юк. Алар да бундый бер сәрвәт, бундый бер икътидарга малик булмадылар. Бу—мәдәниятнең мадди тарафлары.

Инде мәгънәви тарафыны алыйк. Бу җәһәттән беренче булмаса, кәнә ин бөек бу мәүкыйгны ишгаль итәләр, фәлсәфәгә, әдәбиятка, фөнүнгә хезмәттә бу милләт кайсы милләттән калышты? Бу милләт Шекспирләр илән әдәбияттагы икътидарыны[18], Ньютоннар илән фәндә куәи кәшфиятене[19] күрсәтте. Байроннар илә хиссилектә, Бэконнар илә фәлсәфәдә нә кадәр бара беләчәгене күрсәтте, дидем.

Башымда бу фикерләр таралган саен гыйндемдә[20] инглиз милләте зурая бара иде. Фикерем янә Лондонга кайтты.

Әле генә фикеремне сихерләгән шулкадәр зур, куәтле бу дәүләтнең мәркәзе шул Лондон түгелме, дидем. Әле генә фикеремнән кичергән мөтәгаддид икълимнәрдәге васигъ[21] мөстәмләкәтнең мәркәзе әмре бу шәһәр түгелме? дия идем. Болай уйлаган саен Лондон фикеремдә зурая иде. Каршымда нәһер, күренгән күпер—һәрбере тагы да мәһабәт күренә иде. Ерактан ишетелгән Лондон шаушуы да гүя бер җанлы Лондонның тавышы кеби тоела иде. Гүя бу тавыш Лондонның куәтеннән, әһәмиятеннән кинаяле тавыш кеби килә иде. Ничек әйтим, бу дәкыйкадә инглизләрнең вә Англиянең куәт вә шәүкәте тәэсире астында изелә идем. Бу дәкыйкадә Англиянең хакыйкатән бөеклегене гаять каты бер хис итү илә хис итә идем.

Бу төшенчәләрдән фикерем бу кеби бер мәмләкәтнең идарәсе, тәшкилятенә китте. Буны идарә итмәк нә кадәр мәһарәт, нә кадәр җиддият телидер, дидем. Үземнең парламент балконында булганымны онытkан идем. Кинәттән минә шул

---

[1] *Бәхре Сәфид*—Урта диңгез.
[2] *Бәхре Әхмәр*—Кызыл диңгез.
[3] *Бәхре Һинди*—Һинд диңгезе.
[4] *Та*—кадер, чаклы.
[5] *Сатхы*—өсте, мәйданы.
[6] *Сәгыйпәрвәрлек*—тырышлык.
[7] *Мөтәгаддид*—күп санлы, исәпсез.
[8] *Мөстәмләкят*—колонияләр.
[9] *Җәзирә*—утрау.
[10] *Әүҗбиләсенә*—югары ноктасына.
[11] *Тәдриҗән*—әзлекле, эволюцион рәвештә.
[12] *Икълим*—континент.
[13] *Шәраит*—шартлар.
[14] *Вәсаите тәмәдден*—мәдәният чаралары.
[15] *Гонсыр*—элемент, токым.
[16] *Сәмәрә*—җимеш.
[17] *Хәйрәт*—сокландыру.
[18] *Икътидар*—сәләт.
[19] *Куәи кәшфият*—ачышлар ясау куәте.
[20] *Гыйндемдә*—каршымда.
[21] *Васигъ*—киң, иркен.

идарәнең мәркәзе — шул булындыгым бина икәне, бу мәһарәте сәясиянең мәнбагы — шул булындыгым жир икәне, бу кодрәте сәясия әсхабы янымда, уң тарафымда — шау-шу сөйләшкән сакалсыз-мыексыз шул арык кешеләр икәне хәтеремә төште; бу кадәр зур бер мәмләкәт идарәсенең башында бу кадәр грандиозный бер куәтнең мәркәзендә шул кара киемле, заһирән[1] гади кешеләр булуына ышанасым килми иде, ләкин бу хәкыйкать иде.

Бу сәгатьтә балконда булган йөзләп депутат үзләренең Англия парламентының иң иң нөфүзле[2] кешеләре иде. Ышанмаска мөмкин түгел иде. Янымызда парламент кешеләре генә дә түгел иде. Парламентның әксәрият[3] тарафыннан сайланган, әксәриятнең әмният вә игътимадына[4] лаек булган хөкүмәт башындагы баш министр Асквит һәм безнең илә бәрабәр иде. Әле генә төшенчәләремнән соң Лондонның әһәмияте нә кадәр зурайган булса, бу дәкыйкадә Асквитның да шәүкәте гыйндемдә шулкадәр арткан иде.

Ләкин бу простой, сакалсыз-мыексыз, ак сачле карт бер дә үзенең әһәмиятеннән, мәүкыйгыннан[5] хәбәрдар түгел кеби иде. Мөгамәләсе гаять садә, нәзакәтле, самими, сөйләшүләре риясыз иде. Менә бу да иске, тирән бер мәдәниятнең нәтиҗәседер, гасырлардан бирле ирси[6] килгән бер тәрбиянең мәхсулыдыр[7], дидем.

Иптәшләремнән Ефремов янымa килде:

— Максудов, нинди уйга калдыгыз? Әйдә, рәсемнәремезне алалар, мин сез рәсемгә керми кала дип курыктым,— диде.

Бер карт депутат үзе рәсем мөхибләреннән икән. Рус депутатлары илә инглиз депутатларының берәр рәсемнәрене алырга уйлаган. Рәсем ала башлагач, алгы урындыкларга Уирдэль, Хомяков, Гучковлар утырды; икенче рәттә калган рус депутатлары аяк үзрә тордылар. Алар артында хазир булган һәрбер инглиз депутатлары аяк үзрә тордылар.

Карт бер кат рәсем алгач:

— Тик торыгыз, дәхи бер кат төшерәм,— диде.

Бу сүздән соң нәзакәтән Хомяков аңа:

— Сез минем урынга утырыгыз, мин чыгарыйм,— диде. Карт депутат кабул итте.

Икенчесене Хомяков төшерде. Хомяковның инглиз парламентының террасында фотограф аппараты артында маташуы бик кызык тоела иде.

Мәҗлес шуның илә тәмам булды. Буннан соң янә парламентның буңа кадәр күрелмәгән җирләрене күреп йөрдек. Сәгать биштә беренче палатаның рәисе ханәсенә (спикер аталадыр) чәйгә чакырылган идек. Бу чәй мәҗлесеннән башлап Лондонда кунаклык башланадыр, ягъни «светская жизнь» башланадыр. Ләкин кунаклык хәятыны башлаганчы, парламентка якын вакытта, инглиз парламентындагы партияләр хакында, Англиянең осуле идарәсе хакында кыска берничә сүз әйтүне лязем саныймын. Буннан хәбәрдар булуның, бәлки, киләчәктә булачак мөкяләмәләрне[8] аңларга файдасы булыр.

## XII

### Англиянең осуле идарәсе хакында берничә сүз. Англиядә партияләр: хөрриятпәрвәрләр, мөхафәзәкярләр. Ирландия милләтчеләре, гамәлә фиркасе. Асквит вә Бальфур. Бүгенге хөкүмәт — хөрриятпәрвәр. Киләчәк сайлаулар.

Англия берничә гасырдан бирле идарәи мәшрутага маилдер[9]. 1688 сәнәдән бирле идарәи мәшруталы улмактан башка парламентлыдыр. Ягъни министрлар даимән парламент эчендә әксәрият булган партиядән сайланадыр.

---

[1] *Заһирән* — тыштан карaганда.
[2] *Нөфүзле* — абруйлы.
[3] *Әксәрият* — күпчелек (халык).
[4] *Әмният вә игътимадына* — иминлек һәм ышанычына.
[5] *Мәүкыйгыннан* — урыныннан.
[6] *Ирси* — мирас булып.
[7] *Мәхсулыдыр* — нәтиҗәседер.
[8] *Мөкяләмә* — сөйләшү, гәп кору.
[9] *Маил* — тартым, һәвәс.

Англиядә һәм әүвәлге дәрәҗәсендә Конституция бу көнге кадәр үк мөкәммәл түгел иде.

Хөррият вә мөсавәт [1] ноктаи нәзарыннан бик күп косурлар бар иде. Мәсәлән, сайлау хокукы һәр инглизнең хакы булмаенча, бер такым мәхдүд [2] дәүләт сахибләренә махсус иде. Аннан башка вәкилләрнең микъдары вилайәт вә шәһәрләрнең сәкәнәсенә [3] мөтәнасиб [4] түгел иде. Бәгъзы кечкенә генә шәһәрләрдән берничә вәкил сайланып, зур бер вилайәттән һич кемсә сайланмаган җирләр бар иде.

Сайлауларның да башта бер дә тәртибе юк иде. Бу бабта суи истигъмальләр [5] ниһайәтсез иде. Бу соң гасыр эчендә бу косурларның күбесе бетерелде. Бу гасыр эчендә берничә мәртәбә Англиядә сайлау кануннары үзгәртелде. Һәр үзгәртелү һәрвакыт халык файдасына иде, көннән-көн күбрәк кешене сайлау хакы мөкаддәсенә катыштыру фикеренә мөстәнид [6] иде.

Әлбәттә, бу сайлау хокукының киңәйтелүе, мөсавәтнең җәелүе, конституциянең мөкәммәлләнүе үзеннән-үзе булмады, хокуктан мәхрүм кешеләр, авызыны күтәреп, алма пеш, авызга төш, дип торуларыннан хасыйл булмады; билгакес, хокуктан мәхрүм инглизләрнең бик күп тырышулары, бертуктамый һиммәт итүләре, мөмкин булган саен, һәр җирдә үзләренең хокуксызлыкларыны халыкка аңлатулары, мөнәсәбәте килгән саен кычкыру-сөйләүләре аркасында гына бу мөсавәт хокукы вөҗүдкә чыкты. Бу мөсавәт хокукы һәр милләттә, һәр мәмләкәттә шулай озак заманнар тырышу саясендә алынадыр. Безнең төркичә бер мәкаль бар: «Егъламаган балага имчәк бирмиләр», диләр. Бу мәкальнең мокабиле [7] һәр лисанда бар. Русларда: «Дитя не плачет, мать не разумеет», диләр. Бу мәкаль сәясәттә һәм ярыйдыр. Егъламаган балага сөт бирмәгән кеби, сорамаган кешегә дә хокук бирмиләр. Сорагач та тиз генә бирмиләр. Сәбат [8], гайрәт вә үзеннең хокукының мөкаддәслегенә, газизлегенә тирән бер иман лязем. Үзенең теләгәненә үзе ышанмаган кеше инсан түгел кеби, үзенең мәтлабларына [9] кызу бер ышану илән ышанмаган милләтләр дә милләт түгелдер.

Ничә генә мәсьәлә хакында уйлап карасаң, һаман шул «ләисел инсан әлә мәсагый» аять керимәсе хәтергә төшәдер... Бу аять нә гамикъ[10] бер аятьдер. Әгәр бу аятьне яхшы уйласак, къәдәр[11] мәсьәләләрен ялгыш аңлаулардан котылыр идек. Французлар: инсан үзенең язмышының тимерчесе булырга кирәк, диләр. Инсан гына түгел, милләтләр дә шулай ук. Хәрәкәтсез, гамәлсез, ходадан ялваручылардан, кулыны багълаган ялкау зарланучылардан мәккярәви[12] кеше юк.

Нә исә, инглизләр ялкау булмадылар. Унтугызынчы гасыр эчендә гайрәт, иҗтиһад, сәбат саясендә инглиз демократлары вә инглиз тәхет идарәсендәге ирландиялеләр дә байтак зур хокукларны алдылар. Бүгенге көндә Англия конституциясе иң хөр мәшруталардан берседер. Сайлауларга иң бай аристократ лордлар катышкан кеби, иң фәкыйрь рабочий да катышадыр. Бу иң мөһим мәсьәләдер. Бу хокукка чынлап малик булып алган бер кешегә тәдриҗән башка һәр хокукны алырга ишек киң булып ачыладыр. Иң мөһим хокук — һәр мәмләкәттә сайлау хокукыдыр.

Искедән бирле Англиядә мәшһүр зур ике партия бардыр. Берсе мөхафәзәкярләрдер (консерваторлардыр). Икенчесе — хөрриятпәрвәрләрдер (либераллардыр). Мәгълүмеңез, һәр мәмләкәттә мөхафәзәкярлек — һәр шәйдә мәүҗүд хәлне саклау тарафдарлыгыдыр. Шуның өчен бунларга саклаучы партия — мөхафәзәкяр дип исем бирәләр. Һәр мәмләкәттә искедән калма хәл (ягъни кифайәт[13] идарә вә кануннар) идарә башында булган югары табәка[14] кешеләре файдасына ясалган булганга, мөхафәзәкярләр һәр мәмләкәттә югары табәканең — аристократлар-

---

[1] *Мөсавәт* — тигезлек.
[2] *Бер такым мәхдүд* — чикле бер төркем.
[3] *Сәкәнә* — билгеле бер урында яшәүчеләр.
[4] *Мөтәнасиб* — тигез, бер чама.
[5] *Суи истигъмаль* — урынсыз куллану.
[6] *Мөстәнид* — таяныч, нигез.
[7] *Мокабиле* — охшашы.
[8] *Сәбат* — ныклык.
[9] *Мәтлаб* — теләк, максат.
[10] *Гамикъ* — тирән.
[11] *Къәдәр* — язмыш, тәкъдир.
[12] *Мәккярәви* — алдакчы, хәйләкәр.
[13] *Кифайәт* — җитәрлек, булган кадәре.
[14] *Табәка* — катлау, дәрәҗә.

ның вә мал сахибләренең мәнафигыны[1] сакларга, мөдафәгә[2] итәргә тырышучылар буладыр. Мөхафәзәкярләр кулдагы бәрәкәтне кулдан ычкындырмау тарафындагы кешеләрдер. Хөрриятпәрвәрләр — либераллар исә бер туктамый исляхат-реформа ясау, һәрвакыт хөрриятне көннән-көн нәшер итеп, мөсавәтне көннән-көн фигыльгә чыгару тарафындагы кешеләрдер. Болар югары табәканең кулындагы бәрәкәтне саклаучы түгел, бәлки бәрәкәт вә рәфаһ[3] хәлне милләтнең һәр табәкасенә гам итү[4] тарафындагы кешеләрдер.

Менә Англиядә иң зур партия бу ике партиядер; парламент эчендә болар һәрвакыт тигез булмыйлар. Сайлаулар да партиянең бәхетенә карыйдыр. Бер сайлауда мөхафәзәкярләр җиңәдер, икенче сайлауларда исляхпәрвәрләр галәбә итәдер. Парламент эчендә кайсы партиянең кешесе күбрәк булса, министрлар шул партия кешеләреннән сайланадыр. Министрларның әксәрият булган партиядән сайлануы бер мәмләкәттә идарәнең парламентлы булуыдыр. Идарәи мәшрута булу парламентлы булу түгелдер.

Бер мәмләкәттә идарәи мәшрута булыр, ягъни канунтар милләт вәкилләре тарафыннан чыгарылыр, ләкин министрлар парламенттагы күп партиядән булмас. Буңа мисал — Германия. Германиядә министрларны сайлап кую Германия императорының ихтыярында, ул теләсә кемне сайлыйдыр, теләсә кайсы партиядән сайлыйдыр. Ләкин Англиядә идарәи мәшрута булудан башка һәм парламентлыдыр. Ягъни, тәкрар әйтәм, министрлар мотлака парламент эчендә күбрәк булган партия кешеләреннән сайланырга тиештер. Бу ник болай? Чөнки парламент эчендәге күбрәк партиянең фикере мәмләкәт эчендәге халыкның күбрәгенең фикере дигән сүздер.

Бу соңгы гасыр эчендә Англиядә бу ике партия әле берсе, әле икенчесе җиңә килде. Искедән газитә укып килгән кешеләргә Гладстон, Солсбери исемнәре мәгълүмдер. Бу ике кеше унтугызынчы гасырның соңгы яртысында әле берсе, әле берсе нәүбәтләшеп баш министр булып килделәр. Гладстон бер дәрәҗә хөрриятпәрвәрләрдән иде, Солсбери мөхафәзәкярләрдән иде. Буннан өч сәнә мөкаддәм идарә башында мөхафәзәкярләр иде. Баш министр Чемберлен иде. Англиядә буннан өч сәнә мокаддәмге сайлауларда хөрриятпәрвәрләр галәбә чалдылар. Бүген дә парламентта әксәрият — хөрриятпәрвәрләр. Бу соңгы сайлаулардан хөрриятпәрвәрләр икътидарга кичкәч[5], бу партиянең башлыгы Кампал Банерман баш вәзир булган иде. Ләкин үткән сәнә ул вафат булып, аның урынына хөрриятпәрвәрләрнең башлыгы булып калган Асквит баш министр булды. Әле генә безнең мәҗлестә нотык сөйләгән карт — шул Асквит иде. Асквит урта буйлы, калынча гына, бик көлүчән түгел, байтак озын вә куе ак сачле, кызгылт чәһрәле, сакал-мыегы кырган, заһирән простой табигатьле бер карттыр; сөйләве салмак, күз каравында бер тирән, үзенә ышану хис ителәдер.

Хәлбуки аның рәкыйб сәясисе[6] — мөхафәзәкярләр башлыгы Бальфур бөтенләй башка типтагы бер кешедер. Бальфур озын буйлы, карарак йөзле, нәхиф[7] бер адәмдер. Йөзенең һәр галәмәте гаять инҗи рухлы, зәки[8] бер адәм икәнене күрсәтәдер. Нотык сөйләү формасы бунын да салмак исә дә, утлы бер табигать сахибе бер кеше икәнене белдерәдер.

XIII

## Милли Ирландия партиясе вә гамәлә[9] партиясе

Парламентта бу олугъ ике партиядән башка дәхи берничә партия бардыр, болардан мөһим булганнарыннан ике группа хакында бер-ике сүз лязем. Иң әүвәл Ирландия милләтчеләре фракциясе, Ирландия националистларыннан бәхәс итик. Мәгълүменез, асыл Англия ике җәзирәдән мөрәккәб. Бу җәзирәләрдән берсе үзе икегә бүленәдер: Британия вә Шотландия; икенче җәзирә — Ирландиядер. Асыл инглиз исемендәге халык Британия дигән җәзирәдә

[1] *Мәнафикъ* — мәнфәгатьләр.
[2] *Мөдафәгә итү* — үз-үзеңне саклау.
[3] *Рәфаһ* — муллык, иркенлек.
[4] *Гам итү* — күмәк итү.
[5] *Икътидарга кичкәч* — куәтләнгәч.
[6] *Рәкыйб сәясисе* — сәяси конкуренты, көндәше.
[7] *Нәхиф* — ябык, арык.
[8] *Инҗи рухлы, зәки* — ачык рухлы, зирәк.
[9] *Гамәлә* — эшчеләр.

сакин кавемдер [1]. Әүвәлдә Шотландиянең бөтенләй үзенә махсус мәдәнияте, падишаһлары булган. Бу Англия падишаһлары илән Шотландия падишаһларының мөтагаддид [2] сугышлары Англия тарихының иң зур бер кыйсемен аладыр. Шотландиянең хатын падишаһы Мария Стюарт бөтен галәмгә мәгълүмдер. Нә исә, нә булса булган, Шотландия Англия кулына төшкән. Бу көндә Шотландиядә лисан вә мәдәният, дин — һәрбере Англия мәдәнияте вә динедер. Иске Шотландия лисаны мәдәниятләнеп җитмәгән, яки, тагы да тугърысы, инглизләнеп бетмәгән, тауларда мужик авылларында гына калган. Ләкин алай булса да, Шотландия халкы үзенең табигатене җуймаган, табигатьләре асыл инглиз халкына караганда ачыграк, үткенрәк; киләчәктә Шотландиягә сәфәремез заманында бу хакта берничә сүз язарым.

Инде килик Ирландия әхваленә. Ирландиянең хәле бөтенләй башка. Иң әүвәл Ирландия Шотландиягә караганда байтак заман соң Англиягә кушылган. Аннан соң, ирландиялеләр һәрвакыт католиклыкларыны ташламаганнар. Хөкүмәт динене нә кадәр таратырга тырышсалар да, бу хакта һичбер эш эшли алмаганнар. Затән динене, милләтене сөйгән бер милләтнең диненә нә кадәр тәгъриз [3] кыйлынса, шулкадәр хәмияте динийә вә миллиясе [4] арта гына барадыр.

Моннан йөз сәнә мөкаддәм бөтен Ирландиядә хөкүмәт мәэмүрләре арасында һичбер ирландияле кеше юк иде. Ирландиядә бөтен мәнсаблар [5] һәрбере инглизләр кулында иде. Башка һәртөрле мәнсабларда инглиз булган кеби, хакимнәр дә инглиздән иде. Бу хакимнәр арасында бер дә ирландияле кеше булмавы ирландиялеләрнең иң эчләрене пошырган мәсьәлә иде. Ирландиялеләрне мәхзүн иткән [6] бер хөкем вә хакимнәр мәсьәләсе генә түгел иде. Аннан тагы да мөһимрәк җир мәсьәләсе — Аграрный вопрос бар иде.

Ирландия Англия кулына төшкәннән соң Ирландиядә бөтен җирләр инглиз байларының, лордларының кулына төшеп беткән иде. Бунын ничек төшеп беткәнене безнең Кырым мөселманнарыннан һәм башкортлардан сорарга кирәк. Аларда һәм акрынлап җирләр башка милләт байларының кулына китеп бетәдер. Тиз көннән Төркестан әһалисенең һәм җирләренең үз кулыннан китеп беткәнене карап тору фәнендә остару ихтималы бардыр. Бөтен Ирландия халкы инглиз байларының иген игеп хезмәт итүчесе булып калган иде. Ирландия халкы дигән бер халык юк иде. Ирландия дигән Англиянең бер кыйсеме бар иде. Андагы бөтен мал вә әразый [7] инглиз байларының кулында иде. Авылда җаһил, надан вә фәкыйрь католик динендәге Ирландия мужиклары бар иде.

Инглиз байлары бик тыныч иде. Ләкин һәрбере инглиз лорд һәм байлары кулында җир хезмәтчесе көненә калган бичара Ирландия мужикларынын хәле бик начар иде. Хезмәтче булмаганнары инглиз җир хуҗаларыннан кечкенә җир кисәге арендага алып, шуны игеп тамак туйдырырга тырышалар иде.

Ирландиядә халык үрчегән саен җир сахибләре аренда бәһасене арттыра баралар иде. Эш хакыны арттырмыйлар иде. Шулай итеп, көннән-көн Ирландия көйлеләренең [8] тормышы читенләнә бара иде. Фәкыйрьлек ниһайәтсез дәрәҗәгә җиткән иде. Мужиклар бары бәрәңге ашап торырга калган иде. Өстләренә кигән киемнәре дә калын киндер иде. Ул да искереп беткән була иде.

Ул заманда Ирландиядә булган сәйяхләрнең [9] тәгърифенә нәзарән, дөньяда һичбер вакыт авыл халкы бу кадәр мескенлек, фәкыйрьлеккә калмагандыр, диләр. Бәлки, тикшереп карасаң, тагы да бардыр. Аларга каршы инглиз җир сахибләренең, управляющийләренең гадаләтсезлекләре тәгърифтән хариҗ[10] иде. Һичбер вакыт хөкем илән гадаләт алырга хәл юк. Бөтен хакимнәр инглиз булганга, һәрвакыт җир сахибләренең сүзене өсткә чыгаралар иде. Җир сахибләре вә аларның кешеләре мужикларга ачулары килсә, аларның бердәнбер сыгырларыны атып үтерү кирәкме, өйләрене ут төртеп яндыру кирәкме, һичбереннән чиркәнмиләр иде.

---

[1] *Сакин кавем* — җирле халык.
[2] *Мөтагаддид* — күп санлы.
[3] *Тәгъриз* — каршы тору, ризасызлык.
[4] *Хәмияте динийә вә миллиясе* — дин һәм миллилеген саклавы.
[5] *Мәнсаб* — дәүләттә хезмәт урыны.
[6] *Мәхзүн иткән* — кайгырткан.
[7] *Әразый* — җирләр.
[8] *Көйлеләр* — авыл кешеләре.
[9] *Сәйях* — сәяхәтче.
[10] *Тәгърифтән хариҗ* — аңлатудан тыш.

1829 нчы сәнәгә кадәр Ирландия халкы һичбер мәэмүриятләргә [1] керә алмаган кеби, мәҗлесе мәбгусан [2], парламентка сайлауга да катышмыйлар иде. Ләкин 1829 сәнәдә Ирландия халкына сайлау хакы бирелгән иде. Бу да матур күзләре өчен түгел, бәлки җир сахибе байларга депутат булып сайланырга бер василәә [3] булсын өчен иде.

Шул сайлау хакына малик булу Ирландия халкының терелә башлавының ибтидасы [4] булды.

Югарыда һәм әйткән идем: Ирландия халкы католик динендәдер; хәлбуки, беләсеңез, инглизләр протестантлыкның бер нәүгысе [5] англикан мәзһәбендәдерләр. Ирландия халкы арасында диндарлык, үзләренең попларына хөрмәт бик зур иде. Диннәрендә үзләренең өмидсез хәлләренә якянә [6] бер жуаныч күрәләр вә попларда үзләренең дин вә милләт мөдафигълары [7] күрәләр иде. Һәрвакыт мәҗбүр милләтләр дин голәмасына ихтирам итәләр вә шул голәма әтрафына килеп укмашалар. (Бик яхшы итәләр!)

Католик булсалар да, Ирландия мужикларыннан англикан поплар файдасына гошер (иген бәрәкәтенең уннан берене) җыялар иде. Бу үз диненнән башка бер дин попларына көчләп гошер җыю фәкыйрь Ирландия халкына бик агыр тоела иде. Ирландия сайлауларга катыша башлагач, тәсадефан [8] берничә асыл ирландияле депутат булып сайландылар. Бу хәл Ирландия бичараларының күнелене күтәрде. Акрынлап гошер түләмәү өчен хәрәкәтләр күренә башлады. Ул арада араларыннан бер сүзгә оста О'Коннол исемле яшь адвокат килеп чыкты. Төрле җирләрдә җыюлар ясап, халыкны вәгазьләргә башлады. О'Коннол католик диненә хөррият вә Ирландия әһалисенә мөсавәт, хокукта тигезлек теләүгә өнди иде, бу исә ул вакыт һич көтмәгән хәл иде. О'Коннол ясаган җәмгыятьләргә халык һәр җирдә меңләп җыела иде.

Англия хөкүмәте, бердән, хөррият исеменә, икенчедән, Ирландия халкыннан һичбер эш чыгар дип ышанмаганга, бу иҗтимагъ, собраниеләрне ясаудан мәнгъ [9] итми иде. Бу җәмгыятьләрдә О'Коннол фикере акрынлап тарала иде. Күп җирләрдә гошер җыярга килгән кешеләрне куып җибәрәләр иде. Халык котырып гошер җыючыларны һәлак иткән җирләр дә була башлады.

О'Коннолның собрание, нотык мәҗлесләренә (митинг) кеше күп җыела иде. Аның Дублин шәһәрендә ачык һавада ясаган бер собраниесендә утыз биш мең кеше булган иде. Тарихка мәшһүр О'Коннол гыйсъян[10] тарафында түгел иде. Ул һәрвакыт әйтә икән: «Без бервакыт максудка ирешермез, җиңәрмез, ләкин солых илән, идарәи мәшрута вә канун даирәсендәге васиталар илән җиңәрмез, башка васитага ихтыяҗ калмас; әфкяре гомумиянең электригы кяфи[11] булыр»,— ди икән. Алай булса да, Англия хөкүмәте чыдый алмады. О'Коннолны тоттырып яптырды. Аннан соң котылдырдылар. Ләкин ахырында О'Коннол сыйххәте начарланып, озакламый үлде. Ул үлде, ләкин исеме, шәрәфе вә ул мәйданга аткан фикер үлмәде. Инде Ирландия халкында хөррият вә мөсавәт фикере туган, бик матур булып үсәчәк иде. Һәм шул вакыттан башлап һич үлмәде. Хокук, мөсавәт, гадәләт вә тәрәкъкый фикерләре бер тугъдымы, буны үлтерү һич мөмкин түгелдер. О'Коннол үз исәнендә үк бер бик зур партия ясап өлгергән иде. Партиянең исеме «Яшь Ирландия» иде. Шулай ачылып кына барганда, Ирландиядә берсе артыннан берсе берничә ачлык еллар булып, бик күп халык үлеп, күбесе Америкага күчәргә мәҗбүр булдылар. Шулай итеп, бу хөррият хәрәкәте янәдән берничә вакыт туктап торды. Кинәттән бөтен Ирландиядә ике миллионга якын кеше берничә ел эчендә кимегән иде.

1848 нче сәнә Франциядә революция булганыны ишеткәч, янә Ирландиядә фикерләр кузгалып, янә бераз күтәрелеп карасалар да, эш күрә алмый байтак вакыт тукталып торырга туры килгән иде. 1870 нче сәнәләренә таба хәрәкәт янә баш күтәрә. Янә бер милләтпәрвәрләрне янына җыярлык ут йөрәкле бер кеше

[1] *Мәэмүриятләр* — дәүләт идарәханәләре.
[2] *Мәҗлесе мәбгусан* — депутатлар мәҗлесе.
[3] *Василәә* — чара, әмәл.
[4] *Ибтидасы* — башлангычы.
[5] *Нәүгысе* — төркеме, өлеше.
[6] *Якянә* — бердәнбер.
[7] *Мөдафигъ* — саклаучы.
[8] *Тәсадефан* — көтелмәгәндә, очраклы рәвештә.
[9] *Мәнгъ* — каршылык.
[10] *Гыйсъян* — баш күтәрү, фетнә.
[11] *Кяфи* — җитәрлек (кадәр).

зоһур итте [1]. Парнелл дигән бер ирландияле сүнмәгән, бары томаланып яткан хөррият вә миллият хәрәкәтене янә алга чыгарды.

1875 сәнәдә Парнелл депутат булып Лондонга килде. Бунын депутат булуыннан соң инглиз Думасында Ирландия мәсьәләсенә нәзар башкарды. Буңа кадәр Ирландия депутатлары булса да, аларга инглиз депутатлары бер дә әһәмият бирмәй, түбән күрә иде. Сөйләгәндә ирландиялеләрнең хәмиятеннән көләләр, истиһза [2] итәләр иде. Ләкин Парнелл, мәгълүмат сахибе булуы өстенә, Лондонда тәрбия күргәнгә, гаять назик [3], тәмиз [4] иде. Шуның өчен аны бөтен палата берДәнбергә хөрмәт итәргә мәҗбүр булды.

Парнелл, үзе желекләренә кадәр халык тарафында демократ булса да, өстбашына әһәмият бирә иде. Һәрвакыт бик пакь, тәмиз вә матур киенергә тырыша иде. Чөнки буңа инглизләр әһәмият бирә иде. Хәлбуки, буңа кадәр ирландиялеләр начар киенүне гадәт иткәннәр иде. Парнелл нотыкларында гаять назик рәвештә инглизләргә иң ачы хәкыйкатьләрне әйтергә осталыгы илән мәшһүр иде. Аның: «Ирландия бер кәлимәи җәгърафиявия [5] түгел, бу бер милләтдер»,— дигән сүзләре тарихи сүзләрдер. О'Коннол партиясе Ирландиянең бөтенләй аерылуы тарафында иде. Парнелл, билгакес, Англиягә мөлхак [6] калып, бары Ирландиянең үзенә башка бер мәхәлли парламент сорау тарафында иде.

Парнелл парламент эчендә һич башка кешеләргә катышмый торган, хәтта иң хөрриятпәрвәрләргә катышмый торган бер аерым Ирландия милләте фракциясе ясарга тырышып, шуны ясарга муафикъ булды.

Шул көннән башлап һәрвакыт Англия парламентында бу Ирландия милләтчеләреннән мөрәккәб [7] бер фракция була киләдер. Бу фракциянең тырышуы, кычкырулары, бу фракция депутатларының нотыклары, иҗтиһадлары сәясендә бу гасыр эчендә Ирландия халкы файдасына бик күп исляхлар ясалды. Хәзерге көндә һәм Ирландия депутатлары тырышуларыннан һич туктамыйлар. Боларның сораган мәтлабларының иң мөһиме Ирландиягә махсус бер парламент (һәм роль) тәэсис итдерүдер. Әлбәттә, буңа малик булгач, бүтән калган дахили [8] эшләр асат исләях ителәчәктер.

Инглиз парламентында моннан башка мөһим партия — гамәл партиясе — Labour parti дигән партиядер. Бу партия исеменнән үк билгеле: гамәлдән мөрәккәб, безнең Думадагы Трудовая партия кеби бер партиядер. Затән безнең Трудовая партия дигән исемне бу партияне Русиядә тәэсис итүче Аладьин һич шөбһәсез шул инглиз партиясенең исеменнән тәрҗемә иткән иде. Аладьин бик күп сәнәләр Англиядә торган, хосусән шул гамәл партиясе кешеләре арасында катышкан икәне һәркемгә мәгълүмдер.

Бу эшчеләрнең дә сайлауга катышулары бик күптән түгел, болар да күп заман сорау, кычкыру, собраниеләр аркасында гына сайлау хакларына барып житте. Тарихе сәясәтне теләсәң генә кайсы заманда, теләсәң генә кайсы мәмләкәттә тикшерсәң тикшер, һәр җирдә бер хәкыйкать күзгә кеби заһирдыр; бу хәкыйкать буннан гыйбарәт: хөррият вә хокукларны бер дә сорамый-кычкырышмый алып булмый. Бердәнбер генә кычкырып та эш чыкмый, озак заман, сәбат илә, белеп кычкырырга кирәк; сәбат-гайрәт булдымы, теләгән хокук, теләгән хөррият, мөсавәт алынмый калмыйдыр.

Әле генә ирландиялләрдән бәхәс иткән идем. Инде Англия рабочийларыннан бәхәс итәмез. Бу ике таифә [9] һәр икесе гайн васиталар [10], гайн сәбат илә мөсавәт, хокук әмре мөкаддәсенә васыйл булдылар [11].

Англия эшчеләренең хокук намәнә булган мөҗадәләләрене [12] язарга тотынсам, бу баб зураер, икенчедән, сез дә арырсыңыз. Туктыйк! Ләкин шул кадәресене әйтәм: Англиянең соңгы гасыргы хәяте сәясиясенең иң мөһим вакыйгаләре сайлау хокукларыны арттыру хакында булган мөҗадәләи мәгънәвиялрдер. Бу гасыр эчендә сайлау кануны ике-өч мәртәбә үзгәртелде. 1832 дә, 1867 дә. Соң

---

[1] *Зоһур итте* — барлыкка килде.
[2] *Истиһза* — хурлау, мыскыл итү.
[3] *Назик* — нечкә, гүзәл, нәфис.
[4] *Тәмиз* — саф, чиста.
[5] *Кәлимәи җәгърафиявия* — географик сүз.
[6] *Мөлхак* — кушылган.
[7] *Мөрәккәб* — төзелгән.
[8] *Дахили* — эчке.
[9] *Таифә* — төркем.
[10] *Гайн васиталар* — шул ук чаралар.
[11] *Васыйл булдылар* — ирештеләр.
[12] *Мөҗадәләләр* — бәхәсләр.

үзгәртү 1885 тә вакигъ булды. Бу канун буенча сайлауга малик булырга йорт сахибе булу, яхуд елында йөз рубля чамасы квартир түләү житәдер. Күрәсенез, Англиядә әле һич тә гомуми сайлаулар юк. Ләкин хәзер Англия парламентында шактый куәтле гамәлә партиясе булган кеби, мәмләкәт эчендә һәм көннән-көн гамәлә партиясенең әһәмияте арта барадыр. Англиядә гамәлә җәмгыятьләре — бөтен дөньяда иң бай гамәлә җәмгыятьләредер.

## XIV

### Түбән палата рәисе ханәсендә кунакта. Англия хатыннарында сәясәттән хәбәрдарлык. Русиягә нәзарлары.

Бүген сәгать биштә түбән палата, ягъни Англиянең әһали тарафыннан сайланган мәҗлес мәбгусанының рәисе чәйгә чакырганыны язган идем. Рәиснең ханәсе парламент бинасында; гаять мөкәммәл зур-зур бүлмәләрдән мөрәккәб бер квартир; бу квартирдагы зиннәтләрне, картиналарны тәгъриф итеп тормыйм, ләкин шул кадәресене әйтәм: стенада кыйммәтле картиналарның күплеге, ханәнең һәр тарафының гаять нечкә бер зәвекъка муафикъ түшәлгәнлеге ханәгә кергәч үк күзгә төшә иде. Мәгълүмеңез, Лондонга килгәннән бирле бу безнең беренче хосусый ханәгә керүемез иде. Бинаән галәйһи[1] һәр шәйгә дикъкать итә идек. Мин кичә кич бер ханәдә булсам да, бу ханә бер гади инглиз ханәсе иде. Бу исә Англиянең зурларыннан беренең мәсканедер[2].

Ханәгә кергәч, безнең илән бәрабәр булган лорд Уирдэль һәрберемезне рәис хатынына, соңра кызына таныштырды, тәкъдим итте. Рәисә гаять сәрбәст[3] французча сөйләшә, кызы тагы да яхшы сөйли икән. Рәискә һәрберемезне тәкъдим итеп беткәч, кабул салонында һәрберемез төрле тарафка таралдык. Салонда кырыктан зиядә[4] дамалар вә беркадәр ирләр бар иде. Кунаклар һаман килә иде. Лорд Уирдэль безнең рус депутатларыны кеше арасыннан эзләп табып, әле беремезне, әле беремезне кунак дамаларга тәкъдим итә иде. Мине һәм табып бер дамага тәкъдим итте. Тиз генә әйткәндә даманың фамилиясене ишетмәсәм дә, сөйләшергә тотындым. Мадам тәмам мөкәммәл французча сөйли. Думада ничә мәбгус[5] булганыны, нә кадәр партияләр булганыны, партияләр арасындагы фәрекъләрне[6] сорады; бу сөальләрне сүз югында сүз булсын дип кенә сораганга охшамый иде, беләсе килеп сораганга охшый иде. Һәр сөаленә тәфсыйләткә кермәенчә, бер әҗнәби аңларлык рәвештә итеп җавап бирдем. Сөйләшә торгач, минем Русиянең кайсы тарафыннан мәбгус икәнемне сорады. Кайдан икәнемне әйттем. Заграницада Русия җәгърафиясене бик томанлы беләләр. Казаннан, дидем; Казан исә Волга нәһере буенда бер шәһәрдер, дидем. Бу да житмәде; Урал тарафларыннан, дидем. Алай Себергә якын, дидем. Бик ерак түгел, тимер юл илән ике көнлек юл, дидем. Мөселман икәнемне әйтергә тугъры килде. Мөселман һәм татар, дидем. Аңа мадам фәүкыльгадә гәҗәпсенде. Мин татар халкыны бөтенләй башка төрле тәсаувыр итә[7] идем, диде. Татарлар һәммәсе дә сезнең кеби мәдәниятлеме, диде. Укыганнары, тәрбия күргәннәре һәрбере миннән мәдәниятлерәк, дидем. Алай булса да, гаҗәпләнүеннән туктамый иде.

— Сезне ничек татар дип белергә кирәк, сезнең французча сөйләвеңез бер француз кеби,— фәлән дигән булып, бер такым мәдехләргә[8] кереп китте.

— Бу артык мәдехләреңездән мөтәәссирмен,— дидем. Мактаганга каршы мин дә аны мактадым. Мин дә аның французча сөйләвенә чынлап тәхсин иткәнемне белдердем.

— Минем сөйләшүем гаҗәп түгел,— диде.— Мин кечкенәдән Франциядә тәрбия алдым һәм бүген дә безнең имениямез Фраанциядә Луара нәһере буенда,— диде.— Һәр сәнә ике-өч ай Франциядә үткәрәмез, бөтен хадим вә хадимәләремез француз булган кеби, бөтен йөрешкән кешеләремез һәм

---

[1] *Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.
[2] *Мәскән* — тору урыны, өй.
[3] *Сәрбәст* — ирекле.
[4] *Зиядә* — артык, күбрәк.
[5] *Мәбгус* — депутат.
[6] *Фәрекъ* — аерма, үзгәлек.
[7] *Тәсаувыр иту* — күз алдына китерү.
[8] *Мәдехләргә* — мактарга.

күршедәге шату сахибләре французлардыр,— диде.— Минем ирем бик кунак сөядер, әгәр Франциягә килергә туры килсә, безгә рәхим итегез,— диде.— Җәй көне бик күп кунак буладыр,— диде.— Тиздән минем ирем һәм бунда киләчәктер. Мин сезне иремгә таныштырырым,— диде.— Мин сезнең илән озак сөйләп киттем, сезгә бүтән кешеләр белән танышу мәтлүбтыр; әйдәгез, мин сезне берәр кеше белән таныштырыйм,— диде. Якында гына торган бер дамага тәкъдим итте:— Мадам, менә сезгә бер татар депутаты, тәкъдим итәм,— диде.

Бу дама да французча ярыйсы сөйләшә. Бу дама Лондон хакындагы фикерләремне сорады. Бер дә рыясыз мактадым.

— Дөрест, ләкин сез болай сәяхәттә безнең мәдәниятнең матур тарафларыны гына күрәсенез; безнең мәдәниятнең бик күнелсез тарафлары да бар,— диде. Лондондагы фәкаранын[1] дәһшәтле хәленнән бәхәс итте.

Мин бу хакта бер генә төрле дә фикер сөйләүдән качтым. Кунакның вазифасы — күнелсез тарафларга күз йому, күрмәгән булу түгелме? Буннан сәясәткә күчте:

— Сезнең Дума нинди исляхлар ясады?— диде.

Янә кыска итеп, тыңлаучы арымаслык итеп бер-ике мөһим кануннан өстән генә бәхәс иттем. Мадам Англиядә бу көннәрдә һәр ике палатада каралачак җир налогыннан бәхәс итте:

— Без халыкка, әһалигә файдалы бер налог кертергә тырышамыз,— диде.

Хатын бу налогның нидән гыйбарәт икәнене яхшы гына, аз гыйбарәт илән аңлатты. Затән[2] мәсьәләне белә иде.

Бу ике хатынның сөйләшүләрендә бер шәй дикъкатемне җәлеп итте. Хатыннар һәр икесе сәясәттән яратып бәхәс итәләр һәм аңлап сөйләшәләр. Бәхәсләре гадәттә Франция вә Русия салоннарындагы дамаларның политикадан бәхәс итүләренә охшамый. Дөрест, бунлар сәяси кешеләрнең җәмагатьләредер. Ләкин мин Франциядә һәм Русиядә байтак депутат хатыннарыны таныймын. Боларның политикадан бәхәс итүләре бик сатхи[3] буладыр. Хәтта бәгъзан нә дахили, нә харижи сәясәттән бер шәй аңламаганлыклары белән бер нәүгъ нәзакәт күрсәткәннәре дә буладыр.

Без болай сөйләшеп торганда, беренче сөйләшкән дама үзенең ирене алып килеп таныштырды, исеме мистер Пэри, беренче палатада икән. Сонра белдем, палатада ярыйсы гына кувәи нотыкиягә[4] малик бер депутат имеш. Мистер Пэри мине бик каты Франциядәге шатусына[5] җәйгә кунакка чакырды. Җәмагате Лондонда булган мөддәттә ханәләренә килергә үтенде. Кабул көннәремез пәнҗешәмбе көннәредер, диде. Бу хатын ирене алып килеп тәкъдим иткәндә икенче дама да безнең якыннан китмәгән иде.

Мистер Пэри минем илән күрешеп киткәчтән, янә бу дама килде:

— Мин сезгә әйтергә оныттым, әгәр Лондонда вакытта минем кабул көннәремдә боерсаңыз, зиядә мәмнүн булырым. Юкса аерым мәҗлескә дәгъвәт итәргә җәсарәт[6] итмим, чөнки беләм, сез фәүкыльгадә мәшгульсенез, һәр көнегез, һәр сәгатегез алдан тәгъйин ителеп бетерелгән,— диде.— Әгәр кабул көннәремдә килә алмасаңыз, башка бер буш булган көнегездә рәхим итегез. Өйләдән соң сәгать икедән бишкә кадәр ханәдә булам,— диде. Вә адреслары язылган иренең визит картасыны бирде.

Шул сәгать укыдым: «Бироль, Ирландия эшләре нәзарәте министры» дигән иде. Аңланды ки, бу хатын бер министр хатыны икән. Буннан соң бу дама миннән аерылды.

Мәгълүменез, бер салонда бер кешегә туры килеп сөйләшә башлап озак тору мәкъбуль түгелдер, бераз сөйләшкәч, аерылырга лязем буладыр. Әгәр сөйләшүчеләрдән берсе дама булса, һәрвакыт дама аерылып китәргә тиеш буладыр. Чөнки ир кеше даманы ташлап китү әдәпкә могаирдер[7].

Әгәр бер салонда танышып сөйләшүчеләр икесе дә ир кеше булса, бераз сөйләшкәч, һәр икесе бик оста итеп аерылып китәләр, йә мөкяләмәне[8] оста

---

[1] *Фәкара* — фәкыйрьләр.
[2] *Затән* — нигездән, төптән.
[3] *Сатхи* — беркатлы, сай мәгънәле.
[4] *Кувәи нотыкия* — нотык сөйләү сәләте.
[5] *Шату* — замок.
[6] *Җәсарәт* — батырлык, кыюлык.
[7] *Могаир* — үзгә, каршы.
[8] *Мөкяләмә* — сөйләшү, гәп.

кисәләр. Йә берсе әйтә: «Сезгә башка дустларыңыз илән сөйләшүеңезгә манигъ [1] булмыйм»,— ди.

Бу адәбе могашәрәт [2] минем фикеремә бик муафикъ, чөнки, шөбһәсез, бөтен кабул заманында бер генә кеше белән сөйләшеп утырудан берничә кеше илән сөйләшү күңеллерәк һәм кызыклырактыр.

Ирландия министрының хатыны мадам Бироль илән сөйләшеп торганда иптәшләремнән барон Круднер-Струве килде. Миннән сорады:

— Г. Максудов, безнең Русия сәфире — посол хатыны илән таныштыңызмы? — диде. «Юк»,— дидем. Якын алып барып мадам Бенкендорфка тәкъдим итте.

Мадам Думага хөрмәтене изһар итде [3]:

— Бөтен аркадашларыңызга да сөйләдем, ватаным мәгбусларының Англиягә бу рәвештә килүләре илә фәүкыльгадә ифтихар итәм [4]. Бунлар өмид ителмәгән хәлләрдер,— диде. Лондон хакындагы фикеремне сорады. Соңра диде: — Мин сезнең унбиш көнлек програмыңызны карадым. Кичке тәгамәләреңез һәрберсе тәгъйин ителеп беткән. Ләкин буш калган өйлә тәгамләреңез бар, рижа итәм, бер көн буш булдыңызмы, ресторанда йимәк йимәңез, тугъры сәфарәтханәгә [5] рәхим итеңез, капуымыз ачык, тәрилкәләреңез хәзер булыр,— диде. Тәшәккер иттем [6]. Бу сүзләрдән соң: — Берәр дама белән таныштырыйммы? Сез монда һәркемне танымый торгансыңыз,— диде.— Килегез бире, мин сезне Лондонның матур хатыннарыннан берсе илән таныштырыйм,— диде дә, мадам Лэг наменда бер депутат хатыны белән таныштырды.

Мадам Лэг асыл ирландияле имеш. Һәм хәкыйкатьтә гаять җәмилә [7] бер хатын икән. Куе сары сачләре, зур гакыллы күзләре. Бөтен симасында [8] таралган зәкяэ вә җәмал [9] һәркемнең дикъкатене җәлеп итә иде. Мадам Лэг матур французча сөйләшә; кечкенәдән французча сөйләшеп үскән имеш. Аннан магада[10] бик еш Италиядә вә Швейцариядә була имеш. Мадам Лондонның салон вә мөсамәрәләр[11] хәятыннан бәхәс итте. Лондонда бу заман тамм[12] мөсамәрәләр заманы булганга, һәркөн берничә җирдә булырга тугъры киләдер, диде.

— Бу мөсамәрә вә салон хәяты Петербургта бик модадамыдыр? — диде.— Сез бу хәятны яратасыңызмы? — диде.

Петербургта һәм бөйлә[13] бер хәят булганыны, ләкин без, Дума әгъзалары, моңа иштирәк итәргә[14] вакытымыз булмаганыны сөйләдем. Мадам Лэг диде:

— Бездә депутатлар мөмкин булган кадәр бу хәяткә — Светская жизньгә катышырга мәҗбүрдер,— диде.— Салоннан бөтенләй качкан депутат вәхши саналадыр,— диде.

Бу арада кунаклар килеп беткән иде. Кабул салоныннан чәй эчү бүлмәсенә чыктык. Чәй бүлмәсе бик зур бер зал, залның түрендә зур буфет, буфет өстендә бик күп чәшкә вә бер такым йимәк нәрсәләре хәзер; һәркем, теләгән кеше, барып чәшкә алып, хадимнәргә бирә дә, хадимнәр теләвеңә карап кофе, чәй, йә шиколад салып бирәләр.

Моны тәгърифтән максудым — бу кеби зур кабулларның нидән гыйбрәт икәнене белдерүдер. Бу кеби зур кабуллар Петербургта, Берлиндә, Париж һәм монда Лондонда һәм бер рәвештәдер. Бик күп халык килеп җыела, һәрбере аяк үзрә торып, бер-бере илән таныша, сөйләшә; соңра бер бүлмәдә чәй, шиколад хәзерләнгән буладыр, кич белән булса, азрак ашый торган суык нәрсәләр дә була.

Чәй бүлмәсендә мадам Лэг һәм үзенең кабул көненә адресыны биреп миннән аерылды. Моннан соң яныма якын килеп, Стахович мадам Лэг илән таныштыруымны үтенде. Таныштырдым.

---

[1] *Манигъ* — киртә, комачау.
[2] *Адәбе могашәрәт* — әдәпле, дустанә яшәү.
[3] *Изһар итү* — ачып салу, күрсәтү.
[4] *Ифтихар итү* — мактану, горурлану.
[5] *Сәфарәтханә* — илчелек.
[6] *Тәшәккер иттем* — рәхмәт әйттем.
[7] *Җәмилә* — матур, гүзәл.
[8] *Сима* — йөз, чырай.
[9] *Зәкяэ вә җәмал* — сафлык вә гүзәллек.
[10] *Магада* — башка, бүтән, гайре.
[11] *Мөсамәрә* — кичке утырыш, мәҗлес.
[12] *Тамм* — тулы.
[13] *Бөйлә* — шундый.
[14] *Иштирәк итәргә* — катнашырга.

Чәемне эчеп бетердем. Ул арада аркадашларымнан берсе килеп әйтте, кайтамыз, диде. Һәм күренә ки, кешеләр киткәли башлаган иде. Ханә сахибәсе илән һәрберемез аерым күреште. Ханә хуҗасы үзенең көтебханәсене вә эш кабинетыны күрсәтте, бераз беренче палатаның тәнзыймәтене[1] күрсәтте, буннан соң күрешеп кайтып киттек.

Бу кадәр сөйләшүләр, күрешүләр, бу кадәр төрле тәэсирләрдән соң бик арыган идек. Мин бу көн бер җиргә дә бармадым. Теләгән кешеләргә ике җирдә акшам тәгаменә дәгъвәт бар иде. Бәгъзы аркадашлар илән төшкән миһманханәмездә генә йимәк йидек тә, ятарга уйладык. Ләкин тиз генә яту мөмкин булмады.

Бер такым гәзитәчеләр төрлемезне төрле яктан сөальләр илән кумәләр иде. Сәгать тугызларда ашка киткән кешеләремез һәм кайтты. Болар кайткач, һәрберемезне мөдәббирләр[2] безгә махсус куелган салонга җыеп, иртәгесен күрәчәк нәрсәләрне вә булачак мәҗлесләрне аңлаттылар. Нә вакыт кайда җыелу лязем булачагыны белдерделәр. Соңра булмәләремезгә чикелдек. Бүлмәләремез матур, уңгайлы, җайлы, караватларымыз ял итү өчен муафикъ иде.

*(Ахыры киләсе санда)*

[1] *Тәнзыймәт* — тәртип рәвеше.
[2] *Мөдәббир* — эш башкаручы, администратор.

# КОЯШЛЫ ТАУГА КҮТӘРЕЛҮ

## «Бүкән» янында сөйләшү



*Сынчы Фәһим Фәсхетдинов үзе иҗат иткән сыннар арасында.*

Сынчы рәссам Фәһим Фәсхетдиновның остаханәсендә колачка сыймаслык бер мәһабәт имән (әллә нараттанмы соң?) Бүкән бар. Күпне күргән, күпне ишеткән, күпләрне «үз күзе» белән танып белгән тарихи бүкән ул. Тарихи дим, чөнки аның янына еш кына атаклы шәхесләр — Фәһимнең дуслары — рәссамнар, сәнгать белгечләре, галимнәр, язучылар, артистлар һәм, гомумән, остаханә хуҗасын якын иткән кешеләр түгәрәкләнеп җыелып утыралар да эч серләрен сөйлиләр. Сүз, әлбәттә, тормыш-яшәешнең асыл мәгънәсе, әдәбият-сәнгать яңалыклары хакында бара. Кыскасы, әлеге Бүкән — эчкерсез әңгәмәләрнең, кызу-кызу бәхәсләрнең дә, аһ-зарларның да шаһиты ул. Шуңа да аның бу язмага үзәк «персонажлар»ның берсе булып кереп китүе гаҗәп тоелмасын.

Шулай бервакыт, Бүкән янында җай гына гәп корып утырганда, арадан берәү:

— Иҗат кешесе ялгызы гына тау түбәсенә күтәрелүче альпинистны хәтерләтә,— дип әйтеп куйган иде.

Без — бүкәндәшләр — сагаеп калдык: йә, ни өчен ялгыз альпинист, көттермә, тел төбеңдә ни ятканын аңлатып бир, янәсе.

Әңгәмәдәшебез сүзен болайрак дәвам итте:

— Шуңа ялгыз альпинист дим, Иҗат күмәкләшеп тауга күтәрелүне күтәрә алмый. Бу мөмкин түгел. Безнең кыска гына гомердә дә моңа мисаллар күп булды инде. Бер бәйдәгеләр, иртәме-соңмы, күр дә тор, киеренке ситуация тудымы, страховкасын өзә дә кача. Ә ялгыз альпинист исә нинди тауга күтәреләчәген дә, маршрутын да, кирәк-ярагын да үзе сайлый, үзе хәл итә. Кыскасы, Иҗат — индивидуаль хезмәт ул. Ә инде нинди биеклектәге Тауга күтәрелә аласың, монысы талант һәм бәхет эше. Миңа ышанмасагыз, әнә, Фәһимнән сорап карагыз.

Фәһим — ялгыз альпинист?! Үзен сырып алган дус-ишләре булыптамы?

Бу чагыштыруның хаклыгына мин Фәһимнең тормыш юлы һәм иҗаты белән тирәннәнрәк танышкач төшенеп җиттем кебек. Чөнки Фәһим Фәсхетдинов, нәкъ менә берьялгызы озын һәм хәвефле сәфәргә кузгалган альпинист кебек, һичбер тормыш ваклыкларына бирешмичә, михнәт-авырлыкларга баш имичә түбәннән, авыл клубында рәссам булудан башланган хезмәт юлын дәвам итеп, үр артыннан үрләр, үткел артыннан үткелләр яулаган, хәзер инде сынлы сәнгатьнең «Альп болынлыклары» итәгенә күтәрелеп җиткән шәхес. Әйе, ул «таулар»ны түбәннән күтәрелеп яулады. Фидакарь хезмәте белән. Чын альпинистларча.

Бүкән янында журналист һәм язучы **Эльс Гаделнең** Фәһим иҗатына багышланган бер язмасын укып чыккач, хәтердә мондыйрак юллар уелып калган.

Озынрак булса да, автор рөхсәте белән, шуннан бер өзек китереп үтәсем килә. Чөнки биредә, безнеңчә, Фәһимнең холык-фигыле бик тә ачык чагыла кебек.

— Миңа Фәһим белән бу Бүкән артында бик күп тапкырлар киңәш-табыш итешеп утырырга насыйп булды. «Исемдә калганнар»дан бер-ике генә хатирәгә тукталып үтим әле. «Сәнгатькә юлың кайдан башланды»,— дигәч: «Озынрак һәм әйләнчегрәк юл булды шул ул»,— дип искә ала Фәһим. Мәгълүм булганча, булачак сынчы 1944 елда Апас районының Аюкөйдергән авылында туа. Шулай, язмыштан узмыш юк ди, һөнәр училищесын тәмамлап, авылга кайткач, аны тракторга утырталар. Уттай урак өсте. Көннәрдән бер көнне, «Сталинец» комбайнын тарттырып йөргән вакытта, тракторы Аюкөйдергән елгасына батып эштән чыккач, «синнән механизатор чыкмас, ахры, клубта эшләп кара әле» дип, мөдир итеп куялар. Хрущев вакыты, коммунизмга барып житәргә 20 генә ел калып бара. Жан башына йомырка-йон житештерү буенча АКШны куып житеп, узып китәбез дип, Фәһим авылдагы бөтен телеграф баганаларын, иске калай кисәкләренә язып, плакатлар белән тутыра.

Армия хәлләре үзе бер кыйссага тиң. Танк батальонында Фәһим — тупчы һәм Ленин бүлмәсендә бизәүче-рәссам. Беренче көннәрне үк, дневальный швабра белән Ильич башын сугып төшергәч, тегене каталажкага озаталар, ә Фәһимгә приказ — бер тәүлек эчендә Ленин бюстын жыеп-ямап куярга! Шулай итеп, авыл малае гомерендә беренче тапкыр скульптура һәм гипс белән таныша.

Хезмәте бетеп килгәндә генә, төннәрнең берендә 22 танк янып киткәч, командирларны рәшәткәле машинага утыртып алып китәләр, «старик»ларны янган танклар белән бергә танк ремонтлый торган заводка төяп жибәрәләр. Шул заводта Фәһим тимердән кою серләренә төшенә.

Армиядән кайткач, күп жирләрдә каңгырып йөргәннән соң, энекәше Фаризны ияртә дә, Алабуга мәдәният-мәгърифәт училищесына юл тота. Аннары ул — Апас каласының «баш рәссамы». Шунда колхоздан колхозга йөреп, урам-клубларны бизәп яткан көннәрнең берендә Казаннан килгән скульпторлар белән таныша бу: тегеләр сугышта һәлак булганнарга таштан һәйкәл куярга тиешләр икән.

«Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, Фәһим моны Алла бүләге дип кабул итә. Асылда бит әле



*Фәһим кызы Луиза белән.*

аның бер генә профессиональ сынчы белән дә танышканы булмый, ә күңел шул дөньяга тартыла.

Һәм Фәһим «коллегаларын» инде үзе бизәп бетереп килә торган мәдәният сараена «кунакка» чакыра. Эшләве дә, яшәве дә дигәндәй, шушында Фәһимнең бу көннәрдә: әнә, почмакта караваты, әнә, электр плитәсе өстендә чәйнеге, ятагында рәсемнәр, эскиз-планшетлары аунап ята. Ә сәхнәдә яшел сукнолы «президиум» өстәлендә бүген кунаклар өчен бәйрәм табыны әзерләнеп куелган. Үзенең эшләре белән кунакларны таныштырып чыккач, Фәһим аларны шунда чакыра.

— Йәгез әле,— ди Фәһим,— почетлы каравыл астында гына бер сөйләшеп утырыйк әле. Әнә, уң ягыбыздан безгә Владимир Ильич, сул ягыбыздан Леонид Ильич карап тора. Мәҗлесебез түгәрәк шикелле...

— Ә болар безгә карамыйлар ич, читкә борылганнар, әнә, залга карыйлар, алар халык белән,— дип, бер кунак шунда хихылдап куя.



*Луиза Фәсхетдинова иҗат иткән укалы түбәтәй.*

— Ә без аларны үзебезгә барыбер каратабыз,— ди Фәһим.— Үзебез ясадык, үзебезгә барыбер каратабыз аларны,— ди дә, көлеш эчендә сәхнәнең ике канатындагы ике бюстны өстәлгә таба борып куя.

— Тормышта да шулай гына борылсаң иде ул. Торсыннар әйдә торганча,— дип кушылып китә өлкән скульптор.— Алар күзгә карап торганда, нишләптер, тамактан ризык узмый, оялта... Куй, Фәһим, урыннарына. Кстати, кем эше алар?

— Үземнеке инде...

— Чынлапмы? Карале, малай... дип сузып куя кунак.— Яхшы гына эшләр бит болар! Нишләп син монда ятасың әле болай? Әйдә, энекәш, Казанга кил син. Ятма монда. Сәнгать фондына үзем эшкә урнаштырам. Сиңа тирәнрәк чумарга вакыт җиткән. Авыл крәстиянгә калсын. Осталар белән аралашу, тәҗрибә, белем туплау кирәк сиңа. Зур сәнгать ипиен авыз итеп кара әле бер. Аннан үзеңә карарсың...

Ә «зур сәнгать ипиен бер авыз итеп караган» кеше, көнкүрмешендә ачлы-туклы яшәсә яшәр, сайлап алган язмышыннан ваз кичмәс. Фәһим исә шундый фидакарьләрнең берсе. Менә иҗат биографиясеннән кайбер сәхифәләр.

Шулай итеп, 1973 елдан Сәнгать фондының Татарстан иҗади-производство комбинатында эшли башлый. Һәм 1974 елдан башлап Бөтенсоюз, республика, «Зур Идел» зональ күргәзмәләрендә катнаша. 1979 елда плакатчы рәссамнарның Бөтенсоюз конкурсы лауреаты. 1980 елда аның «эшләре» Совет — Польша хезмәттәшлеге уңае белән үткәрелгән конкурста катнаша. 1980 һәм 1994 елларда Казан шәһәрендә аның шәхси күргәзмәләре үткәрелде.

Остаңың осталыгын кимсетү булып яңгырамасын берүк, ләкин Фәһим әйбәт мәгънәдә «эш аты» (эше юкның ашы юк, ләбаса). Фондта 25 елга якын эшләү дәверендә ул республиканың төрле шәһәр-авылларында театр һәм башка биналарының интерьерларын бизәде. Болары, кем әйтмешли, эш арасында эшләнгән эшләр. Асылда ул үзенең иман-кыйбласыннан тайпылмады, бер-бер артлы киртләч-киртләч кыяларны үтә-үтә яңа иҗади биеклекләргә үрмәләде. Тарихилык — бу илаһи кичереш аның җанында һәрдаим сулкылдап торды. Ул Г. Тукай, М. Җәлил, Һ. Такташ, Ф. Кәрим кебек олуг шәхесләребезнең скульптур портретларын иҗат итте һәм, ниһаять, 1994 елның 15 ноябре килеп җитте.

Республика милли китапханәсенең фойе-заллары, баскыч-коридорлары халык белән шыгрым тулы. Җанлылык. Хәрәкәт. Рухи күтәренкелек. Бүген бирергә рәссамның китапханә диварларына куелган сыннарын тәкъдир итү бара. Тарихи мизгел...

Беренче сүз, әлбәттә, татарның төп «китапчысы» академик **Әбрар Кәримуллинга бирелә.**

— Китапка мәдхия бит бу, егетләр,— дип башлый ул сүзен, гадәтенчә, җан кайнарлыгы белән.— Аңлыйсызмы сез моның тарихи әһәмиятен. Элек

без Кол Галинең дә, Сәйф Сараиның да, Курсавиның да төс-кыяфәтләрен күз алдына китерә алмый идек. Фәһим Фәсхетдинов татар әдәбияты вәкилләренең галереясын булдырган, ләбаса. Минем Молдавиядә булганым бар. Кишинев шәһәренең иң гүзәл бакчасында борынгыдан алып бүгенгә кадәр яшәгән әдипләрнең сыннары тора. Гаҗәп бит... Кешеләр бу сыннар яныннан ничектер бер инсафлык һәм горурлык белән үтеп китәләр. Алла боерса, безнең шәхесләребезнең галереясы да китапханәләрдән урам, бакчаларга чыгар әле. Рәхмәт сиңа, Фәһим туган! Рәхмәт сиңа да, Разил Вәлиев әфәнде!

**Шамил Закиров**, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия драма театры директоры:

— Ташкентта, урамда, бөек үзбәк артистларының сыннар галереясы бер. Ышанам, Фәһим, татар театры каршындагы мәйдан да буш тормас.

**Фәрит Якупов**, рәссам:

— Бу — фидакарьлек! Ни өчен дигәндә, борынгы бабаларыбызның төс-кыяфәтләре сакланмаганлыгы һәркемгә мәгълүм, ә Фәһимнең сыннары ышандыра. Алар нәкъ менә шулай булгандыр кебек тоела. Тоем — сәнгатьтә зур нәрсә шул ул. Шушы уңайдан минем бер-ике тарихи чагыштыру китереп үтәсем килә. Беренчесе. Илья Репинның Иван Грозныйга багышланган картинасы бар бит әле. Атаклы антрополог Герасимов Явыз Иванның баш сөяген тикшереп караганнан соң, шундый нәтиҗәгә килә: әйе, ди ул, картинадагы Иван тормышта да нәкъ шулай булган. Икенчесе. Әллә кайда ерак китәсе юк. Юбилей уңае белән рәссам Байназар Әльменовка Каюм Насыйриның портретын язарга әмер бирәләр. Яза рәссам һәм әдипне исән чагында күреп белгән кешеләргә портретын күрсәтә, тегеләр исә: әйе, нәкъ үзе, диләр. Шуның кебек, Фәһимнең сыннарын карагач та: нәкъ үзләре кебек, дип әйтәсе килә. Ләкин бу әле башы гына, минемчә.

Нинди сыннар соң алар? Һәм сәнгати яктан нинди әһәмияткә ия булып торалар. Гомумән, Фәһим Фәсхетдиновның иҗаты кай ягы белән үзенчәлекле. Әйдәгез, шушындый сорауга җавап эзләп, сәнгать белгече **Розалина Шаһиевага** сүз бирик.

— Бу иҗат — хакимият диварларында шытып чыккан рәсми тенденцияләрне яки агымнарны гәүдәләндергән иҗат түгел. Фәһим тудырган милли пластика — рельефлар, бюстлар, тулай сыннар, балчыктан әвәләнеп эшләнгән садә-нәфис савыт-сабалар, һәммәсе дә, борын-борыннан килгән мөселман сәнгатенең дәвамы. Аларда сабырлык һәм тын илаһият, иман вә инсафлык бар; рухи биеклекләргә ашу, камиллеккә омтылу кебек эчке әсәрләнүләр тышкы яктан саран, тотнаклы чаралар аша гамәлгә җиткерелгәннәр. Сүз, аңлашылгандыр, сынчы тудырган татар мәдәнияте һәм фикри каһарманнарының асыл тезмәсе турында бара. Бу галерея эч пошудан, яисә нindидер формаль максатларны күздә тотып, тарихи иллюстративлыкка омтылудан туган хезмәт түгел. Рәссамның йөрәгендә Бакый ага Урманче колачлылыгы, аның киң сулышы, куәт-җегәре, тарихи киң күңеллеге төсмерләнә.

Сүз дә юк, олуг затларның сыннарын тергезү иҗаткяр остаңын изге нияте — борынгыны барлау, андагы көрәш, мәдәният, мәгърифәтчелек орлыкларын җыеп, бүгенге уңдырышлы туфракка күчереп утырту нәтиҗәсендә пәйда булганнар. Ягъни татарның акыл бакчасы гөрләп торсын, тәрәккый итсен, аның нигезе, тамыры корымасын...

Дөрес, мондый асыл затларның сурәтләрен торгызу юнәлешендә узган чор рәссам, сынчылары күч куеп карамады түгел. Ләкин алар еш кына Тукай, Җәлил, Такташ, Мәрҗани, Насыйри исемнәре тирәсендә генә бөтерелеп, анда да бары тик үзләре яшәп килгән чор, система һәм идеология ихтыяҗларыннан чыгып кына эш иттеләр, нәтиҗәдә «геройлар»ның четерекле күләмлелеген, фәрден, моңын һәм каршылыклы эчке дөньяларын, бергәләшү-өзгәләнүләрен, фаҗигаләрен ачып бирә алмадылар. Курыктылар... Фәһим академияләр дә бетермәгән, ләкин ул үз табигатеннән, рухыннан чыгып эш итә. Ул — бозылмаган, азмаган, шайтанга сатылмаган. Аның рухы — милли, иманы — камил! Шунлыктан ул татар әдипләренең рухын барлык вөҗүде белән тоя алган, аларны җанлы итеп гәүдәләндергән.

Гади генә соры тактага беркетелгән сыек-зәңгәрсу, ком төсле, фил сөяге төсендәге рельефлар, бюстлар үзләренең композицион элементлары — алга чыгып торган якалары, күл-әгъзалары, чәч-түбәтәйләре ярдәмендә тирәлеккә бәйләнгәннәр. Әйтерсең лә аларга тарих җиле кагылган, хәрәкәтчәнлек биргән.

Моннан күп еллар элек Янарыш чоры сынчысы һәм дивар бизәүчесе Микеланджело Ватикан бинасының түшәменә Инҗил эчтәлегенә караган фрескалар иҗат иткән. Шуларның берсе Саваоф-демург атабыз Адәмгә җан са-

ла... Фресканың фоторепродукциясенә генә игътибар итсәң дә шуны тоясың: әнә, битараф халәттәге ир затының гәүдәсендә ниндидер хәрәкәтчәнлек билгеләре, чатнау-ярылу сызыклары пәйда була... Әнә, әгъзалар бер-береннән аерылып, кан тамырлары ярылып чыга... Менә ул хәзер торып басар да тәпиләп китәр сыман...

Фәһимнең әһелләре дә шулай: «җан керә башлаган», тоташ җанлы массив итеп сурәтләнгәннәр. Калкулы башлар, өмет тулы киереп ачылган күзләр ничектер дивардан алга, тирәлеккә ыргылган гәүдәләр җан кергән тарих, милли-драматик эпос булып күзалланалар. Әллә соң бу инкыйразга каршы протестмы?.. Әллә башы-аягы киселгән милләтнең, тереклек суы эчеп, бербөтен булып оешуымы?

Әйе, Фәһим татар җанлы, авыр тормыш юлы үтеп, үз-үзен тәрбияләгән, рәссам итеп үстергән корычтай ир-егет. Аның карашлары киң. Белеме — тирән. Моңы, җыры бар. Шушы сыйфатлар аны, югары сәнгати профессиональ белем алмый торып та, рәссам итеп танытты. Әйткәнебезчә, иҗатында Урманче эзләре ярылып ята. Димәк, рухы көчле. «Мәктәп» (школа) дөньяга карашка бәйле нәрсә ул. Бу — түбәнрәк баскыч. Иҗаткяр өчен рух, күңел беренчел. Фәһим исә бу сыйфатка ия зат.



*Калфак: «Ай-йолдыз».*

Фәһимнең утташ (шамот) материалыннан ясалган әсәрләрен минем мәчет-мәдрәсә эчләрендә милли мәдәният әһрамнарында, зур-зур китапханә диварларында күпләп күз алдыма китерәсем килә. Чөнки алар бу биналарның алмаз терәге булырлык.

Керамикасы — бармак эзләрен, җил улауларын, башак чайкалуларын сеңдергән... Табигать белән берләшкән мәҗүсилек бар аларда. Архаик сыйфатлар ярылып ята. Орнаменты — соклану һәм ихтирам уята. Шәкеле буенча гади татар йортындагы табаларны, тәлинкә-касәләрне хәтерләтә. Җылылык бар. Татар сәнгатендә яңа агым бу.

Алма агачыннан ерак төшми, диләр.

Бу сүзләрне Фәһим Фәсхетдинов гаиләсенә карата да кулланып булыр иде. Аның күз алмасыдай кадерле, чая кызы Луиза да сәнгать юлын сайлады: ул татар халкының борын-борыннан килеп тә соңгы дәвердә онытылып бара торган милли традициясен тергезде — Луиза бәрхет җирлектә ука белән чигү чигә. Аның турында еш кына: «Татар сәнгатенең алтын киләчәге»,— диләр. Бу сүзләрдә символик мәгънә бар. Беренчедән, бу Луизаның алтын җепләр белән чигү чигүенә ишарә булып яңгыраса, икенчедән, Луиза чын мәгънәсендә алтын куллы сәнгать остасы. Эшләре шул хакта сөйли.

Луиза 1988 елда Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый. 1991 елда исә Бохара шәһәренең Ука белән чигү фабрикасында эшләп тәҗрибә туплый: ул әлеге һөнәрнең классик үрнәкләре белән таныша һәм дистәләгән чигү технологиясен үзләштерә. Һәм Казанга кайткач, «җиң сызганып» эшкә тотына. Ул чиккән калфаклар, түбәтәйләр, шамаилләр, намазлыклар, гомумән, халык чигү промысыле үрнәкләре күз явын алырлык нәзакатьлелек һәм осталык белән иҗат ителгәннәр. Әйе, нәкъ менә иҗат ителгәннәр, чөнки алар иш-үрнәкләре булмаган сәнгать әсәрләре булып торалар. Луиза чиккән көнкүреш әйберләре Төркия, Венгрия, Алмания илләрендә үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә катнашып, югары бәя алдылар. Ул чиккән түбәтәй, калфаклар менә шул рәвешле татар халкының илчесе сыйфатында дөнья буйлап сәяхәт итеп йөри башлады. Әйе, чын сәнгать әсәре географик чикләрне белми, ул гомумкешелек тудырган байлыкка әверелә.

Менә шулай, Фәһим белән Луиза Фәсхетдиновлар — ата белән кыз — халык рухы белән сугарылган хәзинәне иңнәренә салып, һәрберсе үз юлыннан кояш нурлары яктырткан тауга күтәрелеп баралар.

**Наис ГАМБӘР.**

## ХӘТЕР КӨНЕ

15 октябрьдә Казан, Чаллы, Алабуга һ. б. шәһәрләрдә, республикабыз авылларында, татарлар яши торган байтак кына төбәкләрдә «Хәтер көне» (күмәк-оешкан төстә инде алтынчы мәртәбә) дистә меңләгән милләттәшләребез катнашында билгеләп үтелде. Мәктәпләрдә һәм гимназияләрдә, әлеге көнгә багышлап, махсус дәресләр үткәрелде. Татарстан милли китапханәсендә шул дәһшәтле чорны яктыртучы китаплардан һәм рәсемнәрдән торган күргәзмә ачылды. 1552 елда Казанны Явыз Иван гаскәрләреннән саклаганда һәлак булган шәһитләр рухына багышлап, мәчетләрдә һәм Сөембикә манарасы янында намаз-дога укылды.

Аннары Хәтер көне уңаеннан Казан Кремлендә уздырылган халык җыены карары игълан ителде. Әлеге карарда Кремльне реставрацияләгәндә аны XVI гасырның беренче яртысында булган хәленә кайтару, моннан 443 ел элек Казанны саклап, яу кырында шәһит киткәннәргә һәйкәл куюны тизләтү, Колшәриф мәчетен яңадан торгызу кирәклеге басым ясап әйтелә.

## УФАДА ТАНТАНА

10—11 октябрь көннәрендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев житәкчелегендәге делегация Башкортстан Республикасында Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүнең биш еллыгына багышланган тантаналарда катнашты.

Җөмһүриятебез Илбашы Башкортстан Республикасы Президенты М. Рәхимов белән бергә, Дуслык аллеясына агач утыртты. Бер үк вакытта ул бәйрәм тамашаларын карарга да, Уфадагы кайбер предприятиеләр эшчәнлеге белән танышырга да өлгерде.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ — ТАТАР МИЛЛИ УНИВЕРСИТЕТЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 11—12 октябрь көннәрендә булган дүртенче пленар сессиясендә, ниһаять, «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасының Татарстан дәүләт милли университетын булдыруга кагылышлы өлешен үтәүнең барышы турында»гы мәсьәлә тикшерелде. Аның буенча ТР вице-премьеры И. Хәйруллин чыгыш ясады. Депутатлардан Ф. Шәймәрданов, Ф. Сафиуллин, Р. Мөхәммәдиев һ. б. бу проблемага карата үз фикерләрен белдерделәр. ТР Министрлар Кабинеты алдына Казан дәүләт университеты каршында Татар гуманитар институтын булдыру эшенә керешү һәм аны киләчәктә мөстәкыйль югары уку йорты — Татар дәүләт милли университеты итү бурычы куелды.

## АЗНАКАЙДА — ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

18—21 октябрьдә җөмһүриятебезнең Азнакай районында «Татар әдәбияты көннәре» үткәрелде. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев житәкчелегендә Казаннан килгән бер төркем каләм ияләре (алар арасында Г. Ахунов, Ш. Галиев, Т. Миннуллин, Р. Фәйзуллин, Г. Зәйнашева, Ф. Гыйззәтуллина, М. Маликова, Ф. Галимуллин, М. Галиев, З. Мансуров, Ф. Зөлкәрнәй, Н. Гыйматдинова, З. Хөснияр, Хәйдәр, Р. Әймәт һ. б. бар иде), Әлмәт һәм Азнакай төбәгендә иҗат итүче язучылар (И. Гыйләҗев, Н. Әхмәдиев, Р. Вәлиуллин, Ф. Исмәгыйлова, С. Вильданова һ. б.) белән берлектә, районның төрле предприятие-оешмаларында, мәктәп-гимназияләрендә, мәдәният сарайларында онытылмаслык очрашулар үткәрделәр. Әсәй, Уразай, Тымытык, Урманай, Әлкәй авылларында яшәүче әдәбият сөючеләр, игенче-терлекчеләр, мөгаллимнәр, мәктәп укучылары да язучылар белән аралашудан бик канәгать калдылар.

## ЖУРНАЛИСТЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

18 октябрьдә Казанда — Пресса йортында — Татарстан Республикасы Журналистлар берлегенең киңәйтелгән пленумы булды. Анда республика күләмендәге газета-журналларның баш мөхәррирләре, радио-телевидение житәкчеләре һәм Казан дәүләт университетының журналистика, социология һәм психология факультеты галимнәре катнашты. Доклад белән ТР Журналистлар берлеге идарәсе рәисе — «Молодежь Татарстана» газетасының баш мөхәррире Р. Ратникова чыкты.

Пленум Татарстан Журналистлар берлеге идарәсе Президиумының ТР Журналистлар берлегенең Россия Журналистлар берлеге белән — тигез хокуклы буларак һәм вәкаләтләрне тиешле бүлү шартларында — берләшү турындагы карарын бертавыштан яклады. Бу — устав бурычларын тормышка ашыру өчен кирәк. ТР Журналистлар берлегенең «Татарстан Республикасының атказанган журналисты» дигән мактаулы исем һәм Матбугат көне булдыру турындагы инициативасы яхшы дип табылды. Матбугат көнен исә ел саен 19 майда бәйрәм итү тәкъдим ителде (1902 елда бу көнне беренче татар газетасы һәм 1911 елда рус газетасы чыккан).

## ИҖАТ БӘЙРӘМНӘРЕ

9 октябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык язучысы, җәмәгать эшлеклесе Гариф ага Ахуновның 70 яшьлек юбилеена багышланган зур тантана булды. Юбилярны котларга республикабыз җәмәгатьчелеге, Казан халкы, арчалы якташлары, шулай ук башка төбәкләрдән дә бихисап кунаклар килде. Иң әүвәл Гариф аганы Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев шәхсән кайнар тәбрикләде һәм, җөмһүриятебез халкы исеменнән дә кайнар рәхмәт белдереп, аңа Мактау грамотасы һәм истәлекле бүләк тапшырды. Башкортстанның халык шагыйре М. Кәрим, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, «Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Р. Галиев һ. б. бик күпләр юбилярга һәм аның хәләл җефете— язучы Шәһидә ханымга үзләренең иң җылы сүзләрен җиткерделәр.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев исә Гариф агага, «Идел кызы» романы һәм соңгы еллардагы публицистик эшчәнлеге өчен, Гаяз Исхакый исемендәге премияне тапшырды. Аннары юбилярның әсәрләре файдаланып төзелгән әдәби-музыкаль тамаша булды.

10 октябрьдә Г. Ахуновның якын каләмдәшләре һәм килгән кунаклар аның туган ягында үткән иҗат бәйрәмендә катнаштылар.

* * *

Танылган татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе, Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыяте президенты, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Мәдинә ханым Маликовага 60 яшь тулу уңаеннан, Татарстан Язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында хөрмәтләү кичәсе үткәрелде. Кичәне танылган галим-язучы һәм диктор Фоат Галимуллин алып барды. Юбилярны иң элек туган ягыннан килгән кунаклар — Сарман районы хакимияте вәкилләре, каләмдәшләре, җырчылар, артистлар котлады.

## ТУКАЙДА КУНАКТА

Башкалабызның Г. Тукай музеенда «Казан утлары» журналы һәм «Мәдәни җомга» газетасы хезмәткәрләре Укытучыларның белемен күтәрү институтында укып йөрүче мәктәп директорлары һәм Казандагы мәктәп-гимназияләрнең укучылары белән очраштылар. Әлеге очрашуны «Казан утлары»ның бүлек мөхәррире — язучы Т. Әйди һәм «Мәдәни җомга»ның баш мөхәррире урынбасары — шагыйрь Г. Морат алып барды. Анда шулай ук шагыйрьләрдән «Казан утлары»ның даими авторлары М. Әгъләм, Н. Акмал, язучы Ф. Яхин, танылган баянчы һәм композитор М. Макаров, татарларга кагылышлы чыганакларны өйрәнүче Кытай галиме, профессор Г. Гыйләҗетдин әфәнде дә чыгыш ясады.

## ТАТАРСТАН СӘНГАТЕ ИЛЧЕЛӘРЕ — ГЫЙРАКТА

Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, махсус чакыру буенча, Гыйракта, VII Халыкара Вавилон сәнгать фестивалендә (22 сентябрь — 6 октябрь) булып кайтты. Унбишәр мең тамашачы сыйдырышлы амфитеатрларда уңышлы чыгышлар ясап, Татарстан сәнгате илчеләре, бик күпләрнең күңелләрен яулап алдылар.

Хәзер ансамбль «Төрки дөнья» дип исемләнгән тамашада катнашу өчен Төркиягә җыена.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘЛӘРЕ

Заманыбызның мәшһүр композиторы, җырчы Сара ханым Садыйкованы халык онытмый. 13 октябрьдә Казанның Татарстан урамындагы 13 йортка, аның якты истәлеген мәңгеләштереп, мемориаль такта куелды. 27 октябрьдә «Мәдәни җомга» газетасы һәм С. Садыйкованың хәйрия фонды аның быелгы беренче мәҗлес-табынын оештырды. Бирегә Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе Х. Низамов, Татарстанның халык артистлары — җырчы Р. Билалова, нәфис сүз остасы А. Арсланов, танылган шагыйрьләрдән Ә. Баян, Г. Зәйнашева, Р. Фәйзуллин, Л. Шагыйрьҗан, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире З. Мансуров, галим-язучы Н. Хисамов, Уфадан күренекле шагыйрь Ш. Бикколның хатыны Рәйсә ханым, композиторның якын дусты Р. Исмәгыйлов, хәйрия фонды җитәкчесе Ә. Хөсәенов һ. б. килгән иде.

1 ноябрьдә исә — С. Садыйкованың туган көнендә — аның татар зиратындагы изге каберенә тере чәчәк бәйләмнәре салынды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** сынчы Ф. Фәсхетдинов эше: «Сәйф Сараи».

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы һәм публицист Т. Әйди.

Д. БУНТУКОВ фотосурәтләре.

# ЯҢА КИТАПЛАР

РАВИЛ ФАХРУТДИНОВ. **История татарского народа и Татарстана.** Рус телендә. Казан: «Мәгариф» нәшр., 1995, 256 б. Тиражы — 55 500 данә.




Татар тарихын объектив яктырту юнәлешендә яңа типтагы дәреслек бу. Ул гомуммәктәпләрдә, гимназияләрдә, лицейларда укыту әсбабы итеп чыгарылган. Элегрәк чыккан дәреслекләрдә халкыбыз тарихы, нигездә, бүгенге Татарстан территориясендә булып үткән вакыйгаларга гына таянып язылa иде. Бигрәк тә урта гасыр, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары өстән-өстән генә, анда да рәсми Мәскәү күзлеге аша яктыртыла иде. Халкыбызның күпгасырлы дәүләтчелек чорлары «онытыла» иде. Бу «ак таплар» әлеге дәреслектә шактый ук бетерелеп, чын тарихыбыз ышанычлы чыганаклар, төпле дәлилләр белән бәян ителә. Китап-дәреслек ахырында хронологик таблица, һәм шулай ук, татар тарихына караган фәнни китаплар исемлеге бирелгән. Бүлектәге материаллар төсле һәм график рәсемнәр белән бизәлгән.

Гомумән, бу дәреслек тарихыбыз белән кызыксынган һәркем өчен файдалы һәм гыйбрәтле.

**Татар тарихы: онытылмас сәхифәләр.** Төзүчеләре С. Х. Алишев, Р. У. Әмирханов, Ә. Н. Хәйруллин; С. Х. Алишев редакциясендә.— Казан: «Мәгариф», 1994 ел, 254 бит. Тиражы — 20 мең данә.




Күренекле тарихчыларыбыз Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин, Әхмәд-Зәки Вәлиди хезмәтләренең аерым өлешләреннән бу җыентык татар халкы тарихының борынгыдан башлап XIX йөзгә кадәрге чорын үз эченә ала. Укучыны халкыбыз тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәте, дине, әдәп һәм әхлагына караган кыйммәтле чыганаклар белән таныштыра.

Мәктәп, гимназия, лицей, колледж укучыларына, студентлар һәм укытучыларга атап чыгарылса да, әлеге китап татар тарихы белән кызыксынган һәркем өчен кызыклы һәм файдалы булыр.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог